# НУРИХАН ФАТТАХ

## ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

В ПЯТИ ТОМАХ

**4**

**ТОМ**

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2002

# НУРИХАН ФӘТТАХ

## САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

БИШ ТОМДА

## 4

## ТОМ

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2002

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Ф96

***Редколлегия:***

*З.Р.Вәлиева, Р.М.Миңнуллин, Ф.Г.Галимуллин,
Т.А.Миңнуллин, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Р.Х.Корбанов*

**Фәттах Нурихан**

Ф96 Сайланма әсәрләр. — 5 томда, 4 том. — Казан: Татар. кит.нәшр., 2002. — 463 б.

ISBN 5-298-01200-7 © Татарстан китап нәшрияты, 2002



## Олы әдип «кичү»е

Соңгы елларда укучыга барып ирешкән «Кичү» исемле романында Нурихан Фәттах сугыштан соңгы еллар тормышы белән бәйләнешле бик җитди мәсьәләләрне күтәрә. Әсәрдә тоталитар системага корылган гаделсез җәмгыятьтә чәчәк аткан әхлаксызлык, икейөзлелек, караклык, хәерчелек күренешләре ачып салына, ачы тәнкыйть ителә. Әдипнең балалык, яшьлек елларының да нәкъ шушы чорга туры килүе һәм аның әсәрне үз күргәннәренә, шәхси кичерешләренә таянып язуы эпизодларның тормышчан дөреслеген тагын да көчәйтә.

«Кичү» романының дөньяга килү тарихы да катлаулы. Әсәрнең язылу еллары 1956—1962 һәм 1988—1990 дип куелган. Китапка «Сүз башы»нда автор болай ди: «...роман-эпопея кимендә дүрт кисәктән торырга һәм сугыштан соңгы еллардагы татар тормышын чагылдырырга тиеш иде. Мин тормышны әз генә бозмыйча, бизәмичә күрсәтергә, һәрнәрсәдә, аеруча халык тормышын һәм милли мөнәсәбәтләрне тасвирлаганда дөреслекне ярып салырга тиеш идем.

Роман баштарак «Таяныч» дип, соңга таба беркадәр китапчарак «Хыял вә хәят» дип аталды. Әлеге исемнәрдән күренеп торганча, өстебезгә бик авыр йөк алмакчы идек без. Ләкин нихәл итмәк кирәк, чынбарлык хәтта хыялдан да көчлерәк булып чыкты. «Хыял вә хәят»не 1963 елга кадәр яздым да, ары дәвам итәргә куәтем җитмичә тукталып калдым. Ул елларда бар нәрсәне буып торган милли террор һәм рәхимсез мохтаҗлык әсәремне тиешенчә өчлап чыгарга ирек бирмәде дисәм, мондый сүзләр хәзер аклану булып аңлашылмас дип уйлыйм. Чөнки дөресе шулай».

Романдагы вакыйгалар Башкортстанның Яңавыл дигән җирендә барса да, аларны күп татар авылларында сугыш беткән елларда булып үткән вакыйгалар рәвешендә кабул итәсең. Әле генә урта мәктәпне тәмамлаган яшүсмер егет Габделхәй белән без аның киләчәккә зур өметләр баглап йөргән көннәрендә очрашабыз. Аның әйләнә-тирәсендә мәктәпне тәмамлап чыккан бер төркем яшьләр, мәктәпнең укытучылары коллективы... Гадиләр, әчкерсезләр, дәрәҗә саклап йөрүчеләр, хәйләкәрләр, икейөзлеләр, туклар һәм ачлар... Болар бөтенесе, романдагы вакыйгалар тормышка сабыйларча беркатлырак карый торган, саф, намуслы, чиста күңелле Габделхәй күзәтүләре, бәяләмәләре рәвешендә әсәрнең сюжетына үреп барыла.

Әсәр бер төркем яшүсмер егет-кызларның шау-гөр килеп, чыгарылыш кичәсенә әзерләнеп йөрүләре күренеше белән ачылып китә. Бу яшьләрне алда куанычлы хәбәрләр, шатлыклы көннәр көтә. Шатлыкларның беренчесе — урта белем турында өлгергәнлек аттестаты алу, икенчесе — классташлар, укытучылар белән җыйналып, чыгарылыш кичәсендә утыру, ә өченчесе — югары уку йортына керү. Яшьләрнең

куанычына аларның үзләре кебек үк саф, чиста язгы табигать тә кушыла.

Ләкин олы тормыш юлы, яшьләр көткәнчә, алай ук ал да гөл түгел икән. Әйләнә-тирәдәге дәрәҗәле абзыйларның исәпләре гел яхшыдан гына булып чыкмый. Шундыйларның берсе — хәрби эшкә катнашы булмаса да, һәрвакыт погонсыз китель белән хәрби фуражка киеп йөрүче мәктәп директоры Василий Михайлович (Вәсби Алдынский). Башыннан алып аягына кадәр формалист бу кеше, укытучы буларак әллә ни мактарлык эш кырмаса да, ни сәбәптәндер, директор буларак, бөтен районда, республикада яхшы исәптә йөри. Чөнки ул өстән төшерелгән күрсәтмәләрне бернинди каршылыксыз үтәп, район җитәкчеләренең күңелләрен күрә, ә үзенә буйсынучыларны кулында кысып тота белә. Мәктәп эшләрен дә ул бик оста оештыра. Әнә чыгарылыш кичәсен нинди мул итеп үткәрә: таныш-белеш, дус-ишләре — берсе дә гади кеше түгел. Кайсы склад мөдире, кайсы колхоз рәисе, кайсы ит комбинатында бухгалтер.

Вәсби Алдынский — тоталитар режимга каршылыксыз яраклашкан кеше. Кайчандыр Габделхәйләр кебек ул да шигырьләр язгалаштырган, ләкин шигырьләре тәнкыйть ителгәч, бу эшне ташлаган һәм шуның аркасында үзенә янаган төрмә куркынычыннан котылып исәнимин калган. Тора-бара укытучылыгын да ташлаган ул: тимер юлга эшкә кереп, Яңавыл халкы черек бәрәңге ашаганда, ул «пух» итеп яшәгән. Дус-ишләр аркасындамы, авыру-сырхауга салышып йөргәнгәме — сугышка барудан да котылып калган. Ә хәзер аның төп максаты — бөтен ил күләмендә уздырыла торган «интернациональ процессны»— «национальный мәктәптән урысчага күчү»не оештыру: «...вапшем безне татар мәктәбе харап итә... безнең өчен иң дөрес юл — әкренләп татар мәктәпләрен урысчага күчерә бару... Нигә безгә артта калырга? Так вот, башка җирләрдә татар мәктәпләре бетә. Без кемнән ким?»

Вәсби Алдынский — Василий Михайлович — үзе күптәннән инде «урыс». Халык аның чын татарча исемен дә оныткан, сөйләшүе дә урыслашкан. «Бөек милләт вәкиле»— рус теле укытучысы Антонина Семеновна аның портреттагы дәрәҗәле кешенеке кебек итеп үстерергә тырышкан мыегын «бу мыегыгыз белән сез татар-монгол игосы заманнарындагы кысык күзле варварларны хәтерләтәсез»,— дигәч, анысын да кырып ташлый, шулай итеп, үзенең «татарлыгыннан» тулысынча котыла.

Әсәрдә аеруча кискен куелган мәсьәләләрнең берсе — тел һәм милләт язмышы. Хөкүмәтнең яңа «реформасы»н әсәрдәге геройлар курку катыш шомлану белән көтәләр. Чөнки бу реформа күп кешеләрне эшсез калдыра: татар бакчалары, мәктәпләре ябылу куркынычы астында. Габделхәй, Сәкинә кебек талантлы яшьләрнең үзләре теләгән һөнәрләре буенча югары уку йортларына керү юллары бикләнә. Әсәрдә урта мәктәпне бик яхшы билгеләренә генә тәмамлаган Габделхәйне, ул фәкать татар милләтеннән булганы өчен генә, алтын медальдән мәхрүм итүләре үзе бик күп нәрсә хакында сөйли түгелме соң?

Романда сугыштан соң авыл игенчеләре тормышын сурәтләүгә зур урын бирелгән.

Инде сугыш беткәнгә байтак вакытлар узса да, бу җирләр сугыш уты астында калмаган булса да, татар авылы «фашист гаскәрләре ва-

тып-җимереп киткән украин, белорус авылларын» хәтерләтә: «Кое сиртмәсе янындагы яртылаш җимерелгән мич калдыгы, очы сынган ялгыз чыршы — барысы да, барысы да сугыш елы киноларындагы, фотоларындагы кебек. Тик менә күккә күтәрелгән төтен баганалары күренми дә, җир өстендә аунап яткан мәетләр генә юк... Кайчандыр бай, куппы булган, хәзер инде тәрәзәләре аркылы-торкылы такталар белән кадакланган, чолан такталары каерып алынган бу нык, таза, ләкин үле йорт яныннан узганда Габделхәйнең күңелендә чиксез кызыксыну да, курку-шомлану да уяна торган иде. Бу турыдан ул тиз-тиз генә узып китмәкче булды һәм җансыз-өнсез, әмма каберлек сыман серле истәлекләр белән тулы тәрәзәләргә, кәрнизләргә озаклап карамаска тырышты».

Гади игенче өенә керсәң, анда шыксыз хәерчелек. Габделхәйнең картәтәләре ачлыктан тилмерә, ә бит бу өйдә көн-төн колхоз кырында эшләүче таза-сау өч кеше бар. Бала-чагасы да хезмәттә. Гаиләгә азрак файда булмасмы дип чабата тукучы картәтәгә «Чабата» налогы салу белән яныйлар. Башта «кансамул», аннан «фартия», аннан «ата камамист» булып киткән, сугыштан яраланып кайткан яшь бабай көн-төн колхозда эшли, ләкин аның да көнлек хезмәт хакы 300 грамм оннан артмый. Үз халкын, игенчене әнә шулай алдап, талап, колларча бил бөктереп яшәргә мәҗбүр иткән тоталитар система әсәрдә бөтен ялангачлыгы белән күз алдына килеп баса. Авыл халкы мондый тормыштан канәгать түгел, ләкин ул бу коллыктан чыгу юлларын таба алмый.

Габделхәй кебек яшүсмерләр килеп туктагач поездларда таза-тук чырайлы, тишексез, ямаусыз, матур киемле кешеләрне күрәләр күрүен, ләкин бу кешеләр кебек булу өчен читкә китәргә, ә читкә китәр өчен паспорт кирәк. Тоталитар хакимият ач, ялангач крестьянны җиргә мәҗбүри бәйләп тору юлын тапкан — крестьянга паспорт бирелми.

Кабаладан чыгасың килә икән, «дус-иш» тап. Ә дус-иш, кода-кодагый кулында бөтен нәрсә, хәтта закон үзе дә. Тыныч кына, матур гына җайлаша белсәң, Дәүләтгәрәй абыйлар кебек мул тормышта яшәрсең, ә бәлки, иптәш Сафин Мунир Мунировичлар кебек үсеп «Кеше» дә булып китәрсең... Яшь егет кайсы юлны сайлар? Дөрес, аңа «милләте башкорт» дигән паспортны ясап бирәләр бирүен... Ләкин Габделхәй үзе татар булгач, аның мондый документны аласы килми. Аннан соң «бу белгесезлектән, хәерчелектән ничек котылырга инде?» дип йөргәндә, кемнәрдер «хәрби училищега китәсең» дип егетнең киләчәген хәл итеп куялар. Мондый «шатлыклы» көннәрдә биек трибунадан иптәш Сталин да «бәхетле» Габделхәйгә аталарча кул болгаган сыман тоела.

Әлбәттә, рухи яктан азатлыкка чыгарга омтылган яшь егет үзенчә тартыша, каршылык күрсәтә, курка-курка гына булса да, «зур абыйлар»га үз фикеренең дөреслеген расламакчы була. Явызлык, гаделсезлек дөньясында якты нур булып торган Габделхәй, Сәкинә, Былбылларның самими саф хисләре, уйлары, кылган гамәлләре укучы күңелендә киләчәккә өмет чаткысы да уята.

Зур әдип, фикер иясе Нурихан Фәттах бу әсәре белән үзе яшәгән чорда хакимлек иткән тоталитар системаның чын йөзен ачып, аның милләт ирегeн, шәхес ирегeн буып торуын, гади халыкны, аерым милләтләрне коллыкта яшәтү яисә бөтенләй юкка чыгару өчен бөте-

несен эшләвен күрсәтә алды. Әдәбиятта социалистик реализм өстенлек иткән бер чорда Нурихан Фәттахның «Кичү» романын язып, бик күпләрне борчыган кискен проблемаларны күтәрүе һәм аларны хәл итүнең үзенчәлекле юлларын эзләве иҗади каһарманлык булып кабул ителә.

*Әлфинур Нәҗипова,*
*«Казан утлары», 1998, № 5*

# КИЧҮ

## СҮЗ БАШЫ

Бу әсәрне мин бик күптән — теге заманда, 1956 елда ук яза башлаган идем. Иң әүвәл уйланылганча, ул вакытта мин бөтен дөньяны таң калдырырга тиеш булган киң күләмле, тирән эчтәлекле роман-эпопея иҗат итәргә тиеш идем. Роман-эпопея кимендә дүрт кисәктән торырга һәм сугыштан соңгы еллардагы татар тормышын чагылдырырга тиеш иде. Мин тормышны әз генә дә бозмыйча, бизәмичә күрсәтергә, һәрнәрсәдә, аеруча халык тормышын һәм милли мөнәсәбәтләрне тасвирлаганда дөреслекне ярып салырга тиеш идем.

Роман баштарак «Таяныч» дип, соңга таба беркадәр китапчарак «Хыял вә хәят» дип аталды. Әлеге исемнәрдән үк күренеп торганча, өстебезгә бик авыр йөк алмакчы идек без. Ләкин нихәл итмәк кирәк, чынбарлык хәтта хыялдан да көчлерәк булып чыкты. «Хыял вә хәят»не 1963 елга кадәр яздым да, ары дәвам итәргә куәтем җитмичә, тукталып калдым. Ул елларда бар нәрсәне буып торган милли террор һәм рәхимсез мохтаҗлык әсәремне тиешенчә очлап чыгарга ирек бирмәде дисәм, мондый сүзләр хәзер аклану булып аңлашылмас дип уйлыйм. Чөнки дөресе шулай.

Утыз елдан артык вакыт үткәч, мин элекке кульязмаларны яңадан карап чыктым һәм романның беренче кисәген укучыга тәкъдим итәргә ярый дигән фикергә килдем. Бүген инде мин аны, әлбәттә, элекке хәлендә калдыра алмадым — беркадәр үзгәрттем, тулыландырдым һәм зур әсәрнең бер кисәге итеп түгел, бәлки, аерым роман итеп эшләргә тырыштым. Романның күләме дә, колачы да башта уйланылганга караганда шактый кысыла төште. Шуңа күрә аның исеме дә тарайды һәм конкретлашты. Берничә кисәктән торган «эпопея»ны хәзер яшьлеккә хас бер хыял итеп кенә искә төшерергә туры килә. Шулай да, «Хыял вә хәят»тән үсеп, бүленеп чыккан шушы кыйпылчыкта күпмедер дәрәҗәдә безнең яшьлек еллары чагылыш таба алган булса, анысы өчен дә мин үземне чиксез бәхетле санар идем.

*Август, 1990, Казан*

## Беренче бүлек

### I

Битендә, маңгаенда рәхәт җылы тоеп, Габделхәй уянып китте. Каршыдагы зур тәрәзәдән бүлмәгә иртәнге кояш нуры төшкән. Бу әле җылынырга өлгермәгән, тузан белән, һәртөрле әчкелтем-төчкелтем исләр белән буталмаган саф нурлар. Кичә кичтән яртылаш ачып куелган тәрәзә ябылмый калган. Биек түшәмле класс бүлмәсенә, кояш нурлары белән бергә, иртәнге салкынча һава кереп тулган. Якында гына, урам белән мәктәп бинасы арасында гына үсеп утырган куакларда шатланып, дөнья бетереп чыпчыклар чыркылдаша. Тәрәзә башында, кояш чыгуына сөенеп, эретеп күгәрченнәр гөрли. Бөтен бүлмәдә, барлык исләрне күмеп, яңа чабылган болын исе, баллы чичкәләр исе, куе үлән исе аңкый.

Ел тәүлегенең шушы вакытында һәркөн кабатлана торган, һәркөн кабатланырга мөмкин булган гадәти бер иртә иде бу. Шул ук вакытта моннан соң инде беркайчан кабатланмаячак әүвәлге һәм ахыргы бер иртә иде.

Өченче көн директор Уфадан кайтып төште. Унынчылар да, укытучылар да аны инде күптән дүрт күз белән көтеп торалар иде. Унынчыларның тизрәк аттестатларын күрәселәре килде, укытучыларның исә уку елын тәмамлап, тизрәк ялга чыгасылары килде. Аннан соң, директор кайту белән, чыгарылыш кичәсе булырга тиеш иде. Иң кызыгы аның менә шул иде.

«Кичә»гә инде күптән әзерләнә башлаганнар иде. Директорның кайту хәбәре тиз арада таралып өлгерде һәм мәктәптә, мәктәп тирәсендә, мәктәпкә катнашы булганнар арасында шундук җанлану һәм ыгы-зыгы башланды.

Кайту белән директор тиешле кешеләрне чакыртып алды, чыгарылыш кичәсен иртәгә үк уздырырга боерды. Бу хакта тиешле кешеләргә хәбәр итәргә һәм, иң кирәклесе, кичәдән соң булачак күңел ачуга яисә мәҗлескә тиешенчә әзерләнергә кушылды.

Мәҗлес өчен кирәк булган барлык нәрсә чынлыкта тулысынча диярлек әзер иде, тик шулай да каяндыр нәрсәдер табасы, каяндыр нәрсәдер алып киләсе, нәрсәнедер пешереп бетерәсе, кыздырып бетерәсе бар иде. Аш-суга әзерләнү химия укытучысы Халидә апа белән унынчыларның класс җитәкчесе Фәрхәнә апага тапшырылган иде. Халидә апа, директор хатыны буларак, җитәкче сыман саналса да, Фәрхәнә апа олырак та, дәрәҗәлерәк тә иде. Аннан соң чыгарылыш кичәләре уздыру, аш-су, мәҗлесләр уздыру

белән аның инде күзе чыккан иде. Шунлыктан җитәкчелеккә быел Халидә апа әллә ни дәгъва дә кылмады — телгә-тешкә килмичә, сүзсез генә Фәрхәнә апага юл бирде.

Директор белән, аннан да бигрәк Халидә апа белән килешкәч, аңлашкач, Фәрхәнә апа кичәгенәк унынчыларга иртән иртүк килергә дип кешеләр җибәргән иде. «Кичә» була дигән көнне, иртәнге якта, беренче дәрес башлана торган вакыттан бераз гына соңга калып, мәктәп капкасыннан бер төркем яшьләр килеп керде.

Мәктәп ишегендә йозак эленеп тора иде.

— Иртәрәк килгәнбез!— диде беренче булып Сәкинә.

— Бар, кайтып кит!— диде Җәмилә, шундук элеп алып.

— Кара, йокысы туймаган да!..— диде Сәкинә.

Җәмилә эндәшмәде — ишектәге йозакка карап торгандай итте дә, кискен бер хәрәкәт белән Сәкинәне култыклап алды.

— Әйдәле бер җиргә!— диде.— Фәрхәнә апа тегендәдер... Халидә апалардадыр...

— Мин беркая бармыйм. Бар үзең генә,— диде Сәкинә, киреләнеп.

— Абау, шушыны!— диде Җәмилә.

Арттанрак килүче башкалар да йозаклы ишек янына якынрак килделәр, аптыраган сыман йозакка, бер-берсенә карангалап тордылар. Җәмилә белән Сәкинәнең култыклашып китәргә җыенуын күреп, Назиф:

— Барыгыз әле, иптәшләр, Халидә Забировнадан ачкычны алып килегез,— диде.

Ул моны директорга охшатып, коры һәм боеручан төстә әйтте. Барысы да көлеп җибәрделәр. Үзенең шәп итеп әйтә алуына күңеле үсеп киткән Назиф барысыннан да ныграк көлде.

— Әйдәгез, бөтенебез бергә барабыз!— диде Нәзирә.

— Әйдәгез, әйдә!— диде Җәмилә.

Сәкинәне ычкындырып, ул Нәзирәне култыклап алды. Башкалар теләр-теләмәс кенә алар артыннан иярделәр. Озынча мәктәп бинасы футбол кыры кебек иркен ишегалдының бер ягына, урам буена, директорның өе икенче ягына — артка, каралты-куралар янынарак урнашкан иде. Директор өенә туры ишегалды аша йөриләр иде. Мәктәп почмагы янына җитеп ишегалдына борылыр алдыннан Җәмилә артына әйләнеп карады һәм иптәшләрен оялтмакчы булып:

— Атлыйсызмы, юкмы?— диде.— Абау, шундый җансыз булгач та булырсыз икән! Ничә әйтсәң дә шул Сәкинә мыштырдык инде.

— Кара! Нишләп миңа каныктың әле син?— диде Сәкинә, үпкәләп.

Җәмилә белән Нәзирә иптәшләрен көтеп torгандай иттеләр. Җәмилә тупас кына кыланып Сәкинәнең сул кулыннан эләктереп алды. Сәкинә карышып тормады, һәм алар, тапталган киң сукмакны иңләп, өчәүләп, бер-берсенә сыенып баруларында булдылар. Күпмедер җир киткәч, тынычсыз Җәмилә тагын туктап калды.

— Уф, йөрәккәем сикереп чыга инде!— диде күкрәгенә тотынып.

— Сикерсә, таш бәйлә,— диде үпкәчел Сәкинә, читкә тайпылып.

— Карагыз әле, малайлар!— диде Җәмилә, малайлардан бигрәк кызларга эндәшеп.— Әйдәгез Халидә ападан аттестатларны сорыйбыз! Аттестатларны күрмичә йөрәгем түзми, билләһи газим!

— Әйттем бит — таш бәйлә,— диде Сәкинә.

— Буш хыял!— диде Назиф.

— Маниловщина!— диде Фәнәви, элеп алып.— Безнең аттестатлар җиде кат җир астындагы җиде катлы сейфта саклана.

— Ачкычы җиде башлы дию пәриенең түш кесәсендә!— диде Назиф, остарып.

Барысы да шаркылдашып көләргә тотындылар. Ләкин көлешү шулай да куанычлы булмады — кемдер усал итеп ысылдап куйды, кемдер як-ягына каранып алды. Таралып барган төркем бер тирәгәрәк туплана төште. Яшьләр кинәт кенә тынып калдылар һәм ул-бу була калса, бер-берсен якларга әзер сыман, бер-берсенә сыенгандай иттеләр. Директор өенең ишеге янына килеп җиттек дигәндә генә, чоланда таныш тавышлар ишетелде. Өйдәге кем беләндер сөйләшеп, кулына бидерә тотып, Фәрхәнә апа килеп чыкты. Биленә ул алъяпкыч бәйләп куйган, күлмәк җиңнәрен яшьләрчә сызганып җибәргән иде.

Алар, бер-берсен күреп, аптырабрак калгандай булдылар, елмаеп җибәрделәр, «исәнмесез» диделәр.

— Кунакларны буш бидерә белән каршылау килешми дә инде,— диде Фәрхәнә апа, кулындагы бидерәсен баскыч төбенә куеп.

— Каяле, Фәрхәнә апа, үзем шуны тиз генә тутырып алып килим. Шуннан соң килешер,— диде Назиф, барысыннан алгарак чыгып.

— Ялагай да соң бу Назиф!— диде Фәнәви, бөтенесенә ишетелерлек итеп.

— Юк, ялагай түгел — өлгер һәм тырыш, эшчән һәм булдыклы!— диде Назиф, үз-үзен мактап.

— Барыгыз, без монда көтеп торырбыз,— диде Фәрхәнә апа Назифка.

— Алайса без Америка эшсезләремени, Фәрхәнә апа?— диде Җәмилә.

— Сезгә дә эш табылыр,— диде Фәрхәнә апа.

Ул арада кызлар аны уратып алдылар, директорның кайчан, ничек кайтуы турында, аттестатлар турында сораштыра башладылар, андый-мондый күңелсез хәбәр юкмы диделәр. «Күңелсез хәбәр» барыннан да элек, әлбәттә, аттестат мәсьәләсенә кагыла иде. Кайберәүләр, ягъни бик үк яхшы укымаганнар, Уфада «начар» куеп кайтармадылар микән, көзге сынауга калдырмадылар микән диебрәк шүрлиләр иде. Чөнки имтиханнар башланыр алдыннан укытучылар да, директор үзе дә әледән-әле аларны «начар» белән, көзге сынаулар белән, аттестат бирмәү белән куркытып торалар иде.

— Бернинди күңелсез хәбәр юк, борчылмагыз, иптәшләр,— диде Фәрхәнә апа үз итеп, тавышын әкренәйтә төшеп.

Мондый сүз ишетеп, барысы да җиңел сулап куйдылар. Аттестат турында сүз чыккач, Фәрхәнә апа яшьләр төркеменә игътибар беләнрәк күз йөртеп алды да:

— Габделхәй кая соң безнең?— диде.

Аңа беркем җавап бирмәде.

## II

Бүген иртән мәктәпкә барырга чыккач, Җәмилә белән Сәкинә, кыек юлны туры итеп, Габделхәйләргә дә сугылдылар. Ләкин Габделхәй, ашыгыч эшем бар, бара торыгыз — мин сезне куып җитәрмен дип, өеннән чыкмый калды. Кызлар аның нинди ашыгыч эше барын бик яхшы белделәр һәм артык кыстап тормыйча, үз юллары белән китеп бардылар. Габделхәйнең исә шигырь язасы, дөресрәге, язылган шигырен яңабаштан карап, төзәтеп-шомартып чыгасы бар иде.

Чыгарылыш кичәсендә сөйләячәк шигырен ул инде моннан бер атна элек язып ташлаган иде. Шигырь аңа баштарак бик ошады, шундый ошады — басылачагына әз генә дә шикләнмичә, ул аны шул ук көнне «Коммунизм юлы»на илтеп тә бирде. Редактор Разия апа шигырьне укып чыкты һәм шунда ук үзенең фикерен дә әйтте — әйбәт булган, басарбыз, диде. Соңыннан шулай да өстәп куйды: азагы бераз килеп җитмәгән кебек, диде. Габделхәй редакторның «басарбыз» дигән сүзен генә ишетте бугай, соңгы сүзләренә бөтенләй игътибар да ит-

мәде шикелле. Аның күңелен чиксез куаныч тойгысы биләп алды. Ике-өч көн буена ул әлеге куаныч тойгысы белән дәртләнеп йөрде.

Кичәгенәк газетада басылачак шигырен ул яңадан укып карады. Укыды, ләкин шигырь аны элеккечә үк сөендерә алмады. Аңа хәзер монда нидер ошамаган кебек булды. Кат-кат укый торгач, ул ошамаган нәрсәнең эзенә дә төште. Аеруча дәртле, тантаналы булып тәмамланырга тиешле соңгы юллар ничектер көчсез, сүлпән һәм буталчык булып чыккан иде. Аннан соң шигырьдә иптәш Сталин образы да тулысынча ачылып җитмәгән иде бугай. Дөресен әйткәндә, иң күнелсезе аның менә шул иде. Бит Сталин турында язарга кыюлыгың җиткән икән, ничек тә аны тиешле политик югарылыкта яңгырата да белергә кирәк! Менә бит хикмәт нәрсәдә.

— Рәхмәт сиңа, туган уку йортым. Бөек Сталин — бәхет кояшы!— дип укыды ул, әле кычкырып, әле тавышын әкренәйтеп һәм төрлечә үзгәртеп.

Үз тавышына үзе колак салып тыңлагандай итте дә әлеге строфаның соңгы юлларын әйтеп карады:

— Рәхмәт сиңа, батыр туган халкым —
Улларыңның изге юлдашы,— диде.

«Монда ниндидер логик хата киткән» дип уйлады ул, ниһаять, билгеле бер фикергә килеп. Ләкин нишләп Разия апа шуны күрмәде икән дә, нишләп җиңел генә басарга риза булды икән, дип уйлады ул аннары исе китеп. Әйтерсең аның хатасы өчен ул үзе түгел, бәлки, редактор гаепле иде.

Соңгы дүрт юлны ул яңабаштан, өр-яңадан язарга тотынды. Ләкин күпме генә азапланмасын, күңеленә бер генә матур сүз дә, бер генә матур фикер дә килмәде. Үзүзен көчләп шигырь язарга утырдымы, уйлары аның каядыр читкә тарала да китә. Шул чагында инде кызлар килеп, «Әйдә, Габделхәй, безнең белән!» дип әйтәләр икән, шигырь дигән нәрсәгә аның карыйсы да килми башлый. Ләкин бүген ул кызлар янына чыгарга ашыкмады. Җәмилә белән Сәкинә икесе бергә булганда, аның күңелендә һәрвакыт каршылыклы хис-тойгылар барлыкка килә: кызларның берьюлы икесе белән дә түгел, бары берсе белән генә буласы килә иде кебек.

Шулай да бүгенге тантаналы көндә аның өйдә каласы килмәде. Кызлар китеп беркадәр вакыт үтү белән ул алар артыннан юнәлде.

Габделхәй мәктәпкә килеп җиткәндә, монда инде кызу эш бара иде. Малайлар шау-шу килеп утын кисәләр, утын яралар. Кайберәүләр ишегалды уртасындагы түбәсе ябу-

лы кое янында булаша — чыгыр әйләндереп, тимер чылбырны чылтыратып, су күтәрәләр. Кызлар су ташыйлар, утын ташыйлар.

— Соңлабрак килдең шул — сиңа эш калмады,— диде Фәрхәнә апа Габделхәйгә.

— Калды, калды — әнә чиләктәге пычрак суны түгеп килсен!— дип кычкырды якындагы Җәмилә.

— Эш булды, Фәрхәнә апа,— диде Габделхәй, аклангандай итеп.

Фәрхәнә апа аның чыгарылыш кичәсендә шигырь сөйләргә тиешлеген белә иде. Алай гына да түгел, шәп итеп шигырь язарга ул аңа үзе тәкъдим иткән иде.

— Булдымы соң?— диде Фәрхәнә апа, нинди «эш» турында сүз барганын төпченеп тормыйча.

— Булмады шул әле, Фәрхәнә апа,— диде Габделхәй.

— Ярый, син алайса эшеңне бетер. Без монда җитәрлек,— диде Фәрхәнә апа, китәргә рөхсәт итеп.

Габделхәй кире борылып мәктәпкә китеп бармакчы булды — ул килгәндә мәктәп ишеге ачылган иде инде. Аның хәзер ничек тә үзе генә каласы, ничек тә шул шигырен очлап куясы килә иде.

— Абау! Кая барасың? Түгеп китер инде шул чиләкне!— диде Җәмилә, шагыйрь җегетнең юлына аркылы төшеп.

Җәмиләнең тавышы каттый, хәтта усал булып яңгырады. Габделхәй икеләнеп калды. Бер чиләк су түгеп килү аның өчен берни тормый иде. Ләкин көтмәгәндә аның күңелендә кирелек баш калкытты: кушканны, боерганны аның җене сөйми иде.

— Үзегез дә түгәрсез әле,— диде ул һәм шәп-шәп кенә атлап китеп тә барды.

Икенче якта Сәкинәнең тавышы ишетелгәндәй булды.

— Кара, кара!— диде Сәкинә гаҗәпләнеп, шелтә белән.

Габделхәй туктарга кирәк тапты. Сәкинәнең шулай Фәрхәнә апа янында, кызлар, малайлар алдында шелтә белдерүе аның өчен бөтенләй көтелмәгән хәл булды. Чын мәгънәсендә аңа оят булды — сулы чиләкне каядыр илтеп түгүдән баш тартуы өчен түгел, бәлки, Сәкинәнең — Сәкинә булып Сәкинәнең — аркылы төшүе өчен оят булды.

— Шагыйрь кеше ниндидер чиләкләр белән булашмас инде,— дигән булды Фәрхәнә апа, Габделхәйне яклап.

— Юк, юк, дөрес түгел!

— Түксен, түксен, Фәрхәнә апа!— диештеләр кызлар, явызланып.

— Шагыйрьләр дә эшләп ашарга тиеш!— диде Насиф, күрәләтә кызларны яклап.

— Шагыйрьләр ашамыйлар — җил белән генә туенып торалар,— диде Габделхәй, сүзне уенга әйләндермәкче булып.

— Менә минем кичәдән бирле авызыма бер тәгам ризык капканым юк. Юл буена җил эчеп килдем. Синеңчә, мин шагыйрьмени?!— диде Назиф, чиктән тыш остарып.

— Син шагыйрь түгел, шагыйрь ярдәмчесе,— диде Габделхәй.

— Хәерченең ялчысы икән алайса,— диде Фәнәви.

— Хәерченең ялчысы җегерме беренче җылны үлеп беткән!— дип кычкырды Назиф, калын тавышы белән кызларның, малайларның көлешүен күмеп.

— Ярар, түгәрмен. Сезнең тавыштан карга тавышы тансыграк!— диде Габделхәй, кирелеген җиңеп.

Кызларга карата әйткән соңгы сүзләре аның үзенә бик оста һәм тапкыр булып тоелды. «Шигырь язганда да шулай булсачы!» дип уйлады ул үзалдына, очланмаган шигырен исенә төшереп.

— Төзәлә башлады бу бала. Тәртибенә «өчле» куймый булмас,— диде Назиф, Габделхәй артыннан көлеп калып.

Назифның соңгы сүзләрен дә, иптәшләренең дәррәү кубып яңадан көлешә башлауларын да Габделхәй бик яхшы ишетте. Туктады да чиләген җиргә куеп:

— Алай көлсәгез, бармам да!— диде, үпкәләгән булып.

— Кара халыкның авыз җыруына колак салма, шагыйрь дус!— диде бәләкәй буйлы, җор телле Фәнәви, Габделхәйнең күңелен күтәргән булып.— Шагыйрь кеше барысына да түзәргә тиеш.

— Уң яңагына сугып җибәрсәләр, сулын куярга, сул яңагына сугып җибәрсәләр, уңын куярга тиеш,— диде Назиф, элеп алып.

«Ну, Назиф! Мин сине!..»— диде Габделхәй, эченнән генә. Шулай да ул иптәшләре белән сүз көрәштерүнең файдасыз икәнлеген чамалап алды һәм үз күңелен үзе күтәреп:

— Уң кулыңдагы чиләкне сул кулыңа, сул кулыңдагыны уң кулыңа алып... Ары лап-лап, бире лап-лап, сөңге саплап, киез каплап!— дип сөйләнә-сөйләнә китеп барды.

Җиңүче кызлар, малайлар аның артыннан шаулашып, көлешеп калдылар.

### III

Авыр чиләктән һәм иптәшләренең мыскылыннан котылгач, Габделхәй үзләренең классына, үзенең партасына кереп утырды. Зур тәрәзәләре кояш чыгышына караган иркен бүлмәдә — каршы як стенадагы озын кара

тактасы, озын кара тактадан берничә адым читтәрәк озын «демонстрация өстәле», ишек янындагы ап-ак миче, портретлары, пыяла капкачлы шкафлары, таблицалары — барысы, барысы да таныш һәм кадерле класс бүлмәсендә сәер бер тынлык хөкем сөрә иде. Бу бүлмәне һәрвакыт шау-гөр килеп торган хәлдә күргәнгә, мондагы тынлык, мондагы иркенлек һәм саф һава Габделхәйгә ничектер кызганыч булып тоелды. Каршыдагы кара такта да, пәке очы белән юнылып-сырланып беткән парталар да, пыяла шкафлар, шкаф эчендәге физика приборлары да — барысы якын һәм кызганыч тоелды.

Менә бүген ул монда соңгы кат утыра. Моннан соң ул монда килерме-юкмы, билгесез. Килсә дә инде, күрәсең, монда башкалар утырыр, башкалар белем алыр. Хуҗа булып, батыр булып алар шаулашыр. Никтер моңа ышанасы да килми, ләкин инде моңа ышанмыйча да булмый.

Шулай беравык моңаеп, онытылып утыргач, ул чалбар кесәсеннән әвәләнеп беткән кәгазь кисәге чыгарды. «Моңаерга, Антонина Семеновна әйтмешли, барышнялар сыман җебеп төшәргә ярамый»,— дип уйлады ул. Язарга кирәк, үз-үзеңне мәҗбүр итеп булса да язарга кирәк. Николай Островский әле бер дә җебеп төшмәгән, нинди кыен хәлдә дә көчле әсәр иҗат иткән. Сталинград сугышында совет солдатлары барышнялар кебек моңаеп, җебеп төшсәләр, бернинди җиңү дә булмас иде, Гитлер безне күптән инде кабып йоткан булыр иде. Шулай булгач...

Шигыренең соңгы строфасын ул тулысынча Сталинга — илебезне, халкыбызны коллыктан, үлемнән коткаручы Бөек Кешегә багышларга тиеш. Ул — Кеше генә дә түгел, ул — Аллаларга тиң изге зат. Шигырендә Габделхәй Аның даһи образын тулырак, киңрәк ачарга тиеш. Дүрт юлда ул үзенең бәхетле яшьлеге өчен, унынчыны уңышлы тәмамлап чыгуы өчен, хәзер инде үз алдында бетмәс-төкәнмәс мөмкинлекләр ачылуы өчен юлбашчыга кайнар рәхмәтләрен белдерергә тиеш. Ул моны һәркемнең исен китәрерлек итеп, оста һәм тапкыр итеп әйтеп бирергә тиеш.

Тиешен тиеш тә, тик менә аның күңеленә хәзер бер генә матур, оста һәм тапкыр фикер дә килмәде. Аның уйлары хәзер кайдадыр читтә, еракта чабышып йөрде. Бер дә кирәкмәгәнгә күз алдына усал, кыю Җәмилә килде, йомыкыйрак, уйчанрак Сәкинә килде. Күз алдында әлерәк кенә үзе илтеп түккән җирәнгеч сыекча җәелеп ятты, борынына шундагы ачы, тәмсез исләр килеп бәрелгәндәй булды.

Иҗади эш белән шөгыльләнгәндә иптәш Сталин, күңе-

ленә тиешле фикерләр килмәсә, күн итекләрен шыгырт-шыгырт басып йөренергә тотына. Төннәрен ул йөри-йөри уйлый, йөри-йөри яза. Уң кулында аның һәрвакыт төрепкә булыр. Ул көндез дә, төнлә дә яза ала. Менә ул нинди эшчән һәм корычтай нык ихтыярлы кеше! Шундый булырга иде аңа да... Габделхәйгә дә! Һо, ул чагында! Тәмәке тартуны зарарлы дигән булалар, ләкин тәмәке ул башны яхшы эшләтә ди, имеш. Тәмәке зарарлы булса, иптәш Сталин туктаусыз төрепкә тартмас иде. Ул бит аңа сөргендә чагында өйрәнгән. Ярар, тәмәкесен тартмасаң да була, шулай да өстеңдә аныкы кебек шәп китель, аягыңда аныкы кебек шәп күнитек булса, шигырь, бәлки, үзеннән-үзе язылыр иде.

Күңеленә аның шундыйрак уйлар килде. Бөек шәхескә охшарга тырышкан сыман ул, парта арасыннан чыгып, кара такта янына килде, әрле-бирле йөренде дә яңадан урынына килеп утырды. Юк, йөри-йөри дә ул бернинди яңа фикер уйлап таба алмады. Күңеленнән ул Сталин исеме белән янәшә куеп була торган мактау, данлау сүзләрен әйтеп карады, шул сүзләрдән төрлечә рифмалар ясады, ләкин аларның берсе дә канәгатьлек тойгысы тудыра алмады. Аерым әйткәндә ярыйсы гына булып тоелган сүзләр бөек исем белән бергә әйтелдеме, төссез, хәтта мәгънәсез булды да калды. Шуның өстәвенә Габделхәй уйлап тапкан чагыштырулар чынлыкта кайчандыр, кайдадыр укылган, кайчандыр, кайдадыр ишетелгән һәм күптән инде гадәтигә әйләнеп беткән сүзләр иде.

Теләр-теләмәс кенә, көчәнеп кенә сайлана, чүпләнә торгач, ул шулай да баштагы «бәхет кояшы»на тукталырга булды. «Кояш»ка рифмалаша торган «юлдаш»ны калдырыргамы, юкмы икәнлеген белмичә аптырабрак утырганда, класс бүлмәсе ишегенең шыгырдап ачылганы ишетелеп китте. Ипләп кенә, кыюсыз гына атлап бүлмәгә Җәмилә килеп керде. Габделхәйгә кинәт аякланып, балкып ишектән кояш үзе килеп кергән кебек булды. Аның күңеле яктырып китте, йөрәге шатланып тибәргә тотынды, битенә рәхәт кайнарлык йөгерде. Шул ук вакытта башы беркайчан булмаганча тиз-тиз эшли башлады. Ләкин бу мәлдә «бөек образ» инде каядыр юкка чыккан иде. Үзенең кызарынуын, шатлыгын күрсәтмәс өчен ул башын түбәнрәк иде һәм тынын кысып көтә башлады.

Йоклаган кешене уятмаска тырышкан сыман, һәр адымын чамалап, йомшак кына басып, Җәмилә кара такта белән демонстрация өстәле янындагы аралыктан үтте дә, әйләнеп, Габделхәй утырган арткы парта янына килде.

— Нишләп боегып утырасың болай?— диде юри сузып.

Шигырь язу Габделхәй өчен изге эш, яшерен эш исәпләнелә иде. Аныңча, кыз белән җегет үзара серләшкәндә чит кеше кысылмаска тиеш булган кебек, монда да кем дә булса карап торырга, кысылырга тиеш түгел иде. Җәмиләгә ул күтәрелеп тә карамады. Шулай да ул аны куалап та җибәрә алмады.

— Рәхмәт сиңа, туган йортым... уку йортым... матур йортым... даһи Сталин...— дип кабатлады ул күңеленнән, вәсвәсәгә бирелмәскә, игътибарын читкә юнәлтмәскә тырышып.

Җәмилә ак, матур кулын кара парта өстенә куеп беравык тын гына Габделхәйгә карап торгандай итте дә, уфтанып, хәтере калып:

— Абау! Бигрәк инде — күтәрелеп тә карамыйлар кайберәүләр!— диде.

Габделхәй борынын тартты, ашык-пошык нидер сызгалап куйган булды. Ләкин барыбер эндәшмәде. Ике арада күңелсез тынлык сакланды.

— Гафу ит,— диде кыз, күрәләтә үпкә белән.— Василий Михайловичны гына күрмәкче булганыем,— диде аннары, ялганлап.

— Аның кабинеты монда түгел,— диде Габделхәй, телгә килеп.

Бу сүзләрне ул үзенчә усал итеп, төрттереп әйтте, ләкин Җәмиләгә бу әз генә дә тәэсир итмәде. Ул шундук елмаеп җибәрде һәм, китәргә укталган җиреннән тукталып, үтенгән дә, таләп итү дә сизелгән бер тавыш белән:

— Без хәзер болынга чичкәгә барабыз. Барасыңмы?— диде.

Габделхәй җавап бирергә ашыкмады. Ни өчендер ул үзен Җәмилә белән һәрвакыт уйлап сөйләшергә, сөйләшкәндә дә оста, кырыс һәм бераз гына тупас итеп сөйләшергә тиеш дип исәпли иде.

— Сиңа соң Василий Михайлович кирәкме, әллә минем болынга чичкәгә баруыммы?— диде ул, озын һәм катлаулы итеп.

— Әй!— диде кинәт Җәмилә, корт чаккандай.— Билләһи газим!.. Утырган була. Әлләкем булган!

Чын күңелдән үпкәләп, ул кырт кына борылды да малайлар кебек партага сикереп менде һәм парталар өстеннән зур-зур атлап ишеккә ташланды. Күз кырыеның яртысы белән генә Габделхәй аның артыннан карап калды. Күзенең яртысы белән генә караса да, арттан ул аның сокландыргыч сылу гәүдәсен күреп калды. Көчле

яктыга ялгыш туры караган чактагы кебек, кыз кешенең зифалыгыннан аның кинәт күзе чагылгандай булды, зиһене буталды. Шигырь исә үзеннән-үзе онытылды.

Ничә көн инде үзенең ниндидер көчле, тәэсирле сүзләр сайлап шигырь язарга азаплануы, җан тирләре белән көчәнүе һәм үзе беркайчан да күрмәгән, тоймаган ниндидер чит, ят нәрсәләрне мактарга, данларга тырышуы беренче мәртәбә аңа коточкыч дәрәҗәдә мәгънәсезлек булып тоелды. «Җәмилә турында, кызлар турында, болын һәм хуш исле чәчкәләр турында язарга иде шигырьне!»— дип уйлады ул хыяллану сыман бернәрсә кичереп. Җәмиләнең серле күзләре турында, серле итеп сөйләшүе, көлүе, гүзәллеге турында... Ләкин мондый шигырьләрне элек кенә язганнар. Идеясез, кыйбласыз буржуаз шагыйрьләр генә язган. Алар заманында яраган. Хәзер — юк. Андый коткыга бирелергә ярамый.

Шулай итеп, кабынып китә язган яшь күңелдәге шигъри ялкын үзеннән-үзе сүнде һәм озын кара тактадагы кебек, күңел күгендә яңадан авыр, бәйләнчек һәм мәгънәсез сүзләр калкып чыкты. Даһи Сталин — илебез кояшы... бөек Сталин — безнең юлбашчы... чишмә башы... йөзек кашы... атаң башы...

## IV

Җәмилә китеп күп тә үтмәде, урам яктагы ишекнең шыгырдап ачылганы ишетелде. Авыр ишек шапылдап ябылгач, тәрәзә, шкаф пыялалары сизелер-сизелмәс кенә дерелдәп-калтыранып куйды. Бөтен игътибарын бергә туплап, тыштагы, читтәге һәр тавышка колак салып утырган Габделхәй ишектән килеп керүченең аяк тавышларын гына түгел, хәтта тын алуын да ишеткәндәй булды.

Класс бүлмәсенә мәктәп директоры Василий Михайлович килеп керде. Габделхәй ирексездән башын югары күтәрде, гәүдәсен турайтты, шулай да дәрестәге кебек аягүрә басудан үз-үзен тыеп калды. Иң беренче булып күзгә шул ташланды — Василий Михайловичның озынча яңаклары, чәчсез ачык маңгае һәм муены — кием капламаган барлык ачык төшләре утта пешкән кебек кызарып чыккан иде. Бу исә аның озак вакыт тышта, кояшта булуы турында әйтеп тора иде. Аягына ул ялт итеп чистартылган озын кунычлы күн итек, өстенә — кара төстәге галифе чалбар һәм ак күлмәк кигән иде. Сыек, саргылт чәчле башы яланбаш иде.

Василий Михайловичның мондый кыяфәтен һич тә гадәттәгечә дип әйтеп булмый иде. Гадәттәгечә булганда,

аның түбәсендә хәрби фуражка, өстендә исә барлык төймәләре каптырылган погонсыз китель булырга тиеш иде.

Директорның өе белән мәктәп арасында нибарысы ике, өч йөз адым чамасы гына булса да, беркайчан ул монда өйдәгечә яланбаш яисә күлмәкчән килми иде. Укучылар да, укытучылар да, шулай ук аның белән очрашкан, аралашкан һәркем аны ярым хәрби формада күрергә күнеккән иде. Барлыгы аның галифе чалбар һәм кительдән торган өч костюмы бар. Костюмнарның берсе ак төстә — нәкъ теге киноларда күрсәтелә торган адмиралларныкы кебек. Икенче костюмы кара, өченчесе яшькелт төстә. Ак костюмын ул җәйге-язгы көннәрдә генә кия, карасын — кыш көне, инглиз поставыннан тегелгән яшькелтен, яңасын бары тик тантаналы бәйрәм көннәрендә генә кия иде.

Василий Михайловичның формалы кием яратуы һич тә аның элекке хәрби кеше булуына һәм шуңа күрә әле булса хәрби тормыштан аерылып җитә алмавына кайтып калмый иде. Алай гына да түгел, заманында аңа хәрби хезмәттә булырга да туры килмәде. Яшь чагында авыру сәбәпле ул, гомумән, хәрби хезмәттә булмады. Сугыш елларында исә шул ук ниндидер авыруы аркасындамы, райондагы дус-ишләре аркасындамы янә армиягә алынмады. Кеше рәтенә керердәй ирләр бармак белән генә санарлык калган куркыныч елларда ул Яңавылдагы кирпеч заводының баш инженеры булып исәпләнде. Кирпеч заводы тимер юлга карый иде, тимер юлда эшләү исә армиядә хезмәт итүгә тиңләштерелә иде. Хәрби киемгә ул шунда күнекте.

Ярым хәрби кием аны, беренчедән, сырма, тун, бишмәт-фәлән кигән теләсә кемнән аерып күрсәтсә, икенчедән, кара халык алдында элекке фронтовик кебек итеп күрсәтә иде. Аннан соң шунысын да әйтергә кирәк, кыршау сыман муенны кысып торган утыртма яка, ялтыр төймәләре тезелеп киткән туры изү, калку күкрәк, тактадай иңбаш — кыскасы, шәп китель аны район җитәкчеләренә, хәтта һәр кабинетта, һәр почмакта урысның иконасы урынына эленеп торган олуг дәрәҗә иясенең портретларына да охшата сыман иде. Тик менә аның портреттагы дәрәҗәле кешенеке төсле куе, калын мыегы гына булмады. Ул инде бер мәртәбә үстереп тә карады. Ләкин аның төссез мыегы куе, калын булып чыкмады — нечкә генә булып үсте дә, тычкан койрыгы сыман очлаеп, ике якка салынып төште. Шулай да ул бераз вакыт оялмыйча кеше арасында шул мыегы белән йөрде. «Учительская»да бөтен халык алдында, шаярткан булып, усал һәм зәһәрле итеп, Антонина Семеновна:

— Бу мыегыгыз белән сез татар-монгол игосы заманнарындагы кысык күзле варварларны хәтерләтәсез,— диде.

Шулай диде. Үзе ямьсез итеп көлеп куйды. Башка укытучылар тып-тын калдылар. Василий Михайлович башта агарынып китте, аннан соң әкрен генә кызарына башлады. Шулай да Антонина Семеновна Васильевага каршы сүз әйтергә йөрәге җитмәде — Антонина Семеновна рус теле һәм әдәбияты укытучысы иде.

Укытучы буларак мәктәп директорына буйсынырга тиеш булса да, башкалар арасында ул үзен бөек милләт вәкиле итеп, шунлыктан барлык татар укытучыларыннан өстенрәк, дәрәҗәлерәк итеп тотарга күнеккән иде. Аннан соң аның шулай кеше йөзен җырта торган гадәте дә бар иде. Моны ул «турысын әйтү», «дөреслек өчен көрәшү» дип атый иде.

Василий Михайлович, оятын-хурлыгын йотып, үз-үзен елмаерга мәҗбүр итте, стенадагы көзге каршысына килде дә җентекләп үзенең мыеклы мескен йөзенә карап тора башлады. Көзгедән аңа чыннан да кысыграк күзле, киңрәк яңаклы, авыз читләренең ике ягына да салынып төшкән нечкә мыеклы варвар — «татар-монгол» карап тора иде.

«Шулай икән. Бигрәк җирәнгеч икән болай» дип уйлады ул, күңеле кырылып.

— Вы правы, Антонина Семеновна,— диде ул, аркасы белән мичкә терәлеп, кулларын пальто җиңнәре эченә тыгып утырган Васильевага.— Бүген үк кырдырып ташлыйм.

— Юк, юк, кырдырмагыз — болай бик матур!— диде Фәрхәнә апа, директорның мыегын яклап.

Антонина Семеновнаның иң яратмаганы Фәрхәнә апа иде. Башкалар кебек Фәрхәнә апа Васильева алдында куркып яисә ялагайланып урысча сөйләшергә дә тырышмый иде, урысча сөйләшергә туры килгәндә исә урысча сүзләрне коточкыч ватып-җимереп сөйли иде. Дөреслек, гаделлек яратучы Антонина Семеновна мондый чакта аны төрлечә өтеп ала, йә булмаса урыс теленә хөрмәт күрсәтмәүдә, милләтчелектә гаепләп тәнкыйтьләргә тотына һәм шуның белән бөтен кешенең кәефен кыра иде.

— Кайберәүләрдә әле һаман монгол каны кайный,— диде Антонина Семеновна, Фәрхәнә апага карамыйча.

Василий Михайлович шул ук көнне мыегын кыркып ташлады һәм шуннан соң беркайчан калын, куе мыеклы иптәш булу турында хыялланырга да батырчылык итмәде.

## V

Яңавыл татар урта мәктәбе укучыларының күбесе кебек, Габделхәй дә үзләренең директорларын яратып җиткермәде. Ни өчен яратмаганлыгын ул, күрәсең, үзе дә тиешенчә аңлатып бирә алмас иде. Василий Михайловичны күрдеме, шундук анда нидәндер курку, сагаю һәм үз-үзен якларга әзер булу тойгысы барлыкка килде. Менә әле дә, каршысында директорны күргәч, ул, ниндидер ярамаган эш өстендә тотылган кебек, куркуга якын бер тынычсызлык кичерде.

— Исәнмесез, Василий Михайлович!— диде ул, беренче булып, ясалма бер күтәренкелек белән.

Василий Михайлович та елмайгандай итте, парта арасыннан чыгып үзенә таба атлаган укучысына беренче булып кул бирде.

— А-а, Мухутдинов! Исәнмесез, исәнмесез,— диде.

Мондый көтелмәгән хәлдән Габделхәй тәмам каушап калды, кабаланып, ике куллап директорның сөякчел каты кулын тотып алды.

— Исәнмесез, Василий Михайлович!— диде, тагын да ялагайланып.— Күптән кайттыгызмы, Василий Михайлович? Без сезне көттек!

— Көткәнсездер — беләм,— диде директор.

Шулай диде дә нидер өстәмәкче булды, ләкин вакытында тыелып калды. Габделхәй аның ниндидер кирәкле сүз әйтергә укталып та әйтми калуын бик яхшы аңлады. Ул хәтта директорның нәрсә әйтергә тиешлеген дә белде. Бу, әлбәттә, «аттестат» булырга тиеш иде. Имтиханнарның барысын да Габделхәй «бишле»гә бирде. Уфага да документлар гел «бишле» белән китте. Василий Михайлович Габделхәйгә аттестат кына түгел, алтын медаль дә алып кайтырга тиеш иде. Бу хакта әллә ни шауламадылар, ләкин унынчылар да, укытучылар да, Габделхәй кебек үк, директорның алтын медаль белән кайтуын көттеләр. Яңавыл татар урта мәктәбеннән әле беркемнең дә алтын медаль алганы юк иде. Дөрес, моңарчы аның алтын медальгә торырлык укучысы булмады. Быел менә андый укучы бар. Ул да булса — Габделхәй. Бар өмет Габделхәйдә. Алтын медаль ул Габделхәйнең үзе өчен генә түгел, бөтен мәктәп өчен, барлык укытучылар коллективы өчен үзе бер бәйрәм булыр иде. Мәктәпнең дәрәҗәсе бермә-бер артыр иде.

Әйе, Василий Михайлович кайткан, әнә ул каршыда гына, якында гына басып тора, ләкин аның йөзеннән дә, сүзләреннән дә нишләптер бернинди куаныч тәэсире си-

зелми. Габделхәй моны бөтен күңеле белән тойды. Имтиханнарны тапшырып бетергәннән соң, Василий Михайлович документларны алып киткәннән соң төн йокыларын калдырган татлы хыяллар, бәхет, дан — барысы да кинәт юкка чыкты. Аның урынына күңелдә шыксыз, борчулы бушлык хасил булды.

Шулай итеп, директор әйтәсе сүзен әйтмәде, Габделхәйнең исә сорарга йөрәге җитмәде. Василий Михайлович партадагы дәфтәргә күз төшереп алды.

— Сез һаман шигырь язасыз икән,— диде ул.

— Язган булам шунда, Василий Михайлович,— диде Габделхәй, бөтенләй чит нәрсә турында сөйләнгән кебек.— Ошамый әле. Кичкә өлгертергә кирәк.

— М-да,— диде директор, берни аңлатмый торган бер мөңгерәү белән.— Кирәк дисез инде?..

Аттестат, медаль турында сүз кузгату урынсыз булган кебек, хәзер менә шигырь турында да сүз куерту урынсыз икәнлеген сизеп, Габделхәй сүзне тизрәк икенчегә борырга ашыкты.

— Бер-ике атна эчендә сез бик үзгәргәнсез, Василий Михайлович. Юлда йөрү килешкән сезгә,— диде ул, кирәгеннән артык кыюланып, ярарга тырышып.

— М-да, Мухутдинов,— диде тагын да директор.— Шигырь шигырь инде ул. Но, однако, сезгә бүген шигырь белән генә ярамый. Выпускной вечерда бүген Сафин иптәш тә булачак.

— Шулаймени?!— диде Габделхәй.— Без бит аңа делегация белән барганыек. Безне аның янына кертмәделәр. Әйттергән, киләлмим, вакытым юк дигән.

— Делегация оештыруыгыз дөрес булмаган, Мухутдинов,— диде Василий Михайлович, ярым шелтә белән.— Но, однако, Мунир Мухлисович киләчәк. Мин үзем сөйләштем аның белән. Үзем.

— Шәп булган, Василий Михайлович!— диде Габделхәй, куанып.

— Шәбен шәп тә, ул анда сезнең шигыregезне тыңлар өчен килмәячәк,— диде Василий Михайлович.— Выступление әзерләргә кирәк. И непременно урысча. Политически выдержанный. Йөзгә кызыллык китерерлек булмасын.

Мунавир Мухлисович райкомның беренче секретаре иде. Аның чыгарылыш кичәсенә килергә ризалык бирүе бик зур яңалык, бик зур шатлык иде, әлбәттә. Чыннан да, ул килә-нитә калса, барлык унынчылар өчен, бөтен мәктәп өчен бу чиксез зур дәрәҗә һәм тантана булачак иде. Мунавир Мухлисовичның хатыны Галия апа яисә

Галя Гатовна элегрәк Яңавыл татар урта мәктәбендә башлангыч классларда укытучы булган. Аны монда әле дә беләләр. Ләкин ире беренче секретарь булгач та, Галия апа балалар укытуын ташлаган һәм хәзер өйдә генә ята, беркайда эшләми бугай. Хатыны укытучы, үзе икенче секретарь чагында иптәш Сафин да мәктәпкә еш килгән. Беренче булгач менә килми башлаган. Бит алар, өстәгеләр, беркайчан астагылар, түбәндәгеләр белән буталмаска һәм һәрвакыт саф һәм дәрәҗәле килеш калырга тырышалар. Быел әнә килмәкче була икән. Ник? Бәлки, Василий Михайлович алтын медаль алып кайткандыр да медальне дә, аттестатны да беренче секретарь алдында бирергә җыенадыр? Бик астыртын кеше инде ул Василий Михайлович. Хәзер әнә берни сиздермәгән булып кылана. Анысы ярый, ләкин нишләп «выступление»не урысча әзерләргә куша соң ул? Беренче секретарь татар, хатыны татар, кунаклар татар, укытучылардан Антонина Семеновна да, немец теле укытучысы гына урыслар.

— Ләкин ни бит, Василий Михайлович...— диде Габделхәй, нәрсәдер каршы әйтергә җыенып.

— Никаких «ни»!— диде Василий Михайлович, кырт кисеп.— Әйтелгән — эшләгез!

Ялтыратылган күн итекләре белән шыгырт-шыгырт басып, директор ишеккә таба атлады. Тагып куйган кебек, Габделхәй аның артыннан иярде.

— Язып бетергәч тә минем янга керегез,— диде Василий Михайлович коридорга чыккач, ләкин шундук фикерен үзгәртте дә: — Впрочем, хәзер үк керегез. Бер биш кенә минутка,— диде.

## VI

Үзара сөйләшкәндә директор «Василий Михайлович» булса да, чынлыкта ул урыс та, керәшен дә яки анда чуаш та, мари да түгел иде. Ул чеп-чи татар иде. Аның чын исеме Вәсби, атасыныкы — Муллахан иде, фамилиясе бик борынгыдан килә торган Суяргуллар затыннан иде. Шул борынгыдан килә торган Суяргуллар затыннан булган Муллахан карт кайдадыр Борай ягында гомере буена җир тырнап иген иккән, мал-туар асраган ярлы гына, кара гына бер кеше булган. Күрәсең, атасы шундый кара игенче булганга, улы Вәсби шундый ак кеше булырга тырышкандыр да инде. Исемен бозып, урысчалатып әйткәнгә ул әз генә дә үпкәләми, ачуланмый да. Киресенчә, болай әйтү аның дәрәҗәсен генә күтәреп җибәрә сыман иде. Үзенең чукындырылган яңа исеменә

ул шул дәрәҗәдә күнегеп беткән иде, әгәр дә мәгәр берәр укучы «Василий Михайлович» димичә, «Вәсби абый» яки анда «Вәсби Муллаханович» дисә, директор абый, артык кызмыйча гына, шулай да җанга тия торган итеп, сеңдереп кыздырырга тотына торган иде. «Вәсби абый»ны укучылар түгел, укытучылар әйтсә, Василий Михайлович шулай ук һәр очракта төзәтергә, кисәтергә кирәк дип исәпли иде. Мондый чакта ул гадәттә: «Нинди Мулла, нинди Хан инде ул, Замила Галиахметовна?! Мин инде сезне предупреждать иттем... эндәшмәгез миңа шул... извините за выражение... авыл хатыннары кебек»,— дия торган иде.

Мәктәп директоры вазифасыннан тыш Василий Михайлович югары классларда физика, математика фәннәре укыта иде. Укытучы буларак, ул әллә ни мактарлык түгел, ләкин директор буларак бөтен районда, хәтта бөтен республикада иң булдыклылардан санала иде. Аның бөтен булдыклылыгы исә үзенә буйсынган һәркемне кулында кысып тотуга, югарыдан килгән күрсәтмәләрне бернинди каршылыксыз үтәүгә кайтып кала иде. Иң мөһиме — ул район җитәкчеләренең берсе белән дә телгә-тешкә килмәскә тырыша иде.

Район җитәкчеләре белән килешеп яшәсә дә, мәктәптә, үз коллективында аны бөтенләй диярлек хөрмәт итмәделәр. Берәүләр аны ачыктан-ачык дошман күрделәр, икенче берәүләр дошманлыкларын сиздермәскә тырыштылар. Мондый мөнәсәбәтнең сәбәбе, барыннан да элек, Василий Михайловичның үтә коры һәм формалист кеше булуына кайтып кала иде бугай. Үзе физика-математика укытучысы, хатыны химия укытучысы булганга күрә, ахрысы, аның өчен дөньяда бары физика-математика да химия генә игътибарга лаек фәннәр исәпләнелә ала иде. Аннары, әлбәттә, урыс теле.

Бу, билгеле, Василий Михайловичның шәхси карашы гына да түгел, бу бөтен илдә хөкем сөргән гомуми политика басымы нәтиҗәсендә барлыкка килгән мәҗбүрият иде. Менә шушы гомуми политик карашларны башкаларга көчләп тагарга тиеш булганга, Василий Михайловичның иң ачуын китергәне, эчен пошырып, үртәп торганы татар теле белән татар әдәбияты иде. Тумыштан татар булганга ук, билгеле, үзенең татарлыгын да оныта алмый, хәтта аны онытырга да теләми, шул ук вакытта, коммунист һәм җитәкче буларак, татарлыкны ул онытырга, аңа каршы килергә, аны дошман күрергә тиеш сыман иде.

Габделхәйнең шигырь белән пычранып утыруын

күргәч, аның күңелендә үзеннән-үзе яшьлек хатирәләре калкып чыкты. Бит кайчандыр ул да яшь булды, киләчәктә нәрсәдер кырмакчы булып, очынып-тилереп йөрде! Ул чакта әле хатын да, балалар да юк, җилкәңә таудай булып өелгән җаваплылык тойгысы да юк. Бары дәртле яшьлек бар да, тау-тау бәхетләр вәгъдә иткән матур киләчәк кенә бар. Хәзер инде яшьлек тә, дуслар-иптәшләр дә, хәтта киләчәк тә юк. Киләчәк ул беркайчан булмады бугай, «Киләчәк» дигән вакыт инде күптән килде, бары тик еракта н шундый матур булып күренгән бәхет тә, байлык та, дан-шөһрәт тә кайдадыр качып-посып калды.

Да, бар иде заманалар. Иң гаҗәбе шул, Вәсби Алдынский да, ягъни яшь чактагы Василий Михайлович та Мухутдинов кебек шигырь белән җенләнә иде. Да, да, рабфакта укыганда ул чын-чынлап шагыйрь булам дип тилереп йөрде. Начар да язмады. Рифмалары матур, килешле чыга торган иде. Ул вакытта күпләргә шигырь җене кагылган иде. Әле анда, әле монда шаулатып әдәби кичәләр үткәрәләр, бәхәсләшәләр... талашалар. Әх!..

Берзаман ул иптәшләре арасында талантлы шагыйрь саналып йөрде. Да, талантлы. Заманалар үзгәреп китмәсә, Вәсби Алдынскийдан менә дигән шагыйрь чыгар иде, мужыт. Сәхип әл-Назаридан, хәтта Такташтан, Кутуйдан да талантлырак шагыйрь чыгар иде. Но, однако, менә чыкмады. Бөтен эшне замана бозды. Бозылды замана. Юк, Вәсби Алдынскийдан шагыйрь дә, беркем дә чыкмады. Шагыйрь булу, бөек кеше булу турындагы хыял «тормыш кыясына» бәрелеп чәлпәрәмә килде. Дәрт сүнде, күңел суынды, күңелдә бары ачу, үртәлү дә, курку гына торып калды.

Рабфакта укыганда аның шигырьләре сирәк кенә булса да гәзитләрдә, журналларда басылды. Бер елны ул, тырышып-тырмашып йөри торгач, аерым җыентык чыгару бәхетенә ирешге. Шигырь җыентыгы. Китап. Вәсби Алдынскийның түбәсе күккә тиде. Китапны үз күзләре белән күреп, үз кулында тотып карагач, ул берничә көн кая басканын белми йөрде. Унысы бер белен калынлыгындагы китапларын кибеттән күпләп сатып алды да барлык таныш кызларына, дус-ишләренә бүләк итеп йөрде.

Шулай куанычтан исереп, кая басканын белми йөргән көннәрнең берсендә «Кояшлы иртә» исемле җыентыкка рецензия басылып чыкты. «Өч тиенлек шигырьләр» дип аталган рецензия азагына Гадел Тәрәшле дигән имза куелган иде. Да, Гадел Тәрәшле. Көнчел, ялагай, икейөзле дуңгыз. Дуңгызның да дуңгызы. Кешедә бары начар

якларны гына күрә торган, тирестә, б...та тибенә торган тавык кебек, шуннан үзенә тәм таба торган бер бәндә.

Әлеге рецензиядән соң Вәсби Алдынский шактый вакыт исенә-акылына килә алмады. Исенә-акылына килгән иде, шигырь язуга да, әдәбиятка да кинәт кенә күңеле сүрелеп куйды. Гадел Тәрәшленең кайбер сүзләре аңа хәзер дөрес сыман тоелды. Моны бары үз-үзенә танныйсы гына килмәде. Әкренләп ул шигырь язудан гына түгел, әдәбияттан һәм шигырьче иптәшләреннән дә читләшә башлады. Шулай итеп, әдәбият арбасына тагылып китә язган Вәсби Алдынский таулы-ташлы юлда очраган беренче дыңгырдыкта ук, тәгәрмәчтән чәчрәп калган каты ләпек кебек, читкә чәчрәп төшеп калды. И шуның белән котылып та калды. Утыз җиденче, утыз сигезенче елларда аның шигырьче иптәшләре, дус-ишләре, таныш-белешләре бербер артлы кулга алынганда ул инде әдәбият дөньясыннан бик еракта иде. Гадел Тәрәшледән дә усалрак, кансызрак тәнкыйтьчеләр аның «өч тиенлек» шигырьләр китабына нишләптер игътибар итмәделәр. Шомлы, дәһшәтле елларда Янавыл кирпеч заводында кара эшче булып эшләгән Вәсби Суяргулов барысын да белеп-ишетеп торды.

Кирпеч заводына ул тикмәгә генә кермәде. Нәрсә буласын алдан сизенгән сыман, укытучылыгын ташлап, монда ул үз теләге белән керде. Барлык тимер юлчылар кебек, кирпеч заводы эшчеләре начар яшәмиләр иде. Тимер юлчыларның ашау-эчү дә яхшы, кием-салымга да мохтаҗлык юк. Тимер юлчыга һәртөрле талон бирелә. Аларның магазиннары аерым, мәктәпләре, клублары аерым, хәтта икмәк заводы да, электр станциясе дә — барысы да аерым, барысы да аларныкы. Тирә-яктагы авыл халкы, Янавылның ярлы-ябагае черек бәрәңге ашап шешенгәндә, тимер юлчылар пох! итеп яшәделәр. Вәсби Суяргулов та бернинди мохтаҗлык күрмәде. Дөрес, монда ул үзен һәрвакыт качкын итеп, яшеренеп ятучы итеп тойды. Кемдер аның элекке эшләрен белеп алыр да, тиешле җиргә барып әйтер һәм көтмәгәндә тиешле җиргә алып та китәрләр сыман тоелды. Кайчан алып китәрләр — төнләме, таң алдыннанмы, әллә көпә-көндез эш вакытындамы, аның өчен бөтен мәсьәлә шуңа кайтып калды.

Шул рәвешчә куркыныч утыз җиденче, утыз сигезенче еллар да узып китте. Кулга алулар турында бик үк ишетелми башлады. Сугыш башланыр алдыннан Вәсби Алдынский тәмам тынычланып калды. Аллага шөкер, исән калды, ахрысы. Сугыш башлангач исә бөтенләй икенче борчулар китте. Да, уйласаң чәчләр үрә торырлык. Күрде мескен башлар!

## VII

Коридордан шыгырт-шыгырт атлап барганда Василий Михайлович, әйтерсең, берни күрмәде. Кабинет ишеге алдында туктап, гадәтләнгән бер хәрәкәт белән кесәсеннән ачкыч чыгарды да ашыкмыйча гына йозакны ачты һәм үз артыннан ишекне ябып кабинетына керде. Директорның шулай берни әйтмичә кабинетына кереп китүе, җитмәсә, ишекне шапылдатып ябып куюы Габделхәйгә гаҗәбрәк тоелды. «Үзе чакырды, үзе артына борылып та карамады»,— дип уйлады ул, хәтере калып. Нишләргә белми көтеп торгандай иткәч, кыюсыз гына ишек шакыды.

— Да!— диде эчтән Василий Михайлович, «керегез» дигәнне аңлатып.

Габделхәй керде, түргәрәк узды, бернинди япмасы булмаган озын шәрә өстәлнең бер кырыенда тукталып калды. Василий Михайлович өстәл тартмасын ачып бик игътибар белән аннан нидер эзләргә тотынды. Ниһаять, ул кирәкле әйберсен тапты, өстәл тартмасын кире ябып куйды, бикләде дә башын калкытты һәм ике куллап иягенә таянды.

— Беләсезме, ник чакырдым мин сезне?..— диде ул, бераз көттереп.— Шигыregезне күргәч исемә төште... бер серьезно сөйләшергә кирәк сезнең белән. Сез безнең иң алдынгы, талантлы укучыбыз, Мухутдинов...

Габделхәй үзенең алдынгы, талантлы укучы икәнлеген белә иде, ләкин аның бу турыда беркемгә кычкырып әйткәне дә, сиздергәне дә юк иде шикелле. Ул моны сер сыман итеп бары күңелендә генә саклый иде. Үзе сер итеп тоткан яшерен нәрсәне чит кеше авызыннан — мактауга саран директор авызыннан ишеткәч, аның өчен бу көтелмәгән яңалык булып тоелды. Шатлыктан аның йөрәге җилкенеп куйды. Шулай да көтелмәгән шатлык тойгысы ташып чыкмасын өчен, ул тыелыбрак торырга кирәк тапты. Чынында ул Василий Михайловичның моннан да зуррак, куанычлырак хәбәр әйтүен көтте. Директорның өстәл тартмасында нидер эзләве дә аңа тикмәгә генә түгелдер шикелле тоелды. «Медаль турында әйтмәкче була» дип уйлады ул шундук үзалдына. Ләкин нишләп шулкадәр көттерә, ялындыра соң ул? Медальнең алтыны булмады, көмеш кенә булды дип әйтмәкче була микәнни соң?

Василий Михайлович тагын күпмедер көттереп торгандай итте дә әкрен генә сүз башлады:

— Ладно, унны бетердегез, аттестат алдыгыз — даль-

ше нишләргә, кая китәргә исәп?— диде ул, дәрес сорагандагы кебек.

— Ныклап уйлаган юк әле, Василий Михайлович,— диде Габделхәй, теләр-теләмәс кенә.

Ул ялганлады һәм шул ук вакытта ялганламады да. Ул үзен шагыйрь булырга, нииндидер бөек кеше булырга тиеш дип исәпләде. Моңа инде ул күптән күнеккән иде, шуңа күрә бу яшерен хыялының кайчан да булса тормышка ашачагына әз генә дә шикләнми иде. Ләкин, никадәр гаҗәп булмасын, шушы көнгә кадәр әле ул киләчәктә нишләргә тиешлеге турында да, ничек итеп хыялын тормышка ашырачагы турында да белми иде. Бу турыда кем белән булса да фикер алышырга аның кыюлыгы җитмәде. Укытучылар исә үзләре белеп аннан берни сорашмадылар. Алар, гомумән, аның киләчәге белән дә, хыяллары-ниләре белән дә кызыксынмадылар. Алар бары үз өсләренә төшкән бурычларын гына үтәделәр: дәрес укыдылар, дәрес сорадылар, билге куйдылар, кайчагында саран гына мактау сүзләре әйттеләр, кайчагында шелтә белдерделәр. Әгәр дә мәгәр Мухутдинов Габделхәй мәктәптә «иң алдынгы, талантлы» укучы булмаса, Василий Михайлович, бәлки, аны үз кабинетына чакырып та тормаган булыр иде һәм «алдынгы, талантлы» булмаган бик күп укучыларны моңарчы кулларына шыгырдавык кәгазь тоттырып, дүрт ягың кыйбла дигәндәй озатып калган кебек, аны да шулай озатып калу ягын карар иде.

— Шагыйрь булыргамы исәп, Мухутдинов?— диде директор, көлемсерәгәндәй итеп.

— Шулай инде, Василий Михайлович,— диде Габделхәй, кызарынып.— Сез бит беләсез... әдәбиятны яратам... шигырь язам.

— М-да. Однако, сез физиканы да яратасыз!— диде Василий Михайлович.

— Әдәбиятны ныграк яратам,— диде үзсүзле Габделхәй.

— Нәрсә яратканлыгыгызны сез әле үзегез дә рәтләп белмисез, Мухутдинов,— диде директоры, шактый коры итеп.

Габделхәйгә бу бик сәер тоелды. Үзенең нәрсә яратканын үзе дә белмәскә шулкадәр аңгыра микәнни соң ул? «Алдынгы, талантлы» укучы шулай аңгыра булырга тиеш микәнни?! Шулай да ул эндәшми калды. Василий Михайлович белән бәхәсләшү, нәрсәгә булса да аны ышандырырга тырышу, гомумән, читен нәрсә иде.

— Сез әле яшь — күп нәрсәне аңлап та җитмисез,—

диде директор, кырыслыгын йомшарта төшеп.— Яшь чакта яраткан нәрсәң соңыннан онытыла. Но кайчакта шулай да була: акыл кергәч карашлар, теләкләр үзгәрә, бөтен нәрсәнең, асты өскә килә. Киләчәктә шулай булмасын өчен сезнең яшьтә олылар сүзенә колак салу мишәйт итми. Сезгә караганда мин күбрәк яшәгән, күбрәк күргән. Тормыш тәҗрибәсе дә җитәрлек, Аллага шөкер. Бишектәге бала бишкә төрләнә, диләр картлар. Була бит шулай? Була!

— Буладыр,— диде Габделхәй.

— Секрет итеп мин сезгә шуны әйтим,— диде Василий Михайлович, бөтенләй үз кеше булып.— Һәрбер талантлы кеше яшь чагында шигырь яза. Шигырь язу гына шагыйрь булу дигән сүз түгел. Беләсезме, сезнең кебек чакта мин дә шигырь яздым.

— Сез дә?!— диде Габделхәй, исе китеп.

Василий Михайлович эндәшмичәрәк утырды.

— Да, Мухутдинов мин дә,— диде аннары дәртсез, шыгырдавык бер тавыш белән.— Как это не удивительно, яздым. Сезне мактаган кебек, мине дә мактадылар, шигырьләремне газеталарда, журналларда бастылар. Даже бер китап та чыгардым. Но мин вакытында акылга утыра белдем. Шигырьгә дә, әдәбиятка да кул селтәдем. Хәзер менә шуның өчен сөенеп бетә алмыйм.

— Шуның өчен... сөенеп? Ник?— диде Габделхәй, аптырап.

— Никме?— диде бераздан Василий Михайлович.— Если ул вакытта мин профессионал шагыйрь булып киткән булсам...— «мине сөргенгә сөрерләр иде» димәкче булды ул, ләкин укучысы алдында болай дип әйтергә ярамаганлыгын тиз арада шәйләп алды һәм башкачарак юнәлештә дәвам итте: — ...ул чагында, беләсезме, ...ну, ул чагында миннән Тукай да, Такташ та чыкмаган булыр иде. Беләсезме, обществога файдалырак кешеләр кирәк. Шагыйрьләрнең хәле икеле-микеле аларның. Гомергә шагыйрь булып яшәп тә булмый. Мин менә физика-математика факультетын бетердем. Физиклар, математиклар, химиклар һәркайда, һәркайчан кирәк. Везде и всегда. Общество шуны сорый. Хәзер шигырь, әдәбият заманы түгел. Пушкиннар, Тукайлар заманы күптән узды. Техника заманы хәзер. Атом заманы. Век атома! Кая карама — машина, кая карама — техника. Техника шигырьне, әдәбиятны, йомшак күңелле кешеләрне кысрыклап чыгара. Сез инде бала түгел, сезнең белән ачыктан-ачык сөйләшергә була. Беләсезме, ни өчен Пушкиннар, Тукайлар юк? Икенче Пушкиннар, икенче Тукайлар... менә шуның өчен. И алар булмаячак та! Кай-

чандыр Англиядә сарыклар кешеләрне «ашап» бетергән кебек... ул турыда беләсез ич... вот... хәзер дә техника шигырьне, шагыйрьне... әдәбиятны, культураны, даже бөтен халыкларны, нацияләрне ашап бара. Менә шундый заманда шагыйрь булу турында хыяллану, извините за выражение, глупость булыр иде.

Василий Михайлович гадәттә булмаганча бик нык җанланып, хәтта кызып-кызып сөйләде. Күрәсең, бу аның күптән уйлап йөри торган, күптән инде чын күңелдән инанган фикерләре иде. Менә ул тынып калды һәм үз сүзләренең ничегрәк тәэсир ясавын белергә теләгән кебек, укучысына күз төшереп алды. Ул аның берәр каршы сүз әйтүен көтте, әгәр дә мәгәр Габделхәй каршы сүз әйтсә, үзенең шундук яңа көч белән кызып китәчәген, ахмак җегет алдында дөрес һәм логичный фикерләрен киңрәк, тирәнрәк итеп аңлатырга мәҗбүр булачагын уйлап алды.

Ахмак җегет эндәшмәде. Аның карашынча, әдәбият турында, шигырь язу-язмау турында бары әдәбият укытучысы Фәрхәнә апа белән генә, аннары «Коммунизм юлы» редакторы Разия апа белән генә сөйләшергә була иде. Бу мәсьәләдә бөтен Яңавылда алардан да ышанычлырак кеше дә юк иде. Шуңа күрә директорның шундый ачы, зәһәрле сүзләре анда бары шикләнү, сагаю һәм ачу гына тудырды. Василий Михайловичның беркайчан икенче Пушкиннар, Тукайлар булмаячак дигән сүзләренә каршы аның үч итеп, ачу итеп: «Менә мин булачакмын!» — дип кычкырасы килде. Ләкин ул кычкырмады. Бу кабинетта, мондый сөйләшү вакытында ул үзен ничек тотарга кирәклеген чамалый алды һәм физика-математика укытучысы әдәбият турында, шагыйрьлек турында нинди генә кимсеткеч сүзләр әйтсә дә, бернинди коткыга бирелмәскә дип күңеленә беркетеп куйды.

— Сезгә берәр технический вузга китәргә кирәк, Мухутдинов,— диде Василий Михайлович, яңадан сүзгә башлап.— Сез математикадан, физикадан начар укымадыгыз. Тагын бераз тырышсагыз, шигырьләрегезне онытып торсагыз...

— Шигырь язуны мин ташламаячакмын, Василий Михайлович,— диде Габделхәй әкрен генә, ләкин нык итеп, үз-үзенә ышанып.

Беркайчан көлми торган Василий Михайлович башын чайкап, үз-үзеннән канәгать булып, көлеп куйды:

— Да, сез шунысын да учтите,— диде ул, яшь җегетнең киреләгенә әз генә дә игътибар итмәгән сыман.— Сез бит татарча язасыз. Онытмагыз, татар теленең хәзер бернинди значениесе юк. Татар теле авыл капкасын чыкканчы гына кирәк ди торганые минем этәй. И дөрес әйткән. Бу бит

әле теге заманда. Элек. Татар теле хәзер авыл капкасын чыкканчы да кирәкми. Ул бары авыл хатыннары, картлар теле генә. Ун-унбиш җылдан алар да үлеп бетәчәк. Илле җылдан бер татар калмаячак. Понимаете шуны?!

## VIII

Яңавыл татар мәктәбе директорының татар теленә, татар әдәбиятына кагылышлы фикерләрен Габделхәй болай да белә иде. Элегрәк тә бу хакта аңа Василий Михайлович белән әйткәләшеп алырга туры килгәне бар иде. Ләкин директорның әле беркайчан да укучысы алдында үз карашларын шундый ачык итеп, шундый куркыныч һәм оятсыз итеп әйтеп биргәне дә, татар теленә карата ачыктан-ачык шундый кимсеткеч сүзләр сөйләгәне дә юк иде бугай. Директор кешенең, шундый чиста, пөхтә итеп киенгән кешенең, бу рәвешчә сөйләнүе Габделхәйгә чиктән тыш ят һәм кыргый булып тоелды. Бөтен тәне, бөтен әгъзалары белән бөрешеп, ул бер йодрыкка укмашып калды.

— Татар беткәч... кем генә калыр соң дөньяда?— диде ул, еш-еш тын алып.

— Анысын тарих күрсәтер. История покажет,— диде Василий Михайлович.— Киләчәктә бөтен дөньяда бер генә тел булачак. Так вот, иптәш Сталин әйтә: ул тел немец теле дә булмас, француз, инглиз теле дә булмас, ди. По всей вероятности, ул урыс теле булыр. И без шуңа барабыз да. Киләчәктә бары урыс теле генә булачак. Башта Советлар Союзында, аннары — бөтен дөньяда. Бу безнең интернациональ бурыч. Без, татарлар, үз телебездән никадәр тизрәк баш тартсак, шулкадәр яхшырак булыр. Тизрәк без мировой культурага ирешәчәкбез.

— Мин моны аңлый алмыйм,— диде Габделхәй.

— Согласен, аңлавы читенрәк,— диде Василий Михайлович.— Но однако, тормыш шуны күрсәтә. Киләчәктә аңларсыз әле. Хәзергә сез — шагыйрь, татар шагыйре! Если сез турыдан-туры урысча язсагыз, тогда дело другое.

Директорның авыз тутырып «шагыйрь», «татар шагыйре» дип әйтүе Габделхәйнең күкрәгенә килеп тыгылган авыр ташны ычкындырып җибәрде. Аңа хәзер тын алуы җиңелрәк була башлады.

— Мин бит татарча укыдым, татарча язарга өйрәндем!— диде ул, Василий Михайлович белән хәтта бәхәсләшергә әзер булып.

— Вот-вот! Безнең бөтен бәла дә шунда,— диде директор.— Сезнең кебек талантлы кешеләрне татар мәктәбе харап итә дә инде. Сезне генә түгел. Элек мәдрәсә харап

иткән кебек, вапшем безне татар мәктәбе харап итә. Без сезне укытабыз, тырышабыз, государство күпме акча түгә, однако, результат нинди? Соңгы өч-дүрт ел эчендә безнең Яңавыл татар мәктәбен бетереп чыккан йөзләп укучының күпмесе вузга керә алган дисез? Күп булса, унлап кеше. Алары да разный пединститут, сельхоз, ветеринария... тоес мал врачлары, картлар әйтмешли, бет бырачлары. Вот вам простая арифметика! Ә технический вузларга, физика-математика факультетларына — ни одного! Оят бу безнең өчен. Киләчәктә болай булмаячак. Безнең өчен иң дөрес юл әкренләп татар мәктәпләрен урысчага күчерә бару. Беренче класстан башлап унга кадәр. Шәһәрләрдә генә түгел, барлык авылларда. Бары шул чагында гына без Москва, Ленинград вузларына керә алырлык укучылар әзерли алырбыз. Сезнең белән ачыктан-ачык сүләшергә була. Национальный мәктәп мәсьәләсендә безнең политика шундый. Чуашларда, мари, удмуртларда күптән чын мәгънәсендә үз телләрендә урта мәктәпләр юк. Начальный классларда гына, кайберсендә җидегә кадәр генә үз телләрен предмет буларак укыталар. Төньяктагы чукчаларда үз телләрендә башлангыч класслар да юк. Сплошь урысча.

— Алайса Москва, Ленинград вузларында чукчалар гына укыйлардыр хәзер?— диде Габделхәй, усал итеп.

Василий Михайлович ишетмәмешкә салынды һәм бер башлаган сүзен очлыйсы килеп:

— Татариядән, Башкириядән, чит өлкәләрдәге татар авылларында да күп мәктәпләр урысчага күчте,— диде.— Аларның кайберләрен утыз җиденче, утыз сигезенче елларда ук яптылар...— Үзенең кирәкмәгәнне сөйли башлавын аңлап, ул беразга тоткарланып калды, тынып торды да: — Так вот,— диде,— башка җирләрдә татар мәктәпләре дә бетә. Без кемнән ким? Нигә безгә артка калырга? Без үзбәк тә түгел, әрмән, грузин да түгел. Без — татарлар! Без беркайчан сыната торган халык түгел!

Үзенең чамадан тыш кызып китүен күреп, Василий Михайлович кинәт тынып калды. Галифе кесәсеннән зур кульъяулык чыгарып тирләгән маңгаен сөртте, аннары кульъяулыгын авызы янына китерде дә «кых!» итеп җиңелчә генә төкереп куйды һәм беләгендәге сәгатенә карап алды.

— Ладно, шуның белән бетереп торыйк,— диде.— Шулай да уйлап карарга кирәк, Мухутдинов.

— Уйлармын. Шулай да...— диде Габделхәй.

Әйтәсе сүзен ул әйтеп бетермәде — беренче булып урыныннан кузгалды. Бүтән вакыт булса, Василий Михайлович аны кире урынына утыртыр һәм өстәл пыяласын шакылдатып: «Чтоб это было в последний раз! Иди-

те!»— дип куалап чыгарыр иде. Ләкин хәзер ул алай итә алмады. Ул хәтта киребеткән укучысының тупаслыгын да йотарга мәҗбүр булды һәм чыгарга рөхсәт итеп:

— Барыгыз, выступлениегезне языгыз,— диде аталарча.

## IX

Габделхәй кызарынып-бүртенеп ишектән килеп чыкты һәм, күзенә ак-кара күренмәгән килеш, коридордан китеп барды. Коридорда аңа Антонина Семеновна очрады. Рус теле укытучысы гадәтенчә өстенә ак кофта, кара юбка кигән, кыска, сыек — саргылт чәчләрен күпертеп, тырпайтып куйган иде. Габделхәй аны ничектер күзгә-күз килеп бәрелешә язгач кына күреп алды, ясалма елмаеп кычкырып исәнләште дә читкә тайпылды.

— Василий Михайлович кыздырган, ахрысы, сезне, Мухутдинов,— диде Антонина Семеновна, дусларча ярым шаяртып.

— Кыздырды... Юк, кыздырмады. Болай гына,— диде Габделхәй, буталып.

— Василий Михайлович андамы?— диде Антонина Семеновна, сүз өчен сүз булсын дигәндәй.

— Анда,— диде Габделхәй, ерагая барып.

Ул озын коридорның аргы башына кадәр барды, сул яктагы соңгы ишекне ачты да яңадан үзләренең класс бүлмәсенә — физика кабинетына барып керде. Яңадан ул үзенең тәрәзә янындагы, иң арттагы таныш партасына барып утырды һәм яңадан шигыренә тотынмакчы булды. Ләкин аның хәле хәзер шигырь язуга җайланырлык түгел иде. Хәзер аның бер нәрсәгә дә күңеле бармады. Хәзер аның кәефе бозылган, күңеле кырылган, барлык хыяллары, өмет-теләкләре чәлпәрәмә килгән иде.

Аякларын сузып, аркасы белән партаның арткы тактасына бик нык терәлеп ул шактый озак утырды. «Медаль турында сорарга онытканмын!»— диде ул бераздан, уйлана башлагандай итеп. Шунда да сорамагач, кайчан сорыйсың тагын? Кичкә кадәр көтәргә туры килә. Яисә Антонина Семеновнадан сорыйсы калган. Ул беләдер, сер итеп кенә әйтер иде әле. Юк, кирәкми. Әгәр синең мәктәбең, телең бетә икән, әгәр сиңа татарча шигырь язу ярамый икән, нәрсәгә кирәк ул медаль-фәләннәр? Медальсез дә ул барыбер Казанга китәчәк, барыбер шагыйрь булачак. Монысы инде хәл ителгән... ташка уеп язылган.

Ләкин хәзер менә күңеле кырылган бер вакытта ул шигырь язу-язмау мәсьәләсендә билгеле бер карарга килде. «Язмыйм. Шигырен дә, выступлениесен дә,— дип уй-

лады ул, тыелгысыз бер кирелек белән.— Барлык телләрне бер телгә калдырырга тырышучыларга... синең телеңә, җаныңа тел тидерүче агач директорга үч итеп язмыйм!»

Мондый фикергә килгәч, аңа ничектер җиңел булып киткәндәй тоелды. Шул ук вакытта эчтә, күңелдә бушлык хасил булды. Аның хәзер каядыр барасы, нидер эшлисе килде. Класс бүлмәсендә, парта арасында утырып кына берни эшләп булмый иде. Ул ашыгып коридорга чыкты. Директор кабинеты яныннан үткәндә ничек тә ул якка карамаска һәм ничек тә ул турыдан тизрәк узып китәргә тырышты.

Урамга чыккач, ул, уңга китимме, сулга китимме дигәндәй, беравык икеләнеп торды. Сулга китсә, кызлар артыннан болынга барып чыгачак иде: баягынак ул тәрәзәдән аларның болын ягына китеп барганнарын күреп калды. Уңга китсә, тимер юл станциясе ягына барып чыгачак иде. Икеләнүен җиңеп ул уңга китте. Тигезле-тигезсез урамнар читеннән атлап бара торгач, озакламый тимер юл вокзалы буена барып җитте.

Тимер юл возкалы Яңавылда иң күңелле урыннарның берсе иде. Көннең, төннең кайсы вакытында килмә, тормыш монда беркайчан тукталып тормый. Вокзал ишеге һәрвакыт ачык. Вокзал алдында җигүле ат-арба, каядыр китүче, каяндыр кайтучы капчыклы, чемоданлы кешеләр була. Монда үзенә бертөрле исләр килә, үзенә бертөрле тавышлар ишетелә. Агач-күмер төялгән, комбайннар, танклар, станоклар төялгән кызыл вагоннарын тартып, өй тәүмәлеге паровозлар узып киткәндә, аяк астындагы җир селкенә, вокзал тәрәзәләре калтырый. Иң күңеллесе — пассажир поездлары. Алар каяндыр ерактан — зәңгәрләнеп торган кырлар, урманнар, аксыл болытлар ягыннан киләләр. Чаж-чож итеп, як-ягына кайнар пар бөркеп килгән тимер паровоз «телеграф» йортын узып туктау белән, шыгырдап вагоннар да туктый. Вагоннардан бәхетле якларга юл тотучы бәхетле кешеләр коела. Алар арасында бәрелеп-сугылып йөрүе дә күңелле. Аларның киеменә, йөзенә карыйсың, аларның сүзләренә колак саласың. Алар һәрвакыт ашыгалар. Җиргә аяк басу белән, кайберләре бидон, бидерә тотып кайнар суга йөгерә, кайберләре якындагы базар ягына ашыга, кайберләре перрон буена — аяк асларына бидерәләрен, кәрзиннәрен куеп, кулларына күбәтә тотып, юка гына көлчәләр, бәрәңге кәлҗемәләре сатып торган Яңавыл эспикүләннәре тирәсенә җыела. Алар беркайчан сатулашып тормыйлар. Аларның акчалары унлык та утызлык, йөзлек. Аларның өс-башлары менә дигән — бер җире тузмаган, бер җире ямалмаган.

Паровоз кычкыртып кузгала башлау белән, алган нәрсәләрен кадерләп тоткан килеш, алар вагоннарга йөгерәләр. Вагонга утырыр алдыннан бераз гына ыгы-зыгы булып ала. Вагон әкрен генә кузгала бара, кызулый башлый. Бу вакытта инде барысы да утырып бетә, ләкин шул чакны соңга калган берәрсенең ашыгып йөгерүен күреп алалар да кычкыра, көлешә башлыйлар. Соңга калучы исән-имин тоткага килеп ябыша. Аны, күтәреп алгандай, тартып менгезәләр. Вагоннар кызулаганнан-кызулый бара. Иң азакта кулына төреп саргылт флагын тоткан проводник хатын һәм ике зур түгәрәк күз сыман булып буфер тәлинкәләре генә күренеп кала. Паровоз, моңсу һәм сагышлы итеп кычкырта-кычкырта, зәңгәр билгесезлеккә китеп югала.

Хәзер дә Габделхәй перронда озак кына бәлтерәп йөрде дә, станциядә туктамыйча җилләнеп кенә узып киткән товарный вагоннарын санап, басып торды. Шуннан соң Себер, Урал якларыннан килүче пассажир поездын көтеп алды. Пассажир поезды киткәч, бөтен дөнья бушап калгандай булды.

Әле булса күңеле тынычлана алмаган ялгыз җегеткә монда да күңелсез була башлады. Ул яңадан үзләренең мәктәпләре ягына борылды. Перронда төрле ашамлыклар күргәч, төрле кызыктыргыч исләр иснәгәч аның өздереп-өздереп ашыйсы килде. Ләкин әлегә ашау турында уйларга иртәрәк иде. Әлегә аны онытып торырга һәм ашауга кадәрге буш вакытны ничектер уздырып җибәрергә кирәк иде. Моның өчен базарга кереп, анда-монда карангалап, шулай ук халык арасында бәрелеп-сугылып йөрергә була иде. Дөрес, бүген базар көн түгел, ләкин анда беркайчан кеше өзелеп тормый. Саталар, алалар, кычкырып сөйләшәләр. Анда күбрәк авыл халкы. Ярлы халык, ач һәм томана халык. Шулай да үз халкың.

Хәзер аның нишләптер базарга да кереп торасы килмәде, Яңавылның иң зур магазиннары, райком, райбашкарма, Сталин клубы һәм шундый «хөкүмәт йортлары» урнашкан Ленин урамындагы универмагка да керәсе килмәде. Аның күңеле һаман мәктәп ягына тартты. Аның өчен бөтен Яңавылда иң якын җир бары шунда гына иде.

## X

Болыннан кайтып килүче кызларны ул ерактан ук күреп алды. Күреп алды да адымын кызулата төште. Юк, дөньяда әле бөтенләй үк күңелсез түгел иде, дөньяда әле яшәргә, язарга һәм нәрсәгәдер өметләнергә була иде бугай. Елмаеп

ул кызлар каршысына китте. Кызларның һәркайсы кулларына болыннан җыеп алган чичкә тоткан. Чак-чак кына арыган, йончылган күренәләр, шулай да һәркем шат, көләч. Төркем алдыннан гадәттәгечә Җәмилә килә.

Кызлар да аны ерактан ук күреп алдылар, ачуланган булып, шелтәләп, оялтып нидер кычкырган булдылар. Барысы да бергә кычкырганга, аларның сүзләрен аермачык аңлап та булмады. Кызлар белән ара бик нык якынайгач, Габделхәй кырт кына борылды да мәктәп ягына китте. Кызлар аннан көләргә тотындылар.

— Курыкты! Курыкты!— дигән сүзләр ишетелде.

Габделхәй исә мәктәпкә керә торган бәләкәй капка янына туктады да кызларның килеп җиткәнен көтеп тора башлады. Кызлар килеп җитү белән ул эчке якка керде һәм капканың келәсен эләктереп куйды.

— Билетыгыз бармы? Билетсыз кертмим!— диде Габделхәй, беренче булып килеп җиткән Җәмиләнең юлына аркылы төшеп.

— Кит әле!— диде Җәмилә һәм җиңел генә капкадан кереп китмәкче булды.

— Әйттем бит — билетсыз кертмим!— дип кычкырды Габделхәй, батыраеп.

Ул арада башкалар да килеп җиттеләр, кычкыра башладылар. Җәмиләнең тавышы ныграк ишетелде. Бер кулын капка ярыгыннан тыгып келәне ачарга азапланганда, икенче кулы белән Җәмилә рәшәткә тактасына тотынды. Болыннан яңа гына өзеп алган хуш исле чичкәләр Габделхәйнең битенә үк килеп тигәндәй булды. Шул чакны ул Җәмилә кулындагы чичкә бәйләмен тартып алды да читкә йөгереп китте.

— Билләһи газим!— диде Җәмилә, ярсып.

Капканы каерып ачты да томырылып Габделхәй артыннан ташланды. Алар куыша-куыша бөтен ишегалдын әйләнеп чыктылар. Габделхәй үзендә искиткеч җиңеллек тойды. Җир өстендә аунап яткан утыннар, буш бидерәләр өстеннән, туарылган арба, чүп, тирес өемнәре яныннан ыргылды гына. Ара-тирә артына борылып карады. Баштарак Җәмилә бик нык артта калган сыман тоелган иде, ләкин куа килүченең аяк тавышлары озакламый якынайганнан-якыная барды. Бер әйләнеп каравында ул бик якында гына Җәмиләнең кызарынган ачулы йөзен күреп алды. Шул чакны Габделхәй, малайлар белән куышкандагы кебек, кырт кына борылды да, менәменә куып җитәргә, тотып алырга тиешле кызны аптыраишта калдырып, кирегә йөгереп китте. Шатлыгыннан ул көлеп җибәрде, ишегалды уртасындагы физкультура

мәйданчыгына таба китте, атынгыч баганалары янына җиткәч артына борылды һәм җиңүче төс белән:

— Тоталмадың!— диде.

— Бир!— дип кычкырды кызарынган Җәмилә.

— Мә!— диде Габделхәй, багана артына качып. Кулындагы чичкә бәйләмен ул кызга таба сузгандай итте, Җәмилә тотып алам дигәндә генә кире тартып алды да янә качып китте.

— Бир диләр сиңа, бир!— дип кычкырды Җәмилә.

— Тоталсаң — синеке!— диде Габделхәй.

Физкультура мәйданчыгыннан ул мәктәпнең тәҗрибә участогы ягына — җиләк-җимеш бакчасы ягына йөгерде. Ачудан Җәмиләнең йөрәгенә капты, хәле бетте, ләкин хәзер аның җиңел генә чигенәсе дә килмәде. Шундый яратып, тырышып җыйган чичкәләрен кире тартып алмаса, аңа хәзер бөтенесе алдында хурлык булыр сыман тоелды. Әнә алар — кызлар-малайлар — читтән генә карап-күзәтеп торалар, эт үскеткән кебек төрле сүзләр кычкырган булалар. Кайберләре хәтта Габделхәйгә ярдәмгә ташланды.

Җиләк-җимеш бакчасы директор өе белән абзар-куралар арасындарак иде. Габделхәй бакча капкасы янына җитте дә яртылаш ачык калдырылган капкадан эчкә керде һәм үзен куа килүче кызларның борын төбендә генә келәне эләктереп куйды.

— Бирәсеңме, юкмы?— дип кычкырды Җәмилә.

Габделхәй чичкәле кулын әле югары күтәрде, әле читкәрәк алды һәм Җәмиләнең ачудан, нәфрәттән очкынланган күзләренә карап шигырь такмаклады:

— Су анасы мин. Китер, кайда минем алтын тарак?
Бир! Бая көндез алып качты синең углың карак!

— Үзең барып җыялар аны бик кирәк булгач! Ялкауланып ятмыйлар,— диде Җәмилә, зәһәрле итеп.

Габделхәйне нидер өтеп, чеметеп алгандай булды. Беркайчан үзенә чын-чынлап ачулана алмас дип, ни әйтсәң дә, нәрсә эшләсәң дә кичерер, гафу итәр дип уйлап йөргән Җәмиләнең, үзен хәтта яшертен генә яратып йөргән Җәмиләнең усал сүзләренә шагыйрь җегет аптырап калды. Бөтен күңелен биләп алган дәрте, тилелеге төртеп тишкән куык кебек кинәт пыш-ш! итте.

— Мә. Эчеңә бәйлә,— диде ул, кулындагы печәнне киртә аша ыргытып.

Аның күңеле кырылды. Дөнья яңадан күңелсезләнеп, кызыксызланып калды. Җәмилә үзенең кадерле нәрсәсен тотып алды. Тотып алды да ашыгып китеп барды. Аның да күңеле кырылды, җылыйсы килде, ләкин

бөтенесе авызын җырып карап торганда күз яшьләре күрсәтү җегетлек түгел иде, әлбәттә.

— Нәрсә, күрмәгәндәй карап каттыгыз?!— диде ул, ачу белән иптәшләренә.

Авыраеп, төссезләнеп-тоныкланып калган чичкә бәйләмен ул киртә аша карагат, кура җиләк куаклары арасына ташлады да читкә китеп барды. Ә бит ул аны чынлыкта Габделхәйнең партасына утыртып куярмын, бәлки, диебрәк җыйган иде.

## XI

Уку бетәргә бер ай чамасы вакыт калгач, башка еллардагы кебек, Василий Михайлович быел да чыгарылыш кичәсе үткәрү өчен әзерлек эшләренә кереште. Эшне ул гадәттәгечә таныш-белешләреннән башлады. «Заготзерно»да склад мөдире булып эшләгән бер танышы мәктәпкә күчтәнәч итеп ярты пот ак он бирде. Кошчылык комбинаты шулай ук үз кеше иде — анысы ике йөз күкәй бирде, ит комбинаты бухгалтериясендәге «сеңлем Тәгъзимә» биш кило колбаса, күп кенә эчәк-бавыр бирде. Май комбинатында Василий Михайловичның якын танышлары юк иде, шуңа күрә майны базардан алырга, аннары «раймаг»тан теләнергә туры килде. Бөтен районда атаклы «Байрак» колхозы председателе иптәш Дәүләтбаев бер симез сарык җибәрде. Укытучыларның үзара җыйган акчаларына мәктәп дирекциясе биргән фәлән тиеннәрне куштылар да эчемлеген, конфетын-мазарын юнәттеләр. Укучылардан бер тиен дә алынмады. Шулай итеп, чыгарылыш кичәсенә шактый мул табын әзерләнде.

Җәйге кояш сүрелеп яктысы, кызуы кими башлагач та, кичке сәгать алтыларда, Сталин клубына, военкоматка һәм райкомга якын урнашкан беренче татар урта мәктәбенә «район җәмәгатьчелеге вәкилләре»— кадерле кунаклар килә башлады. Укучылар һәм берничә яшьрәк укытучы аларны каршылау өчен алдан ук урам як капка янына чыгып бастылар.

Беренче булып, сәгать алты тулар-тулмас борын, роно мөдире, сугыш инвалиды аксак Чынтимеров килде. Мәҗлес уздыру өчен мәктәпкә бер тиен бирмәсә дә, монда ул үзен хуҗаларча тотты. Укучылар белән дә, укытучылар белән дә теләмичә генә исәнләште һәм беркемгә карамыйча диярлек, үз йортына кергән кебек, туп-туры керде дә китте. Укучылар да, укытучылар да никтер аннан бераз гына шүрлиләр иде. Шуңа күрә Чынтимеров белән очрашу да корырак һәм салкынрак булды. Алдан

кушылганча, укытучылардан берәрсе аны директор кабинетына кадәр озатып куярга тиеш булса да, роно мөдирен беркем озата бармады.

Чынтимеровтан соң вак-вак атлап, як-ягына карап, елмаеп бәләкәй генә гәүдәле, тере, сүзчән Разия апа килеп җитте. «Коммунизм юлы»ның редакторы Разия апа элекке укытучы иде, шуңа күрә монда ул үз кеше иде. Бишенче класста Разия апа Габделхәйләргә татар теле, татар әдәбияты укытты. Ул вакытларда ук инде Габделхәй шигырь яза иде. Аның беренче шигырьләрен ут чәчеп торган матур кара күзле, кара чәчле, тезелеп киткән ак тешле Разия апасы укыды һәм беренче киңәшләрне дә ул бирде. Шуңа күрә Разия апасын Габделхәй аеруча якын итә, аның һәр сүзенә колак сала, Разия апа үзе дә быелгы унынчыларны «үз балалары» дип белә иде.

Разия апа күренү белән, чыр-чу килеп кызлар шундук аның каршысына бардылар, уратып алдылар, култыклап-җитәкләп дигәндәй, аны директор кабинетына кадәр озатып куйдылар. Разия апа да эреләнеп тормады — һәркемгә исеме белән эндәште, һәркемнең хәлен-әхвәлен сорашты, якындагы малайларның, кызларның аркаларыннан сөеп куйды.

Беркадәр вакыттан соң үзеннән калкурак буйлы хатыны белән парлашып кошчылык комбинаты директоры — юан гына, таза гына Ибәтуллин килде. Алардан кала, алдан килешеп куйгандай, бер-бер артлы «Заготзерно» вәкиле белән ит комбинаты вәкиле килде. Укучылар яныннан алар башларын югарырак тотып, дәрәҗәле генә үтеп киттеләр, шулай да сәламгә каршы сәлам бирделәр.

Җиденче яртыларда иң олы кунакларның берсе — райбашкарма председателе иптәш Бикчурин күренде. Кая барса да яшел «Победа»га утырып йөри торган председатель мәктәпкә бүген үз аягы белән килгән, үзе генә дә түгел — өчәүләшеп килгән иде. Аның бер ягыннан шат күңелле, чибәр һәм тук кыяфәтле хатыны Нәҗия, икенче ягыннан ялт итеп торган хәрби киемле яшь кенә лейтенант атлый иде.

Тоташ карадан киенгән, түшендә орден-медальләре булган, сабан туе батыры сыман таза, тыгыз тәнле, ак якалы иптәш Бикчурин капкага җитәрәк адымын әкренәйтә төште һәм яшь лейтенантны алданрак уздырып җибәрү өчен читкә тайпылды. Ләкин лейтенантның өлкән кешеләрдән алгарак чыгасы килмәде, ахрысы, юлдашларын уздырып җибәрмәкче булып, ул да читкәрәк тайпылды. Яңавыл өчен гадәттән тыш шәп киенгән, баштан алып аягына кадәр ислемайга коенган җылгыр Нәҗия ачык капкадан керә алмый торган ирләр яныннан җиңел генә

узып китте дә, алтын тешләрен, ак, таза муенындагы муенсаларын ялтыратып, ихахайлап көлеп җибәрде һәм күзенбашын уйнатып, шул ук вакытта «балакайлар» белән, укытучылар белән исәнләшергә дә онытмыйча, керт-керт атлап кереп тә китте.

Райбашкарма председателе иптәш Бикчурин зур башлы, кызыл йөзле һәм калын кара кашлы бер кеше иде. Хатынының шулай иркен генә узып китүенә ризасызлык белдергән сыман ул кашларын җыера төште. Озын буйлы, яшь, бәхетле лейтенантның йөзендә исә шаян елмаю чаткылары күренеп калды. Алар шулай ят, җиңел исләр таратып, укучылар белән теләр-теләмәс кенә исәнләшеп узып киттеләр.

Капка янында көтеп торучылар бу өч кунакны күреп кинәт телсез калдылар. Яшьләрнең күзе иң элек яшь лейтенантка төбәлде, һәркемнең күңеленә: «Кем соң бу?»— дигән сорау килде. Иптәш Бикчуринның шундый зур улы бар микәнни? дип уйладылар кайберәүләр. Нишләп соң моңарчы күренмәде дә, ишетелмәде дә икән? диделәр икенче берәүләр. Кызлар аны ишектән кереп киткәнче күзләре белән ашардай булып карап калдылар һәм шундук чыш-пыш килеп гайбәтләшергә дә тотындылар. Беренче булып Җәмиләнең тавышы ишетелде:

— Уф, йөрәккәем, су бирегез — гашыйк булдым, билләһи газим!— диде ул, бөтенесенә ишетелерлек итеп.

Шулай диде дә астыртын гына Габделхәй ягына күз ташлап алды. Габделхәй исә аны бөтенләй ишетмәмешкә салынды.

## XII

Менә сәгать җидегә якынлашты. Озын коридор кунаклар белән тулды. Кунаклар тыелып кына сөйләштеләр, тыелып кына көлешеп-көлешеп алдылар һәм әледән-әле ишек ягына күз төшергәләделәр. Кунаклар гына түгел, хуҗалар да көтте. Капка төбендә сакта калган укучылар «юк әле, күренми» дип килеп-килеп хәбәр итеп кенә тордылар. Мәҗлесне башлап җибәрү өчен бөтен нәрсә әзер иде, тик менә бер кеше, иң кадерле, иң олы кеше генә килеп җитмәгән иде.

Василий Михайловичның тынычсызлануы йөзенә чыкты. Ул инде ике-өч мәртәбә райкомга да, иптәш Сафинның квартирасына да шалтыратып карады, ләкин берничек тә Мунавир Мухлисовичны туры китерә алмады. Аның хәтта кайда икәнлеген дә белмәделәр. Василий Михайлович «м-да» диде, бармакларын шартлатты һәм кулъяулыгын чыгарып тирләгән маңгаен сөртеп-сөртеп алды.

Көтеп тору озакка сузыла башлагач, кайбер укытучылар, сәгатьләренә карап, кыюсыз гына: «Әллә башлыйбызмы соң?»— диделәр. Василий Михайлович ашыкмаска булды.

Шул вакыт, бөтенләй искәрмәстән дигәндәй, мәктәп капкасы янына аксыл төстәге өр-яңа «Победа» килеп туктады. Кемдер шатланып:

— Килделәр!— дип кычкырды.

Коридорда ыгы-зыгы башланды. Ишеккә якыннар тышка чыктылар, тәрәзәгә якыннар урам якны күзәттеләр. Самавырдай җиз торбаларын ялтыратып, төрле тавышлар чыгарып, баядан бирле карлыккан тамагын чистартып азапланган өч-дүрт кешелек оркестр шатланып «туш» уйнап җибәрде.

Райкомның беренче секретарен каршыларга Василий Михайлович үзе чыкты. Иптәш Сафин белән алар мәктәп ишегалды ягында, бәләкәй капкадан ишеккә кадәр сузып салынган такта басмада очраштылар. Райкомның беренче секретаре корсагы үсә башлаган олы гәүдәле, каратут йөзле, кара чәчле, илле яшьләр чамасындагы чибәр генә бер татар иде. Өстенә ул затлы яшел гимнастерка, шундый ук төстәге галифе чалбар, аягына озын кунычлы хром итек кигән, хәрби фуражкасын салып кулына тоткан иде. Фуражкасының маңгаенда хәрби эмблемасы, кулбашында алтын погоннары, йолдызлары булса, аны, күрәсең, полковник йә генерал дип уйларга да булыр иде. Тик шулай да аңа чын хәрбиләргә хас җыйнаклык һәм төзеклек җитеп бетми иде. Бу барыннан да элек бил каешының бушабрак торуында, изү төймәләренең тулысынча каптырылмавында һәм, гомумән, үз-үзен тотышында сизелә иде. Кием-салымы белән полковникларга, генералларга охшаса да, иптәш Сафин фронтта булмады, сугышта катнашмады. Яшь чагындагы хәрби хезмәтен исәпләмәгәндә, ул, гомумән, армия кешесе түгел иде. Сугыш елларында ул районда иң җаваплы эшләрдә эшләде, орденнар-медальләр белән бүләкләнде. «Икмәк фронты»нда зур җиңүләргә ирешкәне өчен әле былтыр гына аңа икенче мәртәбә Ленин ордены бирделәр. Тыйнак кеше, район җәмәгатьчелеге өчен үрнәк кеше буларак, ул бүген орден-медальләрен тагып тормаган, түшенә бары төрле төстәге шакмакларын гына кадап куйган иде.

Иптәш Сафин Василий Михайлович белән кул биреп күреште, бер-ике сүз әйтеп хәл-әхвәл сорашты, соңга калуы өчен гафу үтенде дә үзеннән чандыррак, тәбәнәгрәк директорның иңбашына аталарча шәфкатьле кулын тиереп алды. Алар шулай кочаклашкан сыман парлашып ишектән керделәр һәм туры директор кабинетына юнәлделәр.

Иптәш Сафинның тормыш иптәше Галия апа яисә Галя Гатовна машинадан соңлабрак чыкты. Аны Халидә апа белән Фәрхәнә апа каршы алдылар. Хатыннар, ирләргә бернинди катнашлары юк кешеләр сыман, бәхетле елмаеп, шатланып үз хәлләрен сораштылар һәм күңелле гөрелдәп, ашыкмыйча гына мәктәпкә керделәр.

Коридорның ике ягында да аларны үрә катып укучылар, укытучылар, кунаклар көтеп тора иде. Озакламый директор кабинетыннан иптәш Сафин белән Василий Михайлович чыкты һәм алар, янәшә атлап, коридор уртасыннан килә башладылар. Алардан бераз калышып, Галия апа яисә Галя Гатовна белән Халидә апа һәм Фәрхәнә апа килде.

Тантаналы кичә буласы класс бүлмәсенең абзар капкасыдай ачып куелган ишеге янына килеп җитәрәк, иптәш Сафин, каршылаучыларны сәламләп, даһиларча кулын күтәрде һәм парад кабул иткәндәге сыман көр тавыш белән:

— Здрасьте, товарищи!— диде.

— Здрасьте, Мунавир Мухлисович!— диде беренче булып бәхетле Антонина Семеновна.

— Исәнмесез! Исәнмесез, иптәш Сафин!— диделәр башкалар, бер-берсен бүлеп.

Җиз торбалы, калай тәлинкәле һәм барабанлы оркестр шатланып, ду китереп тагын «туш» уйнап алды. Командага, үрә катуга күнегеп беткән укучылар, укытучылар, кунаклар — гомуми күтәренкелек тойгысына бирелеп, кинәт шып булдылар, гәүдәләрен турайта төштеләр һәм бөек кешеләр узып киткәнче тын алырга да куркып тордылар.

## XIII

Түргә, стена буена сәхнә сыман итеп җайланган калку урынга унлап урындык тезеп куелган иде. Олы кунакларны шунда утырттылар. Иң уртага, әлбәттә, иптәш Сафин утырды, аның бер ягына райбашкарма председателе иптәш Бикчурин, икенче ягына хәрби диңгез флоты офицеры сыман ап-ак киемле Василий Михайлович урнашты. Калган буш урындыкларга районның җәмәгатьчелек вәкилләре һәм хөрмәтле укытучылар утырды. Хөрмәтле укытучылар арасында элекке укытучы Галия апага яисә Галя Гатовнага да урын табылды.

Олы кунаклар урнашып бетү белән, ашыгып, бер-берсен этеп-төртеп бүлмәгә укучылар кереп тулды. Шакшок килеп, дөбердәп, шау-шу ясап алар үз парталарына урнаштылар. Бик үк олы булмаган кунакларны сәхнәгә каршы яктагы беренче рәтләргә — парталар ягына утырт-

каннар иде. Укытучыларның да кайберләре шунда бик үк олы булмаган кунаклар арасына кысылды, кайберләре коридор ягында, ишек төбендә торып калды, кайбер яшьрәкләр унынчылар янына елыштылар.

Кичәне Василий Михайлович ачты. Ул сәхнә белән парталар арасындагы буш урынга куелган һәм өстенә кызыл җәелгән өстәл янына килеп басты да тамагын кырды. Баштарак директор парталар ягына карап сөйләде, ләкин болай ул олы кунакларга аркасын күрсәтә булып чыкты. Василий Михайлович моны тиз арада абайлап алды һәм иптәш Сафин ягына җиңелчә генә баш иеп «извините» диде дә өстәлнең икенче ягынарак күченде һәм укучылар массасына карата яңы беләнрәк борылды. Аннан соң янә сәхнә ягына күз төшереп алды.

Кереш сүзне Василий Михайлович урысча сөйләде. Иң элек ул бүгенге кичәнең ни өчен җыелуы турында әйтте, бу шатлыклы, тантаналы кичәдә районыбызның беренче секретаре иптәш Сафинның, райбашкарма председателе иптәш Бикчуринның, район җәмәгатьчелегенең һәм шулай ук укучыларның ата-аналары катнашканлыгын әйтте. Район җәмәгатьчелеге арасыннан иптәш Чынтимеров фамилиясен, аннан соң Разия апаны һәм төрле комбинат директорларының исем-фамилияләрен атады.

Кереш сүзеннән соң Василий Михайлович кыска гына итеп быелгы уку елы йомгакларына тукталды, партия тарафыннан үзенә ышанып тапшырылган мәктәп укучыларының фән нигезләрен тиешле дәрәҗәдә үзләштерүләре, бер класста утырып калучыларның былтыргыга караганда ярты процент чамасы азрак булуы, унынчы классны исә быел егерме дүрт укучының барысының да уңышлы тәмамлавы турында сөйләде.

Җыелыш саен диярлек Габделхәйне яхшы яктан гына түгел, хәтта начар яктан да телгә алалар иде. Үзенә карата бер үк вакытта яхшы сүз дә, начар сүз дә ишетергә никадәр күнеккән булмасын, хәзер ул, йөрәге еш-еш типкән хәлдә, Василий Михайловичның үз исемен әйтүен көтте. Ул, билгеле, яхшы сүз, мактау сүзе көтте, иптәш Сафинның, район җәмәгатьчелегенең, аннан да бигрәк, Җәмиләнең һәм алтын погонлы чибәр лейтенантның ушын алырлык искиткеч хәбәр әйтүен көтте, һәркемнең ушын алырлык хәбәр исә, аның исәпләвенчә, медаль булырга тиеш иде.

Унынчы класс турында сөйли башлагач, мәктәп директоры чыннан да Мухутдиновка киңрәк, озаграк тукталды. Ләкин гаҗәп хәл, медаль турында бер генә сүз дә әйтмәде.

— Мухутдинов барлык фәннәрне «отлично»га үзләштерде,— диде Василий Михайлович.— Ун ел буена Мухут-

динов Яңавыл татар урта мәктәбенең даны булды... Без аңа ышанабыз — киләчәктә ул безнең йөзгә кызыллык китермәс, фән-техниканың теләсә нинди тармагында үзеннән лаеклы өлеш кертә алырлык югары квалификацияле белгеч булыр... И без аннан шуны өмет итәбез дә...

«Әһә, кайсы якка бора!» — дип уйлады Габделхәй, директорның сүзләренә үзенчә бәя биреп. Башкалар, аеручa төрдәге кунаклар, икенче төрлерәк уйладылар, ахрысы. «Мухутдинов» исеме чыгу белән: «Кем ул? Кая ул?» — дигән кебек, кызыксынып укучылар ягына карап-карап алдылар. Хәтта иптәш Сафин да, башын ия төшеп, Василий Михайлович урынына күчеп утырган хатынына нидер әйтеп алды. Галия апа яисә Галя Гатовна нидер җавап бирде һәм алар икесе дә күз карашлары белән арттагы Габделхәйне эзләп таптылар. Үзенең шәплегенә үзе гашыйк булып утырган өр-яңа лейтенантның да тәкәббер йөзендә кызыксыну билгесе чагылып калды. Тик ул беркемнән бернәрсә сорамады — әүвәлгечә күзен каядыр бушлыкка текәп, сәхнәнең иң кырыйдагы урындыгында тораташтай катып утыруында булды.

Василий Михайловичтан соң унынчыларның класс җитәкчесе Фәрхәнә апа сөйләде. Ул татарча сөйләде. Ул да быелгы унынчыларның башка еллардагыга караганда тырышрак һәм тәртиплерәк булулары, фән нигезләрен яхшы үзләштерүләре турында әйтте. Аннан соң иң яхшы укучыларның исемнәрен телгә алды. Ул да Габделхәйгә аерым тукталды һәм ул да аңа зур өметләр баглавын белдерде.

Укучылар, укытучылар өчен директорның сүзләрендә бернинди яңалык булмаган кебек, Фәрхәнә апаның сүзләрендә дә бернинди яңалык юк иде. Тик шулай да Фәрхәнә апаны барысы да яратып, үз итеп тыңладылар. Мондагы кешеләрнең барысы да дип әйтерлек татарлар иде, татарча аңлыйлар, татарча фикер йөртәләр иде. Бер бүлмәгә җыйналган татарга икенче телдә — урыс телендә сөйләү күпчелекнең күңелендә һәрвакыт каршылык, кирелек һәм шул ук вакытта мескенлек, хокуксызлык тойгысы тудыра иде. Директор сөйләгәндә тынын кысып, сагаеп утырган кешеләр Фәрхәнә апа сөйли башлагач елмаеп җибәрделәр. Сөйләп бетергәч исә шаулатып кул чаптылар.

Кул чабу туктар-туктамас борын, директорның сүз бирүен дә көтмәстән, Антонина Семеновна урыныннан торды һәм кызыл җәелгән өстәл янына килеп басты. Үзе алдында укучыларның да, укытучыларның да татарча сөйләүләрен, татарча сөйләшүләрен аның җене сөйми иде. Укучыларының үз телләрендә лыгырдауларын ул әле ничектер гафу да итә ала иде, ләкин татар теле, татар

әдәбияты укытучысы Фәрхәнә апаны ул, гомумән, берничек тә гафу итә алмый иде. Теләсә кайчан «учительская»да, директор бүлмәсендә яисә җыелышларда авыз тутырып татарча сөйләшкәне өчен генә түгел, ул, ахрысы, аны авыл хатыннары кебек таза, тупас һәм үзсүзле булганы өчен дә яратмый иде бугай. Җае чыккан саен ул аны өтеп тә ала, төрлечә мыскыл да итә иде. Кайчагында алар укучылар, укытучылар алдында да эләгешеп киткәлиләр иде. Мондый чакта Фәрхәнә апага, әлбәттә, урысча җавап кайтарырга туры килә. Фәрхәнә апаның урысчасы исә ташка үлчим иде. Үзара бәрелешләр еш кына Антонина Семеновнаның барысын орып-бәреп, класстан, бүлмәдән чыгып китүе белән, хәтта башы-йөрәге авыртып урынга егылуы белән тәмамлана иде. Бу юлы Фәрхәнә апа урыс телен бозып та сөйләмәде, алай-болай аңа тел дә тидермәде. Ләкин аның район җитәкчеләре алдында рәхәтләнеп, «оялмыйча поганый телдә болтать итүе» Антонина Семеновнаны шактый чыгырдан чыгарды.

Гомумән, бүген аның кәефе шәптән түгел иде. Фәрхәнә апа сөйләгәндә ул әле кызарынып, әле агарынып көчкә тыелып утырды. Кызыл өстәл янына чыгып баскач та ул, дәресен белмәгән укучы кебек, кирәгенчә фикерен туплый алмыйча һәм тиз генә сүз башлап китә алмыйча торды. Сүз башлагач инде гадәтенчә урыс теленең бөеклеге турында, урыс телен яхшы белгән кешенең беркайчан, беркайда аптырап калмаячагы, урыс телен белгән кешегә һәркайда барлык юллар ачык булуы турында тезеп китте. Атаклы кешеләрнең урыс теленең бөеклеге, көчлелеге турында әйткән мәгълүм сүзләрен искә төшерде. Бу тантаналы кичәдә тәнкыйть сүзләре ят ишетелсә дә, түзмәде, «кайберәүләрнең» укытучы була торып та, урыс телен тиешенчә үзләштерә алмауларына, тиешенчә аны хөрмәт итмәүләренә кызгану белдерде.

Антонина Семеновнадан соң Разия апа сөйләде. Ул да куркып тормады — Фәрхәнә апа кебек татарча гына сиптерде. Шуннан соң райбашкарма председателе иптәш Бикчурин сүз алды. Ул шулай ук татарча сөйләде. Аннан соң химия укытучысы Халидә апа кузгалды. Ул болай да күбрәк урысча гына сөйли иде. Монда да ул күнегелгән гадәтеннән чигенмәде. Алар барысы да мактау сүзләре, тынычландыру, куандыру сүзләре генә әйтергә тырыштылар. Алар барысы да яшьләрне зур тормышка аяк басулары белән котладылар, киләчәктә совет яшьләренең иптәш Сталинның, партиянең ышанычын аклаячакларына, илебез, халкыбыз өчен файдалы кадрлар булачакларына зур өметләр багладылар.

Ил өчен, халык өчен файдалы кешенең ниндирәк булырга тиешлеген ачык кына күз алдына китерә алмасалар да, алсу битле, саф күңелле яшьләр күтәренке, купшы үгет-нәсихәт сүзләрен тын да алмый тыңлап утырдылар. Моңа кадәр тыңлаган барлык дәресләргә караганда да яратыбрак, бирелебрәк тыңлап утырдылар.

## XIV

Котлау һәм үгет-нәсихәт сүзләреннән соң тантаналы кичәнең икенче өлеше — ун классны тәмамлау турында аттестатлар тапшыру башланды. Беренче булып фамилиясе «А» хәрефенә башланган Абдрашитова Галимә чыкты. Менә ул директорның кыска бармаклы сөякчел каты кулыннан кадерле кәгазьне алды да, дәрестә җавап биргәндәге кебек, чатнап торган яңгыравык тавыш белән атабыз Сталинга, туган илгә, мәктәп дирекциясенә рәхмәт сүзләре әйтте. Аның рәхмәте әйтелеп бетү белән коридор ягындагы оркестр, барлык торбаларын, тәлинкәләрен, барабаннарын эшкә җигеп, бөтен дөньяны яңгыратып «туш» уйнады.

Галимәдән соң Назиф чыкты. Аннан сон Фәнәви чыкты. Укучылар директор кулыннан ялтырап торган бер бит кәгазь алдылар, кычкырып рәхмәт әйттеләр һәм музыка, кул чабу, куанычлы чыш-пыш дулкынында җиңелчә генә тирбәлеп, алпан-тилпән атлап, урыннарына барып утырдылар. Бу минутта бөтен дөньяда алардан да бәхетлерәк беркем булмагандыр, мөгаен.

Габделхәй иптәшләренең сүзләренә бөтенләй диярлек колак салмады. Мондый чакта ул үз фамилиясенең «А» яисә «Б» хәрефенә башланмавына үкенү һәм ризасызлык сыман бер тойгы кичерә торган иде. Бу тойгыда түземсезлек һәм омтылыш та бар иде. Хәзер дә ул бары «Мухутдинов» фамилиясе ишетелүен генә көтте. Менә, ниһаять, Василий Михайлович, кызыл япкан өстәлдәге аттестат кәгазьләренең берсенә күз төшереп алды да Габделхәй көткән фамилияне кычкырды. Болай да киеренке тынлык сагаеп калды. Бөтен класс «Мухутдинов» ягына борылып карады һәм йөзләгән күз карашы, аның урыныннан кубып, кызыл өстәл янына барып җитүен күзәтеп тордылар.

Ул, билгеле, яшь лейтенант кебек шәп һәм таза түгел иде. Чандыр һәм ак чырайлы яшь шагыйрьнең өсте-башы да алтын погонлы лейтенантныкы кебек энәдән-җептән генә чыккан түгел иде.

Иң күзгә ташланганы — озын чәч иде. Колакларын күмеп киткән, чүмеч артына төшеп торган чәчләре бераз

гына Такташныкын хәтерләтә иде кебек. Ләкин аныкыдай уттай янган күз карашы, ихтимал, Такташта да булмагандыр. Аның ул дәртле, очкынлы күз карашында балаларча беркатлылык та, кыюсызлык та, шул ук вакытта үз-үзенә ышану, горурлык һәм тәкәбберлек тә бар иде.

Калын, шома кәгазь кисәген Василий Михайлович бүтәннәргә ничек тапшырган булса, аңа да шул рәвешчә тапшырды. Дирекция һәм укытучылар коллективы исеменнән фатиха сүзләре әйтте, нык итеп аның кулын кысты. Шуннан соң оркестр «туш» уйнады. Халык шаулатып кул чапты.

Шуннан соң Габделхәй дә бүтәннәр кебек кычкырып рәхмәт әйтергә һәм, кызыл өстәл янында артык тоткарланып тормыйча, үз урынына барып утырырга тиеш иде кебек. Ләкин, Габделхәй исәпләгәнчә, «тантана» җитәрлек дәрәҗәдә тантаналы булмады. Директор аңа бирелергә тиешле тагын бер нәрсәне онытып калдырды сыман тоелды. Бөтен халык алдында шул турыда Василий Михайловичның исенә төшерү бик зур әдәпсезлек булыр иде, әлбәттә. Ул моны аңлады, ләкин шул ук вакытта директорның ни дә булса әйтүен көтте. Директор исә берни әйтмәде — башын иештереп, өстәлдәге аттестатларны әвеш-түеш китергән булды. Ул арада укучылар арасында чыш-пыш китте. Габделхәй үзе генә түгел, башкалар да директор медаль алып кайткандыр, күрәсең, аны бүген тантаналы кичәдә тапшыралардыр диебрәк уйлаштыралар иде.

Иптәшләренең чыш-пышын ишетеп, Габделхәй каушый башлады.

— Нәрсә, выступлениегезне оныттыгызмы әллә, Мухутдинов?— диде Василий Михайлович.

«Әйе, шул — выступление...»— дип уйлады Габделхәй, үзенең хәзер генә нишләргә, нәрсә сөйләргә тиешлеген исенә төшереп. Ләкин ул бит выступлениегә әзерләнмәде! Ярдәм сораган сыман ул якындагы Антонина Семеновнага күз төшереп алды. «Каушама, сөйлә!»— диде Антонина Семеновна, күз карашы белән елмаеп. Фәрхәнә апа исә ишеттерерлек итеп:

— Шигыреңне укы, Габделхәй,— диде.

Разия апа да шул ук сүзләрне әйтте. Габделхәйгә кинәт җан керде, ләкин әле һаман ул каушавын җиңә алмады — нишләргә белмичә өстәл янында басып тик торды.

Халык көтте. Башта тын да алмый көтте, аннары сабырлыгын җуеп сизелер-сизелмәс кенә гөжләргә тотынды. Кемдер пышылдады, кемдер парта шыгырдатты. Иптәш Сафин яшь җегетнең уңайсызлануын күрмәс өчен, хатынына иелеп нидер әйтеп куйды.

— Башлагыз. Кыюрак!— диде шул чакны якында гына Антонина Семеновна, команда биргән кебек.

Торгынлык юкка чыкты һәм үзенә ышаныч кайта барганын тойган хәлдә Габделхәй, тамагын кыргалап:

— Иптәшләр...— диде.

«Иптәшләр»не ул татарча әйтте. Макталган укучының уңайсыз хәлдә калуына болай да үртәлеп утырган Антонина Семеновна корт чаккандай урыныннан калкып куйды һәм дорфа гына:

— Мухутдинов, говорите по-русски!— диде.

— Гафу итегез,— диде Габделхәй һәм бернинди тоткарлыксыз выступлениегә тотынды.

Сөйләгәндә ул берни турында уйламады. Ул бары кайчандыр кемнәндер ишеткән, китаплардан, гәзитләрдән укыган сүзләрен генә исенә төшерде.

— Без бүген барыбыз да зур шатлык кичерәбез,— диде ул, дәрестә җавап биргән кебек «шартлатып».— Шатланмаска мөмкинме соң?! Бүген без туган мәктәбебез белән, кадерле укытучыларыбыз белән саубуллашабыз. Без олы тормыш юлына аяк басабыз. Безнең күгебез аяз, киләчәгебез якты. Соңгы сүзем итеп шуны әйтәсем килә... бәхетле яшьлегебез, шатлыклы тормышыбыз өчен... партиягә... иптәш Сталинга... шуны әйтәсем килә...

Соңгы сүзләрен, бигрәк тә партиягә, Сталинга кагылышлы сүзләрне аның аеруча күтәренке, тәэсирле итеп тәмамлыйсы килде һәм шигырь язгандагы кебек иң кирәкле сүз таба алмыйча, бу юлы да төртелеп калды. Шулай да артык каушап, тоткарланып тормады — «безне яңадан-яңа җиңүләргә алып баручы» дип шома гына ялгап алып китте. Кирәкле сүзләрен әйтеп бетергәч, ул, «уф, котылдым!» дигән сыман, шаулатып бер тын алды. Аның шулай шаулатып тын алуын бөтен класс ишетеп торды. Фәрхәнә апа, теләктәшлек белдереп, елмаеп куйды. Тәртипсез Назиф кычкырып көлеп җибәрде. Аңа башкалар кушылды. Күп тә үтмәде, шундый авырлыкны җиңеп чыккан батыр Мухутдиновка чын күңелдән шаулатып кул чабарга тотындылар.

## XV

Кул чабу озакка сузылмады. Барысы да, Габделхәй белән эш бетте дип уйлап, Василий Михайловичның икенче фамилияне әйтүен көттеләр. Василий Михайлович чыннан да нидер әйтергә җыенды.

— Шушы кадерле кичәгә багышлап мин шигырь яздым,— диде Габделхәй, кесәсеннән бер бит кәгазь чыгарып.— Рөхсәт итсәгез, мин шуны укып күрсәтер идем.

Ул моны директорга карап әйтте. Василий Михайлович, Габделхәй урыныннан кузгалып китмичә сүз башлый алмаган кебек, Габделхәй дә аның рөхсәтеннән башка сүз башлый алмый иде. Директор, ишетмәгән сыман, эндәшми калуны артыграк күрде.

— Укы әйдә, укы!— диде Фәрхәнә апа, директор өчен җавап биреп.

— Укы, укы!— диделәр башкалар да.

Габделхәйгә шул гына кирәк тә иде.

— «Рәхмәт, мәктәп!»— диде ул шигырьнең исемен әйтеп, Василий Михайловичның җавабын көтмәстән.

Шуннан соң ул дәртләнеп укырга кереште һәм:

— Бакчадагы алсу гөлләр кебек,
Чәчәк аттык синдә без, мәктәп.
Аңыбызга якты нурлар сибеп
Син үстердең безне иркәләп,—

диде яшь, көчле тавыш белән.

Мәктәп һәм Яңавыл күләмендәге атаклы шагыйрьнең шактый озын һәм күңелсез шигыре, выступлениесе кебек үк, дәрестә ишеткән, китаплардан, гәзит-журналлардан укып белгән төссез, шома һәм политик тотнаклы сүзләрдән теркәлгән иде. Василий Михайловичны исәпләмәгәндә, беркем дә монда шигырь белгече түгел иде. Шулай да яшь шагыйрьнең кычкырып һәм дәртләнеп таныш сүзләр көйләве тыңлаучыларга ярыйсы ук тәэсир итте. Укучыларга, укытучыларга һәм кунакларга шигырьнең аеруча соңгы юллары ошады.

— Рәхмәт сиңа, бөек туган халкым —
Улларыңның изге юлдашы.
Рәхмәт сиңа, туган уку йортым,
Даһи Сталин — бәхет кояшы! —

дип тәмамлады Габделхәй, тәрәзә пыялалары зыңгырдарлык тавыш белән.

Фәрхәнә апа куанычыннан елмаеп җибәрде, «булдырдың!» диде. Бөтен класс ду китереп кул чапты. Хәтта иптәш Сафин да башкаларга кушылып кул чапты, иптәш Бикчурин шулай ук калышмаска тырышты. Бите, колак очлары уттай янган бәхетле җегет боларның барысын да күреп, тоеп торды һәм ашыкмыйча гына өстәл яныннан кузгалып китте.

Тәненең авырлыгын да, аягының кайсы якка, ничек атлавын да тоймас хәлдә җиңеләеп, үз партасына таба юнәлгәндә, аның алсу томан элпәсе белән капланган күз карашына ачулы Антонина Семеновнаның тузынып коридорга чыгып барганы күренеп калды. «Кайтып китте.

Килмәячәк бүген»,— дип уйлады ул аның турында тыныч кына. «Хәтерен калдырдым, ахрысы»,— диде аннары үз-үзенә. Ләкин бит аның да хәтерен калдырдылар! Медаль юк. Булмады. Булмаячак. Нәрсә ул шау-шу килеп кул чабулар алтын медаль белән чагыштырганда!

Урынына килеп утыргач та Габделхәй үзен биләп алган исерткеч тәэсирләрдән тиз генә арына алмады. Әле генә нәрсә турында уйлаган иде соң әле ул? Ә, Антонина Семеновна... Юк, медаль бугай. Әйе, медаль. Булмады. Булмагандыр, күрәсең. Нигә соң аны башта ук шулай дип әйтмәделәр икән? Нигә шуны сер итеп тоттылар икән?

Күпмедер вакыттан соң аның колагына бик ерактан, куе томан арасыннан ишетелгән сыман, кемнеңдер тавышы килеп җитте.

— Нәрсә?— диде ул, илтифатсыз гына артына борылып.

— Кәбестә!— диде Җәмилә.— Сәкинә кая? «Сәкинә турында юри сорый. Сөйләшәсе килә»,— дип уйлады Габделхәй үзалдына. Әле күптән түгел генә ул, моннан соң беркайчан Җәмилә белән сөйләшмәячәкмен, дип, үз-үзенә сүз биргән иде. Хәер, ул инде аны шундук оныткан да иде, тик шулай да Җәмиләгә карата күңелендә энә очы кадәр генә кинә торып калган иде. Аннан соң, хәзер менә шундый бәхетле, күңелле мизгелдә Җәмиләнең ут капкандай Сәкинәне таптыруы бөтенләй урынсыз иде.

— Сакина Тазиева юкмени?— диде Василий Михайлович, класска күз йөртеп.

Барысы да бер-берсенә карашып алдылар. Төрле яктан:

— Юк, күренми.

— Кая булды икән соң ул?

— Әле генә шушындае,— диделәр.

— Нәрсә булган тагын?— диде директор, кырыс кына. Иң арткы партада утырган Җәмилә Габделхәйнең аркасына төртеп алды.

— Сәкинәне күрмәдеңме? димен мин сиңа!— диде.

— Нәрсә кирәк сиңа?— диде Габделхәй, чеаләеп.

— Кычкырма шул чаклы!— диде Җәмилә, пышылдап.

Бер-ике сүз белән ул Сәкинә турында үзе белгәнне әйтеп бирде. Баягынак болынга барырга чыккач, алар — Җәмилә белән Сәкинә — әйткәләшеп киткәннәр. Үпкәчел Сәкинә ачуланып кире борылган. Аның артыннан йөгереп караганнар, ләкин куып җитә алмаганнар. Җәмилә аны мәктәпкә кайткандыр дип уйлаган. Мәктәптә юклыгын күргәч, өйләренә кайтып киткәндер дип уйлаган. Аны, билгеле, өйләренә барып алган да булыр иде, ләкин Җәмиләнең барасы килмәгән. Аттестат кирәк булса, үзе килер дип уйлаган. Ләкин Сәкинә менә юк. Кай-

да булыр ул? Анының кайдалыгын Габделхәй дә белмәгәч, тагын кем белер? Бит алар... йөриләр!

Сәкинәнең юклыгы Габделхәйне әз генә дә борчымады. Ул Җәмилә кебегрәк «аттестат кирәк булса, үзе килер әле» дип уйлады. Шулай да Җәмилә алдында бөтенләй кызыксынмаган кеше булып утыру да килешми иде.

— Чыннан да, кая китте икән соң ул?— диде ул, Җәмиләнең үзенә үк сорау биреп.

— Кит, билләһи газим!— диде Җәмилә.— Бу кадәр булгач та булырсың икән!

— Үзләре куалап җибәргәннәр дә, хәзер мин гаепле,— диде Габделхәй.

Сәкинәнең юклыгы җайлы гына барган тантаналы кичәнең тәртибен бозды. Василий Михайлович «Тазиева»ның аттестатын бер читкә алып куйды да аннан соң икенче кешенең фамилиясен әйтергә әзерләнде. Шул чакны Җәмилә кулын күтәреп, парта капкачларын шакылдатып, урыныннан торды.

— Василий Михайлович, Сәкинә Таҗиеваның өйләренә барып килергә рөхсәт итегез?— диде.

— Барыгыз,— диде директор.

«Әйдә!» дигән сыман Җәмилә Габделхәйнең кабыргасына төртеп алды, үзе белән бер партада утырган Нәзирәне җитәкләде дә, беркайчан түбә өстендә рәтләп тормый торган, читләренә аллы-гөлле бизәкләр төшерелгән зәңгәр кыекча яулыгын төзәткәләп, тиз-тиз атлап ишеккә таба элдерде.

Җәмиләнең шулай санга сукмагандай кабыргасына төртеп алуы да, беренче булып, әйдәп китеп баруы да Габделхәйнең ачуын китерде. Кем булган дип торырсың — этеп-төртеп кенә йөртмәкче! Йөртми тор әле. Киреләнеп ул урынында утырып калды.

— Әйдә киттек без дә!— диде шул чакны Назиф, Габделхәй ягына карап.

— Әйдә алайса,— диде Габделхәй, теләр-теләмәс кенә.

## XVI

Боларның барысы да кичәгенәк булды.

Менә хәзер ул идәнгә озын өстәл янына сузылып яткан да яңадан татлы йокыга китәргә азаплана. Ләкин таң аткан, тышта якты, бүлмәгә кояш нуры тулган.

Кичәге көн, дөресрәге, кичәге төн әллә төш, әллә өн булып мәңге аның хәтеренә сеңеп калды.

Кичәгенәк алар үз гомерләрендә беренче мәртәбә укытучылар белән, зур, дәрәҗәле кунаклар белән бер мәҗлестә утырдылар. Бергә, бер өстәл янында ашадылар, эчтеләр.

Беркем бер сүз әйтмәде, беркем бер шелтә-фәлән белдермәде. «Эчте» дигәч тә, кызлар авызларына да алмадылар, малайлар да татып кына карадылар. Әз генә, күз каргамаслык кына. Хәтта директор... Василий Михайлович алар белән стаканын чәкештереп йөрде. Кызык инде. Адәм әйтеп адәм ышанмас — шундый кырыс, шундый коры Василий Михайлович үзенең укучылары белән, укытучылары белән бергәләп аракы эчте! Иптәш Сафин да, иптәш Бикчурин да эчте. Бар рәвешен китереп, чын ирләрчә шаулатып, мактанышып эчтеләр.

Чак-чак кына башына китеп алгач, дөресрәге, туйганчы ашаганның соңында, күңеле күтәрелеп киткән Габделхәй утырган җирдән генә үзенең Яңавылга, Бүә буйларына багышланган яңа шигырен укыды. Шундый хисле итеп, шундый оста итеп укыды — барысы да исләре китеп тын да алмый тыңлап тордылар, аннары күкләргә чөеп мактадылар. Хәер, аның үзенә генә шулай тоелды. Дөресен әйткәндә, «район җәмәгатьчелеге»нең әлләни исе китмәгән сыман күренде. Бу вакытта инде алар аерым-аерым төркем булып нидер гәпләшәләр, нидер хәл итәләр иде. Иптәш Сафин исә үзенең бәлештәй симез, чибәр хатыны Галия апа яисә Галя Гатовна белән китеп тә барган иде бугай.

Аны бары классташлары гына мактады, ахрысы. Малайлар арасында калкурак гәүдәле, көчлерәк Назиф Габделхәйне күтәреп алып югары чөймәкче булды. Габделхәй аны юри бәйләнә дип уйлады. Кем белә, бәлки, чынлап та көнчелектән шулай кылангандыр ул? Чак-чак кына ызгышып китмәделәр. Ярый әле вакытында Габделхәй үзенең хатасын аңлап алды. Аңлап алды да Назифтан гафу үтенергә тотынды. Шуннан соң алар икәүләшеп, кочаклашып тышка чыгып киттеләр. Очынып, дәртләнеп караңгыда, салкынча һавада озак кына җырлап йөрделәр. Аларга Фәнәви килеп кушылды, башка малайлар килеп кушылды. Алар беркайчан ачуланышмаска, мәңге дустату булырга бер-берсенә антлар бирделәр.

Шулай дөньяларын онытып, мәктәп ишегалдында әрле-бирле йөренгәндә, караңгыда көтмәгәндә карышларына Җәмилә килеп чыкты.

— Нишләп йөрисез монда бер-берегезгә тагылып?— диде ул, исе китеп.— Анда сезне югалтып яталар. Сәкинә үпкәләгән. Абау, шул да булдымы — кызы янына барып та карамый!

Күп тә үтмәде, Җәмилә артыннан Нәзирә килеп җитте, Галимә килде. Шуннан соң алар, үзара култыклашып, шаулашып урамга ук чыгып киттеләр. Ләкин әллә ни ерак та китә алмадылар, озак та йөри алмадылар —

Җәмилә барысын да кире борды. Беркем каршы килмәде. Җәмиләнең боерыгына буйсынып яңадан мәктәп ишегалдына кайттылар. Алар кайтып кергәндә бөркү класс бүлмәләрендә беркем калмаган — барысы да тышка, ишегалдына чыкканнар, җыр-бию башлап җибәргәннәр иде. Бу вакытта инде оркестр да, кайбер кунаклар да кайтып киткәннәр, мәктәптә бары үз кешеләр генә, яшьләр калган иде. Күптән түгел армиядән кайткан җыр һәм рәсем укытучысы Нәҗип абый өздереп гармун уйный, укытучы кызлар, яшь хатыннар бииләр, башкалар исә күңелле шаулашып кул чабып торалар иде.

Сәкинә шунда гына, мәктәп ишегалдында гына булган. Аны эзләргә китүчеләр тиз арада кире борылдылар. Бераз соңлап булса да, Сәкинә дә аттестат алды. Ләкин аңа карап кына Сәкинәнең күңеле күтәрелмәде. Менә хәзер дә ул биюче укытучылар янындарак аерылып, берьялгызы басып тора иде.

Урамнан җыйнаулашып кайтып кергәндә Җәмилә тагын Сәкинәнең үпкәләве турында әйтте. «Үпкәләмәсен, ул да шат күңелле булсын»,— дип уйлады Габделхәй үзенең йөргән кызы турында. Ләкин, нихәл итмәк кирәк, Җәмилә Сәкинәдән яхшырак. Гадирәк тә, аңлаешлырак та. Буйсын, чибәрлек ягына килгәндә Сәкинәдән әллә кайда өстенрәк. Тик менә укуы гына Сәкинәнекеннән кайтышрак. Бигрәк тә ул урыс теленнән йомшак, физика-математикадан, химиядән йомшак. Аннан соң бик җиңел акыллы да бугай ул. Бик тиз кызып китә, кычкыра. «Язучы — кеше рухының инженеры» булса да, Габделхәйнең әле нишләптер Җәмиләнең холкын-фигылен, эчке кичерешләрен рәтләп аңлаганы юк. Наданлык бу. Шагыйрь... буласы кеше башкаларны, бигрәк тә кызларны яхшы белергә тиеш. Дөрес, Габделхәйнең инде ярату-яратмау мәсьәләсендә үз карашы бар. Аныңча, чын кеше бары тик яхшы укучы кызларны гына, эшчән, тырыш һәм акыллы кызларны гына яратырга тиеш. Андый кыз бик үк матур булмаска да мөмкин. Чын мәхәббәт тышкы матурлык белән түгел, эчке матурлык белән билгеләнә. Сәкинә нәкъ менә шундый кыз. Сәкинәне яратмаска мөмкин түгел!

## XVII

Шулай уйлана торгач, көтмәгәндә ул теге лейтенантны исенә төшерде. Бер дә юктан диярлек кәефе кырылды. Беренче күрүдә үк лейтенант аңа ошамады. Ошамады гына түгел, ул аны хәтта җаны-тәне белән яратмас булды. Яратмаса да, әледән-әле аның ягына карап алды,

аның турында әйтелгән өзек-өзек сүзләргә колак салды. Берәүләр аны райбашкарма председателенең туганы икән диделәр, икенче берәүләр хатынының энесе икән, диделәр. Венгриядәме, Румыниядәме хезмәт итә икән; ялгамы, бөтенләйгәме кайткан икән дә, шуннан файдаланып, менә монда Яңавылга кунакка килгән икән, диделәр.

Берни әйтеп булмый, иптәш лейтенант чибәр җегет. Барыннан да бигрәк аның менә шул чибәрлеге ачуны китерде бугай. Киң җилкә, калку күкрәк, кара каш, кара чәч. Үзе озын, төз гәүдәле. Кәртинкә инде, кәртинкә. Тик менә йөзе нурсыз. Эре. Тәкәббер, һәркемгә масаеп, мыскыл итеп карый сыман. Кызлар аның йөзенә карамыйлар да, энәдән-җептән чыккан шәп киемнәренә карыйлар да алтын погоннарына кызыгалар. Җәмиләнең авызында гел шул погон да китель, төймә булды. Кичәгенәк лейтенант үзен шактый эре тотты. Унынчыны бетереп кулларына аттестат алган җегетләрнең берсе белән дә беренче булып сүз дә башламады, алар ягына хәтта рәтләп карамады да. Шул ук вакытта, малайларның башлары аша үрелеп, кызларга мактау сүзләре әйтте, кайберләре белән сөйләшергә дә тырышып карады.

Габделхәй һич тә аның үзләре белән аралашуын теләмәде. Ләкин бөтен игътибары аның һаман шул сөйкемсез лейтенантта булды. Чибәр кунакның һәр сүзе, һәр кыланышы анда кире тәэсир тудырды. Габделхәйнең генә түгел, бүтән малайларның да бу кирәкмәгән артык кашыкка ачулары килгән булып чыкты. Икәүдән-икәү генә калгач, Назиф Габделхәйнең беләгеннән кысып тотты да кайнарланып:

— Әйдә тукмап ташлыйбыз шул погонлы күркәне!— диде.

Назифның Җәмиләгә күзе төшеп йөри. Моны һәркем белә. Бервакыт ул хәтта «мин аны өйләренә кадәр озатып куйдым» дип тә мактанган иде. Назифның Җәмиләне көнләп дулавы Габделхәйгә бик үк ошап җитмәсә дә, аның шулай кунак җегетне тукмарга җыенуына каршы килмәде. Назиф ул дуамалрак. Ярсып китсә, лейтенантны чынлап та тукмап ташлавы бар. Ләкин бит лейтенант — хәрби кеше! Ничек итеп аңа кул күтәрәсең? Аның әле кесәсендә наганы да бардыр. Совет армиясенә каршы кул күтәргән дип алып китсәләр?!

Габделхәй Назифка шулайрак диде. Мондый сүз ишетеп Назиф ы-мы итте, үпкәләгән сыман итте, шулай да артык кысташып тормады. Ул арада иптәш Бикчурин хатыны Нәҗия апа белән кайту ягына юнәлде. Хуш исле папиросын төтәтеп, алар белән кунак лейтенант та китеп барды.

Габделхәйгә хәзер барысы да көлке тоелды. Ярый әле дурак Назиф коткысына бирелмәгән. Алай-болай әләгешеп киткән булсаң, харап эшләр! Ятар идең менә монда хуш исле чәчкә арасында... иртәнге кояшта җылынып...

Шуннан соң... шуннан соң алар яңадан үзләренең классларына керделәр, яңадан биеделәр, җырладылар. Барлык кунаклар һәм укытучылар кайтып киткәч, Фәрхәнә апа белән бергәләп таңга кадәр диярлек төрле кызык хәлләр сөйләшеп, хыялланып утырдылар.

Фәрхәнә апа «Гөлмәрфуга, бар суга» дигән яңа җыр өйрәтте. Ул аны яшь чагында Казанда ишеткән икән. Фәрхәнә апаның матур итеп җырлавына яшьләрнең исе китте. Алар аны бөтенләй җырлый белми дип уйлыйлар иде. Баксаң, ул да менә дигән иттереп, моңлы итеп, сузып-сузып җырлый икән!

Алар шулай урындыкларын түгәрәкләп тезеп, бер-берсенә сыенып утырдылар, бер-берсенең якынлыгын тоеп, күз керфекләре йомылганчы, тамаклары карлыкканчы җырладылар да җырладылар. Җырны күбрәк Фәрхәнә апа башлады. Җырлап туктагач, бер-ике сүз белән җырның тарихы турында белешмә бирде — монысын фәлән авылның фәлән кешесе чыгарган диде, монысын кызыллардан ишеттем, монысын солдатлардан ишеттем диде. «Солдатлар»ның нинди төстә булуын сорап тормадылар. Барыбер түгелмени? Ак булса да, кызыл булса да, кемдер җырлаган, үзебезчә, татарча җырлаган. Шул чактагы бер яшь кызның хәтеренә сеңеп калыр дип ул, бәлки, уена да китереп карамагандыр. Бәлки, аны шул ук көнне атып үтергәннәрдер. Җыры менә исән калган.

Шуннан соң... шуннан соң кызлар бер бүлмәдә, малайлар бер бүлмәдә кая туры килде, шунда башларын төртеп йокыга талдылар. Фәрхәнә апа кайтып китмәде — кызлар янында калды.

Дөресен әйткәндә, аларның йокы дигәне йокы да булмады. Бары бераз онытылып кына алдылар. Менә Габделхәй көндәгечә уянып китте. Хәзер инде ничек йоклап ятмак кирәк?!

Йокылы-уяулы килеш беравык уйланып яткач, ул бүлмә эченә күз йөртеп чыкты. Кичәгенәк бөтенесенең игътибарын үзенә җәлеп итеп торган кызыл япмалы өстәл урыныннан күчерелгән, кызылы яртылаш идәнгә салынып төшкән. Идәндә, өстәл өстендә, парталарда, урындыкларда кәгазь кисәкләре, чичкәләр аунап ята. Идәндә төрлесе-төрле кыяфәттә сузылып, бөгәрләнеп малайлар йоклап ята. Тәрәзә аша елмаеп иртәнге кояш карый.

Бөтен дөнья шундый тын, тыныч. Күңелдә шатлыклы, бәхетле бер омтылыш һәм туасы көнгә зур өмет тойгысы тирбәлә. Әйе, бу аның сабыйлык һәм балалык чорыннан чыгып, күптән вәгъдә ителгән олы тормышка — серле дә, аңлаешлы да сыман билгесезлеккә аяк баскан беренче һәм соңгы иртәсе иде.

## XVIII

Шул чакны урам якта көтүченең:

— Чыгары-ың!— дигән тавышы ишетелеп китте.

Шуннан соң чыбыркы шартлады. Күп тә үтмәде, шыгырдап капкалар ачылды. Йокылы тавышлы ниндидер хатын-кыз сыерына, сарыкларына кычкырды. Анасыннан аерылып калган кәҗә бәтие колак тондыргыч чәрелдек тавыш белән кычкыра-кычкыра каядыр йөгереп китте. Ачык тәрәзәдән дымлы тузан исе катыш әчкелтем көтү исе килеп керде һәм мәктәп турысында беркадәр вакыт тигезле-тигезсез атлаган йөзләрчә тояк тавышлары, сарык кычкырган, сыерлар мөңгерәгән тавышлар ишетелеп торды.

Көтү тавышына малайларның барысы да уянып киттеләр. Көтү киткәч йоклап ятарга ярамаганлыгын уйлап урыннарыннан тордылар да өс-башларын рәтләделәр. Икенче бүлмәдәге кызлар да уяндылар, аякларына бастылар һәм бер-бер артлы тышка чыга башладылар.

Барысы да җыелып беткәч, кызлар Фәрхәнә апаны өйләренә кадәр озатып куярга дигән теләк белдерделәр. Кызларның теләгенә малайлар да кушылды. Фәрхәнә апаның бер ягыннан Җәмилә белән Сәкинә, икенче ягыннан Габделхәй белән Назиф барды. Башкалар аерымаерым төркем булып алданрак та, арттанрак та бардылар.

Фәрхәнә апа Яңавыл татар урта мәктәбенең иң өлкән укытучыларыннан санала иде. Баштарак ул башлангыч классларда укыткан, аннан соң үзе укыган. Казанда, пединститутта. Шуннан соң югары классларда татар теле, татар әдәбияты укыта башлаган. Аның күз алдында инде бик күп балалар үсеп буйга җитте, бик күп балалар менә шулай бүгенгечә «яңа тормышка» аяк бастылар һәм нәкъ бүгенгечә диярлек, күмәкләшеп аны өенә кадәр озата бардылар.

Өлкән укытучы исәпләнелсә дә, Фәрхәнә апа чын яшенә караганда яшьрәк һәм тазарак күренә иде. Көне буе балалар шау-шуы, тузан эчендә гомер кичерә торган укытучыдан бигрәк ул иртәннән башлап кичкә кадәр саф һавада була торган игенчене хәтерләтә иде. Тумыш-

тан ул чыннан да игенче кызы булган, яшьрәк чагында ирләр кебек җир сөргән, печән чапкан, әтәсе белән бергәләп урманга, тегермәнгә йөргән. Шул ук вакытта кыш көннәрендә бер-ике ел мәдрәсәдә абыстайдан сабак алырга да өлгергән. Авылда укытучылар җитешмәгән чакта аны мөгаллимә итеп куйганнар. Шуннан башлап ул менә һәркөн диярлек мәктәп юлын таптый.

Белемне ул бик авырлык белән ала. Колхозлашу елларында бик зур мохтаҗлыклар, кыенлыклар күрә. Хәзер инде алынасы белем алынып беткән, михнәтләр онытылган, тормыш җайга салынган. Менә шулай чыгарылыш кичәләре вакытында, яшьләр белән иске җырлар җырлап утырганда ул еш кына элеккеләрне исенә төшерә. Шул чагында яшьләр аны беренче мәртәбә күргән кебек булалар. Дәрес вакытында ул, билгеле, үзе турында сөйләми, хәзер исә, киресенчә, гел үзе турында, элекке гадәтләр, элекке җырлар, элекке кешеләр турында сөйли. Шулай да ул беркайчан вәгазь дә укымый, «без үскәндә кыен булды, хәзер сез рәхәт яшисез» дигәндәй сүзләр әйтми. Ул бары булганны гына сөйли. Ләкин нишләптер ул беркайчан үзенең туган якларын, туган авылын, аннан да бигрәк утызынчы елларны исенә төшерми. Ул күбрәк үзенең Казанда укып йөргән заманнары турында гына сөйләргә ярата.

Әле дә, иртәнге урамнан төркемләшеп барганда да, ул тәмләп, тәфсилләп шул елларны исенә төшерде. Беренче елны Казанда бик авыр булган икән. Башлангыч сыйныфта укытуын ташлап, кемгәдер ияреп киткән дә барган Казанга. Танышы ярдәмендә пединститутны эзләп тапкан, «апшежитиегә» урнашкан. Имтихандагы сорауларның берсенә дә рәтләп җавап бирә алмаган. Ярый әле имтихан алучы укытучы татар кешесе булган. Кызганып «яхшы» куйган да, шуннан җайланып киткән. Укыган чагында ягылмаган салкын бүлмәләрдә торган, трамвайда билетсыз йөргәннәр, көне буена рәтләп ашамыйча-эчмичә, күңелсез лекцияләр тыңлаганнар. Буш вакытлары булдымы, студентларны урам чистартырга, шәһәр читендәге төзелешләргә алып бара торган булганнар. Шулай да ачлыкка, мохтаҗлыкка карамыйча, кичләрен әдәби кичәләргә, җыелышларга, концертларга йөргәннәр. Бер кичәдә Фәрхәнә апа бик-бик якыннан Такташны да күреп калган, аның ялкынланып шигырь укуын тыңлаган.

Һәркем үз уена бирелеп, яшьләр тын да алмый тыңлап бардылар. Фәрхәнә апа сөйләгән һәр нәрсә аларга искиткеч булып тоелды.

— Уф! Бездән булмас инде ул, Фәрхәнә апа,— диде Җәмилә, авыр көрсенеп.

— Нишләп булмасын?— диде Фәрхәнә апа.— Тәвәккәл таш йоткан. Тәвәккәлләргә кирәк.

— Тәвәккәлләп кенә булмый шул, Фәрхәнә апакаем,— диде Җәмилә.— Без инде гәзитләрдә язылган бер белдерүне дә калдырмый укып барабыз. Кайсына карама, беренче сүз итеп: урыс теленнән имтихан дип куелган. Урыс теле суя безне, Фәрхәнә апа. Калганын без аның шартлатып бирериек.

— Казан булып Казанда бер татарча институт юк,— диде Сәкинә дә, сүзгә катышып.— Татарча укытсалар, беребез калмый барып керериек.

— Укытсалар дисең! Имтиханны татарча алсалар да әле!— диде Җәмилә.

— Безнең заманда бар иде,— диде Фәрхәнә апа.— Барлык институтларда татар теле укытыла иде.

— Бик кызык булгандыр ул, иеме, Фәрхәнә апа!— диде Назиф.

— Кызык инде... үз телеңдә...— диде Фәрхәнә апа.— Пединститутта хәзер дә татар теле бүлеге бар диләр бит.

— Безнең пединститутка керәсе килми шул,— диде Җәмилә, көттеребрәк.— Без, Фәрхәнә апа, медицинскига кермәкче булганыек.

— Нишләп үткән заманда сөйлисез?— диде Фәрхәнә апа.— Ныклап уйламадыгызмени әле?

— Нинди заманда сөйләшергә дә белмәссең инде, Фәрхәнә апа,— диде Җәмилә, ничектер аңлаешсыз итеп.

— Җәмиләнең фигыль заманнарын буташтыра торган гадәте бар бит аның, Фәрхәнә апа,— диде Габделхәй.

— Абау! Син генә инде!— диде Җәмилә шундук.

— Аттестат кесәдә — нинди заманда сөйләшсәк тә ярый!— диде Назиф, остарып.

Кызлар көлешеп алдылар. Хәтта Фәрхәнә апа да елмаеп куйды. Куанычтан Назифның йөзе балкып китте. Беркадәр араны яшьләр «фигыль» һәм «заман» темасын төрләндереп, көлешеп бардылар да, киләчәкнең һич тә көлке түгеллеген уйлап, янә тынып калдылар.

## XIX

— Эх, Фәрхәнә апа!— диде Җәмилә бераздан тагын да авыр көрсенеп.— Дәрт бар, дәрман юк. Унны бетердек — инде нишләргә? Аптыраш. Яңавылда каласы килми. Монда рәтле эш тә юк. Читкә китәсе килә, кеше буласы килә.

«Читкә китәсе, кеше буласы килә...»— диде Фәрхәнә апа да үзалдына. Ул инде белә мондый нәрсәләрне. Заманында ул да шулайрак фикер йөртте. Үз иленңдә, үз җиреңдә берни юк, читтә генә тутырып куйганнар сыман тоелды. Юк, читтә дә тутырып куймаганнар. Читтә мондагыдан да авыррак, кыенрак булачак. Кайда гына җиңел соң ул?! Шулай да хәзер аның бу турыда сүз куертасы, яшьләрнең болай да иләс-миләс күңелләрен кырасы килмәде.

— Сез нишләргә уйлыйсыз?— диде ул, Сәкинәгә эндәшеп.

— Белмим әле, Фәрхәнә апа,— диде Сәкинә, теләр-теләмәс кенә.

— Нишләп белмисең?!— диде Җәмилә.— Менә шушы тиле Җәмилә белән Казанга медицинскига китәргә ниятләп торабыз диген — яр да сал!

— Аны син ниятлисең — мин түгел,— диде Сәкинә, үзсүзләнеп.

— Кит, билләһи газим! Бу кадәр булгач та булырсың икән!— диде Җәмилә, дусын оялтмакчы булып.

— Яңавылда чәйханә ачам, шуның директоры булам,— диде Назиф, остарып.

Кызлар тагын көлешкән булдылар. Назифның көтмәгәндә шулай берәр тапкыр сүз әйтеп көлдерә торган гадәте бар иде. Әйткән сүзе бик үк көлке булмаса да, кызлар аның һәр сүзеннән көләргә генә торалар иде.

— Мине официантка итеп алырсың, яме!— диде Нәзирә, Назифның авызына керердәй булып.

— Тапты! Сине генә аласы килеп торадыр Назифның,— диде Галимә.— Аның үз официанткасы бар ич!

Барысы да пырхылдап көлеп җибәрделәр. Назифның шат йөзе сүрелеп калды. Җәмилә исә артына борылды да Галимәгә күзен акайтып алды.

— Чәйханәдә синең эшләр тәгәри инде, иеме, Назиф!— диде Галимә, Җәмиләнең ачулы күз карашына әз генә дә исе китмичә.— Безнең аяк очка сазлыкка йорт салырсың, сыер алырсың, үрдәк үрчетерсең.

— Чучка симертерсең,— дип куйды Сәкинә дә.

Яшьләр тагын көлешергә тотындылар.

— Юк, мин чучка да симертмим, үрдәк тә асрамыйм,— диде Назиф җитди итеп.— Чучканың исеннән җирәнәм. Сез мине көферлеккә этәрәсез. Татар чучка асрамый, үрдәк тотмый. Иң яхшысы — мин корт асраячакмын. Минем, Фәрхәнә апа, беркая аягым тартмый. Барысы да институтка китеп бетсә, Яңавылда рәтле кеше дә калмас.

— Син каласың ич рәтле кеше булып,— диде тагын да Сәкинә.

— Аңа бит чәйханәгә йөрүче кеше дә кирәк булачак,— диде Нәзирә.

— Чәйханәгә рәтсез кешеләр йөрсә дә ярый — директоры гына рәтле булсын,— диде Фәнәви, Назифны яклаган булып.

— Юк, иптәшләр, чәйханәдә эш бармый. Акча да төшми, өскә чыгарга гына тора.

— Лутчы мин үзебезнең Этккенәвылга кайтып, Җаббарен абый урынына колхоз персидәтеле булам!— диде Назиф.— Йөрәк әрни. Колхоз күтәрәмдә. Халык ач-ялангач. Сез менә барыгыз да шәһәргә качып китмәкче буласыз. Кем туйдырыр сезне?

— Син!— диде Сәкинә.

— Акылыгыз алтын икән!— диде Назиф.— Менә шулай качышып беткәнгә күрә авылда җүнле кеше юк.

Яшьләр тынып калдылар. Назифның чын күңелдән сөйләвен һәркем яхшы белде. Аңа каршы ни дә булса әйтеп тә, аның сүзләрен көлкегә әйләндереп тә булмый иде. Бу бик авыр һәм катлаулы мәсьәлә иде. Бүген андый мәсьәләләрне искә төшермәгәндә дә яхшы булыр иде. Ләкин берни эшләп булмый. Назиф шундый. Назиф авыл малае, чын авыл малае.

Шулай да, бара торгач яшьләр сүзне яңадан уенга борып җибәрделәр һәм булачак колхоз персидәтеленнән төрлечә көләргә тотындылар. Арада бер генә кеше — Габделхәй генә тупас шаяртуларга, тупас хыялларга катнашмаска тырышты. Аның киләчәге башкаларныкы кебек томанлы, икеле-микеле түгел. Туып килгән яңа көн кебек якты һәм аяз. Аның өчен бар нәрсә ачык һәм аңлаешлы. Менә шундый чакта ниндидер чәйханәләр, чучкалар, үрдәкләр турында сөйләү — хәтта шаяртып кына сөйләү дә!— аның өчен күңел рәнҗеткәч бернәрсә булып тоелды. Бу әле бүтәннәрнең киләчәгенә кагылганда шулай. Әгәр дә мәгәр мондый нәрсәләр аның үз киләчәгенә кагылышлы рәвештә сөйләнелсә, аның өчен бу мең мәртәбә авыр һәм күңелсез булыр иде. «Ярый әле мин Назиф түгел»,— дип уйлады ул күңеленнән сөенеп.

Тик шулай да аның да киләчәге ал да гөл түгел. Беренчедән, әле булса аның күңелен медаль тырный. Дөрес, өлгергәнлек аттестатында барлык фәннәрдән дә — «отлично». Ләкин шул ук вакытта... Эх, искә дә төшерәсе килми? Аннан соң Василий Михайловичның татар мәктәпләре, татар теле, татар әдәбияты турындагы сүзләре дә аны бик нык борчуга салды. Ул, билгеле, аның бер генә сүзенә дә ышанмады, тик шулай да җитәкчеләр тарафыннан татар теленә карата булган мөнәсәбәтне ул күрмәде-бел-

мәде түгел. Болардан башка да кайгы-борчулар җитәрлек. Бүтәннәр кебек ул да газитләрдән иң элек белдерүләр укыды, кайда нинди институт барлыгы белән, кайда нинди фәннәрдән имтиханнар тапшырырга кирәклеге белән кызыксынды. Аннан да бигрәк ул институтларның кемнәрне әзерләп чыгаруларына игътибар итте. Институтларның барысында да диярлек агрономнар, инженерлар, конструкторлар, укытучылар, медиклар, тагын әллә кемнәр, әллә кемнәр әзерләнә диелгән. Тик аларның берсендә дә әдәбиятчы, шагыйрь дигән кеше әзерләп чыгарыла диелмәгән. Бик гаҗәп нәрсә иде бу. Аныңча, Казанда, һичшиксез, татар шагыйрьләрен җитештерә торган ниндидер уку йорты булырга тиеш иде. Ләкин Габделхәй, Разия апа янына кереп, Казаннан килгән татарча гәзитләрне никадәр җентекләп укымасын, берничек тә андый институт барлыгын белә алмады. Бу хакта аның кемнән дә булса сорыйсы килмәде — сорадың исә, «шагыйрь буласы кеше, шуны да белми» дип көләрләр сыман тоелды.

Габделхәйнең бернигә катышмый баруына иң элек Фәрхәнә апа игътибар итте.

— Нишләп тынып калдың әле, Габделхәй?— диде ул.— Син кая китәргә, нишләргә җыенасың?

— Кая булсын — Казанга, шагыйрьләр янына!— диде Җәмилә, Габделхәй өчен җавап биреп.

— Башта берәр атаклы язучыга самавырчы малай булып керер инде,— диде Назиф, шундук элеп алып.

— Юк, башта Әхмәт байга приказчик булып керергә туры киләчәк аңа,— диде Нәзирә.

— Әхмәт бай карамагына барып капкач, шагыйрь булалмый инде ул,— диде Фәнәви.

— Бай абзыйның кызына өйләнеп җибәрсә, шагыйрь булып торасы да юк,— диде Назиф.

— Әхмәт байны Әмрикәгә качып киткән диләр бит,— диде Габделхәй, иптәшләренең шаяртуына җайлашып.

— Китсәни! Син дә шунда китәрсең,— диде Назиф. «Надан!» дип уйлады Габделхәй дусты турында. Кем сине Әмрикәгә җибәрсен?! Шулай да уендагысын кычкырып әйтмәде — алар бит мәңге дус-тату булырга ант бирделәр!

— Мин, әйдә, Мәскәүдән ары китеп йөрмәм инде,— диде ул.

— Мәскәүгә?!— диде Фәрхәнә апа, чын күңелдән гаҗәпләнеп. Ул, ахрысы, яшьләрнең сүзенә бик үк игътибар да итми иде.— Иң яхшысы Казан инде сиңа, Габделхәй.

— Без дә шулай дибез бит, Фәрхәнә апа,— диде Җәмилә.— Габделхәй Казанга барып урнашса безне дә тарттырып алмас микән дибез.

— Алды, көтеп тор!— диде Назиф.— Казанга бер барып урнашса, бөек татар шагыйре Хаптел-эл-Хай безнең ишеләргә сәлам дә бирми инде ул!

Бу Назиф бер остара башласа һич туктый белми. Шуңа күрә аның шаяртуы еш кына үзара бозылышу белән тәмамлана да. Хәзер дә аның шулай үзен шәп кеше итеп тотуы, туктаусыз үзеннән көлүе Габделхәйнең кытыгына тиде. «Синең ише персидәтелләргә әйләнеп тә карамасыем!»— дип әйтәсе килде аның, ләкин әйтмәде, тагын кичәге антлары исенә төште. Аннан соң, алар инде Фәрхәнә апаларның өйләренә якынлашып киләләр иде.

— Их, килеп тә җиттек!— диде Җәмилә үкенү белән.

— Киттек кирегә!— диде Назиф.

— Персидәтел булгач та, бу безне гел үзе артыннан ияртеп кенә йөртмәкче була,— диде Габделхәй.

— Кире китеп тормыйк инде — әйдәгез безгә кереп чәй эчеп чыгыйк,— диде Фәрхәнә апа.

— Юк, юк, кермибез!

— Рәхмәт инде, Фәрхәнә апа!— диештеләр яшьләр. Ләкин аерылышып китә алмыйча озак кына саубуллашып тордылар, һәркемнең әйтелми калган ниндидер кадерле, бик кадерле сүзләрен әйтәсе килде. Ләкин кадерле, иң кадерле сүзләр дә иң гадәти саубуллашу сүзләре булып чыкты. Кызлар, аналарына елышкан иркә балалар кебек, хискә бирелеп Фәрхәнә апага елыша төштеләр, берсе бер яктан, икенчесе икенче яктан аның күкрәгенә капландылар. Фәрхәнә апа аларның башларыннан, аркаларыннан сыйпады, юату сүзләре әйтте.

— Фәрхәнә апакаем! Шундый яраттык без сине!— диде Җәмилә, балаларча сулкылдап.

— Килеп йөрегез, ташламагыз,— диде Фәрхәнә апа.

— Килербез, Фәрхәнә апа,— диде Җәмилә, яшьле күзләрен сөртеп, көләргә тырышып.— Әллә нәрсә булды, Фәрхәнә апа. Кичәдән бирле җылыйсым килә.

Кызлар укытучы апалары белән кочаклашып җылашканда малайлар тын гына читтә басып тордылар. Менә кызлар да әкрен генә, ипләп кенә кузгала башладылар. Артларына карый-карый малайлар да кузгалды.

— Габделхәй!— диде Фәрхәнә апа китеп баручылар ягына эндәшеп.— Онытканмын — вакытың булса килеп чык әле бүген.

— Ярар, килермен,— диде Габделхәй.

— Сау булыгыз! Сау бул!— диде капка төбендәге Фәрхәнә апа еракլаша барган «иптәшләр»гә кул болгап.

## Икенче бүлек

Үзе артыннан капканы ябып иркен ишегалдына килеп керү белән Фәрхәнә апаны башка төрле уйлар биләп алды. Иң элек ул Дәүләтгәрәй абзыйны исенә төшерде — йокыдан тора алды микән, сыерны савып көтүгә чыгара алды микән? дип уйлады. Аннары Йосыф исенә төште. Йосыф бүген төнлә балыкта булырга тиеш иде. Кайтты микән? диде. Берәр нәрсә алып кайта алды микән? дип тә уйлады.

Чолан ишеге ярым ачык иде — димәк, көтү киткәндә йоклап калмаганнар. Фәрхәнә апа туры өйгә кереп тормады. Күңелен тынычландыру өчен иң элек абзар капкасын ачып карады. Капканы ачу белән борынына җылы тирес катыш чи печән исе килеп бәрелде. Абзар буш иде. Бары тик түбә астындагы печәнлектә бер тавык кына дөнья бетереп, тавыш куптарып кытаклап ята иде. Абзарга күз ташлап алгач, Фәрхәнә апа бакча ягына керде. Бакчаның аргы башында бәрәңге арасында тибенеп йөргән күрше тавыкларын куалап чыгарды да, үзе югында йорт-җирнең исән-имин торуына тәмам ышанып, күңеле тынычланып өйгә керде.

Ул өйгә килеп кергәндә Дәүләтгәрәй абзый кече якта мич алдында самавыр куярга азапланып ята иде.

— Йосыф кайттымы?— диде Фәрхәнә апа беренче сүзе итеп.

— Кычкырма шул чаклы!— диде Дәүләтгәрәй абзый пышылдап, ярым йокылы тавыш белән.

— Ни булды тагын? Йоклыймени?— диде Фәрхәнә апа, иренең кисәтүенә артык исе китмичә.

Дәүләтгәрәй абзый җавап биреп тормады, самавырын көйләп яндырып җибәрде дә Фәрхәнә апаның беләгеннән тотып алды һәм «әйдәле, әйдә!» дигәндәй, серле бер кыяфәттә аны олы якка алып чыкты.

Алты почмаклы өйнең яртыдан күбрәген алып торган олы якның түрендә, никельле карават янында ниндидер ят чемодан тора иде. Караватта исә, түшәмнән идәнгә кадәр салынып торган бизәкле чаршау артында, йомшакта, кара чәчләре тәртипсез рәвештә таралып төшкән ниндидер яшь кыз йоклап ята иде. Дәүләтгәрәй абзый әлеге кызны Фәрхәнә апага күрсәтеп алды да, күз тиюдән курыккан сыман, чаршауның ачык калган итәген җыештырыбрак куйды. Чаршау эченнән шәһәрчә ят исләр катыш җылы тән, җылы тын исе килеп бәрелде.

Фәрхәнә апаның йөзе балкып китте.

— Былбыл түгелме соң?— диде ул Дәүләтгәрәй абзыйга, пышылдап.

— Былбыл дисәң дә ярый, Сандугач дисәң дә ярый,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

Аяк очларына гына басып, алар читкәрәк киттеләр. Ләкин никадәр сак һәм йомшак атларга тырышмасыннар, ике авыр кешенең артыннан идән сайгаклары шыгырдап калды. Йомшак түшәккә чумып яткан кыз, йокы аралаш нидер сизенеп, нидер ишетеп, урынында кыймылдап куйды. Аннан соң аякларын сузып җибәрде, күзләрен ачты. Өстендәге авыр ябынгычын бер якка селтәп ташлады да торып утырды, бер кулы белән чаршауга тотынып, икенче кулы белән карават башындагы күлмәкләренә үрелде. Киенеп алгач, яланаяк килеш тып итеп идәнгә басты. Идән такталары ап-ак, тигез һәм шома иде.

Кызның аягына басканын күреп, Фәрхәнә апа кире олы якка чыкты. Ашык-пошык чәчләрен рәтләп, иртәнге кояш сыман балкып-елмаеп Былбыл Фәрхәнә апага таба атлады һәм яшь, кайнар беләкләре белән аның тыгыз тәнен кочып алды.

— Чибәрттәй! Исәнме, чибәрттәй!— диде ул, сандугачныкыдай шат тавыш белән сайрап.

— Карале, Былбыл! Нинди үскән — танырлык та түгел!— диде Фәрхәнә апа, исе китеп. Былбыл җавап итеп көлеп җибәрде.

— Өйдәгеләр таза-саумы?— диде Фәрхәнә апа.

— Барысы да исәннәр, күп-күп итеп сәлам әйттеләр,— диде Былбыл, бөтен өй эчен күңелле шау-шу белән күмеп.

— Әтиең, әниең?.. Ник алар да килмәде?— диде Фәрхәнә апа, сорау артыннан сорау яудырып.

— Әти дә, әни дә исән... барысы да исән-сау,— диде Былбыл.— Отпусканы икесе дә көз көне алачаклар, икәүләшеп Кисловодскига китәчәкләр. Әни әйтте, чибәрттәңне минем өчен дә үп, диде, менә шулай, менә шулай итеп үп, диде...

Былбыл, әнисенең ничек итеп үбәргә кушканлыгын күрсәткән сыман, Фәрхәнә апаның әле бер як битеннән, әле икенче як битеннән үбеп-үбеп алды, Фәрхәнә апа, әлерәк кенә үзенең укучылары янында уңайсыз елмаеп торган кебек, бу юлы да елмаеп тик торды.

Олы якның ачык ишегеннән керергә кыймыйча торган Дәүләтгәрәй абзый үзенчә шаярткан булып:

— Картайдык. Үбү түгел, кызлар хәзер безнең якка әйләнеп тә карамыйлар,— диде.

— И-и, җизнәй, сине күргән дә юк,— диде Былбыл, сөенеп.

— Кайчан килдең, ничек килдең?— диде Фәрхәнә апа.

— И-и, чибәрттәй, мин инде кичәгенәк үк килеп

җитәргә тиешием,— диде Былбыл, ниндидер күңелсез нәрсәне исенә төшермәкче булып.

Ләкин бу минутта аның йөзендә әз генә дә күңелсезләнү билгесе күренмәде. Аның йөзе, күз карашы, бөтен кыяфәте ташып торган шатлык-куаныч белдерде. Ниндидер күңелсез нәрсә турында әйтергә тиешле сүзен ул азагына кадәр әйтеп бетермәде, шундук этисенә күчте, аның әледән-әле авырып китүе турында, әле күптән түгел генә больницада ятып чыгуы, хәзер инде рәтләнә башлавы турында тезеп китте. Әтисенең бик каты авыруы турында әйткәндә дә аның йөзендә әз генә дә кайгы-борчылу сизелмәде. Ул, әйтерсең, гомумән күңелсезләнә белми иде, ул, әйтерсең, бары шатлана гына, бары көлә-елмая гына белә һәм шунлыктан үзе янындагы бар нәрсәгә яктылык, гүзәллек кенә тарата иде.

Тиз арада ул өстендәге күлмәген җайлап алды, кулындагы тарак кисәге белән чәчләрен тараштырды һәм шул ук вакытта сөйләнүдән, сөенүдән, гаҗәпләнүдән туктамыйча, иркен, биек яңа өйнең түшәменә, бүрәнәләренә күз йөртеп чыкты; тәрәзә янындагы китап-дәфтәр куелган бәләкәй генә өстәл өстендә бәләкәй генә көзге күреп, тиз генә каранып килде.

## II

— Бүген мин таң тишегеннән килеп кердем сезгә,— диде Былбыл, туктаусыз сөйләнеп.— Җизнәйне ныклап күрмәдем дә әле...— Шул чакны ул ишектә елмаештырып басып торган җизнәсенә карап алды да өзелгән сүзен дәвам итеп: — Исәнме, җизнәй... тагын бер исәнләшик әле,— диде.— И-и, чибәрттәй, мин инде кичәгенәк үк килеп төшкән булырыем. Беренче көнне билет алып булмады. Килгәндә машиналары ватылды. Ике якта да урман. Туктадык та утырабыз... Син кайда булдың, чибәрттәй? Җизнәй әйткәнне — мәктәптәме? Мәктәптә, әйе? Вечер булдымы? И-и, чибәрттәй, и-и, җизнәй!.. Шофер сүгенә. Машинаны сүгә, начальствоны сүгә. Ачуым килеп бетте шуңа. Төштек тә җиләк эзләргә тотындык. И-и, чибәрттәй, җиләк шундый күп! Рәхәтләндек. Кайчан җиләккә барырбыз икән? Гел шуны уйлап килдем. Әйдәгез бүген үк?! Менә берзаман шофер кычкыра башлады... пип-тә-пип! Ачуым килеп бетте шуңа. «Әйдәгез, киттек!»— ди. Тотындык чабарга. Ботакка эләгеп бер хатынның күлмәк итәге җыртылды. Үзем йөгерәм, үземнең көләсе килә.

Ул тыныбрак торган арада Фәрханә апа бер-ике сүз кыстырып куйды.

— Карамый йөрсәң шулай була ул,— диде.

— И-и, чибәрттәй, кая ул анда карап йөрү?! Пип-тә-пип!— кычкырта да кычкырта. Ачуым килеп бетте шул шоферга,— диде кунак кызы һәм җыртылган күлмәк итәген күз алдына китереп, ахрысы, рәхәтләнеп көләргә тотынды.

Шуннан соң ул, нидер исенә төшеп, ашыгып кече якка китеп барды, каяндыр бик ерактан үзенең туган якларын сагынып кайткан кеше сыман, өй эчендәге бөтен нәрсәне күздән кичерде, әледән-әле исе китеп, карале, кара! диде, нинди матур! диде, тәрәзә төбендә шау чәчәктә утырган тамчы гөл янына килде дә беренче мәртәбә күргәндәй аһылдап җибәрде, иснәп карады, нәфис бармаклары белән гөлләргә кагылгалап алды. Шуннан соң яңадан үзенең юлда күргәннәрен сөйләргә тотынды.

— ...Килеп җиттек тә, чибәрттәй, булдымы, киттекме? дибез...— Бу вакытта кунак кызы су чәчрәтә-чәчрәтә кече якта битен-күзен юарга тотынган иде.— Булды ди, машина астыннан кычкыра. Юри чакырган икән. Берәрегез ручканы әйләндерегез әле, ди. Бу безне шуның өчен чакырган икән. Ачуыбыз килеп бетте шуңа. Әллә ничаклы маташты шул машинасы белән. Караңгы төшә башлады... Туктале, Йосыф кая соң? Мин аны күрмәдем, чибәрттәй.

— Мин дә күрмәдем әле,— диде Фәрхәнә апа.— Балыкка киткән бугай ул.

— Пассажирлар сукрана,— диде Былбыл битен сөртә-сөртә, чибәрттәсенең сүзләрен тыңлап та тормыйча.— Ух та вах киләләр, хәерсез юлга чыктык, диләр, төн кунарга туры килә инде, диләр. Миңа кызык. Машинасын төзәтә алмасыные мин әйтәм, төнне шушында кунарыек, мин әйтәм. И-и, чибәрттәй, тәки теләгем кабул булды!— диде ул һәм кинәт көлеп җибәрде.

— Җүләр,— дигән булды Фәрхәнә апа.

— Әйтмәсәң дә җүләр инде,— диде Былбыл бик тиз килешеп.— «Җүләр»не ул үзенә карата әйтелгән мактау сүзе дип белде, ахрысы.— Төнлә урманда адашып йөрергә яратам мин, чибәрттәй! Минем әле төнлә Агыйделдә су кергәнем дә бар. Быел әни җибәрмәде. Курыкталар. Нәрсәдән куркалардыр, исең китәр!

— Уфа автобусы кичке биштә килә түгелме соң?— диде Дәүләтгәрәй абзый, сүзгә катышып.

— Биштә,— диде Былбыл.— Без төнге өчтә килеп төштек. Таң атканда. И, шундый матур таң атканда! Таң атканны күргәнең бармы синең, чибәрттәй? Икенче мәртәбә беркайчан таң атканда йоклап ятмаячакмын.

— Алайса синең йокың да туймагандыр инде,— диде Фәрхәнә апа.

— Туймаса тагын!— диде кайгыра белми торган кунак кызы үз-үзеннән көлеп, чак-чак кына масаеп.— Машинада килгәндә дә йокламадым мин — гел тирә-якны карап килдем. Нинди матур сезнең яклар! Мин гел сездә генә торырыем, чибәрттәй!

Сүзен әйтеп бетерер-бетермәс ул яңадан олы якка чыгып китте, әле бер тәрәзә янына, әле икенче тәрәзә янына килде, узышлый гына тагын бәләкәй өстәлдәге бәләкәй көзгегә карап алды, чәчләрен төзәткәләде, аннан соң бакча ягындагы тәрәзәне иңеләй ачып җибәрде дә тәрәзәдән башын тыгып:

— И-и, чибәрттәй!— диде.— Нинди күңелле, нинди тыныч сездә! Былтыр килгәндә сезнең өегез кечкенәе, тәбәнәк кенәе. Хәзер шундый иркен.

— Былтыр түгел, былтырдан элекке җыл,— диде Фәрхәнә апа, төзәтеп.— Ул чакта син үзең дә кечкенә идең.

— Мин беркайчан кечкенә булмаганмындыр кебек,— диде Былбыл.

— Бик үскәнсең, үзгәргәнсең,— диде Дәүләтгәрәй абзый да кызны мактап.

— Чынлапмы, җизнәй?— диде Былбыл һәм кырт кына җизнәсенә таба борылды да бөтен бите-күзе белән, бөтен килеш-килбәте белән балкып, нур чәчеп, елмаеп җибәрде.

— Чынлап булмыйча! Син хәзер — студент. Элек килгәндә укучы гына идең,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Үземне бер дә студент итеп сизмим әле,— диде Былбыл, чак-чак кына күңелсезләнгәндәй итеп.

— Имтиханнарыңны бирдеңме соң?— диде Фәрхәнә апа.

— Бирдем,— диде Былбыл артык исе китмичә.— Тиз-тиз генә бирдем дә үзебезнең Уфага кайтып киттем. Анда бер-ике көн тордым да менә монда килдем.

— Ничегрәк бирдең соң?— диде Фәрхәнә апа, төпченеп.— Син инде анда да «яхшы»га укыйсыңдыр?

— «Яхшы» түгел, «отлично». Барысы да «бишле». Ошамый миңа анда. Кешеләренә, шәһәрләренә ияләшә алмыйм. Яратмыйм Казаннарын, гел үзебезнең Уфаны, Агыйдел буйларын сагынам. Сезне сагынам.

— Шулай булмыйча — Казанның аның бернинди яме юк,— дип куйды Дәүләтгәрәй абзый, кунак кызының салпы ягына салам кыстырып.

— Шулаймы, җизнәй? Шулай бит, иеме, безнең Уфа матуррак бит, иеме?— диде Былбыл сөенеп.

— Шулай булмыйча!— диде тагын да Дәүләтгәрәй абзый.

Дәүләтгәрәй абзыйның яшь чагы Уфада узды. Ул анда техникумда укыды, курсларда укыды. Эше кушканга ай

саен диярлек аңа Уфада булырга туры килә иде. Шунлыктан Уфа аңа танышрак та, якынрак та иде. «Казан кызы» Фәрхәнә апа белән алар, уенын-чынын бергә кушып, кайчагында Уфамы, Казанмы матуррак, ямьлерәк дип җиңелчә генә бәхәсләшеп тә алгалыйлар иде. Хәзер дә Фәрхәнә апа иренең Уфаны мактаган булып Казанга тел тидерергә чамалавын сизеп алды һәм алдан ук үзенең бу мәсьәләгә мөнәсәбәтен белдерергә кирәк тапты.

— Уфаны хурлыйсым килми, шулай да Казан яхшырак,— диде ул ярым шаяртып.

— Теләсәң нәрсә әйт — Уфа ул Уфа инде,— диде Дәүләтгәрәй абзый да бирешәсе килмичә.

— Ура!— диде Былбыл, балаларча кул чабып.— Чибәрттәй җиңелде!

— Ярар, хәзергә җиңелдем,— дигән булды Фәрхәнә апа бик тиз килешеп.

Шуның белән бу турыда сүз дә бетте, бәхәсләшер җай да калмады. Былбыл тынып калды. Ләкин күп тә үтмәде, яңадан җанланып китте, ашыгып кече якка чыкты, шаулап утырган самавыр торбасын калкытып карады — торбадан төтеннең ничек чыгуын күрәсе килде, ахрысы. Ул арада өйгә ачы төтен исе таралып өлгерде.

— И җүләр,— диде Фәрхәнә апа.

— Җүләр шул,— диде Былбыл көлеп.— Мин аны янмый дип торам. Самавыр шаулавы ошый миңа, төтен чыгуы... Бөтен нәрсә ошый миңа. Сездә рәхәт. Суга барып килимме, чәбәрттәй?— диде ул кинәт мич янындагы буш бидерәгә күз төшереп.— Нинди эшегез бар — әйтегез.

— Бакчага күрше тавыклары кермәде микән — бар, куып чыгар алайса,— диде Фәрхәнә апа.

## III

Кояш инде чын-чынлап кыздыра башлаган иде, күк йөзе аксыл-зәңгәр иде, бары тик көнбатыш якта гына, офык читендә, җирнең кайсыдыр төшендә әле яңа таң атуын, хәтта караңгы булуын белдереп, куе зәңгәрсу пәрдә эленеп тора иде. Каршыда ямь-яшел бәрәңге бакчалары, киртәкоймалар белән аралашып, төзелешләре, тышкы кыяфәтләре белән бер-берсеннән әллә ни аерылмаган агач йортлар, каралтылар йокымсырап утыра. Еракта, йортлар-каралтылар артында, кырлар-басулар артында, иртәнге саф һавада аермачык булып Сакат таулары караеп күренә. Ерактагы таулар белән Яңавыл арасындагы тигезлектән, чип-чиста күк йөзендә кара төтен койрыгы калдырып, станциягә таба поезд шуыша. Поезд тавышы нишләптер ишетелми. Шуңа

күрә ул чын булып түгел, төштәме, кинодамы күргән поезд гына булып тоела, йортлар-каралтылар арасында әлегә бернинди хәрәкәт, ыгы-зыгы сизелми — бөтен җирдә җанны иркәли торган илаһи бер тынлык, тынычлык хөкем сөрә. Бары тик уңда, станция ягында гына әледән-әле паровозлар кычкырып куйганы ишетелә дә аннары якын-тирәдәге ишегалларында эт, кош-корт тавышлары ишетелә.

Тышка чыгу белән, баскычтан җиргә төшү белән Былбыл, дөньяның матурлыгына сокланып, туктап калды, як-ягына каранды һәм елмаеп җибәрде, йөгергәләп бакча ягына кереп китте дә суган түтәле янында үтешли яшел кыяк өзеп шытырдатып ашарга кереште. Суган ачысы әз генә дә тәэсир итмәде. Бәрәңге арасыннан сикереп атлый-атлый, йөгергәләп ул бөтен бакчаны карап чыкты. Бакчада бернинди күрше тавыклары күренмәде. Бары тик киртә баганасында каркылдап утырган кара карга гына, бәрәңге арасында йөргән ят кызны күреп, теләмичә генә очып китте.

— Кө-өш!— диде Былбыл, очып киткән карга артыннан кулын болгап.

Шуннан соң ул яңадан чоланга килеп керде.

— Карагыз әле, Йосыф кая соң?— диде, ачык өй ишегенә кычкырып.— Мин аны бик сагындым, чибәрттәй!

Яңа тактадан ясалган зур чоланның ике ягында да ике бүлмәсе бар иде. Былбыл чоланга килеп кергәч, сул яктагы бүлмә ишеге ачылып китте. Ишектән тузгыган чәчләренә мендәр мамыгы эләгеп калган, озын итәкле яшькелт күлмәге әвәләнеп беткән чандыр гына бер кызый килеп чыкты.

— Мине сагындыңмы соң?— диде кызый, Былбыл апасының юлына аркылы төшеп.

— Дездемона!— диде Былбыл, чибәрттәсе белән очрашкандагы кебек бөтен йөзе белән балкып.

Ул аны кочагына алды. Кызчык көлә-көлә нечкә беләкләре белән кунак апасының муенына сарылды.

— Буып үтерәсең!— диде Былбыл.— Онытмаган, Дездемона да онытмаган мине!

— Онытырга... әллә син минем туганым түгелме?— диде кызый, олыларча.

Шатланып шырык-шырык көлгән, ике куллап муеныннан, ике аяклап биленнән кочып алган кызыйны күтәреп, Былбыл өйгә килеп керде.

Алар каршысына Дәүләтгәрәй абзый килеп җитте.

— Чорсызланма, кызым,— диде Дәүләтгәрәй абзый Дездемонага.— Барыгыз юынып керегез. Тыштагы юынгычка җылы су салынган.

Былбыл белән Дездемона көлешеп, куышып яңадан тышка чыктылар. Киртә баганасына беркетеп куелган юынгыч янында Былбыл чандыр кызыйның иң элек башындагы, киемендәге мамыкларын сыпырып төшерде, аннан соң тарагын юешләп чәчен тарады. Дездемонаны юындыргач, үзе дә юри генә, әштер-өштер генә юынгандай итте дә яңадан алар көлешеп, узышып өйгә керделәр.

Кунак кыз хөрмәтенә чәйне олы якка әзерләгәннәр иде. Өстәл өстендә хуҗаларча шаулап җиз самавыр утыра, өстәлгә исә төрле савытларга салып тәмле ризыклар — баллар-майлар, ак күмәчләр куелган иде.

— Әйдәгез, утырыгыз,— диде Фәрхәнә апа, ягымлы елмаеп.

## IV

Мәктәп белән, сөекле укытучылары белән аерылышу тәэсиреннән тиз генә арына алмаган яшьләр беркадәр җир тын гына, моң гына атлап бардылар. Шулай да мондый тынлык, моңсулык озакка сузылмады. Беренче булып тынлыкны Җәмилә бозды һәм барысы да берьюлы диярлек дөнья хәлләре турында яңадан сүз башлап җибәрделәр. Дөнья хәлләре әлеге дә баягы бер үк нәрсәгә — «зур тормышка» аяк баскач нишләргә, кая, ничек атлап китәргә дигән төп мәсьәләгә барып терәлде. Берәүләр моңа җиңел караган сыман тоелды, күптән инде эчен тырнаган нәрсәне уен-көлке белән алыштырырга тырышты. Икенче берәүләр исә уфтанырга, кайгырырга тотынды. Күпчелек беркемгә катышмыйча, эндәшмичә калуны артыграк санады.

Алар шулай бер зур төркем булып, элегрәк бик үк сизелмәгән якынлык, туганлык тойгысы белән, Яңавылның яртылаш чирәм баскан киң урамыннан бардылар да Сталин клубы янындагы бакчага якынлаштылар. Сталин клубы да, бакча да күпләрнең танышу, очрашу һәм аерылышу урыны исәпләнелә иде. Клубка житәрәк алар туктап калдылар. Кемдер бакчага керергә, шунда сөйләшеп утырырга тәкъдим итте. Ләкин анда кереп сөйләшер сүз дә, теләк тә юк иде инде, ахрысы. Шулай бераз вакыт таптанып, икеләнеп торганнан соң, теләр-теләмәс кенә таралыша башладылар. Назиф белән Фәнәви Эткенәвылга кайтып киттеләр. Истәкләр — Истәккә, Уразылар — Уразыга юнәлделәр. Җәмилә, Сәкинә, Нәзирә Яңавылның бер ягындарак торалар иде. Кызлар бер-берсен култыклап алдылар, карлыгып беткән тавышлары белән «Гөлмәрфуга»ны көйли-көйли, шулай ук кузгалып киттеләр. Габделхәй дә аларга иярде. Ярты юлда Нәзирә үз-

ләренә кереп калды. Бер-берсенә үпкәләшкән сыман, Җәмилә белән Сәкинә дә, Габделхәй дә бик озак берни эндәшми бардылар. Беренче булып Габделхәй телгә килде:

— Кызлар янында болай бару килешми инде,— диде һәм Җәмилә белән Сәкинәнең икесен ике яктан култыклап алмакчы булды.

Сәкинә шундук кулын тартып алды, читкәрәк тайпылды. Җәмилә алдында аның шулай киреләнүе Габделхәйнең хәтерен калдырды.

— Ярар болай да,— диде Җәмилә дә, Сәкинә кебек үк читкә тайпылып.

Башланып китә язган сүз башланмый калды. Кыен, күңелсез бер тынлык барлыкка килде. «Соңгысы булсын! Моннан соң мин сине беркайчан озатып куймаячакмын»,— дип уйлады Габделхәй Сәкинә турында. Алдан килешенгән сыман, ләкин бернинди килешү булмаса да, Сәкинә белән Җәмиләне ул өйләренә кадәр озатып куярга тиеш сыман иде. Иң четереклесе шунда — Сәкинәләрнең өе якынрак, Җәмиләләрнеке арырак иде. Хәзер ул ничегрәк хәл итәргә дә белмичә барды. Ул яңадан сүз башлап карады, ләкин бу юлы да сүз ялганып китә алмады. Аның хәлен аңлагандай шул чакны Җәмилә туктап калды һәм беркемгә дә атап әйтмичә генә саубуллаша башлады.

— Тукта! Без сине озата барабыз ич!— диде Габделхәй, каушагандай итеп.

— Рәхмәт. Кифая түтәйләргә кереп чыгасым бар — өйдә микән, фермада микән,— диде Җәмилә.

Шулай диде дә, кызу-кызу атлап, якындагы тыкырыкка таба китеп барды. Шушы тирәдә аның чыннан да бертуган апасы тора иде.

Сәкинә белән Габделхәй ни әйтергә белми аптырап тордылар да берни эндәшмичә кире борылдылар. Сәкинәләрнең өе икенче яктарак калган иде.

— Никтер үпкәләгән,— диде бераздан Сәкинә.

«Синең кебек»,— дип әйтмәкче булды Габделхәй, ләкин әйтмәде — баягы ярсуы онытылган иде инде.

## V

Көн якты иде, кояш кыздыра иде. Урамнарда берәнсәрән атлылар, җәяүлеләр очрады. Парлашып серләшеп йөрү өчен һич тә уңай вакыт түгел иде. Шулай да нидер сөйләшергә, аңлашырга кирәк. Чөнки моннан соң очрашу өчен бернинди сәбәп тә булмаячак, Сәкинәне өйләреннән чакырып чыгару, бакчага-фәләнгә, киногa-театрга алып бару мөмкин дә булмаячак. Күптән инде Габделхәй үзенең сөй-

гән кызы бар дип исәпли иде. Үзенә бик күңелсез чакларда ул аңа үзенең эч серләрен сөйли, аның белән кайгы-шатлыкларын уртаклаша. Кисәк кенә очрашмый, серләшми башласалар, аңа, күрәсең, бик кыен, бик авыр булыр иде.

Сәкинә белән янәшә атлап барганда, ул беренче мәртәбә шул турыда уйлады һәм вакытның шундый тиз үтүенә, имтиханнарның шулай тиз бетүенә чын-чынлап үкенү хисе кичерде. Ләкин үкенсәң дә, үкенмәсәң дә хәзер инде берни эшләп булмый. Үткән вакытны, үткән имтиханнарны, үткән ун елны, хәтта менә кичә генә, бүген генә булган күңелле очрашуларны кайтарып та булмый, яңадан кабатлап та булмый. Адәм баласының һәр адымы, һәр сулышы күз алдында — сизелеп, күренеп!— артта кала бара, үлә һәм югала бара. Шулай ук Сәкинә белән бергә булган серләшүләр дә үлгән-югалган. Хәзергечә менә шулай эндәшмичә, үпкәләгән сыман барулар да үләр, онытылыр микәнни? Нинди кызганыч!

Аңа кинәт моңсу булып китте. Күңеленә берәр уй килде исә, шул кечкенә уен үстерә-үстерә, ул әллә нинди нәрсәләргә барып җитә һәм, нәтиҗәдә, очына-кырыена чыга алмаслык уй-хыяллар арасына кереп бутала да аптырап туктап кала иде. «Нишләп миңа үткән гомер кызганыч булып тоелды икән соң әле?» дип уйлады ул бераздан. «Сәкинә белән аерылышу кызганыч миңа»,— диде ул аннары уй җебенең очына чыгып. Җәмилә дә кызганыч. Бик кызганыч. Ләкин кайсы кызганычрак соң?

Шул ук минутта диярлек Сәкинә туктап калды һәм философ юлдашының катлаулы уйларын бүлдереп, гади генә итеп:

— Бар инде кайтып кит,— диде. Алар үзләренең чик буена — гадәттә туктый торган таныш җиргә килеп җиткәннәр иде. Бу — урам чаты иде, урам чатындагы амбар почмагы иде. Юлга чыгыбрак торган, бүрәнә башларына арба тәгәрмәчләре ышкылып киткән, сыерлар, сарыклар ешынып, төкләр, йоннар эләгеп калган амбар почмагы иде бу. Монда якында гына Яңавылның май заводы урнашкан һәм әлеге урам якка чыгыбрак торган амбар да май заводына карый иде.

Монда акка буялган тәбәнәк ялгыз йорт ягында һәрвакыт гүелдәп сепарат әйләнгәне, кемнәрнеңдер кычкырып сөйләшкәне, шакы-шокы китереп, тимер бидоннар күчергәне ишетелеп тора. Җәен-көзен, хәтта язын-кышын шул яктан, саф һаваны бозып, ачыган-күпчегән сөтэремчек, әйрән исләре килә. Ләкин мондагы гүелдеккә ят, авыр исләргә Габделхәй инде күптән күнеккән. Сәкинәне озатып куюының беренче көнендә үк аңа дөньяда

май заводы булган җирдән дә матуррак бер җир дә юктыр сыман булып, күпчегән сөт-эремчек исләреннән дә татлырак бер ис тә юктыр сыман булып тоела башлаган иде. Бу почмак артында, моннан бер йөз адымнар чамасы читтәрәк Сәкинәләрнең шомырт куаклары арасында бәләкәй генә өйләре балкып утыра. Кызын озата килгәч, аның әле бер генә мәртәбә дә шушы амбар почмагыннан ары узганы булмады — узарга рөхсәт юк.

Сәкинәнең инәсе авыру. Түшәк өстендә ята. Әтәсе элеваторда атлы эштә эшли. Өйдә Сәкинәдән башка кул арасына керердәй беркем юк. Бөтен йорт эше, инәсен карау-тәрбияләү тулысынча Сәкинә җилкәсендә. Йорт эшләре күп — сыерлары, сарыклары бар, зур гына бәрәңге бакчалары бар. Шуның өстенә тагын аларда ике бала ята. Аларны карау, көн дә бакчага илтеп кую, бакчадан алып кайту шулай ук Сәкинәгә йөкләтелгән. Кайчан гына булмасын, мәктәптән кайтуына аны таудай эш көтеп тора. Сәкинәнең хәлен аңлаганга күрә, озата килгәч Габделхәй аны беркайчан тоткарламаска тырыша.

Бүтән көннәрдә шулай булды. Бүген аның тиз генә аерылышасы килмәде. Сәкинәгә хәзер ниндидер бик кирәкле, бик кадерле сүз әйтәсе килде, аның белән ныклабрак сөйләшәсе килде.

— Туктале, китмәле,— диде ул кызның кулыннан тотып.

— Җибәр,— диде Сәкинә.

Тик шулай да тавышында башка көннәрдәге кебек кисkенлек, кирелек сизелмәде. Аның бу «җибәр»ендә хәтта якынлык, җылылык та бар иде бугай. Моңарчы үзенең кызыннан кирле-мырлы сүзләр генә ишетергә күнеккән Габделхәйне мондый җылылык, якынлык дәртләндереп җибәрде.

— Әйдә, тагын бераз йөреп киләбез,— диде ул.

Ипләп кенә, куркып кына ул аның йомшак кулына тотынды, яратып аны үзенә табарак тартты. Габделхәйнең ихтыярына буйсынып, Сәкинә сүзсез генә урыныннан кузгалды һәм алар, амбар почмагы ягыннан кузгалып, читкәрәк китеп бардылар.

Габделхәйнең үз гомерендә беренче җиңүе булды, ахрысы, бу беренче мәртәбә кызны үзенә буйсындыруы һәм беренче мәртәбә... буйсынуы булды, ахрысы, һич югы, аның үзенә бу шулай тоелды, чөнки моңарчы аларның яратышулары бер-берсе яныннан сүзсез генә атлап барудан ары узмады. Бу хәтта чын мәгънәсендә яратышу да түгел иде бугай. Моңарчы ул һәрвакыт кыз артыннан үзе тагыла һәм янәшә атлап барганда да аннан чак-чак кына артка калып

бара торган иде. Хәзер ул аны үзе ияртеп алып китте. Хәзер ул үзендә яңа көч-куәт барлыкка килгәнен тойды.

Беркадәр алар кулга-кул тотынышып бардылар. Шулай да Сәкинә кулын ычкындырырга кирәк тапты — урамда таныш-белешләр очрап куярга мөмкин иде.

— Болай да ярар,— диде ул.

Габделхәйнең хәтерен калдырудан курыккан сыман ул моны иплән кенә, ишетелер-ишетелмәс кенә әйтте.

— Ие шул,— диде Габделхәй.

Сәкинә җавап кайтармады — як-ягына каранып, моңсу гына атлавында булды.

— Апаңнан хат киләме?— диде Габделхәй, сүзгә башлап.

— Юк,— диде Сәкинә.

— Шуның балаларына бәйләнеп калырсың микәнни инде?— диде Габделхәй.

Аның тавышында «шуның балалары»на карата ачыктан-ачык яратмау, Сәкинәгә исә теләктәшлек һәм ярдәм итәргә әзер тору сизелде.

— Белмим,— диде Сәкинә, үлемгә дучар ителгән бер өметсезлек белән.

Ул карый торган балаларның инәсе — Сәкинәнең бертуган апасы Уфада тора иде. Сугыш елларында аның апасы медицина институтын бетергән, кияүгә чыккан. Моннан бер ел элек ике баласын, хатынын ташлап ире моның марҗага өйләнгән. Сәкинәнең апасы ниндидер «кантур»-да эшли икән. Былтыр җәй Яңавылга кайткач, ул әлеге балаларын калдырып китте. Киткәндә бөтенләйгә калдырам дип уйламагандыр инде. Бер-ике ай торсыннар әле, килеп алырмын дигән. Аның әле квартир ягы да җайлы түгел икән. Ире белән аерылышсалар да, бер үк квартирада — берсе бер бүлмәдә, икенчесе икенче бүлмәдә торып яталар икән. Мәхшәр инде, мәхшәр. Менә шул квартираны суд аша бүлешеп, аерым-аерым квартира ясыйсы бар икән. Хаста инәләре каршы килмәгән, калсыннар, ничек тә күз-колак булырбыз дигән. Әткәләре дә каршы килмәгән. Сәкинәдән сорап та тормаганнар. Балаларын калдырып киткәч, ана кеше көн аралаш диярлек хат язган, сагынам, фәлән-төгән дигән. Бер ай үтә, ике ай үтә — Уфадан кайтучы-килүче булмый. Бераздан боларга хат килеп төшә: ачуланмагыз инде, хәлем бик начар, акча җибәреп торырмын — кышка икесен дә бакчага урнаштырыгыз — фатир ягы җайланса, язга кайтып алырмын дигән. Менә кыш та үтте, яз да җитте. Быел җәй балаларның монда торып калуына бер ел булды. Апа кешенең хаты да юк, хәбәре дә юк. Үзе кайтып төшәргә итә микән әллә?

Болар турында Габделхәй Сәкинәдән ишетеп белде.

Җае чыккан саен ул Сәкинәнең апасын, балаларын белешеп торды. Сәкинә, билгеле, гомер буена апасының балаларын карап ята алмаячак. Хәзер аңа укырга китәргә, алай да булмаса, берәр эшкә керергә кирәк булачак. Моннан бер атна элек әтәсе-инәсе кече кызларыннан Уфага хат яздыралар: балаларыңны быел да кайтып алырга исәбең булмаса, үзең кайт Яңавылга, таза кешегә монда да эш табылыр, җавабыңны озак көттермә диделәр. Хатны алар май башында салганнар иде, хәзер инде июль.

— Аңа тагын язарга кирәк!— диде Габделхәй.— Беләсеңме, языйм әле үзем! Языйммы? Син күчереп җибәрерсең. Оялтып, гарьләндереп язарга кирәк аны, тетмәсен тетеп! Нинди ана ул үз балаларыннан аерым яшәүче? Аның җаны юктыр. Үзе институт бетергән, үзе врач. Аның сеңлесе — син, ун класс белемең була торып, көнтөн сыер саварга, кош-корт карарга, аның балаларын карарга тиеш! Бүген үк яз син аңа.

— Язып булмый,— диде Сәкинә сүлпән генә.

Аның шулай буйсынучан-тыныч тавыш белән җавап бирүе, әз генә дә бу гаделсезлеккә каршылык күрсәтергә тырышмавы Габделхәйнең кайнарлыгын сүрелдерә төште. Ул аптырап калды. Ул бит аңа — Сәкинәгә яхшы булсын өчен тырыша. Сәкинә ничек тә бу тормыш баткагыннан котылырга, ничек тә укырга, кеше булырга тиештер ич!

Габделхәй карашынча, кешеләр ике төркемгә бүленәләр иде. Аларның бер төрлесе — укыган кешеләр, икенче төрлесе — укымаган кешеләр. Укыганнарны ул тагын икегә бүлеп карый. Тормышка ачык максаты булган, ниндидер зур эшләр башкарырга омтылган кешеләр, аныңча, иң беренче баскычта, югарыда торалар. Икенче баскычта, түбәндәрәк — укыган, ләкин бернинди максаты булмаган кешеләр тора.

Аның уенча, укыган һәрбер кеше дан-шөһрәткә омтылырга һәм ниндидер бөек эшләр башкару турында хыялланырга тиеш. Барлык тырышлыклары, барлык максатлары йорт-җир, кием-салым, тамак кайгысыннан узмаган кешеләрдән дә кызганычрак беркем юк.

Сәкинә беркайчан аның кебек каядыр читкә китәргә, ниндидер зур эшләр башкарырга омтылмады. Аның күңелендә ниләр барын, гомумән, белә торган түгел иде. Бу яктан караганда ул һич тә Габделхәйгә тиң түгел. Аннары аны матур дип тә булмый — кыска буйлы, юантык кына, озын чәчләрен ике толымга үреп йөртә, күзләре яшькелт-зәңгәр. Ул бары укуда гына алдынгы. Шулай булгач, кайчан да булса ул барыбер югары үрләргә тиеш.

Начар укыган кеше югары үрли алмый. Аңа бары ярдәм итәргә, аны бары үгетләргә, ышандырырга гына кирәк.

Ни генә булмасын, аны монда сыер-сарык арасында, чит балалар янында калдырырга ярамый. Ничек тә аны үзеңнең артыңнан ияртергә кирәк. Революционерлар, укымышлылар кара халыкны агарту эшен иң элек хатын-кыздан башлаганнар. Хатын-кыз әле дә иң нык изелгән, иң хокуксыз халык. Татар хатыннары бигрәк тә. Менә аның җанлы мисалы. Юк, элек кенә ул шулай булган. Хәзер, билгеле, эшләр башкачарак. Ләкин шулай да Сәкинәне моннан, Яңавылдан алып китәргә кирәк. Кая? Әлбәттә, Казанга, бары Казанга гына!

— Карале,— диде ул бераздан,— балаларын илтергә дә ташларга Уфасына! Йортны, мал-туарны синнән башка да карарлар. Сиңа медицинскига түгел, берәр техническига китәргә була!

Уйламыйча, ләкин кычкырып әйтелгән үз сүзен ишетеп Габделхәй кинәт тынып калды. Хәзер ул үзе инанган фикерен түгел, бәлки, башкалар фикерен әйтә иде бугай. Василий Михайлович та аны шулайрак үгетләгән иде түгелме соң?!

— Юк инде, булмас, ахрысы,— диде Сәкинә, теләр-теләмәс кенә.

Габделхәй эндәшмәде. Сәкинәнең менә шул күңелсезлеге, дәртсезлеге еш кына аның кайнарлыгына салкын су сипкәндәй булды. Мондый чакларда ул нәрсә әйтергә дә белми аптырады да калды. Хәзер дә шулай булды. Алар кешесез тар урамнан беркадәр җир бардылар да кире борылдылар һәм яңадан таныш исләр аңкыткан таныш амбар янына килеп чыктылар. Сәкинә тәвәккәллек сизелеп торган бер үтенеч белән:

— Сау бул инде, Габделхәй. Бар инде кит,— диде.

— Ярый, сау бул,— диде Габделхәй.— Бүген кич Сталин клубына барасыңмы? Бар. Кинога керербез. Мин сине кичке... сигездә көтеп торырмын.

— Белмим әле,— диде Сәкинә.— Өйдә эш күп булмаса...

— Чыгасың алайса?

— Иртәгә, бәлки?

— Ярар, иртәгә!— диде Габделхәй.— Бүген булмаса — иртәгә, иртәгә булмаса — иртәгә соңга! Сәгать сигезгә.

— Сигезгә,— диде кыз, әкрен генә.

## VI

Габделхәй үзләренең ишегалдына киртә аша гына сикереп керде дә, өй ишеген шакып тормыйча, тактадан эмәлләгән бәләкәй генә лапасның печәнлегенә менеп

китте. Монда, түбә астында аның үзе җайлаган бик уңай урыны бар иде. Өс киемнәрен салып бер читкә куйды, иске ябынгыч астына кереп ятты да шундук йокыга китте.

Ул бик озак йоклады. Берзаман йокы аралаш табан астының кытыкланганын тоеп, уянгандай итте һәм артык борчылмыйча гына «чебен микәнни?» дип уйлады. Шулай да чебен аркасында гына йокысын бүлдерәсе килмәде — чебенне кугандай итеп аягын селтәде дә икенче ягына әйләнеп яңадан йокыга чумды. Күпмедер вакыттан соң бәйләнчек чебен яңадан табан астында йөри башлады. Габделхәй, аны-моны уйлап тормыйча, башын калкытты, торып утырды һәм тиз-тиз генә киенә башлады. Бит аның каядыр барасы, кемнедер күрәсе бар иде бугай!

Шул чакны астан иплә кенә кара әрем сузылганы күренде. Җиргә төшә торган баскычка арты белән утырып торган килеш күлмәк җиңен рәтләп булашкан Габделхәйнең аркасын әлеге әрем очы кытыклый башлады. Габделхәй моны ничектер күз кырые белән күреп калды. «Әһә, менә нинди чебен икән!» дип уйлады ул һәм юри күрмәмешкә салынып, үз эше белән мәшгуль булды. Әгәр артына борылып караса, әлбәттә, ул кече энесе Фидәилнең такыр башын һәм шат-хәйләкәр йөзен күреп алган булыр иде. Ул юри озаграк маташты. Әрсез әрем очы һаман югарырак үрелде, кыюланып абыйсының муенын кытыклады, колагына килеп җитте. Түземлеге төкәнгән абый кеше, бәйләнчек чебеннең кулыннан эләктереп алмакчы булып, кисәк кенә артына борылды.

Шат күңелле «чебен» абыйсының мәкерен сизмичәрәк калды. Тоттырмас өчен тиз генә иелергә йә булмаса баскычтан төшеп китәргә акылы җитмәде. Карчыгадай өстенә ташланган абыйсыннан ул ялт кына читкә тайпылды. Аның шулай тайпылуы булды, сөяп куйган ышанычсыз баскыч бер якка янтайды, малай исә икенче якка янтайды.

Мондый тамашаны күреп Габделхәй көләргә дә, жыларга да белмәде. Тиз генә төшеп энесенә ярдәм итәсе дә килде, шул ук вакытта тиз генә төшеп булмаганлыгын да шәйли алды. Фидәил исә беркадәр вакыт тыны-өне бетеп, исенә килә алмыйча ятты да ыңгырашып куйды, башын калкытты. Габделхәй анда-монда тотынып җиргә төшеп өлгергәндә Фидәил дә аягына басты. Энесенең пычранып, юешләнеп беткән өстен-башын, кызганыч кыяфәтен күреп, абый кеше тыела алмыйча көләргә тотынды.

— Шул кирәк сиңа, чебен! Икенче йоклаган кешене уятмассың,— диде ул.

Төшкән җире йомшак булганга, Фидәилнең берние дә

имгәнмәгән иде бугай. Шулай да, җыларгамы-җыламаскамы дигәндәй, икеләнебрәк торганда, абыйсының үзеннән көлүен күреп-ишетеп, хурланып малай акырып җибәрде. Кинәт җылавыннан туктап калды һәм бар тавышына:

— Сәкинә! Сәкинә!— дип кычкыра башлады. Габделхәйнең моңа әллә ни исе китмәде — тыела алмыйча һаман көлүендә булды.

— Сәкинә кияве, Сәкинә кияве!— диде Фидәил бөтен тирә-якка ишетелерлек итеп.

Бу юлы инде Габделхәй көлүдән туктап калырга мәҗбүр булды.

— Чебен! Күрсәтермен әле мин сиңа кияүне!— диде ул, энесе артыннан ташланып.

Фидәил, артына борылып карый-карый, үртәшә-үртәшә туп-туры өйгә йөгерде. Абый кеше аның артыннан ашыкты. Хәзер аның Фидәилнең кирәген бирүдән бигрәк, өйдәгеләрне энесенең ничек итеп әрем белән кытыклап азаплануын, ничек итеп җиргә егылып төшүен сөйләп көлдерәсе килде. Ләкин аңа кызык хәлне сөйләп көлдерергә туры килмәде. Каршыга коты алынган Фидәил килеп чыкты. Аның артыннан ук диярлек кулына корымланып беткән кыскыч тоткан инәләре күренде. Габделхәй белән алар чак-чак кына бәрелешми калдылар.

— Күземә күренмә! Туп-туры җылгага йөгер!— диде инәсе, Фидәил артыннан кычкырып.— Кичә генә юдым күлмәген. Адәм хуры, җитмәсә, шул көе өйгә килеп кергән.

Габделхәй инәсенең ачулы булуын тиз генә чамалый алмады. Фидәилнең баскычтан егылып төшүе турында сөйләмәкче булып авызын гына ачкан иде, Шәмсебанат апа әрнеп, ачынып:

— Йөрисең шунда, олы самый,— диде.— Тапкан көлер нәрсә, дивана!

Олы тормыштагы, яңа тормыштагы беренче көн Габделхәй өчен менә шулай башланды.

## VII

Габделхәйнең шундук авызы йомылды. «Сәкинәне озатып куйганны яратмый микәнни?» дип уйлады ул инәсе турында. Шулайдыр. Берәрсе күргәндер дә әйткәннәрдер, әнә малаең кызлар белән йөри башлаган дигәннәрдер. Фидәил дә юкка сөйләнмәс. Тыңлап торгандыр. Сиздермичә тыңлап торырга, читтән генә күзәтеп торырга аңа гына куш.

Габделхәй, өйдәгеләр ягына әйләнеп карамаска тырышып, ишек төбендәге почмак янына килеп, өстен-башын

чишенә башлады. Өф итеп кенә тота торган, яхшылыкка гына киелә торган пинжәген салып чөйгә элмәкче булган иде, пинжәктәге үрмәкүч авы сыман чүп-тузан күреп, шунда гына каккалый-суккалый башлады. Шуны гына көтеп торган кебек, инәсе шундук сукранырга тотынды:

— Как әйдә, как шунда!— диде.— Көлеп торган була бит әле авызын җырып. Үрнәк күрсәтә! Бар тышка чык — әнә чалбарыңның да карар җире калмаган. Кешедән көлгән була җитмәсә.

«Нәрсә булган соң шулкадәр? Нигә кәефе кырылган?»— дип уйлады Габделхәй, эче пошып инәсе турында. Соңгы елларда инәсе бер дә тазалыкка туймый. Тик торганда дигәндәй әле йөрәге авырта, әле башы авырта. Бөтенләй көтмәгәндә кәефе кырыла. Берәр кыек сүз әйтсәң дә, ялгыш өйдә кычкырып сөйләшә башласаң да, киреләнеп-карышып торсаң да, җитә кала — шундук йөзе бозыла, тавышы үзгәрә. Габделхәй аның кайчан, нәрсәгә кәефсезләнүен дә белә кебек. Инәсе аның нишләптер Фидәилгә дә, Илгизгә дә артык ачуланмый, бары аңа — Габделхәйгә генә ачулана сыман. Анысы аның шулай тиештер дә. Бит өйдә инәсеннән кала иң өлкәне ул — Габделхәй. Бөтен җаваплылык аның өстенә төшә. Дөресрәге, инәсенең ул беренче ярдәмчесе, уң кулы. Сул кулы — Илгиз. Фидәил — койрык. Сәкинә турында тагын берәр авыз ачсын әле — «Койрык!» диярга була. «Чебен» дисәң дә шәп. Теләсә нәрсә сөйләнеп, чебен кебек безелдәп йөрмәсен, маңка!

Габделхәй каршы эндәшеп тормады, чалбар балакларына карана-карана мыштым гына тышка чыгып китте дә өс-башын каккаларга-суккаларга тотынды. Өйдә давыл тынсын өчен ул юри озаграк маташты. Ул кире өйгә кергәндә чыннан да давыл тынган иде. Инәсе, башына тастымал урап, кызыл чичкәле мендәр өелгән агач караватына бөгәрләнеп яткан иде.

Габделхәй киемнәрен җайлап элеп куйды да тавышсыз гына түр почмакта эзләнә башлады. Монда гадәттә иске чүпрәк белән каплап куелган агач табакта һәркемнең үзенә тиешле көнлек азыгы була. Инәсе балалар бакчасыннан эштән кайтканда калдык-постык ипи кисәкләре, кайчагында хәтта пирог, бәлеш кисәкләре алып кайта, шуларны тип-тигез итеп өч кисәккә бүлә дә әлеге табакка салып куя. Базардан, магазиннан сатып алынган йә булмаса өйдә пешерелгән ризыклар да тигез кисәкләргә бүленеп шунда куела иде.

Габделхәй өйгә килеп кергәндә, бердәнбер өстәлнең бер кыръенда Илгиз баш калкытмый нидер укып утыра

иде. Абыйсының ашарга эзләнүен күреп, ул башын калкытырга кирәк тапты.

— Мич алдында күбәтә белән сиңа бәрәңге бар,— диде.

Габделхәй төпченеп тормады — мич алдындагы калай күбәтәне өстәлнең икенче башына китереп куйды да үзенә дип калдырган ипи кисәге белән тәмләп-тәмләп бәрәңге ашарга тотынды. «Безнең бәрәңге беткәние бит инде — каян алдылар икән шундый тәмле бәрәңгене?»— дип уйлады ул ашаган арада. Бу турыда нишләптер энесеннән сорыйсы килмәде. Каян булсын, инәсе балалар бакчасыннан алып кайткандыр инде. Ул шулай кайчагында аннан бәрәңге, бер-ике кишер йә булмаса чөгендер ише нәрсәләр дә алып кайткалый. «Артып калды да бүлешеп алдык» дигән була яисә «пубыр бирде» ди. Кем белә аны, әллә «пубыр» биргән, әллә үзе алган. Дөресен әйткәндә, бу бит... бу бит урлашу. Социалистик милеккә, балаларга тиешле өлешкә кул сузу. Нинди хурлык, нинди мәсхәрә! Шундый аңлы, алдынгы укучы, кичәгенәк кенә шундый дөрес сүзләр сөйләгән укучы хәзер менә рәхәтләнеп... урланган бәрәңге ашап утыра!

Үзалдына ул шулайрак дип уйлады һәм уйлаган саен коры бәрәңге тамагына аркылы утыра сыман тоелды. Яңа сауган җылы сөт белән эчеп җибәрсәң тамакка утырмас иде дә соң — аларның сыерлары да, кәҗәләре дә, хәтта тавыклары да юк. Печәнлекләре генә бар. Анысы да элекке хуҗалардан калган. Сөт булган көнне була, булмаган көнне — юк. Сөтне Сәкинә генә эчә инде. Сыерлары да бар, май заводы да якында гына. Ләкин сөт булсын өчен Сәкинәләр кебек көне-төне эшләргә кирәк. Ул менә шигырь язып, кызлар белән йөреп гомер уткәрә. Булмый болай. Нидер эшләргә кирәк, нәрсәнедер үзгәртергә кирәк.

— Каян алдыгыз бәрәңгене?— диде ул Илгизгә, утыра торгач.

— Инәкәй базардан алып кайтты,— диде Илгиз.

— Шулаймени?— диде Габделхәй, җиңел сулап. Өлкән улының талымлый торган гадәтен белгәнгә күрә, Шәмсебанат апа алдан ук Илгизгә шулай дип әйтеп куйган иде. Абый кеше Илгизнең ялганына бер сүзсез ышанды һәм ярып пешерелгән тәмле бәрәңгене ашыкмыйча гына ашавында булды. Калай күбәтәдә ашар нәрсә калмагач, ирексездән аның күз алдына кичә ашаган ашлар килде. Шәп ашаттылар аларны! Башта күкәйгә басылган токмачлы аш бирделәр, аннан соң пешкән бәрәңге белән ит бирделәр, чәй бирделәр. Иң соңыннан берәр стакан алсу морс булды. Бит дөньяда кемнәрдер көн дә шулай ашап торалар! Нинди бәхетледер алар!

— Күрдеңме әле — синең шигыреңне гәзиткә басканнар,— диде Илгиз утыра торгач, бөтенләй көтмәгәндә.

«Шигырь» сүзе ишетеп Габделхәй дерт итеп китте. Ул аны бөтенләй исеннән чыгарып ташлаган иде. Шигырь ул бары хыялда гына була торган нәрсә иде, чын тормышта исә бары чүпрәк белән ябылган агач табак, табак төбендә бер-берсеннән аерып куелган ипи кисәкләре, пешкән санаулы бәрәңге, агач караватында бөгәрләнеп яткан инәсе һәм тәрәзәгә бәргәләнеп безелдәгән чебеннәр генә булырга мөмкин иде. Ашавыннан туктап, ул беренче мәртәбә энесенә игътибар белән рәк карады. Илгиз китап түгел, «Коммунизм юлы»н укып утыра иде.

— Менә укы,— диде Илгиз, газетаны абыйсына таба этәреп.

Габделхәй, тынычлыгын җуйган хәлдә, шулай да тыныч булырга тырышып, «Коммунизм юлы»н кулына алды һәм күрмәс күзләре белән үзенең шигырен эзләп тапты. Иң элек ул шигырьнең калын, эре хәрефләр белән язылган исемен укыды, үзенең исем-фамилиясен укыды. Таныш юлларга озаклап карап торганнан соң, әкрен генә, иҗекләп кенә үзе язган сүзләрне укырга кереште. Бер мәртәбә укып чыккач, үз-үзенә, үзенең бөеклегенә сокланып, таң калып утырды да яңадан укырга тотынды. Әйе, басканнар... Чыннан да басканнар бит, малайкай! Бер генә хәрефен дә төшереп калдырмаганнар!

## VIII

Өйдән чыгып китү белән Габделхәй, гадәттә, көндәлек тормыш мәшәкатьләре турында уйламаска тырыша иде. Мондый чакта дөнья аңа матур булып, күңелле булып тоела, ләкин өйләренә кайтып кердеме, ишегалдындагы, өйдәге таныш әйберләр, таныш кыяфәтләр, таныш мөнәсәбәтләр белән күзгә-күз очраштымы, бөтен нәрсә гап-гади һәм күңелсез була да кала. Әле генә хыял вәсвәсәсе азындырган яшь күңелнең өйдәге, якын-тирәдәге, бөтен дөньядагы мохтаҗлык һәм кысынкылык белән һич тә килешәсе килми башлый. Ләкин шул ук вакытта ул үзенең бүген дә, иртәгә дә шушында — һәрбер тишек-тошыгыннан ярлылык, мохтаҗлык саркып торган тар, кысан өйдә яшәргә тиешлеген дә аңламый булдыра алмый. Мондагы барлыюклы әйберләргә, мондагы гадәтләргә, мондагы кешеләргә — инәсенә, энесенә ул бөтен күңеле белән, кендеге белән береккән. Шуңа күрә ул алардан, әйтерсең, беркайчан да аерыла да алмаячак, беркайчан аларны ташлап, каядыр хыял өндәгән якларга китеп тә бара алмаячак кебек иде.

Үз шигыренең газетада басылуы аны күз ачып йомган арада хуш исләр аңкыган, талгын җилләр искән кояшлы болыннарга, бәхетле шәһәрләргә алып китте. Үз алдына елмаеп ул озак кына тынып утырды. Аның эндәшмәвен күреп Илгиз дә эндәшмәде, инәсе дә тып-тын урынында ята бирде. Хәер, инәсенең үз хәле хәл. Өлкән улына ул бөтенләй игътибар итмәгән сыман тоелды. Чынлыкта ул бары аны гына күзәтеп ятты, кайчан ничек сүз башларга икән дип уйлап кына ятты.

Урам якта кемнәрнеңдер кычкырып сөйләшә-сөйләшә узып барулары ишетелеп калды. Урамдагы тупас тавышларны ишетү белән, шагыйрь җегет, хыял дөньясыннан аерылып, үзенең каты урындыгына төшеп утырды. Күзләрен ачыбрак караса, өстәл өстенә япкан шакмаклы ашъяулыкның почмак турысында тишек булуы, ул тишекнең кичәгегә караганда зуррак булуы күренде. Кемдер аны бармагы белән юри зурайткан иде бугай. «Фидәил эше» дип уйлады абый кеше. Беренче мәртәбә аңа хәтта ярып пешерелгән бәрәңге дә тәмсез булып тоелды. Бәрәңгенең яңасы җиткән вакытта иске бәрәңге ашап утыр, имеш! Шулай да каян тапканнар соң болар мондый вакытта шундый таза, яхшы бәрәңгене? Базардан, имеш!

— Ашап бетер,— диде ул, бер-ике бәрәңгесе калган калай күбәтәне Илгизгә таба этәреп.

— Ярар,— диде Илгиз, бик тиз риза булып.

— Туйдың да мени?— диде Шәмсебанат апа, тавыш биреп.

Габделхәй берни эндәшмичә, көтә башлады. Инәсенең тавышыннан ул хәзер үзенә карата шелтә, моң-зар буласын сизенгән кебек булды. Инәсе озак көттермәде, бернинди керешсез шундук тезәргә дә тотынды.

— Хәзер инде сиңа бер атна ашамасаң да була. Атналыкны ашап кайткансыңдыр,— диде.

Инәсенең сүзеннән кызык табып Илгиз көләргә тотынды.

— Нәрсә ыржаеп утырасың?!— диде абый кеше, үртәлеп.

— Бер атна ашамый йөрсәң, Хуҗа Насырттин ишәгенә әйләнерсең!— диде Илгиз.

Габделхәй энесенә усал итеп бер карап алды, ләкин шуннан да көчлерәк тәэсир итәрдәй башка чарага кулы бармады. Шулай да ул ачуын йотты һәм бик кирәкле эш башкарган сыман, шкафның иң югары шүрлегенә куелган иске дәфләрләрен актара башлады. Монда Фидәилнең кулы җитми торган җирдә аның беренче шигырьләре, рәсемнәре, төрле кирәк-ярак язулары саклана иде.

Ул арада инәсе урыныннан торды, башындагы тастымалын салып ташлады да, су эчеп куйды һәм караватында таралып яткан энә-җепләрен, ямаулыкларын алып гадәттәге шөгыленә — нидер ямаргамы, тегәргәме тотынды.

## IX

— Мизал бирделәрме соң, улым?— диде бераздан Шәмсебанат апа, күтәрелеп карамыйча гына.

Габделхәй иске дәфтәрләрен актарудан туктап калды, каушап, кызарынып инәсе ягына борылды. Медаль турында ул нишләптер онытып җибәргән иде. Чыннан да, бу дөньяда «шигырь» генә түгел, «мизал» да бар бит әле. Медаль! Ул да бары буш хыял гына булып чыкты. Кемнәргәдер бирәләр, кемнәрнедер мактыйлар, данлыйлар — аңа менә тәтемәде. Нинди хыялланган иде ул бермәлне «медаль» дигән нәрсә турында! Әйе, булмады. Баштарак булырына бик үк ышанып җитмәсә дә, соңыннан... бер вакыйгадан соң ул инде әз генә дә шикләнми башлаган иде.

Яңавыл татар урта мәктәбендә барлык укучылар өчен иң куркынычы урыс теле иде. Татар мәктәбе булгач, күпчелек фәннәр татарча укылырга тиеш булса да, күпчелек фәннәр, киресенчә, урысча гына укытылды. Физика-математика — урысча, химия-биология, зоология, немец теле — шулай ук урысча. Хәтта тарих та сигездән унга кадәр — урысча. Укытучыларның күбесе татарлар. Сөйләвен алар урысча сөйлиләр, ләкин берәр нәрсәне аңлап җитмәсәң, татарча аңлаталар. Дәрестә сорауларга урысча җавап бирергә тиеш булсалар да, шулай да укучылар башка вакытта үзләрен иркенрәк тоталар — чыш-пыш килеп татарча сөйләшәләр, бер-берсенә татарча хатлар язалар. Тәнәфестә инде бөтенләй татарча! Ләкин урыс теле, урыс әдәбияты дәресендә... Антонина Семеновна дәресендә... чебен очкан тавыш та ишетелми.

Антонина Семеновна — Ленинград марҗасы. Сугыш вакытында эвакуация белән килгән дә торып калган. Монда килгәндә аның малае да булган. Малаен сугышка алганнар. Күп тә тормаган, үле хәбәре килгән. Шуннан соң микән, Антонина Семеновна бик нык холыксызланган. Бәлки, элегрәк тә шулай холыксыз булгандыр. Мәктәп ишегалдындагы иске генә бер өйдә берүзе тора, кеше белән аралашмый, мондагы халыкны яратмый. Аның бар юанычы шул урыс теле дә урыс әдәбияты бугай. Дәрескә кереп утыру белән дөньясын онытып Пушкин, Лермонтов, Толстой турында, дөресрәге, алар иҗат иткән әсәрләр турында сөйли башлый. Беркайчан китапка,

дәфтәргә карамый. Барысы да яттан. Аныңча, дөньяда иң бөек әдәбият — урыс әдәбияты, иң даһи язучылар — урыс язучылары. Урыс телен инде әйткән дә юк. Урыс теле — иң бөек тел, иң көчле, изге тел. Урыс телен белмәгән кеше бу дөньяда кеше исеменә лаек була алмый. Иптәш Сталин үзе урыс телендә сөйләшә, урыс телендә уйлый, урыс телендә яза. Бит тумыштан ул — грузин! Урыс телендә дөрес язарга иптәш Сталиннан өйрәнегез, дигән иптәш Калинин. Менә бит ул эшләр ничегрәк тора. Ватан сугышы елларында урыс теле барлык халыкларны цементлаучы какшамас көчкә әйләнде. Совет халкы бары тик бөек урыс теле ярдәмендә генә тарихта тиңдәше булмаган җиңүгә ирешә алды. Бүгенге көндә бөтен дөнья халкы үз теләге белән урыс телен өйрәнә. Халыкара трибуналардан Пушкин теле, Толстой һәм Ленин-Сталин теле яңгырый! Шикләнмичә әйтергә була — кырык-илле елдан урыс теле бөтен планетаны яулап алачак!

Еш кына ул русча дөрес сөйләшмәгән укытучыларны төзәтә, тәнәфестә берәрсенең ялгыш кына укучылар белән татарча сөйләшкәнен ишетеп калса, бернинди тәкәллефсез рәвештә замечание ясый. Инде укытучылар киңәшмәсендә үзара сөйләшеп утырганда, укытучылар татарча сөйләшсәләр, аңсызларга ул карчыга булып куна.

Дәрестә укучылар белән генә калганда аңа каршы беркем сүз әйтә алмый. Урыс теленә җитәрлек дәрәҗәдә игътибарлы булмаган укучыларны ул әледән-әле чиреккә, еллыкка «начар» кую белән, икенче елга класста утыртып калдыру белән куркыта. Берәр кирерәк укучы шулай да үзенең татарлыгын, татар теленең дә тел булуын якларга, исбат итәргә тотынса, Антонина Семеновна аны кырт кисә дә урыс теленең бөеклеге турында Ломоносов, Тургенев, тагын әллә кемнәр әйткән сүзләрне исенә төшерә һәм иң ахырда болай гына, кирәксез нәрсә турында сөйләнгән сыман гына: «Берәр даһи язучының, галимнең татар теленең бөеклеге турында әйткән сүзләрен мин хәтерләмим»,— дип куя.

Мәктәптә аны беркем яратмый — укучылар да, укытучылар да. Укучылар аны «каз-күз» дип йөртәләр һәм бары «начар» алу, күчми калу куркынычы булган өчен генә аның сүзенә каршы килмәскә тырышалар. Урыс телен, әдәбиятын яхшы белергә кирәклеген беркем инкарь итми. Беркемнең урыс теленә каршылыгы юк, чөнки кая барма — бөтен эш урысча. Өйдә, базарда, авылда, анда-монда әле татарча сөйләшергә дә була, ләкин вокзалга, тимер юл буена төштеңме — дөнья үзгәрә дә куя. Бөтенесе — урысча. Алай-болай ялгышып кассир марҗага, идән себерүче марҗага татарча эндәшсәң, ул синең

йөзеңә генә төкерми — эттән алып эткә салып, шундук синең үзеңне, телеңне, халкыңны мыскыл итәргә тотына.

Шулай. Барысы да шулай. Быелгы унынчылар өчен урыс теле аеруча авыр булды. Уку елы башыннан ук инде Антонина Семеновна күп кешенең, бигрәк тә якын-тирәдәге авыллардан — Эткенәвылдан, Истәктән, Уразыдан килеп йөрүчеләрнең котын алып куйды. Тырышмасагыз, сочинениедә коелып калачаксыз, диде. Өлгергәнлек аттестаты бирелмәячәк, аттестатыгыз булмаса, кем булырсыз да кая барырсыз? диде. Барлык фәннәрдән яхшы укыган, тик урыс теленнән генә йомшаграк булган Фәния, мескен, түзмәде, җылады. Ул үзе болай чит авылдан килеп тә йөрми, ул — Яңавыл, дөресрәге, Яңавылга кушылып бетә язган Җобанай кызы. Ләкин өй тулы бала-чагалары булган Фәниеләр шундый ярлы — Фәниянең яхшылыкка киеп йөри торган күлмәге дә ике-өч җирдән ямаулы. Фәниянең өйдә укып дәрес әзерләнеп утырырга вакыты да юк, шул ук вакытта аның иң зур хыялы — кая да булса читкә китү, институтка булмаса, техникумга керү, кеше булу.

Урыс теленнән дә, Антонина Семеновнадан да бөтен мәктәптә диярлек бары бер генә кеше, бары Габделхәй генә курыкмады. Урыс телен ул беләм дип исәпләде. Антонина Семеновна да әледән-әле шуны тукый килде. Беркайчан ул аңа каты бәрелмәде, беркайчан аның йөзен җыртмады. Кайбер укучылар Антонина Семеновна Габделхәйне яклый диделәр. Габделхәйнең үзенә бу бер дә яклау булып тоелмады. Аныңча бу шулай булырга тиеш тә иде, чөнки ул урыс телен чын күңелдән тырышып укыды. Башка фәннәрне онытса онытты — урыс теленнән бирелгән өй эшләрен дә онытмады, Антонина Семеновнаның киңәшләрен дә онытмады. Анысы гына җитмәгән, үзлегеннән ул туктаусыз китап укыды. Урыс классикларын — Гогольне, Пушкинны, Лермонтовны, Толстойларны, тагын әллә кемнәрне укыды. Антонина Семеновна агитациясенә ул берсүзсез ышанды һәм үзен хәзердән үк коммунистик җәмгыятьтә яшәячәк чын кеше итеп тәрбияләргә булды. Үз-үзенә ул хәтта шундый максат куйды: башта урыс классикларын укып чыгам, аннан соң дөнья әдәбияты классикларын укый башлыйм диде. Ул, билгеле, татар әдәбиятыннан да йөз чөермәде, ләкин мәктәптә татар китабы юк дәрәҗәсендә иде. Сталин клубы каршындагы китапханәдәге барлы-юклы татар китапларын ул инде күптән укып чыккан иде.

Чыгарылыш имтиханында Габделхәй урыс теленнән сочинениене ирекле темага язды. Булачак шагыйрь кеше нишләп анда һәркем белгән, чәйнәлгән Корчагиннар, Маяковскийлар турында язарга тиеш? Шагыйрь кеше ул

кайда да иҗат итәргә тиеш. Ул иҗат итте. Бөтен бер дәфтәрне язып тутырды. Беренче булып бетерде дә, дәфтәрен комиссиягә тапшырды да, җиңүче тойгысы белән җиңеләеп, масаеп мәктәптән чыгып ук китте. «Отлично» булырына ул әз генә дә шикләнмәде.

Өч-дүрт көннән барысын да җыеп кемнең ничек язуын аңлатканда, көтелгәнчә, иң элек аны мактадылар, «отлично» диделәр. «Уртача»лар күп булса да, «яхшы»лар да, хәтта икенче «отлично» да бар иде. Икенче «отлично» Сәкинәнеке иде. Шунысын да әйтергә кирәк, аттестат бирдермим дип янаган Антонина Семеновна беркемгә дә «начар» куймаган иде. Унынчыларның түбәләре күккә тиде. Һәркем үзен бәхетле санады. Сират күперен үткәч, калганы инде аның чүп кенә!

Класстан таралганда директор Габделхәйне көтеп алды һәм гадәттә булмаганча серле һәм йомшак итеп:

— Кабинетка керегез әле, Мухутдинов,— диде.

Габделхәй керде, көтә башлады. Василий Михайлович нишләптер сүз башламады — өстәл тартмаларын ачкалап, кәгазьләрен әвеш-түеш китергән булды. Аның гадәте шул: кем керсә дә, кем белән сөйләшсә дә, эшем кешесе булып, иң элек шулай өстәл тартмаларын актарып булаша. Шакып-нитеп тормыйча шул чакны кабинетка Антонина Семеновна килеп керде. Бүген ул бераз гына борчулы, бераз гына тынгысыз сыман тоелды. Укучылар белән сөйләшкәндә дә ул бүген гадәтенчә башка суккан сыман мәҗбүри, катгый тонда түгел, ничектер йомшак, дусларча итеп, кешеләрчә сөйләште. Габделхәй дә, башкалар да андагы бу үзгәрешкә игътибар итми калмадылар, һәркем аның турында: соңгы очрашу булганга күрә шулай күңеле йомшагандыр дип уйлады.

Директор кабинетына килеп кергәч, Антонина Семеновна беркайчан кулыннан калдырмый торган калын кара портфелен өстәлгә бастырып куйды, актарып аннан бер дәфтәр чыгарды һәм дәфтәрне кулыннан ычкындырмыйча, Габделхәйгә карап сөйли башлады. Ул сөйләгәндә икенче яктан төртеп тишәрдәй булып Василий Михайлович карап торды.

— Сочинениеңнең эчтәлеге бик яхшы, Мухутдинов,— диде Антонина Семеновна.— Синең мөстәкыйль фикерли алуың күренеп тора. Ләкин кайбер сүзләрдә хаталар киткән. Менә, карап чык.

Мондый көтелмәгән яңалыктан каушап калган Габделхәй калтыранган кулына дәфтәрен алды, актара башлады. Һәр бит саен кызыл кара белән төзәтелгән хаталар күреп аның коты алынды. Ул катты да калды. Нишләп?

Ничек? Мөмкин түгел! Хаталы сүзләрне ул укырга тырышып карады, ләкин укый алмады. Ул бары шуны гына аңлады: күп кенә сүзләрне ул «е» язылысы урында «и» язган, «и» язылысы урында «е» язган иде. Әйе, бу аның йомшак ягы. Ул аны үзе дә белә.

Василий Михайлович аңа башланмаган бер дәфтәр тоттырды һәм шыгырдап торган күңелсез, шулай да йомшаграк бер тавыш белән:

— Менә нәрсә, Мухутдинов,— диде.— Без... комиссия килештек тә шундый фикергә килдек. Син хәзер, үзегезнең класска кереп, төзәтелгән сочинениеңне күчереп яз. Ашыкма. Без монда көтеп утырырбыз. Аңлашылдымы?

— Аңлашылды,— диде Габделхәй, үлемгә хөкем ителеп тә ярлыкау ишеткән җинаятьче кебек.

Үзе дә сизмәстән ул җиңел сулап куйды һәм чыгып китмәкче булып урыныннан торды.

— Чыгып йөрмәсен, шушында гына утырып язсын,— диде Антонина Семеновна.

— Алай да була,— диде Василий Михайлович.— Син, Мухутинов, алайса шушында гына яз. Бер-ике сәгатькә без чыгып торырбыз. Кабинетны эчтән бикләп куярсыз.

Василий Михайлович шулай диде һәм сейфны, өстәл тартмасын шартлатып бикләде, ачкычларын кесәсенә салды. Кабинет ачкычын ул Габделхәйгә тоттырды. Чыгып киткәндә тавышын әкренәйтә төшеп, татарчалап:

— Син инде аңлыйсың булыр — бу турыда ләм-мим!— диде.

## X

Ләм-мим икән, ләм-мим, Габделхәй бу турыда хәтта инәсенә дә әйтмәде, хәтта үз-үзенә танырга да теләмәде. Бу эш аңа ничектер төштә генә булган сыман тоелды. Ләкин инәсенең «мизал» турында сүз кузгатуы аны сагайта калды. Фәрхәнә апалар, Халидә апалар дәрәҗәсендәге белемле булмаса да, инәсе аның китапча дөрес итеп сөйләшә ала һәм теләсә «мизал» дип түгел, «медаль» дип тә әйтә ала иде. Аның шулай «мизал» диюендә Габделхәй күрәләтә көлү, хәтта мыскыл сыман нәрсә сизде. Василий Михайлович документларны алып Уфага киткәч тә, улының куанычына, медаль булачак дигән сүзләренә Шәмсебанат апа үзенең икеләнүен белдерде.

— Медальне аны синең кебекләргә бирмиләр. Юкка өметләнмә,— диде.

Ул чакта Габделхәй бу турыда сүз куертып тормады. Олы яшьтәгеләр гел шулай бернәрсәгә дә ышанмыйлар.

Инәсе бигрәк тә. Ләкин менә көтмәгәндә аның сүзе дөрес булып чыкты түгелме соң?! Инәсе янында Габделхәй хәзер үзен кыен хәлдә сизде.

— Медаль юк. Алтыны да, көмеше дә,— диде ул, төшенке генә.

— Нигә юк — әйтмәделәрме?— диде инәсе.

— Әйтмәделәр,— диде Габделхәй, Илгиз ягына карангалап.— Уфа бирмәгән. Аңлашыла ич инде. Алар теләсә нәрсәдән хата табарга гына торалар.

— Хата тапканнар шул,— диде инәсе, беркадәр күтәренкелек белән.— Урысча язганыңа «уртача» гына куйганнар.

— Булмас!— диде Габделхәй үзе дә сизмәстән, кызарынып-бүртенеп.— Сочинениедән мин «отлично»га яздым!

— Яздың!— диде инәсе.— Бер язганны күчереп яздың. Белми дисеңме әллә?

Габделхәй катты да калды.

— Син... каян беләсең аны?— диде ул, беркадәр вакыт эндәшми торганнан соң.

— Беләм инде,— диде инәсе, көлемсерәп.— Фәрхәнә апаң әйтте.

— Аңа кем әйткән?!— диде Габделхәй, исе китеп.

— Кем булсын, Халидә апаңдыр,— диде инәсе.— Ир белән хатын арасында сүз торамыни? Халидә апаңа Вәсби абыең әйткәндер. Менә шулай тарала инде ул.

— Таралды микәнни?— диде Габделхәй, эсселе-суыклы булып.— Нинди хурлык! Иптәшләр белсә, алар ни әйтер?

— Тапкансың хурланыр нәрсә!— диде инәсе, яңадан үзенең ямау-бәйләү эшенә тотынып.

Габделхәй уйга калды. Хәзер ул нәрсәгә аптырарга да белмәде. Барыннан да элек аны Василий Михайловичның сүзендә тормавы, үзе эндәшмәскә кушып та, үзенең беренче булып серне чишүе гаҗәпләндерде. Директор кеше шулай буламыни? Сер сакларга дип килешкәннәр икән, иң элек ул үзе — директор — сер сакларга тиеш түгел идемени? Аннан соң аны күчереп язылган сочинениенең хаталы булып чыгуы да бик нык гаҗәпләндерде. Димәк, аларның төзәттергәннәре дөрес булмаган. Димәк, башта ул дөресрәк язган булган. Шулаймы? Аның моңа бик ышанасы килде, ләкин ул моңа ышана да алмады. Гомер буена урыс теле, урыс әдәбияты укыткан югары белемле Антонина Семеновнаның кайда «е», кайда «и» язарга кирәклеген белмәвенә ышана алмады. Сочинениедә, бәлки бүтән төрле хаталар тапканнардыр? Бәлки, эчтәлеге ошамагандыр? Юк, берничек тә ул моңа ышана алмады. Аның өчен бу чыннан да сер булып калды.

— Җә, улым, инде нишләргә исәп?— диде инәсе, яңадан сүзгә башлап.

Тынып, бөрешеп, кечерәеп калган Габделхәй кырын күзе белән генә инәсенә карап алды. Ул аның тынычсызланган ябык чыраен күрде, гадәттәгегә караганда җитезрәк, кабаланыбрак хәрәкәтләнгән бармакларын күрде. Тавышының ничектер тотлыгыбрак, калтыраныбрак чыгуын шәйләде һәм шундук барысын да аңлагандай булды. Хәзер аның инәсен медальдән дә зуррак нәрсә борчый иде бугай. Аның менә хәзер шул борчыган нәрсәсен улына да әйтәсе килә иде бугай. Инәсен борчыган нәрсәләрне исә Габделхәй болай да сизенә иде, шуңа күрә ике арада булырга тиешле зур сөйләшүдә аның өчен әллә ни яңалык та булмаячак иде кебек.

— Мин сине, улым, орчык буе чагыңнан карап үстердем,— диде инәсе, Габделхәйнең нәрсә дә булса әйткәнен дә көтмәстән.— Ун җыл буена атасыз карадым, ун җыл буена көттем мин шушы көнеңне. Кеше балалары арасында ким-хур булмасын, өсте бөтен, тамагы тук булсын дип тырыштым. Борлыкмасыннар, сөмсерләре коелмасын, дидем. Сез бит өчәү! Бер капканда да — өч кашык! Әтәгез киткәч күргәннәремне, интеккәннәремне бер Ходай гына белә. Песи баласы кебек куеныма салып, җылы тынымны өреп... авызымдагын өзеп карадым мин сезне. Ярый, күрдем бу көннәрне. Таралмыйча, әрәм-шәрәм булмыйча, исән-имин үсеп җиттегез. Хәзер инде сездән дә рәхәт күрәсе килә.

Габделхәй бүлдермичә, караңгы чырай белән тыңлап кына утырды. Үскән чакта үзенең... үзләренең нинди авырлыклар, нинди мохтаҗлыклар күрүләрен ул болай да белә иде. Шуңа күрә бу турыда сөйләп, аңлатып торуның кирәге дә юк иде. Сугыш елларында гына түгел, хәтта бүген дә — сугыш бетеп инде күпме вакыт үтүгә дә карамастан, әле булса алтын тауларының үсеп чыкканы юк. Тормыш һаман элеккечә авырлык белән, этептөртеп кенә барыштыра. Анысы шулай. Ләкин киләчәктә һичшиксез җиңел булачак, муллык-байлык булачак. Моңа беркем шикләнми. Бу турыда партия, иптәш Сталин ачык итеп әйтте. Аннан соң инәсенең элек гел үзем генә карадым, үзем генә азапландым дип әйтүе дә бик үк дөрес түгел. Әтәсе яраланып кайтып яңадан сугышка китеп барганда, ул инде кул арасына керә башлаган иде. Илгизгә күз-колак булу, Фидәилне тирбәтү, уйнату — барысы да аның өстендә иде. Илгиз үсеп арттан куып җиткәч кенә, соңгы бер-ике елда гына җаваплылык кими төште сыман. Габделхәйне гел карап үстердем, кеше иттем дисәң, кеше ышанмас. Ул бары үз тырышлыгы белән

генә алдынгы булды. «Мизал» бирмәгәннәр икән, бирмәгәннәр. Шуның өчен генә аны тырышмаган, көч куймаган дип әйтерсеңме соң? Әнә, Назиф авыл малае, тормышлары да начар түгел. Барыбер әлләни булдыра алмады. Чәйханә директоры, колхоз персидәтеле булу турында хыяллана. Институт турында хыялланмый, имеш, ул. Анда, имеш, шәһәр балалары гына, бай балалары гына укый, шуңа күрә Назиф институтларны яратмый, имеш. Тәтемәгәч яратмый инде. Син, инәкәй, үзең гел дөресен сөйләргә кирәк дисең, үзең янә тузга язмаганны сөйләп утырасың. Габделхәең булмаса, Илгиз белән Фидәилне ничек карар идең дә ничек кеше итәр идең аларны!

Үзалдына Габделхәй шулайрак дип уйланды, ләкин уйлаган уйларын кычкырып әйтергә шулай да йөрәге җитмәде. Аннан соң бу турыда әйтмәсәң дә була. Бит боларның барысы да көн кебек ачык!

Шәмсебанат апа, көч-куәт җыйган сыман, беравык тынып утырды да яңадан сүзгә башлады.

— Киңәш юк, табыш юк, инә кешегә әйтү юк...— диде.

— Тагын ни булган?— диде Габделхәй, түземлеген җуеп.

— Казанга биш җылга укырга китәсең ди ич... Дөрес түгелме әллә?— диде инәсе.

## XI

Габделхәйнең өй эчендәге беркемгә дә үзенең эч серләрен, уйларын-хыялларын белдергәне юк иде. Унны бетергәч нишләү, кая киту-китмәү турында да әлегә бернинди суз булмаган иде.

— Кем әйтте?— диде ул.

— Кем әйтсә дә барыбер түгелмени?— диде инәсе.— Тагын синең биш җыл укыганыңны көт... Биш җылда кем бар да кем юк. Мин үлеп китсәм, нишләрсез үзегез генә? Илгиз белән Фидәил нишләр? Уйладыңмы шул турыда?

Соңгы сүзләрен ул калтыравык-кызганыч тавыш белән әйтте. Әллә чынлап та үзенең киләсе биш ел эчендә үлеп китү ихтималына ышанып, борынын тарткалап алды һәм кулындагы эшен ташлады да күлмәк кесәсендәге кулъяулыгына тотынды.

— Моңарчы әле өстерәлештереп килдек,— диде.— Син дә китеп барсаң, мине дә эштән чыгарсалар...

— Нишләп сине... эштән чыгарырлар икән?— диде Габделхәй, берни аңламыйча.

Инәсе озак кына җавап кайтармады.

— Мизал белән җиңел генә институтка кермәкче бул-

гансың да, анысына да керәлмәссең, ахрысы,— диде ул кинәт үз-үзенә каршы килеп.

— Медальсез дә керәчәкмен. Теләсә нинди институтка!— диде Габделхәй, усалланып.

— Үзеңә артык ышанасың, улым,— диде Шәмсебанат апа коры, гына.— Синең шигырең кемгә кирәк хәзер?!

— Инәкәй!— диде Габделхәй, урыныннан торып, кызарынып.— Минем шигырьгә кагылма. Шигырьнең монда катнашы юк.

— Балалар бакчасындагы татар группасын ябачаклар,— диде инәсе, улының тузынуына әз генә исе китмичә.

Бу сүзләрне ул тирән бер өметсезлек белән, эчке бер тетрәнү белән әйтте. Габделхәй баштарак моны аңлап та җитмәде кебек, ләкин шул ук вакытта ул йөрәк турысында авыр таш барлыкка килүен тойды. Акылы аңлаганчы күңеле инде барысын сизеп алган иде.

Инәсе аның гомере буена диярлек балалар бакчасында тәрбияче булып эшләде. Балалар бакчасы аның икенче туган йорты сымаграк иде. Габделхәй бакчага йөрмәде, ләкин Илгиз белән Фидәилнең берничә елы шунда үтте. Дөресен әйткәндә, ач үлемнән аларны шул балалар бакчасы гына коткарып калды. Хәзер дә ул туйдырып, исәнимин саклап килә түгелме соң?

Инәсенең бу көтелмәгән хәбәре бөтен өй эченә килгән кайгы булып кына түгел, бәлки, аннан да зуррак һәм шомлырак бер кайгы, фаҗига булып ишетелде. Габделхәйнең моңа ышанасы килмәде. Кинәт кузгатылган күңеленә урын тапмыйча, ул аягүрә басты, ашыгыч эше бар кеше сымак тышка чыгып китте, тар ишегалдында әйләнгәләде дә яңадан өйгә керде, яңадан өстәл башына килеп утырды һәм тагын тышка чыгып китте. «Булмас, булмас! Мөмкин түгел!»— диде ул, үз-үзен юатырга тырышып.

— Минем урысчам такы-токы. Бөтен нәрсә урыска әйләнгәч, без нишләрбез, улым?— диде инәсе, Габделхәй яңадан өйгә килеп кергәч.— Яңадан авылга кайтып китәрбез микәнни?

— Кем әйтте, каян ишеттең?— диде Габделхәй, телгә килеп.

— Сәлимә апаңа ронода әйтеп җибәргәннәр: быел көзгә әзерләнеп торыгыз — татар группасын ябачакбыз дигәннәр,— диде инәсе.

— Ул нәрсә әйткән?— диде Габделхәй.

— Нәрсә әйтсен — аптырап кайткан. Эшебез эш булмады, ашыбыз аш булмады. Син берәр эшкә керсәң, ичмасам, Илгизне укытып чыгарырыек. Мин хәзер бүтән эшкә ярамыйм. Нишләрбез, улым?

— Япмаячаклар! Ябып кына карасыннар!— диде кинәт Габделхәй, йодрыкларын йомарлап.— Хаклары юк! Булмас, ышанмыйм!

— Алар бездән хак сорап тормыйлар шул,— диде Шәмсебанат апа, көрсенеп.— Аларныкы замана. Алар әйттеме — бетте!

— Бөтен кеше өчен закон бар. Совет законы!— диде Габделхәй, инәсенең мескенләнүенә ачуы килеп.

— Уфадан сезнең теге директорыгыз бутап кайткан ди. Шул тыкшына теләсә кая. Аннан, имеш, сораганнар, ул әйткән, имеш, мәктәпне дә гел урыска күчерәбез, кадрлар җитәрлек, фәлән-фәсмәтән дигән, имеш. Башы аягы астына килгере, коры бугаз, тәмуг кисәве... Сугышка бармыйча качып ятты да башкаларныкы кебек аның да мизал тагып йөрисе килә. Кара йөз!

Василий Михайловичның татар теле, татар әдәбияты, физика-математика турындагы сүзләренә Габделхәй тиешенчә игътибар итеп җиткермәде, ахрысы. Менә хәзер турыдан-туры үзенә, инәсенә, энеләренә — бөтен күнегелгән тыныч тормышка чын мәгънәсендә куркыныч янавы беленгәч, аңлаешсыз сыман булып тоелган сүзләр бөтенләй икенче яктан, чын мәгънәсе белән аңлашыла башлаган кебек булды. Шул ук вакытта Габделхәй үз гомерендә беренче мәртәбә мәктәп директорының ни дәрәҗәдә зарарлы, кара эчле кеше булуын да төшенде кебек. Үз-үзен, инәсен, энеләрен яклап аның көрәшкә ташланасы, мәкерле директорның барып бугазыннан аласы йә булмаса караңгы төндә берәр җирдә сагалап торып, түбәсенә таш белән тондырасы килде.

— Юк, андый закон юк!— диде ул, ишекле-түрле йөреп.— Бетереп кенә карасыннар... ябып кына карасыннар.— Сталинга язам!

«Сталинга язу» гаделлекне яклауның иң соңгы һәм иң көчле ысулы иде. Мондый ышаныч хәтта иң көчсезгә дә көч-куәт бирергә, хәтта үлене дә тергезеп аягына бастырырга мөмкин сыман иде. Бу минутта Габделхәй чыннан да үзен тау-ташларны актара ала торган әкият батырыдай итеп хис итте. Аның шулай әтәчләнүенә инәсенең әз генә дә исе китмәде.

— Синең кебекләр тимер юлга эшкә керәләр,— диде ул, бөтенләй икенче яктан суктырып.

— Кара эшче булыпмы?!— диде Габделхәй.— Майланып беткән сырма киеп... майлы чүпрәк тотып... күмер тузаны эчеп?!

— Кара кием кисәләр дә, ак күмәч ашыйлар,— диде инәсе.— Кара кием киясең килмәсә, кантурга кер. Хисапчылар курсына укучылар кирәк ди әнә...

— Илектер станциясенә дә алалар малайларны өйрәнчек итеп,— диде шул чакны Илгиз дә сүзгә катышып.

— Кер үзең бик кирәк булса!— диде абый кеше, тупас кына.

— Керермен дә шул!— диде Илгиз, батыраеп.

— Менә үстерәсең-үстерәсең дә аларны игелек күрермен дип... Өйгә бер тиен файдасы тиярлек булмагач, ник кирәк миңа синең ун җыллык белемең?— диде Шәмсебанат апа олы улына.

— Туктале, инәкәй,— диде Габделхәй, тынычрак булырга тырышып.— Унны бетергән малайларны армиягә алалар икән дигән сүз дә йөри. Алып куйсалар, барыбер минсез каласың ич.

— Булыр, булыр. Алырлар да җибәрерләр дә. Әле армиягә, әле институтка. Адәм баласына бер дә үз илендә, үз өендә тормаска тиештер инде. Алалар, озаталар, таркаталар...

— Менә, күрдеңме?! Синең өчен барыбер түгелмени?— диде Габделхәй.

— Барыбер түгел,— диде Шәмсебанат апа.— Тимер юлга керсәң, армиягә дә алмыйлар, тамагың да тук була. Барыбер түгел.

— Мин тимер юлга эшкә кермәячәкмен,— диде Габделхәй, нык итеп.

— Инәкәй!— диде шул чакны Илгиз.— Китсен абый укырга. Эшкә мин керермен — минем шагыйрь буласым юк.

— Шагыйрь...— диде Шәмсебанат апа.— Нәрсә әйтергә дә белмим инде мин сезгә. Моңлы кеше бәхетсез була диләрие элек. Моңлы кеше, бәхетсез кеше эше ул шигырь язу. Затта юкны... Каян кагылгандыр сиңа шигырь җене.

— Каян булсын — картыйдан, синнән!— диде Габделхәй.

— Минем шигырь язганым булмады, кеше язганны гына күчереп яздым,— диде Шәмсебанат апа, тыйнак кына.— Без үскәндә ярыйдырые ул. Хәзер әнә заманалар башка.

— Инәкәй, мин монтерлыкка укырга керәм,— диде Илгиз, тагын үзе турында искә төшереп.

Илгиз абыйсыннан яшь ярымга кечерәк булса да, гәүдәгә аның белән бер чама иде. Быел ул тугызны бетереп унга күчкән иде.

— Бер җыл укыйсың калгач, ничек була инде ул?— диде Шәмсебанат апа.— Шулкадәр тырышып укыт та сезне... син тагын җилгә очырырсың микәнни ул тугыз җылыңны?

— Унынчыны кичке мәктәптә укырмын,— диде Илгиз. Күрәсең, бу турыда ул инде күптән уйлап куйган иде.

Әллә улларының гел үзләренчә булырга тырышуларына, әллә чыннан да үз сүзен генә сүз дип исәпләгәнгә, ана кешенең тиз генә Илгизне дә яклыйсы килмәде. Үпкәләгән сыман ул тынып калды һәм ашыгып яңадан бетмәс-төкәнмәс ямавына-тегүенә тотынды.

## XII

Киләчәк турында сөйләү-аңлашу шуның белән төкәнде. Уртак фикер табылмады, һәркем үз фикерендә калды. Габделхәй дә, Илгиз дә, инәләрен артык борчымаска теләп, шыпырт кына чыгып киттеләр. Габделхәй үзенең бүген Фәрхәнә апаларга барырга сүз бирүен исенә төшерде. Сәкинә дә исенә төште. Бит ул аңа да кичке сәгать сигездә очрашырга сүз биргән иде! Инде сәгать сигезенче. Кая барырга да белмичә ул бераз вакыт икеләнеп торды. Акылы Сәкинә ягына тартты, күңеле нишләптер Фәрхәнә апаларга омтылды. «Ярар, бүген әле Сәкинә үзе дә чыкмас, эше күптер,— дип уйлады ул, билгеле бер карарга килеп.— Бүген булмаса — иртәгә, иртәгә булмаса — берсекөнгә дип килештек ич. Шулай булгач...»

Шулай булгач ул Фәрхәнә апаларга барырга булды.

Шәмсебанат апалар белән Фәрхәнә апалар гомер-гомергә дус-тату булдылар, бер-берсенә йөрешеп, ярдәм итешеп тордылар. Моның кайбер сәбәпләре дә бар иде. Яңавылның үзәк урамы исәпләнелгән Ленин урамының сазлы очына күченгәнче, Фәрхәнә апалар Шәмсебанат апаларга ике-өч өй аша гына тордылар. Элегрәк, дөньялар имин чагында, алар бер-берсенә ашка-суга йөрештеләр. Мондый дуслыкның сәбәбе, билгеле, өйләрнең бер-берсенә якын урнашуында гына түгел иде. Шәмсебанат апа Фәрхәнә апаның ире Дәүләтгәрәй абзый белән яшьтәшләр һәм авылдашлар иде. Аннан соң, Дәүләтгәрәй абзый Габделхәйнең этәсе Котдус белән дә кордаш иде. Ирләре сугышта чагында Шәмсебанат апа белән Фәрхәнә апаның серләре тагын да ныграк килеште һәм өч ел буена алар чын мәгънәсендә бер семья кебек яшәделәр — кайгысы да, шатлыгы да, хәтта телеме дә уртак булды.

Дәүләтгәрәй абзый сугыштан Котдуска караганда иртәрәк кайтты. Әлбәттә, яраланып кайтты. Кайту белән үзенең элекке эшенә — райфога урнашты һәм сугыш беткәнче шунда утырып калды. Аларның тормышы гөрләп, тәгәрәп барды. Шулай да ике йорт арасындагы дуслык, якынлык сүрелмәде, һич югы, Габделхәйгә шулайрак тоел-

ды. Күпчелек вакытларын алар Фәрхәнә апаларда үткәрделәр. Габделхәйнең үзенә дә, энеләренә дә анда беркайчан караңгы чырай күрсәтмәделәр, кыек сүз әйтмәделәр.

Йосыф белән яшьтәш булгангамы, Фәрхәнә апа да, Дәүләтгәрәй абзый да Габделхәйне аеруча якын күрделәр. Ни генә булмасын, Габделхәй дә аларны чын күңелдән яратты һәм, күрәсең, шул сәбәпледер, башкалар да үзен шул ук дәрәҗәдә яраталар дип исәпләде.

Дәүләтгәрәй абзыйлар Ленин урамының иң кырыенда йорт урыны алып, шунда таудай яңа өй салып чыккач, аралар ерагайгач, ике арадагы мөнәсәбәтләр дә суына төшкәндәй булды һәм барып-килеп йөрүләр сирәгәя башлады. Габделхәйнең быел җәй Йосыфларда бөтенләй булганы юк иде әле.

Тоташ ак челтәрләр корылган, челтәр артында алсу чичкәле гөлләр елмаеп утырган зур, яңа тәрәзәләргә артык туры карамаска тырышып, шул ук вакытта челтәр аша кемнәрнеңдер үзен карап-күзәтеп тору ихтималын уйлап, Габделхәй җиңел генә ачыла торган биек, яңа капкадан ишегалдына килеп керде. Шуннан соң аяк астындагы кирпеч кисәкләренә басып, яңа, киң баскыч алдына килде. Такта чолан ишеге дә, өй ишеге дә ачып куелган, ачык ишекләргә чебен кермәсен өчен тәрәзәдәге кебек челтәрләр эленгән иде. Ачык ишектән хуҗаларның шаулашып-гөрләшеп сөйләшкәне, Йосыфның, ахрысы, скрипка шыңгырдатканы ишетелеп тора иде.

Колагына шат гөрелдек тавышлар ишетелү, борынына тәмле аш исләре килеп бәрелү белән Габделхәй шундук үзләренең ярлы өй эчен һәм әлерәк кенә булып алган күңелсез сөйләшүне исенә төшерде. Аларның өендә беркайчан менә шундый шат тавышлар да, скрипка шыңгырдавы да ишетелмәде, тәмле, итле аш исләре дә бөркелеп тормады, ахрысы. Габделхәйнең күңелендә шундук көнләшү һәм ачу тойгысы баш калкытты. Беркайчан, берничек аңлатып булмый торган бер сиземләү белән ул үзен монда — бу иркен, яңа һәм бәхетле йортта, ниндидер хәвеф-хәтәр көтеп торганлыгын шәйләгәндәй булды. «Кунаклар бар. Кире борылып китәргәме әллә?» — дип уйлады ул, икеләнеп.

Шулай да, ниндидер көчкә буйсынып, ул ачык ишектән эчкә керде һәм бик авырлык белән атлап ары юнәлде. Чолан уртасында ул туктап калды һәм йөрәге еш-еш типкән хәлдә өй эчендәге, өстәл янындагы тавышларга колак салды. Юк, монда барысы да ниндидер ят, ямьсез тавышлы кешеләр иде бугай. «Кермим!» — диде ул, ныклы бер карарга килеп.

Ул инде кире борылып китәргә дә иткән иде, шул чакны нидер кычкырып өйдән Дездемона килеп чыкты.

Дездемона Фәрхәнә апаның сугыш бетәр алдыннан туган бердәнбер кызы иде. Дездемона шатланып, кулларын җәеп, Габделхәйгә килеп сарылды. Габделхәй аны күтәреп алды һәм алар сөйләнә-сөйләнә өйгә керделәр.

## XIII

Олы якның түрендә, тәрәзә янындарак Йосыф белән Рамус басып тора иде. «Әһә, менә нинди ят тавышлы кеше бар икән монда!» — дип уйлады Габделхәй, чыраен сытып. Рамус аның иң яратмаган, иң җене сөймәгән кешеләрнең берсе иде.

Рамусны ни өчен яратмаганлыгын ул бик яхшы белә иде. Беренчедән, ул аны үзеннән тазарак булганы өчен яратмый. Икенчедән, аның төсен-битен, кыяфәтен җене сөйми иде. Аннан соң Рамус Василий Михайловичның олы малае иде. Директорның үзен яратмагач, ул, билгеле, аның малаен да ярата алмый иде.

Атасы кебек агач йөзле, балык күзле, дәртсез-җансыз кыяфәтле булуы өстенә Рамус дөньяга килмәгән бер җайсыз, чорсыз һәм тәкәббер нәрсә иде. Ул беркайчан, беркемгә, бернигә шатлана-куана да белми, гаҗәпләнә дә белми сыман иде. Аның өчен дөньяда, әйтерсең, барлык нәрсә таныш, билгеле. Ул инде бөтен нәрсәне күреп-белеп бетергән, барлык кайгы-шатлыкларны кичергән, бөтен җирдә булган, бөтен нәрсәне татып караган. Шуңа күрә ул, әйтерсең, дөньядагы һәркемнән остарак, белемлерәк һәм тәҗрибәлерәк иде. Кыскасы, бу дөньяда аның исен китерерлек берни дә калмаган иде.

Йосыф белән алар Яңавылның тимер юлга карый торган уникенче урыс мәктәбендә укыдылар. Быел менә икесе дә Габделхәй кебек үк унны бетерделәр. Урыс мәктәбендә чыгарылыш имтиханнары әзрәк. Шуңа күрә алар өлгергәнлек аттестатын да бер атнага элегрәк алдылар. Инәсе татар теле һәм әдәбияты укытучысы булгангамы, Йосыф өйдә, тышта, кеше арасында татарча сөйләшүдән әз генә тартынмый. Рамус исә ничек тә урысча гына сөйләшергә тырыша иде. Атасы директор булган татар мәктәбендә укучыларны ул, гомумән, кешегә дә санамый һәм шул нигездә Габделхәйгә дә гел кимсетеп карарга күнеккән иде.

Фәрхәнә апаның улы Йосыфның — Җобанай ягында бергә уйнап үскән Йосыфның — Рамус белән дус булуы, шуның белән ниндидер уртак сүз табып сөйләшеп-серләшеп йөрүе Габделхәйнең күптән инде саруын кайната иде. Озак вакытлар аның Фәрхәнә апаларга килми йөрүенең сәбәбе дә Йосыфның үзенә карата менә шул хыянәте

булды бугай. Менә хәзер дә аларның тәрәзә янында янәшә басып торган килеш чөке-чөке сөйләшүләре Габделхәйнең күңелен тырнап куйды. «Юкка килдем» диде ул тагын да үз-үзенә, үкенеп.

Аның килүен барысы да күреп алдылар, күреп алдылар да эшләреннән, сүзләреннән аерылып борылып карадылар. Йосыф кулларын сузып күрешергә килде. Габделхәй исә муенына сарылган Дездемонаны идәнгә бастырып куйды.

— Исәнмесез,— диде ул, Йосыфка кул биреп, ләкин чынлыкта бөтен өй эче белән исәнләшеп.

— Исәнме, Габделхәй,— диде Йосыф, елмаеп.— Әйдә, түрдән уз.

Күрешкәндә ул нык итеп аның кулын кысты һәм озак кына җибәрмичә селкеп торды. Үзләре мәктәбендә ул яхшы спортсмен исәпләнелә һәм үзенең чыннан да спортсмен икәнлеген сиздерү өчен күрешкәндә шулай кул көчен күрсәтергә ярата иде. «Көн дә итле аш ашасаң, кулың көчле була»,— дип уйлады Габделхәй, Йосыфның шулай кулны озак җибәрми торуын яратмыйча.

— Котлыйм, кичәгенәк сез дә аттестат алгансыз икән,— иде Йосыф.

— Алдык,— диде Габделхәй, тыелып кына.

Рамус та ашыкмыйча гына болар янына килде, авыз эченнән мыгырданып ниндидер котлау сыман сүз әйтте һәм Йосыф кебек үк Габделхәйнең кулын кысарга үрелде. Габделхәй аның нәрсә әйткәнен рәтләп ишетмәде дә, шулай ук аның кул кысуын да тоймады. Шул ук вакытта ул үзенең артында гына:

— Ә, Габделхәй икән! Менә әйбәт иткәнсең килеп,— дигән сүзләр ишетте.

Кече якның ачык ишегендә кояштай балкып Фәрхәнә апа басып тора иде. Ул анда мич алдында нидер пешерү белән булаша иде бугай — бит очлары кызарып чыккан, ак таза беләкләре сызганып куелган иде.

— Әле генә уйлаганыем — гомерең озын булыр әле,— диде Фәрхәнә апа.— Күрдеңме соң, бездә кунак бар.

— Күрдем,— диде Габделхәй, артык ачылып китмичә. Күңеленнән уйлап куйды: «Андый кунакны күргәнеңнән күрмәгәнең артык». Фәрхәнә апаларның яңа өйләре элекке байларныкы кебек олы яклы, кече яклы итеп салынган иде. Кухня хезмәтен үти торган кече як белән олы як арасында тар гына аралык калдырылган. Бер яктан икенче якка кергәндә-чыкканда менә шул аралык аша үтеп йөриләр иде. Габделхәй аралыкта, олы як ишеге янында тукталып тора иде. Йосыф аны олы якка, Дездемона кече якка өндәде.

Нишләргә белми аптырабрак торганда, ул кече якка борылып карарга мәҗбүр булды. Әле генә Фәрхәнә апа басып торган төштә ят бер кызны күреп ул дерт итеп китте. Ул аны таныды. Моннан берничә ел элек бөтен өй эчләре белән килеп, алар Фәрхәнә апаларда ял итеп, кунак булып киткәннәр иде. Фәрхәнә апаларның читтә, гомумән, туган-тумачалары күп иде. Җәй саен алар Яңавылга ял итәргә кайталар, кайткан саен диярлек берәр балаларын калдырып китәләр иде. Моннан ике-өч ел элек Уфадан кунакка кайткан әлеге кызыйның тагын ниндидер дус кызы да бар иде. Алар бер-берсеннән калмыйча гел бергә тагылып йөриләр иде. Шуңа күрә аларның берсен дә ялгыз гына туры китереп тә, сүз кушып та булмый иде. Ул вакытта Габделхәй кызларның берсенә — менә хәзер кече як ишеге төбендә басып торганына чын-чынлап гашыйк булды һәм ай буе Йосыф янына керергә куркып, кыздан, үз-үзеннән оялып-качып йөрде. Әтәсе-инәсе белән кыз Уфага кайтып киткәч исә үзен тоткыннан котылган кебек хис итте. Ул чактагы тәэсирләр, хис-тойгылар, беркайчан җуелмый торган нурлы тап булып, серле сурәт булып, мәңге аның күңелендә сакланып калды. Еш кына Габделхәйгә ул үзе ярата алачак, үзен искиткеч бәхетле итәчәк хатын-кыз Сәкинә, хәтта Җәмилә булып түгел, бәлки, нәкъ менә шундый «нурлы тап» сыман булып тоелды.

## XIV

Башына ул маңгай турысыннан кысып, бик килешле итеп, авылча ак яулык бәйләп куйган, биленә түшлексез алъяпкыч бәйләгән иде. Ут тирәсендә, аш тирәсендә булышканга алсу бите тагын да ныграк кызарып чыккан. Сызганылган матур беләгенә, бармакларына чак-чак кына он буялып калган иде. Өсте-башы җыйнак, килешле — Габделхәйнең әле Яңавылда, Сталин клубында да, пассажир поездыннан төшүчеләр арасында да беркайчан мондый матур сынлы, күркәм һәм ягымлы кызны күргәне юк иде бугай.

Алар, бер-берсеннән күзләрен алмыйча, күпмедер вакыт карашып тордылар. Бу карашу әйтеп бетермәслек дәрәҗәдә озак булып тоелды. Шул ук вакытта бу карашу коточкыч тиз һәм аз да булып тоелды. Бер дә юктан Габделхәй кызарына башлады, тик торганда, бөтенләй кирәкмәгәндә үзенең өс-башына игътибар итте. Үз гомерендә беренче мәртәбә күргән сыман, үзенең тузанланган, катып беткән брезент өсле кара ботинкасына, сидрәп, таушалып беткән киң балаклы чалбарына, иске гимнастерка-

дан бозып тегелгән килешсез күлмәгенең җиң очларына карап алды. Шундый сылу шәһәр кызыннан бөркелеп торган нәфислек, исерткеч гүзәллек янында ул үзен бик мескен, ярлы һәм ахмак итеп тойды. Үзенең шул ярлылыгы, мескенлеге, ямьсезлеге өчен шундук күңелендә, мәңге бетмәс сызлавык булып, гарьләнү-хурлану ачысы баш калкытты. «Юкка килгәнмен»,— дип уйлады ул, тагын да төшенкелеккә бирелеп.

— Исәнмесез,— диде ул, шулай да беренче булып. Чибәр кыз җавап кайтармады — сөрмәле күзләрен тутырып, аптыраган сыман карап тик торды. Ике арада уңайсыз тынлык барлыкка килде.

— Мин сезне беләм,— диде Габделхәй, ашыгып.

— Шулаймыни? Исәнмесез,— диде кыз.

Ул моны ничектер бик җиңел генә, бер дә исе китмичә генә әйтте. Аның «исәнмесез»ендә Габделхәй хәтта үзенә карата саксызлык, салкынлык сизеп алды. Бу аны үтереп ташлагандай булды. Йөзендәге уңайсыз кызыллык шундук юк булды. «Тук. Чибәр. Шәһәр ялкаулары барысы да шундый»,— дип уйлады ул, кунак кызын түбәнсетмәкче булып.

— Былбылны беләсеңдер ич, Габделхәй?— диде Фәрхәнә апа, яңадан ишек янына килеп.

«Әйе, исеме Былбыл иде бугай»,— дип уйлады Габделхәй.

— Беләм,— диде ул.

— Син Габделхәйне беләсеңме соң?— диде Фәрхәнә апа, бу юлы кызга эндәшеп.— Габделхәйне дә белмәгәч... Беләсеңдер. Бердәнбер Габделхәебез инде ул безнең.

Кулларын ак чалбар кесәсенә тыгып алар янына Рамус килеп җитте. Күрәсең, Былбыл белән Габделхәйнең сөйләшүен ул читтән генә тыңлап торган иде. Көнләшүенә түзә алмыйча, кыз алдында үзен шәп кеше итеп күрсәтмәкче булып, ахрысы, һәм гадәтенчә шактый тупас итеп:

— Яңавылда Габделхәйне белмәгән бер эт тә юк,— диде.

Рамус үзе шаяртам дип уйлады, ахрысы — үз сүзеннән үзе кызык табып көләргә тотынды. Дездемона да көлеп җибәрде. Фәрхәнә апа белән Былбылның йөзе үзгәреп китте. Шулай да алар, ипсез кунакларының урынсыз сүзләрен уенга борып, елмаерга мәҗбүр булдылар. Мондый шаяртуга бары Габделхәй генә елмая алмады. Бөтен тәне белән ул бер йодрыкка йомарланып калды. Аның ярсып оятсыз Рамуска ташланасы килде. Ләкин кеше өендә, кунак кызы алдында мондый нәрсә мөмкин түгел иде. Үз-үзен тыеп, шулай да таштай катып калган йөз белән ул Рамус ягына бер карап кына

алды. Рамус аның бозылган йөзен әллә күрде, әллә күрмәде — шул ук тупас, дорфа шаярту белән шаярткан булып, Габделхәйнең аркасына кагып алды. Монысы инде чамадан тыш иде. Габделхәй, үзе дә сизмәстән, шаяртучының кулына сугып җибәрде һәм алай-болай сугышырга туры килсә дигән сыман, ашыгып олы якка таба атлады.

Ул кергәндә Йосыф яңадан үзенең скрипкасына тотынган һәм татарча ниндидер көй чыгарырга азаплана иде. Скрипка тавышы ярсыган Габделхәйне айнытып җибәрде. Берни булмаган кебек ул ике тәрәзә арасындагы этажерка янына килде, урындыкка утырды да этажеркадагы таныш китапларны караштыра башлады. Шундук аның янына Дездемона килеп җитте, кылтаеп-чорсызланып кулына асылынды, нидер эзләп чалбар кесәсен актарды. Габделхәй, берни сизмәгәндәй, кулындагы китапка кадалып тик утырды. Ләкин әдәпсез кызый куен кесәсеннән шигырь язылган куен дәфтәренә тотынгач, түзмәде — каты гына итеп карак кулны тотып алды да өйдәгеләр игътибар итмәс дәрәҗәдә тыелып кына:

— Сиңа кирәкми ул,— диде.

— Шигырь дәфтәре! Шигыреңне укы әле!— диде кызый, тарткалашып.

Якында гына, идән уртасындагы озын аш өстәле янында Былбыл табак-савыт урнаштыру белән мәшгуль иде. Габделхәй аның нидер эшләвен күреп-сизеп утырды, ләкин бер генә мәртәбә дә күтәрелеп карамады. Дездемонаның «шигырь» турында сүз чыгаруы аның җен ачуларын кузгатты.

— Кит әле моннан!— диде ул, кызый кулын янә читкә этәреп.

«Шигырь» сүзен Былбыл да ишетеп калды. Эшеннән тукталгандай итеп ул Габделхәй ягына борылды һәм:

— Бүгенге гәзиттә ул сезнең шигырь басылганмы әллә?— диде.

Гәзиттә басылган шигырь астына авторның исем-фамилиясе язылган иде, шуңа күрә аның кемнеке икәнлеген сорау урынсыз иде.

— Минеке,— диде Габделхәй, шулай да башын калкытмыйча гына.

— Миңа бик ошады сезнең шигырегез,— диде Былбыл.

Габделхәйгә рәхәт булып китте. Ул инде чибәр кыз белән яңадан татулашырга да, ягымлы итеп сөйләшә башларга да әзер иде, ләкин шул вакыт алар янына тагын сөйкемсез Рамус килеп җитте һәм Габделхәйне мактаган сыман, чынлыкта исә аның дәрәҗәсен төшерергә тырышып:

— Это — наша знаменитость!* — диде.

Габделхәйнең йөзенә кан бәрде. Ләкин ул, берни ишетмәгәндәй, башын калкытмыйча, тешен кысып, урынында берегеп утыруында булды. «Күрсәтермен әле мин сиңа «знаменитость»ны!»— диде ул, үз-үзенә көчсез бер ярсу белән.

## XV

Ул арада Йосыф скрипкасын көйләп бетерде һәм җылатып, чыңлатып нииндидер ямьсез көй уйный башлады. Уйнаучы алдында яхшатлы булып күренергә тырышып, барысы да ахмакларча тынып калдылар. Габделхәй тыңламады һәм, үз-үзен мәҗбүр итеп, китаптагы нииндидер физик формуланы аңларга тырышты. Ул инде бер үк сүзләрне биш-алты мәртәбә укып чыкты, ләкин бер нәрсә дә аңлый алмады — бөтен игътибарын буташтырып, ачу һәм нәфрәт көчен таркатып, колак төбендә туктаусыз скрипка чыңлады.

Йосыф уйнап бетергәч, беренче булып Рамус кычкырды:

— Браво! Браво! Во какие у нас таланты!** — диде.

— И-и, Йосыф, шундый матур итеп уйнадың,— диде Былбыл сузып, кылтаеп.

Чытык йөзле Фәрхәнә апа кече яктан сузылып карады да Йосыфка эндәшеп, ләкин чынлыкта Габделхәйне күз алдында тотып:

— Йосыф, юынтык суын гына түгеп кер әле,— диде.

Габделхәй кичәгенәк мәктәптә дә Фәрхәнә апаның юынты суы түктерүен исенә төшерде һәм яратмыйча: «Нинди бетмәгән юынты суы инде ул?»— дип уйлады. Уфа кызы исә, Рамус белән Йосыф алдында үзенең эшчәнлеген күрсәтмәкче булып, тиз генә кече якка чыгып китте һәм бөтен өйгә чәрелдәп:

— Үзем чыгарырмын, чибәрттәй!— диде.

Аңа булышка дип шундук маймул Рамус кузгалды, атасы кебек мыштырдык Йосыф кузгалды. Ләкин алар килеп җиткәнче, кунак кызы тулы чиләкне җилтерәтеп алып чыгып та китте. Каш астыннан як-ягына каранга-лап Габделхәй аларның шулай тыз-быз килүен ачу белән күзәтеп утырды. «Эшләгез, шул кирәк сезгә!»— дип уйлады ул зәһәрләнеп. Маймул Рамус шулай да кызны куып җитте, ахрысы, Габделхәй аларның чыркылдашып тышкы ишектән чыгуларын ишетеп утырды. «Нинди эшчән!»— дип уйлады ул «маймул» турында. Үзләрендә

* — Бу безнең атаклы кешебез!
** — Шәп! Менә нинди талантлар бар бездә!

бер дә эшчән түгел, Халидә апа нәрсә кушса да, эшлисе килмичә кырык сүзгә җитешә. Монда әнә нинди өлгер, нинди җитез! Алар барысы да мәкерле, икейөзле — атасы да, улы да.

Габделхәй карасына коелып, үзалдына үртәлеп утырганда, каяндыр Дәүләтгәрәй абзый кайтып керде. Ачык ишек аша Габделхәй аның кулында авыр гына сумка булуын күреп алды. «Магазиннан кайтты»,— дип уйлады ул, яратмыйча. Дәүләтгәрәй абзый райфо кешесе. Ниндидер начальник. Бәләкәй генә начальник булса да, Яңавылдагы теләсә нинди олы начальник белән эшнә. Яңавылда аны белмәгән кеше юк. Кайда да аның сүзе — сүз. Кирәк нәрсәне алар итәк астыннан гына алалар, менә шулай караңгы төшкәч кенә алып кайталар. Үзләре алып кайтасылары килмәсә, китереп бирәләр. Авылдан колхоз персидәтелләре тәпән-тәпән бал, түшкәсе белән ит калдырып китәләр. Белми түгел, беләбез — барысы да күз алдында. Шуңа да аларда һәркөнне итле аш пешә, атна саен кунак була. Яши белә ул Дәүләтгәрәй абзый! Беркем белән бозылышмый, беркем белән ачуланышмый.

Кече якта сумкасын калдырып Дәүләтгәрәй абзый олы якка чыкты. Габделхәйне күреп алды да:

— Исәнме, Габделхәй,— диде, салмак кына.— Инәң нишләп ята, хәле ничек? Илгиз белән Фидәил ни хәлдә?

Дәүләтгәрәй абзыйның беренче булып исәнлек-саулык сораштыруы, тыныч, ягымлы тавышы Габделхәйне юаткан сыман булды. Никтер аның кинәт кенә җылыйсы һәм Дәүләтгәрәй абзыйга зарланасы килде.

— Инәкәйнең кәефе юграк әле,— диде ул.

— Чирләп киттеме әллә?— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Шулай бугай,— диде Габделхәй.

— Сез борчыйсыздыр инде... Илгизме, Фидәилме...— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Борчымадык шикелле,— диде Габделхәй. Дәүләтгәрәй абзый Габделхәйгә якын гына урындыкка утырды да, бик нык арыган кеше сыман, күнитекле аякларын сузып җибәрде. Йөгергәләп аның янына Дездемона килеп җитте һәм нечкә генә куллары белән әтисенең күнитеген салдырмакчы булып көчәнә башлады. Ул шулай олыларның аяк киемнәрен салдырырга ярата иде. Дәүләтгәрәй абзый урыныннан торды һәм утырган урындыгын да алып «ишек төбенә»— кече як белән олы як арасындагы аралыкка чыкты. Габделхәй үз урынында утырып калды. Якында гына Дездемонаның көлә-көлә чыр-чу килеп итек салганы, Дәүләтгәрәй абзыйның, иренеп кенә, үскән, кызын мактаганы ишетелеп торды. Дәүләтгәрәй абзый, го-

мумән, җай гына, салмак кына сөйләшә иде, шуңа күрә аның кайчан ачуланганын, кайчан шатланганын бик үк белеп тә булмый иде.

Бераздан кайдадыр югалып торган Йосыф та скрипкасын күтәреп олы якка чыкты. Аның артыннан ук Дездемона белән Дәүләтгәрәй абзый килеп керде.

— Әти, тыңлале,— диде Йосыф, яңадан скрипкасын шыңгырдатмакчы булып.

Урысча укыса да, Йосыф шулай китапча «әти-әни» дип сөйләшә һәм сүз арасында Яңавылча булмаган кайбер ят сүзләр кыстыргалый иде. Чыкылдап торган татар баласының әтәсе-инәсе белән урысча сөйләшүе ни дәрәҗәдә ят һәм кыргый булып тоелса, Яңавыл шартларында Йосыфның шулай «әти-әни» дип сөйләшүе дә ят һәм кыргый булып тоела иде. Шулай да китапларда «әти-әни»не күп укыганга, Габделхәйгә аның тел бозуы әллә ни зыянлы булып тоелмады.

— Тыңлыйм, улым, тыңлыйм,— диде Дәүләтгәрәй абзый, тыныч кына.— Бер җылда бер көй үрәнсәң, ярый инде.

— Тыңлале син, әти, тыңлале!— диде Йосыф һәм әлерәк кенә уйнаган көйне яңадан чыжлата башлады.

Дәүләтгәрәй абзый бирелеп тыңлады. Аның белән бергә Габделхәй дә тыңлады. Хәзер аңа Йосыфның уйнавы дәртлерәк, матуррак, дөресрәк сыман тоелды. Берничә минут эчендә Йосыфның шулай оста итеп уйнарга өйрәнүенә ул шаккатты. «Менә, ичмасам, талант!»— дип уйлады ул үзалдына.

Шул чакны ашыгып, көлешеп олы якка Былбыл белән «маймул» килеп керде. Йосыф һаман уйнавында булды, ләкин ягымлы скрипка тавышы Габделхәй өчен кинәт ишетелми башлады. Тынычлык югалды һәм бөтен өй эче караңгыланып калгандай булды.

## XVI

Ниһаять, күптән көтелгән аш өлгерде. Терсәкләрен як-якка тырпайтып, ике куллап зур, авыр мискинең тоткаларын чүпрәк белән тоткан килеш, кече яктан Фәрхәнә апа чыкты. Мискине җайлап кына олы яктагы өстәл уртасына китереп куйды һәм канәгать төс белән елмаеп, өй эчендәге яшьләргә күз йөртеп алды. Аның артыннан ук диярлек бер-берсе өстенә куелган коштабаклар күтәреп Былбыл керде, җитез генә кыланып коштабакларны тезеп чыкты. Ул арада озын саплы чүмеч тотып, кылтаеп, як-ягына каранып Дездемона килеп җитте.

Фәрхәнә апа иркә кызының кулыннан озын саплы чүмечне алды да коштабакларга кайнар шулпа бүлә башлады.

— Әйдәгез, кунаклар, утырыша башлагыз,— диде Дәүләтгәрәй абзый, яшьләрне табын янына чакырып.

— Әйдәгез, әйдә,— диде Фәрхәнә апа да.

Иптәшләрен кыстап-нитеп тормыйча өстәл янына беренче булып Йосыф утырды. Аның янындагы урындыкка тиктормас Дездемона менеп утырды. Габделхәйнең урын сайлап торасы юк иде — ул болай да өстәлгә якын гына утыра иде. Шунлыктан ул урындыгын беркадәр күчергәндәй генә итте. Аның урыны Йосыфның икенче ягына туры килде. Маймул Рамус, ниндидер сәбәп тапкан булып, һаман читтә буталды. Бүтән вакыт булса, әйткәнне дә көтеп тормастан, өстәлнең түрге башына ук килеп утырган булыр иде. Хәзер ул ашыкмады — Былбыл утырганны көтте. Габделхәй моны бөтен күңеле белән сизеп утырды. Алай гына да түгел, ул хәтта алар арасында инде ниндидер сөйләшү-аңлашу булуын да чамалап алды.

— Сиңа нәрсә әйтелде — ник утырмыйсың?— диде Дездемона, Рамус янына килеп.— Әйдәле, әйдә!

Габделхәйгә кылтык кызның кыланышы беренче мәртәбә көлке тоелды. Канәгать йөз белән ул үзалдына көлемсерәп куйды. Маймул Рамус, Дездемонаның сүзен тыңлаган сыман итеп, өстәлнең ишеккә караган башына — Габделхәйгә каршы якка килеп утырды. Аның бер ягында буш урын калды. Ул, күрәсең, Былбыл шунда утырыр дип чамалады. Ләкин буш урынга Фәрхәнә апа килеп утырды. Аңа моннан кирәк чакта торып китәргә, кече якка чыгып керергә җайлы иде. Маймулның икенче ягына Дәүләтгәрәй абзый, Дәүләтгәрәй абзыйның икенче ягына Былбыл килеп утырды. Габделхәй җиңел сулап куйды. Шәп булды Маймулга!

Ашый башлаганчы Дәүләтгәрәй абзый иелеп өстәл астыннан бер шешә ак аракы алды да башта үз рюмкасына салды, аннан соң яшьләр алдындагы рюмкаларга тамызып чыкты.

— Балалар, мине тыңлагыз әле,— диде ул, яшьләргә карап.— Бүген бездә бәйрәм. Бу көнне без күптән көттек. Әйтеп куйган сүзебез дә барые — Йосыф унны бетерсә, яшьләрне җыеп күңел ачарбыз дип. Заманында безнең үзебезгә болай аш-су ясап, күңелле итеп утырулар төшмәде. Балаларыбыз рәхәт яшәсен дидек. Сезнең өчен дә, безнең өчен дә куанычлы көн бүген. Сез менә унны бетердегез, яңа тормышка аяк бастыгыз. Нур өстенә нур булып Уфа кызыбыз да килеп төште. Кая соң әле үзе?

Дәүләтгәрәй абзый кайчагында шулай шаяртырга яра-

та иде. Былбылны күрмәгән сыман кыланып ул каршы яктагыларга игътибар беләнрәк карап чыкты. Дездемона кычкырып көлеп җибәрде. Дәүләтгәрәй абзыйның уң ягында утырган Былбыл шулай ук чын күңелдән көләргә тотынды.

— Монда ич мин, җизнәй!— диде ул.

— Әй, монда икәнсең!— дигән булды шат күңелле Дәүләтгәрәй абзый.

Юан бармакларының очы белән генә тотып ул тулы рюмканы кулына алды һәм бу юлы инде беркемгә дә карамыйча гына:

— Сезнең хөрмәткә эчеп җибәрсәм, ачуланмассыз,— диде.

— Ачуланмыйбыз, ачуланмыйбыз!— дип кычкырды беренче булып әдәпсез Рамус.

Дәүләтгәрәй абзый аракының тамчысын да калдырмый эчеп бетерде дә тәлинкәдән каклаган каз ите алып чәйнәргә тотынды.

— Әйдәгез әле, иптәшләр... балалар, җитешегез,— диде Фәрхәнә апа, яшьләрне ашарга кыстап.

— Сезне болай аздыру килешеп тә бетми инде,— диде Дәүләтгәрәй абзый, яңадан сүзгә башлап.— Әллә иң элек эчеп җибәрсеннәр микән, Фәрхәнә?

— Мин каршы түгел,— диде Фәрхәнә апа.— Алар хәзер олы кешеләр. Үз акыллары үзләре белән.

— Без эчмибез, җизнәй, кыстый күрмә,— диде Былбыл.

— Юк, юк, эчәбез!— диде Маймул, каршы килгән булып.

— Әйдәгез әле, әйдә, ашагыз,— диде Фәрхәнә апа, кыстап.

— Кая соң минем кашык?— диде шул чакны Былбыл, як-ягына каранып, эзләнеп.

Барысы да ашауларыннан туктап аның ягына борылып карадылар.

— Үземә кашык куймаганмын ич мин!— диде Былбыл, көлеп һәм тиз генә урыныннан торды да кашыкка дип кече якка йөгерде.

Былбыл чыгып китү белән, Дәүләтгәрәй абзый ашъяулык астына яшерелгән кашыкны алып Былбыл коштабагы янына куйды. Былбыл кашык алып килеп яңадан үз урынына утырган иде, өстәлдә кашык күреп, чын күңелдән аптырап калды, аңлап алды да көләргә тотынды. Аңа ияреп бүтәннәр дә көлешә башладылар.

— Кем эше бу? Йосыфтыр әле!— диде Былбыл, Йосыф ягына каранып.

— Йосыф булмый кем булсын?— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Бар этлек шул Йосыфтан чыга. Разведчик булыр, ахрысы, минем улым.

— Түгел! Түгел!— диде Дездемона, кулларын чәбәкләп.— Йосыф абый түгел, әти үзе!

— Балалы өйдә бур тормас,— диде Фәрханә апа.— Ашап кына утырыгыз әле, иптәшләр... балалар.

Иптәшләр... балалар ашап кына утырдылар да. Бер коштабак токмачлы ашны күз ачып йомганчы ялт итеп куйдылар. Аштан соң бәрәңге, кишер, кәбестә белән аралаштырылган йомшак бәрән ите килде. Иткә тотыныр алдыннан Дәүләтгәрәй абзый тагын икенче рюмка тәкъдим итте, ләкин артык кыстап тормады — башкалар күрмәсен дигәндәй үзе тиз генә эчеп җибәрде.

— Белеп ашагыз — безнең иң олы кызыбыз Диздекәй карап үстергән бәрән булыр бу,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Алдый, алдый! Үзе карады,— диде олыларча сөйләшергә ярата торган кызчык.

Итле бәрәңге дә ашалып беткәч, Фәрханә апа зур табада томалап пешерелгән балык китерде. Балыклы таба өстенә бәлеш кебек итеп камыр капланган иде. Табаны Фәрханә апа туп-туры өстәл уртасына китереп утыртты, пычак очы белән каерып камыр капкачны ачты һәм капкачны өске ягы белән буш коштабакка куйды. Табада түгәрәк күзләре ап-ак булып пешкән кушбашлар, алабугалар тезелеп ята иде.

— Менә болары Рамус белән Йосыф тоткан балыклар,— диде Фәрханә апа, аңлатып.

— Монысын кем тотты?— диде Былбыл, иң зур балыкка күрсәтеп.

— Мин!— диде Рамус.

— Тоттың!— диде Йосыф, көлемсерәп.

— Тагын кайчан барасыз балыкка? Мине дә алып барыгыз әле, Йосыф,— диде Былбыл.

— Браво! Барабыз!— диде Рамус.

Фәрханә апа балыкларны һәркемгә тигез итеп бүләргә тырышты. Тик менә иң олы кушбаш мәсьәләсендә генә икеләнгәндәй итеп калды.

— Туктале, монысын тоткан кешенең үзенә бирик,— диде ул олы кушбашны урыныннан кузгатмакчы булып.

«Кемгә бирер икән — Маймулгамы, Йосыфкамы?» — дип уйлады Габделхәй, олы кушбаштан күзен алмыйча. Башкалар да шулайрак дип уйладылар, ахрысы.

— Әтигә бир. Иң олысы — әтигә!— диде Йосыф.

— Ярар алайса,— диде Фәрханә апа, шундук килешеп.

Габделхәйгә бер кушбаш белән бер алабуга туры килде. Балыкны ул теләр-теләмәс кенә ашады. Никтер аңа нәкъ шушы балыкларны маймул Рамус тоткандыр сыман булып, ашый башлау белән, бөтенесе алдында «бу

балыкларны мин тоттым!» дип кычкырыр сыман тоелды.

Яшьләр балык ашаган арада, Фәрхәнә апа тагын кече якка чыгып китте, аның чыгуын күреп, Былбыл да аның артыннан кузгалды. Теге якта мич алдында шакы-шокы килеп алар нәрсәнедер күчерделәр, нәрсәнедер әвеш-түеш китерделәр. Балыкны да ялт итеп куйгач, өстәл янындагылар беравык тынып утырдылар. Урыныннан беренче булып Дәүләтгәрәй абзый кузгалып китте. Аннан күрмәкче дигәндәй, Йосыф та кузгалды.

— Таралышмагыз — хәзер баллы катык белән җимеш суы килә,— диде Фәрхәнә апа, кече яктан чыгып.

— Мин җимеш суын эчтем инде,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Кунакларны сыйла, балаларны...

Стаканнарга салынган җимеш суын олы якка Былбыл алып чыкты. Бал катыштырып тәмләтелгән салкын катыкны тыштан Фәрхәнә апа алып керде.

— Катыгы — үзебезнеке,— диде Фәрхәнә апа, аңлатырга кирәк табып.— Өрекләре, йөземнәре — Былбыл күчтәнәче.

— И-и, чибәрттәй, кеше алдында оятлы итәсең инде,— диде Былбыл, уңайсызланып.

## XVII

Баллы катык ашалып, җимеш суы эчелеп беткәч, яшьләр таралыша башладылар. Йосыф скрипкасына тотынды. Фәрхәнә апа белән Былбыл олы яктан кече якка табак-савыт ташыдылар. Дәүләтгәрәй абзый тышка чыгып китте. Габделхәй, Йосыфның скрипка шыңгырдатуын тыңлагандай итте дә шулай ук тышка чыкты. Бераздан скрипкасын күтәреп Йосыф та күренде. Алар баскычта тын алып, җилләнеп утырганда маймул Рамус чыкты. Аның баскыч төбендәгеләр янында тукталып торасы килмәде — каядыр ары китеп барды. Йосыф туктаусыз скрипкасын көйләвендә булды. Дәүләтгәрәй абзый белән Габделхәй аның уйнавына колак салгандай итеп, тын гына утырып тордылар.

— Ничек соң, Габделхәй, кая китәргә, нишләргә исәп?— диде бераздан Дәүләтгәрәй абзый.— Безнең җегетләр әнә Казанга, авиационнныйга кермәкче булалар.

Йосыфның Казанга, авиация институтына китәргә ниятләвен Габделхәй болай да белә иде, ләкин аның «җегетләр» белән китәргә исәпләвен ул әле белми иде. Димәк, бергә барачаклар Казанга, керсәләр — бергә укыячаклар.

Алар янына Былбыл да чыкты һәм өске басмада тот-

карланып калды. Дәүләтгәрәй абзыйның соңгы сүзләрен ул ишетеп калды бугай.

— Сез бит әле өчегез дә быел унны бетердегез, иеме?— диде ул.

Соравын ул беркемгә дә төбәп әйтмәде, шулай да Габделхәй аны үзенә атап әйтелгән дип аңлады. Бу тагын да баягынак кунак кызының: «Бүгенге гәзиттә ул сезнең шигырь басылганмы әллә?»— дигәне сымаграк булды, чөнки аларның өчесенең дә быел унны бетерүләре турында инде сүз булган иде.

— Бетердек,— диде Габделхәй, кызның соравын җавапсыз калдырмас өчен генә.

— Сезгә филолог булырга кирәк, Габделхәй,— диде Былбыл.— Шигырь язучыларның барысы да филолог булалар. Безнең университетта татар кафедрасы бар...

Габделхәй сагая калды. «Университет», «кафедра» сүзләрен аның элек тә ишеткәне бар иде, тик менә аларның мәгънәләрен генә төгәл аңлап җитми иде. «Филологны ул, гомумән, белми иде. Ят, серле һәм аңлаешсыз иде ул «филолог» сүзе. Хәзер менә Былбылның ят, аңлаешсыз сүзләрне шундый тиз һәм җиңел әйтүе Габделхәйгә гаҗәеп тылсым кебек тәэсир итте. Чибәр кунак кызы аңа искиткеч башлы һәм белемле булып тоелды.

Ике арада сүз шулай җайланып китәргә генә торганда, каршыга көтмәгәндә Маймул килеп басты.

— Фу, филолог!— диде, кулын селтәп.

Аңа беркем игътибар итмәскә тырышты, ләкин тыныч кына утырганда безелдәп килеп җиткән, биткә, күзгә кунган черкигә игътибар итмәү мөмкин булмаган кебек, бу әдәпсез бәндәгә дә игътибар итмәү мөмкин түгел иде.

— Филологка ни булган?— диде Габделхәй, тыелып кына.

Рамус җавап биреп тормады, ямьсез көлеп тагын кулын гына селтәде. Ярый әле шул чакны Фәрхәнә апаның тавышы ишетелде — ул да тын алырга дип баскыч төбенә чыккан иде.

— Университетта татар кафедрасы бармыни?— диде Фәрхәнә апа, бик нык гаҗәпләнеп.

— Бар!— диде Былбыл.— Кырык дүртенче елны ачканнар.

— Без монда берни белми ятабыз, томаналар,— диде Фәрхәнә апа, үз-үзен тәнкыйтьләп.

— Татар кафедрасында шагыйрьләр, язучылар укый,— диде Былбыл.— Әдәби кичәләр оештыралар, үзләренең газеталарын чыгаралар.

— Без укыганда да әдәби кичәләр буладырые,— диде Фәрхәнә апа.— Безнең янга да язучылар киләдерие. Бервакыт Такташ килде.

— Такташ?!— диде Габделхәй.— Сезнең әйткәнегез булмады бугай.

— Исемнән чыккандыр,— диде Фәрхәнә апа.— Кутуй да килә торганые.

— Фәрхәнә апаң ул... Галимҗан Ибраһимовны үз күзләре белән күргән кеше,— диде Дәүләтгәрәй абзый, беркадәр серле һәм тантаналы итеп.

Мондый сүз ишетеп баскыч төбендәгеләр тынып калдылар.

— Теге... халык дошманымы?— диде Габделхәй, үзенең белемле икәнлеген күрсәтәсе килеп.

— Утыра шунда юк-барны лыгырдап!— диде Фәрхәнә апа, Дәүләтгәрәй абзыйга ачуланып.— Ул чакта кем белгән аның халык дошманы икәнен? Маңгаена язып куймаган — кеше кебек кеше.

— Кызык,— диде Былбыл.— Сөйләле, чибәрттәй, ничек күрдең? Безнең әти гел искә төшерә аны.

— Кемне? Галимҗан Ибраһимовнымы?!— диде Габделхәй, коты алынып.

— Галимҗан Ибраһимовны, Солтангалиевне, Гаяз Исхакыйны, тагын әллә кемнәрне!— диде Былбыл.

— Ярар, балалар, бик кычкырып сөйләшмәгез,— диде Фәрхәнә апа, тынычсызланып, як-ягына каранып.

— Әйдәгез, өйгә керик,— диде Дәүләтгәрәй абзый да. Барысы да кузгалышып куйдылар, керә торган якка борылдылар.

— Хәзер дә безгә язучылар килә, диспутлар була, автографлар бирәләр,— диде Былбыл.

«Нәрсә соң ул диспут, автограф?»— дип сорыйсы килде Габделхәйнең, ләкин сөйкемсез Рамус һәм Былбыл алдында надан булып күренмәс өчен сорамаска булды. Чынында ул андый чит сүзләргә игътибар да итмәде — аны хәзер каршылыклы уйлар биләп алды. Шундый чибәр һәм акыллы кызның җиңел генә, хәтта тотнаксыз рәвештә үз әтисенең халык дошманы Ибраһимовны... фашистлар, империалистлар ялчысы Солтангалиевне, Гаяз Исхакыйны белүе турында авыз тутырып, кычкырып сөйләве аңлашылып җитмәде.

Үзенең бик зур хата җибәрүен Былбыл үзе дә төшенмәде, ахрысы.

— Беләсезме, безнең университетта тагын кем укыган? Толстой!— диде ул, сүзне икенчегә борып.

— Кайсы Толстой әле ул?— диде Фәрхәнә апа.

— И-и, чибәрттәй!— диде Былбыл.— Шуны да белмәгәч инде!

— Язучы Толстойлар икәү-өчәү булган түгелме соң?— диде Фәрхәнә апа, Былбылның тәнкыйтенә әз генә дә исе китмичә.

— Өчәү!— диде Рамус.— Лев Толстой, Граф Толстой, Алексей Толстой.

— Бөек Толстой бер генә — Лев Толстой!— диде Былбыл, шактый тантаналы итеп.

— Граф Толстой тоже был великим *,— диде Рамус.

— Граф Толстой шул ук Лев Толстой бит инде!— диде Былбыл, көлеп.

Ләкин Рамусның бирешәсе килмәде һәм ул кычкырып, кулларын бутап Граф белән Левның икесе ике Толстой булуын исбатларга тотынды.

Габделхәй бәхәскә катнашмаска тырышты. Ул Былбылның чыннан да күп белүен күрде. «Филологлар шундый белемле була торганнардыр инде»,— дип уйлады Габделхәй. Ул да филолог булырга тиеш. Шагыйрь генә түгел, филолог та!

## XVIII

Толстойлар турындагы бәхәс өйгә кереп яңадан урыннарга утыргач та дәвам итте. Былбыл Казан университетында укыган бик күп атаклы кешеләрнең исемнәрен әйтте. Ленин, Лобачевский, Щапов... дип тезеп китте.

— Горький!— диде Рамус, янә дә барысыннан да уздырмакчы булып.

Былбыл тагын каршы килде һәм Горькийның Казан университетында укымаганлыгын исбат итә башлады. Рамус бирешергә теләмәде. Былбыл, яклау эзләп, башта Йосыфка, аннары Габделхәйгә карап алды. Йосыфның әдәбиятка кагылышлы бәхәскә кереп торасы килмәде.

— Мин инде литературадан экзамен бирдем «отлично»га,— диде ул, әтисе кебек тыныч кына.

Былбыл да, Рамус та көләргә тотындылар. Габделхәй көлмәде. Аның күңеленә бер уй килде. «Казан университетында бер генә атаклы татар да укымады микән-ни?»— диде ул үз-үзенә һәм дәрестә үткән, аннан-моннан укып белгән гыйлемен барларга тотынды. Аның хәзер ничек тә берәр атаклы татар исеме әйтеп ялтырап аласы килде. Ләкин, никадәр исенә төшерергә тырышмасын, андый кешене хәтерли алмады.

---

* — Граф Толстой да бөек язучы булган.

— Белдем!— диде ул кинәт.— Каюм Насыйри да Казан университетында укыган!

Былбылның кызып бәхәсләшүдән кызарып чыккан йөзе сүрелеп калды. Каюм Насыйриның Казан университетында укуын-укымавын ул, ахрысы, белеп җиткерми иде, ләкин Казанда берничә татар галиме булганлыгын шулай да чамалый иде, ахрысы.

— Бездә Җәләй бар, Камай бар,— диде ул.

— Ну, пошло! Бездә, бездә...— диде Рамус яратмыйча, хәтта нәфрәт белән.— Подумаешь, великие татарские ученые!*

Маймулның бу мыскыллы сүзләре турыдан-туры Габделхәйнең йөрәгенә килеп кадалды. Аның бөтен эче-тышы актарылып чыкты, үзеннән-үзе йодрыклары йомарланды. Ул яңадан тешен кысып эндәшми калырга мәҗбүр булды. Шулай да мондый киеренкелек озакка бармады — көтмәгәндә бөтен өйгә таныш скрипка тавышы чыңлап китте. Чәче кыска итеп алынган, озынча зур башын чак-чак кына кыңгыр салып һәм бөтен гәүдәсе белән як-якка селкенгәләп, Дәүләтгәрәй абзый «Салкын чишмә»не сыздыра башлады. Скрипка тавышы бераз гына карлыккан сыман тоелды, шулай да аның дәртле, моңлы һәм тынычландыргыч авазлары бөтен өй эчен тутырды, ачык тәрәзәдән тышка, кичке тынлыкка агылып чыкты.

Шәп итеп, яхшы итеп скрипкада уйнарга өйрәнү Дәүләтгәрәй абзыйның күптәнге хыялы иде. Ул аңа яшь чагында музыка түгәрәгенә йөргәндә өйрәнештереп калган иде. Ләкин менә шул бик күптән өйрәнештереп калганнан артыгын өйрәнергә аның вакыты да, мөмкинлеге дә булмады. Ул уйный белгән көйләр дә бик күптәнге, музыка түгәрәгендә отып калган көйләр генә иде. Күңеле аеруча нечкәргән чакларда ул менә шуларны яңадан казып чыгара һәм тыңлаучылар алдында шуның белән бераз гына мактанып алырга да ярата иде. «Салкын чишмә»дән соң ул, тын да алып тормыйча, «Уел»га күчте, «Уел»дан — «Тәфтиләү»гә.

Үзе белгән, үзе яраткан көйләрне уйнап бетергәч, Дәүләтгәрәй абзый, тыңлыйлар микән дигән сыман, башын күтәреп карады, урындык аркасына элеп куелган кульяулыгын алды да битен, аеруча күз төпләрен сөрткәләде. Аңа шаулатып кул чаптылар. Мактау сүзләре дә ишетелде. Бераз вакыттан соң Дәүләтгәрәй абзый яңадан уйный башлады.

— Менә монысы мин малай чакта ишеткән көй,— диде ул.

---

* — Башланды!.. Татарның бөек галимнәре, имеш!

Уйнап туктагач, җиңүче төс белән яшьләргә күтәрелеп карады.

— Кем белә — нинди көй?— диде.

Бу көйне ул, гомумән, сирәк уйный иде, шуңа күрә аның нәрсә уйнаганын хәтта Йосыф та әйтә алмады. Йосыф исә күптән инде әтисенең барлык көйләрен отып алуны һәм аның кебек скрипкада өйрәнүне үзенең төп максаты итеп куйган иде. Габделхәй бары тыңларга гына ярата һәм бер генә көйне дә хәтерендә калдыра алмый иде. Күп белүче Былбыл белән Маймул Рамус та авызларына су капкандай тынып калдылар.

— «Көзге ачы җилләрдә» түгелме соң?— диде Фәрхәнә апа.— Яшьләр белмиләр андый җырларны.

— Нинди матур көй, җизнәй!— диде Былбыл, телгә килеп.

— Татар бригадасы көе. Кызыл әрмисләр марш атлап йөрерләрие шушы көйгә,— диде Фәрхәнә апа, аңлатып.

— Безнең әти дә сөйли аларны... татар бригадасын,— диде Былбыл.

Дәүләтгәрәй абзый скрипкасын Йосыфка тоттырды.

— Җәле, улым, син дә күрсәт өнәреңне,— диде.

Йосыф кыстатып тормады, бераз гына ашыгып-кабаланып үзе белгән «Ком бураны» белән «Әпипә»не уйнап алды.

Йосыф уйнаганда Фәрхәнә апа кече якка чыгып китте һәм, гадәтенчә, табак-савыт шалтыратырга тотынды. Аның артыннан Былбыл да иярде. Дәүләтгәрәй абзый шулай ук каядыр чыгып китте. Олы якта үзләре генә калгач, Маймул, чыраен сытып:

— Брось ты пиликать!— диде Йосыфка.— Терпеть не могу разные там «Әпипә». Давай что-нибудь повеселее.*

Музыка тавышы тынып, Василий Михайловичныкына охшаш ямьсез, шыгырдавык тавыш ишетелү белән Габделхәй айнып киткәндәй булды. Шундук ул үзенең янында гына иң явыз дошманы барлыгын исенә төшерде. Музыка тәэсире бетте, тынычлык югалды һәм кем дә булса хәзер искәрмәстән йөзенә китереп сугар, йә аркасына китереп кадар сыман тоелды.

## XIX

Рамусның киңәшенә колак салган сыман, Йосыф шундук скрипка шыңгырдатуыннан туктап калды. Маймул Рамус кабаланып этажерканың аскы бүлеменнән патефон

* — Шыңгырдатма әле шуны!.. Җенем сөйми «Әпипә»ләрне. Әйдәле берәр күңеллерәк нәрсә уйна.

тартып чыгарды, шапылдатып аны өстәлгә куйды да, тоткасыннан шыгыр-шыгыр әйләндерә-әйләндерә, көйләп җибәрде. Иске патефон гыжылдавык тавыш белән фокстрот көйли башлады. Бөтен өй эчен җанны урти торган чит-ят музыка һәм шалтыр-шолтыр тавыш тутырды.

— Давай танцевать!— диде Маймул, кече яктан килеп чыккан Былбыл каршысына килеп.

— Хәзер,— диде Былбыл һәм тиз-тиз генә өстәл өстен сөртеп алды да яңадан теге якка чыгып китте.

Рамус аны көтеп торды. Балкып Былбыл яңадан олы якка чыгып килгәндә, кыю гына кыланып, аның биленнән, кулыннан тотып алды. Шалтыр-шолтыр музыкага алар идән уртасыннан әйләнгәләп киттеләр.

Эшен ташлап Фәрхәнә апа килеп җитте һәм көлемсерәп биючеләргә карап тора башлады. Дездемона, бөтен өй эчендә үзен хуҗа санап, чыр-чу килеп, туктаусыз аяк астында буталды.

Фокстроттан соң алар вальс биеделәр. Вальс пластинкасын озаграк әйләндерделәр. Былбыл Йосыф белән дә биеде. Йосыфтан соң чират Габделхәйгә җитте. Көлепелмаеп Былбыл Габделхәй каршысына килеп туктады да, сул кулын күкрәк турысына куеп, уң кул очы белән күлмәк итәген тоткан килеш, киноларда күрсәтелә торган барышнялар сыман, чак-чак кына баш иде.

— Әйдәгез, мин сезне танцыга чакырам,— диде, тылсымлы итеп.

— Мин тансавайт итә белмим,— диде Габделхәй, караңгы чырай белән.

— Иһи!— диде Былбыл, күзләрен зур ачып, матур кашларын сикертеп.— Белмисез? Әйдәгез өйрәтәм — җиңел генә ул!

— Өйрәнәсем килми,— диде Габделхәй.

Үзенең шулай катгый рәвештә җавап бирә алуына, кемне сайласам да булдыра алам дип, чибәрлеге белән, масайган кыз алдында җебеп төшмәвенә Габделхәйнең күңеле күтәрелеп куйды.

— Оставьте его в покое — он стишки сочиняет*,— диде Маймул, сүзгә кысылып.

— Сез бер дә шагыйрьләрне яратмыйсыз икән,— диде Былбыл, Рамуска ачуланган булып.

— Терпеть не могу шәирләрне!** — диде Маймул оятсызланып, Габделхәйнең күзләренә карап.

Шагыйрь җегетнең йөзенә кинәт кан бәрде, күз алла-

---

* — Борчымагыз аны — ул шигырь яза.

** — Җенем сөйми шагыйрьләрне!

ры томаланып калды. Ул, исенә-акылына килеп, нәрсә булганын аңларга өлгергәнче, маймул Рамус Уфа кызының биленнән тотып алды. Борын төбендә генә җилләнеп алар китеп тә бардылар. Габделхәй, авыр, хәлсез аякларын өстерәп, ишеккә таба юнәлде.

Тышта әле бик үк караңгы түгел иде. Шулай да инде көн сүрелгән һәм кичке һавада тынлык һәм тынычлык урнашкан иде. Баскычта үзе генә Дәүләтгәрәй абзый утырып тора иде. Габделхәй әйтми-нитми кайтып китәргә һәм моннан соң беркайчан бу өйгә аяк басмаска дип чыккан иде. Ләкин баскычта Дәүләтгәрәй абзыйны күреп ул тагын икеләнеп калды. Аның яныннан үпкәләгән сыман кайтып китү килешмәс шикелле тоелды.

— Корыга китте бит әле, Габделхәй,— диде Дәүләтгәрәй абзый, күккә карап.— Яңгыр кирәк, яңгыр.

— Яңгыр?— диде Габделхәй, бик үк аңламыйча.

— Бәрәңгеләргә яңгыр кирәк. Печәнгә дә соң түгел,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Печәнгә төшкәннәр инде. Берәр чүмәлә әзерләп булырмы быел...

— Шулай шул,— диде Габделхәй.

Алар шулай печән турында гәпләштеләр дә тынып калдылар. Өйдән һаман гыжылдавык музыка тавышы ишетелде, урамнан тузан туздырып, тирә-якка әчкелтем төтен исе таратып, ниндидер машина узып китте. Шул чакны җилләнә-җилләнә Былбыл килеп чыкты.

— Их, нинди рәхәт монда!— диде ул һәм борылып өйдәгеләргә:

— Сез дә чыгыгыз!— диде.

Аның тавышын ишетеп, баскыч төбенә Йосыф белән Маймул да чыкты.

— Әйдәгез, патефонны монда чыгарабыз!— диде Былбыл.

Маймул белән Йосыф ашыгып, хәтта бер-берсен узышып, яңадан өйгә кереп киттеләр һәм патефонны күтәреп чыктылар да баскыч өстенә, киң тактага җайлап куйдылар. Уфа кызы белән Маймул баскыч алдында, җир өстендә тансавайт итмәкче булып карадылар, ләкин чирәм арасыннан таш, кирпеч кисәкләре күренеп торган тигезле-тигезсез урында парлашып бию уңайсыз булып чыкты. Танцы үзеннән-үзе тукталып калды. Патефонны кире өйгә кертеп куярга туры килде.

Ләкин беркемнең дә яңадан өйгә керәсе килмәде. Шул ук вакытта таралышырга да ашыкмадылар. Капка янында Йосыфның үзе ясаган турнигы бар иде. Спорт Йосыфның иң яраткан шөгыле иде. Кызлар белән дә, яшьтәшләре белән дә ул бары спорт турында гына җанланып, дәртләнеп сөйләшә ала иде. Кунакларны ул үзенең тур-

нигы янына алып килде һәм турникта беренче булып уйнап күрсәтте. Ашаганнан соң тәне шактый авыраюга да карамастан, күнегүләрне ул җиңел һәм оста башкарды. Йосыф дөпелдәп җиргә төшкәч, бердәнбер хөкемче Былбыл, мактау белдереп, кул чапты.

— Менә ул — спортсмен!— диде.

— Булмый... авыр...— дигән булды Йосыф тыйнак кына.

— Кем тагын, кем?— диде Былбыл, болай да котырырга гына торган малай-җегетләрне котыртып.

Аның сүзләренә беренче булып Рамус кузгалды. Атасының иске кителеннән бозып тегелгән ак пинжәген салып киртәгә элде, учына төкерде дә, җиңел генә ыргылып, шома тимерне эләктереп тә алды. Көн саен диярлек турник белән булашканга, күнегүләрне ул да ярыйсы ук оста башкарды. Былбыл аңа да мактау сүзләре әйтте. Рамус турниктан төшәргә ашыкмады — дәртләнеп, кызарынып тагын беркадәр атынды, чәчләрен полтыратып, туп-туры Былбыл каршысына сикереп төште.

— Оһо!— диде Былбыл.

Беркадәр тынлыктан соң ул янә Габделхәйгә борылып карады.

— Хәзер — Габделхәй!— диде Былбыл, ярым боеру тавышы белән.

Йосыфның да, Рамусның да бары Уфа кызы алдында шәп күренү өчен генә шулай кара тиргә батып азаплануларын Габделхәй бик яхшы белде һәм аларның һәр кыланышын яратмыйча күзәтеп торды. Кыланчык кыз үзенә эндәшкәч ул, бар ачуын бергә җыеп:

— Мин маймул түгел,— диде.

Кызның көләч, бәхетле йөзе шундук сүрелеп калды. Үпкәләп, хәтере калып ул матур иреннәрен күптерде һәм әдәпсез малайга арты белән борылды, Габделхәй күңеленнән тантана итте. «Шул кирәк сиңа! Икенче масаймассың»,— дип уйлады ул. Аның тагын да усалрак, тагын да тупасрак итеп әйтәсе, юри кызның ачуын китерәсе һәм, шул рәвешчә барысы өчен аннан да, башкалардан да үч аласы килде. «Шул кирәк сезгә! Шыт!»— дип кабатлады ул күңеленнән.

## XX

Габделхәйнең сүзләре Былбылның гына түгел, башкаларның да кытыгына тиде. Тынычрак, салмаграк Йосыф, Габделхәйнең холкын белгәнгә, ачуын тышка чыгармаска тырышты. Рамусның исә һич тә моны йотып җибәрергә исәбе юк иде, ахрысы. Ул үзен бар яктан да

Габделхәйдән шәбрәк, көчлерәк һәм бәхетлерәк дип исәпли иде. Үзенең шәплегенә, көченә таяна торган бәхетле кешеләргә генә хас бер кыюлык, тәвәккәллек белән ул ашыкмыйча гына Габделхәй янына килде.

— Әйдә, күрсәт батырлыгыңны — нәрсә катып торасың багана кебек!— диде.

Шулай диде дә бар көченә Габделхәйнең күкрәгенә төртеп җибәрде. Габделхәйнең әле беркайчан да Рамус белән күрәләтә бәрелешкәне дә, көч сынашканы да юк иде. Ул аны бары читтән генә, ерактан гына дошман күреп йөри иде. Турыдан-туры бәрелешергә Рамусның директор малае булуы да, артык оятсыз, былагай булуы да комачаулый иде бугай. Шуңа күрә ул Габделхәйгә чыннан да бар яктан да көчлерәк һәм өстенрәк булып тоела иде.

Хәзер менә аның искәрмәстән китереп төртүе булды, тәненә агач кулның килеп кагылуы булды Габделхәйдә кинәт тиле ярсу, көч-куәт барлыкка килде. Бу минутта ул үз дошманының директор малае булуын да, үзеннән көчлерәк, кыюрак, шәбрәк булуын да онытты һәм йодрыгын йомарлап бар көченә оятсыз кыяфәткә тондырды. Оятсыз кыяфәт мыйк! итеп калды, артка чөйлекте. Шулай да тиз арада исенә килде һәм Габделхәйнең үзенә дә берне китереп сылады.

— Ташлагыз! Нәрсә сез...— диде Йосыф, сугышучыларны аермакчы булып.

Ләкин ул арада ике әтәч чын-чынлап эләгешеп киттеләр. Рамус, Габделхәйне ике куллап тотып, күтәреп алды да баш аркылы ыргытмакчы булды. Тарткалаша торгач, ул аны шулай да аркасы белән җиргә екты һәм кулларын як-якка каерып, тезе белән күкрәгенә басмакчы булды. Габделхәй тимер кулны ярсып тешләп алды. Авыртуга түзә алмыйча Маймул чинап җибәрде. Габделхәй исә пружинадай сикереп йөзтүбән әйләнде дә сикереп аягына басты. Ике яшь әтәч, уттай янган күзләре белән бер-берсенә карашып торгандай иттеләр дә яңадан бер-берсенә ташландылар. Бу юлы инде беркемнең егыласы да килмәде, кулын тешләттерәсе дә килмәде. Сабан туе көрәшчеләре кебек алар бераз вакыт бер урында таптандылар һәм икесе дә берьюлы диярлек бер-берсенең кулларын тотып алдылар. Бу юлы да Рамус өлгерлек күрсәтте — ике куллап Габделхәйнең биленнән эләктереп алды һәм тагын да баш аркылы чөймәкче булып азаплана башлады. Бу аның иң яраткан алымы иде, ахрысы. Ләкин тагын күтәреп ташлый алмады. Алар тагын әүмәкләшеп җиргә егылдылар.

Монысында Рамус алданрак сикереп торды. Торды да аяклана алмаган Габделхәйне бар көченә капка ягына

төртеп җибәрде. Габделхәй арты белән капкага барып бәрелде. Ул бернинди авырту тоймады. Ләкин үзенең директор малаеннан хәлсезрәк, көчсезрәк икәнлеген аңлады. Бу минутта ул үзендә чиксез нәфрәт һәм дошманлык тойды. Аңа берничек тә җиңелергә ярамый иде. Аңа ничек тә җиңәргә, дошманын ничек тә сытарга, изәргә һәм барысы өчен бик каты үч алырга кирәк иде. Капкага бәрелгәч ул туп кебек кире ыргылды һәм читкә тайпылган Рамусның ике куллап башыннан тотып алды да бар көченә аны үзенә кыса башлады. Алар тагын җиргә егылдылар. Монысында Габделхәй өстә калды һәм исенә-акылына килергә өлгермәгән дошманын изәргә, сытарга тотынды.

Колак төбендә куркып, шомланып кычкырган тавышлар, кирәксез киңәшләр ишетелде. Кемдер Габделхәйнең күлмәген тотып алды. Габделхәй тоткан кулны ачу белән сугып җибәрде.

— Җибәр күлмәкне, җибәр!— дип ярсып кычкырды.

Аны тотып алучы Йосыф булып чыкты. Габделхәй күлмәк тартучыга борылган арада Рамус аягына басты. Аның өсте-башы, бите-күзе тузанга, яшел чирәмгә буялган, киемнәре әвәләнеп беткән, авыз читеннән исә шыбырдап кан ага иде. Учы белән ул авыз читен тотып карады да яңадан Габделхәйгә укталып куйды. Габделхәйне артына яшереп, Йосыф аның юлына аркылы төште.

— Булды!.. Сугыштыгыз, кыйнаштыгыз!..— диде нык итеп.

— Кил әйдә, кил. Тагын бирермен!— диде Габделхәй, гайрәтләнеп.

Сугышчылар, бер-берсеннән ике-өч адым читтә басып торган килеш, өс-башларын каккаладылар, канаган, күпкән, авырткан җирләрен тотып-тотып карадылар. Габделхәйнең канаган җире юк иде, бары тик авызына тузан кергән дә кул аркасы чыелган һәм... уң аягындагы ботинканың башы купкан иде. Ботинка башы, очлы кадакларын күрсәтеп, шүкә авызы сыман ыржаеп тора иде. Кадерләп кенә кигән ботинкасының шулай харап булуын күргәч, Габделхәйгә нәрсәдер бик-бик кызганыч булып тоелды. Күз ачып йомган арада ул уң аягындагы шул туфлиен салып кулына тотты да элеккедән дә ярсыбрак үзенең дошманына ташланды. Ләкин аны тагын Йосыф эләктереп алды.

— Җитте! Булды!— диде Йосыф, ачуланып.

— Нәрсә шуны яклыйсың?— диде Габделхәй, көдерәеп.— Сөяген он итәм мин аның! Масаймасын... директор малае булгач та!..

Якында гына Дәүләтгәрәй абзыйның тавышы ишетелеп китте.

— Ни булды, балалар, нишлисез?— диде ул, борчылып.

Габделхәй тирә-ягына күзен ачыбрак карады һәм өй эчендәгеләрнең барысының да аптырап үзләренә карап торуларын күреп алды.

— Үзе башлады. Әллә аннан кыйнатып торыргамы?!— диде ул, хуҗалар алдында акланган сыман.

— Ие, ие, Рамус үзе башлады!— диде Былбыл да.

Дәүләтгәрәй абзый белән Фәрхәнә апа башларын чайкадылар, шелтә сыман, үкенү сыман бер-ике сүз әйттеләр дә, яшьләр эшенә кысылуны кирәксез санап, авыр гына, күңелсез генә кире борылдылар. Алар артыннан Былбыл да иярде. Тиз арада ул өйдән комган белән җылы су алып чыкты. Иң элек Рамус янына килде һәм юыну өчен кулына җылы су салмакчы булды. Рамус ачу белән комганны сугып җибәрде. Сулы комган шапылдап җиргә барып төште. Рамус, беркемгә карамыйча, капкага юнәлде. Урам якта, капка артында аның Габделхәйгә карата әйтелгән янау сүзләре ишетелде:

— Я еще покажу тебе!*

---

* — Күрсәтермен әле мин сиңа күрмәгәнеңне!

## Өченче бүлек

Чыгарылыш кичәсендәге кебек үк, һәртөрле җыелышларда, очрашуларда, дәрес вакытында мәктәп директоры да, укытучылар да, гомумән, барлык акыллы кешеләр, бөтенесе беравыздан диярлек: сезнең киләчәгегез — алда, сезнең өчен барлык мөмкинлекләр тудырылган, сезнең өчен барлык юллар ачык дип әйтергә яратсалар да, мәктәптән тәмам киселеп, берничә көн мәктәпсез чын тормышта яшәп карагач та Габделхәй акыллы, белемле укытучыларның, өлкән кешеләрнең бик үк дөрес әйтмәгәнлекләренә төшенде. Мәктәптә чакта вәгъдә ителгән томанлы мөмкинлекләр белән тормыш хакыйкате арасындагы аерманың ни дәрәҗәдә зур һәм тирән булуын көннән-көн төшенә барган саен, каушау һәм аптырау тойгысы да көчәя барды.

Алдагы киң, якты дөньяга, бәхетле тормышка омтылган яшь күңелнең юлына аркылы төшүче иң беренче албасты — мохтаҗлык һәм хәерчелек булды. Үзеңнең киләчәктә кем булырга тиешлегеңне, кая китәргә ниятләвеңне ачыклау белән генә, инәңнең бирелмәгән рөхсәтен алып кына ярлылык-хәерчелек мәсьәләсен хәл итеп була торган түгел иде. Хәерчелек мәсьәләсен хәл итү өчен исә барыннан да элек акча дигән бик тә күңелсез бернәрсәне хәл итәргә кирәк иде.

Акча ул кайберәүләрдә капчыклап йөрде, тик менә аларда гына — Габделхәйләрдә генә — капчыклап та, янчыклап та булмады. Айның билгеле бер вакытында күренгәләп алды да тиз арада каядыр таралып юкка чыкты. Сугыш беткәнче алар әтәләре өчен беркадәр пособие алып тордылар. Ләкин сугыш бетеп ярты ел чамасы үтмәде, нишләптер анысы да туктап калды. Шәмсебанат апа дөреслек эзләп башта райсобеска барды. Райсобеста райвоенкоматка барырга куштылар. Военкоматтан Шәмсебанат апа кайгырып, карасына коелып кайтты. Бер атна чамасы рәтләп сөйләшмәде. Габделхәй төпченмәде.

Сугыш елларында үскән барлык малайлар кебек ул шактый иртә үз иркендә яши башлады. Дус малайлары белән бергәләп алар еракка — Бүә буена су керергә дә йөрделәр, карагат, җиләк-җимешкә дип йөрделәр. Алып кайткан җимешләрен, карагатларын базарда яки тимер юл буенда сатып, әзме-күпме акча эшләделәр. Исәя башлаган малай-шалай берзаман, олылардан күрмәкче, «эспикүлән» эшенә әвәсләнеп китте. Буш вакытлары булдымы, тимер юл буена баралар да поездлан төшкән пассажирлардан, каядыр ерак җирләргә китүче солдатлардан папирос, зажигалка, карандаш, дәфтәр ише вак-төяк

нәрсәләр сатып алалар. Аннары, бәясен бераз арттырып, шуларны базарда сатып йөриләр. Акчасы күбрәк кеше кием-салым, сәгать кебек эрерәк, затлырак әйберләр алып сата. Мондый товарның файдасы да күбрәк кала.

Габделхәй дә бераз вакыт шундый сату-алу белән йөрде, кайчагында Илгизне дә иякртте. Шулай итеп алар беркайчан инәләреннән акча сорамадылар. Киресенчә, еш кына үзләре алып кайттылар. Кайчагында, инәләре әйткәнне дә көтмәстән, үзләре тапкан акчага берәр бидерә бәрәңге, бер-ике кило он алып кайттылар.

Әйе, инәсенә ул һәрвакыт үзе ярдәм итте һәм беркайчан аннан бер тиен акча алмады. Хәзер дә алмас. Хәер, инәсенең бирер акчасы да юк — ул аны белә. Кыскасы, акчаны тагын үзеңә табарга туры киләчәк. Бары үзең генә! Ләкин ничек итеп?

Дөрес, аның күптән, бик күптән беркемгә әйтмичә тиенләп җыйган яшерен акчасы бар. Илле ике сум да кырык тиен чамасы. Искечә. Яңача ул алай ук түгел. Биш сум да егерме дүрт тиен генә. Бу бик аз. Илле ике сумны хәтта акча дип тә булмый. Яңавылдан Казанга кадәр билет бәясенә генә җитәчәк. Поездда беркем билет алып йөрми анысы. Каяндыр Урал, Себер якларыннан килгән байлар — зур корсаклы директорлар, начальниклар-фәләннәр генә ул йомшак вагоннарда билет белән йөриләр. Авыл халкы, Яңавыл халкы вагон араларында, вагон түбәләрендә йөри, товарный вагоннарга эләгеп китә. Казанга барып төшсәң, анда инде акча кайгысы бетәчәк. Шәһәр халкы көрәп акчасын ала, авыз тутырып ипи ашый. Барып төшкәч тә стипендия сорарга була. Бирмиләр икән, элекке көнлекчеләр кебек берәрсенә ишегалды себереп торучы булып эшкә ялланасың йә булмаса хәлсез корткаларның сумкаларын, чемоданнарын күтәрешәсең. Киноларда күрсәтәләр ич. Ничек тә тамак ялгарлык акча эшләргә булыр әле. Инде алай да булмый икән, Идел буена эш эзләп китәсең, баржа бушатасың. Горький кебек. Горький университетка акчасы булмаган өчен түгел, аттестаты булмаган өчен керә алмаган. Теге... Маймул шуны да белми.— Горький, имеш, Казан университетында укыган! Укыган, укымыйни!

«Туктале, нишләп мин Горький кебек баржадан утын, тоз бушатып йөрергә тиеш?»— диде ул бераздан, үз-үзенә каршы килеп. Аның бит беркайда бастырылмаган шигырьләре бар! Казанда ул югалмаячак. Барып кына җитсен, анда инде ничек тә акча табачак!

Ләкин, төптән уйлап караганда, шундый ерак юлга илле ике сум белән түгел, йөз дә илле ике сум, хәтта мең дә илле ике сум белән чыгу хәерлерәк булыр иде, әлбәттә.

Хезмәтче булып яллanулар, баржа бушатулар, шигырь бастырулар — алар барысы да һавадагы торна.

Акча кирәк, акча! Акча монда да кирәк, Казанда да кирәк булачак. Билет алу өчен генә түгел, тамак өчен генә түгел, яхшырак чалбар, пинжәк, яңарак туфли алу өчен дә кирәк булачак.

Авызы ачылган ботинкасын исенә төшергәч тә Габделхәйнең эче жу итеп китте. Теге көнне ул Йосыфлардан яланаяк кайтты. Икенче көнне ботинкасының купкан башын кире урынына беркетергә тырышып карады, ләкин берни барып чыкмады. Бөтенләй яланаяк калмас өчен ул түфлинең купкан өлешен киез итек ямаган кебек, тышкы яктан берничә кат кәтүк җебе белән тегеп, эләктереп куйды. Болай үзе киярргә ярый сыман, шулай да ямалган җире ямьсез булып күренеп тора. Дөрес, аның ямалган ботинкасын әлеге беркем дә күрмәде. Күрсәләр, нәрсә дип әйтергә дә, ничек итеп шуның белән урамга чыгарга, кеше күзенә күренергә? Аның бит әле Сәкинә белән очрашасы да бар!

Габделхәй шулай ямалган ботинкасы хакында, гомумән, акчасызлык, мохтаҗлык хакында уйланып-бетеренеп йөргәндә, көтмәгәндә аяк астыннан диярлек икенче төрле кайгы һәм борчу калкып чыкты.

## II

Улы Габделхәй белән булган сөйләшүдән соң Шәмсебанат апа бик озак тынычлана алмады. Илгизнең эшкә керәм дип канатланып йөрүе дә, Фидәилнең үзе ише малайлар белән Бүә буена җиләккә йөрүе дә, Габделхәйнең исә элеккегә караганда ягымлырак булуы да — берсе дә күңелен юата алмады. Ул һаман борчулы, боек йөрде. Агач корты кебек аның күңелен бертуктаусыз нидер талый, нидер кимерә иде кебек.

Балалар бакчасында татар группасын ябалар икән дигән сүз дә әлегә тынып торды. Бакчадагы кайберәүләрне бу сүз әле һаман агулап торса да, Шәмсебанат апа өчен хәтта бу да арткарак чигенде. Аңа хәзер бу ялгандыр, берәр төрле уйдырмадыр сыман тоела башлады.

Бу көннәрдә Шәмсебанат апа үзеннән бигрәк балалары, бигрәк тә Габделхәй өчен борчылды. Ул аның чын мәгънәсендә үсеп җиткәнлеген күрде, үз кулы астыннан чыга барганын күрде. Ул әле күңеле белән һаман аны үзе янында торгызмакчы булды, шул ук вакытта тотып торырга инде көченнән килмәгәнлеген дә аңламый булдыра алмады. Әгәр дә мәгәр аның Габделхәе кая да булса китеп барса, моннан соң инде беркайчан кире Яңавыл-

га, инәсе, энеләре янына әйләнеп кайтмас, кайта алмас — югалыр, юкка чыгар һәм шундый нык күнегелгән тормышның асты-өскә килер сыман тоелды.

Күңелсез сөйләшүдән соң бер-ике көн үткәч, Шәмсебанат апа улы белән яңадан сүз башлады.

Авыр язмышка дучар ителгән кеше кебек, бик кыенлык белән:

— Улым...— диде,— син анда... Казанга китәм дисең дә... синең бит паспортың юк. Нишләрсең икән?

Көндәлек тормышта адым саен диярлек һәртөрле язу, документ, белешмә кебек нәрсәләр таләп ителсә дә, бу мәсьәләдә Габделхәй әле бик тәҗрибәсез иде. Институтларга керү турындагы белдерүләрнең һәркайсында керүчедән нинди документлар соралуы ап-ачык итеп язылган иде. Ләкин, Габделхәй фикеренчә, югары уку йортына керү өчен аттестаттан башка, берничә шигырь дәфтәреннән һәм шагыйрь булырга көчле теләктән башка берни дә кирәкмидер шикеллерәк тоела иде. Аннан соң, берничә фәннән керү имтиханы тапшыру да аның өчен нишләптер мәҗбүри түгел сыман иде. Бит аның аттестатында барысы да «бишле!» Аңа алтын медаль бирергә тиешләр иде! Алтын медальлеләрне исә теләсә кайда имтихансыз алалар. Мәсьәләгә кайсы яктан килеп карасаң да, югары уку йортларына керү турындагы белдерүләрдә әйтелгән таләпләр аның өчен түгел, бәлки, бөтенләй башка кешеләр өчен язылган сымаграк аңлашыла иде. Шуңа да ул кирәкле документлар эзләү турында әлегә уйлап та карамады.

Инәсе паспорт хакында сүз чыгаргач, ул каушап калды. Аның өчен бик тә, бик тә четерекле мәсьәлә иде бу. Иң куркынычы шул — аның туу турындагы таныклыгы юк иде. Илгизнең, Фидәилнең, барлык классташларының туу турында таныклыклары бар, аныкы менә юк. Ул дөньяда бар да, юк та. Чынлыкта ул туган, үскән, кеше булган, ләкин Закон каршында ул — кеше түгел.

Мәктәпкә укырга кергәндә дә, күрәсең, аның таныклыгын сорап тормаганнар. Ул чакта, бәлки, тәртибе шундый булгандыр. Укыган чакта да беркем аннан таныклык сорамады, аның кирәклеге турында искә дә төшермәделәр. Укыймы? Укый. Әйдә, укысын, кеше булсын. Ул әнә укыды, унны бетерде, теләсә нинди кеше түгел — шагыйрь кеше булмакчы. Шагыйрь булу өчен туу турындагы таныклык таләп ителми, шигырь яза белү таләп ителә. Шулай булырга тиеш түгелмени? Үз-үзен юатып еш кына ул шулайрак фикер йөртте.

Былтыр яз көне Илгиз кебек үк укуын ташлап тимер юлга, вагоннар депосына эшкә керергәме әллә дип җенлә-

неп йөргәндә, беренче сүз итеп аннан туу турында таныклык һәм мәктәптән белешмә сорадылар. Аның кулында бер төрле язуы да юк иде. Кирәкле кәгазьләрнең юклыгы беленгәч, аның белән хәтта сөйләшеп тә тормадылар. Шуннан соң ул укуын ташлап эшкә керү турындагы уеннан бик тиз баш тартырга мәҗбүр булды. Бу хакта ул беркемгә дә сөйләп тормады. Шулай да бу беренче сабак аның күңелендә шактый тирән уелып калды.

Узган бер ел эчендә бу да онытылып өлгерде. Габделхәй үзенең туу турында таныклыгы булмаган кимчелекле кеше икәнлеген ничектер исеннән чыгарып ташлады. Менә хәзер аның исенә төшерделәр. Шундук аның күңелендә былтыргы каршылыклы уй-фикерләр калкып чыкты.

Инәсе әйткәнчә, Габделхәйнең әтәсе Котдус белән алар Казанда педагогия техникумында танышканнар, дөресрәге, алар анда бергә укыганнар. Габделхәйнең әтәсе Котдус кайдадыр Оренбург ягында туган, бик яшьли ятим калган, балалар йортында тәрбияләнгән. Шуңа күрә ул үзенең нәсел-нәсәбен, атасын-анасын рәтләп белмәгән дә. Соңгы курста укыганда алар өйләнешеп бергә тора башлаганнар. Укуларын тәмамлагач, аларны Татарстанның иң ерактагы төбәкләрнең берсенә — Агыйдел буендагы Бурсык дигән авылга укытучы итеп җибәргәннәр. Габделхәй менә шунда Бурсыкта туган.

Бу еллар дөньяның бик тә буталчык чагы булган. Көтмәгәндә авылдагы кемнәр беләндер яшь укытучылар арасында каршылык килеп чыккан. Тормыш шартлары да шәптән булмаган. Бер-ике ел эшләгәннәр дә болар, Яңавылга — инәсенең туган якларына кайтып киткәннәр. Иң элек Янтыкка кайтып төшкәннәр. Укытучы кеше, культуралы кеше буларак, яшь ата белән ана кечкенә Габделхәйне «әти», «әни» дип сөйләшергә өйрәткәннәр. Ләкин авыл балалары көлгәнлектән, Габделхәй тиз арада «әткәй-инәкәй»гә күчкән. Боларын Габделхәй үзе дә хәтерли. Ләкин аның биографиясендә ул үзе белми, хәтерләми торган нәрсәләр дә җитәрлек.

Инәсе әйткәнчә, Габделхәйнең туу турындагы таныклыгын алар — әти белән әни кеше — «Йосыф-Зөләйха» китабы эчендә саклап тотканнар. Әтисе дә, әнисе дә искечә яхшы белгәннәр һәм кайчагында элекке китапларны карап-укып утыра торган булганнар. «Йосыф-Зөләйха», «Бүз йекет», «Кисекбаш» исә Котдус әтинең иң кадерләп саклый торган китаплары булган. Анда-монда күченеп йөргәндә «Йосыф-Зөләйха» да, аның эченә кыстырылган таныклык та, күз тиюдән саклый торган догалыклар да һәм шулай ук Габделхәйнең кургаш кәгазьгә төрелгән

беренче чәче дә юкка чыккан. «Йосыф-Зөләйха» катыргысы эчендә «Буз йекет» белән «Кисекбаш» та булган.

Әлеге китапларны Шәмсебанат апа берзаман Таифә исемле бер укытучы кызга биреп торган икән. Таифә, надан булса да, җылан кебек астыртын һәм кара эчле булып чыккан. Китапларны ул бер айдан китерермен дип алып киткән, ләкин китермәгән. Бер айдан китап хуҗасы Котдус Мөхетдиновны авыл советына чакыртып сорау ала башлаганнар. Совет балаларына син шулай «Йосыф» китабы укытасыңмыни, яшь буынны дин сөреме белән агулыйсыңмыни? Фәлән-төгән... берсе дә калмаган.

Котдус Мөхетдиновның моңа бик нык кәефе кырылган, борчылган, йокыдан, тамактан калган. Уйлашканнар-киңәшкәннәр дә болар, көннәрдән бер көнне кайтканнар да киткәннәр. Ярый әле тоткарлаучы булмаган. Илгиз Янтыкта туган. Янтыкта бер кыш торгач Яңавылга күченгәннәр.

Котдус Мөхетдиновны Яңавылда кулга алалар. Таң алдыннан татлы йокы вакытында киләләр дә каядыр алып китәләр. Чит кешеләрнең тупас тавышлары, инәсенең йөрәк өзгеч итеп, куркыныч итеп кычкырып җибәрүе, шапылдап ишек-капка ябылуы — барысы да Габделхәйнең исендә, йөрәк түрендә. Ләкин барысы да... төштәге кебек кенә.

Котдус Мөхетдинов халык дошманы булган икән дип, сәвиткә каршы яшерен армия туплауда катнашкан икән, солтангалиевчеләр белән бер шайкада торган икән дип, тагын әллә нәрсәләр дип ул вакытларда бөтен Яңавыл шаулап торды. Шулай да озак шауламадылар — Котдус Мөхетдиновтан соң тагын бер халык дошманын, аннан соң икенче, өченче халык дошманнарын фаш иттеләр. Шулай итеп, әкренләп аны бөтенләй диярлек онытып бетерделәр.

Ул елларда Шәмсебанат апа гел кайгылы йөз белән йөрде. Габделхәйгә ул «әтиеңне Кызыл Армиягә алдылар» дип ышандырырга тырышты. Габделхәй ышанса да ышанды, ышанмаса да ышанды. Ул бары әтисенең каядыр китеп баруын гына, үзенең әтисез икәнлеген генә белде. Шушы хәлдән соң алар Яңавылда озак тора алмадылар, барлы-юклы төенчекләрен төйнәделәр дә яңадан әнисенең туган якларына — Янтыкка кайттылар да киттеләр.

Сугышның икенче елында бөтенләй көтмәгәндә-уйламаганда, солдат киемнәре киеп, яраланып Янтыкка Котдус Мөхетдинов кайтып төште. Ул вакыттагы бәхетшатлыкны, ул вакыттагы куанычны Габделхәй мәңге хәтерендә калдырды. Дөрес, монысы да төштәге кебек кенә булды. Шулай да монысы, өнгә якынрак иде. Теге вакытта аның әтисен чыннан да кулга алганнар, атарга

хөкем иткәннәр, ләкин үлем җәзасын унбиш ел төрмә һәм гомерлек сөрген белән алыштырганнар. Сазлы, урманлы җирләрдә күпмедер эшләгәч, боларны Чиләбе ягына китереп аударганнар. Шунда Чиләбе трактор заводын төзегәндә сакчылардан бер татар кешесе белән танышып, дуслашып киткән. Сугыш башлангач, Котдус Мөхетдинов, сугышка җибәрүләрен үтенеп, Мәскәүгә, иптәш Сталинның үзенә хат язган. Илгә, партиягә турылыклы булуымны үлемем белән исбат итәсем килә, дигән. Котдус Мөхетдиновның хаты, күрәсең, тиешле җиргә барып җиткән — моны армиягә алганнар, сугышка җибәргәннәр. Сугышта бу бик зур батырлык күрсәткән, яраланган. Аның белән бер ротада сугышкан, бергә ут эченә кергән һәм шундый ук батырлыклар күрсәткән бик күпләргә орден-медальләр биргәннәр, командирларына «герой» бирелгән, Котдус Мөхетдиновны исә... бер айга ялга җибәргәннәр.

Бер айдан ул китте, хатлар язып торды. Бер елдан соң хаты килми башлады. Күп тә үтмәде, көтмәгәндә Котдус Мөхетдиновның батырларча һәлак булуы турында язу килде.

Габделхәйнең туу турындагы таныклыгын сорап Шәмсебанат апа башта Бурсыкка, аннары Казанга язып карады. Бурсыктан да, Казаннан да рәтле җавап килмәде. Бу турыда Габделхәй соңыннан, үсә төшкәч белде. Әгәр шул таныклык мәсьәләсе юлына аркылы төшсә, нишләргә? Бит аңа болай да паспорт алу вакыты җиткән. Паспорты булмаса, кая барыр, кайда укыр яисә нинди эшкә керә алыр икән соң ул? Инәсе әйткәнчә, әллә тагын Янтыкка күченеп китәргәме? Бөтенләйгә шунда төпләнеп калыргамы? Бит авылда берниндн таныклык та кирәкми, паспорт та кирәкми. Күрәгең генә нык булсын — б... табылыр!

## III

— Дәүләтгәрәй абыең белән сөйләшеп карарга кирәк, улым,— диде Шәмсебанат апа, улының уйларын сизенеп.— Булышса ул гына булыша алыр сиңа.

Инәсенең сүзләре Габделхәйгә бик дөрес булып тоелды. Әйе, мондый чакта аңа ярдәм кулы сузардай ике генә кеше бар — Дәүләтгәрәй абзый белән Фәрхәнә апа гына. Ләкин аларны искә төшерү белән, аларда булган теге ямьсез күренешләр күз алдына килде. Шундук аның йөзе үзгәрде, йодрыклары йомарланды. Үзенең эчке кичерешләрен инәсенә күрсәтмәс өчен ул тиз арада тышка чыгып китте.

Озак кына уйланып, икеләнеп йөргәннән соң, ул шулай да Фәрхәнә апаларга барырга кирәк дигән фикергә килде.

Сугышса әллә, ул бит Йосыф белән сугышмаган. Аннан соң Маймул үзе башлады. Барысы да күреп тордылар ич.

Габделхәй Йосыфларга килеп кергәндә Дәүләтгәрәй абзый инде эштән кайткан иде. Фәрхәнә апа белән Былбыл икәүләшеп бакчада кыярларга су сибеп йөриләр иде. Йосыф өйдә юк иде, ахрысы.

Габделхәйне барысы да дусларча елмаеп, ачык йөз белән каршы алдылар. Аларның бу ягымлыгында Габделхәй үзен инде күптән гафу итүләрен, хәтта, ихтимал, Рамус белән булган ызгышуны онытуларын аңлап алды.

— Килдеңме, югалган мал?— диде Дәүләтгәрәй абзый, күңелле генә көлемсерәп.

— Мактап кына йөрисең икән әле,— диде Фәрхәнә апа.— Әйдә, юын, ашарга утырырсың.

Бу сөйләшү барысы да өйгә кергәч булды.

— Мин әле генә ашап килдем,— диде Габделхәй, ялганлап.

Йөгергәләп аның янына Дездемона килеп җитте.

— Югалган мал!— диде ул, абыйсының кулларына асылынып.

— Карале, чибәрттәй, бу Диздекәйне!— диде Былбыл көлеп, ниндидер бик кызык нәрсә әйтмәкче булып.

— Йосыф кая?— дигән булды Габделхәй болай гына, ни дә булса әйтергә кирәк булган өчен генә.

— Йосыфны очратмадыңмыни?— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Әле генә мин аны Сәлимнәргә җибәрдем, җылымнарын белешергә. Шунда сезгә дә кереп чыгарга куштым.

— Иртәгә ял көне. Балыкка барабыз, балыкка!— диде Былбыл.

— Син дә барасыңмыни балыкка?— диде Диздекәй Былбыл апасына.— Җылан тарту авыр бит ул.

— Нәрсә, нәрсә?— диде Былбыл, аңламыйча.— Нинди җылан?

— Җылан шул, ник җылан булмасын!— диде Дездемона.

— Җылан түгел, җылым,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Аптыратма кешене, кызым.

— Ул кеше түгел, ул безнең улыбыз,— диде Дездемона, Габделхәй абыйсына сырпаланып. Аннан көләргә тотындылар.

— Кит, аптыратма абыеңны,— диде Фәрхәнә апа да иркә кызын куган булып.

— Абый түгел, ул безнең улыбыз!— диде Дездемона.

— Уф, үләрсең синең белән!— диде Былбыл, көлә-көлә.

— Үлмә әле, үләргә иртәрәк,— диде телмәт кызый, остарып.

— Без инде сезгә дә әйтербез дигәниек,— диде Дәүләтгәрәй абзый Габделхәйгә.— Райфодан үзебезнең атны алабыз. Көне буена. Рәхәтләнеп бер ял итәрбез дидек. Инәңә дә, Илгиз белән Фидәилгә дә әйтербез дидек. Андый-мондый эше юктыр ич инәңнең?

— Юк,— диде Габделхәй.

— Барабыз алайса?— диде Былбыл Габделхәйгә.— Жизнәй әйтә, ул якта карагат, җиләк күп була икән. Габделхәй белә аны ди. Карагат җыярга бидерә алып барабыз.

Габделхәй үзенең Буә буендагы карагат-җиләкне яхшы белүен-белмәвен бик үк белми иде, ләкин бу турыда Былбыл әйткәч, аңа ул чыннан да шундый белеме булган кеше-сыман тоелды. Былбыл аңа бүген беренче мәртәбә күргәндәгегә караганда да матуррак һәм ягымлырак булып күренде. Былбыл исә, гадәтенчә, олы як белән кече як арасында ары-бире йөреп, әле өстәлгә тәлинкәләр китереп куйды, әле кашык-фәлән алып чыкты, яисә узышлый гына тәрәзә челтәрләрен төзәткәләп алды. Габделхәй яныннан узганда аның ягыннан җиңел, татлы ис таралып калды. Үзен яңадан бәхетле итеп тоя башлаган яшь җегет дөньясын онытып аның һәр хәрәкәтен күзәтеп утырды.

## IV

— Ничек соң имтиханнарга әзерләнә башладыңмы әле, Габделхәй?— диде Дәүләтгәрәй абзый, аны татлы хыялларыннан бүлдереп.

— Минем әле...— диде Габделхәй, ни әйтергә дә белмичә.

— Бер ниятләгәч тотынырга кирәк,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Безнең Йосыф физика белән алгебраны өр-яңадан кабатлап чыкты,— диде Фәрхәнә апа.

Аның шулай Йосыф белән мактануы Габделхәйгә ошап җитмәде. Үзенең Йосыфтан һәм аның җан дустыннан башлырак, белемлерәк икәнлеген күрсәтү өчен ул, бик гадәти нәрсә турында сөйләнгән сыман, җиңел генә әйтеп куйды:

— Нәрсәсен кабатлыйсың инде аның?— диде.— Әле генә имтихан тапшырдык, барысы да истә. Имтиханнардан курыкмыйм мин.

— Җәй көне укыйсы да килми инде ул,— диде Былбыл да аның сүзләрен куәтләп.— Мин дә университетка керер алдыннан кабатлап тормадым.

— Имтиханга әзерләнү генә им түгел,— диде Дәүләт-

гәрәй абзый.— Хәзердән үк аяк киенә башлау зыян итмәс, Габделхәй. Фотога төшәргә, справкалар алырга... юлга чыкканда аларның барысы да кирәк була. Иң кирәге — акча.

Акча сүзе чыккач та Габделхәйгә уңайсыз булып китте. Әйтерсең, «акча» кычкырып әйтергә, бигрәк тә кызлар алдында әйтергә ярамый торган ниндидер оятлы нәрсә иде.

— Минем туу турында таныклык юк бит әле, Дәүләтгәрәй абый,— диде ул, үзенең акчадан да күңелсезрәк нәрсәсен исенә төшереп.

Таныклык турында ишеткәч, Дәүләтгәрәй абзый да, Фәрхәнә апа да шикле рәвештә тынып калдылар һәм берберсенә карашып алдылар.

— Загска барып карадыңмы соң?— диде Дәүләтгәрәй абзый, озак кына эндәшми торганнан соң.

— Юк шул әле,— диде Габделхәй.— Мин әле шул турыда киңәшергә дип килгәнием. Инәкәй дә шулай диде. Булмаган таныклыкны каян алыйм инде мин аны?

— Шулай,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Нишләрсең икән соң?— диде Фәрхәнә апа Габделхәйгә түгел, Дәүләтгәрәй абзыйга эндәшеп.— Үзең барып карамый булмас шул, иеме?

— Шулай,— диде Дәүләтгәрәй абзый, тагын да ничектер аңлаешсыз итеп.— Ярар, ул турыда артык борчылма син, Габделхәй,— диде ул аннары билгеле бер карарга килеп.— Үзем барып карармын тиешле җиргә. Адәм булгач әрәм булмассың, Алла боерса. Сиңа бит иң кирәге — паспорт.

— Шулай инде,— диде Габделхәй.

— Ярар, берәр атнадан әйләндереп чыгарырбыз без аны,— диде Дәүләтгәрәй абзый, ышанычлы итеп.

— Безнең җизнәй тотынса, булдырмый калмый инде ул,— диде Былбыл.

Габделхәй җиңел сулап куйды — аның кинәт өстеннән авыр йөк төшкәндәй булды. Дәүләтгәрәй абзыйның әйткән сүзен үтәячәгенә ул әз генә дә шикләнмәде. Аның төп йомышы, нигездә, башкарылды дип исәпләргә була иде, аңа инде саубуллашып кайтып киткәндә дә начар булмас иде. Бит бүген ул Сәкинә белән очрашырга тиеш! Шулай да ул нишләптер ашыкмады. Аның һич тә моннан, бу якын, ягымлы кешеләр яныннан кузгалып чыгып китәсе килмәде. Сүзеңдә тормау бик үк яхшы түгел иде, әлбәттә, хәтта начар, бик начар иде. Һич югы, шуның өчен генә булса да ул моннан чыгып китәргә тиеш иде. Ләкин ул менә утырды да утырды.

— Безнең Илгиз монтер булам дип котырып йөри бит әле,— диде ул, бер дә юктан энесен исенә төшереп.

— Алай икән,— диде Дәүләтгәрәй абзый. Бераздан Габделхәйнең балалар бакчасындагы татар группасын ябарга итүләре турында сүз башлыйсы килеп китте, ләкин башламады, тыелып калды. Аның өчен бу берни белән чагыштырып булмый торган зур һәм куркыныч, җаваплы нәрсә иде. Акча турында кычкырып сөйләшергә ярамаган кебек, бу турыда да кычкырып, башкаларга ишеттереп сөйләргә ярамый сыман иде. Аның үзе өчен генә түгел, бүтәннәр өчен дә бу шулай сыман иде. Чөнки, аның аңлавынча, бу милләтчелек булачак иде.

— Җылдан-җыл инәкәй дә олыгая,— диде ул, инәсе турындагы фикерен икенче якка юнәлтеп.— Фидәил дә борчый. Кичәгенәк суга батканда чак калган. Яңгыр телибез дип малайлар белән су сибешкәннәр, бер-берсен җылгага төртеп төшергәннәр. Кемдер арттан килгән дә моны да капландырган суга. Батып үлгәндә чак калган. Кайтып кергән берзаман җылый-җылый. Өстеннән шыбырдап су ага, үзе пычранып беткән. Сүзен дә рәтләп сөйли алмый — очкылык тота. Инәкәй тиргәргә тотынды. Ул кайгырмый кем кайгырсын безнең өчен?

Алар олы якта, өстәл янында сөйләштеләр. Ашагачэчкәч, табак-савыт юу тәмам булгач, Фәрхәнә апа белән Былбыл аш өстәленең бер башына тегү машинасы җайлап куйдылар да нидер тегәргә тотындылар. Былбыл үзенең чемоданыннан мода журналы алып килде, журнални каршына ачып куйды да тиз-тиз кыланып һәм әледәнәле көлештереп, иңбашларын сикерткәләп, машинаның шүресен, энәсен тикшереп карады. Фәрхәнә апага ниндидер киңәшләр бирде, ничек кисү, ничек тегү турында үз белгәннәрен сөйләде.

Габделхәй, болай гына караштырып утырган китабыннан аерылып, тегүчеләр ягына карап-карап алды, аларның сүзләренә, хәрәкәтләренә игътибар итте. Ул караганда нишләптер Былбыл да аның ягына карады. Бик кыска вакыт эчендә аларның күз карашлары очрашып алды. Габделхәй шундук күзен читкә борды, китабына иелде, укыгандай итеп утырды да монда бары Йосыфны гына көтеп торган сыман, Йосыфка әйтәсе бик кирәкле сүзе бар сыман, үзалдына сөйләнгәләп, «Йосыф та озаклады» дигән булды.

Шулай корыны бушка әйләндереп утыра торгач, кирәгеннән артык кыюланып:

— Тегү эше бик кызыктыр ул?— дип куйды.

Ул моны Былбылга әйтте. Шәһәрдә тегү-чигү түгәрәгенә йөргән һәм хәзер менә бөтен осталыгын җигеп, җан

тирләре белән тырышып, ниндидер шәп күлмәк тегәргә азапланып утырган кызның күңеленә мондый сорау сары май булып ятты. Ул шундук башын калкытты һәм эчкерсез бер елмаю белән елмаеп, җылы нур балкыткан тылсымлы күз карашын Габделхәйгә төбәп:

— Сезнең тегәргә өйрәнәсегез киләме?— диде.

— Безнең Йосыф бер дә аптырап тормый — үзенең җыртыгын-тишеген үзе ямый да куя,— диде Фәрхәнә апа.

— Мин дә үзем,— диде Габделхәй, беркадәр мактану белән. Ләкин шул чакны ул үзенең ямаулы ботинкасын күз алдына китерде, кызарынды һәм акланган сыман: — Минем машина белән теккәнем юк,— диде.

— Теләсәгез, өйрәтәм!— диде Былбыл.

Сүзнең бу якка китү мөмкинлеген уйламаган Габделхәй аптырабрак калды.

— Шулай да... тегү хатын-кыз эше инде ул,— диде.

Күрәсең, Былбыл да мондый җавап көтмәгән иде.

— Нишләп хатын-кыз эше генә булсын?!— диде ул, үз һөнәрен якларга әзер булып.

— Күбрәк хатын-кыз тегә,— диде Габделхәй.

— Юк, ирләр дә тегә!— диде Былбыл.

— Элегрәк тегүчеләр авылдан авылга йөреп тегәләрие,— диде Фәрхәнә апа.— Барысы да Казан ягыннан, барысы да ирләрне.

— Менә, күрдегезме?!— диде Былбыл, җиңүче төс белән.

— Мин дә хәтерлим андый тегүчеләрне,— диде Габделхәй.

— Менә, күрдегезме?!— диде тагын да Былбыл.— Җегет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.

— Элек кенә шулай булган ул,— диде Габделхәй, остарып.— Элекке кешенең бөтен һөнәре шул җитмештән артмагандыр инде. Хәзерге заманга туры килми ул мәкаль.

Былбыл мондый фикер белән килешмәде. Фәрхәнә апа да килешмәде. Былбыл әйтте, сез халык иҗатын ялгыш аңлыйсыз икән, диде, мәкальдә һич тә төп-төгәл җитмеш төрле һөнәр турында сүз бармый, ул бары рифма өчен генә әйтелгән, диде. Халык иҗатына хас нәрсә бу диде. Фәрхәнә апа андый ук тирән фәлсәфәгә кереп тормады — дәрестә сөйли торган сүзләрне ул өйдә сөйләргә яратмый иде. Ул бары Габделхәйнең элекке кешеләрне аз һөнәрле итеп күз алдына китерүенә генә каршы килде. Элекке кешенең дә һөнәре күп булган, диде. Шуны исбатлау өчен шундук мисал да китерде. Безнең әтәйне авылда иң оста Шәйми дип йөртәләрие, диде. Шәйми картның кулыннан килмәгән эше югые, диде. Мич тә чыгара, тактадан кисмәк тә ясый,

өстәл-урындык та ясый, итек тә баса, өй бурауны инде әйтеп тә торган юк. Мал-туар карау, сугым сую, йорт-җир, бакча эшләрен — барысын да элекке кеше үзе башкарган, диде.

— Мәрхүм әтәй бер генә эшкә өйрәнә алмады,— диде Фәрхәнә апа, сүзен тәмамлап.— Ул да булса — тегү эшенә...

— Менә, күрдегезме?!— диде Габделхәй, Былбылның үзе кебек.

— Тегү машинасы алырга хәленнән килмәде,— диде Фәрхәнә апа.— Үскәндә без сигез бала үстек. Бераз акчасы булдымы, безгә... балаларга кием-салым алырые, чәен-шикәрен алырые. Җыл да тегүче кертә торганыек. Тегүче бит бушка текми. Әтәй әйтә торганые: ичмасам, шушы тегү эшенә дә өйрәнә алмадым — тегүчегә бирәсе акчага ике кызыма билле тун тегәргә булырые, ди торганые.

— Аның өчен тегү — җитмеш беренче һөнәр булгандыр алайса,— диде Былбыл, көлеп.

— Аның өчен җитмеш беренче һөнәр — акча табу булган,— диде Дәүләтгәрәй абзый, үзенчә нәтиҗә ясап.

— Финансист кеше шулай бөтен нәрсәне акчага кайтара да калдыра инде ул,— диде Фәрхәнә апа.

— Безнең жизнәй — иң акыллы финансист!— диде Былбыл, җизнәсен мактап.

— Акыллысын акыллы да соң...— диде Фәрхәнә апа, нидер әйтмәкче булып.

— Бөтен нәрсәнең тоткасы — акча,— диде акыллы финансист, нәтиҗә ясап.

## V

Дәүләтгәрәй абзыйның бөтен нәрсәне акчага кайтарып калдыруы Габделхәйгә бик үк ошамады. Акчаның кирәклеге болай да билгеле иде, ләкин дөньяда акча белән тигезләп булмый торган, акчага сатылмый торган нәрсәләр дә бар. Бу хакта Габделхәй инде күп укыды, күп ишетте. Дәүләтгәрәй абзый райфо кешесе, бухгалтер кеше, карт кеше. Бәлки, чынлап та ул бар нәрсәгә акча күзлегеннән карыйдыр. Ләкин менә Былбылның — аңы һәртөрле искелек калдыклары белән бозылмаган алдынгы карашлы кызның — җизнәсе ягына авышуы, аны яклавы Габделхәйгә шактый гаҗәп тоелды.

Дәүләтәгрәй абзый исә үзенең иң кирәкле сүзен әйтте дә ашыкмыйча гына тышка чыгып китте. Габделхәй тын гына утыруында булды. Ул арада Фәрхәнә апа яңадан үзенең бала вакытлары турында сөйли башлады. Ул әтәсе Шәйми карт үлгәч сигез бала өелешеп калулары турын-

да, үзенең ат җигәргә өйрәнүе, ирләр белән бергә атлы эшләргә йөри башлавы, Сәет абыйсының шәһәргә укырга китүе турында сөйләде.

Габделхәй инде кайчандыр бу турыда ишеткән иде. Беренче мәртәбә ишеткәндә Фәрхәнә апаның үзе турындагы һәрбер сүзе аңа яңалык булып тоелган иде. Хәзер исә Фәрхәнә апаның бу сүзләре аңа бөтенләй диярлек тәэсир итмәде. Картларның, өлкән кешеләрнең элекке заман турындагы сүзләренә карата аның карашы әле шактый буталчык һәм каршылыклы иде. Ул яшәгән кыска гына гомер эчендә туктаусыз аның аңына: сезнең ата-бабаларыгыз авыр һәм караңгы заманда яшәгәннәр, укый-яза белмәгәннәр, көнетөне байларга бил бөккәннәр дигән фикер сеңдерелде. Мәктәптә шулай диделәр, китапларда, гәзит-журналларда — һәркайда шундый караш үткәрелде. Ләкин шул үткән заманның җанлы шәһите булган өлкәннәр, картлар моның киресен сөйләделәр. Еш кына ул картлар, өлкәннәр сүзенә ышанды, ләкин алардан аерылып яңадан дәреслекләр, гәзит-журналлар белән очраштымы, үткән заман аңа тоташ караңгылык патшасы булып, шул патшалыкта яшәгән барлык кешеләр сукырлар, наданнар, аңгыралар, гомумән, коллар һәм хаерчеләр өере булып тоелды.

Бервакытны алтынчыда укыганда, ахрысы, тарих дәресендә ислам диненең барлыкка килүе дигән теманы үткәч, ул инәсе белән дин турында, Алла турында бәхәс куертып җибәрде. Кайчандыр Казанда укыган һәм әле дә яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләвен дәвам иттергән инәсе, буш вакыты булдымы, искечә китаплар укый, үзалдына бисмилла әйтә, амин тота һәм кайчагында белгән догаларын кабатлый иде. Пионер Габделхәй инәсенең мондый икейөзлелегенә күптән инде эче пошып, оялып-хурланып йөри иде. Диннең ничек башланып китүе турында сүз куерткач, инәсенә ул барысын да әйтеп бирде. Иң яманы шул: «Әткәйнең кулга алынуына син гаепле булгансыңдыр әле!» — диде ул аңа. Инәсе шаккатты. Шуннан соң җыларга тотынды. «Куенымда җылан үстергәнмен икән!» — диде ул, ачынып. «Нишләп мине гаеплисең, улым?» — диде. «Синең иске китапларың өчен алып киткәннәр ич аны», — диде Габделхәй. Ул инде бу турыда Янтык картыйсыннан, картәтәсеннән сорашып белешкән иде. «Йосыф-Зөләйха»ны әйтәсеңме?» — диде инәсе. «Шуны», — диде Габделхәй. «Ул бит дин китабы түгел, борынгылар турындагы китап», — диде инәсе.

Ул чакта алар арасында шундыйрак сөйләшү булды. Соңыннан Габделхәй үзе дә тупаслыгы, аңсызлыгы өчен бик нык үкенде, кайгырды. Фәрхәнә апа элеккеләрне

сөйли башлагач, аның күңелендә яңадан менә шул чактагы нәрсәләр яңарды. Габделхәйнең элеккеләр белән артык кызыксынмавын күреп, Фәрхәнә апа да сүзеннән туктап калды.

Бераздан Габделхәй тагын Йосыфны искә төшерде, кайтмыйммы дигән сыман, тәрәзәгә барып урам якны карап килде. Аңа монда, әлбәттә, күңелле иде. Ләкин аны монда күңеллелектән башка әле икенче бернәрсә дә тоткарлап тора иде. Монда озаклап утыруының төп сәбәбе чынлыкта... Рамус иде бугай. Теге көннән соң ул монда килгәнме-юкмы, иртәгә балыкка барачакмы-юкмы — Габделхәйне хәзер барыннан да бигрәк менә шул нәрсә кызыксындыра иде бугай. Әгәр иртәгә ул да килсә һәм Йосыф белән бергәләп балыкка барырга тиеш булса, Габделхәйгә монда сөйләнгәләп утыруның кирәге дә юк иде.

Күңеленнән ул шулайрак дип уйлады, ләкин бу хакта сүз башларга ничектер кыюлыгы җитмәде. Тегү машинасы туктап торган арада, өй эчендә шылт иткән тавыш ишетелмәде. Бары тик тәрәзә челтәре белән пыяла арасына кереп калган зур чебеннең бәргәләнеп безелдәве һәм тышта, бакча ягында, Дәүләтгәрәй абзыйның шыгырт-шыгырт китереп коедан су алганы ишетелде.

— Ярый, сау булыгыз,— диде Габделхәй, ниһаять, китәргә җыенып.

— Нишләп? Китәсең дәмени әле?— диде Фәрхәнә апа.— Йосыф кайтып җитәр инде.

— Иртәгә кайчан кузгалырга исәп, Фәрхәнә апа?— диде Габделхәй.

— Сез чынлап та киләсезме соң?— диде Былбыл, эшеннән аерылып.

— Киләм!— диде Габделхәй ашыгып һәм үзе дә сизмәстән, кычкырып: — Рамус киләме?— диде.— Ул булса, килмим.

— Юк, юк, ул килми,— диде Былбыл, никтер көлеп.

— Бу арада Рамусның күренгәне юк әле,— диде Фәрхәнә апа, яшьләрнең сөйләшүендә бернинди катнашы юк кеше сыман.

Габделхәй, күңеле күтәрелеп, ишеккә юнәлде. Капкадан чыгып бераз киткәч тә, ул Йосыф белән очрашты.

— Ә, исәнме, Йосыф! Сау бул, Йосыф,— диде ул, шаяртып.

— Киттеңмени? Әйдәле керәбез,— беләгеннән тотып алып.

Габделхәй берсүзсез аның артыннан иярде.

— Мин киного билет алдым,— диде Йосыф, өйгә кергәч.

— Ничә билет?— диде Былбыл.

— Өч билет. Ярты сәгать вакыт калды. Әйдәгез тизрәк,— диде Йосыф.

— И-и, ник дүртне алмадың — чибәрттәй дә барган булырые,— диде Былбыл.

— Үзегез генә барыгыз,— диде Фәрхәнә апа.

— Әле дә соң түгел — тагын берне табарга була,— диде Йосыф.— Әйдә, барсаң, киен, әни.

— Бармам мин,— диде Фәрхәнә апа.— Сәлимне күрдеңме? Шәмсебанат апаң нәрсә ди? Барамы?

— Сәлим өйдә юк. Хатыны гына,— диде Йосыф.— Җылымны алырсыз, ди. Шәмсебанат апа риза, барырбыз, ди.

— Сталин клубындадыр ич?— диде Габделхәй дә, сүзгә катышып.— Бүген нинди кино соң әле анда?

— Сталин клубында. «Иван Грозный»,— диде Йосыф.

— Иске кино икән,— диде Фәрхәнә апа. Кече яктагы Былбыл бу яктагы сөйләшүне ишетмичәрәк калды һәм ишек янына килеп:

— Нинди картина, Йосыф?— диде.

— «Иван Грозный»,— диде Габделхәй.

— Җә, әни, барасыңмы? Әйдә, киен,— диде Йосыф, ашыктырып.

— Күрдем мин аны,— диде Фәрхәнә апа.— Татарны мыскыл итә торган кино. Бармыйм.

Йосыфның кайтуын күреп, тыштан Дәүләтгәрәй абзый да килеп керде. Ул да сүзнең нәрсә турында барганын ишетеп калган иде. Фәрхәнә апа белән бәхәсләшкән кебек:

— Анда бит Казан татарларын мыскыл итәләр. Яңавыл татарларына сүз әйтүче юк,— диде.

Йосыф көлеп куйды. Фәрхәнә апа да күңелсез генә елмайгандай итте. Ул арада өр-яңа күлмәген киеп, түшенә ясалма роза чәчәге кадап кече яктан Былбыл килеп чыкты һәм, карап тормыйлармы дигән сыман, җегетләр ягына күз төшереп алды да тиз-тиз генә көзге ягына борылды, көдрәләткән күперенке чәчләрен, изүләрен төзәткәләде, ислемай шешәсен ачып, бармак битенә хушбуй тамызды, муенына, колак артларына сөртте. Өй эченә ят, җиңел ис таралды.

— Әйдәгез, мин әзер!— диде ул, Йосыфка борылып һәм, жегетләрне көтеп тормастан, очынып-сикергәләп тышка ук чыгып китте.

Урамнан өчәүләшеп барганда Былбыл:

— Ник көлдегез?— диде Габделхәйгә.

— Юк, көлмәдек,— диде Габделхәй.

— Көлмәдегез? Мин ишетеп тордым,— диде Былбыл.

— Юк, көлмәдек,— диде Йосыф та, Габделхәйне яклап.

— Әллә миннән көләләр микән дип уйлаган идем,— диде Былбыл.

Кинога алар нәкъ башланыр алдыннан гына барып җиттеләр. Халык күп иде, клуб эче шыгрым тулы иде. Алар өчәүләшеп, ашыгып барысының күз алдында алга таба уздылар. Утырып торган кешеләр чиктән тыш кызыксынып аларга, дөресрәге, ят шәһәр кызына карап калдылар. Куанычыннан нишләргә белмәгән Габделхәй үзенә төбәлгән һәм кызыксынучан йөзләр арасында бер-ике җирдә классташ кызларын күреп калгандай булды. Кемдер хәтта арттан: «Габделхәй!»— дип кычкырган сыман да тоелды. Ләкин хәзер ул кемне дә булса күрер, танырдәрәҗәдә түгел иде. Алар җиденче рәтнең унынчы, унберенче, уникенче урыннарына утырдылар. Йосыф Былбылның сул ягына, Габделхәй уң ягына туры килде.

## VI

Сеанс башлангач, иң элек журнал күрсәттеләр. Журналда махсус күзлек кигән, каска кигән, зур бияләйле корыч коючылар дөрләп янган мартен мичләрен ачып карадылар; әкәмәт зур чүмечләрдән чәчрәп торган кайнар, сыек металл агыздылар; рельслар сыман булып озынча корычлар тезелде. Үкереп, бөтен экранны тутырып, ниндидер машиналар, танклар үтеп китте. Тантаналы итеп диктор нәрсәдер аңлатып торды. Шуннан соң Кубань буе далаларындагы иксез-чиксез бодай басуларыннан бер-бер артлы тезелеп барган комбайннар күренде. Күкрәкләре ачык батыр комбайнчы шәһәрдән килгән журналистка кычкырып нәрсәдер сөйли, аңлата башлады. Ашлык басуларындагы комбайннар артыннан ук диярлек, диңгез дулкыннарын ярып, бөтен экранны тутырып, крейсерлар узып китте. Күктә самолетлар очты, колакларны тондырып шат музыка яңгырап торды. Аннан соң Мәскәүдә, Ленинградта, тагын ниндидер шәһәрләрдә кызыл байраклар, портретлар, транспарантлар күтәреп, ташкын булып демонстрантлар узды. Штыклы автоматларын әзер тотып, күн итекле аяклары белән шапшоп басып, тыгыз сафлар белән корыч солдатлар үтте.

Если завтра война, если завтра в поход... —

дип җырладылар яшь, көр тавыш белән меңләгән, ун меңләгән ирләр, бөтен дөнья империалистларына янап. Ленин мавзолеенда, аталарча кулын күтәреп, иптәш Сталин фатиха биреп торды.

Бер ун минут чамасы дәвам иткән журналдан соң гөлт

итеп ут кабынды. Залда беразга ыгы-зыгы булып алды — кино башлануга, соңга калучылар үз урыннарына килеп утырдылар. Шуннан соң ут яңадан сүнде һәм залның арткы стенасына ясалган төннекләрнең берсеннән ак экранга калтырап-дерелдәп куе яктылык бөркелде.

Габделхәй кинода нәрсә турында сүз барганын озак кына аңлый алмый утырды. Кайчандыр аның бу картинаны күргәне бар иде, андагы күренешләрнең күбесе әле дә хәтерендә иде. Шуңа күрәдер, ахрысы, экрандагы кешеләр аны бөтенләй диярлек кызыксындырмады. Ул күбрәк үз янындагы Былбылны уйлады. Ул аннан килгән җиңелчә хуш исне тойды, аның кулы кызның утыргыч култыксасындагы кайнар, нәфис кулына тиеп китте. Бер мәртәбә ул үзенең ямаулы ботинкасы белән кызның танкеткасына, икенче мәртәбә очлы терсәге белән тәненә орынып алды һәм, утка пешкән кебек, тиз арада читкә тайпылды. Ләкин икенче якка авышу белән, тупас каты тәнле нindидер ир кешегә төртелде.

Кинода күрсәтелгән нindидер күренешкә карата үз фикерен әйтеп, бер мәртәбә Былбыл аның колагына иелгәндәй итте һәм нидер аңлатырга тотынды. Габделхәй аңламады. Ул бары үз колагы янында җылы, нәфис дулкын тирбәлүен генә тойды. Менә берзаман бөтен зал шаулатып көләргә тотынды. Габделхәй йокыдан уянып киткәндәй булды. Залдагыларның нәрсәдән көлгәнен ул аңламыйчарак калды. Үзе дә сизмәстән Былбыл ягына борылды, аның кулына кагылып:

— Ни булды? Ник көләләр?— диде.

Пышылдап кына Былбыл нәрсәдер аңлатырга тотынды. Габделхәй аңламады. Бу минутта ул кинодан бигрәк үзенең кыюлыгы, әрсезлеге турында уйлады, әдәпсез кулын тартып алды да, оятыннан нишләргә белмичә, яңадан экранга текәлде. Ярый әле Былбыл аның уттай янган битен күрмәде. Беркадәр игътибарын туплагач, ул залның нәрсәдән көлүен төшенеп алгандай булды.

Мәскәү патшасы янына килгән татар илчесе, урыс сүзләрен бозып: «Казан балшой, балшой, Маскыва малинки-малинки»,— диде. Зал, күрәсең, шуннан көлде. Урысча сөйләшә белмәгән татар илчесен мыскыллап көлде. Шул сүзләрне әйткән борынгы татардан бигрәк, бүгенге татардан — барлык татарлардан көлде.

Габделхәйгә кыен һәм күңелсез булып китте. Хәзер ул экранда күрсәтелгән күренешләргә, кешеләргә игътибарсыз гына карый алмады, хәзер ул һәр сүзгә колак салырга, һәр хәрәкәтне күңеле аша үткәрергә мәҗбүр булды. Соң дәрәҗәдә уяу һәм сак булып, экранда үзен

тагын мыскыл итүләрен, үзенә, халкына пычрак атуларын көтте.

Менә Казанга сугыш белән килгән Иван Грозный гаскәрләрен күрсәттеләр. Казан җирендә муеннарыннан җиргә күмеп куелган урыс әсирләрен һәм аларны төрлечә мәсхәрә итүче вәхши татарларны күрсәттеләр. Кинодан аңлашылганча, Казан татарлары һәрвакыт канэчкеч һәм кыргый булганнар, Мәскәүгә, урысларга һәрвакыт явызлык эшләгәннәр, аларны кысканнар, талаганнар һәм аларга берничек тә дөньяда яшәргә ирек бирмәгәннәр. Гаделлекне, дөреслекне яклаучы, үз туган илен дошманнан сакларга, соңгы тамчы канына кадәр «поганый татарин» белән сугышырга әзер торучы батыр урыслар, мәскәүлеләр тимер киемнәргә төренеп, тәреләр күтәреп, вәхшиләр оясын туздырырга киләләр. Иван Грозный да, аның якыннары да, гаскәр дә — барысы изгеләр, гайрәтлеләр. Алар — чын халык вәкилләре. Алар урыс даны өчен, Мәскәүнең иминлеге өчен сугышалар. Нәкъ хәзерге замандагы кебек... фашист илбасарларына каршы көрәшкәндәге кебек, гадел сугыш алып баралар.

Кинодан Габделхәй бик авыр тойгы белән чыкты. «Ник күрсәтәләр моны? Ник?!»— дип уйлады ул, чиктән тыш аптырап. Халыклар дуслыгы диләр, урыс белән татар дус, туган диләр. Дус, туган булгач, бер-береңне мыскыл итү нигә кирәк, кемгә кирәк? Татарның үз киносы юк. Казан өчен сугышның чынында ничек булганын татар үзенчә күрсәтә алмый. Киносы булса да, бүгенге татар урысны шулкадәр мыскыл итеп күрсәтмәс иде. Бит татарча китапларда урысны мыскыл иткән бер сүз дә юк! Урыс китабында, урыс киносында андый сүзләр тулып ята. Ник болай бу? Кая монда дөреслек, кая тигезлек?

Кинодан чыгучы халыкның күбесе шулай ук күңелсез һәм караңгы чырайлы иде. Бары тик кайбер урыс кешеләре генә, уенын-чынын бергә кушып, кинода әйтелгән сүзләрне кабатлыйлар, үзләренең таныш татарлары белән мыскыллашалар. Усалрак малай-шалайлар исә, бөтен урамга ишетелерлек итеп: «Казан балшой-балшой, Масква малинки-малинки!»— дип, «Бей татар!»— дип кычкыралар, шаркылдап көлешәләр иде.

## VII

Габделхәй, Йосыф һәм Былбыл, халык төркеменнән аерылып, үзләре ягына киттеләр. Алар сөйләшмәделәр. Кино турында сөйләшеп, фикер алышып булырлык түгел иде. Әгәр андагы сүзләрне, андагы күренешләрне яңадан

искә төшерә башласаң, иң якын кешеңнең нечкә җиренә кагылырсың да аның күңелен җәрәхәтләндерерсең шикелле иде.

Йосыфлар өенә килеп җитәрәк Габделхәй туктап саубуллаша башлады.

— Әйдә, Габделхәйне озатып куябыз,— диде Былбыл Йосыфка.

— Әйдә,— диде Йосыф.

— Мин үзем дә курыкмыйм,— диде Габделхәй. Шулай да карышып тормады. Алар әкрен генә кайткан юллары белән китеп бардылар.

— Әйдәгез әле берәр күңелле нәрсә турында сөйләшәбез!— диде Былбыл, малайларның икесен дә култыклап алып.

— Нәрсә турында сөйләшәбез соң?— диде Йосыф.

— И-и, Йосыф, җегет кеше шундый сорау биреп торамыни?!— диде Былбыл.— Кызлар белән булганда нәрсә турында сөйләшәләр соң? Ай турында, йолдызлар турында!

— Казан турында, Уфа турында ярамыймы?— диде Габделхәй, кызның җаена ятарга тырышып.

— Миңа бөтен нәрсә кызык,— диде Былбыл, чак-чак кына ясалма бер күтәренкелек белән.— Әнә карагыз әле, карагыз — ай йөгерә! Кызык бит, ы-ымы?

— Ай йөгерми, болытлар агыла,— диде Йосыф.

— Юк, йөгерә!— диде Былбыл.

— Әллә сез астрономия укымадыгыз?— диде Йосыф, күрәсең, Былбылны чын күңелдән сөйли дип уйлап.

— Нәрсә соң ул астрономия? Беренче мәртәбә ишетәм андый сүзне,— диде Былбыл.

— Нәрсә?!— диде Йосыф, шаккатып.— Ну... күк турында...

— Күк турында түгел, айлар, йолдызлар турында,— диде Былбыл, үзенең берни белмәвен онытып.

— Айлар дип сөйләшмиләр. Күктә ай бер генә,— диде Габделхәй.

— И-и, карагыз әле, карагыз!— диде Былбыл, ишетмәмешкә салынып.— Әнә, әнә, күрәсезме?

— Нәрсә соң, нәрсә?— диде Йосыф, күккә каранып.

— Берни күрмим,— диде Габделхәй дә.

— И-и, шуны да күрмәгәч!— диде Былбыл.— Күзегез шунда калсын!— диде ул кинәт һәм үзенең хәйләсеннән канәгать булып көләргә тотынды.

— Ах, харап булдым!— диде Габделхәй ыңгырашып, күзенә тотынып.

— Ни булды?— диде Былбыл, көлүеннән туктап.

— Уф, беттем, харап булдым!— диде Габделхәй, анын саен шомлы итеп.

Аптырап Йосыф та, Былбыл да туктап калдылар.

— Берни күрмим — күзем күктә калды!— диде Габделхәй.

Былбыл яңадан көләргә тотынды. Соңлап булса да, Йосыф та аңлап алды һәм шулай ук көлеп куйган булды. Өчәүләшеп, бөтен урамны шаулатып алар шулай көлешә-көлешә бардылар һәм көтмәгәндә ачыган сөт, әйрән исе аңкып торган җиргә килеп җиттеләр. Габделхәй шундук Сәкинәләр өе ягына карап алды. Анда ут янмый иде, ул якта тып-тын һәм караңгы иде. Таныш амбар почмагы да, караңгылыкка күмелеп утырган таныш йорт та — берсе дә хәзер Габделхәйнең күңелендә үкенү һәм вөҗдан газабы уята алмады.

— Минем бик озаклап айга карап торганым бар,— диде Былбыл, яңадан ай темасына күчеп.— Айда көянтәсе-чиләге белән Зөһрә кыз басып тора диләр. Бер дә көянтәле-чиләкле кызга охшамаган андагы таплар.

— Минем дә караганым бар — охшамаган,— диде Габделхәй дә.

— Минем ныклап караганым юк,— диде Йосыф.— Минемчә, айга бары шагыйрьләр генә озаклап карый.

«Шагыйрь» сүзен Йосыф, әлбәттә, Габделхәйгә карата әйтте. Былбыл янында үзен шулай «шагыйрь» дип атавы Габделхәйне үсендереп җибәргәндәй булды.

— Чынлап карасаң, шагыйрь булмаган кешегә дә күренә ул,— диде, «шагыйрь» сүзенә аеруча басым ясап.

— Юк, күренми,— диде Йосыф.

— Алайса, син анда берни дә күрмисеңмени?— диде Былбыл.

— Айны мин астроном булып күзәтәм,— диде Йосыф, әллә чынлап, әллә шаяртып.

— Ура! Бездә шагыйрьләр дә, астрономнар да бар,— диде Былбыл.

— Бер астроном, бер шагыйрь,— диде төгәллек яратучы Йосыф.— Өченчесе кем?

— Өченчесеме? Өченчесе шагыйрь дә, астроном да түгел,— диде Былбыл.— Өченчесе — филолог... то-есть шагыйрь дип әйтсәң дә була.

— Бөтен дөньяны шагыйрьләр баскан икән,— дигән булды Йосыф.

— Беләсезме, мәктәптә укыганда мин дә татарча шигырьләр яздым,— диде Былбыл.

— Чынлапмы?— диде Габделхәй, исе китеп.— Кызларның шигырь язганын беренче мәртәбә ишетәм.

— Сез бар эшне ирләрнеке, кызларныкы дип бүләргә яратасыз икән,— диде Былбыл, җиңелчә шелтә белән.

— Юк, мин алай бүлмим,— диде Габделхәй.

— Юк, юк, бүләсең, Габделхәй!— диде Былбыл, кайнарланып. Аның шул «бүләсең, Габделхәй» дигән сүзендә яшь җегеткә карата аеруча якынлык сизелеп киткән сыман булды.

— Чынлап, минем ишеткәнем югые кызларның шигырь язганын,— диде Габделхәй.

— Малайлар гел шулай инде алар — беркайчан безнең сүзгә ышанмыйлар,— диде Былбыл, үпкәләгән сыман. Ләкин үпкәләү аңа бөтенләй ятышмый иде.

— Хәзер язасыңмы соң?— диде Габделхәй, аның үзе кебек «син»гә күчеп.

Былбыл тиз генә җавап кайтармады. Станция ягында сузып-сузып паровоз кычкырды, кемнеңдер капкасы артында эт өргәне ишетелде.

— Искә төшерәсе килми,— диде бераздан Былбыл, күңелсез генә.— Куркыныч төштәге кебек... Менә бу «Иван Грозный» кебек... Ташладым мин шигырь язуны. Бишенчедә, алтынчыда яздым. Үзем язган шигырьләрне сәхнәгә чыгып сөйләдем. Бер мәртәбә радиодан да сөйләттеләр. «Кышкы көндә» дип атала. Җиденчедә безнең мәктәпне яптылар. Без укыган мәктәп бик иске иде. Ике катлы агач йорт. Урыс мәктәбе таштан салынган. Тәрәзәләре зур, спорт заллары, актовый заллары бар. Ишегаллары иркен. Татар мәктәбендә балаларга бернинди шартлар юк дигән сылтау белән, безне үз мәктәбебездән куалап чыгардылар да бөтенебезне урыс мәктәбенә тутырдылар. Шундый кыен булды, шундый кайгырдым. «Бармыйм! Бармыйм!» дип җылаганым әле дә хәтердә. Уку урысча. Күп нәрсәне аңламыйбыз. Парталарга урыс балалары белән аралаштырып утырттылар. Татарча бер сүз әйтсәң, укытучылар тирги, урыс балалары мыскыл итә, чәчтән тарталар, төртеп китәләр. Арткы партада Саша дигән бер җүнсез малай барые. Тәнәфестә булсын, кайтырга чыкканда булсын, күзне ачырмый... «Татарка, поганка! Татарка, поганка!» дип кычкыра. «Поганка» нәрсә булгандыр — аңламыйм. «Татарка»ны аңлыйм. Нигә минем «татарка»лыгым мыскыл сүзедер — шулай ук аңлашылмый. Беркөнне кайттым да, «татарка» буласым килми, мин әйтәм, җылыйм. «Берни эшләп булмый, кызым, мин — татар, син — татарка»,— ди әти. «Татарка» булган өчен хурланмаска, горурланырга кирәк, ди, татар ул бөек халык, ди. Шулаен шулай да, ничек итеп горурланасың «татарка» булган өчен? Тарих дәресендә Иван Грозный да Петр Первый. Татарны җиңүче бөек патша-

лар. Урыс патшалары нинди генә илне басып алмасыннар, кайда гына җырткычлык эшләмәсеннәр — һәркайда «азатлык өчен көрәшәләр», «урыс данын арттыралар». «Татар», «татар-монгол» бары сүгенү сүзе буларак кына кулланыла. Әдәбият дәресендә Пушкин да Лермонтов, Толстой... Шулай ук бөекләр.

— Алар чыннан да бөек,— диде Габделхәй.

— Анысы шулай,— диде Былбыл.— Ләкин безнең дә үзебез өчен кадерле бөек кешеләребез бардыр бит?

— Бар!— диде Габделхәй, ашыгып.

— Мин Казанга баргач кына белдем: Мулланур Вахитов Ленин белән бергә эшләгән. Аннан соң — Солтангалиев!— диде Былбыл, тавышын әкренәйтә төшеп.— Алар — революционерлар... бөек революционерлар!

— Мин дә беләм,— диде Йосыф, чак-чак кына мактанып.— Тукай, Такташ.

«Шуннан башка беркемне дә белмисең шул!»— дип уйлап куйды Габделхәй Йосыф турында. Ләкин Былбыл алдында бу турыда кычкырып әйтергә кирәксенмәде.

— Мин кайтып җиттем,— диде ул, өйләре ягына караштырып.— Сез мине озата килдегез, әйдәгез хәзер мин сезне озатып куйыйм.

— Син безне озатма инде, яме, Габделхәй. Без — икәү, курыкмабыз,— диде Былбыл, гади генә итеп.— Иртәгә очрашырбыз. Ярый, сау бул.

— Сау булы...гыз,— диде Габделхәй, теләр-теләмәс кенә.

Йосыф белән Былбыл китеп бардылар. Алар киткән якка, караңгыга Габделхәй озак кына карап торды. Йосыфтан ул әз генә дә көнләшмәде. Шулай да бу минутта Былбыл янында аның Йосыфны түгел, үзен күрәсе килде.

## VIII

Икенче көнне ул иртән иртүк Йосыфларга китте. Ул килеп кергәндә иркен ишегалдында, лапас янында җиңел кәрендәскә җигелгән ат тора иде. Дәүләтгәрәй абзый белән Йосыф җиргә җәеп салынган җылымны төреп яталар иде. Габделхәй туры алар янына килде, исәнләште һәм әйткәнне дә көтмәстән, Йосыфка җылым төрергә булыша башлады.

— Инәң киләме? Хәле ничек?— диде Дәүләтгәрәй абзый, беренче сүзе итеп.

— Килә. Миннән торып калдылар,— диде Габделхәй.

— Әйбәт булган,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

Хәзер ул гадәттәгегә караганда кызурак, ашыгыбрак кыймылдый, ашыгыбрак сөйләшә иде. Балык тоту аның иң яраткан шөгыльләреннән берсе иде, шуңа күрә һәрбер

балыкчы кебек, ул да бу эшкә тыныч кына карый алмый иде, ахрысы.

Җылым төрелеп беткәч, Дәүләтгәрәй абзый абзар баганасындагы дүңгәләктән атның каеш тезгенен чишеп алды, тезген очын дуга башындагы боҗра аша үткәрде дә камыт бавына бәйләп куйды. Шуннан соң ул туктаусыз авызлык тимерләрен чылтыратып, башын чайкап, койрыгын селтәп, чебен-кигәвен куып торган кара бияне ипләп кенә, җайлап кына капка ягына борды.

— Кая, чыгалармы әле тегеләр?— диде ул Йосыфка һәм шул ук вакытта өй эчендәгеләргә эндәшеп.

Аның шул сүзләрен генә көтеп торган кебек, чолан ишегендә Фәрхәнә апа белән Былбыл күренде.

— Җәгез, булдыгызмы?— диде Дәүләтгәрәй абзый, хатын-кызны ашыктырып.

— Булдык, булдык, җизнәй!— диде Былбыл.

Башына ул чәчен бергә туплап кыска гына яулык бәйләп куйган, өстенә эре чичкә төшерелгән кыска итәкле ситсы күлмәк һәм иркен балаклы озын чалбар — спортсменнар чалбары киеп куйган иде. Фәрхәнә апа белән алар икесе дә кулларына авыр-авыр төргәкләр, сумкалар тотканнар иде.

— И-и, чибәрттәй, Габделхәй килеп тә җиткән!— диде Былбыл, Габделхәйне күреп.— Исәнме, Габделхәй. Кара, син бик иртә торасың икән.

— Балыкка барганда йоклап ятып булмый инде,— дигән булды Габделхәй.

Ашыгып ул Былбыл янына килде һәм авыр сумкаларның берсен үз кулына алды.

— Рәхмәт,— диде Былбыл.

— Әллә бәрәңге салмаганнар инде?— диде Фәрхәнә апа, кәрендәс төбендәге яшел печәнне актаргалап.

— Эх, салмаганбыз шул!— диде Йосыф.

Ул тиз генә чоланга кереп китте һәм аннан тулартулмас итеп салынган бер бидерә иске бәрәңге алып килде, бидерәне җылым янына, кәрендәс артына куймакчы булды. Дәүләтгәрәй абзый бу эшне күрде, сүзсез генә бидерәне Йосыфның кулыннан алды да печән арасына җайлап утыртып куйды.

— Коелып бетәр ул анда... артта,— диде ул бераздан, аңлатырга кирәк табып.— Диздекәй кая? Бармыймени?

Соңгы сүзен ул Фәрхәнә апага карап әйтте. Фәрхәнә апа җавап биреп өлгергәнче, Йосыф яңадан өйгә кереп китте һәм йокысы ачылып җитмәгән сеңлесен күтәреп килеп тә чыкты. Диздекәйнең йөзе чытык иде. Бер туфлиен аягына кигән, икенчесен кияргә өлгермичә кулы-

на гына торткан иде. Йосыф сеңлесен кәрендәс эченә печән өстенә утыртып куйды да:

— Киен тизрәк!— диде.

Дәүләтгәрәй абзый ым кагу белән, Габделхәй олы капканы ачып куйды һәм ат-арба урам якка чыкканчы капканы тотып торды. Шуннан соң алар Йосыф белән икәүләп капканы кире ябып куйдылар, эчке яктан аркылы агач салып бикләделәр. Инде кузгалып китәргә генә дигәндә, нидер исенә төшеп, Йосыф кире ишегалдына йөгереп керде. Өй ишеген бикләргә оныткан икән. Йосыф богау йозагын тышкы ишекнең тимер бигенә элдерде дә, йозакны борып бикләде дә, зур тимер ачкычны ишек төбендәге такта астына яшереп куйды. Габделхәй белән алар ишегалдыннан соңгы кеше булып чыктылар. Бәләкәй капканы ныклап бикләп тормадылар — ул бары эчтән генә яхшылап бикләнелә иде.

Кәрендәснең уң ягына Дәүләтгәрәй абзый, сул ягына Былбыл утырды. Сытылырга гына торган чытык йөзле Дездемонаны Былбыл үз алдына утыртты. Габделхәй ат башына, Йосыф артка, җылым янына урнашты. Фәрхәнә апаны утыртмадылар. Ул әкрен генә арттан иярде. Шәмсебанат апалар килеп җиткәч, алар бергәләп юл буйлап килергә, Йосыф аларны кайтып алырга тиеш иде.

— Син безнең лакей,— диде Былбыл арттагы Йосыфка.

— Әниләрне алырга кайтканда мин барин булырмын,— диде Йосыф.

— Мин — кучер,— диде Габделхәй, Дәүләтгәрәй абзый кулындагы дилбегәне үз кулына алмакчы булып.

Ат бик көр иде, яшь һәм җитез иде. Дәүләтгәрәй абзыйның дилбегәне үз кулыннан ычкындырасы килмәде.

— Кучерлыкка укырга кирәк,— диде ул, көлемсерәп.

## IX

Кояш чыгып әкрен генә җир өстеннән күтәрелә барса да, көн әле салкынча иде. Юл буендагы үләннәрдә чык тамчылары елтырый; арба артыннан әлегә тузан да тузып калмый, тирә-якта кошлар, чикерткәләр тавышы да бик үк ишетелми иде.

Яңавылдан Бүә буена бару өчен тимер юлны чыгарга, тимер юлны чыгу өчен исә беркадәр җир тимер юл яныннан барырга кирәк иде. Юл аша чыга торган турыга җитәрәк Дәүләтгәрәй абзый атын тыя төште, поезд-фәлән килмиме дип як-ягына карагандай итте дә кычкырып:

— Аллага тапшырдык!— диде һәм дилбегәне бушайтып җибәрде.

Кәрендәс юл аша чыкканда, рельслар арасындагы шпаллар дөбердәп калды. Такыр юлдан ат иркенләп, җиңеләеп юырттыра башлады.

— Мә, кучер, син тот хәзер,— диде Дәүләтгәрәй абзый, дилбегәне Габделхәйгә биреп.

Габделхәй дилбегәне алды һәм куанычыннан елмаеп җиңелчә генә сызгырып җибәрде.

— На, малкай!— диде.

Габделхәйнең кайнарланган битенә салкынча җил бәрде. Ат тоягыннан, тәгәрмәчләрдән як-якка җиңелчә балчык кисәкләре чәчрәп калды.

Күп тә үтмәде, арба юлы тузанланып беткән вак куаклар арасына килеп керде. Юл читендә моңаеп, йокымсырап, тузан кунган үләннәр, ак, зәңгәр тәтәйләр, чыпчык сабыннары утырып калды. Куаклардан куркытылган вак кошлар очып чыкты. Куаклыкны узгач, арба юлы түбән таба йөгерә башлады. Атның үзенә буйсынмаска чамалавын сизеп, Габделхәй дилбегәне тартыбрак тотты. Юл һаман түбәнәя барды һәм бөтенләй искәрмәстән диярлек, текә булып аска шуышты. Тигез басулар, тузанлы куаклар артта калды. Аякларын терәп баскан килеш, артына каерылып, Габделхәй бар көченә атны тыярга тырышты. Ләкин аны алай гына тыеп калырлык түгел иде инде.

— Җибәр, үз көенә җибәр!— диде Дәүләтгәрәй абзый.

Тауның яртысын узгач, Габделхәй дилбегәне бушайтып җибәрде. Үзен иректә сизгән кара бия кушаяклап чабарга тотынды.

Аста, түбәндә чытыр-чатыр урманнар, сазлыклар һәм уйдык-уйдык акланнар белән тулы иңкүлек башланды. Язгы ташу вакытларында су баса торган бу иңкүлекнең каршыдагы ягы Сакат тауларына барып терәлә. Әле тауларга якын килеп, әле ерагаеп, урманнар, болыннар арасыннан Бүә суы агып ята иде.

Тау төшкәндә Дездемона чыркылдап кычкыра башлады, Былбыл да курыкты, ахрысы — ул шундук Габделхәй янындагы тимер тоткага ябышты. Габделхәй аның кулын тойды, чак-чак кына артына борылгандай итте дә:

— Курыкма! Мин монда!— диде.

Берзаман кучерның колак төбендә генә Дәүләтгәрәй абзыйның мактап әйткән сүзләре ишетелеп китте.

— Булдырдың, Габделхәй!— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Кучерлыкка имтихан бирдең. «Бишле»!— диде Былбыл да, җизнәсенең сүзен җөпләп.

Шатлыгыннан авызы колагына җиткән Галделхәй каерылып артына борылып карады. Аның күз карашы Былбылның күз карашы белән очрашты. Оста кучерга

күңеллерәк булып китте. Шул ук вакытта ул Йосыфның юклыгын да күреп алды.

— Йосыф кая?— диде коты алынып.

Габделхәй атны тыя төште. Барысы да артларына борылып карадылар — кәрендәс артында чыннан да Йосыф юк иде. Габделхәй атны туктатырга кирәк тапты. Артка, тау ягына карап бераз вакыт көтеп тордылар. Еракта, агачлар арасында Йосыфның тавышы ишетелеп китте. Озакламый ул үзе дә күренде.

— Исән, исән!— диде Былбыл.

Дәүләтгәрәй абзый берни әйтмәде — бары кәрендәс артындагы җылымга гына күз ташлап алды.

— Мин үзем төшеп калдым,— диде Йосыф, килеп җиткәч.

Былбыл белән Габделхәй аннан көләргә тотындылар. Йосыф яңадан үз урынына — җылым янына менеп утыргач, ат яңадан кузгалып китте.

Куе урман эчендәге юл тар һәм чокыр-чакырлы иде. Ике якта да ботак очлары тоташып, аралашып үскән талшомырт, карама, зелпеләр тыгызланып утыра иде. Тәгәрмәч казыган чокыр-чакырлы җирләрдә кәрендәс әле бер якка, әле икенче якка авышты. Биткә, күзгә ботак очы тимәсен өчен, арбадагыларга әледән-әле башларын иягә, читкә янтаерга туры килде.

Дымсу һәм ярым караңгы урман эченнән озак кына баргач, кинәт көн яктырып китте. Түбә өстендә яп-якты, чип-чиста булып зәңгәр күк йөзе күренде. Шул ук вакытта якында гына шаулап аккан су тавышы ишетелде.

Ташкичү дип атала торган бу төштә Бүә бик нык саегып калган иде. Язгы ташудан соң елга уртасында озын гына ком утравы барлыкка килгән иде. Елга ярлары ике якта да текә һәм биек иде. Балыкчылар килгән якта, Яңавыл ягында ул бөтенләй диярлек шәрә иде. Каршы якта исә күз күреме җиткән кадәр ераклыкта яр буйлары комлыклар һәм җырып чыккысыз тал куаклары белән капланган иде.

Бүә ярына якынлашкач, Дәүләтгәрәй абзый дилбегәне яңадан үз кулына алды һәм атны туктатты да яшьләрнең барысына да арбадан төшәргә кушты. Су янында ул үзе дә җиргә төште. Атның күкрәген, янбашларын сыйпалады, корсак астына кунган кигәвеннәрне куалап җибәрде. Авызлыкны ычкындырып аркалыкны бушайткач, кара бияне суга якынрак китерде. Кара бия, озын муенын сузып, пошкыра-пошкыра аяк астында туктаусыз агып яткан суны тәмләп эчәргә тотынды. Ат су эчкәндә Дәүләтгәрәй абзый яратып, иркәләп аның корсагыннан, янбашыннан сөеп тор-

ды. Эчеп туйгач ат башын калкытты, рәхмәт әйткән сыман җиңелчә генә пошкырып куйды.

Дәүләтгәрәй абзый аркалыкны күтәртеп бәйләде дә арбага менеп утырды һәм атны саерак, тигезрәк җирдән алып бара башлады. Шул ук вакытта кычкырып: «Аллага тапшырдык!»— диде. Тимер кыршаулы тәгәрмәчләр астында, су төбендә вак ташлар кыштырдады, тәгәрмәч тәпиләре тирәсендә су чупылдады.

Яшьләр суга, яктылыкка, су өстеннән очкан акчарлаклар тавышына — тирә-якка сокланып, хозурланып яр кырыенда карап тордылар, су уртасына керә барган арбалы атны, Дәүләтгәрәй абзыйны күзәттеләр. Яр читендә сай булса да, елганың уртасы шактый тирән булып чыкты. Су башта алгы тәгәрмәчнең тугымына җитте, аннан соң тугымны да күмеп китте. Бераздан су арткы тәгәрмәч тугымын да күмә язды. Суның иң тирән төшендә, уртада, арткы тәгәрмәч тугымы да күмелде. Чыланмас өчен Дәүләтгәрәй абзый атбашына күчеп утырды. Ул арада кәрендәскә су керде һәм аска салынган печән калкып, агып китте. Артка бәйләп куелган җылым су астында күмелеп калды.

Икенче як яр читенә килеп чыккач, ат туктады һәм бөтен гәүдәсе белән кагынып, өстендәге су тамчыларын койды. Кәрендәс төбеннән шыбырдап су акты. Дәүләтгәрәй абзый дилбегәне селтәп җибәрде, «на, малкай!» диде һәм ат таллар арасыннан җиңел генә кузгалып китте.

Ул арада малайлар, Былбылдан читкәрәк китеп, өс киемнәрен, чалбарларын салдылар.

— Барыгыз, бар, сез алдан китегез!— диде Былбыл, малайларны үз яныннан куалап.

— Кем белән чыгасың — минем беләнме, Былбыл апаң беләнме?— диде Йосыф Дездемонага.

— Синең белән. Син көчлерәк,— диде Дездемона. Йосыф иелеп аны кулына күтәрде. Дездемона ике куллап абыйсының муеныннан, аяклары белән биленнән кочып алды. Бер кулы белән сеңлесен, икенче кулы белән төрелгән чалбарын, аяк киемнәрен тотып, Йосыф алдан атлады. Габделхәй дә чалбары белән ямалган ботинкасын тотып аның артыннан атлады. Яланаякка су башта салкын тоелды. Ләкин тирәнгәрәк керә барган саен аның салкынлыгы бөтенләй сизелмәс булды. Аякларга, бөтен тәнгә туктаусыз нидер сөйләнеп, каядыр ашыккан судан, елгадан гаҗәеп бер рәхәтлек һәм көч-куәт бирелде.

Кичүнең тирән төшенә җиткәч, Габделхәй онытылып артына борылып карады.

— Карама!— дип кычкырды Былбыл, кабаланып.

Ул да малайлар кебек чалбарын, аяк киемнәрен салып кулына тоткан, күлмәк итәген күтәреп учына алган һәм вак ташларга иплəп кенә баса-баса суга таба килеп ята иде. Габделхәй оялып шундук йөзен читкә борды. Былбылның нидер кычкыруын ишетеп, Йосыф та артына борылып карады. Аңа да ярым боерып, ярым үтенеп әйтелгән «карама!» яңгырады.

Малайлар, тирән җирне үтеп, икенче якка, комлыкка барып чыктылар һәм үзара мәгънәле генә карашып, елмаешып, ат юлыннан югары менеп киттеләр. Яр өстендә аларны Дәүләтгәрәй абзый көтеп тора иде. Малайлар чалбарларын киделәр, ләкин аяк киемнәрен киеп тормадылар. Барып җитәргә инде күп калмаган иде. Хәзер инде тәпи-тәпи барсаң да була иде.

Ул арада Былбыл да менеп җитте һәм кәрендәстә үзе утырган урында печән юклыгын, җитмәсә, кәрендәс төбенең чыланган булуын күреп, кычкырып җибәрде.

— Монда утырып булмый!— диде.

— Габделхәй янына, ат башына утыр. Анда коры,— диде Йосыф.

— Үзем генәме?! Мин куркам!— диде Былбыл

— Икегез утырыгыз,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Сыярбыз микән соң?— дигән булды Габделхәй һәм бер дә юктан кызарына башлады.

— Сыярбыз, сыярбыз!— диде Былбыл.

Дәүләтгәрәй абзый кәрендәс төбенә үзенең иске гимнастеркасын җәеп куйды, шуның өстенә утырды да Диздекәйне үз алдына утыртты.

— Әйдәгез, кузгалдык, балалар,— диде беркемгә дә атап әйтмичә, шулай да Габделхәйне күз алдында тотып, чөнки дилбегә аның кулында иде.

Ат кузгалып китте. Алар ярты чакрым чамасы җирне ачык болын уртасыннан бардылар да ярым караңгы әрәмә арасына килеп керделәр. Юл монда тигез иде, шулай да кәрендәс әледән-әле як-якка чайкалды. Арба чайкалганда Былбыл куркып җиңелчә генә кычкырып җибәрде, көлде һәм үзенең сөенечен белдереп, каядыр читкә күрсәтеп, әледән-әле: «Карале, кара!— диде.— Нинди матур!»— диде. Бер мәртәбә арба бик нык янтайгач, ул Габделхәйнең беленнән тотып алды. Бәхеттән исергән җегетнең куанычы эченә сыймады. Бөтен тәне уттай янды, колак очлары кызарып чыкты. Үзенең шатлыгын, кызаруын, оялуын башкаларга сиздермәс өчен ул кирәксә дә, кирәкмәсә дә дилбегә какты, Дәүләтгәрәй абзый сыман «әйдә, малкай!» диештереп, кычкырып-кычкырып алды.

Бөтенләй көтмәгәндә диярлек юлчылар яңадан болынга килеп чыктылар.

— Каяле, мин дә тотып карыйм дилбегәне!— диде Былбыл, Габделхәйнең колагына пышылдап.

Кучер, икеләнгәндәй итеп, Дәүләтгәрәй абзый ягына карап алды.

— Бай абзый нәрсә әйтә бит әле!— диде ул, көлеп.

— «Бай абзый», дилбегәне тотыйм әле,— диде Былбыл.

— Күп калмады инде, балалар,— диде Дәүләтгәрәй абзый, икеле-микеле итеп.

— Әнә, алырга кушты,— диде Былбыл һәм Габделхәйнең кулындагы дилбегәне алды да көлә-көлә селтәнергә тотынды.— На, малкай! На!

Кара бия дилбегәнең икенче кулга күчүен сизеп, колакларын шомартып, әле уңга, әле сулга карап-карап алды, ләкин җайланган адымын әз генә дә үзгәртмәде.

— Бик каты чаптырма әле! Арбадан төшеп калам инде,— диде Йосыф Былбылга, үзенчә шаярткан булып.

— Менә хәзер тауга җитәбез — шунда төшеп калырсың,— диде Былбыл.

— Ачуымны китерсәгез, тауга җиткәнче дә төшеп калырмын!— диде Йосыф.

Болын аша үткәч, иске такыр юл яңадан саз һәм урман исе килгән куе чытырманлыкка килеп керде. Чытырманлыктан соң арба юлы беркадәр үргә күтәрелде һәм шул чакны иркен генә болын күренде.

— Менә килеп тә җиттек, балалар,— диде Дәүләтгәрәй абзый, эчке бер тантана белән.

## X

Ат туктау белән барысы да шыбырдашып җиргә коелдылар һәм арбадагы әйберләрне алып куйдылар. Дәүләтгәрәй абзый атны борды һәм дилбегәне Йосыфка тоттырды.

— Мә, улым, тиз йөре,— диде.

Йосыф, дилбегә үз кулына кергәч тә, масаеп, горурланып Былбыл белән Габделхәй ягына карап алды, кәрендәскә, этисенең дымлы гимнастеркасына утырды да:

— Барин китте!— диде һәм бер дә кирәкмәгәнгә сызгырып җибәрде.

— Тиз йөре!— диде Дездемона, кул болгап.

— Брезент алырга онытма,— диде Дәүләтгәрәй абзый, Йосыф артыннан кычкырып.

Алар нәкъ Бүә яры буена туктап калганнар иде. Ярның бу ягы сөзәк иде, су буе комлы һәм иркен — җы-

лым тартырга җайлы иде. Каршы якта исә, кызыл балчыгы коелып торган текә яр өстендә, тыгызланып, берберсенә сыенып карамалар, юкәләр, усаклар тынып калган, алардан арырак, барысыннан да биегрәк булып, бик зур ялгыз чыршы калкып утыра иде. Бераз гына үрдәрәк, тирән су өстенә тамырлары-ниләре белән, тамыр арасындагы туфрак кантарлары белән зур-зур агачлар егылып төшкән иде. Аларның кайберләре су уртасында утырып калган, кайберләре корыган башлары белән суга капланган, кайберләре исә башкалар өстенә сузылып ятканнар иде. Ул тирәдә су тагын да тирәнрәк булып, серле һәм куркыныч булып тоела иде.

Иртәнге кояш нурында коенган болын өстендә, куакларда, каршыдагы урман ягында бөтен нәрсә туктаусыз гүләп, чеңләп, шаулап тора сыман иде. Шул ук вакытта юкәләрдән, чык тамчылары җемелдәшкән болын өстеннән хуш исләр бөркелә. Суның тирән җирендә чулт-чулт итеп чабаклар сикерә, яр буенда, канатларын сызгыртып, түбәннән генә керәшәләр очып йөри иде. Кайдадыр ерakта, Очлы тау ягында тоныграк тавышлы ниндидер олы кош кемгәдер кычкырып-кычкырып куя иде.

Суга иң элек Дәүләтгәрәй абзый якын килде, сүзсез генә карап торды да үзенең артындагы Габделхәйгә эндәшкән сыман:

— Тегеләрне күтәргә туры килер,— диде.

— Әйдә, җизнәй, көтеп тормыйбыз!— диде Былбыл, аның нәрсә турында әйткәнен чамалап.— Өч кеше бер җылымны тарта алмыйбызмы әллә?

— Без әле дүртәү,— дигән булды Габделхәй.

— Юк, Былбыл, көтәргә туры килер,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Барыгыз, сез хәзергә җиләк, карагат карый торыгыз, мин җылымны җайлап куярмын. Өчәүләп без тартуын тартырбыз, бәлки, ләкин аның иң кызыгы — бергәләп тарту, Былбыл!

— Шулай шул,— диде Габделхәй дә, килешеп. Дәүләтгәрәй абзыйның җиләк-карагат җыярга кушуы аның күңеленә хуш килде.

— Кайчан су керәбез?— диде Дездемона.

— Шаулама!— диде Габделхәй, Дездемонага бармак янап.— Су буенда кычкырып сөйләшергә ярамый — балык курка.

— Әйе, әйе, курка,— диде Былбыл да.

Дәүләтгәрәй абзый җылымны җиргә җәеп салды һәм игътибар белән аның һәр күзәнәген карарга тотынды.

— Барыгыз, бар, ераграк китегез моннан,— диде ул, яшьләргә кул селтәп.— Кирәк булгач үзем чакырырмын.

Габделхәй белән Былбыл, Дездемонаны ияртеп, болын ягына китеп бардылар. Бу яктагы болыннар, әрәмәләр Габделхәйгә таныш иде. Ул мондагы һәрбер куакны, һәрбер чокыр-чакырны биш бармагыдай белә иде. Былбылның ул сул ягыннан, яныннан гына атлап барды. Ул аңа мондагы әрәмәләр, җиләклекләр турында сөйләде. Узган кышны икесенә бер мылтык алып Йосыф белән шушында ауга килүләре, күпме патрон шартлатып, бер чыпчык та атып ала алмаулары турында сөйләде.

— Нинди мылтык? Автоматмы әллә?— диде Былбыл, куркып.

— Ау мылтыгы!— диде Габделхәй.— Дәүләтгәрәй абзыйныкы. Ул бит аучы да.

— Беләм,— диде Былбыл.

Шуннан соң Габделхәй өченче ел көз көне инәләре белән, күрше хатыннар белән шушы ук болынга балан җыярга килүләре, адашулары һәм елгада балык шартлатып йөрүче нindидер шикле бәндәләрне очратулары турында сөйләде.

Алар шулай мавыгып үзара сөйләшеп барганда Дездемона туктап калды, шыңшырга тотынды һәм киреләнеп җиргә үк утырды.

— Ни булды?— диде Былбыл, чүгәләп.

Дездемона ни булганын әйтеп тормады, сул аягын ике куллап тотып алды да иелеп табанына кадалган үлән шырпысын эзләргә тотынды. Аяк киемен ул этисе янында калдырган булган икән. Дездемона янына Габделхәй дә иелде, Былбыл белән бер-берсенә якын килеп, алар икесе дә әбәләк кызыйның уч төбедәй бәләкәй генә кара тәпиен карарга тотындылар. Габделхәйнең битенә Былбылның яулык астыннан чыгып калган берничә чәч бөртеге тиеп китте, борынына кайнар тыны килеп бәрелгәндәй булды. Артык якынаюдан куркып, уңайсызланып ул тиз генә башын читкәрәк алды. Былбыл исә, берни сизмәгәндәй, бирелеп Дездемонаның табаныннан шырпы эзләде.

— Кая соң, берни күрмим!— диде ул, табанга өрә-өрә.

— Мин анда бармыйм!— диде Дездемона, шыңшып.

— Ә, менә икән!— диде Былбыл, ниһаять.

Нәфис тырнак очлары белән ул нидер эләктереп алды, көлеп җибәрде. Аннан күрмәкче, авыртудан котылудан сөенепме, Дездемона да көлеп җибәрде.

— Булды!— диде ул, җиңел сулап.

— Кем элек?— диде Былбыл.

— Мин элек!— диде Дездемона.

Алар шундук урыннарыннан сикереп тордылар, аякларына бастылар. Дездемона «элек» булды. Былбыл апа

арткарак калды, Габделхәй тагын да арткарак калган булып чыкты.

— Бар, тиз генә аягыңа киенеп кил,— диде Былбыл Дездемонага.

Әле генә «бармыйм» дип карышкан кызый хәзер «аягыма кимим» дип карыша башлады.

— Барсын шулай гына,— диде Габделхәй.

## XI

Чабылган болын аша үткәч, алар күләгәле әрәмә эченә килеп керделәр. Габделхәй алдан барды. Ул аркылы сузылып яткан, ауган агачларны атлап чыкты, кайберләрен әйләнеп үтте, үзеннән артта килүчеләрнең битенә тимәсен өчен, ботакларны як-якка аерып тотып торгандай итте.

Әрәмә артык куе түгел иде, шулай да Дездемона тагын шыңшырга тотынды. Хәзер ул «анда бармыйм» дип киреләнде.

— Бар син кит,— диде Былбыл аңа.— Әтиең әнә анда гына — күренеп кенә тора.

— Бар, бар,— диде Габделхәй дә.— Моннан без сине карап торырбыз.

— Сукмакка чыгарып куй!— диде Дездемона, таләп итеп.

Кызның сүзен тыңлап, кире әрәмәдән чыгарга туры килде. Яр буендагы Дәүләтгәрәй абзый күренеп кенә тора иде. Дездемона, артына борылып карый-карый, әтисе ягына йөгерде. Ул ерагайгач Габделхәй Былбылга карап алды да яңадан кузгалып китте. Якында гына ул яхшы белгән «карагат күле» бар иде. Аның хәзер Былбылны шунда алып барасы килде.

Сирәк куаклар аша үткәч, борынга черегән яфрак исе, саз исе килеп бәрелде. Озакламый саз исен ылыс исе алыштырды. Алар төбендә берән-сәрән абага сыман үләннәр үсеп утырган ниндидер чыршылыкка килеп керделәр. Бер-берсеннән тигез ара калдырып утырган чыршы төпләрендәге җир өсте тоташ кызгылт ылыс белән түшәлгән иде. Тын алуы монда иркенәеп китте. Куе чыршы араларыннан тасмадай сузылып, кыйгачлап кояш нурлары төшкән. Кояш нурларында бер ботактан икенче ботакка сузылган үрмәкүч аулары җемелдәшә. Тирә-як тып-тын. Бер-берсенә сыенып, бер-берсеннән уздырып биеккә, яктыга үрелгән төз, купшы чыршылар, иртәнге илаһи тынлыкны бозарга теләмәгәндәй, тынып-йокымсырап утыралар иде. Аяк атлаган саен бары тик йомшак, коры ылыслар кыштырдаганы ишетелә дә чырт-чырт итеп коры ботаклар гына сынып калгалый иде.

— Нинди күңелле!— диде Былбыл, исе китеп.— Менә нинди күңелле икән монда!

Шулай аяк астындагы ылыс юрганын таптап, аркылы сузылган үрмәкүч ауларын өзгәләп бара торгач, көтмәгәндә тукран тавышы ишетелеп китте. Кайдадыр якында гына корыган чыршы башында тукран корыч томшыгы белән бер-бер артлы тукылдатып алды. Былбыл да, Габделхәй дә икесе берьюлы сискәнеп киттеләр, туктап калдылар һәм шундый каты тукылдатучының үзен күрмәкче булып, муеннарын сузып, як-якка карана башладылар.

— Кая соң ул? Күрәсеңме син?— диде Былбыл пышылдап, Габделхәйгә таба елышып.

— Күренми,— диде Габделхәй.

Тын алырга да куркып, алар озак кына күзәтеп тордылар, ләкин тукылдаган тавыш яңадан кабатланмады. Габделхәй кузгалып китмәкче булып аягын гына кузгаткан иде, тукран тагын тукылдата башлады.

— Әнә!— диде Габделхәй, якындагы агач башына күрсәтеп.

Бик нык игътибар белән Былбыл каядыр югарыга карарга тотынды.

— Юк, берни күрмим,— диде ул.

— Күзең шунда калсын!— диде Габделхәй.

— Ай, күзем күрми!— дигән булды Былбыл, шаянланып.

Икесе дә, кичәге сөйләшүне искә төшереп, көлешеп алдылар һәм кузгалып киттеләр. Тоташ яфраклы агач урманы уртасында утрау сыман булып утырган чыршылык зур түгел иде. Озакламый чыршылар артта калды һәм яңадан саз исе — куе, сусыл үлән һәм җыелып, череп яткан су исләре килә башлады. Монда кайчандыр шаулап Бүә аккан. Елга үзенә яңа юл салган, иске юл күлгә, күл сазлыкка әйләнгән. Хәзер ул камыш сыман биек үләннәр белән, вак-вак түмгәкләр, ялгыз куаклар белән капланган озынча бер батынкы җир иде. Котырып үскән куаклар арасында, оя-оя булып утырган камышлы түмгәкләр арасында — әле анда, әле монда төнбоеклар, бака җилфәкләре белән чуарланган кесәлдәй куе яшькелт сулар ялтырап ята иде. Уйдык-уйдык суларның кайберләре зур гына, кайберләре кибеп бетеп бара һәм шул сулы чокыр төпләрендә корыган саз үләннәре моңаеп утыра иде.

— Мин куркам. Анда бармыйк, Габделхәй,— диде Былбыл.

Ул моны баягыча ярым пышылдап әйтте, якындагы ниндидер куркыныч җан ияләре ишетмәсен дигән сыман итеп әйтте. Кызның йөзендә Габделхәй куркудан бигрәк шомлану, тынычсызлану күрде.

— Нәрсәдән куркасың?— диде ул, кызның үзе кебек үк пышылдап.

— Үзем дә белмим,— диде Былбыл.— Әнә анда... куаклар арасында кемнәрдер карап торалардыр кебек.

— Кем булыр икән соң ул анда?— диде Габделхәй, сүзне уенга бормакчы булып.— Әйдәле, барып карыйк — чыннан да берәрсе яшеренеп ятмый микән анда?

Бу сазлыкка әле быел кеше аягы басмаган иде бугай. Карагат әле ныклап пешмәгән, үрдәк атарга инде соң. Габделхәй төбәп барган куакның кояшка каршы ягына килде дә, иелә төшеп, бер ботакны күтәргәндәй итте. Авыр ботакның төбеннән алып очына кадәр эре җимешле тәлгәшләр асылынып тора иде. Яңа пешә башлаган карагат шундый эре, тәлгәшләр шундый күп иде — ботакта хәтта яфракларга да урын калмаган иде.

— Менә ул!— диде Габделхәй, бер-ике тәлгәшне өзеп алып.

— Бу миңа күчтәнәчме, Габделхәй?

— Күчтәнәч, ләкин аны әле ашарга ярамый,— диде Габделхәй.

— Мин аны ашамыйм — гәрәбә кебек итеп тагып кына куям,— диде Былбыл, балаларча куанып һәм чыннан да каралҗым карагат тәлгәшен изүендәге сәдәпкә тагып куйды.— Матурмы?— диде ул аннары.

— Матур,— диде Габделхәй, аның түшенә кырын күзен төшереп.

— Монда җиләк юкмыни?— диде бераздан Былбыл.

— Җиләк бар барын, тик моннан ерак,— диде Габделхәй.— Монда әле кызыл карагат та бар. Анысын инде җыйсаң да була.

— Минем эти ярата кызыл карагатны,— диде Былбыл.— Балыктан соң кереп җыярбыз, яме? Мин этигә кызыл карагат алып кайтырмын.

— Мин аны сиңа үзем җыеп бирермен. Күпме кирәк — шулкадәр!— диде Габделхәй.

— Ярар, шулай итәрбез,— диде Былбыл, килешеп. Ул шулай дип әйтергә дә өлгермәде, ниндидер кара, шома нәрсәнең аяк астыннан гына диярлек шуышып баруын күреп алды һәм коты алынып:

— Җылан!— дип кычкырып җибәрде.

Куркудан Габделхәй дерт итеп китте, борылып Былбыл ягына карады һәм шул мизгелдә кояшлы ачык җирдә ашыга-ашыга боргаланып, куркыныч елкылдап китеп барган зур гына җыланны күреп алды. Җыланга карата анда табигый дошманлык тойгысы саклана иде. Бу аның канына сеңгән иде. Җыланны күрсәң, теләсә кайда үте-

рергә, үтерә алмасаң, ничек тә аннан ераграк булырга кирәк иде. Бары тик йорт җыланына, мөгезле җыланга һәм тузбашка гына кагылырга ярамый иде. Йорт җыланы йортны саклый, бәхет китерә, җыланның мөгезен күргән кеше гомергә бәхетле була дип исәпләнелә иде. Аларны куркыткан кара җыланны үтерергә кирәк иде. Ләкин ул әнә качты. Качсын әйдә.

— Уф!— диде Былбыл, йөрәк турысына кулын куеп.— Шундый курыктым! Йөрәк дөп-дөп тибә. Тотып карале менә!

Аны-моны уйламыйча, ул Габделхәйнең үзеннән-үзе салынып төшкән кулын тотып алды, аны-моны уйламыйча үзенең бик каты дөпелдәп типкән йөрәге турысына китерде. Кызның йомшак кулы үз кулына килеп тигәч тә, йомрыланып калкып торган тыгыз күкрәгенә кагылып киткәч тә, яшь җегетнең куркудан юкка чыккан кайнар каны яңадан уянды, кулына җан керде һәм көчле дулкын булып бөтен тәненә таралды. Җылан, курку, җирәнү — барысы онытылды, якында, янәшәдә бары тере булып, сокландыргыч булып илаһи зат кына торып калды. Корт чаккандай кулын ул шундук тартып алды, колак очларының кызарына барганын тойган хәлдә күз карашын читкә борды. Былбыл да, үзенең саксызлыгын аңлап, тынып калды.

— Нинди куркыныч!— диде ул, телгә килеп.

— Әйдә, китик моннан,— диде Габделхәй.— Кемнәрдер карап та тора дисең...

— Әйдә,— диде Былбыл, күндәм генә.

## XII

Бер ярты сәгать чамасы вакыт үткәч, атларын кызу атлатып, Йосыфлар да килеп җитте. Атны ярдан читкәрәк, зур шомырт куагы төбендә туардылар да кешәнләп якындагы болынга утларга җибәрделәр. Фәрхәнә апа белән Шәмсебанат апа, балыкчылар балык тотканчы дип, якын-тирәне әйләнеп чыкмакчы булдылар. Бу яктагы болыннарны, куаклыкларны — кайда җиләк, кайда карагат булуын алар да яхшы беләләр иде. Шуңа күрә яр буенда артык тоткарланмыйча, үзара нидер сөйләнеп, әкрен генә читкә китеп бардылар. Ләкин алар әле генә Габделхәй белән Былбыл булган якка түгел, бөтенләй икенче якка киттеләр.

Әкрен генә, ялкау гына агып яткан Бүә шундый саф, шундый тонык сулы иде, ныклабрак карасаң, су төбендәге иң вак ташларны да аермачык күрергә була иде. Мондый тонык суда балык тотып булмаячак иде, әлбәттә.

Җылым сала башлаганчы Дәүләтгәрәй абзый Йосыф белән Илгизне үргә, ләм-ком актарып, суны болгата башларга җибәрде, Габделхәйгә үзе янында калырга кушты.

— Мин нишләргә тиеш, җизнәй?— диде Былбыл, үзенең эшсез калуын күреп.

— Син балык җыеп торырсың,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Балыкны без җыябыз Фидәил белән!— диде Дездемона.

— Алайса мин су комларга барам!— диде Былбыл һәм, рөхсәт булганны да көтмәстән, якындагы кәрендәс ягына йөгерде.

Анда ул аяк киемен салып куйды, як-ягына каранып һәм чак-чак кына оялып-уңайсызланып өс киемнәрен салып ташлады, чәчен-башын, күкрәкчәсен төзәткәләде һәм Йосыф белән Илгиз артыннан йөгерде. Габделхәй аның биегәндәге сыман матур аяклары белән килешле йөгергәләп баруын арттан карап калды. Ул аның кояшта янган сылу беләкләрен, аркасын күрде, бүтән чакта чит күзләргә күрсәтелми торган барлык зифа буен күрде һәм, сокландыргыч матурлыкка исе китеп, зиһене чуалып, шундук күзен читкә борды. Нишләптер Дәүләтгәрәй абзый аңа карап торадыр сыман тоелды. Ул тиз генә Дәүләтгәрәй абзый ягына күз салды, аның үзенә игътибар итмәвен күреп, яңадан Былбыл ягына борылды. Ләкин бу вакытта сихри күренеш инде юкка чыккан иде. Ул бары аның куаклар артында:

— Йосыф! Илгиз!— дип кычкырган шат тавышын гына ишетте.

Былбыл китеп барганнан соң, Дәүләтгәрәй абзый беркадәр вакыт көтеп торды, тоныкк су уртасыннан болыт сыман булып әкрен генә болганчык агым якынаеп килгәне күренгәч, «Аллага тапшырдык»ны әйтеп суга керде дә Габделхәйгә ым кагып:

— Әйдә, Габделхәй, башладык!— диде.

Габделхәй җылымның икенче башындагы шома агачны җайлап кулына тотты. Әкрен генә тартылган челтәрле җылым су эчендә күмелә барды. Дәүләтгәрәй абзый, кулындагы җылым таягын ничек тә елга төбеннән шудырырга тырышып, һаман эчкәрәк, тирәнгәрәк керде. Су башта аның балтырына, тезенә җитте һәм туктаусыз күтәрелә барды. Дәүләтгәрәй абзыйның ак ыштанына кыстырып куелган күлмәк эченә һава тулды. Болай да олы гәүдәле ир кешенең аркасы мендәр сыман күпереп торды.

Яр читендәге вак ташларны, бакыргач кабыкларын шыштырдатып, себереп-өстерәтеп җылым койрыгы тәмам

суга кумелгәч, Габделхәй дә суга керде һәм авыр җылымны агымга каршы тарта барып, әкрен генә атлап китте. Ул арада Дәүләтгәрәй абзый елганың уртасына җитте. Су өстеннән аның зур башы, киң кулбашлары, ара-тирә кулындагы җылым таягы гына күренде. Җылым тарту минут саен авырая барды. Дәүләтгәрәй абзый исә һаман тартуында булды һәм ничек тә икенче як ярга барып чыгарга, ничек тә елганы җылым белән иңләп, бүлеп алырга тырышты.

Габделхәй, аякларын комлы су төбенә терәп, әкрен генә алга таба хәрәкәтләнде. Чынлыкта бу алга таба бару да түгел, бары җылымны агымга каршы тигез итеп тотарга тырышу гына иде.

Нык тартылган җылым җәтмәсенә әледән-әле нәрсәләрдер килеп бәрелде. Габделхәйгә шундый зур-зур балыклар килеп бәреләдер сыман тоелды. Бу анда яңа көч һәм омтылыш тудырды. Ул туктаусыз җылымны, Дәүләтгәрәй абзыйны күзәтте, шул ук вакытта тал куаклары артындагы чыр-чуга да колак салды. Анда, куаклар артында, су өстендә Былбылның шат һәм дәртле тавышы ишетелеп-ишетелеп китте.

Дәүләтгәрәй абзый елганың икенче як ярына барып чыккач, «булды бу» дигән сыман, канәгать бер төс белән Габделхәй ягына карап алды. Габделхәй аның ни әйтергә теләгәнен чамалап алды һәм үзе тирәсендә бөтерелгән Фидәилгә пышылдап:

— Бар, йөгер тегеләр янына!— диде.

Шуны гына көтеп торган Фидәил су чәчрәтә-чәчрәтә, үргә таба йөгерде. Кычкырып, кулларын бутап аның артыннан Дездемона чапты. Күп тә үтмәде, тал куаклары артыннан су комлатучылар килеп чыкты. Чыр-чу килеп, коточкыч шау-шу ясап, алар җылым тартучыларга таба якыная башладылар.

## XIII

Җылым тартучылар янына беренче булып Илгиз килеп җитте һәм җылым алдыннан ук диярлек Дәүләтгәрәй абзый янына йөзеп чыкмакчы булды. Ау барышын уяу күзәтеп торган Дәүләтгәрәй абзый, судан зур йодрыгын чыгарып, Илгизгә ачуланып алды. Бу аның җылым алдына керергә ярамый дигәнен аңлатты. Илгиз, кирегә йөзеп, комлы ярга барып чыкты да, өстендәге суларын коеп, дөп-дөп басып, җылым артына төште. Илгиз артыннан ук диярлек яр буйлап ашыгып Былбыл килеп җитте.

— Мин нишләргә тиеш? Мин нишлим, җизнәй?— диде ул Дәүләтгәрәй абзыйга.

Ул шат иде, ул эшчән иде. Бу минутта ул шундый чибәр иде!

— Монда кил, монда!— диде Габделхәй.

Былбыл тиз арада Габделхәй янына килеп җитте һәм аның кебек үк җылым таягына тотынды.

— Баудан тарт!— диде аңа Габделхәй.

Җылым таягына койрык сыман итеп озын гына бау ялганган иде. Суда бүртеп тыгызланган бауны Былбыл ике куллап тотып алды да бар көченә тартырга тотынды. Теге якта Илгиз Дәүләтгәрәй абзый янына барып чыкты һәм шулай ук җылым таягына тагылган баудан тарта башлады. Бераздан Йосыф килеп җитте. Йосыф бауга тотыну белән җылым тарту җиңеләеп китте. Шауламаска, тавыш-мазар чыгармаска тырышып, дәртләнеп һәм бердәм булып алар үргә таба хәрәкәтләнделәр. Дәүләтгәрәй абзый кул селтәп аларга туктарга кушты. Бу яктагылар туктагандай иткәч, үзе алгарак чыкты һәм әкрен генә елга уртасына таба борыла башлады.

Дәүләтгәрәй абзый таза иде, көчле иде, тик шулай да бөтен бер җылымны агымга каршы тартып бару аның үзенә генә авыррак иде. Йосыф әтисе белән Илгизне күзәтеп кенә барды һәм әтисенә авыр була башлагач та, агым уңаена йөзеп, Илгиз янына барып та җитте. Илгиз кулындагы бауны алар икәүләп тарта башладылар.

— Ашыкма! Күтәрмә! Төптәнрәк алып бар!— диде Дәүләтгәрәй абзый, үзенең көчле һәм җитез улын тыеп.

Шул ук вакытта ул Габделхәйгә дә ара-тирә боерыклар бирде:

— Ярга тартыгыз, ярга!— диде.

Бу вакытта инде алар елга уртасыннан узганнар һәм Габделхәйләр ягындагы комлы ярга якынлашып киләләр иде.

Шапыр-шопыр су чәчрәтеп, ярга иң элек Йосыф килеп чыкты.

— Ашыкма, ашыкма!— диде Дәүләтгәрәй абзый.

Менә ул үзе дә комлы ярга аяк басты. Болганчык су өстендә дугаланып тартылган зур челтәр — җылым челтәре авызының моңарчы су астында булган аскы өлеше күренде. Җылым авызы җыела, кысыла барды һәм шул чакны «капчык» төбендә чәбәләнгән, тыпырчынган, ялтйолт килгән эреле-ваклы кушбашлар, чабаклар, алабугалар күренеп калды. Күптән көтелгән шул тере балыклары белән, су төбеннән эләгеп кергән яшел-йөшел үләннәре, муртайган агач тамырлары һәм йодрык зурлыгыдай таш-

лары белән авырайган җылым тыгыз судан, агымнан котылып, арып-алҗып, кызу ком өстенә килеп егылды.

Җылым тартучылар, бауларын-таякларын бер читкә ташлап, барысы берьюлы диярлек балыкка ябырылдылар. Дәүләтгәрәй абзый җылымга бер күз карашы ташлап кына алды — күпме нәрсә кергәнен болай гына, читтән генә чамалады да канәгать төс белән читкә китеп барды. Балык җыюны ул тулысынча яшьләргә тапшырды. Бу эштә тәҗрибәлерәк кеше буларак, Йосыф җылымның авыр таш бәйләнгән төбеннән ике куллап тотып балыкларны, чүп-чарны җир өстенә селекте. Комлыкка эре-эре кушбашлар, алабуга, чабаклар белән бергә вак кәсәләр, ташбашлар коелды. Фидәил белән Дездемона, кызык итеп, иң элек вак балыкларны җыя башладылар.

— Аларын суга җибәрегез, суга!— диде Дәүләтгәрәй абзый.

Балыклар, койрыклары белән җиргә бәреп, югары сикерделәр һәм ничек тә суга төшеп котылмакчы булдылар. Балык күрү белән кыргый дәрт һәм аучылык омтылышы уянган адәм балалары елтыр тәнле юеш балыкларны тимер бидерәгә тутыра тордылар.

Бераз хәл җыйгач, Дәүләтгәрәй абзый икенче мәртәбә сөзеп карамакчы булды һәм җылымның бер башыннан өстерәп яңадан суга кереп китте. Җылымның икенче башыннан Йосыф белән Габделхәй килеп тотты. Аларның шулай мыштым гына дигәндәй яңадан суга кереп баруларын күреп, янә Былбыл килеп җитте.

— Мин нишлим, җизнәй? Миңа ни эш кушасың?— диде.

— Син, Былбыл, бидерәдәге балыкны саклап тор,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

Илгиз белән Фидәил балык куркытырга дип үргә йөгерделәр.

Балыкчылар бу юлы озак булашмадылар, тиз арада җылымнарын тартып чыгардылар. Монысында балык бөтенләй диярлек эләкмәде. Җәтмә төбеннән бер бәләкәй шүкә белән бер алабуга гына чыкты. Дәүләтгәрәй абзый еракта балык оясы булып тоелган тирәнрәк, аулаграк төшне дә сөзеп карамакчы булды. Сөзүен сөзделәр, ләкин балык инде киткән иде. Өченче мәртәбә җылымга берни эләкмәде. Моның шулай булырга тиешлеген Дәүләтгәрәй абзый үзе дә белә иде, әлбәттә. Тик әле булса күңеле тынычланып җитмәгән иде бугай. Хәзер инде аның, балык тотудан бигрәк, балык эләкмәвен күреп тынычланасы килә иде бугай.

— Җитеп торыр, балалар. Комсызлыкның да чиге була,— диде ул, нәтиҗә ясап.

Шуннан соң алар җылымны өстерәп читкә, тигезрәк җиргә алып чыктылар. Койрыгыннан күтәреп, төбендәге чүп-чарны койдылар да печәне чабылган җир өстенә кибәргә җәеп куйдылар. Дәүләтгәрәй абзый малайларны утынга җибәрде, үзе кәрендәс төбендәге балтасын алып учакка таган әзерләргә тотынды. Таганны җайлагач, балык чистартучы Былбыл янына килде.

— Буламы, Былбыл?— диде.

— Була, җизнәй!— диде Былбыл.

Ләкин тәҗрибәле җизнәй ничегрәк «булганын» шундук чамалап алды һәм су буена чүгәләп балык чистартышырга тотынды. Малайлар күп итеп утын алып килделәр, утыннарын булачак учак янына өеп ташладылар да үзләре су керергә йөгерделәр. Былбыл аларның җыйнаулашып килүен күреп-ишетеп торды. Малайлар су керә башлагач, күзенә төшкән чәчләрен төзәткәләп, алар ягына карап-карап алды.

— Ярар, калганын үзем карармын, Былбыл,— диде Дүәләтгәрәй абзый, аның тынычсызлануын күреп.

Балыкны чистартып бетермичә китеп бару Былбылга уңайсызрак тоелды, ахрысы.

— Мин нишлим соң, җизнәй?— диде ул, гадәтенчә.

— Су керә тор,— диде Дәүләтгәрәй абзый. Былбыл су керергә китәргәме-юкмы дигәндәй икеләнебрәк торганда алар янына йөгереп малайлар килде.

— Дәүләтгәрәй абый, атны коендырыйк әле?— диде Илгиз.

— Коендырыгыз. Шушы тирәдә генә,— диде Дәүләтгәрәй абзый, рөхсәт итеп.

Илгиздән чак кына калышып алар янына Габделхәй дә килеп җитте. Дәүләтгәрәй абзыйның сүзләрен ишетү белән ул:

— Мин — беренче!— дип кычкырып җибәрде.

— Мин — икенче!— диде Фидәил, бәләкәй абыйсыннан уздырып.

— Мин — өченче!— диде Былбыл.

Илгиз дә, аннан арттанрак килгән Йосыф та берни әйтә алмый калдылар. Бүтәннәр исләренә килеп өлгергәнче, Габделхәй болынга ат янына йөгерде, аның артыннан малайлар иярде, Былбыл иярде. Алар килеп җиткәнче бәхетле Габделхәй ат янына якынлашты, кыюланып, шулай да ипләп кенә, сакланып кына аның муеныннан, күкрәгеннән сыйпалады, тәнендәге кигәвеннәрне куалады. Атның юашлыгын күреп ул аның башыннан сыйпап алды һәм шуның белән тиешенчә дуслашты да тезгенне чиште. Элегрәк җәй көннәрендә аның колхозда

атлы эшкә дә йөргәне бар иде, атка атланып малайлар белән узышканы да бары иде. Биек ат сыртына ул элегрәк арба-фәләнгә басып атлана иде. Ләкин якында гына көнчел малайлар карап торганда, Былбыл карап торганда хәзер ул калку урын эзләп тора алмый иде инде — ике куллап ат сыртына тотынды да бар көченә югары ыргылды һәм атланып та алды.

Атка артык якын килмичә, малайлар Габделхәйне читтән генә күзәтеп тордылар. Алар аны су ягына китәр дип көттеләр һәм ул атлангач та, юл биреп, шундук читкә тайпылдылар. Ләкин Габделхәй болын ягына борылды һәм очынып, сөенеп, еракта́гы әрәмәләр ягына элдерде. Малайлар аның артыннан кычкырып, шаулашып калдылар. Тавышлар ерагая башлау белән ул кире борылды һәм шатлыктан «әһә-әй!» дип кычкыра-кычкыра, Бүәгә якынайды.

Малайлар аны яр буенда көтеп торалар иде.

— Атта бик шәп чабасың икән син, Габделхәй!— диде Былбыл, мактап.

Бу минутта Габделхәйгә бүтән берни дә кирәкми иде. Ул җиңүче, ул бәхетле иде. Су янында ул җиңел генә сикереп төште һәм эре генә:

— Кем икенче?— диде.

— Мин икенче!— диде Илгиз.

— Юк, мин!— диде Фидәил.

— Фидәил икенче!— диде Былбыл да, Фидәилне яклап.— Син, Габделхәй, тәртипне бозма — без бит кычкырдык инде.

— Дөрес, кычкырдык,— диде Габделхәй.— Хәзер — Фидәил, аннан — Былбыл.

— Хәзер — мин, хәзер — мин!— диде Фидәил һәм сул аягы белән тезгенгә басып, үрмәләп диярлек ат сыртына менеп китте.

Габделхәй аңа арттан булышып торды. Фидәилнең дә олы абыйсы кебек болын ягыннан һай-һулап чабып киләсе килде. Ләкин шул чакны Дәүләтгәрәй абзыйның тавышы ишетелде.

— Атны интектермәгез, балалар,— диде ул.— Суда гына йөртегез.

— Ярар, ярар, Дәүләтгәрәй абый,— диде Габделхәй, атны су ягына борып.

— Җибәр! Мин — үзем!— диде Фидәил, атка атланып алгач та.

Абый кеше аның кычкыруын колагына да элмәде. Йосыфның читтә булуыннан файдаланып, ул үзен атның тулы хуҗасы итеп тойды. Җитәкләгән килеш атны бераз су эчендә йөртте дә Фидәилгә төшәргә кушты. Фид-

әил карышты, аяк-кулларын селтәде. Габделхәй сүз тыңламас энесен аттан тартып төшермәкче булган иде, малай чәрелдәп кычкырырга тотынды.

— Ярар, утыр шунда кичкә кадәр,— диде абый кеше. Ачуланып ул энесенә су сибәргә тотынды. Шуны гына көтеп торган кебек, көлә-көлә Дездемона да Фидәилгә су сибәргә кереште.

— Атка да сибегез, атка да!— дип кычкырды Габделхәй.

Барысы да төрле яктан атка су сибәргә тотындылар. Башкаларга караганда үзен остарак, тәҗрибәлерәк санап, Габделхәй атның әле бер ягына чыкты, әле икенче ягына чыкты, аның әле янбашын, әле күкрәген юды. Башкалар да аннан күрмәкче атны юындырырга, сыларга-сыйпарга тотындылар. Агымга каршы күкрәген куеп, елга уртасындарак басып торган кара бия үзе тирәсендә чыр-чу килүчеләргә карангалап, колакларын шомартып, чиксез рәхәтлеккә бирелеп тик торды.

Ат белән мавыккан арада, Фидәилгә беркем игътибар итмәде. Ат өстендә тик утыру аның үзенә дә күңелсез була башлады, ахрысы. Артык шауламыйча, шыпырт кына шуып төште дә башкалар кебек су сибәргә керешеп китте. Шуны гына көтеп торган Габделхәй Былбылга ым какты.

— Әйдә, атлан!— диде.

— Ничек атланырга соң моңа?— диде Былбыл, атның кай җиренә тотынырга да белмичә.

— Менә шулай ике куллап җилкәсенә тотын,— диде Габделхәй, өйрәтеп.— Аягың белән минем кулга бас.

Өйрәткәнчә, Былбыл атның калку җилкәсенә тотынды, сул аягы белән Габделхәйнең уң кулына басты да бар көченә талпынып җибәрде. Габделхәй аны табаныннан тотып югары күтәргәндәй итте. Былбыл атка шактый җиңел атланды. Ләкин аның атлануы үзенчә булды. Ике аягын да атның сул ягында калдырып, атның биленә җайлап утырды да сөенечтән көлеп җибәрде.

— Нык тотын. Ике куллап тотын,— диде Габделхәй.

Атның алдына чыгып ул әкрен генә кузгалып китте. Куркыпмы, шатланыпмы, Былбыл җиңелчә генә кычкырып җибәрде. Шундук бер яктан Йосыф, икенче яктан Илгиз килеп җитте.

Су эченнән бара торгач, утырган урынында Былбыл җайлаша төште, тезгенне үз кулына алды да кыюланып:

— Җибәрегез, җибәр! Үзем!— дип кычкыра башлады.

«Үзем икән, үзем» дип уйлады Габделхәй һәм йөгәнне ычкындырып читкәрәк чыкты. Шул чакны ул Фидәилнең, ат койрыгына тагылып, арттан йөзеп килүен күреп алды.

— Борыл! Ярга таба борыл!— дип кычкырды ул Былбылга.

Былбыл көлә-көлә һаман эчкәрәк, тирәнгәрәк керә барды. Фидәил яхшы йөзә белми иде. Абый кеше Фидәилне ат койрыгыннан куалап җибәрмәкче булды. Фидәилнең чәрелдек тавышын ишетеп барысы да артларына борылып карадылар.

Малайлар Фидәил тирәсендә ыгы-зыгы килгәндә, Былбыл ат өстеннән шуып төште дә суга чумып юк та булды. Күпмедер вакыттан соң су астыннан килеп чыкты, башын калкытты, битендәге суны сыпырып төшерде һәм Габделхәйне күреп елмайды да «әйдә, ку!» дигән сыман дусларга кул болгады.

## XIV

Былбыл үргә, ауган агачлар ягына йөзде. Анда никтер бик куркыныч сыман иде. Тирәндә, су төбендә ауган, егылган агачлар арасында нindидер ят һәм куркыныч нәрсәләр бардыр кебек иде. Былбылның берни уйламыйча нәкъ шул якка таба йөзеп баруы Габделхәйне шомландырып куйды. Аннан соң ул аны ерак йөзә алмас, хәлсезләнер дип тә уйлады. Былбылда исә бернинди хәлсезлек галәмәте сизелмәде — ул бик тиз һәм тигез йөзде. Габделхәй, никадәр кызу йөзмәсен, һич тә аңа якыная алмады.

Тиздән Былбыл ауган агачлар турысына җитте, ауган агачларны узып китте, Габделхәй исә һаман арттан өстерәлде. Алда икенче төрле ярлар, икенче төрле күренешләр ачылды. Уң якта куе таллык башланды, сул якта язгы ташудан соң утырып калган озынча комлыклар күренде.

Комлы ярга кадәр ничек тә куып җитмәкче булып, Габделхәй бар көченә йөзәргә тотынды. Бермәлне ул кызга шактый якынаеп калды. Былбыл артына борылып күреп алды һәм үчекләшкән сыман:

— Ник каласың? Калма!— дип кычкырды. Габделхәйгә агым бу турыда көчлерәк сыман тоелды.

Шулай да ул бөтен көчен эшкә җигеп алга ыргылды. Ара бераз кыскара төште.

— Җитәм, барыбер җитәм!— диде ул, җилкенеп.

Былбыл көлде, чалкан әйләнде дә матур беләкләрен алмаш-тилмәш хәрәкәтләндереп бернинди көчәнүсез диярлек кызулый башлады. Габделхәйнең эче жу итеп китте — ул үзенең алай ук кызу йөзә алмаганлыгын танырга мәҗбүр булды.

— Туктале! Мин сине!— диде ул, ерагая барган кызга янаган булып.

Ләкин аның янау тавышы бик көчсез булып чыкты, хәтта үзенә дә ныклап ишетелмәде. Ара ерагайганнан ерагайды. Габделхәй хурлыклы рәвештә артка кала барды. «Юкка бәйләндем»,— дип уйлады ул, пошынып. Аның хәзер кызны куып җитәргә дә, барысына кул селтәп кире китәргә дә көченнән килмәде. Кояшлы көн кинәт караңгыланып калды, яр буендагы таллыклар, комлыклар күренмәс булды.

Шул чакны ул Былбылның сулга — елганың уң як ярына борылуын күреп алды. Менә ул сай җиргә җитте, су төбенә басты да елмаеп Габделхәй ягына карады. Аның шундый эчкерсез елмаюын күрү белән, судан килеп чыккан тере балык сыман, әкияттәге су кызы сыман елкылдап, нур чәчеп торган сылу тәнен күрү белән, искиткеч бер могҗиза булып, яшь җегетне яңадан көч-куәт һәм омтылыш биләп алды. Үзенең котылуына сөенеп ул шулай ук ярга таба борылды.

Комлыктан читтәрәк, арырак тал куаклары күпереп утыра иде. Яр буе тын һәм аулак иде. Түбәндә, ауган агачлардан арырак, ат коендыручыларның чыр-чуы ишетелә дә, баш өстендә очып йөргән ялгыз акчарлакның чи-чи дигән борчулы тавышы ишетелә иде. Монда аның оясы, ояда бала чыгарырга утырган дусты бар иде бугай. Югарыдарак, тоташ яшел урман белән капланган калкулык өстендә, төшлеккә якынлашып килүче кояш кыздыра иде.

Былбыл сай җирдә беравык басып торды, Габделхәйнең дә ярга борылуын күреп, коры җиргә чыкты һәм беркем аягы басмаган чиста ком өстенә ауды.

— Уф, арыдым!— диде ул якында, үзе янында Габделхәйне күреп. Аннан соң, үзенең аннан яхшырак йөзүе өчен гафу үтенгән сыман һәм шул ук вакытта бераз гына мактанасы килеп, әйтеп куйды: — Мин бит Агыйделдә үскән,— диде.

Габделхәй аның сүзләренә бөтенләй диярлек игътибар итмәде. Арып, хәлсезләнеп ул да комга ауды. Былбылның сул ягына, бик якынга ауды һәм үзенең ни сөйләгәнен үзе дә рәтләп аңламастан:

— Әһә! Тоттыммы?!— диде.

Былбыл комда йөзтүбән капланып ята иде. Авырайган юеш беләген Габделхәй тупас кына кыланып кызның батынкы биленә салды. Кыз тынып калды. Аның шулай тынып калуын аңсыз бала үзенчә юрап, әле генә сихри сыман тоелган батынкы, тыгыз билне үзенә таба якынайтмакчы булды. Мондый көтелмәгән әдәпсезлектән кыз аптырап калды, башын калкытты, торып утырды һәм тырма кебек авыр, җансыз кулга сугып җибәрде.

— Кагылма миңа!— диде ул, усалланып.

Аңсыз баланың оятлы йөзенә кинәт кан бәрде. Ул үзен хурланган итеп тә, хаталанган итеп тә тойды. Беркадәр вакыт йөзтүбән капланып ятты да, үкенү сыман бер нәрсә тоеп, хатасын уенга әйләндермәкче булып, болагайланып кызның юеш тәненә кайнар ком сипте. Ләкин эш узган иде инде — кырылган күңелне ком сибеп кенә төзәтеп, хатаны уенга әйләндереп булырлык түгел иде.

Былбыл атылып аягына басты һәм берни әйтмичә, горур төстә, дошманнарча, үпкәләгән сыман читкә китеп барды. Габделхәй, оятлы йөзен кая куярга белмичә, кайнар комга капланды. Шулай да сыңар күзе белән генә ул чибәр кызның яртылаш комга буялган матур аякларын, комлы үкчәләрен, сары җирлеккә кызыл чияләр төшерелгән тыгыз тукымадан тегелгән һәм сылу тәнне йомырылап кысып торган тар, кыска киемен, күкрәкчәсен күреп калды. Ул аның яр буендагы комнарны шыгырдатып атлавын, аннары суга керүен, йөзеп китүен ишетеп ятты.

Аяз күктә кояш көлде, елга өстендә чи-чи килеп акчарлак көлде, комлы ярны, таллыкларны юып, көлә-көлә серле Буә акты. Мәсхәрәгә калган малай-җегет берни тоймады, берни сизмәде. Аның өчен бөтен нәрсә юкка чыкты. Әйтерсең ул бар дөньядан аерылгандай булды. Дөресрәге, якты дөнья, тере дөнья искәрмәстән аннан баш тартты. Бер нәрсәнең кызыгы, мәгънәсе калмады. Күкрәгендә авырттырып, ачыттырып бары оят һәм хурлык кына торып калды.

Шулай онытылып ята торгач, мәңге үлмәс мин-минлек кинәт башын калкытты. «Китсен! Бик кирәге бар иде!»— дип уйлады ул, пычракка салып тапталган дәрәҗәсен акламакчы булып.

Китсен! Китә бирсен! Кем соң ул шул кадәр? Бер дә әллә кем түгел әле. Бер кыланчык шунда. Ул киткәннән дөнья җимерелмәс. Кайтып китсен үзенең Уфасына. Бүген үк китсен — ул киткәч, ичмасам, тынычлап яшәргә булыр.

Йөзтүбән капланып ул озак ятты. Кымшанмыйча, кузгалмыйча ятты. Берзаман аның күңеленә: «Югалтырлар, борчылырлар, шикләнерләр»,— дигән уй килде. Аннан соң үтереп ашыйсы дә килә башлады. Күрәсең, төш җиткәндер.

Тукмап ташлагандай хәлсез тәнен көчкә күтәреп, ул аягына басты, суга керде, тәнендәге комнарын сыпырып төшерде дә чумып алды. Баштанаяк бөтен тәнендә шифалы суның иркәләвен тойгач, аңа бераз җиңеләеп китте. Аның килгән юл белән кайтасы килмәде. Нишләптер ул анда — бая гына китеп барган яр буенда — малай-

ларны йә булмаса Уфа кызын очратыр сыман тоелды. Аның хәзер беркем белән очрашасы килмәде. Ул туп-туры Бүәнең икенче ягына чыкты, таллык җырып яр өстенә менде һәм шәрә тәнен ботак-сатакка, каты үлән сабакларына сыдырттырып әрәмәлек арасыннан китеп барды.

Ул ашыкмады, шулай да туктап та тора алмады. Аны хәзер кемдер әйдәп, җитәкләп алып бара сыман тоелды. Яр буенда, ат коендырган төштә һаман тавышлар ишетелде. Шул тавышлар арасыннан Габделхәй үзе өчен хәзер чит булган, дошман булган теге кызның тавышын тотып алмакчы булды. Анда аның тавышы ишетелмәде. Аның борынына кинәт төтен исе килеп бәрелде. Барган юлыннан чак кына уңга каерылып ул туры учакка таба атлады.

Учакка җитәр-җитмәс, якында гына, куе шомырт куаклары артында кемнәрнеңдер әкрен генә сөйләшеп утыруларын ишетеп ул туктап калды. Куак артында сөйләшеп утыручылар баштарак кына аңа «кемнәрдер» булып тоелды. Аларның кемнәр булуын ул бик тиз аңлап алды. Ләкин әлеге «кемнәр», бик аңлаешлы сүзләр сөйләсәләр дә, шулай да аларның кем, нәрсә турында сөйләшкәннәрен тиз генә төшенеп җитә алмады. Сүз арасында ул үзе өчен барлык сүзләрдән якынрак «Габделхәй» дигәнне ишетеп калды. Аның шундук колагы үрә торды.

«Габделхәй»не инәсе әйтте. Ул аны бик нык кайгырып-борчылып әйтте. Дәүләтгәрәй абзый белән Фәрханә апа ни өчендер аны юатырга, ниндидер ышанмастай нәрсәгә ышандырырга тырышалар сыман тоелды.

Инәсе тормышның авырлыгыннан зарланды: «Котдус исән булса»,— диде дә төртелеп туктап калды. Аның тавышында күз яше сизелгәндәй булды.

— Исән булырга да мөмкин, Шәмсебанат,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Сугыш бит ул!..

Габделхәй шуннан башкасын ишетмәде. Олыларга күренәсе килмичә ул артына чигенде, читкәрәк китте. Инәсенең тормыш авырлыгы турында, аттай өч малайны, өч тамакны туйдырырга, аларнын өстен-башын карарга кирәклек турында Фәрханә апалар, Дәүләтгәрәй абзыйлар белән сөйләшеп утыруында бернинди яңалык юк иде. Әтисе Котдусны искә төшерүендә дә бернинди яңалык юк иде. Бик нык кайгырган, борчылган чакларында ул һәрвакыт диярлек шундыйрак сүзләр сөйли. Әледән-әле үзенең Котдусын искә төшерә, бергә булган чакларын, кайчандыр бик күптән әйткән сүзләрен кабатлый. Элегрәк мондый искә төшерүләр, күз яше агызып алулар еш кабатлана иде. Пособие мәсьәләсендә военкоматка барып кайтканнан соң, инәсенең кайбер сүзлә-

реннән Габделхәй шуны аңлады: Котдус Мөхетдинов үлмәгән, ул, ахрысы, теге якка качып киткән. Әлегә бу бик үк билгеле түгел, шулай да тикшерелә дигәннәр бугай военкоматта. Үлгәнме, качканмы икәнлеге ачыкланганчы пособие туктатылып тора дигәннәр, ахрысы, аңа.

Әнә алар шул турыда сөйләшеп утыралар. Ничектер сагаеп, шомланып һәм серле итеп сөйләшеп утыралар. «Исән булырга да мөмкин...» Ничә ел инде алар аның шулай исән булырга да мөмкин булуына ышанып яшиләр! Шул ук сүзләрне аларга теләсә кем әйтә. Теләсә кем генә түгел, Дәүләтгәрәй абзый да әйтә. Әллә соң ул аның кайдалыгын беләмикән? Исән булса, кайда булыр аның... аларның этиләре? Гаҗәп. Исән булса, көтмәгәндә кайтып төшсә нинди шәп булыр иде! Бу турыда уйлавы да куркыныч. Бу шундый зур һәм серле нәрсә. Исән булса... Исән булган кеше үзенең балалары янына, хатыны янына, үзенең иленә, өенә кайтырга тиештер ич инде... сугышка чаклы, сугыш вакытында кайда гына, кем генә булуына да карамастан үз җиренә кайтырга тиештер ич?!

## XV

Чигенә барып, ул яңадан Бүә ярына барып чыкты. Комга утырды, суга керергә дә, кермәскә дә белмичә, күрмәс күзләре белән уйга калды.

Берзаман ул якында гына үзен эзләүләрен ишетеп алды.

— Абый!— дип кычкырды Илгиз.

Шулай кычкырып ул ары китеп барды. Габделхәйнең һаман үтереп ашыйсы килде.

— Абый!— дип кычкырды тагын икенче яктанрак Илгиз.

— Ни булды, ник кычкырасың?— диде абый кеше, тавыш биреп.

— Кая булдың, нишләп йөрисең?— диде Илгиз, абыйсы янына килеп.

— Йоклап киткәнмен,— диде Габделхәй, ялганлап.

Икәүләп алар учак янына килделәр. Табынны ялгыз карама төбенә, күләгәле җиргә әзерләгәннәр иде. Барысы да чабылган болын өстенә җәелгән киң ашъяулык тирәсенә түгәрәкләнеп утырганнар да кемнедер көтәләр иде сыман. Йосыф белән Фидаил янында Габделхәй өчен дип урын калдырылган иде. Ул туры шунда барып утырды. Уфа кызы Йосыфның икенче ягында утыра иде. Габделхәй аның ягына карамаска тырышты һәм килеп утыру белән, аны-моны сораштырмыйча, кашыкка тотынды.

Ашаганда аңа беркем игътибар итмәде. Аякларын читкәрәк сузып җибәреп, табынга ничектер яны беләнрәк утырган Фәрхәнә апа гына беркадәр вакыттан соң:

— Нишләптер безнең Габделхәй тынып калган әле,— диде.

Барысы да Габделхәй ягына борылып карадылар.

— Балык ашаганда сөйләшергә ярамый — балык кача,— диде Габделхәй.

— Ашаганда качмый инде ул!— диде Дездемона.

— Төшереп җибәрсәң кача,— диде Фидәил.

— Габделхәй дөрес әйтә, балалар,— ашаганда сөйләшергә ярамый,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Ашаганда сөйләшсәң, ач каласың.

Балык шулпасы тәмле булды. Изелеп пешкән балык үзе шулпадан да тәмлерәк булды. Ашап туйгач, корымланган бидерәне су буена алып төшеп, ком белән ышкып юдылар да учакка чәй кайнатырга куйдылар. Кара карагат яфрагы, мәтрүшкә салып кайнатылган чәй дә бик тәмле булды. Чәй эчәр алдыннан Фәрхәнә апа һәркемгә үзләре җыеп алып килгән җиләктән, карагаттан өлеш чыгарды. Дәүләтгәрәй абзый исә киндер чүпрәккә төрелгәнербөтен ипине кулына алды да үткер чалгы пычагы белән кисәргә әзерләнде.

— Кибән башы — үземә!— диде Дездемона.

— Юк — миңа!— диде Фидәил.

— Мин элек әйттем — үземә!— диде Дездемона.

— Син көн дә ашыйсыңдыр әле кибән башын,— диде Фидәил, үпкәләп.

Табын янында уңайсыз тынлык урнашты. Шәмсебанат апаның йөзе кызганыч булып үзгәреп китте.

— И, улым!..— диде ул, кече улын шелтәлисе килеп, ләкин аның шелтәсе шелтә булып түгел, әрнү булып ишетелде.

Габделхәй энесенең кабыргасына төртеп алды. Хәтере калып, Фидәил җыларга ук кереште.

— Солдат кеше җылап тормый инде ул, Фидәил,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Солдат кеше җылап торса, нимес аны ата да үтерә.

Фидәил шып булды. Өлкәннәр бер-берсенә карашып алдылар. Дәүләтгәрәй абзый кулындагы ипине тәгәрмәч кебек итеп әйләндергәләде дә, Фидәил белән Дездемонага карап:

— Мин кычкыртмадым. Сез кычкырткан дөрес түгел. Кемгә элек?— диде. Соңгы сүзен ул кисәк кенә әйтте һәм аның «кемгә элек» дигәне «кемгәлек» булып ишетелде.

— Миәлек!— диде солдат буласы Фидәил.

— Миәлек!— диде Дездемона да, арткарак калып. Үзен алдаганнарын ул күреп торды, аның да хәтере калды, ләкин этисенең сүзенә каршы килергә, үпкәләргә, җыларга шулай да кыюлыгы җитмәде.

— Беренче кибән башы — Фидәилгә!— диде Дәүләтгәрәй абзый, түгәрәк ипинең бер кырыен кисеп алып.— Икенче кибән башы — Диздекәйгә!

Дәүләтгәрәй абзый түгәрәк ипинең икенче кырыен да кисеп алып, кибән башны кызына бирде. Диздекәй яшь аралаш елмаеп җибәрде. Балаларның куанычын күреп, олылар җиңел сулап куйдылар.

Чәй эчеп бераз ял итеп алгач, хатын-кызлар табак-савытларны җыештыра башладылар һәм барысын да су буена алып төшеп шалтыр-шолтыр китереп юарга, ышкырга тотындылар. Эшләре беткәч, Шәмсебанат апа белән Фәрхәнә апа, буш бидерәләрен күтәреп, яңадан әрәмәләр ягына китеп бардылар.

Ул арада кояш, төшлекне узып, баю ягына авышты. Көн сүрелә, күләгәләр озыная һәм икенче якка күчenә башлады. Кичке якта Дәүләтгәрәй абзый тагын бер мәртәбә җылым салып карамакчы булды. Бу юлы су комлатучылар да, җылым тартучылар да, тук булганга, күрәсең, артык тырышмыйча гына, эленке-салынкы гына кыландылар. Шулай да балык кермәде түгел, керде. Дәүләтгәрәй абзыйның тәмам күңеле булды. Гадәтенчә, вак балыкларны ул алып тормады — биш-алты эре кушбаш белән алабуганы, бер-ике шүкәне алды да калган барысын суга койды.

— Икенче килүгә үсеп торыгыз!— диде коелган балыклар артыннан.

Күләгәләр озынайганнан-озынайды. Тирә-якта су исе, яшел үлән, тал исе килә башлады. Күләгәле җирләрдә генә түгел, ачык, кояшлы җирдә дә чебен-черки күбәйде. Су өстеннән куышып, узышып энә караклары очты, елганың әле бер төшеннән, әле икенче төшеннән чулт-чулт итеп көмеш балыклар сикерде.

Дәүләтгәрәй абзый, өйгә алып кайтасы балыкларын юеш печәнгә төреп, капчыкка салды да яхшылап кәрендәс төбенә урнаштырды. Шуннан соң кибәргә җәеп куйган җылымны селеккәләп, яңадан чүп-чардан чистартты һәм җайлап кына җыя башлады.

— Бар әле, тегеләрне чакырып кил,— диде ул үзе янында булашкан Йосыфка.

Йосыф кузгалып китәргә өлгергәнче тегеләренең үзара сөйләнеп су буена таба кайтып килүләре күренде. Ләкин алар туры кәрендәс янына килмәделәр, кыеклатып елга

буена төштеләр дә, башларындагы яулыкларын салып, битләрен-кулларын юдылар.

— Бүә буена килеп су да кереп булмады инде,— диде Фәрхәнә апа, үкенгәндәй итеп.

— Керегез. Тиз булыгыз,— диде Дәүләтгәрәй абзый, аларның сөйләшүен ишетеп.

— Әйдәле, Шәмсебанат,— диде Фәрхәнә апа, тәвәккәлләп.— Су да керми китсәң гөнаһлы булырсың.

— Әйдә алайса,— диде Шәмсебанат апа.

Алар комлы яр буйлап түбәнгәрәк китеп бардылар.

— Мин дә сезнең белән барам!— диде Дездемона.

— Мин дә!— диде Былбыл.

Хатын-кызлар су керергә китеп баргач, ир затындагылар юлга әзерләнә башладылар. Бер ярты сәгатьтән бөтенесе әзер булды — ат җигелде, су керүчеләр кире килделәр. Фәрхәнә апа белән Шәмсебанат апа парлашып кәрендәскә утырдылар, алар арасына Дездемона кысылды. Йосыф дилбегә тотып ат башына утырды. Калганнар җәяүләп арттан кайтырга тиешләр иде. Ат кузгалып китәр алдыннан гына Былбыл кәрендәс артына, җылым янына килеп утырды.

— Мин монда кайтам,— диде ул.

— Син... кайтасыңмыни?— диде Фәрхәнә апа, артына борылып, гаҗәпләнеп.

— Кайтам,— диде Былбыл.

— Мин дә утырам,— диде Фидәил дә, Дездемона сыман инәсе янына елышмакчы булып.

— Алайса, болай итик,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Син, Фәрхәнә, ат тотарсың. Йосыф үз урынына артка утырыр, аның урынына Былбылны утыртырбыз да... Фидәил дә утырыр.

— Алай итмик, әти,— диде Йосыф.— Кичүне чыгарып куйыйк та әниләр үзләре кайтып китсеннәр. Иң кыены кичү. Без җәяүләп кайтырбыз.

— Дөрес, улым,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Урыксурык ат интектереп йөрисе юк.

— Әйдә, алайса, ат башына утыр,— диде Фәрхәнә апа, Былбылга эндәшеп.

— Ярар инде, кичүгә кадәр шушында гына барырмын,— диде Былбыл, теләр-теләмәс кенә.

Фәрхәнә апа кысташып тормады, алдына борылды да дилбегәне селтәп җибәрде. Көне буе ашап, ял итеп көч җыйган кара бия җиңел генә кузгалып китте.

— Кичүдә безне көтеп торыгыз!— дип кычкырды Йосыф.

— Көтәрбез, көтәрбез!— диде бәхетле Фидәил, кул болгап.

— Көтәрбез, көтәрбез!— диде Дездемона да.

## Дүртенче бүлек

### I

Онытыла язган күңелсез нәрсә өйгә кайткач яңадан искә төште — каны саркып торган чи яра булып, ачыттырып сызлый башлады. Бүтән вакытта читтән кайтып кергәч һәр почмагы, һәр чүпрәге шундый кадерле булып тоела торган җылы өй эче Габделхәйгә бүген котсыз булып күренде. Бу кысан, тәбәнәк һәм ярлы өйдә анын бер минут торасы килмәде. «Авылга китәргә кирәк. Картыйларга, картәтәйләргә!»— дип уйлады ул, тормышка ашмастай нәрсә турында хыялланган кебек. Аңа хәзер киңлек, иркенлек һәм җирдәге оҗмах бары анда гына сыман тоелды.

Ләкин хәзер вакыт соң иде, хәзер генә берничек тә авылга китеп барырлык түгел иде. Үз-үзенә урын таба алмыйча ул урамга чыкты һәм станция ягына китеп барды. Анда яктырак, күңеллерәк. Анда авылдагы кебек киңлек-иркенлек юк, ләкин анда һәрвакыт хәрәкәт сизелә. Әле бер яктан, әле икенче яктан дөбердәп поездлар килә. Вагоннарга, әчкелтем ят исләргә, ят кыяфәтле кешеләргә ияреп ниндидер башка илләрнең-җирләрнең бу яктагы караңгылыкка, тарлыкка охшамаган дәртле рухы, омтылышы килә. Үзеннән-үзе аларга ияреп, вагоннарга тагылып-тотынып китәсе, алар күргән киңлекләрне, иркенлекне һәм бәхет илен күрәсе килә.

Ләкин бүген хәтта монда да Габделхәйгә әллә ни күңелле булып тоелмады. Пассажир поезды килергә әле иртә иде, станциядә — читтәге юлларда арыган-алҗыган кыяфәттә буш күмер вагоннары гына тезелеп тора иде. Аннан соң тонык кына ут балкыган вокзалдагы кешеләр дә бүген нишләптер күңелсез һәм йончылган булып күренделәр. Балалары, капчыклары, төенчекләре белән озынча утыргычларда йокымсырап утырган кешеләрне күргәч, Габделхәй нишләптер Сәкинәне исенә төшерде. Сәкинә аңа хәзер бик-бик кызганыч булып тоелды. Бит алар очрашырга сүз куешканнар иде! Менә хәзер кинәт кенә, искәрмәстән генә очрашып куйсалар нинди шәп булыр иде! Уфа кызына үч итеп, ачу итеп. Аларның Сәкинә белән икәүләшеп көлешә-көлешә узып киткәнен читтән күреп калса, Уфа кызы тагын да шәбрәк булыр иде. Икенче көлмәс, кыланчыкланмас. И-и! димәс, их! димәс. Борыны бик тиз салыныр иде! Шыт! Шул кирәк аңа. Монда килеп әллә кем булып йөрергә кем булган шулкадәр?!

Шулай үзалдына уйланып-хыялланып ул караңгы урамнардан Сталин клубы ягына атлады. Анда инде кино

башланган. Урам якта кинога керә алмый калган малай-шалай гына җыелып тора. Һаман шул «Иван Грозный»-ны күрсәтәләр икән.

Габделхәйнең урысча кычкырып сөйләшкән татар малайлары янында туктап торасы килмәде. Ул туры үзләренең мәктәбе ягына китеп барды. Мәктәп тирәсен әйләнеп үтте дә кире үзләре ягына борылды. «Сау бул инде, сау бул, мәктәп»,— дип уйлады ул. Кабат монда килеп булмас. Килсәң дә кызыгы булмас. Нинди кызганыч — күпме гомер шунда үтте, күпме шатлык-кайгы шушында туды. Сау бул, тагын килеп булмаса, сау бул инде, кадерле мәктәп!

Икенче көнне таң атып әтәчләр кычкыра башлау белән ул уянып китте. Менә тагын яңа бер көн башланды. Инәсе эшкә иртүк китә иде. Янтыкка кайтып килү турында аның белән элегрәк тә сүз булган иде инде. Укуын бетергәч тә ул кайтып, андагыларның хәлен белеп килергә тиеш иде. Авыл турында әйткәч инәсе сөенде генә. Тиз-тиз генә күчтәнәч төйнәп бирде, анда кайткач кемгә нәрсә әйтергә кирәген исенә төшерде. Аннан соң әйтеп куйды: «Әллә Фидәилне дә аласыңмы үзең белән?»— диде. Габделхәйнең үзе генә барасы килде. Инәсе кыстап тормады, күп итеп сәлам әйтергә кушты да эшенә китәргә ашыга башлады.

Янтыкка ике юл бара иде. Аның берсе әйләнгечтән — күпер аша, икенчесе турыдан — Сакат аша, карурман аша бара. Тау менә, тау төшә. Турыдан юл куркынычрак исәпләнелә. Элек-электән монда качкыннар яткан, юлчыга юлбасарлар чыккан. Хәзер исә узган-барганны Яңавыл ышпанасы талый дип сөйлиләр.

Габделхәй турыдан китте. Озак кына ул кичәге дымлы, караңгы юлдан барды һәм күпмедер вакыттан соң кояш яктысы төшкән кичү турысына барып җитте. Яр буенда комлыкта тояк эзләре, кәрендәс эзләре ярылып ята иде. Шунда ук аяк эзләре дә күренде. «Кем эзе булыр бу?»— диде ул, җиңелчә хыялга бирелеп. Теге Уфа кызыныкы түгел микән? Юк, түгелдер. Табаны бик зур бу кешенең. Йосыфныкыдыр.

Кичәге күренешләрне яңадан искә төшереп тору Габделхәйгә йомшаклык, җебегәнлек булып тоелды, ләкин ул күренешләр — якты көн, елга, комлык һәм сихри гүзәллек аның күз алдыннан китмәде дә. Үзе дә сизмәстән ул көрсенеп куйды. Өстендәге барлы-юклы киемнәрен салып бергә җыеп төрде дә, инәсенең күчтәнәче белән бергә ике кулына җайлап тотты да анадан тума суга керде. Салкынча һава белән чагыштырганда су җылырак тоелды. Киемнәрен икенче як ярга чыгарып куйгач, кире килеп тирән җирдә чумып-чумып алды. Иртәнге суда коенгач җиңел һәм рәхәт

булып китте. Кичәдән бирле җанын игәп, күңелен тырнап торган уйлар кул белән алгандай юкка чыкты.

Кичүдән соң юл икегә бүлендә — берсе аның кичәгенәк балык тотып ял итеп яткан болын ягына китте, икенчесе Сакат ягына борылды. Юл чатында Габделхәй киенде һәм судан, Бүәдән, кәрендәс эзләре батып калган яр буйларыннан аерыласы килмәгәндәй, беравык артына борылып карап торды да Сакат юлы белән китеп барды.

Юл буенда берән-сәрән юкәләр, балан, шомырт куаклары очрады. Аннары сөреп нарат утыртылган ачык җир башланды. Шуннан соң тоташ юкә урманы китте. Урман юлында, күләгә белән аралашып, кояш нурлары балкып-балкып алды. Агач башларында туктаусыз бал кортлары гүләп торды, һавада исерткеч бал исе, кояш нуры һәм яшел яфрак исе аңкып торды. Урман юлы, уңгасулга борылмыйча, әкрен генә югары үрмәләде.

Габделхәй ашыкмады. Әледән-әле агач башларына каранды, кошлар тавышына колак салды, бара торгач кинәт артына борылды да, кемнедер күрергә теләгән сыман, ботаклар арасыннан карап тора башлады. Анда... артта калган кичүгә якын җирдә, кичәгенәк балык тотып яткан яр буенда чыннан да кемдер торып калган сыман булып, «кемдер» һаман аны күзәтә сыман булып тоелды. Иң гаҗәбе шул: Габделхәй кебек, ул да моңсу, ул да сагышлы сыман иде.

Тау өстенә менеп җиткәч аяк атлавы җиңеләя төште. Урман сирәгәйде, юкә агачларын сарып алган баллы гүелдек тоныкланган сыман тоелды. Менә озакламый юкә урманы да бетте, юкә урманыннан соң берән-сәрән чикләвек куаклары очрап куйды. Чикләвек куаклары да артта калгач исә яздан бирле ат тоягы, арба тәгәрмәче күрмәгән тар юлның ике ягында да бодай басулары җәелеп китте. Бодай инде баш кыскан. Тигез, куе. Сизелер-сизелмәс кенә искән талгын җилдә туктаусыз тирбәлеп, чайкалып утыра. Нинди хозур, нинди күңелле!

Бодай җире еракка-еракларга сузылды. Баш өстендә тургайлар сайрады, юлда чыпчыклар чыр-чу килде. Кеше якынлашуын күреп, чырылдап, пырылдап алар шундук көтүләре белән күтәрелеп киттеләр. Кайдадыр якында гына, бодай арасында, чалгы чарлаган сыман тавыш чыгарып тартар кычкырды. Ялан табаннарың белән кайнар җирне тою, күз алдында төпсез зәңгәр күкне күреп бару, шыштырдаган-кыштырдаган, безелдәгән һәртөрле тавышларны ишетеп бару күңелле, искиткеч күңелле һәм рәхәт иде.

Ләкин күңелле, рәхәт юл да озакламый арыта, ачыктыра башлады. Кул очындагы җиңел төенчек авырай-

ганнан-авырайды. Барыннан да бигрәк, ашыйсы килде. Хәер, ашыйсы килүнең туганнан бирле бетеп торганы да булмады, ахрысы. Иртән ул үзләрендә берни капмады диярлек. Авылга барып җитсәм, туйганчы салкын катык белән кайнар бәрәңге ашармын дип уйлады. Шул гадәти кечкенә уй тора-бара беркайчан тормышка ашмастай хыялга әйләнә башлады.

Күп тә үтмәде, еракта, Янтык ягында — зәңгәрсу рәшә диңгезе артында әкияттәге сыман бәләкәй генә, матур гына өйләр, бәрәңге бакчалары һәм күккә ашкан биек тупыллар күренде. Елның кайсы гына вакытында булмасын, һәрвакыт кайнар бәрәңге белән салкын катык ашый торган һәм шунлыктан дөньяда иң бәхетле исәпләнергә хакы булган кешеләр менә шунда яшәп яталар иде инде.

## II

Ерактан шундый матур һәм төзек булып, муллык, байлык һәм гүзәллек дөньясы булып тоелган Янтык якына барган саен төссезләнә барды. Юлдан уң якта, авыл читендә «Алга» колхозының ат фермасы таралып ята. Ат фермасы басылып, тишелеп беткән салам түбәле берике озын, тәбәнәк корылмадан, киртәләнеп алынган утарлардан һәм йөз еллык тирес-салам өемнәреннән гыйбарәт иде. Киртә буенда тышкы якта колынлы бия ашанып йөри дә, юл буенда Сакат ягыннан килүче ялгыз кешегә исе китеп, ала бозау карап тора иде.

Габделхәй җимерелеп, баганалары кыйшаеп беткән һәм атлы арба узып китәрлек кенә киңлектә яртылаш ачып куелган капкадан авыл урамына килеп керде. Чын мәгънәсендә әле бу урам да түгел, бу бары бер тыкрык кына иде. Кайчандыр биш-алты йорт балкып утырган тыкрыкта хәзер нибарысы бер йорт утырып калган иде. Тыкрыкның ике ягыннан да киртә сузыла; киртәнең урта бер җирендә, уң якта, ике баганалы иске капка караеп утыра, капка артында исә уртасы чокырланып торган иске өй урыны ыржаеп ята иде. Ишегалдында, дөресрәге, кайчандыр ишегалды булган ташландык җирдә, черек салам түбәле кәҗә абзарыннан, иске тирес, салам, чүп-чар өемнәреннән башка берни юк; бәрәңге бакчасын әрем, алабута күмеп киткән; өй артындагы шомырт куагын талап, сындырып бетергәннәр.

Тыкрыктагы бердәнбер исән йорт та иске һәм тәбәнәк. Йортның кыйшайган түбәсе, маңгайга төшереп киелгән солдат пилоткасы шикелле, урам якка таба чөйлегебрәк тора. Әллә шунлыктан, әллә аскы ниргәләр җиргә бат-

канлыктан, өй түбәсе өйнең үзеннән зуррак һәм биегрәк булып күренә. Ишегалдындагы каралты-кура төзек кенә, таза гына. Бакча ягында, аллы-гөлле мәк чичкәләре арасында, бер-ике умарта янында, бер башында авыр таш, тимер тәгәрмәч бәйләнгән сиртмәсен, һавада асылынып калган буш бидерәсен тотып, озын торыклы кое баганасы калкып утыра.

Төзек өйнең каршысында, тыкрыкның икенче ягында шулай ук кое сиртмәсе утырып калган. Сиртмәнең бавын кисеп алганнар, сиртмә агачында як-якка каранып олы козгын утыра. Нәкъ әкият китапларындагы кебек. Юк, фашист гаскәрләре ватып-җимереп киткән украин, белорус авылларындагы кебек. Кинода, киножурналларда, газета-журналлардагы фотоларда аларны еш күрсәтәләр. Күрсәттеләр. Габделхәй аларны күп күрде. Кое сиртмәсе янындагы яртылаш җимерелгән мич калдыгы, очы сынган ялгыз чыршы — барысы да, барысы да сугыш елы киноларындагы, фотоларындагы кебек. Тик менә күккә күтәрелгән төтен баганалары күренми дә җир өстендә аунап яткан мәетләр генә юк. Аннан соң автоматлы солдатлар да кайдадыр шул тирәдә генә качып яталардыр сыман.

Габделхәй, як-ягына карангалап, күңелсез тыкрыкны узып китте дә, тар елга аша салынган тишек-тошык күперне чыгып, олы урамга килеп керде. Уңда аны тагын бер ташландык йорт каршылады. Кайчандыр бай, купшы булган, хәзер инде тәрәзәләре аркылы-торкылы librara такталар белән кадакланган, чолан такталары каерылып алынган бу нык, таза, ләкин үле йорт яныннан узганда, Габделхәйнең күңелендә чиксез кызыксыну да, куркушомлану да уяна торган иде. Бу турыдан ул тиз-тиз генә узып китмәкче булды һәм җансыз-өнсез, әмма каберлек сыман серле истәлекләр белән тулы тәрәзәләргә, кәрнизләргә озаклап карамаска тырышты. Шул ук вакытта карамыйча да булдыра алмады. Ташландык хәлендә дә бу йорт үзенә, карата хөрмәт һәм соклану уята иде.

Элек ул Гали бай йорты булган, диләр. Гали бай заманында иген белән сату иткән, бөтен авыл халкын киендереп-туендырып торган. Анысы инде аның бушка туйдырмагандыр — монысын картый белән картәтәй генә әйтә. Алар гел элеккене мактап сөйләргә яраталар. Гали бай көз көне халыктан очсызга ашлык сатып алган да кыш көне шул ук ашлыкны Сарапулга, Илдиәнгә илтеп саткан. Бер ачлык елны бөтен авылга бушлай он тараткан, имеш. Авылдагы мәчетне дә ул салдырган, мәдрәсә тоткан, ярлы шәкертләрне үз исәбенә укыткан. Әллә чын,

әллә ялган — хәзер инде каян беләсең! Бай — бай инде ул. Революциядән соң моны кулга алганнар, хатынын, балаларын — барысын җыйнап сөргенгә озатканнар. Өйләре менә утырып калган. Гали бай йортын нишләптер җенле, ияле дип тә сөйлиләр. Гали байга баеп китәргә, имеш, өй ияләре, гаиб ирәннәр, җен-пәриләр булышкан. Җен-пәриле булганга да әле булса исән килеш утырадыр бу йорт — юкса күптән инде аны сүтеп алып утынга яккан булырлар яисә, фермага күчереп, мал абзары итеп тотарлар иде.

Бу йорт хакында Янтыкта тагын шунысын да сөйлиләр иде: Гали бай, имеш, исән икән, сугыш алдыннан качып-посып авылга кайтып киткән икән дә кайткач авыл картларына әйткән икән, имеш: минем йортны сүтмәгез, озакламый, Алла бирса, дөньялар үзгәрер, мәчет манараларын кисүчеләрнең үзләренең башлары аяк астына тәгәрәп төшәр дип әйтеп әйткән икән, имеш.

Гали бай йортыннан соң бер-ике йортны узып киткәч, Габделхәй тагын бер йортка игътибар итте. Бу теге тыкрыкта торып калган йорттан да мескенрәк, искерәк һәм таушалганрак иде. Моның да аскы ниргәләре череп җиргә баткан, түбә кыегы кемнедер сөзәргә җыенган сыман шулай ук алга сөрлеккән һәм шундый нык сөрлеккән — хуҗалар, күрәсең, чыннан да берәрсен сөзеп ташламасын дигәндәй, түбәне урам яктан нечкәрәк озын бүрәнә белән терәтеп куйганнар. Урам яктагы өч тәрәзәнең берсе дә төзек түгел: берсенең аскы өлгесенә такта кадакланган, икенчесенең бер өлгесе бөтенләй пыяласыз, өченчесе эчке яктан томалап куелган — тышкы якта ватыккитек пыяла кисәкләре генә елтырап күренә. Мөрҗәдән сыек кына булып төтен чыга, урамга балтырганлы тәмсез аш исе таралган. Әйтүләренә караганда, бу теге Хәсән күлендә япон самурайлары белән сугышта батырлык күрсәткән, орден алган, бөтен районга атаклы Мансур Хәбибрахманов йорты икән. 1941 елны Гитлер басып кергәч, Мансур Хәбибрахманов, атаклы батыр буларак, үзе теләп, беренчеләрдән булып сугышка киткән һәм шунда үлеп тә калган.

Габделхәйнең тәрәзәләргә каранып баруын өй эчендәгеләр күреп калдылар ахрысы. Шул чакны ниндидер бер хатын-кыз эчке яктан тәрәзәгә килеп капланды һәм «кем икән бу?» дигән сыман, кузгалмыйча озак кына карап торды. Мансур Хәбибрахмановның тол хатыны, ахрысы. Күрәсең, үткән-сүткәнне карап калып, әле һаман үзенең Мансурын көтәдер. Мескенкәем. Нинди кызганыч!

## III

Габделхәй картәтәләренең өе зур гына, биек кенә иде. Каралты-кура, киртә-койма нык кына, төзек кенә. Өй артларында, урам буенда зур гына урын биләп, әкәмәт зур булып, биек булып, карт, юан тупыл үсеп утыра. Аның күләгәсе бөтен урамны, бөтен ишегалдын каплап ала. Шуңа күрә монда кояш нуры төшкән җиргә караганда караңгырак та, салкынрак та тоела сыман. Урам яклары төзек булса да, ишегаллары шулай да ташландык хәлдә. Кая карама тәртипсезлек күзгә ташлана: киртә буенда калай комган аунап ята, лапас астында киселгән, туралган каен утыны таралып ята — беркемнең аны яхшылап өеп куярга кулы җитмәгән. Әллә вакыты юк, әллә хәле юкмы соң? Шунда ук, чапкычка аркылы төшеп, үткер балта тынып калган. Ишек төбендә үк диярлек, аяк астында кабыгы төшерелгән ап-ак юкагачлар аунап ята.

Габделхәй, ишегалды ягындагы сыңар тәрәзәгә карана-карана, чолан ишегенә таба атлады. Тәрәзәдә беркем күренмәде. «Өйдә юклар бугай»,— дип уйлады ул. Ләкин чолан ишеге ачык иде. Тавыш-тынсыз гына атлап Габделхәй ачык ишектән керде, өч-дүрт басмалы тар баскычтан менде һәм каршыдагы ябык ишегалдында туктап тормыйча, уңга, икенче як ишеккә таба борылды.

Фәрхәнә апаларныкы кебек, картәтәйләрнең дә йорты алты почмаклы, ике яклы иде. Тик аларның бүлмәләренә чолан яктан аерым-аерым ишек аша кереп-чыгып йөриләр иде. Бүлмәләрнең берсе җәйге як, яисә җәйге өй дип, икенчесе кышкы як яисә кышкы өй дип атала иде. Җәй көне алар, гадәттә, зуррак, иркенрәк якта торалар, кыш көне утын әзрәк сорый торган кече якка күченәләр иде. Салынган чакта аларның да йорты шулай байларча иркендә, рәхәттә яшәү өчен җайланган булган.

Кышкы якның ишеге ачык иде. Габделхәй, биек бусагадан ары узмыйча, ачык ишегалдында туктап калды. Картәтәсе, бөтен идәнне юкә кабыгы белән күмеп, артсыз урындыкта чабата ясап утыра иде. Ишектә кемдер барлыгын чамалап, ул эшеннән туктап калды, күзенә төшкән киез эшләпәсен күтәргәндәй итте дә Габделхәйгә текәлде, таныды һәм:

— Һы, Гаптелхәй түгелме соң?— диде.

Ишектә елмаеп торган үсмер җегетнең чыннан да Габделхәйме, түгелме икәнлеген тикшереп карамакчы булган сыман, картәтәй урыныннан кузгалып куйды, тезендәге бар нәрсәсен идәнгә сыпырып төшерде дә аягына басты.

— Исәнме, картәтәй!— диде Габделхәй, бусага аша атлап.

— Килдеңме?— диде карт, каешланып беткән, буын-буын булып каткан сөякчел кулын күрешү өчен сузып.

Габделхәйнең картәтәсе җитмешнең теге ягында иде инде. Бер керфеге калмаган күзләре кысылып, йомылып беткән, иске чүпрәк сыман тире каплап торган яңак сөякләре йодрыктай булып калкып чыккан иде. Кайчандыр ат кылыдай каты, куе сакал-мыегы сирәкләнеп беткән һәм хәзер аның борын астында, ияк очында элекке гайрәтле чакларыннан калган ике-өч бөртек аксыл төкләр генә тырпаеп тора иде. Картәтәйнең колак артында да шундый ук төкләр күренгәли, маңгайдан югарырак түбә өсте исә яшен ташыдай шоп-шома һәм такыр иде. Өстендәге күлмәге терсәк турысыннан, җилкә турысыннан ямалып куелган, ачык изүеннән картларча ябык һәм сөякчел тәне күренеп тора иде. Ак киндер ыштаны күлмәгенә караганда арурак күренә, ләкин гел чабата ясау белән шөгыльләнгәнлектән, тез башлары сидереп беткән иде. Аягына ул кунычы кисеп ташланган ямаулы иске киез итек киеп куйган иде.

Габделхәй өйгә керде, күреште. Шуннан соң, тоткарланып тормыйча, түргә узды, үрелеп тәрәзәдән урам якка карап алды. Ишек ачык булса да, өй эчендәге һава бөркү тоелды. Картәтәсе янында озак тормыйча ул икенче якка чыгып китте. Монда ишек-тәрәзәләр ябып куелган, аннан соң бу якта аш-су пешә, шунлыктан аш өстәлен, казан тирәсен чебен сарып алган иде.

Теге яктагы кебек, бу яктагы өй эче дә бик ярлы иде. Өйдә элеп алырлык берни юк. Казан янындагы киштәдә борынгыдан калган чаршау калдыгы эленеп тора да караулы агачта керләнеп беткән тастымал асылынып тора. Аннары ишек төбендәге агач чөйләрдә иске-москы киемсалым күренгәли. Түрдәге сике өстендә керләнеп беткән мендәргә башын ташлап, чәче мамыкка буялып беткән бер кыз бала йоклап ята. Ябылмаган тәнен, кулларын, аякларын чебен сарган.

Габделхәй селтәнеп чебенне куып җибәрде дә бала өстенә яулык сыман чүпрәк ябып куйды. Инәсе җибәргән күчтәнәчне почмактагы шүрлекнең иң югары тактасына куйгач, кире картәтәсе янына чыкты.

— Картый кая?— диде ул.

— Кем белә аларны...— диде картәтәй, дәртсез генә. Ул яңадан чабатасына тотынган иде. Аның өчен хәзер дөньяда тез өстенә сузып салынган чабатасыннан башка беркем, берни юк иде сыман.

— Җиләккә киткән бугай... балаларны ияртеп,— диде ул бераздан.— Сезнекеләр соң... тазалармы? Нишләп яталар?

— Тазалар. Сәлам әйттеләр,— диде Габделхәй.

— Каян килдең — турыданмы, күперләнме?— дип куйды тагын бераздан картәтәй.

— Турыдан,— диде Габелхәй.

— Син гел турыдан... каңсамулларча!— диде картәтәй, көлемсерәп.

## IV

Картәтәй усал, ачы телле иде. Кайбер яңа, ят сүзләрне ул үзенчә бозып әйтергә ярата иде. Аннан соң, Шәмсебант кызының «каңсамул» улы килгән саен, аны бераз чеметкәләп алудан да тартынып тормый иде. Шунлыктан Габделхәй аның белән сөйләшкәндә уйлабрак сөйләшергә һәм, гомумән, телгә-тешкә килмәскә тырыша иде.

Картәтәй исә, йончылган хәлсез кыяфәтенә бер дә туры килми торган бер җитезлек белән чабата ясавында булды — бармакларын тиз-тиз алыштырып, як-якка таралып торган шелеләрне тартып-тартып куйды, учы белән, бармак битләре белән сылап-сыйпап куйды һәм чандыр тез башында шакмакланып ак чабата күз алдында үсә барды. Шул ук вакытта картәтәй Габделхәйгә дә күз төшереп алды, бер-ике сүз белән Яңавыл турында, базар хәлләре, тегесе-монысы турында сораштырды. Габделхәйнең Яңавыл хәлләре турында да, базар хәлләре турында да сөйләшәсе килмәде. Аның барыннан да бигрәк үзе турында — үзенең унны бетерүе, аттестатында барлык билгеләрнең «отлично» булуы, Казанга укырга китәргә ниятләве турында сөйлисе килде. Картәтәсе аның быел унны бетергәнен әллә белми иде, әллә чабатасы белән артык мавыккан иде — Габделхәй сөйләргә теләгән нәрсәләр турында ул берни сорашмады.

Утыра торгач Габделхәй шулай да түзмәде, беренче булып үзе башларга булды һәм күңелендәгесен барысын да берьюлы сөйләде дә бирде.

— Һы, алай икән,— диде карт, исе китмичә. Шуннан соң икесе дә тынып калдылар.

— Нәрсә алып килдең?— диде картәтәй кинәт кенә.

Ул моны шаяртып әйтмәкче булды сыман, ләкин бу бик туры әйтелде, тупас итеп әйтелде. Картәтәсенең холкын белгәнгә, Габделхәйнең моңа да әллә ни исе китмәде. Ул аның шулай дип сораячагын алдан ук сизенгән һәм җавабын да алдан ук әзерләп куйган иде.

— Картый кайтсын инде,— диде ул һәм шундук сүзне икенчегә борырга ашыкты.— Катнарга чабатаң бармы — бир әле үзем катныйм,— диде.

Мондый тәкъдимгә куанган сыман, картәтәй як-ягына карап алды. Никадәр карт һәм хәлсез булмасын, үз эшен ул үзе генә эшли, чит кеше кысылса кул бозыла, эш киреләнә дип исәпли иде. Ләкин Габделхәйне ул чит кеше дип белми иде, ахрысы. Сике астыннан, иелеп, калыплап куелган чабата алып бирде.

— Тезеңә әнә теге чүпрәкне сал — чалбарсыз калырсың ату,— диде картәтәй, киңәш итеп.

Габделхәй күрсәтелгән чүпрәкне тезе өстенә җәеп салды да эшкә тотынды.

— Шелеңне яхшы тарт, шөшле сабы белән сугып-сугып куй. Нык булсын,— диде картәтәй, өйрәтеп, киңәш итеп.

— Ярар, шулай итәрмен,— диде Габделхәй.

Бераз вакыт сүзсез генә эшләгәч, картәтәй үзалдына зарланып куйды.

— Юкагач ташуы авырайды,— диде.— Бер барганда биш-алтыдан ары күтәреп булмай. Бик бирештем быел, улым. Күз дә начар күрә. Урманнан кайткач, ике-өч көн бил авыртып җәдәтә. Анысына да түзәриең — каравылчы тота. Яз көне балтамны алып калды. Һы! Утырып кына җыламадым. Кыяктай үткер балтам эт кулында калды.

— Кайсы каравылчы?— диде Габделхәй, болай гына, сүз урынына сүз булсын өчен генә.

— Һы! Җалабикыф Сабачианны белмәскә!— диде картәтәй.— Маңкасын җыялмаган бернәрсә. Шул этләр көненә калдык. Бүә буе урманында икенче эзең булмасын — башыңны чабып өзәрмен, карт тәре, ди.

— Син үзең тәре димәдеңмени?— диде Габделхәй.

— Һы, әйтмәгән кая ул!— диде картәтәй.— Син ул — тәре, мин — хак мөселман дидем. Аңлыймыни ул аны? Бик бирештем быел, улым. Үз урманың үзеңә, үз басуың үзеңә ирек түгел. Безнең ул Бүә буйларын, урманынболынын патша да тартып алалмаган — болар алды. Денсезләр... Берсен калдырмай тартып алды. Эт көненә калдык, улым. Безнекеләр күреп кайткан — башы аягы астына килгере Сабачианның чоланында ята ди минем балта. Әллә каян танырга була: сабына тимер каккан.

— Чоланында яткач, су эчәргә кергән буласың да аласың да чыгып китәсең,— диде Габделхәй, җиңел генә.

— Һы, алырсың эт авызындагы сөякне!— диде картәтәй.— Беркөнне тагын финагин килеп кергән өйгә... Пачай Матжан. Анда карай, монда карай синең кебек. «Көненә ничә кием чабата ясыйсың, карт?»— ди. Ник кирәк ул сиңа, мин әйтәм, аягыңда күн итек, өстең бөтен, тамагың тук — үгез кебексең... чабата киеп йөрергә чамаламыйсыңдыр ич, мин әйтәм. Синең чабатаң кирәкмәй

миңа, ди. Налук түләтәм мин синнән, ди. Калхуз эшенә чыкмайчы баеп ятасың, ди. Эт көненә калдык, улым.

Урман каравылчысы Сабачианның картәтәсенең балтасын алып калуы турында Габделхәй белә иде инде. Бу хәл моннан ике-өч ел элек булган. Шулай да менә картәтәсе һич шуны оныта алмый — килгән саен сөйли, сөйләгәндә дә гел әлерәк кенә, быел гына булган хәл итеп сөйли. Ләкин чабатага налог түләтмәкче булулары турында Габделхәйнең әле ишеткәне юк иде.

— Чабатага налук!.. Пачай Матҗан үзе генә уйлап чыгаргандыр аны, картәтәй,— диде ул, ышанасы килмичә.

— Һы, кем белә аларныкын,— диде картәтәй.— Алар бездән сорап эшләмәй — кирәк икән, тарта да ала. Тәкыйулланың алма бакчасын элегрәк мактап гәзитләргә язалары. Исәр әйткәндәй, әллә утыз, әллә җегерме җыл карады, бала урынына тәрбияләп үстерде. Чичкә атканда аппак булып утырырые... бөтен авыл күрке булып. Кисте. Үч итеп кисте. Ачудан. Бар карап торганым шушы бакчае — анысы да харамга чыкты, диде. Әлеге дә баягы, Миннегали таягы... алма сатып баеп ятасың дип налук китереп төшергәннәр. Шуннан каста булды, һы, булмай, булырсың каста. Тагын үзе килеп бәйләнә ди әле, ник кистең, сәвиткә каршы кул күтәрәсеңмени? дип әйтә ди. Эт көненә калдык, улым. Бәрәкәт качты дөньядан. Кот калмады. Үзебез гаепле... Алланы оныттык, фасикъ булып беттек,— диде карт, фәлсәфи төстә сүзен тәмамлап.

— Чабата өчен налук түләдеңме соң шулай да?— диде Габделхәй, мәсьәләне ачыклыйсы килеп.

— Һы!— диде карт, үртәлеп.— Әнә иске туным, әнә иске киезем, менә ямаулы күлмәгем — ничә бет табасың, барысы да синеке!— дидем. Тиргәп чыгардым, кеше каны имеп симергәнсең,— дидем. Икенче килмәде.

Картәтәсенең мондый сүзләрен, мондый моң-зарын Габделхәйгә элегрәк тә тыңларга туры килә торган иде. Кайчан гына тыңламасын, нәрсә турында гына тыңламасын, ул аны бик үк аңлый да алмый иде. Картәтәсе аңа бүгенге көн кешеләре, бүгенге көн гадәтләре турында түгел, бәлки, ниндидер үткән заман турында, үткән заман кешеләре һәм гадәтләре турында сөйли кебек иде. Аның моң-зары гына түгел, башка кешеләрнең моң-зары да Габделхәйгә нишләптер ялган һәм ясалма булып, элекке заманнардан калган бер аңсызлык булып тоела торган иде. Зарланырга яратучылар, аныңча, бүгенге көндәге политик хәлне, илдәге төп законнарны, тәртипләрне аңламыйлар яисә аңларга теләмиләр сыман иде. Чабатага налук салу, әлбәттә, көлке, ләкин яшь юкә агачларын кисеп, урманны корыту да дөрес

түгел! Җалабиков Сабачиан урман каравылчысы. Урман — «хөкүмәтнеке». Дәүләт милкенә кул сузу — җинаять. Моның өчен төрмәгә утырталар, сөргенгә сөрәләр. Ярый әле картәтәй балтасын биреп кенә котылган. Әгәр сугыш елы законнары нигезендә алып киткән булсалар? Менә бит ул эшләр кай таба бара!

## V

Утыра торгач, картәтәй үреләә торган чабатасы белән бергә тезендәге чүпрәген сыпырып төшерде дә аягына басты.

— Җитәр. Хәл юк,— диде һәм, кунычы киселгән киезтекләрен өстерәп, ишек төбендәге агач караватка барып ятты.

Кулларын баш астына куйды, аякларын сузып җибәрде. Үпкәләгән сыман озак кына тынып ятты да коры гына:

— Инәң акча җибәрдеме?— диде.

— Юк,— диде Габделхәй.

Карт эндәшмәде. Аның чыннан да үпкәләгән, хәтере калган икәнлеге хәзер үзеннән-үзе сизелеп тора иде.

— Һы, көтәрсең аннан!— диде ул бераздан һәм тагын тынып калды.

Габделхәйнең инәсе белән картәтәсе арасында күптән инде читләшү, салкынлык сыман бернәрсә яшәп килә иде. Картәтәйнең дүрт кызы, бер улы бар. Кызларның барысы да читтә, башка авылларда. Төп йортта — Вәлиәхмәт улы. Башка авылларда булсалар да, ата кеше үзенең кызларын да онытмый. Шулай да ул аларны мохтаҗлыкка төшкәч кенә исенә төшерә, ахрысы. Мохтаҗлыкның исә бер генә көнгә дә бетеп торганы юк. Кызларының, кияүләренең тормышлары бик үк шәптән түгеллеген ул белми түгел, белә. Кайберсенең тормышы аның үзенекеннән дә начаррак. Бары тик Шәмсебанат кына, картәтәй исәбенчә, башкаларга караганда мулрак, иркенрәк тормышта яши. Алай гына да түгел, Шәмсебанат хәтта бик шәп яши. Шәмсебанат акча суга. Шәмсебанат кызының бай яшәвенә картның, билгеле, әз генә дә каршылыгы юк. Булдыра ала икән, кулыннан килә икән, яшәсен әйдә, рәхәтләнеп яшәсен. Тик шулай да ата кеше кайчагында үзенең кызыннан көнләшеп тә куя. Көнләшү генәме, шартлар дәрәҗәгә җитә!

Шәмсебанат аена йөз сиксән биш сум акча ала, җитмәсә, ире өчен дә бушка акча килеп тора. Дөрес, аның бакчасы да бакча түгел — бер-ике түтәл кишер, суган утыртырлык уч төбедәй җире бар. Сыеры да, кәҗәсе дә

юк. Аның урынына — дүрт тамак. Ләкин андый нәрсәләрне карт күрмәмешкә, белмәмешкә салына. Тамак өчен дә, өс-баш өчен дә, аныңча, Шәмсебанатка акча тотып торасы юк — балалары да, үзе дә, аныңча, балалар бакчасында туеналар, киемен дә «хөкүмәттән» алалар. Шулай булгач, игелексез, миһербансыз Шәмсебанат кызы аңа — картатасына — кимендә ун-унбиш тәңкә биреп барса да, бер җире дә кителеп төшмәс иде. Һы, биреп барырга тиеш тә бит, бирмәй, бармак гел үзенә таба кәкере.

Картәтәйнең күңелендә шундыйрак бер үпкә бар иде. Аена бер-ике мәртәбә базарга чабата сатарга баргач ул, бик керәсе килсә дә, кирелеген җиңә алмыйча, кызы Шәмсебанатка керми китә. Өйләре базардан әллә ни ерак та түгел югыйсә. Шулай ук кызы Шәмсебанат та, атасының холкын белгәнгә, туган авылына сирәк кайта, кайтса да әтәсе белән бозылышып-ачуланышып китә.

Бу турыда Габделхәй яхшы белә. Олылар арасына аның керәсе дә килми, кемнең дөрес, кемнең дөрес түгеллеген ачыклыйсы да килми. Менә хәзер яңадан шул күңелсез бәхәс шаукымы калкып чыккач аның эче пошып куйды.

— Мин укырга китәм бит әле, картәтәй,— диде ул, сүзне икенчегә бормакчы булып.

Картәтәсе озак кына эндәшми ятты һәм үзенең берни аңлатмаган «һы» дигән ымлыгын әйтеп куйды. Габделхәй аны әз булса да кызыксыныр, ничек укыдың, кая барасың, кем буласың? дип әйтер дип көткән иде. Ләкин картәтәсенең шул хәтер калдыргыч «һы»сы аны тынып, бөрешеп калырга мәҗбүр итте. Шундый атлыгып, шундый сагынып килгән өй, авыл кинәт чит-ят булып тоелды. Тәбәнәк өй эчендә аермачык булып ач чебеннәр безелдәве генә ишетелде. «Инәкәй бөтенләй монда... авылга кайтмакчы була тагын»,— дип уйлады Габделхәй күңеленнән, чиксез бер төшенкелеккә бирелеп. Кая кайтасың, ник кайтасың монда?!

## VI

Алар шулай тынып калган арада, теге якта кемнәрнеңдер кайтып кергәне ишетелде. Габделхәй аларның кемнәр икәнлеген аяк тавышларыннан ук танып алды. Эшен ташлады да чолан аша теге якка чыкты.

— Китагай! Гаптелхәй улым түгелме соң?!— диде картый, Габделхәйне күргәч.

Карты кебек үк озын, чандыр гәүдәле картый, мич алдына якын килеп, алъяпкычындагы чыршы күркәләрен

бушатып ята иде. Мич алды сикесендә, кояшлы болын исләре таратып, җиләк тулы агач савыт тора иде. Ялан-башлы бер малай, чыршы күркәсе белән булашкан картыйсы ягына ялт-йолт каранып, савыттан учлап-учлап җиләк ашый иде. Шунда ук малайдан зуррак бер кызый да бар иде. Габделхәй абыйсын күргәч, җиләк буры тиз генә гөлбәч артына шылды, кызый исә гаҗәпләнеп кунак абыйсына текәлде. Болар яшьбабайның балалары — Габделхәйнең туганнан туган энесе белән сеңлесе иде. Аларның берсе Зифун, икенчесе Сиринә дип атала иде. Эне белән сеңелнең өс-башлары ярлы, йөзләре чырайсыз, тәннәре чыра кебек иде.

Картый, чыршы күркәләрен бушатып, алъяпкыч итә-ген сыпырып куйды, кулларын итәгенә сөрткәләде дә, елмаеп, дәртсез генә гөрелдәп Шәмсебанат кызының зур улын яратып алды — аркасыннан каккандай, кочаклагандай итте.

— Китагай! Үскән, акыллыланган. Кайчан килдең? Инәң нишләп ята — тазамы, чирләмәйсезме? Бер дә килмәйсез, ташладыгыз,— диде ул, бер-бер артлы тезеп.

Шуннан соң, болай гына килешеп бетмәс дигән кебек, күз төпләрен чылатып алды, баш артына шуышып төшкән яулыгын тартыбрак куйды һәм өстенә чигүле тастымал ябып куйган самавырга барып тотынды.

— Гаптелхәй улым килгәч самавыр куймай ярамас,— диде.

— Инәкәй сезгә күчтәнәч җибәргәние,— диде Габделхәй, шүрлектәге төенчеген алып.

Аның кулындагы зур гына төенчекне күреп картыйның куанычы арта төште. Кузгалтылган самавырын урынында калдырып ул өстәл янына килде һәм калтыранган куллары белән төенчекне чишә башлады. Шәкерт абыйлары алып килгән күчтәнәчне күреп, балалар телсез калдылар һәм комсызланып, түземсезләнеп төенчекнең чишелүен көттеләр.

Өй эчендәге ыгы-зыгыны ишетеп, күрәсең, сикедәге кызый да йокыдан уянып китте һәм уяну белән ни өчендер шыңшып җыларга тотынды. Аңа игътибар итүче булмады. Мендәр мамыгына баткан, тузгыган чәчләрен тырпайтып, чытык йөзле кызый олылар янына килеп җитте. Ул арада комсыз Зифун, төенчекнең чишелеп беткәнен дә көтмәстән, кулын сузып нидер умырып алды һәм башкалар исләренә килеп өлгергәнче, кулына эләккән нәрсәне авызына кабып та җибәрде. Сиринә, энесе өчен уңайсызланып, кызарынып, шәкерт абыйсы ягына карап алды, аннары пышылдап, зәһәрле итеп «убыр!» диде,

ләкин «убыр»ның гына бернинди тәэсире юклыгын күреп, тәртипсез энесенең beләгеннән чеметеп алды.

Габделхәй, аларның бу кыланышларын күрмәс өчен, читкәрәк китеп барды. Соңга калдым, ахрысы, дигән сыман ашыгып, картәтәй килеп керде. Кунычы киселгән киезтекләрен өстерәп, буш капчык шикелле асылынып торган киндер ыштан төпләрен җилфердәтеп түргә, өстәл янына узды. Картәтәйләрен күреп балалар тынып калдылар, читкәрәк тайпылдылар. Картәтәй өстәл янындагы урындыкка килеп утырды да, балалар кебек үк түземсезләнеп, серле төенчеккә текәлде.

— Һы, самавыр куярга кирәк. Тамагы кипкәндер Гапделхәйнең,— диде, киңәш итеп.

Нык тартылган төенне картый, ниһаять, чишеп җибәрде. Төенчектән иң элек шундый кадерле һәм тансык ис бөркеп торган бер бөтен ипи — Яңавылда, тимер юлчыларының ипи заводында пешкән, чиле-пешле булып, ләчтә булып пешкән бер кирпеч ипи килеп чыкты.

— Их!— диде Зифун һәм онытылып тагын кулын суздь.

Чәче-башы тузгыган бәләкәй кызый шыңшудан чынчынлап җылауга күчте, Сиринә исә шулкадәр зур байлыкка ышанырга да, ышанмаска да белмичә, сихерләнгән кебек карап тик торды.

Казан яныннан картый зур гына пычак алып килде, пычакның чыра телеп агарып, шомарып беткән йөзен алъяпкыч итәгенә сөртте дә әнинең әлерәк кенә Зифун сындырып алган почмагыннан бер юка телем кисеп алды. Телемне өстәлгә куеп аны өчкә бүлде, аннан соң һәр кисәкне икегә бүлеп чыкты. Олырак кисәкне иң элек картына бирде, икенче кисәкне кечкенә кызы Риммага тоттырды. Кырые китек кисәк Зифунга, аның ише Сиринәгә булды.

— И-и!— диде Зифун, шыңшып.

— Шыт! Шул кирәк сиңа — комсызланмассың моннан соң!— диде Сиринә, тантана итеп.

— Биргәнгә рәхмәт әйтергә кирәк,— диде картәтәй, коры гына.

Калган ике кисәкне картый шүрлеккә куйды.

— Монысы Гаптелхәй улым белән безгә,— дигән булды.

Комсыз Зифун үзенә тигән кисәкне чәйнәп-нитеп тормады — шул көе йотып кына җибәрде. Бәләкәй кыз Римма белән Сиринә исә, Зифунны кызыктырып, яңакларын күпертеп, үз өлешләрен авыз эчендә генә сакларга булдылар.

— Китегез, кит!— диде картәтәй, балаларны өстәл яныннан куалап.— Җитеп торыр хәзергә.

Төенчек эченнән тагын ике кисәк иллешәр граммлы

бөртек чәй, ярты кило чамасы эре шакмаклы шикәр, укмашып беткән карамель һәм шулай ук ярты кило чамасы печенье чыкты. Боларның барысы да Шәмсебанат апаның күптән инде авылга җибәрергә дип әзерләп куйган байлыгы иде.

— Һы! Шундый тәм-томнар гына ашап ятасызмы?— диде картәтәй Габделхәйгә.

Ул моны комсыз бер гаҗәпләнү белән, атасын оныткан игелексез кызына карата ачу һәм көнләшү белән әйтте. Аңа каршы Габделхәй берни эндәшмәде. Балаларның, олыларның үз гомерләрендә беркайчан ипи, чәй-шикәр күрмәгән кебек кыланулары аңа бик авыр тәэсир итте.

Ул аларның ыгы-зыгысына катнашырга теләмәгәнлеген сиздереп, стенага ябештерелгән иске гәзит кисәген укырга тотынды.

— Лыгырдама инде! Китагай!— диде картый, ачуланып.— Тутырып куйганнар ди анда. Үзеннән, балаларыннан өзеп җибәргәндер әле. Синең аркада көллесе өйдән бизеп бетте.

— Һы! Бизәр шул, ник бизмәсен. Малайлар үсте, эшкә ярады. Ай саен акча килеп тора. Бизәр шул,— диде карт тешсез уртлары белән әкрен генә ипи йомшагын әвәләп.

— Тутырып куйган ди акчаны! Утырасың шунда, карт самый!— диде картый, кычкырып.

Картый үзе шикәр-кәнфиткә дә, печеньегә да кагылмады, бары чәйне генә борынына бик якын китереп иснәп карады да төенчекне бәйләп кире шүрлеккә куйды. Шуннан соң ул шалтыр-шолтыр килеп яңадан самавырына тотынды.

Картәтәй, хәлсез терсәкләре белән өстәл тактасына таянып, авыз эчендәге ипиен әвәли-әвәли, урынында торып калды. Ашап бетергәч, өстәлнең бер башыннан икенче башына кулын сузып, әле генә корткасы ипи кискән төшне капшап карады. Ләкин аңа кадәр балалар өлгергән иде бугай инде — ашъяулыксыз как такта өсте ялап алгандай чип-чиста иде. Картның кәефе кырылды. Күңелен борчыган бер үк нәрсә турында уйланып утырдыутырды да, теләр-теләмәс кенә кузгалып китте. Хәзер ул үз ягына чыгып тормады — бу якның ишек төбендәге тар сикесенә барып ятты.

## VII

«Һы, тәм-том гына ашап яталар!» — дип уйлады ул, тынычлана алмыйча. Ул анда шикәр белән чәй эчсен, син монда карт башың белән көн-төн бил бөгеп утыр, көн-төн балтырган шулпасы чөмер. Изгелек юк хәзерге кешеләрдә,

миһербан юк. Һы, укыган кешедә ниндәй миһербан булмак кирәк? Үзләренә генә булсын аларның, картатайга булмаса да ярай. Катмас әле! Катса тагын... Ипине менә мин ашарга тиешием дә, юк, тәтемәй. Укыган кешеләр ашай. Укыган икән, гәҗитен кимерсен. Ипине кем карап үстерә, шул ашарга тиеш. Юк шул, алай түгел — басуга аяк та басмаган, тырманы сабаннан аера белмәгән әрәмтамаклар ашый. Фасикъ дөнья. Бәрәкәт качты.

Фикерен ул шуннан ары үстерә алмады. Аның уйлары бер үк нәрсә тирәсендә буталды һәм уйланган саен кәефе генә кырыла барды. Кәефе кырылгач исә тупасланасы, кырасы-җимерәсе килде. Бер кереп, бер чыгып, туктаусыз нидер эшләгән сыман йөреп торган корткасына кинәт ачуы килеп:

— Буламы инде анда, юкмы?— дип кычкырды.

— Була! Талагың ташыгандыр,— диде кортка, картның үзе кебек үк тупас итеп.

— Һы, син тотынсаң була инде ул... иртәгә,— диде карт, зәһәрләнеп.

Картый җавап кайтарып тормады. Картәтәй озак кына үзалдына сукранып, мыгырданып ятты. Корткасы белән алар, гомумән, тату, тыныч яшәмиләр иде. Бернинди сәбәп юк чагында да корткасына кычкыру-җикерүне ул гадәти нәрсәгә саный, корткасы шулай ук җавапсыз калмый иде. Читтән тыңлап торганда аларның үзара сөйләшүе дә тиргәшү, кычкыру булып тоела иде.

Аларның бу сәер гадәте дә, мондагы мохтаҗлык, ярлылык та Габделхәйгә ят нәрсә түгел иде. Шулай да, никадәр ярлы һәм мохтаҗ булмасыннар, килеп керү белән картыйсы карбаздан иң элек салкын катык алып кереп бирә торган иде. Бу юлы нишләптер аны күрмәделәр дә шикелле.

— Арыгансыңдыр, улым, ятып тор,— диде картый, Шәмсебанат улының күңелсезләнеп утыруын күреп.— Чәй кайнап чыккач уятырмын.

— Ятып торасы килми,— диде Габделхәй, теләр-теләмәс кенә.

Картый кыстап тормады — балалар чыгып китүдән файдаланып, күчтәнәчле төенчекне яңадан үрелеп алды да, яңадан чишеп өстәлгә җәеп салды да чәй-шикәр ише нәрсәләрнең барысын да яңадан әвеш-түеш китерергә тотынды. Тиздән самавыр да кайнап чыкты, ташып, җиз капкачын дыңгырдатып, түгелә дә башлады.

— Әнә кара!— диде картәтәй, яткан җиреннән башын калкытып.

Картый, авыр самавырны шактый җиңел күтәреп, өстәлгә утыртты. Борыны китек чәйнүккә хуш исле бөртек

чәй чеметкәләп салды, чәй өстенә чыжлап торган кайнар су агызды, шуннан соң чәйнүкне шаулап торган самавыр өстенә утыртып куйды. Әчкелтем-төчкелтем аш-умач ис-ләрен куалап, чебен безелдәвен томалап, өй эченә җылы, тәмле исләр таралды.

— Җәгез, килегез,— диде картый, карты белән Габ-делхәйгә эндәшеп.

Картәтәй урыныннан торды, аякларын идәнгә төшер-де һәм барыргамы-бармаскамы дигәндәй тынып утырды да урыныннан кузгалды. Кыстатып тормыйча, Габделхәй дә өстәл янына килде. Алар килеп урнашу белән, кар-тый йомырыларга чәй агыза башлады.

Шул чакны чыр-чу килеп тыштан бала-чага йөгереп керде.

— Актимер бабай килә!— дип кычкырды беренче бу-лып Сирине.

— Актимер-Күктимер!— диде Зифун, апасыннан ка-лышмаска тырышып.

— Актимел-Күктимел!— диде бәләкәй Римма, көлә-көлә.

— Ут чыкканмы әллә — ник чабышасыз?— диде кар-тәтәй.

— Актимер килә ич!— диде Зифун.

— Актимер?— диде картәтәй, сагаеп.

— Килсәни, кеше килгәнгә тилерәләрмени?— диде картый.

Картәтәй урыныннан торды, тәрәзәгә якын килеп, урам якка карады, аннары берни әйтмичә кире урынына ки-леп утырды.

— Һы, көтеп кенә торадырыем менә монда,— диде мыгырданып.

Шул ук вакытта диярлек шыгырдап капка ачылганы ишетелде. Барысы да, тын калып, керүчене көттеләр. Бер-ике минут чамасы вакыт үтмәде, тышта ишек төбендә кемнеңдер кычкырып сәлам биргәне, «хуҗалар өйдәме?» дигәне һәм таягын тукылдатып чолан баскычыннан ме-неп килгәне ишетелде. Кунакны каршыларга дип картә-тәй урыныннан торды.

— Һы, Шуктимер мактап кына йөри әле,— диде сук-ранып.

Ачып куелган ишектән шомарып беткән таяк белән иске киндер капчык тоткан бәләкәй генә, чандыр гына бер карт килеп керде. Башына ул кулдан суккан киез эшләпә, аягына ак ыштыр урап яңа чабата кигән иде. Чабата бавы балтырына аркылы-торкылы уратып, тезенә кадәр күтәртеп бәйләнгән иде. Янтыктан төньяктагы Ар-Уразының Актимер карт картәтәйнең күптәнге белеше

иде. Янтыкка килеп чыккан саен диярлек ул кордашы Кәрим агайларга сугылмый узмый иде.

Актимер карт, таягын, капчыгын ишек төбенә куйды да бер-ике адым түргәрәк узды, җирән сакалын сыпырып алды һәм кычкырып:

— Ассаламагалайкум!— диде.

— Әйдә, түрдән уз, Актимер,— диде картәтәй.

— Сауме-исанме, Карим агай?— диде Актимер карт.— Исанлекләр ничыграк, җингай? Исанлек-саулыкме?.. А-ай, сездә кунак та бар икән. Гаптылхай иным түгелме соң? Исәнме, иным.

Ул шулай һәркем белән исәнләшеп чыкты. Исәнлек-саулык алгач, картый юлаучыны чәй эчәргә чакырды, удмуртча белгән бердәнбер «пукче» (утыр) дигән сүзен әйтте. Картәтәй үзе янынннан урын җайлады. Актимер башындагы эшләпәсен салып сикегә куйды да күрсәтелгән урынга килеп утырды. Шуннан соң, хуҗаларга, табынга хөрмәт йөзеннән, кычкырып «бисмиллаирахман ирахим» диде.

— Мактап кына йөрисең икән, Актимер,— диде картый, чәй ясап.

— Аллам сакласын сызне хурларга,— диде Актимер.

— Базарысьа бертиськот? Суресет луиза?* — диде картәтәй, удмуртчага күчеп.

Яшьрәк чагында ул бер ай Ар-Уразыда эшләгән, шунда беркадәр удмуртчага өйрәнгән. Үзенең дә төшеп калганнардан түгеллеген күрсәтмәкче булып, чит кеше алдында да, удмуртлар алдында да шулай бер-ике сүзне удмуртча әйтеп куйгалый иде.

— Базардан, Карим агай,— диде Актимер карт.— Ундым дисан да ярай, унмадым дисан да ярай. Сарык алып барганыем, Карим агай. Җыл да икы бәрән бирадырые. Саттым. Налукка кирәк, җингай. Бугаздан алалар, җа налукны тулайсын дилар, җа йортынны язып чыгабыз дилар. Җорттан колак кагасы килмай бит, Карим агай.

— Шулай инде, шулай,— диде картый, Актимернең сүзен җүпләп.— Җәле, Актимер, җитештереп кенә утыр әле.

— Җорттан колак каксам нишлармын дидым, Карим агай,— диде удмурт карты, үз алдына куелган ипи кисәгенә кагылырга да, кагылмаска да белмичә.

— Аша, аша, тартынма, Актимер — анысы синең өлеш,— диде картый.— Бәхетле тамак икәнсең. Кызым җибәргән... Шәмсебанат.

— Сарык кадәрлемы, җортмы, иным?— диде Актимер-карт, Габделхәйгә карап.— Базардан кайтышлый ук

* — Базардан кайтышмы? Юлың уңдымы?

кереп түләдым налукны. Калганына шырпы-сабын алдым тыгеларьга, Карим агай.

— Аларга ышаныч юк, Актимер кордаш,— диде картәтәй.— Язып та алырлар, куалап та чыгарырлар.

— Нишләп кешене үз йортыннан куалап чыгарсыннар инде!— диде Габделхәй, сүзгә катышып.— Элек кенә... патша заманында гына ул куалап чыгарганнар. Хәзер — юк, алай түгел ул.

— Дурысь, иным, шулайдыр,— диде Актимер карт, бик тиз килешеп.

— Китереп терәделәр, кордаш,— диде картәтәй, Габделхәйнең сүзенә колак та салмыйча.— Каманизмга китереп терәделәр. Бай да юк, ярлы да юк — барыбыз да бертигез... барыбыз да хәерче!

— Хәерче!— диде картый, кычкырып.— Булганына шөкер ит — Алла сугар. Алдың тулы ризык, шуңа да канәгать итмәгәч!

— Дурысь, җиңгай,— диде Актимер, ярарга тырышып.

— Үзебезнең комсызлык аркасында шушы көнгә калдык,— диде картый.— Биргәненә шөкер итәргә кирәк. Элекке пигамбәрләр әнә күпме михнәтләр күргәннәр!

Картый үзенчә укымышлы иде. Үз фикерен дәлилләү өчен ул еш кына китап сүзләре кулланырга, изгеләр тормышыннан мисаллар китерергә ярата һәм күңеле аеруча күтәренке чакларда элекке мөнәҗәтләрдән, хикәяләрдән кыска-кыска өзекләр сөйләп ала, тыңлаучы булса, бар белгәнен берьюлы чыгарып салырга да күп сорамый иде.

— Безнең күргән берни түгел — ни күрмәгән Йосыф пигамбәр!— диде ул көйләп һәм, чәй эчүчеләрнең каршы сүз әйтә алмавыннан файдаланып, Йосыф пигамбәрнең михнәтләреннән бер-ике кыйсса сөйләп алды.

— Дурысь, җингай,— диде Актимер.— Игыньнарь ничек сун сызьдә, Карим агай? Сабан ашлык бызда айбат булды, арыш кына сирәк.

— Ничек булса да, безгә буласы түгел, Актимер,— диде картәтәй, төшенке генә.— Урак вакыты гына җитсен, килерләр дә ялмап та алырлар, бөртеген калдырмый алып китәрләр. Белмәйсеңме әллә?

— Дурысь, Карим агай,— диде Актимер карт, уфтанып.

— Нишләп бөртеген дә калдырмасыннар инде, картәтәй?!— диде Габделхәй, картәтәсен оялтмакчы булып.— Йөз кило хөкүмәткә тапшырсаң, унбиш кило колхозчыга кала. Тырышып эшләгәндә...

— Бик бирештем быел, Актимер,— диде Кәрим карт, Габделхәйнең сүзләрен ишетмәмешкә салышып.— Күзем дә начар күрә, кул да калтырый. Җегәр юк, Актимер, җегәр.

— Бызьга шул кабергә барасы гына калды инды, Карим агай,— диде Актимер, пошынып.— Исымнан чыккан, бызның бит тыге Юлдаш карт та улде. Але шушы атнада гына. Урыны уҗмакта булсын.

— Һы!— дип куйды Кәрим карт, белеше Юлдаш картны кызганып.

— Мәрхүм,— диде картый да.— Корткасы исәнме соң әле? Улы белән килене дә барые бугай.

— Барые, җингай,— диде Актимер.

— Һы!— диде картәтәй.— Сиксәнгә җиттеме Юлдаш карт?

— Җитмыш тугызда дидылар,— диде удмурт карты.

Алар шулай дөнья хәлләре турында сөйләнгәләп әзмәз ипи каптылар, җебетеп кенә шикәр суырдылар һәм туктаусыз чәй эчтеләр. Чәйне картый ясап кына торды. Башта пешерелгән чәй җитмәде. Борыны китек чәйнүккә яңадан бер-ике чеметем чәй салырга, сүрелә башлаган самавырга күмер өстәргә туры килде. Ярый әле борынгы «микулай» самавыры зур иде, «сәвит» самавыры булса, ихтимал, суы да җитми калган булыр иде.

Биш-алты йомырыны бушаткач һәм тәненә, маңгаена рәхәт тир бәреп чыккач, Актимер карт, хуҗаларга рәхмәт әйтә-әйтә, урыныннан кузгалды. Гәпләшеп чәй эчкәннең соңында картәтәйнең дә күңеле күтәрелеп китте. Бушап калган өстәл тирәсен шундук балалар яулап алды.

Актимер карт бусагага утырды да, куеныннан чигүле янчык чыгарып, караеп беткән төрепкәсенә тәмәке тутыра башлады.

— Уйда тартмаймын — курыкма, җингай,— диде үзалдына сөйләнеп.

— Тупсага утырырга ярамай бит, Актимер — бәхетең булмас,— диде картый.

— Син ачуланма инды, җингай,— диде удмурт карты, канәгать төс белән кеткелдәп.— Гумырьга тупсага утырдым — бахытем шуннан булмагандыр. Кайнар чәй ычкачь, торыпкамьне бер тартып җибәрсәм, миа хазырь шуннан артык бахыть киракмай.

— Һы, кемгә — бәхет, кемгә — ләхет,— диде картәтәй, Актимер картны яклаган сыман итеп.

Актимер карт, картый сүзен тыңлап, шулай да бусагадан торды, чакмасын чагып тәмәкесенә ут кабызды, таягы белән капчыгын кулына алды да, ике сүзнең берендә рәхмәт әйтә-әйтә саубуллашып, әчкелтем тәмәке исе калдырып чыгып китте. Киселгән киез итеген өстерәп, Кәрим карт белешен капкага кадәр озатып куйды.

## VIII

— Карале, сиңайтәм, Ибрайлар зыянлап сыерларын суйганнар икән,— диде картәтәй, өйгә кергәч.— Әллә бер-ике кила ит алып кайтасыңмы? Көтеп торырга бирерләр әле. Кирәксә, чабата белән түләрмен. Болай да алардан ике кием өчен аласы бар.

— Китагай!— диде картый шаккатып.— Сыйлы көнең — сыер. Җәй уртасында... мескенкәйләрем! Акчасын чыгарсалар ярай да бит.

— Чыгармас Ибрай! Ике хакын чыгарыр әле ул. Базарга алып барсалар кулына да тидермәсләр,— диде картәтәй.

— Көтәргә бирер микән соң?— диде картый.

— Бирер, бирер,— диде картәтәй.— Үз кешеңә дә бирмәгәч... Качарга җыенмайбыз, үләргә дә...

— Гаптелхәй улым килгәч бик әйбәт булыр. Киленнәр дә эттәй арып кайталар,— диде картый, ризалыгын белдереп.— Каяле, Сиринәне генә җибәрәем.

— Ниндәй Сиринә ул!— диде картәтәй.— Сиринәгә кем ит тоттырып җибәрсен — бар үзең.

Картый самавырын түгеп, өстәлен җыештырды да, башындагы яулыгын рәтләштереп, чыгып та китте. Картәтәй аның Ибрайлар ягында күздән югалуын гына көтеп торды да, урам як тәрәзәне иңеләй ачып, бар көченә:

— Сиринә! Сиринә!— дип кычкыра башлады. Тамаклары туйгач каядыр уенга чыгып киткән балалар, картәтәләре тавышын ишетеп, озакламый көтүләре белән кайтып керделәр.

— Син чакырдыңмы, картәтәй?— диде Сиринә, картәтәсенең колагына якынрак килеп.

— Кайда йөрисең кычкырганда?— диде Кәрим карт, кырыс кына.— Китмә. Көтеп тор.

Шуннан башка ул берни әйтмәде. Бик ашыгыч эше бар сыман, авырткан аякларын җитез генә өстерәп, чоланга чыгып китте һәм тузанлы әрҗәләр, капчык, чапчак ише нәрсәләр арасыннан нидер эзләргә тотынды. Эзләгән нәрсәсен тапмагач, ашыгып кире өйгә керде, шүрлекне, сике астын, сандык артларын капшап карады. Шуннан соң нидер исенә төште дә, янә лас-лос атлап, үзалдына сукранып, кире чоланга чыкты. Бераздан ул тузанга буялып беткән ярты литрлы кара шешә алып керде, шешәне чүпрәк белән сөрткәләп Сиринәгә бирде. Бөтен өйдә бердәнбер дип әйтерлек буш шешә иде бу. Картәтәй аны корткасыннан да, бала-чагадан да яшереп

саклый иде. Булган барлык шешәне сугыш елларында, иң кадерле байлык сыман, «хөкүмәт»кә биреп бетергәннәр иде. Нимес танкларын шартлату өчен ул шешәләрдән бензинлы граната ясыйлар икән дип сөйлиләр иде.

— Мә, тиз йөре! Нык тот,— диде картәтәй.

— Акча?— диде Сиринә, шешәне кулына алып.

Картәтәй, күлмәк изүенә кулын тыгып, яшерен кесәсеннән йомарланып беткән берничә берлек алды, санап кызга бирде.

— Тиз йөре!— диде ул, тагын кисәтеп.

Ибрайларга караганда магазин якынрак иде. Аннан соң көндез анда әллә ни кеше дә булмый иде. Сиринә тиз арада кайтып та җитте һәм ике куллап тотып кайткан авыр гына шешәне исән-имин картәтәсенә тапшырды. Җәйге-көзге эш вакытында сатуда аракы өзелеп тормый иде. Аракыны Яңавылдан мичкәсе белән генә ташыйлар һәм кәрәчин саткан кебек, литрлап, чүмечләп саталар иде. Тулы шешәне Кәрим карт калтыранган кулына алды, алдап җибәрмәгәннәрме дигән сыман, кәгазь бөкене ачып иснәп карады, борынын җыерды, бөкене кире шешә авызына тыгып куйды да чоланга чыгып китте.

Күп тә үтмәде, куанычыннан җиңел-җиңел атлап картый да кайтып керде. Шакмаклы ашъяулык кисәгенә төреп ул зур гына ит тоткан иде.

— Бирде, бер сүзсез бирде, рәхмәт яугыры,— диде картый, ишектән килеп керү белән.— Китагай! Бигрәк симез булган — кисәргә карасы юк. Бичаракайларым... безгә сөенеч тә сөенечен, үзләре зар җылайлар шул. Яшь балалары бар, сөтсез кыен булыр инде.

Картәтәй итне кулына алды, башта авырлыгын чамалап карады, аннан соң яктыгарак килеп кыяфәтен карады, корткасына кире бирде дә канәгать бер төс белән:

— Бөтенләй сал,— диде.

— Шуны да бүлгәләп торсаң!— диде картый, эре генә.— Мондый эсседә ит саклап буламыни?! Исәпләшербез әле, белмәгән кеше түгел.

— Һы,— диде карт, күңеле булып.

— Онытып торам икән,— диде картый, нидер исенә төшереп.— Буә буенда бер марҗаны үтереп ташлаганнар ди. Яшь кенә ди. Акчасы да күп булмаган. Турыдан киткән булган икән, теге Тирән чокыр янында үтергәннәр ди.

Ишектән чыгып барган картәтәй туктап калды, аптырап, теле тотлыгып:

— Һы!— дип куйды.— Күрүчеләр булганмыни? Кайчан?

— Гыйльмулла малае күргән,— диде картый.— Берничә кеше җыелып кайтып киләләр икән, өстенә килеп

чыкканнар. Килеп җиткәндә теле булган, бичаракаемның. Җөрәк турысына гына казаганнар ди, пычак эзе шул көе ярылып ята ди.

— Һы!— диде карт исенә-акылына килә алмыйча.— Кем икән — тотмаганнармы?

— Кем булсын — чуен юлдагы ышпана инде. Ничек Габделхәй улыма чыкмаганнар! Алла саклаган инде. Гел турыдан йөри. Ишетсен колагың — икенче турыдан йөремә, улым,— диде картый, бер читтәрәк эндәшмичә утырган Габделхәйгә.

— Ярар,— диде Габделхәй, гамьсез генә.

— Һы!— диде тагын да картәтәй.— Алар шул хатын-кызга чыгалар да...

— Милитсиәсе дә юк бит аның кирәк чагында,— диде картый.

— Бүә буена да милитсиә куеп булмый бит инде!— диде Габделхәй, картыйның аңсызлыгына исе китеп.

— Милитсиәсе ышпана белән бер сүздә булгач, куйсаңни, куймасаңни,— диде картәтәй.— Илдә бәрәкәт калмады, улым. Үз җиреңдә үзең иркенләп йөри алмыйсың. Озакламай болар бер-берсен ашай башларлар әле.

— Тәүбә-әстәгафирулла!— диде картый, коты алынып.— Авызыңнан җил алсын — фирештәнең амин дигәненә туры килер!

— Килсә килер инде,— диде карт.— Фасикъ дөнья. Илдән бәрәкәт качты. Олыны олы дип белмәйләр, кечене кече дип белмәйләр.

## IX

Кичкә таба, кояш баер алдыннан, печәнчеләр кайтты. Этәсе кебек бераз гына бөкерәеп йөри торган Вәлиәхмәт абзый ишектән беренче булып керде. Аның артыннан кулына ак төенчек тоткан, бик нык арыган кыяфәттә хатыны керде. Иң артта Иленура күренде. Иленура этәсенә дә, инәсенә дә охшамаган — картыйсына тартым иде. Бернинди ачлыкка-мохтаҗлыкка карамастан, аның барлык саны төгәл, күркәм иде. Сылу ак йөзле, куе коңгырт чәчле һәм тере матур күз карашлы иде Иленура. Кояшта матур булып янган нәфис, түгәрәк муенына ул эре кызыл гәрәбә, ике як колак очларына көмеш сыман алкалар тагып куйган иде. Иленура Габделхәй белән бер яшьтәрәк иде. Төссез, хәлсез ата-аналары, картыйсы, картәтәсе һәм энеләре-сеңелләре янында Иленура ниндидер могҗиза белән генә кырау сукмый калган алсу чичкәне хәтерләтә иде.

Вәлиәхмәт абзый Габделхәйне күреп алды һәм теш казналарын тартып торган коры иреннәрен авырлык белән генә кыймылдатып елмайгандай итте.

— Габделхәй килгән ич,— диде.— Исәнме, Габделхәй. Шундый зур гәүдәле кешенең тавышы чыпчыкныкы сыман бик зәгыйфь булып чыкты. Габделхәйнең күңелендә яшь бабасына карата кызгану һәм әрнү хисе калкып куйды.

— Габделхәй дисеңме?— диде яшәби, шундый ук хәлсез бер тавыш белән.

— Габделхәй?!— дип кычкырды Иленура, бөтен өй эчен яшь, көр тавыш белән күмеп.— Гомерле булырсың әле — бүген генә сине сүләдек лапса. Әүлияме әллә син, Габделхәй?!

— Кызык, минем турында нәрсәләр сөйләдегез икән?— диде Габделхәй, печәнчеләр белән исәнләшкәч, Иленура янында озаграк тоткарланып.

— Сүләдек инде,— диде яшәби, кызы өчен җавап биреп.— Бигрәк сагындым шул Гаптелхәйне, ичмасам, бер килеп тә чыкмый диде Иленура. Кызлар күңелендә нәрсә булсын — сагыну да юксыну инде.

— Кит!— диде Иленура, инәсенә кычкырып, муенындагы гәрәбә шикелле кызарынып.— Бер дә алай димәдем. Укуын да бетергәндер — ичмасам, бер килеп тә чыкмай дидем лапса!

— Шулай дидеңмени соң әле? Истән чыккан,— дигән булды яшәби. Шуннан соң кулындагы төенчеген каенанасына бирде һәм аңлатып, Габделхәйгә карап: — Күнлек ризык,— диде.— Ярты кила он. Печәнгә йөрүчеләргә җан башыннан өч йөз грамм он бирелә. Безгә өч кешегә күп тия. Яртысын болында пешереп ашайбыз, яртысы өйгә кайта. Хәзер инде тамак тук. Печәннең файдасы бар аның, Гаптелхәй.

Бу сүзләрне ул Габделхәй алдында үзләренең һич тә ач түгеллекләрен күрсәтергә тырышкан сыман итеп әйтте, ләкин чынлыкта бу Габделхәйнең түгел, үзләренең күңелләрен юату өчен әйтелде бугай. Габделхәйгә уңайсыз булып китте. Төенчеккә төйнәп алып кайтылган куш йодрыктай он өчен, Иленура өчен, яшәбисе өчен уңайсыз булып китте. Күрәсең, яшьбабай да шундый ук уңайсызлык кичерде — бернигә катышмыйча, хәлсез бер елмаю белән елмаештырып, баскан урынында катып тик торды. Шуннан соң ул, кулындагы бишмәтен чөйгә элеп, аягындагы солдат итеген салып куйды, аяк астында диярлек аунап яткан бер мендәрне баш астына кыстырды да туп-туры как идәнгә сузылып ятты.

Эшчеләр кайткач, картәтәй дә үз ягына чыгып ишек төбендәге сикесенә ятты. Габделхәй, эш югында эш булсын дип, картәтәсенең калыплап куелган чабатасын катнарга тотынды. Хатын-кыз табак-савыт, бидерә-көянтә шалтыраттылар, дөп-дөп басып баскычтан төштеләр, мендәләр, кычкырып сөйләштеләр. Бала-чага үзара чыр-чу килде. Картый аларга кычкырып-кычкырып алды.

Бераздан көтү кайтты. Ишегалдында сыер мөңгерәгән, сарык кычкырган тавышлар ишетелде, урамда — тәрәзә турысында — ниндидер хатын-кызлар сөйләшеп тордылар. Теге якта, казанда, авыз суларын китереп, бөтен өйгә, бөтен ишегалдына, урамга тәмле ис таратып, итле аш пеште.

Чабатасын катнап бетергәч, Габделхәй чоланга чыкты. Яшь бабасын ул йоклагандыр дип уйлаган иде, ләкин ул йокламаган икән.

— Каян килдең — турыданмы, күпердәнме?— диде яшьбабай.

— Турыдан,— диде Габделхәй.— Мин баягынак ук килдем инде. Бодай басуыннан килдем. Бодай быел каерылып уңган, яшьбабай.

— Анда бер марҗа кызын чәнчеп ташлаганнар ди бит әле, дүрәкәй,— диде яшьбабай, җанланып. Аннары урыныннан калыккандай итте дә ачык ишек аша теге яктагы әтәсенә кычкырды: — Әтәй!— диде.— Бүә буенда бер марҗа кызын чәнчеп киткәннәр ди!

— Һы,— диде карт, берни аңлатмый торган ымлык чыгарып.

— Кешеләр килеп җиткәндә теле булган, ике-өч җирсенә казаганнар, дүрәкәй! Ике йөз илле сум акчамны алдылар дигән.

— Кем ишеткән соң аны?— диде Габделхәй, казап үтерелгән марҗа кызының шулай дип әйтүенә шик белдереп.

— Гыйльмулла Зәкиләре артыннан килеп җиткәннәр. Ат белән кайталар икән. Арбасына салган да шундук кире Яңавылга борылган. Шунда әйткәндер инде, энем,— диде яшьбабай.

— Кемнәр казаганын да әйтте микән?— диде Габделхәй, төпченеп.

— Анысын белмәймен,— диде яшьбабай.— Кем булсын — Яңавыл ышпанасы. Кичтән балык каптырырга килгән булалар да үткән-сүткәнне аңдып кына яталар.

— Мин анда беркемне дә күрмәдем,— диде Габделхәй.

— Алар сиңа күренеп ятамыни, дүрәкәй!— диде яшьбабай.

— Һы, ярай инде, бәхетең, улым,— диде картәтәй теге

яктан, Габделхәй белән сөйләшкән сыман.— Бер тәңкә акчаң өчен җаныңны алырлар. Ярай инде, Ходай саклаган.

— Саклаган!— диде Габделхәй, көлеп.— Ходайда минем кайгы ди!

— Алай сүләшмә, улым,— диде карт.— Көфер сүзе сүләйсең. Укыган дип тормас ул сине. Әллә нәрсә күрерсең.

— Сакланып йөрү кирәк, Габделхәй,— диде яшьбабай да, әтәсе сүзен куәтләп.

Габделхәйнең Ходай турында әйтелгән кимсетүле сүзе олыларга күңелсез тәэсир итте һәм алар икесе дә яшь җегет өчен уңайсызланып тынып калдылар. Бу кыен тынлыкны Габделхәй үзе дә тойды һәм уңайсызлыгын оныттырмакчы булып:

— Печән ничек соң быел, яшьбабай?— диде.

— Печәне ярыйсы, эше авыр,— диде яшьбабай, теләртеләмәс кенә.

— Бодай уңган быел!— диде Габделхәй, дәртләнеп.

— Шулай шул,— диде яшьбабай.

— Басу капкасына терәлеп утыра. Шундый биек!— диде Габделхәй, кирәгеннән артык мактауга бирелеп.

— Аны әле җыеп аласы да бар, энекәем,— диде яшьбабай, сүлпән генә.

— Комбайннар җитәрлекме соң быел, яшьбабай?— диде Габделхәй, аның саен белдекләләнеп.— Комбайны булса, аны инде урып алуы берни түгел, иеме, яшьбабай? Вакытында уралмау харап итә сезне.

— Анда гына эш тормай,— диде яшьбабай.

Шул чакны, сике такталарын шыгырдатып, картәтәй урынында кыймылдап куйды.

— Машина эшләй, машина ашай хәзер, улым,— диде Габделхәйгә, эндәшеп.— Җире безнеке, ашлыгы — хөкүмәтнеке. Сызыра да ала. Синең үзеңә ашарга каламы, юкмы — сорап та тормай.

Картәтәсенең кирле-мырлы сүзләрен ишетү белән, Габделхәйнең барлык изге теләкләре, күтәренке уй-хисләре юкка чыкты. Картәтәсенең дөрес сөйләмәгәнлеген дә яхшы белде, тик шулай да аның ише искелек калдыгы белән бәхәсләшергә үзендә көч тапмады. Бәхәсләшү түгел, аның белән хәтта җайлы гына, иплəп кенә сөйләшеп тә булмый сыман иде. Ул үзе турында гына, үзенең бүгенгесе, хәзергесе турында уйлый ала, үзенең чабатасыннан башка бернәрсәне күрергә дә, белергә дә теләми иде. Бит мохтаҗлык бер монда гына, Янтыкта гына, Яңавылда гына түгел. Бөтен илдә шулай! Сугышта җимерелгән-кырылган авылларны, шәһәрләрне торгызасы бар, завод-фабрикаларны эшкә җибәрәсе бар. Украина, Бело-

руссия әле һаман җимерек хәлдә. Андагыларның хәле безнекеннән дә яманрак. Ярый әле сугыш монда кадәр килеп җитмәгән — шуңа сөенергә кирәк. Ул әнә сөенә белми. Ул, гомумән, бернәрсәгә дә сөенә белми бугай. Политик аңсызлыгы турында инде әйтеп тә торган юк.

— Синең шул бер үк балык башы булыр инде, картәтәй,— диде Габделхәй, картәтәсен җиңелчә шелтәләп.

Күңеленнән ул яшьбабасының үзен яклавын өмет итте. Моңарчы еш кына аларның сүзләре килешә торган иде. Элегрәк шулай өчәүләшеп чәкәләшеп киткәндә яшьбабай гел Габделхәйне яклый торган иде. Ни әйтсәң дә, яшьбабай аңлырак, белемлерәк. Бөтен яшьлеге аның шаушулы елларда — колхозлашу, культуралашу елларында үткән. Белеме дүрт сыйныфтан ары узмаган, ләкин шаулы елларда ул үз авылының, үз чорының иң алдынгы, иң актив яшьләреннән исәпләнелгән. Башта «каңсамул»-га, аннан «фартия»гә кергән, шуннан «ата каманис» булып киткән. Картәтәй бик үк риза булмаган, ләкин ул каршы килгән саен, яшьбабай киреләнеп алдынгылар рәтендә йөри биргән. Сугыш башлану белән ул беренче елны ук сугышка алына, Сталинград янында каты яраланып авылга кайта. Ярты ел чамасы урында ятканның соңында яңадан аягына баса, ләкин ул вакытта инде хәрби хезмәткә яраклы булмый — сул як кулы гарипләнеп кала. Сугышта булып кайтуын исәпләмәгәндә, беркайчан ул читтә йөрмәгән. Бөтен гомере авылда үткән. Актив комсомол, актив коммунист авылда нинди эшләр башкара алса, ул да шуларның барысын да башкарган. Колхоз оешкан елларда фермада ат караган, колхозда яшелчә бакчасы оештырылгач, шунда бригадир булган. Яшелчә бакчасыннан соң «Алга» колхозында җиләк-җимеш бакчасы утыртканнар. Баш кеше итеп, бригадир итеп тагын «каманис» Вәлиәхмәт иптәшне куйганнар. Сугышка шул чагында алынган. Сугыштан яраланып кайткач, хәле шәптән булмаса да, иң җаваплы эшкә — амбарга төнге каравылга билгеләгәннәр. Ныклап торып аягына баскач исә шул ук амбарда ашлык кабул итүче һәм «заф» булган. Быел менә бригадир итеп сайлаганнар.

## X

— Безнең әтәй әйтсә әйтә инде ул,— диде яшьбабай, гамьсез генә, бер якны да яклыйсы килмичә.

— Мин әйткәнне тыңласагыз, эттәй уңган кеше буладырыегыз да, тыңламадыгыз,— диде картәтәй, сикесеннән торып утырып.— Әнә, бәләкәй авыллар сугышка чаклы

да, сугыштан соң да машина кертмәделәр — үзләре эшләй, үзләре ашай. Ул чакта да әйттем мин сезгә.

— Син әйтү белән генә бармай шул дөнья,— диде яшьбабай.— Югарыда синнән дә акыллырак кешеләр утыра, этәй. План килеп төштеме, үтәмәй хәлең юк.

— Эшләү пылан белән, ашау гырам белән,— диде картәтәй.

— Пыланын да үтәйсең. Анысы гына үтермәй. Пылан өстенә пылан килеп төшә — шунысы үтерә, энекәем,— диде яшьбабай.— Былтыр көз орлыкка дип калдырган ашлыкны да илебатырга илтеп тапшырдык. Быел язга чыккач үзебезнең шул ук орлыкны хөкүмәттән үтичкә сорап алдык. Анысы да ялынып-ялварып кына әле. Көз көне икеләтә түләү шарты белән, дүрекәй!

— Элек байга сорап бардык, хәзер — хөкүмәткә!— диде картәтәй.— Бай бирсә үзенекен бирде, хөкүмәт — безнекен.

— Байның да үзенеке булмаган ла, ул да ярлыдан алган,— диде Габделхәй.

— Байның эшләгәне булды, эшләмәгәне булды,— диде картәтәй.— Үз ашлыгын теләсә сатты, теләмәсә ярлыга таратты.

— Тараткандыр! Табарсың байдан!— диде яшь җегет, чамадан тыш остарып.

Картәтәй эндәшмәде — бала белән сатулашып торуны, күрәсең, кирәксез санады.

— Элек аның ялкавы гына, эш сөймәгәне генә ярлы булган, энекәем,— диде яшьбабай.

— Машина бозды дөньяны, машина!— диде картәтәй, ачу белән.

— Алайса, яңадан сукага, агач тырмага тотыныргамыни?— диде Габделхәй.

— Һы!— диде картәтәй.— Элек, улым, сука да агачые, ашаган калачые. Хәзер әнә сука да тимер, тырма да тимер — б...ны кимер! Ишеткәнең юкмыни?

— Әтәйнең шул инде: атны сагына, суканы сагына,— дип куйды яшьбабай, ялкау гына.

— Сагынырсың!..— диде карт, уфтанып.

— Сугышка чаклы аның җитәрлек аты да барые,— диде яшьбабай, аңлатып.— Бөтен эшне ат белән башкардык. Трактор шул кызык өчен генә... Күпме атны сугышка алып кырдырдылар, дүрәкәй! «Башкырт дивизиясе» дигән булып, атка атландырып танкка каршы сугышка җибәрделәр. Адәм әйтеп адәм ышанмас: кулда кылыч, агач мылтык...

— Агач мылтык?!— диде Габделхәй, ышанмыйча.

— Чып-чын агач мылтык!— диде яшьбабай.— Ничек

исән калганбыздыр — әле дә исем-акылым китә. Күпме ат, күпме кеше кырылды! Таудай өелеп калдылар, дүрәкәй! Хәзер менә ат та юк. Аттан бигрәк эшләр кеше калмады.

— Барысы да укымышлыга әйләнде,— диде картәтәй.

— Укымышлы! Тапкан бер сүз!— диде яшьбабай, әтәсенә кычкырып.— Эшләрдәй кеше ничек тә читкә китәргә тырыша — укыганы да, укымаганы да. Тамак куалай энем, тамак.

— Ат та юк, кеше дә юк, шулай булгач, трактор-комбайн кирәкмимени?— диде Габделхәй, яшьбабасының йомшак җирен капшап.— Авылда никадәр машина күп булса, шулкадәр яхшырак түгелмени? Әнә алдынгы колхозларда шулай бит... гәзитләрдә гел язалар...

— Болай караганда әйбәт ул,— диде яшьбабай, беравык эндәшми ятканнан соң.— Машина тиз эшләй, күп эшләй. Ләкин ул бушка эшләмәй. Эшләгән өчен барысын да җыя да ала. Натурплата. Ат белән эшләгәндә натурплата юк. Хөкүмәткә тиешлесен илтеп саласың да әзме-күпме үзеңә дә кала. Машина эшләгәч алай түгел. Иң әүвәл хөкүмәткә план тутыра алмай җаның чыга. Анысын тутырасың — натурплата дигәнен сала башлыйсың. Ягъни трактор, комбайн эшләгән өчен мытыеска түләйсең. Мытыес кемнеке? Хөкүмәтнеке!

— Һы, аның чокырының тулганы юк,— диде картәтәй.— Күпме бирсәң дә ала — бир генә!

— Менә син шунысын да уйлап кара, энекәем,— диде яшьбабай Габделхәйгә.— Аның тагын шул ягы да бар: ат белән эшләгәндә элек кеше, әйтик, гектарыннан йөз илле пот алган, трактор белән эшләгәндә кайчагында иллегә дә тулмай.

— Булмас ла, яшьбабай!— диде Габделхәй, шаккатып.

— Ник булмасын, була!— диде яшьбабай.— Шулай. Җылдан җыл кими бара. Җыл да каерылып уңмай ул ашлык!

— Никтер ышанасы килми,— диде Габделхәй, икеләнеп.— Әнә гәзитләрдә язалар: әллә нинди бай колхозлар, миллионер колхозлар бар диләр. Сездә персидәтел булдыксыз — шуңа ул, яшьбабай.

— Их, энекәем!— диде яшьбабай, ачынып.— Яшь шул әле син. Китапчарак уйлайсың. Персидәтел берүзе берни эшләй алмай. Теләсә кемне утыртып куй — барыбер шул булачак.

— Ник?!

— Ник дисәң, шул — персидәтелнең кулы-аягы бәйле. Гектарына мең пот алса да, халыкка, эшләгән кешегә

тамагы туярлык бүлеп бирә алмаячак. Халык барыбер ач калачак.

— Шулай да — ник? Нишләп алай?— диде Габделхәй, төпченеп.

— Аңлаттым бит инде,— диде яшьбабай.— Үз планыңны тутырсаң, өстәмә план килеп төшә. Күршеләр өчен, артта калган колхозлар өчен янәсе, үзара ярдәмләшү өчен. Район планын тутырсаң, тагын әйтәләр: сез нәрсә үз кайгыгызны гына кайгыртасыз — бөтен республика кайгысын кайгыртырга кирәк диләр.

— Кеше кайгысын кайгырткан арада үз халкың ачтан кырылып бетәчәк,— диде картәтәй.

— Гектарына ... мең пот алып булса, ул чагында!..— диде Габделхәй, буш хыялга бирелеп.— Ул чагындамы, яшьбабай!

— Алырсың — тот капчыгыңны!— диде яшьбабай, көлеп.— Мин бит аны болай гына әйттем.

— Мең пот алсаң да, ике мең пот алсаң да шул булачак,— диде картәтәй үз сүзен тукып.

— Алырсың мең пот!— диде яшьбабай да, тынычлана алмыйча.— Мытыеска гектар исәбе булсын да, натурплата тулсын. Гектарыннан күпме чыга, анда аның эше юк. Ашлык уңса да, уңмаса да, мытыес үзенә тиешлесен каерып ала. Ул сөреп, чәчеп киткән урында ник шунда гөмбә үсми — гамендә дә юк. Менә бит ул эшләр ничегрәк, энекәем. Җирне яхшыртабыз дип бозып кына бетердек.

— Ничек — бозып?— диде Габделхәй, аңламыйча.

## XI

Ул, игенче булмаса да, колхоз, авыл тормышын яхшы беләм дип исәпләде, чөнки буш вакытларында әледән-әле Сталин клубындагы китапханәгә керә, шунда гәзит-журнал укырга ярата иде. Бүгенге көн политикасына кагылышлы озын-озын мәкаләләрне, докладларны, һәртөрле карарларны ул җентекләп укып, өйрәнеп бара иде. Моңа ул сугыш елларында әвәсләнде. Бит сугыш елларында, бигрәк тә соңгы елларда бер аның гына түгел, бөтен илнең күзе — гәзиттә, колагы — радиода булды, һәркемне фронттагы хәлләр, иң соңгы хәбәрләр кызыксындырды. Ул вакытта безнең гаскәрләрнең һәр адымы, һәр җиңүе турыдан-туры аның үзенә дә кагылган кебек, бөтен илдәге ачлык, мохтаҗлык та һәм шулай ук һәрбер уңай яки кире үзгәреш тә турыдан-туры аңа да кагылды. Шунлыктан авыл, авыл хуҗалыгы, колхоз турындагы һәр яңалык белән кызыксынмау мөмкин түгел иде. Ләкин бу мәсьәләдә ул

күбрәк гәзиттә язганга, радиодан сөйләнгәнгә генә ышана һәм бары шуларны гына дөрес дип исәпли иде. Иген эшенә, җир эшенә кагылышлы нәрсәләрне ул теләсә дә, теләмәсә дә тиешенчә аңлап җиткерә алмый иде.

— Трактор җирнең әрлән балчыгын чыгарып сөрә,— диде яшьбабай, фикерен дәвам итеп.— Нурмысы аның — җегерме ике сантиметр. Җегерме ике сантиметр тирәнлектә сөрмәсең — штраф. Астагы әрлән балчыгын өскә чыгара, өстәгесен күмеп куя. Арышның, бодайның тамыры җегерме ике сантиметрга төшмәй. Өстә генә. Күп булса, ун сантиметр.

— Укыган кешенең шуңа да башы җитмәй,— диде картәтәй.

— Билчәннеке тирән китә,— диде яшьбабай.

— Һы! Башы булган кеше билчән белән арышны гына аерырга тиешие дә — баш юк. Аңгыранумнар!— диде картәтәй.

— Сүләсәң сүз күп инде ул, энекәем,— диде яшьбабай, көрсенеп.— Трактор, комбайн җирне таптап бетерә, ташка әйләндерә. Анда ниндәй ашлык үссен?! Элек кеше җирне белеп, кадерләп торган. Хәзер аның кадере китте. Мытыеска җир кирәкмәй, колхозга — кирәкмәй, колхозчыга — шулай ук кирәкмәй.

— Ничек инде ул — «кирәкмәй»?— диде Габделхәй.

— Шулай. Кирәкмәй,— диде яшьбабай.— Әйтик, менә хәзер өләшеп бир элеккечә һәр кешегә — беркем алмаячак, төкереп качачак! Халыкны җирдән биздерделәр. Эш менә нәрсәдә, энекәем!

— Кызык,— диде Габделхәй.

— Кызык шул,— диде яшьбабай.— Шундаен да кызык, утырып кына җыласы калды, дүрәкәй. Калхуз да элекке калхуз түгел хәзер. Элекке бердәмлек, тырышлык, гаделлек юк.

— Үзе ашыга, үзе ачыга, үзе баралмай, үзе таралмай. Белмәйсеңмени?— диде картәтәй һәм янә көрсенеп, уфтанып куйды.

— Син гел дошман сүзләр генә сөйлисең, картәтәй,— диде Габделхәй, коры гына.

— Һы, рәхмәт, улым,— диде картәтәй, хәтере калып.— Мин инде күптәнге дошман. Калхузга мин беренче булып кердем. Җегерме җыл бил бөктем. Менә хәзер күзем дә рәтләп күрмәй, аякның да хәле юк. Өйдә чабата ясап ятам. Шулай да әле онытып җиткермәгәннәр — бау-шу ишәргә кирәк булса, миңа китерәләр. Акыллы кеше күптән төкереп качты шәһәргә, шахтыга... Без менә өелешеп ятабыз... дошман кешеләр...

Йомшак кына атлап чоланга яшәби килеп чыкты.

— Нишләп «өелешеп ятасыз» сез монда?— диде ул, күрәсең, каенатасының сүзләренә ишарәләп. Аңа беркем җавап бирмәде.

— Тиргәштегезмени?— диде яшәби.

— Һы, тиргәштек дисәң дә ярай,— диде картәтәй.

— Лыгырдама инде юк-барны!— диде яшьбабай, әтәсенә кычкырып.

— Син быел укуыңны да бетердең бугай?— диде яшәби Габделхәйгә.

— Бетердем,— диде Габделхәй, теләр-теләмәс кенә һәм картәтәсен күз алдында тотып: «Нәрсә әйтер икән?»— дип уйлап куйды. Хәзер ул аннан ни өчендер шүрли башлагандай булды.

— Хәзер укыганнар заманасы,— диде яшьбабай, Габделхәйне мактап.— Безнең әтәй сүләй дә соң ул сүләвен, үзе томана: искечә дә белмәй, яңача да.

— Укымасак та яшәдек әле,— диде картәтәй.— Бер дә кешенекеннән ким җиребез булмады. Җимертеп эшләдек, җимертеп ашадык. Сез әнә укыган да бит, тамагың ач булгач, төкерәеммени?!

— Безнең Иленура назан калды инде,— диде яшәби пошынып, шулай да артык кайгыртмыйча.— Җидене дә көчкә бетерештерде. Кеше арасында кием-салымы да булмады, ашарына да юк. Ач баланы интектергәнче дидек инде.

— Һы, бер дә кешедән ким җире юк әле,— диде картәтәй, Иленураны яклап.— Укымагач, көн дә әнә үзеңнең янында, көн дә өч йөз гырам он алып кайта. Укыган булса, койрыгын да күрмәсиең.

— Укыса, синеке түгел инде ул балаң — хөкүмәтнеке,— диде яшәби, каенатасына ярарга тырышып.

— Калды инде,— диде яшьбабай да.

— Теләсә, әле дә соң түгел,— диде Габделхәй, җанланып. Бездә торып укыр — җибәрегез безгә, яшәби. Мин Казанга китәм. Иркенләп торырлар.

— И, энекәем!— диде яшьбабай.— Кая инде ул безгә!

Шул чакны тыштан Зифун килеп керде, әтәсе янына сузылып ятты да колагына нидер пышылдарга тотынды.

— Зифун менә укымышлы булыр!— диде яшьбабай, малаен мактап.— Безнең Зифун әтәсеннән дә, инәсеннән дә уздырыр, апасы өчен дә укыр. Гел дөнья болай тормас әле, рәтләнер.

— Һы, көт, рәтләнер теге дөньяда!— диде үзсүзле карт.

— Сифуннар, Типуннар авыз тутырып ипи ашарлар,—

диде яшьбабай, янындагы улын иркәләп.— Мукчаларын тутырып китәр ләбаса минем улым беркөнне мәптеккә!

— Мукча тулы ипи булырмы?— диде бала, ихлас бер ышану белән.

— Мукчага ипи салмайлар — китап-дәфтәр салалар,— диде әтәсе, аңлатып.— Ипине син кесәңә генә салып барырсың.

— Мин кесәне бик зур итеп тектерермен!— диде малай, хыялланып.

— Капчык кебек итеп тегеп бирермен, улым,— диде инәсе.

— Ыы шул, кулыма мукча тотармын, кесәмне аркама асармын,— диде малай, көлеп.

— Һы, капчык асып чыгасы гына калды!— диде карт, сике такталарын шыгырдатып.

— Җитәр инде, пычрак каргасы!— диде яшьбабай, әтәсенә кычкырып.— Өзмәс тә, куймас та шул бер тотынса...

— Улың каманис булгач, пычрак каргасы булмай хәлең юк,— диде картәтәй, тынычлана алмыйча.

## XII

Казандагы итле аш, ниһаять, пешеп чыкты. Бөтен өйгә бәйрәм төсе керде. Барысының да күңелләре күтәрелеп китте. Балалар, ике өйне бер итеп, чыр-чу килеп куыштылар да кинәт кенә тынып калдылар. Олылар исә, әле генә булып алган сөйләшүне онытып, әкрен генә өстәл тирәсенә җыела башладылар.

Хатын-кызлар казан янында булашкан арада, картәтәй капшанып шүрлектән өч йомыры алды. Йомыры-ларның зуррагын, яхшырагын Вәлиәхмәт улы алдына, икенчесен Габделхәй алдына, өченчесен, сайсызын үзенең алдына куйды. Шуннан соң киез итекле аякларын шактый җитез хәрәкәтләндереп чолан якка чыгып китте. Аның шулай тыз-быз килеп йөрүенең серен бик яхшы аңлаган яшьбабай канәгать төс белән көлемсерәп куйды.

— Безнең әтәйнең шул ягы әйбәт,— диде.

Картәтәй, берәрсе берәр сүз әйтсә шундук аны чукып алырга әзер булып, җитди, хәтта усал бер кыяфәттә яңадан өстәл янына килде, яртылы шешәне тантана белән улы алдына утыртып куйды, калтыранган бармаклары белән кәгазь бөкене ачты да хөрмәт йөзеннән «каманис» улына:

— Әйдә, үзең кара. Түгәрмен кебек,— диде.

Яшьбабай шешәне үз кулына алды, тулымы-түгелме дигәндәй, чамалап бераз кулында тотып торды һәм иплэп кенә әтәсенең йомырысына агыза башлады.

— Мин эчмим. Миңа салма,— диде Габделхәй, ашыгып.

— Һы, синең әле шундай өнәрең дә бармыни?— дигән булды картәтәй.

— Эч. Буыннарың йомшап китәр,— диде яшьбабай, артык кыстамыйча гына.

— Аның буыны болай да йомшактыр. Укыган кешедә буын буламыни?— диде картәтәй.

Габделхәйнең ачуы килеп куйды. Картәтәсенә үч итеп аның үзенең дә «буынлы» икәнлеген күрсәтәсе килеп китте. Әйткән сүзеннән кире кайтып ул инде эчәргә дә ризалык белдермәкче иде, ләкин шул чакны яшьбабай аракы агызудан туктап калды.

— Нәрсә соң бу?— диде ул, аракы салынган йомырыны күзенә якынрак китереп.

— Һы!— диде карт, эре генә.— Каманис кеше ышанмай инде ул. Иснәп кара.

— Иснәп! Иснәп түгел, күзең белән кара син аңа иң элек!— диде яшьбабай, йомырыны әтәсенең күзенә төртеп.

— Нәрсә бар?— диде карт, каушагандай итеп һәм күрмәс күзләрен челт-мелт йомгалап, йомырыга текәлде.— Берни күрмәймен. Әллә чүп төшкән?

— Кара ич бу, язу карасы!— дип кычкырды яшьбабай.

— Нишләп кара булсын, ак лабаса!— дигән булды карт, шаяртмакчы булып.

— Син үзең ак!— диде яшьбабай. Урыныннан торып, ул аракылы шешәне яктыгарак, тәрәзә янынарак күтәреп карады.

— Каралы шешә. Яздан бирле йөридерие бер шешә буталып,— диде яшьбабай.— Күзең чыккандыр карабрак бирсәң. Кем алып кайтты — Сиринәме?

— Күзем булса, мин аны Сиринәгә дә кушып тормаган булырыем,— диде карт, акланмакчы булып.

— Нишләргә соң?— диде яшьбабай, икеләнеп.— Каян килеп кергәндер бу каралы шешә безнең өйгә?

— Эчмәгез, эчмә,— диде яшәби, кулын селтәп.— Әллә агуланырсыз.

— Әрәм бит әле,— диде яшьбабай.

— Әрәм булгач, эчәсең инде,— диде яшәби.

— Менә ул назанлык бәласе!— диде аш белән булашкан картый, картын оялтмакчы булып.

— Син кысылма — казаныңны кара,— диде карт, тупас кына.

Аның шулай үртәлүенә картыйның күңеле күтәрелеп киткәндәй булды.

— Назан ирне ки яр итмә үзеңә, кыяматтә кара җагар йөзеңә...— диде ул, хәтерендә калган «китап сүзен» такмаклап.

Габделхәй көлемсерәп куйды, Иленура ачыктан-ачык көләргә тотынды. Аннан күрмәкче балалар да көлделәр. Яшәби дә, каенатасына сиздермәскә тырышып, елмаеп куйды. Картый исә, үз-үзен җиңүче санап, батыраеп, җиңнәрен сызганган килеш коштабакларга аш бүләргә кереште. Хәтере калган картның ачудан, уңайсызлыктан калку яңаклары, ирен читләре тартышты. Үлсәм үләрмен, шулай да үземнекен эшләрмен дигән бер кирелек белән үз йомырысын кысып тотты да шәмәхә төсендәге аракыны авызына якын китерде.

— Укымышлылардан курыккан күлмәк күптән тузган,— диде ул, үз-үзен дәртләндереп.

Барысы да, тыннарын кысып, аның авызына текәлделәр. Карт, чыраен да сытмыйча, үзенә тигән өлешне эчеп җибәрде, шомарып беткән зур учы белән авыз читләрен сөртеп куйды, капшанып тәлинкәдән суган кисәге табып алды һәм, тамагын кыргалап, тешсез авызында әвәләргә тотынды.

— Ай-йай, булдырасың икән әле син, дүрәкәй,— диде яшьбабай, әтәсен мактап.

— Төшеп калганнардан түгел,— диде карт, тыйнак кына.

— Булдырмас ул! Чабатадай авызы килешеп кенә тора!— диде картый, пыранлап.— Агу салып бирсәң, агу эчәр. Яшь чагында авызына да алмады, карт самый. Кая аңа ул чакта болай эчеп утырулар!

— Һы, элек!— диде карт, канәгать бер төс белән.— Элек заманасы ниндәй булды? Коллык заманы. Сәвит безгә азатлык бирде. Хөррият. Теләсәм эчәм, теләмәсәм — түкереп ташлыйм.

— Хөрриятне аракы эчәр өчен бирмәгәннәрдер лапса!— диде Иленура, сүзгә катышып.

Картәтәсенең аракы эчеп, җитмәсә бозык, шикле аракы эчеп утыруы өчен аңа Габделхәй алдында бик нык уңайсыз иде. Ләкин картәтәсе аны ишетмәде дә. Ул хәзер, гомумән, беркемне ишетмәде, беркемгә игътибар итмәде — ашыгып, авызын пешерә-пешерә кайнар шулпа чөмерергә тотынды.

— Шөкәтсез! Шөшле авыз!— диде картый, тынычлана алмыйча, картын игәп.

Ләкин картка инде берни дә тәэсир итәрлек түгел иде. Бөтен өй эчендә, барлык ирләр арасында бердәнбер батыр кеше буларак ул, беркемгә дә күтәрелеп карамый-

ча, ашавында булды. Яшьбабай да тәвәккәлләп йомырысын кулына алды, яртысын эчте дә ашарга тотынды.

— Ниме?— диде бераздан яшәби, борчылып.

— Нәрсә «ниме»?— диде яшьбабай, көлеп.

— Эчегезне актармадымы?— диде яшәби.

— Актарса, иң элек әтәйнекен актарыйе,— диде Вәлиәхмәт абзый.

— Аталы-уллы... оят юк, тәүфикъ юк. Көферлек арттырып. Балалар алдында...— диде картый, тыела алмыйча.

Шулай да бераздан ул да тынып калды — кайнар аш, итле аш барлык ачуларны, кире тойгыларны юкка чыгарды. Беркадәр тамак ялгап алгач, яшьбабай үзенең, әтәсенең йомырыларына тагын аракы агызды һәм:

— Әйдәле, әтәй, кайгыларны онытып... тагын берне,— диде дә җырлап җибәрде:

Сандугачлар ояда,
Оялары пыяла.
Яшәсен иптәш Ысталин—
Шәп яшибез дөньяда!

Иленура әтәсе өчен оялып кып-кызыл булды, гафу үтенгән сыман Габделхәй ягына карап алды. Габделхәй исә, күзләрен түбән иеп, эчүчеләр ягына карамаска тырышты. Картый белән яшәби дә күрмәмешкә, ишетмәмешкә салындылар. Картәтәй икенче йомырыны да кулына алды һәм улына җавап итеп:

Сандугачлар ояда,
Оялары пыяла.
Дөмексен иптәш Ысталин,
Шат яшибез дөньяда!— диде.

Шулай диде дә йомырысын авызына каплады. Ул эчеп бераз торгач яшьбабай шелтә белән:

— Әтәй! Җырның сүзен бозма!— диде.

— Лилин биргән хөрриятне кысарга хакың юк!— диде картәтәй.— Теләсәм — җырлаймын, теләмәсәм — юк.

— Хөррият булгач, мин дә җырлап күрсәтәем әле,— диде картый сүзгә кушылып һәм көйләп янә такмак әйтә башлады:

Исереккә сәлам бирмә,
Бирсә дә ул, аннан алма,
Исерекнең хәлен белмә,
Алла диген, бәдәвам,— диде.

Иленура, авызын каплап, пырхылдап җибәрде. Яшьбабай, «тик тор!» дигән сыман, яраткан кызына ачулы гына карап алды, Габделхәй исә, шагыйрь кеше буларак, кар-

тыйсының «шигыренә» шундук үзенчә бәя бирде. «Йомшак эшләнгән. Коры дидактика» дип уйлады. «Коры дидактика»ны Антонина Семеновна әйтергә ярата иде. Габделхәй дә, аннан күрмәкче, теләсә нинди шигъри юлга карата шундый тәнкыйть сүзләре кулланырга тырыша иде. Ләкин «коры дидактика» картәтәйгә бөтенләй көтелмәгәнчә тәэсир итте. Корткасының җае чыккан саен, китап сүзе сөйләргә, мөнәҗәт әйтергә яратуын ул болай да өнәп бетерми иде. Хәзер аның шулай ирләр арасына кысылып, остарып утыруы картның тәмам күңелен болгатып җибәрде.

— Тынычлап ашарга да ирек юк,— диде ул, үпкәләп.— Ашаганың да күренә, эчкәнең дә. Үз акчама алган — синекенә түгел.

Шулай сөйләнә-сөйләнә ул ашалып бетмәгән ашын калдырып, чайкалып урыныннан торды. Мысык-мысык борынын тарткалап, өстәл арасыннан чыкты да ишек төбендәге сикегә, үз урынына барып ятты.

Габделхәйгә кыен, бик кыен булып китте. Менә хәзер кем дә булса торыр да карт кешене барып юатыр, берәр җылы сүз әйтер шикелле тоелды. Ләкин беркем аның янына бармады, беркем юату сүзе әйтмәде. Барысы да тынып, сагаеп калдылар.

— Картәтәй җылай!— диде Иленура беренче булып, кызганып.

— Җыласа... Эчмәскә яхшы булыр моннан соң... карт башына!— диде картый.

— Үзеңне-үзең белмәгәч, эчәсе түгелие дә соң,— диде яшьбабай да.

— Ярар инде, каныкмагыз барыгыз да бер кешегә!— диде яшәби.

## XIII

— Картый, ишеттеңме әле — Бүә буенда бер марҗаны чәнчеп ташлаганнар,— диде Иленура, картыйсына эндәшеп.

— Ишеттем, кызым,— диде картый.— Ходаем, афәтле үлемнән сакла. Тамак харап итә кешене. Тамак тәмугка кертә адәм баласын. Гаптелхәй улым да турыдан гына килгән бит әле.

— Турыдан?!— диде Иленура, ашавыннан туктап.— Кит, дивана! Икенче җөре тагын шуннан!

— Каян йөрим соң?— дигән булды Габделхәй.

— Чигәсенә чәнечкәннәр ди, мескенкәемнең,— диде Иленура, Габделхәйгә җавап биреп тормыйча.

— «Мескен» түгел, «мәрхүмә» кирәк,— диде картый, төзәтеп.

— Чигәсенә түгел, күкрәгенә,— диде яшьбабай да, сүзгә катышып.

— Юк, чигәсенә!— диде Иленура.— Аннан — аркасына. Сәлимә әйтте.

— Белә синең Сәлимәң!— диде яшьбабай, әтәсенә кычкырган кебек кычкырып.

— Белмәс инде!— диде Иленура, сүзен бирәсе килмичә.

Үз сүзенә ныграк ышандырасы килгән сыман ул хәтта иңбашын сикертеп куйды һәм «шулай ич, иеме?» дигәндәй, яклау эзләп Габделхәйгә карап алды.

— Фәнзия апаның кызы бар икән лапса, ишеттегезме әле?— диде ул шундук, «чигәсенә чәнечкән» марҗа кызын да, Сәлимәне якларга кирәген дә онытып.

— Монысы ничәнче инде? Бишенче бугай?— диде яшәби, тыныч кына.

— Бишенче,— диде Иленура.

— Кызлардан бәхете бар Фәнзиянең,— диде яшьбабай.

— Бер малайлары да булмагач, күңелсездер ул, иеме, әнкәй?— диде Сиринә, инәсенең авызына карап.— Безнең Зифун бар, иеме, әнкәй?

Олылар җиңелчә генә көлешеп алдылар. Сиринә, гаеп сүз әйттем, ахрысы, дип уйлап, олыларның әле берсенә, әле икенчесенә карап-карап алды, ләкин нинди гаеп сүз әйтүен аңлый алмады.

— Менә, энекәем,— диде кызмача яшьбабай, бернигә катышмыйча утырган Габделхәйгә.— Элекке заман булса, Фәнзиядән ярлы кеше булмасые.

— Нишләп?— диде Иленура.

— Ник дигәндә, шул, дүрәкәй, җир бүлгәндә кызларга элек өлеш чыкмаган, җир малайларга, ирләргә генә бирелгән,— диде яшьбабай, аңлатып.— Менә шуннан, әйтик, берәүнең биш малае бар ди, дүрәкәй. Аннан килеп, үзе, ата кеше. Булдымы алты? Алты кеше, алты ир кеше, дүрәкәй. Моңарга хәзер, ызначытса, алты өлеш җир бирелә. Берәүнең хәзер биш кызы бар ди. Фәнзияләрнеке кебек. Атасыннан башка ир заты юк. Бирелә моңа, ызначытса, бер өлеш җир.

— Нигә алай соң ул?— диде Иленура, аңламыйча.

— Хатын-кызның хокукы булмаган патамушты,— диде яшьбабай, бөтен өйгә кычкырып.— Хокукың юк — җирең дә юк. Хатын-кызны чутка да тыкмаганнар. Менә шуннан, әйтик, безгә өч өлеш тия: әтәйгә, миә, Зифунга. Сезнең берегезгә дә юк. Аңлашылдымы?

— Кит! Яшәгәннәр инде шунда!— диде Иленура, иңбашын сикертеп һәм, «шулай ич, иеме?» дигән сыман, Габделхәйгә елмаеп куйды.— Безнең картәтәй генә мактай элекке заманны. Яшәгәннәр эт көнендә.

— Бер дә кешедән ким яшәмәдек,— диде картәтәй, сике ягыннан аваз биреп.

— Әй! Син исәнмени әле, әтәй?— диде яшьбабай, көлеп.— Әйдә, кил. Ату бетерәм.

— Кил инде, кил, әтәй — ашың да суына,— диде яшьәби ипләп кенә, ягымлы итеп.

Карт җавап кайтармады. Тагын бераз кызгандырып алырга теләгәндәй, ахылдады-ухылдады да торып утырды.

— Булмай. Тәкать калмаган,— диде шулай да, әле һаман ялындырасы килеп.

Габделхәй җитез генә урыныннан торды, картәтәсе янына килде дә аны култыклап алды.

— Әйдә, картәтәй!— диде.

— Менә... игелекле бала булгач...— диде картәтәй, Шәмсебанат кызының улын мактап, һәм бернинди каршылыксыз өстәл янына үз урынына килеп утырды.— Боларда шәфкать-миһырбан калмады, улым,— диде җыламсырап.— Минем күзләрем йомылганны гына көтәләр. Калдырыр байлыгым да юк... шөшлемнән башка. Күз кырыена да чыгармайлар, улым. Кайткач инәңә әйт, Шәмсебанат кызыма — килеп алсын. Бер көн торасым килмәй шушы зобаныйлар янында.

— Җә инде, әтәй, сүләмә юк-барны — әллә кеше ышандырырсың!— диде яшьбабай, җиңелчә шелтә белән.

— Китагай! Аны гына кыерсыталардыр!— диде картый да.

— Картәтәй, аша инде — ашың суына лапса,— диде Иленура.

Яшәби каенатасы янына ашлы күбәтәсен этебрәк куйды һәм мөмкин кадәр ягымлы итеп:

— Аша, эткәй, аша,— диде.— Син безнең алтын терәгебез. Бар карап торганыбыз — син. Син булмасаң, икенче көнне үк коры таякка калабыз без. Күңелеңә авыр алма безнең юк-бар сүзне. Аша, эткәй, аша.

Яшәбинең шулай юатып, юмалап, йомшак итеп әйткән сүзләреннән соң гына картәтәй кашыгына тотынды.

— Рәхмәт киленгә, ул гына аңлай мине,— диде.

— Менә, маладис безнең әтәй!— диде яшьбабай да, әтәсен мактап.

Шуннан соң ул буш йомырыга яңадан болганчык аракы агызды һәм йомырыны әтәсенең алдына куйды.

— Шуның өчен тагын берне күтәреп җибәр әле, әтәй,— диде.— Хатын-кыз тиргәшә торсын. Тиргәшмәсә ул хатын-кыз да булмай. Хәзергә без — ирләр. Ирләр авыр эш эшләй. Шуңа ул ашарга да, эчәргә дә тиеш. Шулай бит, иеме, энекәем Гаптелхәй?

— Утырган була лапса!— диде кинәт Иленура, әтәсенә үпкәләп, матур иреннәрен күптереп. Ләкин шундук Габделхәй ягына борылып карарга да онытмады. «Син тагын чынга ала күрмә аның сүзләрен!»— дигән сыман елмайгандай итеп куйды.

— Хатын-кызның берниндәй хокукы булмаган аның, энекәем,— диде яшьбабай, кулларын болгап.— Хәзер алар безнең белән тигез хокуклы. Дөньяны менә шул бозды: тигезлек!

— Шуңа да муенга атландылар,— диде картәтәй, улының сүзен куәтләп.— Тын алырга да ирек юк.

Хатын-кыз, ирләр, тигезлек-тигезсезлек турында еш кына кузгалып куя торган бәхәснең башы чынлыкта, гомумән, барлык ирләр, хатын-кызлар арасындагы тигезлек-тигезсезлеккә кайтып калмый иде. Чынлыкта бу картый белән картәтәйнең күптәнге бәхәсенә, үзара ниндидер каршылыкларына кайтып кала иде. Габделхәй дә, башкалар да моны бик яхшы аңладылар һәм бер дә монда бөтен дөнья проблемаларын хәл итәбез дип исәпләмәделәр. Тынычлана башлаган сыман тоелган картның яңадан үзен «кыерсытулары» турында авыз ачуы булды, картый да, эндәшми калуны кирәксез санап:

— Шөшле авыз! Атланганнардыр синең муенга!— диде.

— Һы, ireккә чыктылар!— диде картәтәй, үзенә карата әйтелгән тәнкыйть сүзләренә бу юлы бөтенләй игътибар итмичә.— Кияүгә барып өч көн тормайлар — ирек алалар да кайтып киләләр. Ирдән аерылып кайткан хатын бөтен авылга бер булырые булса. Хатын кыйнаган кеше дә бөтен авылга бер булырые. Андай кешене бөтен авыл халкы каһәрләрие.

— Элек бит, әтәй, ирек булмаган, ирек! Хөррият!— диде кызмача яшьбабай.— Хәзер бөтен нәрсә ирек. Сүләмә син элеккене.

— Һы, ирек,— диде карт, мыгырданып.— Барысы да ireккә чыкты. Берсенең ире кыйнай, икенчесенең хатыны кыйнай. Фасикъ дөнья.

— Ирек кирәкмәгәч алай, эчмә!— диде картый, яңадан кыза башлап.— Оят кирәк әзрәк, карт самый. Шул яшеңдә... балалар алдында... Мәчит карты булып, сакалыңны сыйпап кына утыра торган бер вакытта.

— Кая мәчитең? Ник манарасын кисеп төшердең?— диде картәтәй.

— Ярар инде! Кит, тәмле ашның тәмен җибәреп...— диде Иленура.

Картый белән картәтәй тынып калдылар.

## XIV

— Фәнзиягә аш илтеп бирергә кирәк... баладан котылган кешегә...— диде шул чакны яшәби, урыныннан кузгалып.

— Әнкәй, үзем барам!— диде Иленура.— Габделхәй, әйдә икәү? Шунда кинога да керербез.

Әгәр Иленура кинога гына чакырса, Габделхәй әле берсүзсез риза булган булыр иде, ләкин аның бала тапкан хатын янына барырга чакыруы җегет кешенең хәтерен калдырды. «Үзе кебек хатын-кыз дип белә микән?!» — дип уйлады ул.

— Нинди кино ул тагын арыган көенә?— диде яшәби, кызының «кино» сүзен ошатмыйча.— Фәнзия апаңнарга барырсыз да кайтырсыз.

— Һы! Кинога барма дип әйтеп кара син аларга!— диде картәтәй, сукранып.— Элек без ата-ананың күз карашыннан да курка торганыек. Куркыр болар!

— Курка торган заманалар үткән инде, картәтәй!— диде Иленура, җиңел генә һәм «иеме?» дигән сыман янә Габделхәйгә елмаеп алды.

Габделхәйнең күз карашы исә бернинди теләктәшлек белдермәде.

— Син нәрсә теләсә кемгә кычкырасың әле?— диде яшьбабай, үзенең ата кеше икәнлеген күрсәтәсе килеп.— Менә хәзер мин «барма» дип әйтәм икән, бармайсың! Ник дисәң, патамушты син минем кызым.

— Карарлар синең сүзеңә!— диде Иленура, үчекләшеп, иңбашларын сикертеп.

Үпкәләгән сыман ул өстәл яныннан ук торып китте. Күп тә үтмәде, анысын анда орып, монысын монда орып, затлырак, рәтлерәк киемнәрен барларга тотынды.

— Ашап туйгач амин тоту юк, рәхмәт әйтү юк — торды да китте әнә, тәүфикъсыз!— диде яшәби, башбирмәс кызын шелтәләп һәм шул ук вакытта каенанасы белән каенатасына ярарга тырышып.

— Шуңа да бәрәкәт качты өйдән,— диде картәтәй.

— Кызыбыз кинога җыена. Болай булгач Фәнзиягә үзең барасың инде,— диде яшәби яшьбабайга, серле елмаеп.— Фәнзия синең яраткан кызың ич. Хәлен дә белерсең.

— Булган — беткән. Син дә искене актарып утырган булмале,— диде яшьбабай ачусыз гына.

— Ярар, ярар, ник ачуланасың? Болай гына әйтәм. Адәм баласы бит...

Яшьбабай аның сүзләрен ишетмәде, ахрысы — гармун тарткандагы кебек кулларын җәеп җибәрде дә бөтен өй эчен яңгыратып җырларга тотынды:

Кара каен саз саен,
Төядем чана саен.
Апакаем-җаныкаем,
Карама кеше саен.

«Саен» күп кулланыла. Ямьсез. Коры дидактика»,— дип уйлады үзалдына яшь шагыйрь, яшьбабасының җыр сүзләренә игътибар итеп.

— Киногa барып йөрисе юк — кәнсирт үзебездә башланды,— диде яшәби, көлемсерәп.

Күп тә үтмәде, төзәнеп-ясанып Иленура Габделхәй янына килеп басты.

— Әйдә, киттекме, Габделхәй?— диде.

— Киносы нинди? Нәрсә күрсәтәләр?— диде Габделхәй, Иленураның мондый җитезлеген бик үк ошатмыйча.

— «Ибан Грузный» бугай,— диде Иленура.

— Теге мосылманнарны кырган Ибан Грузныймы?— диде картый, исе китеп.

— Шул булмай, шулдыр инде,— диде Иленура.

— Тәүбә-әстәгафирулла!— диде картый.— Кайдагыны казып чыгарганнар, илаһым. Көфер һаман көферлеген итә... Алла дошманнары, мәлгуньнәр!

— Фасикъ дөнья,— диде карт.— Ирекка чыктылар. Хөррият.

— Мин аны күрдем инде. Барасым килми,— диде Габделхәй.

Иленураның шат йөзе күңелсезләнеп калды. Күңеле кырылганын күрсәтмәс өчен ул тиз генә читкә китеп барды. Яшәби чигүле сөлге белән төреп бәйләнгән зур гына чүлмәк тотып кызы янына килде, чүлмәкне кызына бирде дә:

— Кайнар. Пешә күрмә, түгеп җибәрә күрмә,— диде. Шуннан соң яратып кызының аркасыннан сөеп куйды.— Иртән иртүк торасың бар — кинога кереп торма, кызым,— диде.

— Карармын әле,— диде Иленура. Чыгып китәр алдыннан, күрәсең, бер карарга килеп, кискен генә әйтеп куйды: — Бармам,— диде.— Нәрсәм калган соң минем анда?! Кайтырмын.

— Савaптан булсын — менә монысын да бирерсең,— диде картый, Иленурага кечкенә төргәк тоттырып.— Шәмсебанат кызымның күчтәнәче. Күз каргамаслык кына... чәй-шикәр. Тизрәк савыксын дип әйттеләр диген.

— Әйтермен,— диде Иленура.

— И, энекәем!— диде яшьбабай, Габделхәйгә эндәшеп.— Тотарсың хәзерге яшьләрне! Синең сүзеңне алар чүп урынына да күрмәйләр. Шулар белән менә алып бар

син калхуз эшен. Син башлы җегет. Маладис син! Без менә укымаган. Илне туйдырырга кирәк, төзәтергә кирәк ул җимерек-ватыкны. Без дә эшләмәсәк, кем эшләр? Без, беләсең килсә, эш аты, энекәем. Бөтен әрәмтамакны туйдыручы эш аты. Эх, энекәем!

## XV

Иленура чыгып киткәч, өстәл тирәсе бушап, күңелсезләнеп калгандай булды. Вакыт инде соң иде, тышта караңгы иде. Иленураны озатып куйгач, яшәби күзләре йомылып беткән, шулай да олыларның сүзенә колак салып, кызык итеп утырган балаларны куалап йокларга яткырды. Шуннан соң каенанасы белән икәүләп алар тиз-тиз генә табак-савытларны җыештырдылар. Тамагы туйган, күңеле түгәрәкләнгән картәтәй алпан-тилпән үз ягына чыгып китте. Өстәл янында Вәлиәхмәт абзый белән Габделхәй генә торып калды. Кызмача яшьбабай кычкырып җырлап-җырлап алды, озын кулларын бутап сөйләнгәләп алды. Айнык чагында бик аз сөйләшә торган яшьбабай, бераз салып алгач, шулай кирәгеннән артык сүзчәнләнеп китә иде.

Тамагы тук булса да, Габделхәйнең эче пошты. Аның монда яшьбабасы сөйләгән сүзләрне тыңлап та утырасы килмәде, шул ук вакытта үзен генә калдырып китәргә дә уңайсыз шикелле иде. «Әллә Иленураны эзләп китим микән?»— дип уйлады ул утыра торгач. Ләкин аның караңгы урамга да чыгасы килмәде. Шулай нишләргә белмичәрәк утырганда, Иленура үзе кайтып керде.

— Әнкәй! Фәнзия апаның бәбәен күрдем!— диде ул килеп керү белән, кычкырып, шатланып.

— Хәле ничек Фәнзия апаңның?— диде инәсе.

— Хәле әйбәт. Рәхмәт әйтте,— диде Иленура.

— Исем кушканнармы соң әле?— диде яшәби.

— Юк. Әй-лә. Белмәймен. Сорамадым,— диде Иленура.— Бер дә кеше баласы кебек түгел ул, песи баласы кебек кенә.

— Кит, самый, сүләмә юкны. Кеше баласын песи баласына охшаталармыни?!— диде яшәби.

— Нишләп самый булыйм мин?— диде Иленура, инәсенең Габделхәй алдында үзен шулай дип атавына хәтере калып.— Ышанмасаң, үзең барып кара.

— Ярар, хәзер китәм,— диде инәсе.— Менә әтәң белән икәүләп барып карарбыз. Әйдәле, Вәлиәхмәт иптәш. Кәнсирт тәмам. Йокларга вакыт. Шешә төбендә дә берни калмаган.

— Нәрсә, мине әллә шешә төбендәген күтәп утыра дип белдеңме?— диде яшьбабай, хатынына бәйләнмәкче булып.— Дөрес, миңа җиткән. Артыгы белән җиткән. Миңа синең шешә төбең кирәкмәй, йокың да кирәкмәй. Ни өчен дигәндә, шул: туйдым мин бу дөньядан! Көн-төн чабасың бушка, өч йөз гырам он өчен. Бер тиенгә кирәге юк дөньягызның! Балалар хакына гына... Эх, энекәем Гаптелхәй!

— Бик ватылдың бу арада, Вәлиәхмәткәем,— диде яшәби, ирен кызганып.— Тәмам хәлдән тайдың. Бу болганчык нәрсәң ярап куйды тагын. Зарары юк микән ул каралы савытның — шул гына эчемне тырнап тора. Тормышлар рәтләнгәч, су кебек чип-чистасын алып кайтып эчерермен әле мин сиңа, Вәлиәхмәткәем.

— Кирәкмәй су кебек чистасы да, болганчыгы да!— диде яшьбабай, киреләнәсе килеп.— Эчкече дип белдеңме әллә син мине? Юк, эчкече түгел мин. Сугышка кадәр этәйдән яшереп тә эчкәнем булмады. Сугышырга, мылтыктан атарга өйрәтмәделәр, иң элек эчәргә өйрәттеләр. Сугышка керер алдыннан үзләре бирәләр. Батырлык өчен янәсе. Валлаһи, энекәем. Эчмәсәң, пот сут. И тәки өйрәндем, энекәем. Көн-төн камыт киеп тарттым. Бөтен бригат минем кулда. Аларны бит эшләтергә кирәк. Эшләткәч тамагын да туйдырырга кирәк, күңелен табарга кирәк. Бригадирмын дип кешедән артык гырам алганым юк. Гырам! Намусым саф. Безгә харам килешмәй, энекәем. Каманис булсам да, Алладан куркам мин. Алладан бигрәк, кеше сүзеннән куркам. Ул бит синең күзеңә карап тора, Алла урынына, патша урынына күрә сине. Минем үземә берни кирәкмәй. Бүген үлсәм дә үкенмәймен, энекәем.

— Китагай! Лыгырдама инде син дә!— диде картый, улына кычкырып.— Көфер сүзе сүләп монда! Фирештәнең амин дигәненә туры килер, мордар китәрсең, әстәгафирулла-тәүбә!

— Ачуланма, инәй,— диде кинәт яшьбабай, күндәм генә.

— Мин ачуланмай, кем ачуланыр сиңа?!— диде картый.

— Бетте, бетте, инәй,— диде Вәлиәхмәт абзый һәм, төкле зур кулын сузып, Иленураны кочып алмакчы булды.— Кил әле, кызым, Иленура,— диде.

— Нәрсә?!— диде Иленура, челәеп.

— Кил әле, кил, кызым, аркаңнан гына сөярмен яратып,— диде ата кеше, борынын тарткалап.

— Бик кирәге барые!— диде Иленура, мыскыллы көлемсерәп.

— Мин бит дөньяда сезнең өчен генә яшәймен, сез-

нең өчен генә!— диде яшьбабай һәм, урыныннан кубып, кызына таба бара башлады.

— Белдек, безнең өчен генә,— диде яшәби, иренең биленнән кочып алып.— Әйдәле, чыгып ят әле урыныңа.

— Ятмаймын!— диде Вәлиәхмәт абзый, киреләнеп.

— Алай бик шаулама инде син — балаларны уятырсың,— диде яшәби, күгәрчен кебек гөрләп, йомшак кына итеп.

— Уянсын!— диде яшьбабай, аның саен батыраеп, ләкин үзе бернинди карышу галәмәте күрсәтмичә ишеккә таба атлады.

— Энекәем, чоланга чыгып ят — анда сиңа урын җәелгән,— диде яшәби Габделхәйгә.

— Ярар, ятырмын,— диде Габделхәй.

— Балакайларымның көллесен үбәсем, кочасым килә!— диде яшьбабай, туктаусыз сөйләнеп.— Әнә ул якын да килмәй. Минем кызым ич ул... Эх, белмәйсез генә... туйдым-җиләдем бу эт тормышыннан!..

## XVI

Көндез үк инде кояшның үтә нык кыздыруы, тупылдагы каргаларның кирәгеннән артык кычкырулары, шаулашулары, кичкә таба күптән көтелгән дымлы җил исеп куюы «яңгыр явар ахрысы» дигән бер сизенү тудырган иде. Чыннан да шулай булып чыкты. Төн урталарында барлык җанлы-җансызны уятып, дөбердәп күк күкрәгәне, аннан коеп яңгыр яуганы ишетелде. Габделхәй куркып уянып китте. Чоланда яшьбабасының иске шинеле астында ул, такта түбәгә шапылдап яңгыр яуганын һәм түбә кыегыннан җир өстенә өзлексез яңгыр суы коелганын тыңлап ятты. Яңгыр бик озак яуды. Әле тынып, басылып яуды, әле җилләп, яшенләп яуды.

Җил, яңгыр, күк күкрәүләренә күнегә төшкәч, искәрмәстән Габделхәй яңадан йоклап китте. Күпмедер вакыттан соң тишек түбәдән шып-шып тамчы тамганын тоеп ул тагын күзләрен ачып җибәрде. Башына, аягына авыр булып салкын тамчы тама иде. Караңгыда кулын сузып ул идәннең корырак җирен капшап карады да урынын читкәрәк күчерде.

Яңгыр төне буе яуды. Таң атып хатын-кыз сыер саварга чыга торган вакытта да әле өстән туктаусыз сибәләп тора иде. Иртүк торган яшәби сөт савып алып керде, ләкин сыерны абзардан чыгармады. Болай өзлексез ява торган булса, көтүнең чыгуы икеле иде. Сөтле бидерәсен яңгырдан каплаштырып, яшәби өйгә килеп кергәндә

өлкәннәрнең барысы да уянган, казан астына ягылган, самавыр куелган иде.

— Ял булды әле бу, иеме, әнкәй?— диде Иленура, яткан җиреннән.

— Ялын ял да, печәнгә барып булмаса, көндәгечә он кайтмаячак бит әле, кызым,— диде яшәби.— Яңгыр яуганда да килеп кенә торсыные ул он дигән нәрсә.

Яшәби белән Иленура өй эчендә сөйләштеләр. Чоланда Габделхәй аларның һәр сүзен ишетеп тыңлап ятты. Бераздан ул да торды һәм башкалар кебек өстәл янына килде. Сүзсез генә, тәмләп кенә чәй эчтеләр, сибәләп яуган яңгыр тавышына колак салгандай иттеләр. Яңгыр әле әкренәйде, әле көчәйде. Бер-ике мәртәбә хәтта кояш та күренеп алды. Ләкин тиз генә аязыр шикелле тоелмады. Мондый чакта өйдә утырудан да хәерлесе юк иде.

— Гаптелхәйне дә печәнгә алып барабызмы, дигәниек, Алла бабай каршы төште бит әле,— диде яшәби, үз алдына сөйләнеп.

— Бүген бармасак, иртәгә барырбыз, име, Габделхәй?— диде Иленура.

— Иртәгә генә барып булмас әле,— диде яшьбабай.— Бер башлагач, китте инде бу бер атнага.

— Белгән юк инде Ходайныкын,— диде картый. Габделхәй сүзгә катышмады. Аның бик нык эче пошты. Ул үзен хәзер тоткындагы кебек хис итте. Бер атна буена шулай яңгыр яуса, нишләп утырыр икән соң ул монда күрәләтә артык кашык булып?

Төш урталарында яңгыр шулай да туктады. Яңгыр бәргәләвенә каршы торып арып-алҗып беткән тупыл яфраклары кинәт хәрәкәтсез калдылар. Бакчадагы егылган, җиргә яткан бәрәңге сабаклары хәлсезләнеп шулай ук тынып калдылар. Канаулардан болганчык сулар акты. Урамда ыштан балакларын күтәреп чабышып йөргән шат малайлар күренде. Кара ләпек сылашкан авыр күнитекләрен көчкә өстерәп, урамнан ярым солдат киемендәге бер кеше узып китте.

— Кантурга барып кайтаем әле мин дә,— диде яшьбабай, урамдагы кешене күреп.

Ул җыенып чыгып китәргә дә өлгермәде, яңадан яңгыр сибәләргә тотынды.

— Йөрмә интегеп, беркем юктыр әле анда,— диде яшәби.

— Ничек түзеп ятмак кирәк өйдә!— диде яшьбабай. «Шулай шул — ничек түзеп ятмак кирәк монда?!»— дип уйлады Габделхәй дә. Аның да җыенып чыгып китәсе килде. Әлегә ул кая китәргә, нәрсә эшләргә тиешлеген

анык кына белмәде дә. Аның, билгеле, авылдан болай тиз генә кайтып китәсе дә килми иде, ләкин шул ук вакытта монда бер эшсез-шөгыльсез ятып та булмый иде кебек. Аннан соң өзлексез аның күңелен бер уй, бер кайгыборчу тынгысызлап торды. Аның хәзер теге Уфа кызын яңадан күрәсе һәм ничек тә аның белән яңадан килешәсе, үзенең тупаслыгы өчен гафу үтенәсе килә башлады. Аннан соң ул бит Казанга китәсе кеше! Шулай булгач, Казанда укый торган кеше белән бөтенләй үк бозылышу да дөрес булмас кебек. Үзенең бу йомшаклыгын ул минминлеге алдында шулайрак дип акларга тырышты. Ни генә булмасын, Былбыл аңа хәзер бик кадерле һәм якын булып тоелды. Дөресен әйткәндә, ул аны чын-чынлап сагына һәм юксына башлады.

Бераз вакыт үткәч ул, икеләнүен җиңеп, юлга җыена башлады.

— Нишләп алай бик тиз?— диде яшәби.

— Тагын бер-ике көн тор әле, Габделхәй. Их, болынга да барып булмады!— диде Иленура, өзгәләнеп.

— Кызлар белән танышырыең,— дигән булды яшәби, шаяртып.

— Минем әле документлар да әзер түгел Казанга китәргә,— диде Габделхәй.

— Ә, ие шул,— диде яшәби, бик тиз килешеп. Иленурадан башкалар аның шулай кисәк кенә китәргә ниятләвенә артык борчылмадылар да, ахрысы. Аңа бары кайткач сәлам әйтергә куштылар да, гафу үтенгән сыман, «гаеп итмә инде — алама чакка туры килдең» диделәр. Картый исә «Илгизем белән Фидәилемә» дип, Габделхәй үзе алып килгән чүпрәккә төреп, икешәр пешкән күкәй бирде, пешкән бәрәңге һәм кичә үзе җыеп алып кайткан җир җиләген бирде.

— Күпер аша кит,— диделәр аңа озатып калганда.

— Ярар,— диде Габделхәй.

— Үзем озатып куям әле авыл чыкканчы,— диде Иленура, Габделхәй инде ишек тоткасына тотынгач.

Габделхәй көтәргә булды. Иленура мич артында гөлбәчтә киемнәрен алыштырды, көзгегә карап алды, Габделхәй янына килгәч, никтер көлеп куйган булды. Ишектән алар икәүләшеп чыктылар.

— Дөньяңны онытма — бәрәңге күмәсе дә бар,— дип калды яшәби, кызы артыннан.

Урам уртасы җырып чыккысыз пычрак, аяк асты юеш иде. Баскан саен аяк батып, таеп китә иде. Габделхәй белән Иленура бераз җир янәшә бардылар да, урам читеннән корырак, катырак җир караштырып, бер-бер-

сеннән аерым киттеләр. Урамнан шулай әле бер-бер артлы, әле янәшә атлап бардылар. Бөтен игътибарны аяк астына, юеш, пычрак җир өстенә юнәлтергә туры килде. Иленура әледән-әле кычкырып көлгән булды, нәрсәдер сөйләнгән булды. Закирҗан бабайларның капка төбендә өелешеп торган каз төркеменә килеп чыккач исә куркып «ай!» дип кычкырып җибәргән булды.

Чишмә тыкрыгында Габделхәй урамнан читкә борылды.

— Сау бул. Мин моннан китәм,— диде ул Иленурага.

— Ярар алайса,— диде Иленура.— Безне онытма. Их, рәтләп сүләшеп тә булмады!.. Казанга китсәң хат яз. Безне онытма, кара аны!

— Язармын,— диде Габделхәй.

Иленурадан аерылгач, ул иркен сулап куйды. Пычранмасын өчен иң элек чалбар балакларын күтәрде, каderле ботинкасын салып кулына тотты. Юеш, тайгак җир өстеннән яланаяк барудан да җайлысы юк иде. Чишмә чокырын чыгып, сөзәк калкулык өстенә килеп менгәч, Габделхәй артына борылып карады. Кояш нурында кибенеп утырган, чыланып беткән бакчалардан, авыл өйләреннән, тупылдардай башка берни күренмәде. Иленура хәзер, күрәсең, бата-чума киртә буйларыннан кайтып барадыр дип уйлады ул.

Калкулык өстеннән беркадәр җир баргач, ул Яңавылга китә торган киң юлга барып чыкты. Яңавыл юлы үргә таба күтәрелде. Бәләкәй әрәмә янында олы юлдан уңга тар гына икенче юл тармакланып китте. Ике ягында да яшел бодай басуы җәелеп яткан тар юл турыга — Сакат ягына бара иде. Юл чатында Габделхәй туктап калды, икеләнгәндәй итте. Өйдән чыкканда «күпердән кит» дигән сүзләр исенә төште. Аның күпердән түгел, турыдан, кичүдән китәсе килде. Кичүдә, аннан да бигрәк, кичүгә якын болында аны кемдер көтеп тора сыман иде. Шул ук вакытта өйдәгеләрнең турыдан китмәскә киңәш итүләренә дә колак салмыйча булмый сыман иде. Әлерәк кенә кеше үтерелгән урман аша кайту, ни әйтсәң дә, бик үк күңелле булмаячак иде.

Кич булса, караңгы булса ул бернигә карамыйча күпердән киткән булыр иде, әлбәттә. Караңгыда иң куркынычы — мәет өрәге. Караңгы урман аша үткәндә кеше үтерүчеләр түгел, бәлки, менә шул мәет өрәге аркылы төшәргә мөмкин сыман иде. Ләкин күк йөзендә балкып кояш көлеп торганда, яңгырдан соң бөтен дөнья шундый саф, якты һәм ягымлы булганда Габделхәй хәтта өрәкләрдән дә курыкмады — турыдан китәргә булды.

## Бишенче бүлек

### I

Райондагы барлык дәрәҗә кешеләре кебек, райбашкарма председателе иптәш Бикчурин да хезмәттә үзенә буйсынган кешеләр белән һәм шулай ук элекке таныш-белешләре белән шәхси мөнәсәбәткә керүне ярамаган нәрсә дип исәпли иде. Шуңа күрә ул үзенең кабул итү бүлмәсендә дә, урамда-нидә очрашканда да андый кешеләр белән үзен мөмкин кадәр коры һәм рәсми тотарга тырыша иде. Аны болай да районда коры һәм каты бәгырьле кеше дип беләләр иде. Чынлыкта исә ул бөтенләй андый кеше түгел иде. Районның баш кешесе, хуҗасы, бәләкәй генә патшасы иптәш Сафин кебек ул да үзен, икенче дәрәҗәдәге булса да, баш кеше, хуҗа кеше итеп тотарга ярата иде.

Яңавыл районының барлык түрәләре сыман ул да бу якта туып үскән кеше түгел иде. Аның каян килүен, элек кем булуын рәтләп белмиләр дә иде. Бары тик сайлау вакытларында игълан ителә торган кыскача биографияләрдә генә аның һәм аның кебекләрнең кайчан кайда туулары, кайда кем булып эшләүләре турында кыскача мәгълүмат бирелә һәм бары шул чагында гына серле башлыкларның әзме-күпме сере ачылып куя иде. Баксаң, аларның берсе, әйтик, Борай, Тәтешле ягында, икенчесе әллә кайда көньяк Башкортстанда яки хәтта Себердә туган булып чыга. Ләкин кайда гына тумасыннар, аларның һәркайсы ярлы крестьян семьясында туган, бик тырышлык белән укыган, укыгач, фермада, заводта, шахтада эшләгән. Эшләгән чакта ук инде комсомол комитеты секретаре, партком секретаре була, аннан соң ниндидер курсларда укый. Кайберләре армиядә хезмәт итәләр, сугышта катнашалар, батырлыклар күрсәтәләр, орден-медальләр белән бүләкләнәләр һәм партия кая җибәрсә, шунда китәләр, иң җаваплы эшләрне башкаралар. Аларны тотып кына нинди профессия кешеләре икәнлеген дә әйтеп булмый, игенче дисәң, игенче түгел, эшче дисәң, эшче түгел. Укымышлы, интеллигент дип тә булмый. Дөрес, аларның күбесе элекке мулла, мөгаллим затыннан. Ләкин алар инде күптән үз ата-бабаларыннан, үз авылларыннан, үз халкыннан баш тартканнар һәм, югарыдан-югарыга үрләү җиңелрәк булсын өчен, үз чыгышларын оста итеп яшереп бетергәннәр. Аннан соң сугыш елларында һәм сугыштан соңгы елларда кешенең чыгышына-тумышына егерменче-утызынчы еллардагы кебек артык игътибар да итми башладылар.

Райбашкарма председателе итеп куелганчы, иптәш Бикчурин район финанс бүлеге мөдире булып эшләде. Финанс мәсьәләсендә ул, билгеле, әлепне таяк дип тә белмәде. Шулай да ул монда үзен бары яхшы яктан гына күрсәтте һәм озакламый аны райбашкарма председателе итеп күтәрделәр. Райфо бүлеге мөдире булып эшләгәндә аның үзенә буйсынган кешеләр арасында да, башка таныш-белешләре арасында да якын дуслары юк түгел иде. Ул чакта әле ул үзен иркенрәк, гадирәк тота һәм авылдан килгән агай-эне белән, инспектор, бухгалтер белән сөйләшкәндә «моңа ягымлы итеп карасам, үземә начарлык булмасмы, монысына кешечә җавап бирсәм, дәрәҗәм төшмәсме» дип кан калтырап утырмый иде.

Нәкъ менә шул чагында, ягъни иптәш Бикчурин райфо мөдире булып утырган чакта, алар Дәүләтгәрәй абзыйлар белән якынаеп калдылар да: бер-ике мәртәбә бер-берсенә кунакка бардылар, бер-ике мәртәбә уртак мәҗлестә булдылар, хәтта бер мәртәбә бергәләшеп Бүәдә балык та тоттылар. Ләкин иптәш Бикчурин югары үрләгәч, андый барышу-килешүләр, уртак мәҗлесләр һәм Бүәдә чыланып, пычранып җылым тартулар кабатланмый башлады. Бу үзеннән-үзе шулай килеп чыкты. Дәүләтгәрәй абзый беренче булып үзе бармады, иптәш Бикчурин шулай ук аларның бусагасын атлап керү дөрес булыр дип исәпләмәде. Хәзер алар иптәш Сафиннар белән йөрешә башлаганнар иде. Дөрес, алай-болай очрашканда алар Дәүләтгәрәй абзыйлар белән дә бер-берсен күрмәмешкә салынып китмәделәр. Кешеләрчә хәл-әхвәл сораштылар, йорт-җирнең иминлеге, хатыннарның, бала-чагаларның исәнлеге белән кызыксындылар. Күңелләре нечкәреп китсә, «теге вакытта» Бүә буенда балык тотып, балык пешереп яткан чакларны искә төшерделәр, «эх, тагын бер барып чыгасы иде!» дигән сүзләр дә ычкындырдылар. Мондый сүзләрне күбрәк иптәш Бикчурин әйтте. Дәүләтгәрәй абзый, буйсынган кеше, түбән дәрәҗәдәге кеше буларак, тыйнаклык саклап эндәшми калуны артыграк санады.

Менә быел элекке дуслар тагын очраштылар. Ирләр түгел, хатын-кызлар очрашты.

Ул көнне Фәрхәнә апа белән Былбыл, кирәк нәрсә карангалап, базарда, базар тирәсендәге магазиннарда йөрделәр. Шулай, «Раймаг» дип аталган һәм бөтен Яңавылда бай саналган магазинның ярым буш шүрлекләренә күз атып торганда, кеше арасыннан көтмәгәндә Нәҗия килеп чыкты. Килеп чыкты да бу, бөтен магазин эчен шаулатып көлеп алды һәм урманда адашкан кеше сыман кычкырып:

— Туганкаем Фәрхәнә апа!— диде.— Исәнме-саумы? Хәлләр ничек? Исәнмесез! Теге бичырда рәтләп сүләшеп тә булмады, бер дә килмәй башладыгыз. Безнекенең вакыты юк — онытып бетердек бер-беребезне, туганкаем Фәрхәнә апа.

Нажия шулай бер-бер артлы тезде-тезде дә, исәнләшәм дип уйлап, күрәсең, Фәрхәнә апаның әле кулын кысты, әле беләгеннән тоткандай итте. Аннан соң, каршысындагы кешенең чыннан да Фәрхәнә апамы-түгелме икәнлегенә шикләнгән сыман, башын артка ташлап, күзләрен кысыштырып, сынап-сынап карагандай итте. Шул ук вакытта Былбылга да карап-карап алды һәм бернинди әдәп сакламыйча, туп-туры сорап куйды:

— Бу кемнең шундаен да чибәр кызы соң әле?— диде. Соравын шундый тупас итеп, йөзгә бәреп әйтүе кунак кызына бик үк ошап җитмәсә дә, сорау үзе күрәләтә мактау рәвешендә булганга, бу шалтыравык хатынга Былбыл берничек тә ачулана алмады — рәхәт бер уңайсызлык тоеп, кызарынып басып тик торды.

— Минем Уфадагы абыйның кызы, Зәйнулланың. Казанда укый... унивситта... унивирситта... Әйтә дә белмим шуны,— диде Фәрхәнә апа, көлештереп.

— И, чибәрттәй!— диде Былбыл, тагын да ныграк уңайсызланып.— Институтта гына диген инде, әйтелмәгәч...

— Булмый, тел күнми шундый ят сүзләргә,— диде Фәрхәнә апа.

— Каяннар әйтеп бетермәк кирәк инде аларны, туганкаем Фәрхәнә апа!— диде Нажия сөенеп, Фәрхәнә апаны яклап.— Безнең тел каткан инде. Үз татарыңны белсәң, шул җиткән. Саескан да сандугач сайравына үрәнмәкче булган икән дә, теле көтек булып калган. Кая инде безгә сандугач кебек сайраулар?!— Шулай, тын алырга да ирек бирмичә, тиз-тиз генә сөйләде дә, ашыгып: — Бездә дә Уфа кунагы бар лабаса, Фәрхәнә апакаем,— диде һәм, үзенең шәп, җылгыр кеше булуына куанып, башын артка ташлап көләргә тотынды.

— Теге чибәр җегетне әйтәсеңме?— диде Фәрхәнә апа, унынчы классларның чыгарылыш кичәсенә килгән яшь лейтенантны күз алдында тотып.

— Шул инде, шул, туганкаем Фәрхәнә апа,— диде Нажия һәм ялт кына артына борылды да, магазин залының икенче башында нидер карап торган хәрби кешегә эндәшеп,— Хәниф, кил әле монда!— дип кычкырды.

Хәниф, үз исемен ишетеп, Нажия апасы ягына борылды һәм ризасыз бер кыяфәттә, теләр-теләмәс кенә килә башлады. Бу вакытта Былбыл Фәрхәнә апа белән Нажия-

дән читтәрәк, пыяла витринага иелеп, төймә ише нәрсәләргә каранып тора иде. Ирексездән ул хатыннарның үзара сөйләшкән сүзләренә колак салды һәм, «Хәниф» исеме чыккач та, сиздермичә генә аның ягына карап алды. Лейтенант Хәнифне ул бер күрүдән таныган сыман булды.

— Каяле, кил әле монда — үзеңнең авылдашың белән таныш,— диде Нәҗия, яшь лейтенантның беләгеннән тотып алып.

Аның шулай чит кешеләр алдында, кызлар алдында малай сыман итеп кулыннан тотып алуына, үзе турында бөтен магазинга кычкырып «гайбәт сатуына» Хәнифнең, билгеле, ачуы килде. Фәрхәнә апа белән дә, Былбыл белән дә ул коры гына «исәнмесез» дип исәнләште дә тынып калды. Ләкин шат күңелле җиңгәсе аңа боегып торырга ирек бирмәде.

— Кара, кара!— диде ул, аны җиңелчә генә шелтәләп.— Яхшылап күреш, таныш. Менә сиңа хәзерге яшьләр, туганкаем Фәрхәнә апа!

Хәнифнең йөзе үзгәреп китте, очлаебрак торган тәкәббер ияге муенына таба тартыла төште. Шулай да ул хатын-кыз алдында ямьсезләнүдән тыелып кала алды — көч-хәл белән үз-үзен елмаерга мәҗбүр итте һәм әдәп саклап башта Фәрхәнә апа белән, аннан соң Былбыл белән исәнләште, үзенең кемлеген әйтте.

— По-моему, без таныш,— диде ул, Былбыл белән исәнләшкәндә.— Только вот исемнәребезне генә белмибез. Фәрхәнә апа елмаеп куйды.

— Танышмыни?— диде.

— Таныш,— диде Хәниф.

— Шулай шул — таныш,— диде Былбыл да, лейтенантның сүзләрен дөресләп.

— Менә сиңа хәзерге яшьләр, туганкаем Фәрхәнә апа!— диде Нәҗия, көлә-көлә.

## II

Былбыл белән Хәниф беренче мәртәбә Уфа автовокзалының билет кассасы янында очраштылар. Яңавылга баручы, кайтучы халык күп иде, автобус бер генә һәм буш урыннар бик әз иде, шуңа күрә касса алдында гадәттәгедән ныграк шау-шу һәм ыгы-зыгы иде. Билет сатыла башлау белән, көтеп торучылар барысы берьюлы касса авызына килеп тыгылдылар. Китте этеш-төртеш, китте кычкырыш!

Былбыл чиратка бик иртә баскан иде, аның урыны җиденче генә кеше иде, касса янында ныклы тәртип булганда, билет аңа җитәчәк тә җитәчәк иде. Ләкин кас-

са ачылу белән, чиратта торучылар янында күз алдында яңа чират барлыкка килде. Алар барысы да ирләр, көчлеләр һәм оятсызлар иде. Чираттагылар никадәр нык-лык, усаллык күрсәтмәсен, аларның әле берсе, әле икенчесе акчалы кулын касса авызына китереп тыкты һәм кочактай билет алып китә торды.

Менә берзаман Былбыл алдында ике генә кеше калды — берсе яшьрәк ир кеше, икенчесе начар гына киенгән авыл хатыны иде. Ир кеше касса янына исән-имин барып җитте, кулын сузып билет алды да акылдан шашкан сыман бәхетле елмаеп җибәрде. Аның урынына шундук авыл хатыны басмакчы булды. Шул чакны каяндыр икенче бер ир кеше барлыкка килде. Өстенә шакмаклы пинжәк кигән, киң аркалы, үгездәй таза җилкәле ир кеше өтәләнгән авыл хатынын җиңел генә читкә этәреп калкандай гәүдәсе белән касса авызына капланды. Хатын чәрелдәп җибәрде, ярсып бар көченә үзенең законлы урынын яулап алмакчы була башлады. Шакмаклы пинжәк аның чәрелдәвен чебен безелдәве урынына да күрмәде — тыныч кына билет алды, оятсыз, мәсхәрәле көлемсерәп читкә китеп барды. Аның урыны бушау белән, касса алдындагы дзотны күкрәге белән алтын погонлы яшь лейтенант каплады.

Сугыштан соңгы еллар булганга, чираттагы кара халык арасында хәрбиләр булуы бер дә гаҗәп түгел иде. Хәрбиләрнең теләсә нинди погонлысын теләсә кайчан һәм теләсә кайда очратырга була иде. Хәрбиләр сугышта җиңүче булсалар да, кара халык чынлыкта беркайчан аларны яратмады. Яхшы киемле, тук, таза кыяфәтле булган өчен, халык сакчысы, халык якчысы булуына да карамастан, халыктан үзен өстен куеп, халыктан аерымланып яшәве өчен яратмады. Өлкәнрәк яшьтәге, түбәнрәк дәрәҗәдәге хәрби кеше булса, халыкның әле, бәлки, ачуы да килмәс иде. Ни әйтсәң дә, солдат авыл агаена, авыл апасына аңлаешлырак та, якынрак та. Сугышта да булгандыр, кан да койгандыр, хәзер, бәлки, демобилизациягә эләгеп, армиядән котылып, туган ягына кайтып барадыр. Андыйларга күңелләр дә ачык, кассаларга юл да ачык. Монда исә әллә нинди ялт итеп торган погонлы ять-яшь кенә лейтенантның әрсезләнеп чират алдына килеп керүе болай да аягында көчкә басып торган халыкны ярсытып җибәрде. Чираттагы хатыннар, ирләр тагын да яманрак шауларга, кычкырырга тотындылар. Былбыл алдындагы авыл хатыны әле татарчалап, әле урысчадан лейтенантны оялтмакчы булды, алай да тәэсир итмәгәч, беләгеннән тарткалап чыгармакчы булды.

Ачудан авыл хатыны гына түгел, Былбыл да шартлар

дәрәҗәгә җитте. Ничә сәгать аяк өсте басып торуы, иңбашларының, аякларының сызлавы, баш авыртуы — барлык газаплары өчен аңа бары шушы чибәр, тыныч һәм оятсыз лейтенант кына гаепле сыман тоелды.

— Ничек оялмыйсыз? Сез бит лейтенант! Халыкка яхшы үрнәк күрсәтү урынында!..— дип кычкырды ул, үз-үзен белешмәстән.

Ул хәтта авыл хатыны кебек кулын сузып аның кителеннән эләктереп тә алмакчы булды, ләкин яшь лейтенант та алай үзенә кагылдыра торган, үзен кыерсыттыра торганнардан түгел иде бугай. Ялт кына артына борылды да теш арасыннан гына сыгып:

— Чәрелдәмәгез, зинһар!— диде һәм кассага акча сузды.

— Кертмәгез, кертмә!

— Өстерәп чыгарыгыз!— дип кычкырдылар арттан.

— Минем — бронь! Минем хакым бар,— диде лейтенант, аңлатырга кирәк табып.

— Безнең дә хакыбыз бар! Безгә дә кайтырга кирәк!— диделәр чираттагылар.

Төрле яктан кысылган, тирләгән-пешкән һәм бер-берберсен чәйнәп ташлар дәрәҗәдә ярсыган хәлдә, бер-берсенә тыелгысыз ачу-нәфрәт тойган хәлдә, беренче мәртәбә алар шунда очраштылар.

Ул көнне лейтенантның да хәле шәптән түгел иде, әдәп саклап, хәтер саклап тора торган чак түгел иде. Шуңа күрә ул үзенә кычкырган, үзен йолкып ташламакчы булган халыкка ярыйсы ук усал һәм тупас сүзләр дә әйтте. Шул исәптән, әлбәттә, яшь, чибәр кызга да эләкте.

Тавыш артык зурга киткәч, каяндыр милиция сержанты килеп чыкты, сыбызгысын сызгыртып, касса янында әзме-күпме тәртип урнаштырды. Бу вакытта инде яшь лейтенант билет алып китеп барган иде. Лейтенанттан соң өтәләнгән авыл хатыны да билет алды. Чират Былбылга җитте. Былбыл акчасын сузарга өлгермәде, тар бүлмәдә, төннек сыман кечкенә тәрәзә артында бәхет өләшеп утырган кассир хатын тәрәзә капкачын ябарга үрелде һәм:

— Билет бетте,— диде.

Нәкъ кинодагыча, нәкъ театрдагыча булды. Шулкадәр зарыгып, өметләнеп көт тә, борын төбендә генә касса ябылып куйсын әле! Утыр да җыла. Йә булмаса очраган бар нәрсәне кырырга-җимерергә тотын. Дөньяның астын өскә китер. Хәер, Былбылга инде болай да дөньяның асты өскә килгән сыман тоелды. Болай да аның җылыйсы килде һәм үзенә тиешле билетны тартып алган лейтенантны өзгәләп-йолыккалап ташлыйсы килде.

Бөтенесенә кул селтәп ул өйләренә кайтып китте. Бе-

раздан тынычлана төште, халык алдында үзенең кызып китүе, ярсып китүе өчен үкенү сыман бернәрсә кичерде. Тик шулай да яшь лейтенантның салкын, мыскыллы күз карашы, тупас сүзләре, тәнгә кадалган шырпы булып, бик озак аның күңелен әрнетеп-ачыттырып торды.

## III

Көтмәгәндә таныш кешесен күреп, ул аптырап калды. Уфадагы, автовокзалдагы барлык хис-тойгысы ташкын булып әз генә вакытка яңадан калкып чыкты, кире кайтты һәм тагын шундый бер-бер хәл була-нитә калса, тагын шундый күз карашы, шундый ук сүзләр, шундый ук тавыш була калса, бар көченә ыргылырга әзер булып, күкрәк читлегендә тулып-чайкалып торды.

— Танышмы?!— дигән булды Нәҗия мут елмаеп, бармак янаган булып.— Бер авылдан булгач, барысын да белеп тә бетерә алмассың, туганкаем.

«Бер авылдан» сүзен ул аеруча яратып әйтте һәм, үзүзеннән канәгать булып, көлеп куйды. Җиңгәсенең танышлыкка үзенчә мәгънә бирүе Хәнифкә, күрәсең, бик үк ошап җитмәде. Шуңа күрә ул үзенең Былбыл белән кайда ничек танышуын кыска гына аңлатып бирергә кирәк тапты. Ләкин аңлатканда үзенең тупаслыгын да, хәтер калдыргыч сүзләр ычкындыруын да әйтми калдырды. Аның сөйләвенә караганда, ул көнне чиратсыз билет алу да, чираттагы халыкның кычкыруы, шаулавы да — барысы да бер шуклык, шаянлык кына булып тоелды. Җиңгәсе, аның сүзен бүлдереп, кычкырып көлеп алды, Фәрхәнә апа исә, бер якка да кушылмыйча, килешүчән бер төс белән көлемсерәп торды.

Былбыл көлмәде дә, елмаймады да. Ул Хәнифнең бер генә яклы итеп сөйләвен күреп-ишетеп торды, күңеленнән моңа нәфрәтләнмичә булдыра алмады. Аның сөйләүчене бүлдерәсе, хатыннар алдында аның йөзен ертып: «Юк, алай түгел ул!»— дип әйтәсе килде. Ләкин шул ук вакытта ул аның ялганлавына һәм ул чактагы тупаслыкны искә алмавына, ямьсез, күңелсез урыннарны читләтеп үтүенә хәтта сөенгәндәй булды. Хәниф аңа тегендәге, теге вакыттагы кебек чит, дошман да түгел иде. Ул инде аңа ничектер якынрак сыман да иде — тегендә очрашкан, бозылышкан өченме, менә монда көтмәгәндә яңадан очрашкан өченме — бик күптәнге таныш кебек якын һәм аңлаешлы иде. Шулай итеп, ачу-нәфрәт сизмәгәндә юкка чыкты. Бераздан Былбыл үзүзеннән ояла башлагандай булды. Теге чакта ямьсез итеп

кычкыруы, тупасланып аны чираттан кысырыклап чыгарырга тырышуы, гомумән, андагы тотнаксызлыгы өчен ояла башлагандай булды. Бер кызарып, бер агарып ул төркемнән читтәрәк басып торды. Яшь, чибәр һәм ягымлы лейтенантка ул күтәрелеп карарга да курыкты. Аның алдында ул үзен хәзер бала-чага итеп, бернинди ихтыяры булмаган, бернәрсәгә хакы-хокукы булмаган тәҗрибәсез бер кызчык итеп тойды.

Үзара сөйләнгәләп алар урамга чыктылар. Урам уртасында Нәҗия туктап калды.

— Карале, туганкаем Фәрхәнә апа,— диде.— Бөтенләй читләшеп беттек бит әле бу арада. Сез килмәйсез, без бармайбыз. Нишләп ташлаштык соң әле? Килегез әле Дәүләтгәрәй абзый белән парлашып.

— Бер дә җитешеп булмый бит, Нәҗия,— дигән булды Фәрхәнә апа, «ташлашу»ның сәбәпләрен бик яхшы белсә дә.

— Дөнья мәшәкатенең беткәне юк аның, туганкаем,— диде Нәҗия.

Фәрхәнә апаны ул култыклап ук алды һәм кызулабрак китеп барды. Яшьләр арттарак калдылар.

— Карале, туганкаем Фәрхәнә апа,— диде Нәҗия, ярым пышылдауга күчеп.— Синең белән тел яшереп торасы юк. Туп-туры әйтсәм, үпкәләмәссең. Әйдәле сездә бер шаулатып аш-су ясап ташлайбыз? Өегез иркен, кеше күзеннән җырак. Исмәгыйльне әйтәм, сүрәп булса да алып барам мин аны сезгә. Болай да инде аның аркасында дуслар белән бозылышып беттем.

Бик сәер тәкъдим иде бу, иптәш Бикчурин хатыны Нәҗия генә әйтә алырдай кыю һәм әдәпсез тәкъдим иде. Фәрхәнә апа эндәшмәде. Эндәшсә дә, күрәсең, каршы әйтергә батырлыгы җитмәс иде. Аннан соң, аның алай каршы да киләсе килмәде. Ул хәтта күңеленнән сөенеп тә куйды. Нәҗия андый-мондый кешенең хатыны түгел. Аннан соң, алар бит элекке дуслар да!

— Кирәк нәрсәсеннән тормам — барысын да үзем җайлармын, Фәрхәнә апакаем. Әзерләшергә дә үзем килермен,— диде Нәҗия, Фәрхәнә апаның икеләнгәндәй итүен күреп.

— Әйдә инде! Сөйләмә юкны!— диде Фәрхәнә апа.— Кунак чакыру, аш-су ясау дигәндә безнең Дәүләтгәрәй үлә дә китә инде. Аңа шул балык булсын да, аш-су, мәҗлес булсын.

— Аларга шул балык та, аракы инде, туганкаем!— диде Нәҗия.

— Килештек, алайса?— диде Фәрхәнә апа ачылып,

билгеле бер фикергә килеп.— Кайчанга? Шушы ялга ничек булыр? Кунагыгызны да калдырмагыз.

— Туганкаем Фәрханә апа!— диде Нәҗия, балкып.— Тел яшереп торасы юк, турысын гына әйткәндә, шул кунакның күңелен табарга тырышам да инде мин. Исмәгыйльнең вакыты юк. Үзенә генә күңелсез. Карале, туганкаем Фәрханә апа, синең бу Сандугачың чыннан да былбыл кебек икән бит! Безнең кунакка менә дигән пар буласы икән.

Чигенергә кирәк булса, сүзне уенга әйләндерергә җай калдырып, җылгыр хатын көлеп куйган булды. Фәрханә апа тагын эндәшми калды. Ул инде болай да сизенгән иде. Аның һич тә Былбыл эшенә, Былбыл язмышына кысыласы килмәде. Аныңча, өлкәннәр, гомумән, яшьләр эшенә кысылырга тиеш түгелләр иде. Элекке заманнарда картлар әнә яшьләр эшенә кысылып, күпме бәхетле язмышны газапка әйләндергәннәр. Картларның үзсүзлелеге, кирелеге, аңсызлыгы аркасында күпме фаҗига булган элекке тормышта. Бүген андый фаҗигаләр булмаска тиеш. Бүген һәртөрле димләүләр, ярәшүләр искелек калдыгы булып исәпләнелә. Башкалар өчен искелек калдыгы булган нәрсә Былбыл өчен дә, әлбәттә, шулай исәпләнергә тиеш. Инде чынлап та ратышып китәләр икән, анысы шулай ук яшьләрнең үз эше.

Бу мәсьәләдә Фәрханә апа шулайрак фикер йөртте.

— Җиңгәйгә охшаган. Безнең җиңгәй бик матур. Заманында илдә бер чибәр булган,— диде ул, Былбылның әнисен мактап.

— Хәнифне әйтәм, туганкаем, Фәрханә апа,— диде Нәҗия.— Бер дә рәтле кыз табалмай. Читтә берәр марҗа башын-күзен әйләндереп куймаса ярарые дип куркам. Әллә нинди белмәгән-күрмәгән кеше белән туганлашасы да килмәй. Без, ичмасам, бертуган кебек. Озакламай хезмәтен тутыра. Үзебезгә кайтырмы, Уфагамы, Казангамы — әлегә белгән юк. Әллә, мин әйтәм, чәчләрен чәчкә бәйләйбезме шул дошманнарның?! Валлаһи дип әйтәм, чукындырып салабыз без аларны, туганкаем Фәрханә апа!

— Чукындырырга дигәндә, бездән сорап тормаслар — бик теләп чукындырырлар,— диде Фәрханә апа.— Ошашсалар, килешсәләр... үзләре эше... Сөйләштек, алайса, шушы ял алдыннан, кичке якта... рәхим итегез өчәүләп.

## IV

Былбыл белән Хәниф, Фәрханә апа белән Нәҗиядән калышып, әкрен генә арттан бардылар. Аларга хәзер бернинди димче дә, арадашчы да кирәкми иде. Алар болай

да бергә, болай да таныш иде. Шулай булса да алар бер-берсенә карата бернинди якынлык хисе тоймадылар. Киресенчә, аларның хәзер бер-берсеннән аерылып китәселәре, бер-берсеннән котыласылары килде. Беренче очрашу, шул чакта әйтелгән сүзләр, кыланышлар, шул чактагы хис-тойгылар тәэсире шундый көчле, шундый ямьсез һәм күңел кайтаргыч иде,— шул турыда яхшы белә торып, әле булса шуларны тиешенчә онытмый торып, менә хәзер кисәк кенә икенче җайга, икенче көйгә күчү, дуслашу, якынаю, гомумән, мөмкин нәрсә түгел сыман иде.

Сүзсезлектән интеккән Хәниф бара торгач чалбар кесәсеннән көмеш сыман портсигар чыгарды, портсигарын учында килешле генә тотып, икенче кулы белән «Казбек» папиросы алды, шартлатып портсигарын япты да икенче кесәсеннән зажигалка чыгарды, ут кабызды һәм, хуш исле төтен өреп, кабаланып тарта башлады. Төтенне ул читкә җибәрергә тырышты, ләкин үч иткәндәй төтен Былбыл ягына тартылды.

— Гафу итегез,— диде ул, төтенне куалап.

— Тартыгыз әйдә... тартасыгыз килгәч,— диде Былбыл.

Хәниф йотлыгып бер-ике суырды да, утлы папиросын бармак очында әвәләп, читкә ташлады.

— Сезнең Яңавылда булганыгыз бармы?— диде ул, сүзгә башлап.

— Бар,— диде Былбыл һәм, тәмәке төтененнән, ахрысы, тамагы карлыгып сүзсез калды.

— Минем әле беренче булуым,— диде Хәниф.

— Ошыймы соң... безнең Яңавыл?— диде Былбыл.

— Ничек дип әйтергә... авыл инде, кара авыл,— диде Хәниф.

— Миңа ошый,— диде Былбыл.

— О, сез авыл патриоты икән!— диде Хәниф.

Аның тавышында җиңелчә көлемсерәү сизелде. Былбылның бу шундук кытыгына тиде. Аның да шундый ук мыскыллы көлемсерәү белән җавап бирәсе килде.

— Ие шул, авыл патриоты,— диде ул, көчәнүле бер горурлык белән.— Патриот булу сезгә ошамыймыни?

— Юк, што сез!— диде Хәниф, юл куючан бер өстенлек белән.

— Юк, сез яратмыйсыз Яңавылны!— диде Былбыл, кирәгеннән артык кайнарланып.

— Мин авылда тумаган, шуңадыр, күрәсең,— диде Хәниф.— Сез... чыннан да Уфаныкымы?

— Мин Яңавылныкы,— диде Былбыл, үчекләшкән сыман һәм үз ялганыннан үзе көлеп куйды.

— Ник көләсез?— диде Хәниф.

— Болай гына,— диде Былбыл.— Бернәрсә искә төште. Сез, нәрсә, чибәрттәй әйткәнгә ышандыгызмыни?

— Нәрсә соң ул «чибәрттәй»?— диде Хәниф.

— Минем апа. Әнә теге бездән алдарак бара торган «Фәрхәнә апа»,— диде Былбыл.— Мин аны чибәрттәй димен. Бала чактан ук өйрәткәннәр. Монда... бездә апаларны төрлечә атыйлар: чибәрттәй, чибәр җиңгәй, чибәр әби, чибәр бабай...

— «Бабай» да апамыни?— диде Хәниф.

— Анысы ялгыш әйтелде,— диде Былбыл, көлеп һәм дәвам итте: — Актүтәй, актәй, аккай, мулләттәй...

— Телеңне сындырырсың,— диде Хәниф.

— Миңа ошый,— диде Былбыл.— Ник, ямьсезмени: баләби, балбабай, шикәрәби, шикәрбабай, картый, картәтәй, яшәби, яшьбабай, нәнәй, дүрнәй, җырак әби, җырак бабай... Нинди матур барысы да! Саф үзебезчә, татарча.

— Дүрнәй нәрсә? Дурной дигән кебек,— диде Хәниф.

— Дүрнәй ул — зур инәй дигән сүз!— диде Былбыл.

— Дүрнәй — дурной, дурной — дүрнәй,— диде Хәниф кабатлап, яратмыйча.

— Сез бик тупас!— диде Былбыл, үртәлә башлап.

— Извините... гафу итегез,— диде Хәниф.— Мин сезне оскорбить итәргә уйламадым. Просто так.

Бераз вакыт тагын сүзсез бардылар. Сүзне бу юлы да Хәниф башлады. Аның Былбыл белән сөйләшәсе һәм ничек тә үзе турындагы начар фикерне үзгәртәсе килә иде бугай.

— Нәрсә әйтте соң сезнең чибәрттәгез — нишләптер минем истә калмаган,— диде ул, йомшаграк булырга тырышып.

— Кеше сүзен сез бик тиз онытасыз икән,— диде Былбыл.

— Кызлар хәтере кебек минем хәтер,— дигән булды Хәниф.

— Кызлар хәтере сезнеке кебек булса!..— диде Былбыл.

— Шулай диләр ич,— диде Хәниф.— Мин сезне Яңавылга кайтып баручы берәр укучыдыр дип уйладым.

— Дөрес уйлагансыз,— диде Былбыл.— Чибәрттәй дә шулай диде ич.

— «Чибәрттәй» кем була соң сезгә? Үзегез әйтәсез: Яңавылныкы дисез, үзегез нишләптер аның белән йөрисез...— диде Хәниф.

— Аның белән йөрергә ярамыймыни?— диде Былбыл.

— Сез кеше сүзен юри кирегә борасыз икән,— диде Хәниф.

— Нишләп кирегә бору булсын?— диде Былбыл.— Ул минем апам — әтинең бертуган сеңлесе. Без үзебез Яңавылдан ун чакырымда Каймаша дигән авылда торабыз. Әти минем колхоз председателе. Хәзер мин Яңавылда кунакта. Аңлашылмыймыни?

Ул боларны шаяртмыйча, җитди итеп, үзеннән яшьрәк, аңсызрак малай-шалай белән сөйләшкәндәге сыман итеп әйтте. Соңгы сүзен әйткәндә хәтта Хәнифнеке кебек көлемсерәү, өйрәтү, мыскыл тоны сизелеп китте. Яшь, чибәр лейтенант кызның шаяртуын аңлый алмады. Ул бары үзен түбәнсетүләрен генә сизенде. Бу аның минминлегенә тиде, күңелен кырды. Ул яңадан чалбар кесәсенә тыгылды, портсигар чыгарды, калтыранган бармаклары белән папирос кабызырга азаплана башлады.

— Аңлатугыз өчен рәхмәт. Мерси,— диде ул папиросына ут кабызгач, күрәләтә салкынлык белән.

— Ауфвидерзайн!— диде Былбыл.

## V

Шушы сөйләшүдән соң ике көн үткәч, алар тагын очраштылар. Монысы инде кунакта, Фәрхәнә апаларда булды.

Үзенең элекке хезмәттәшен, хөрмәтле иптәш Бикчуринны ашка алуга Дәүләтгәрәй абзый бик теләп, хәтта сөенеп риза булды. Алар шундук әзерлек чарасына керештеләр. Иң элек «ризабыз, килешенгән көнгә, килешенгән вакытка өчәүләшеп килегез» дип Нәҗиягә хәбәр бирделәр. Ялга каршы базарга чыгып Дәүләтгәрәй абзый ярты сарык алып керде. Шул ук көнне иртәннән башлап олы мичкә ягылды. Фәрхәнә апа белән Былбыл көне буена диярлек мич тирәсендә, казан тирәсендә булаштылар. Төштән соң зур-зур сумкалар күтәреп, Нәҗия килеп җитте. Үзе белән күп кенә бал-май һәм ят азыклар алып килде. Бер килгәч-килгәч дип, озак кына Фәрхәнә апага булышты.

Бер-ике сәгатьтән ул кайтып китте һәм көн кичкә авышканда, билгеләнгән вакытка яңадан килде. Монысында алар өчәүләп килделәр. Аларны тәрәзәдән карап, көтеп кенә торалар иде. Кадерле кунаклар күренү белән, каршы алырга дип иң элек Дәүләтгәрәй абзый чыкты, аның артыннан Фәрхәнә апа чыкты. Кунаклар кешечә җәяүләп кенә килгәннәр иде.

— Капкагыз ачыкмы — без киләбез!— дип кычкырды ерактан ук шат күңелле Нәҗия.

— Әйдәгез, әйдә рәхим итегез!— диделәр Дәүләтгәрәй абзый белән Фәрхәнә апа, бер-берсен бүлдереп.

Капкадан кергәч тә иптәш Бикчурин элекке хезмәттәшенә беренче булып кул бирде, елмайгандай итте, шулай да артык ачылып китмәде. Нәҗия исә шатлыгыннан Фәрхәнә апаны кочаклаплар алды. Бары Хәниф кенә үзен мәҗбүр ителгән кеше сыманрак хис итте һәм үзара куанышкан кешеләргә якын килмичә, бер читтәрәк тaптанып торды.

Җиңгәсе аны чыннан да мәҗбүр итеп алып килде. Аның шулай ни өчен «чибәрттәй»ләргә кунакка алып баруын Хәниф аңламады түгел, аңлады. Аның анда барасы да килде, шул ук вакытта аягы да тартмады. Өченче көн урамда саубуллашыр алдыннан булган сөйләшүдән соң ул үзен җиңелгәнгә, түбәнсетелгәнгә санады. Шуңа күрә, аныңча, ике арада әле сөйләшәсе сүз дә бетмәгән иде, тагын нидер ачыклыйсы да, нәрсәнедер хәл итәсе дә бар иде кебек тоелды. Ләкин кызлар янына абый-җиңгәй белән бергәләп бару, аларга ияреп, тагылып йөрү чамадан тыш ахмаклык булачак иде. Моңарчы ул кызлар янына беркайчан да ярдәмчеләр белән йөрмәде һәм хәзер дә андый кешеләрнең кирәге юк иде сыман. Ул кискен рәвештә баш тартты. Тик Нәҗия җиңгәй аңа караганда үзсүзлерәк булып чыкты. Аннан соң, ни әйтсәң дә, ул бит кунак кеше монда! Кунак — хуҗаның ишәге. Кая алып барсалар — шунда бар, нәрсә эшләргә кушсалар — шуны эшлә.

Ни булса булды, ул килде. Килүен килде, ләкин хезмәттә аякны ничек атларга, кулны, гәүдәне, башны кайчан ничек тотарга җитәрлек дәрәҗәдә белем алган лейтенант иптәш Фәрхәнә апалар ишегалдына килеп кергәч, нишләргә дә белмичә, каушады да калды. Аның күңеленә иң әүвәл: «Минем болай әрсезләнеп йөрүемә Былбыл ни әйтер?»— дигән бер уй килде. Ул икеләнде, ул уңайсызланды. Ихтимал, бу аның үз гомерендә беренче мәртәбә чын-чынлап уңайсызлануы булгандыр.

Аны күргәч Былбыл, чыннан да, ни әйтергә дә белмәде. Шатланса, ачык йөз күрсәтсә әдәпсезлек булыр сыман, ачуланса, караңгы йөз күрсәтсә шулай ук әдәпсезлек булыр сыман тоелды. Ул чибәр иде, матур буй-сынлы иде, өстендәге хәрби киеме, түшендәге гвардия билгесе нур сибеп, әллә кайдан күзнең явын алып тора иде. Ул горур, тәкәббер иде һәм аның менә шул тышкы ягы — горурлыгы, тәкәбберлеге, кием-салымы, ялтыр-йолтыр нәрсәләре элекке барлык тупаслыкларын, ипсезлекләрен күмеп, томалап калдыра иде.

Кунаклар өйгә керделәр, яңа өйгә шаулатып сәлам бирделәр, туп-туры олы якка уздылар һәм мондый чакта булганча, анысын-монысын сөйләнгәләп, әле Дездемонага, әле Йосыфка эндәшкәләп, урыннарга утырыштылар,

яңа өйне, өй җиһазын, тырыш, булдыклы хуҗаларны мактадылар. Шуннан соң бакчаны, ишегалдын мактадылар. Күбрәк, әлбәттә, Нажия шаулады. Ирләр исә җүпләп, хуплап, ара-тирә берәр сүз кыстырып куйдылар.

Алар шулай сөйләнгәләп утырган арада, идән уртасындагы өстәлгә яңа ашъяулык җәйделәр, табак-савыт, кашык-чәнечке ташый башладылар. Былбыл, чибәрттәсенә булышып, әле олы якка, әле кече якка чыкты. Ул йөгереп кенә йөрде һәм шулай йөгергәләп йөргән арада, үзенең нишләптер бик эшлекле, булдыклы булып күренергә тырышуын шәйләп алды. Ул тынычрак, салмаграк йөрергә кирәк дигән уйга килде һәм шундук ашыкмыйча йөри башлады, ләкин күп тә үтмәде, яңадан ашыгырга тотынды, чибәрттәсенә бөтенләй урынсыз сораулар бирде, ялгышты, бер мәртәбә чак-чак кына кулындагы тәлинкәсен төшереп җибәрмәде.

Кунакларга өстәл тирәсенә якынаерга куштылар, һәркем үзенә билгеләнгән урынга утырды. Өстәл уртасына зур мис белән кайнар аш китереп куйдылар. Тәлинкәләргә аш бүленде. Дәүләтгәрәй абзый рюмкаларга аракы салды һәм җиңел генә, шау-шусыз гына аш мәҗлесе башланып китте.

Былбылның урыны Хәнифкә каршы якка туры килде. Былбыл һич тә тыныч кына, басылып кына утыра алмады — берәр йомыш тапкан булып әледән-әле кече якка чыгып китте, андагы тәрәзә төбендәге көзге каршысына килеп, уттай янган битенә карады, чәчен төзәткәләде, изүен төзәткәләде. Тынычлангандай итте дә яңадан олы якка ашыкты.

Ул ничек тә лейтенант ягына карамаска тырышты, ләкин ихтыярсыздан күз карашы шул якка борылды. Мондый йомшаклыгы, җебегәнлеге өчен аның үз-үзенә, кунакларга ачуы килде. Аңа әллә нәрсә булды. Габделхәй янында да аңа «әллә нәрсә» булган иде. Ләкин аның янында ул үзен иркенрәк тоткан иде, үз-үзен шат һәм бәхетле итеп тойган иде.

## VI

Аш мәҗлесе тиз генә җанланып китә алмады. Барысы да болай мәҗбүри җыелышып, ашап-эчеп утыруның урынсызлыгын, вакытсызлыгын бик яхшы аңладылар. Шуңа күрә өстәл янындагы Хәниф белән Былбыл гына түгел, башкалар да үзләрен шактый кыен хәлдә сизделәр. Хуҗа кешенең иң олы кунактан түбәнрәк дәрәҗәдә булуы да нәрсәнедер тоткарлап торадыр сыман тоелды. Болай да

начальниклар алдында буйсынучан Дәүләтгәрәй абзый хәтта үз өендә дә иптәш Бикчурин белән үзен тигез саный алмады һәм кадерле кунакның хәтерен калдырудан куркып, ничектер тыелып-кысылып утырырга мәҗбүр булды.

Икенче рюмкадан соң иптәш Бикчуринның йөзе, ниһаять, ачылып китте. Шул чакны өстәл янында, әйтерсең балкып кояш чыкты. Кояш чыгу белән һәркемгә рәхәт, җиңел һәм күңелле булып китте. Нәҗия, чыккан кояшны болыт каплый күрмәсен дигәндәй, бөтен өйгә шаулатып көлеп алды, көлә-көлә иренең аркасыннан сөеп куйган булды. Бәхеткә каршы, өстәл янындагы кояшның сүнәргә исәбе юк булып чыкты. Райбашкарма башлыгы җанланганнан-җанлана барды, ике сүзнең берендә «хәтереңдәме, Дәүләтгәрәй?» дигәндәйрәк сүзләр кыстырып, райфода бергәләп эшләгән чакларны, андагы кешеләрне һәм кайбер кызык хәлләрне исенә төшерде. Дәүләтгәрәй абзый исә: «Хәтердә, хәтердә! Нишләп хәтердә булмасын!»— диештереп, очлы, такыр башын сыйпаштырып, кадерле кунакны ашарга-эчәргә кыстады. Үзе дә ипләп кенә берәр кызык хәл сөйләп алды. Аларга хатыннар кушылды, көлделәр, гөрләделәр һәм аш мәҗлесе мәҗлес төсенә керә барды.

Хәниф Йосыф янында утырды. Ашаган-эчкән арада ул аның укуы белән, киләчәктә нишләргә, кем булырга ниятләве белән кызыксынды. Йосыф кыска-кыска гына җаваплар бирде. Алар арасында әллә ни сүз ялганып китә алмады. Йосыф тамагы туйганчы ашады да беркемгә бер сүз әйтмичә өстәл яныннан торып ук китте.

— Кая барасың?— диде Фәрхәнә апа, аның каядыр җыенуын күреп.

— Рамусларга,— диде Йосыф.

Бер-ике рюмкадан Хәнифнең дә күңеле күтәрелеп китте. Йосыфның кирле-мырлы торуына аның әллә ни исе китмәде. Йосыф каядыр чыгып киткәч ул, җаен туры китереп, шундук кыз янына күчеп утырды. Бөтенесе алдында, бигрәк тә җизнәсе белән чибәрттәсе алдында аның шулай кыюлануы Былбылга әдәпсезлек булып тоелды.

— Извините, сез миңа ачуланмыйсызмы?— диде Хәниф.

— Юк, нишләп мин сезгә ачуланырга тиеш?— диде Былбыл.

— Болай гына,— диде Хәниф.

Ул арада өлкәннәр урыннарыннан кузгалыша башладылар.

— Ял итеп, җырлап-биеп алыгыз,— диде Фәрхәнә апа кунакларга.

— Дәүләтгәрәй абзый, туганкаем, әйдәле, эскерипкәңне уйнап җибәр әле бер!— диде Нажия.

— Дөрес сүз бу, Дәүләтгәрәй,— диде иптәш Бикчурин да, хатыны тәкъдимен яклап.

— И, җизнәй, уйнале, уйна!— диде Былбыл да.

— Болай төрле яктан сорагач, уйнамый булмас,— диде Дәүләтгәрәй абзый, тыйнак кына риза булып.

Аның мондый күндәмлеген Нажия үзенчә аңлаткан булды.

— Яшьләр сорагач, шундук риза булды, туганкаем!— диде ихахайлап.

— Уйнар, кем сораса да уйнар,— диде Фәрхәнә апа.

— Былбылны җырлатабыз!— диде Нажия, кирәгеннән артык кыюланып.

Шулай сөйләнгәләп ул яшьләргә якынрак килде, симез кулы белән өстәл читенә таянып, Былбылның үзенә генә әйтергә тиешле ниндидер сүзе бар сыман, колагына иелде һәм:

— Нинди җыр җырлыйсың килә, сеңлем?— диде.

Былбылның йөзенә ялкын үрләде, йөрәге дөпелдәп тибәргә тотынды. «Якын килмә!» дигән сыман кулларын югары күтәрде, кузгалгандай итеп куйды, ләкин торып китә алмыйча кире урынына утырды.

— Юк, юк!— диде ул, башын чайкап.

— Җырлайбызмы, гөрләйбезме?— дип кычкырды Нажия бөтен өй эченә.

— Каягыз әле... чыгарыгыз әле мине,— диде Былбыл, өстәл арасыннан чыгып китә алмыйча.

— Бетте, бетте, былбылым-күгәрченем!— диде Нажия, кире чигенеп.— Җырламыйбыз, туганкаем. Гөрләшегез, гөрләш!

— Нажия!— диде шул чакны иптәш Бикчурин, кырыс кына.— Кил әле монда!

— Әнә Исмәгыйль абый чакыра,— диде Хәниф җиңгәсенең симез беләгенә кагылып.

— Бетте, бетте, туганкайларым!— диде Нажия һәм, җиңел-җиңел атлап, бармакларын шартлатып, идәннең ачык җиреннән йөзеп-биеп китеп барды. Ачык тәрәзә янында тәмәке пыскытып торган ире янына килде дә кыланчыкланып аны ике куллап кочып алды, үбеп алды.

— Ни булды, кем тия, картым?— диде.

— Сагындым. Утыр шунда гына,— диде Исмәгыйль абзый, урындыкка күрсәтеп.

Нажия китеп бару белән Былбыл, читлектән котылган кош кебек, кабаланып кече якка чыгып китте. Күңеле кырылган лейтенант, өстәл янында беркем юклыктан

файдаланып, яртылаш кына эчелгән рюмкасын тотырды да ялт итеп эчеп куйды һәм шулай ук торып читкә китеп барды.

Шул чакны Дәүләтгәрәй абзый, скрипкасын көйләп, «Әпипә»не чыңлатып җибәрде.

## VII

Кече якта Фәрхәнә апа белән Былбыл шалтыр-шолтыр табак-савыт юдылар, нидер күчерделәр, нидер әзерләделәр. Көтмәгәндә алар янына Хәниф килеп керде.

— Берәр төрле булышчылар кирәкмиме сезгә?— дигән булды ул, шаяртып.

— Булышчылар кирәк инде ул, Хәниф!— диде Фәрхәнә апа, елмаеп. Ашыгыч эше бар сыман, ул тиз генә чыгып китте.

— Извините, сез әле дә миңа ачуланасызмы?— диде Хәниф үзенә яны беләнрәк торган Былбылга.

— Мин сезгә әйттем: мин сезгә ачуланмыйм,— диде Былбыл, коры гына.

— Мин сезне шундый усалдыр дип уйламаган идем,— диде Хәниф.

— Сезгә ни кирәк монда?!— диде Былбыл билен турайтып, дорфа гына.

— О-о!— диде Хәниф, күзләрен зур ачып.

Бер-берсен беренче мәртәбә күргәндәге кебек, тегендәге, автовокзалдагы кебек алар бер-берсенә ярсып, дошманнарча карашып тордылар. «Менә нинди икән бу?!»— диде Хәнифнең гаҗәпләнгән күз карашы. «Урыныңнан гына кузгал — хәзер ботарлап ташлыйм!»— диде болай да тынычсыз һәм ярсыган кызның гүзәл-дәһшәтле кыяфәте.

— Җиңгәңнең мыскыл иткәне җитмәгән... тагын сез мыскыл итмәкче буласызмы?!— диде Былбыл, өзек-өзек тавыш белән, авызыннан утлар чәчеп.

— Извините, җиңгәй өчен мин гаепле түгел,— диде Хәниф.

— Кем соң?!— диде Былбыл, үз-үзен белештермичә. Хәниф көлеп җибәрде һәм бала-чаганы юатырга, башыннан сыйпаларга ниятләгән батыр кыяфәттә, ярты адым чамасы алгарак атлап куйды.

— Килмәгез!— диде Былбыл.

Ул тагын нәрсәдер әйтмәкче булган иде, киселеп калды — көтмәгәндә кече якка Фәрхәнә апа килеп керде. Яшьләрнең кыяфәтләренә ул бөтенләй игътибар итмәгән булып күренергә тырышты һәм тыныч кына, иләп кенә Былбылга:

— Булдымы? Самавыр куярбыз,— диде.

Хәниф шундук чыгып китте, олылар янына килде, папирос кабызды, ләкин өйдә тартырга ярамаганлыгын шәйләп, утлы папиросын гөл төбенә төртеп сүндерде дә, үз-үзен кая куярга белмичә, стенадагы фоторәсемнәргә кадалды.

Дәүләтгәрәй абзый скрипка уйнавыннан туктап калды, Нәҗия кул чапты, аңа иптәш Бикчурин кушылды. Хәниф тә, нәрсә өчен икәнлеген аңламастан, болай гына кул чапкан булды.

— Җитеп торыр хәзергә,— диде Дәүләтгәрәй абзый, скрипкасын чөйгә элеп.— Бик булдырып булмый хәзер, Нәҗия. Бармаклар да карыша.

— Ниндәй булмаган ди әле ул, Дәүләтгәрәй абзыкаем!— диде шат күңелле Нәҗия, төчеләнеп.

— Булмый,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Менә минем Йосыф үземнән шәбрәк булдыра.

Нәҗия, аның сүзен үзенчә аңлап, шаркылдап көләргә тотынды.

— Уф, харап иттең, Дәүләтгәрәй абзыкаем!— диде, күз яшьләрен сөртә-сөртә.— Кая соң әле ул безнең Йосыф пигамбәр? Йосыф пигамбәребез кая булды соң әле безнең? Әле генә шушындае бит?

Шулай сөйләнеп һәм туктаусыз көлә-көлә ул кече якка чыгып китте. Ул чыгып киткәч тә, Дәүләтгәрәй абзый ымлап ирләрне өстәл янына чакырды, рюмкаларга күздәй тутырып аракы салды да:

— Көлсәләр көләрләр инде. Әйдәгез әле күтәрик тегеләр күрмәгәндә!— диде.

Кызмача ирләр рюмкаларын тоттылар, чәкештереп-нитеп тормыйча, аяк өсте генә эчеп җибәрделәр. Иптәш Бикчурин белән Дәүләтгәрәй абзый эчкәч эһ тә итмәделәр. Хәниф исә, яшь һәм тәҗрибәсез кеше буларак, чыраен сытты, тиз генә каранып өстәлдәге тәлинкәләр арасыннан яшел кыяр эзләп тапты, кетердәтеп ашарга тотынды. Иптәш Бикчурин да өстәлгә күз йөртеп алды, уртадагы тәлинкәгә үрелеп аннан бер кисәк какланган каз ите алды.

— Эх, яратам шушы каз итен!— диде майланып, лычкылдап торган кара кучкыл ит кисәген кабып.

Аның артыннан ук диярлек Дәүләтгәрәй абзый да бер кисәк каз ите алды һәм тәмләп-тәмләп чәйнәргә тотынды.

— Син аны чәйнисеңмени, Дәүләтгәрәй?— диде иптәш Бикчурин, гаҗәпләнеп.— Чәйнәмә син аны! Авызыңда тот — кәнфит кебек эреп кенә бетә ул.

— Шулай икән шул,— дигән булды Дәүләтгәрәй абзый, бик тиз килешеп.— Белмәгәнмен синең каз яратканыңны, Исмәгыйль ... иптәш Бикчурин. Җыл да как-

лап куям мин. Әле дә башланмаган ике казым бар. Берсе — сиңа болай булгач!

— Рәхмәт, Дәүләтгәрәй, рәхмәт!— диде иптәш Бикчурин, күңеле булып.— Андый нәрсә минем кулдан килми. Нәҗияне әйткән дә юк. Рәхмәт, Дәүләтгәрәй туган.

Шулай рәхмәт әйтә-әйтә, ул уң кулы белән Дәүләтгәрәй абзыйның иңбашыннан кочып алды, сул кулы белән Хәнифне кочаклады һәм әле берсенә, әле икенчесенә карап:

— Иң якын кешеләрем — сез!— диде.— Бөтен Яңавылда, бөтен дөньяда — сез! Минем бит монда барышып-килешеп йөрерлек туган-тумачам да юк. Мине монда япаялгыз дияргә була. Миңа киләләр икән, сорарга гына киләләр, зарланырга... тегесе җитми, монысы җитми, анысын алай итәргә, монысын болай итәргә... Нәрсә дисең аларга? Ярар, ярар дисең, карарбыз, уйларбыз дисең. Башкасы безнең кулдан килә торган түгел. Эх! Бөтен Яңавылда иң якын туганнарым — сез... Дәүләтгәрәй, Фәрхәнә апа... Райфода да без бертуган кебек яшәдек... Хәниф минем иң якын энем. Сөлек кебек чагы. Эх!

— Әйдәгез әле тагын берне күтәрик!— диде Дәүләтгәрәй абзый җайлап кына, өстәлдәге буш рюмкаларга үрелеп.

— Мин эчмим,— диде Хәниф һәм абыйсының кочагыннан чыгып читкә китеп барды.

Дәүләтгәрәй абзый өченче рюмкага салып тормады. Иптәш Бикчурин белән алар күтәрделәр, чәкештерделәр дә эчеп җибәрделәр. Дәүләтгәрәй абзый таза, юантык Исмәгыйльдән озынрак иде, шуңа күрә чәкештергәндә аңа чак-чак кына иелергә туры килде. Эчкәч иптәш Бикчурин тагын каз итенә үрелде, бер кисәкне авызына капты да үз-үзеннән, бөтен дөньясыннан канәгать бер төс белән:

— Эх, яратам шушы каклаган каз итен!— диде.— Авыл искә төшә, яшь чаклар искә төшә, Дәүләтгәрәй.

Аның артыннан ук диярлек Дәүләтгәрәй абзый да бер телем каклаган каз ите алып капты, әлерәк кенә әйткән сүзләрен искә төшереп:

— Бер каз синеке, Исмәгыйль,— диде.— Әйткән сүз — аткан ук! Синдәй кешегә каз җәлләп тораммы соң?! Син безнең иң якын кешебез, туган-тумачадан да якынрак кешебез. Моннан соң да гел барышып-килешеп яшәргә язсын.

— Шулай, Дәүләтгәрәй!— диде иптәш Бикчурин һәм баягыча тагын каты, нык кулы белән хуҗаның биегрәк иңбашына үрелде, кысып тотып алды.

— Әйдәле, менә монда утырып торыйк,— диде, Дәүләтгәрәй абзый, өстәл янындагы урындыкларны идән

уртасынарак күчереп.— Синдәй олы кешегә аяк өсте тору килешми.

— Синең янда килешә, Дәүләтгәрәй,— диде иптәш Бикчурин.— Беләсең ич, иң якын кешем — син! Эх, Дәүләтгәрәй! Күңелемдә авыр төер бар. Олыгая барган саен шул борчый. Беләсеңме, мин бит... кеше үтерүче!

## VIII

Бу шундый көтмәгәндә әйтелде, бу шундый ап-ачык итеп әйтелде, кызмача Дәүләтгәрәй абзый кинәт айнып китте, куркып китте, як-ягына каранып алды, күзләрен челт-мелт йомгалады, урыныннан торып ишеккә таба барып килде. Ярый әле якын-тирәдә тыңлап торырдай беркем юк иде.

— Туктале, тукта, иптәш Бикчурин...— диде ул, каушап-кабаланып.— Алай кычкырып сөйләшмик әле без.

— Мин аны сиңа гына әйтәм. Синнән сүз чыкмаячагын беләм,— диде Исмәгыйль.— Эх, Дәүләтгәрәй!.. Юлбасар да түгел, талаучы да түгел, шулай да менә — кеше үтерүче мин. Ничек дисеңме? Ашыкма, хәзер әйтәм. Чиләбе трактор заводын ишеткәнең бармы? ЧТЗны? Менә шуны без төзедек. Юк, юк, мин түгел. Без саклап кына тордык. Этләр, автоматлар белән. Аңлыйсыңмы, төшендеңме хәзер? Минем биографиядә бу турыда: партия чакыруы буенча Чиләбе трактор заводы төзүгә китә, башта ташчы, аннан бетончы булып эшли; гади эшчедән бригадир булып күтәрелә, алдынгы була, фәлән-төгән дип язылган. Төшендеңме хәзер? Мин ул таш-бетонның янына якын да барган кеше түгел. Аттык без. Кешеләргә аттык, Дәүләтгәрәй!

Эчкәч иптәш Бикчуринның чишелә торган гадәтен Дәүләтгәрәй абзый элек тә белә иде, ләкин аның авызыннан әле беркайчан мондый сүзләр чыкканы юк иде.

— Күп... аттыгызмы?— диде ул, исе-акылын җыя башлап.

— Күп. Бик күп,— диде Исмәгыйль беравык эндәшми утыргач, авыр сулап.— Син сугышта булган кеше, Дәүләтгәрәй. Анда да без кеше үтердек. Ләкин анда без дошманны үтердек. Монда мин үзебезнең кешеләрне үтердем. Урысын-татарын, арын-чирмешен... берсе дә калмады. Үз кешеләр. Беләсеңме, бер гаепсез кешеләр!

— Бер гаепсез?!

— Бер гаепсез, Дәүләтгәрәй,— диде иптәш Бикчурин.— Башта конвойда йөрдем. Аңгыралыгымны, наданлыгымны күрделәр дә бәләкәй генә начальник иттеләр. Шуннан китте. Соңга таба зуррак начальник булдым. Ләкин зуррак

начальник булгач кына, хата җибәрдем. Хатам шул — бер якташны, үзебезнең бер татарны кызгандым. Сизделәр, тикшерә башладылар. Атарга тиешләр иде. Сугыш коткарды. Үзем теләп сугышка киттем. Яраландым. Шуннан менә бу якка, Яңавылга килеп чыктым. Анысын беләсең.

— Беләм,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Бульдозерлар белән издерделәр кешеләрне, туфракка, вак ташка катыштырып издерделәр, Дәүләтгәрәй. Күбесенә мин үзем приказ биреп, карап тордым. Менә шунысы кыен. Искә төшә дә йоклый алмыйм. Әйтер кеше юк. Нәҗиягә сөйләргә куркам.

— Синең монда ни гаебең бар соң, иптәш Бикчурин? Минемчә, монда синең бер гаебең дә юк!— диде Дәүләтгәрәй абзый, кунагын тынычландырмакчы булып.

— Белмим. Бар микән, юк микән — белмим. Үземне-үзем атып үтергән булсам, дөресрәк булгандыр кебек,— диде Исмәгыйль.— Беләсеңме, ул кешене мин яңадан фронтта очраттым! Үз кулымда үлде. Яхшылап күмдем. Менә ул язмыш. Эх!

Дәүләтгәрәй абзый урыныннан торып әрле-бирле йөренде дә чөйдәге скрипкасына барып тотынды, ниндидер көй чыгармакчы булды — булдыра алмады, скрипкасын яңадан чөйгә элеп куймакчы булды, шулай ук булдыра алмады. Уен коралын утын агачы кебек тотып кече якка чыгып китте, ләкин анда да озак тора алмады — тагын Исмәгыйль янына килеп туктады.

— Утыр әле, йөрмә, Дәүләтгәрәй!— диде иптәш Бикчурин.

Дәүләтгәрәй абзый сүзсез генә үз урынына утыргач, ыргактай кулы белән аны яңадан әләктереп алды да:

— Эх, гармун юк, гармун!— диде.— Яшь чакта мин бөтен тирә-якта беренче гармунчы идем, Дәүләтгәрәй. Эх!

Шулай диде дә бар көченә кычкырып җырлап җибәрде:

Биек тауның башларында
Карабодай кубәсе.
Бардыр әле башларымның
Әллә ниләр күрәсе.

Аңа әкрен генә, җайлап кына Дәүләтгәрәй абзый кушылды.

## IX

Алар шулай кочаклашып җырлап утырганда, олы якка Нәҗия килеп керде. Килеп керде дә идән уртасында туктап калды һәм бот чабып көләргә тотынды.

— Карале, кара, туганкаем Фәрхәнә апа — боларның дөньясы түгәрәкләнгән!— диде.

Нәҗиядән беркадәр калышып, ике куллап зур гына таба белән кайнар бәлеш күтәреп Фәрхәнә апа керде. Бәлешне табасы белән өстәл уртасына, җәелгән чүпрәк өстенә куйды да, Нәҗиянең сүзенә колак салмаган сыман булып күренмим тагын дигәндәй, тукталып, көлемсерәп карап торгандай итте.

— Әйдә, кисә башла, Нәҗия,— диде һәм ашыгып яңадан кече якка чыгып китте.

Алар шулай Нәҗия белән икесе әле теге якка, әле бу якка чыгып, тегесен-монысын әзерләделәр. Бөтен өйгә итле бәлеш исе чыкты. Иптәш Бикчурин белән Дәүләтгәрәй абзый, дөньяларын онытып, парлашып җырлауларын белделәр.

Тын алып, беркадәр тынычланып тыштан Хәниф керде.

— Әйдәгез, утырышыгыз, кунаклар,— диде Фәрхәнә апа, кунакларны табынга чакырып.

Барысы да көттермичә яңадан урыннарына утырыштылар. Былбылның урыны буш калды. Аның юклыгына беренче булып Дәүләтгәрәй абзый игътибар итте.

— Кая соң безнең Сандугачыбыз?— диде ул.— Диздекәй дә күренми.

— Диздекәй йоклый,— диде Фәрхәнә апа.— Былбылның башына ис тигән бугай. Аның башы авырта.

— Туктале, үзем алып килим әле,— диде Дәүләтгәрәй абзый гадәттә булмаганча җиңел генә урыннан кузгалып.— Мондый чакта йоклап яталармыни?!

— Ярар, йөремә инде — үзем барып карармын,— диде Фәрхәнә апа, иренең юлына аркылы төшеп.

Дәүләтгәрәй абзый күндәм генә кире урынына утырды, үзенең төп вазифасын исенә төшереп, рюмкаларга аракы сала-сала, кунакларны ашарга-эчәргә кыстады.

— Әйдәгез әле, җитешегез, кунаклар,— диде.

— Бәлеше бик тәмле күренә, Дәүләтгәрәй — шайтан сидеге белән бутамыйча гына ашыйк әле,— диде иптәш Бикчурин, кайнар бәлеш кисәген кулына алып.

— Ярар алайса,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Ашагыз, аша, кунаклар. Хәниф, син дә җитеш.

Кунаклар бәлеш ашый башлаганда Фәрхәнә апа да килеп җитте һәм сүзсез генә үзенең урынына утырды. Былбыл турында бер сүз дә әйтмәде. Башкалар да аның исемен телгә алмауны яхшырак күрделәр. Бары тик Нәҗия генә түзмәде.

— Их, мин булсаммы!— диде.— Мин булсаммы! Кызларның башы авыртканына карап тораммы?!

Ул моны ярым шелтә, ярым шаярту белән әйтте, алай гына да түгел, үртәлеп һәм гайрәтләнеп әйтте. Хәниф аның үзенә төрттергәнлеген бик яхшы аңлады. Йөзе бозылды, матур кара кашлары бергә кушыла язды, авызы ямьсез булып бөрешеп калды.

— Ярый әле син булмагансың,— диде иптәш Бикчурин.

— Мин булсаммы?! Мин булсаммы?!— диде әдәпсез Нәҗия, бер үк сүзләрне кабатлап.

— Кирәкмәгән җиргә кысыласың, җиңгәй,— диде Хәниф, телгә килеп.

— Ай Алла, туганкаем! Бетте, бетте. Шуңа да ачуланып торырга син теге,— диде кайгыра белми торган Нәҗия.

— Ашап кына утырыгыз әле, кунаклар,— диде Фәрхәнә апа.

Кунаклар ашап кына утырдылар. Ашап утыру озакка сузылды. Өй эче караңгыланып китте. Тышта нидер дөбердәп куйды. Ачып куелган тәрәзәдән саф, дымлы җил исеп керде, һәркем күңеленнән «яңгыр җиле» дип уйлады. Яңгыр күптән көтелә иде, яңгыр күптән кирәк иде. Дымлы җил шундук кешеләрнең кәефен үзгәрткәндәй булды. Караңгы тәрәзәне ялт-йолт китереп, тавышсыз гына яшен яшьнәп алгач, бернинди шик калмады — бүген яңгыр явачак иде. Тәмле аш һәм яңгыр җиле, яшен һәм күк күкрәү тәэсирендә мәҗлес үзеннән-үзе түгәрәкләнә башлады.

Беренче булып иптәш Бикчурин торды, аның артыннан ук диярлек Дәүләтгәрәй абзый торды, Хәниф торды. Алар, тирләгән битләрен, маңгайларын сөрткәләп, ишеккә таба юнәлделәр, тышка чыктылар.

— Ява бу, явачак,— диде иптәш Бикчурин, кара болытлар белән капланган тынычсыз күккә карап.

— Яусын инде,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Ява башлаганчы кайтып китәбезме әллә?— диде Хәниф.

— Без белмибез, җиңгәңә әйт,— диде иптәш Бикчурин. Аның әле кайтып китәргә исәбе юклыгы үзеннән-үзе сизелеп тора иде.

— Кунып китәрсез,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Күп күрдем мин яңгырны,— диде иптәш Бикчурин.— Карлысын да, бозлысын да, кургашлысын да... Яңгырдан куркып тормыйбыз әле, энем Хәниф. Таңга кадәр күңел ачабыз!

— Дөрес, картым!— диде арттан килеп җиткән Нәҗия, иренең соңгы сүзләрен куәтләп.

— Мин нәрсә әйттем?— диде иптәш Бикчурин Хәнифкә карап, кете-кете көлеп.— Мин — начальник, җиңгәң — прокурор. Закун! Ул ничек әйтсә, шулай.

Хәниф кайту турында бүтән сүз кузгатмады. Портсигарын алып папирос кабызды һәм теләмичә генә тартырга тотынды.

Кунаклар яңадан өйгә керделәр. Керү белән иптәш Бикчурин Дәүләтгәрәй абзыйга күз кысты һәм тулы рюмкага килеп тотынды.

— Әйдәле, хатын-кыз күрмәгәндә генә...— дигән булды Дәүләтгәрәй абзый.

Алар эчеп җибәрделәр. Дәүләтгәрәй абзый тагын скрипка уйнатмакчы булып карады, ләкин иптәш Бикчурин аны тагын кочып алды, урындыкка утыртты.

— Җырлыйк әле,— диде ул, якындагы буш урындыкка утырып.

Алар икәүләшеп эчкечеләр җырлый торган такмакларны сузып җибәрделәр. Фәрхәнә апа елмаеп куйды, Наҗия көлеп җибәрде. Җырны иптәш Бикчурин әйдәп барды. Аның тавышы да көррәк, ягымлырак иде, җыр сүзләрен дә ул яхшырак белә иде. Бер-ике тыннан соң аларга сыек, моңсыз һәм чәрелдек тавыш белән Наҗия кушылды. Бераз гына җырлагандай итте дә, тамагы карлыгып, йөткеренеп алды. Тын юлы алай да ачылып китмәгәч, кече якка чыгып кайнар чәй капты, яңадан ирләр янына килеп утырды һәм сул кулы белән ачык күкрәген тотып, кушылып китте. Шул чакны ул күңелсезләнеп утырган Хәнифкә күз төшереп алды.

— Әйдә, син дә җырла!— диде.

Хәниф эндәшмәскә тырышты. Тынгы белмәс җиңгәй урыныннан торып каенэнесен җырларга кыстый башлады. Ирләр җырлауларыннан туктап калдылар.

— Наҗия!— диде иптәш Бикчурин, бармак янап.

— Әүкәй, Исмәгыйль?— диде Наҗия, эт кояшыдай ялтырап.

Алар үзара аңлашкан арада, Дәүләтгәрәй абзый скрипкасын көйләп җибәрде һәм булдыра алган барлык осталыгын җигеп, янә «Әпипә»не чирттерә башлады. Иптәш Бикчурин бөтен өйне дер селкетеп, бармакларын шартлатып биергә керешеп китте. Скрипка тавышына ул бик үк колак та салмады. Ул бары үз көен, үз ритмын гына белде һәм үз-үзен дәртләндереп сызгырып-сызгырып җибәрде. Биеп туктагач, «Эх!» диде дә, кулъяулык эзләп кесәсенә тыгылды.

— Гармун юк, гармун! Без яшь чаклардагы гармун булсыные хәзер!— диде.

Аңа кул чаптылар, мактау сүзләре әйттеләр.

— Әйдә, хәзер — син!— диде Наҗия, әлеге дә баягы Хәнифкә бәйләнеп.

— Мин болай бии белмим,— диде Хәниф.

— Нәрсә генә беләсең соң син, энекәем?— диде Нәҗия, ачынып.

— Мин тансовать итәм,— диде Хәниф.

— Әйдәле алайса, әйдә,— диде Нәҗия һәм бер кызудан Хәнифне җилтерәтеп, әйләндереп алып китте.

Хәниф бу юлы карышып тормады — җиңгәсе белән парлашып бии башлады. Ләкин болай музыкасыз гына әйләнгәләүнең бернинди кызыгы булмады.

— Музыка кая, музыка?— диде Хәниф.

— Шул да булдымы бию?— диде иптәш Бикчурин, кулын селтәп.— Баскан саен табаныңнан ут чыкмагач, бию буламыни ул?!

— Яшьләргә ярый инде,— диде Фәрхәнә апа, көлемсерәп.

— Яшьләргә дигән буласың, Фәрхәнә апа туганкаем, бар әле Күгәрченеңне алып кил,— диде Нәҗия, әйләнгәләвеннән туктап.— Нинди эш инде бу вакытта йоклап яту?! Тансы-мансы биесеннәр. Җегетебез ялгыз. Күңелсезләнәсең килмәсә дә күңелсезләнерсең.

Җиңгәсенең сүзләренә Хәниф бөтенләй ачуланмады, киресенчә, бу аңа кыюлык булып тоелды.

— Каяле, үзем генә алып килим булмаса,— диде. Җилләнеп ул чоланга чыгып китте һәм беренче очраган ишекне тартып җибәрде — ишек эчтән бикле иде. Шул ук вакытта диярлек аның янына ашыгып Фәрхәнә апа килеп җитте.

— Хәниф, Хәниф,— диде ул, борчылып.— Анда түгел, акыллым. Үзем әйтермен, үзем чакырырмын. Син бар, кереп тор.

Хәниф, кызмача булса да, үзен-үзе аңламас дәрәҗәдә түгел иде.

— Мин бит болай гына... болай гына,— диде ул, гафу үтенгән сыман сөйләнгәләп.

Аңа кинәт оят булып китте, үзенә-үзе бик кызганыч булып тоелды. Аның хәзер Фәрхәнә апага зарланасы һәм аннан яклау табасы килде.

— Мин үзем чакырырмын, үзем,— диде Фәрхәнә апа, пышылдап.

Шул вакыт тышта бик каты нидер шартлап ярылгандай булды, ниндидер дөбердек тавыш ишетелде һәм озак та үтмәде, такта түбәгә бик каты бәреп яңгыр ява башлады. Фәрхәнә апа куркып, шомланып өйгә кереп китмәкче булган иде, искәрмәстән тышкы ишек ачылып китте һәм караңгыда ашыгып Йосыфның кайтып кергәне күренде.— Яңгыр ява!— диде Йосыф, килеп керү белән.

# X

Сакат урманына җитәрәк яңгыр сибәли башлады. Көн дә караңгыланмады. Түбә өстеннән элеккечә елмаеп кояш карады, шулай да менә яңгыр сибәләргә тотынды. Гаҗәп инде бу җәй көне. Яңгырдан котылмакчы булып, Габделхәй тизрәк урманга җитәргә ашыкты.

Менә ул йөгерә-йөгерә урманга килеп керде. Ләкин урман ул көткәнчә булып чыкмады. Яңгыр монда хәтта шәбрәк ява шикелле тоелды — бөтен тирә-як шаулап, шыбырдап тора иде. Юлдан читтәрәк бер-ике чыршы күренде. Чыршы астына кереп яңгыр туктаганны көтеп торырга булыр иде, әлбәттә. Ләкин бүтән вакытта аңа шундый якын, аңлаешлы була торган чыршы да хәзер нишләптер чит, ят булып тоелды. Ул анда кереп вакыт уздырмаска булды һәм юеш, тайгак юлдан бик кыенлык белән, саклык белән атлап, һаман алга баруында булды. Ул инде тәмам чыланып бетте. «Кайткач кибенербез әле»,— дип уйлады ул, үзләренең коры, җылы өйләрен күз алдына китереп.

Тау төшүе бик читен булды. Бер-ике мәртәбә таеп, ул пычрак юлга утырды, чалбарын, кулын пычратты, янбашын авырттырды. «Ярар, кичүгә җиткәч Бүәдә юармын әле»,— диде ул, янә күңелен төшермәскә тырышып. Шуннан соң ул корыган чикләвек таягы сындырып алды һәм аеруча тайгак җирләрдә таягына таяна-таяна төште. Сакат тавының иң текә җирен узып, юл буендагы тирән чокырга җитәрәк кинәт теге чәнчеп ташланган яшь марҗа хатыны исенә килде. Куркудан, яшь марҗа хатынын кызганудан йөрәге чемердәп китте. «Әллә чокырны читтәнрәк, урман эченнәнрәк әйләнеп үтим микән?»— дип уйлады ул икеләнеп. Анда, чокыр төбендә кемдер аны көтеп, сагалап торадыр шикелле тоелды.

Як-ягына каранып, курка-курка гына, ниһаять, ул чокыр турысыннан да узып китте. Чокырдан ераклашкач туктап калды, исән-имин котылуына ныграк ышанырга теләгәндәй, тирә-якка күз төшерде, як-яктагы тавышларга колак салды. Чокыр ягында да, күз күреме җиткән урман эчендә дә шикләнерлек берни сизелмәде, берни ишетелмәде. Кинәт ул үзенең бик нык арыганлыгын, ачykканлыгын тойды. Хәзер инде ашыкмасаң да була иде. Кичүгә генә җитәсе дә, теге якка гына чыгасы да... анда инде Яңавылга күп тә калмый.

Ул яңадан кузгалып китте. Түбә өстеннән шыбырдап, әчне пошырып өзлексез яңгыр яуды, агач башларындагы яфраклардан, яңгырга кушылып, эре-эре тамчылар коелды. Биттән, муеннан яңгыр суы акты, тәнгә

сылашкан, чыланган, авырайган киемнәр атларга, уйларга-хыялланырга комачаулады.

Бу вакытта инде күкне тоташ болытлар каплап алган, көнне караңгылатып җибәргән иде.

Сакат тавын төшеп, беркадәр җир тигезлектән баргач, Габделхәй күптән көтелгән кичү турысына килеп җитте. Килеп җитүен җитте, ләкин шул чакны аның алдында гаҗәеп бер күренеш ачылды. Бүә танымаслык булып үзгәргән, Бүәдә су күтәрелгән иде! Яр буендагы таллар, камышлар, куе үләннәр — барысы да кайдадыр су астында калган; башка вакытта пыяладай үтә күренмәле чиста су комланган, болганчыкланган; әле кайчан гына барлыгы-юклыгы да рәтләп сизелмәгән ягымлы, юаш елга бары язгы ташу чорында гына була торган дәһшәтле кыяфәткә кереп, коточкыч тирән һәм куркыныч ташкынга әйләнгән иде. Бүә сай чагында, әрсезләнеп, яр астына ук төшеп үскән куаклар, муеннарыннан суга чумып, тончыгып-калтыранып утыралар иде. Бөтен тирә-як каядыр омтылган һәм бар нәрсәне юып, күмеп, агызып алып китәргә көченнән килгән илаһи көч-куәт алдында тынып-йомылып калган сыман иде.

Җәй көне Бүәнең бу кадәр ташыганын Габделхәйнең әле күргәне юк иде. Бик озак ул исенә-акылына килә алмый торды. Бер үк вакытта ул соклану, таң калу, курку һәм шомлану да кичерде. Үзе алдында, берничә адымлык җирдә генә ул тетрәндергеч көч-куәт чыганагы күрде, кыргый гүзәллек күрде. Ирексездән ул аның алдында баш иярgә мәҗбүр булды һәм гомерендә беренче мәртәбә серле табигать каршында үзенең ни дәрәҗәдә көчсез, ярдәмчесез һәм кечкенә икәнлеген аңлагандай булды.

Әле куркып, әле онытылып адәм баласы тулып аккан суга карап торды да торды. Каты җирне җырып, урман-таулар арасыннан еландай боргаланып шуышкан, туктаусыз агып торган бу шомлы, дәһшәтле ташкынга күпме карасаң да, ул сине ялыктырмый, киресенчә, караган саен сихерле һәм үзенә тарта, суыра бара сыман иде. Бу ташкынны тулысынча аңлау-төшенү өчен әйтерсең аңа бары кушылырга һәм аның белән бергә каядыр агып китәргә генә кирәк иде.

Габделхәй туктап калган җирендә каккан казыктай кузгалмыйча торды да торды. Ул арада яңгыр шәбәя башлады. Эре тамчылар су өстенә чупылдап-чупылдап коелдылар, чәчрәделәр һәм Бүәгә кушылып юкка да чыктылар. Яңгыр пәрдәсе аша теге як бөтенләй күренмәс булды. Габделхәй туңа башлады. Ул, як-ягына карангалап, ышыкланырдай урын эзләде.

Калку урындагы моңаеп утырган ялгыз карама аны үз янына чакырды. Ашыгып ул шунда йөгерде, куе ботаклар астына керде дә калын, кытыршы кәүсәгә аркасын терәде. Сихерләнгән кебек ул моннан да су өстенә карады. Беренче тәэсир — курку, соклану, шаккату тойгылары кими төшкәч, үзенең хәзерге хәле турында уйлый башлады. Нишләргә, кая барырга да ничек итеп теге якка чыгарга? Күпергә китәргәме? Күпер ерак. Анда тиз генә барып җитәрлек түгел. Моның өчен иң элек Сакат тавын менеп, яңадан олы юлга чыгарга кирәк булачак. Аннан соң, мондый ташуда күперне су агызып алып киткән булырга тиеш, чөнки Бүә күпере, гадәттә, җәйге вакыт өчен генә, җиңелчә генә салына. Елганы боз тоту белән аны сүтеп алалар, сүтеп алырга өлгермәгән очракта яз көне аны су алып китә.

Болай булгач, кире Янтыкка кайтырга, су кимегәнен шунда көтеп ятарга микәнни? Ләкин аның хәзер һич тә авылга күңеле тартмады. Бу аңа нәрсәдәндер кире чигенү булып тоелды. Аның чигенәсе килмәде. Ул бары алга барырга, ничек тә Яңавылга кайтып җитәргә тиеш иде. Бит аны анда кемдер көтеп тора!

«Әгәр шушында төн кунсам?!» — дип уйлады ул, билгеле бер фикергә килеп. Төнлә, бәлки, яңгыр да туктар, су да кимер. Иртән, бәлки, кичү аша чыгарга да булыр.

Аның өстендә киеме бер генә кат иде, бер кулында таяк, икенче кулында ямалган ботинкасы белән картыйсы биргән төенчек иде. Үзе ул суга баткан чебеш кебек чыланып беткән, туңган-бөрешеп беткән иде. Читтән караганда аны хәзер хәер сорашучы берәр ятим бала дип уйларга булыр иде. Ләкин ул үзенең тышкы кыяфәтен күрмәде һәм тышкы кыяфәт сыман юк-бар нәрсә турында уйламады да. Ул бөтенләй икенче нәрсәләр турында хыялланды. Үзе туктап калган җирне ул яңгыр пәрдәсе аша түгел, бәлки, күңелендәге алсу томан элпәсе аша гына күрде. Шушында, шушы карама төбендә ул чыбык-чабыктан корамаланган, өстенә хуш исле печән капланган коры шалаш, шалаш алдында утлы учак күрде. Шалаш алдында, коры печәндә, имеш, елмаеп Уфа кызы Былбыл утыра. Ул әле генә су кереп чыккан. Ул шундый сылу. Аңа хәтта туры карап та булмый — күз ояла. Аның тәнендә су тамчылары елтырый. Учакта, корымлы бидерәдә, балык пешә, бәрәңге пешә. Алар бүген бергәләп кайнар балык, бәрәңге ашаячаклар. Картый карбаздан салкын катык кертеп бирәчәк.

Салкын катыкны исенә төшергәч, ул суыктан калтыранып, сискәнеп китте. «Карале, аяк өсте йоклап торам

түгелме соң?»— дип уйлады ул, исе китеп. Юк, болай аяк өсте йокларга ярамый. Туктале, шушы тирәдә печән кибәннәре булырга тиеш лапса! Нигә шунда барып кешечә рәхәтләнеп йокламаска... лапса?

«Лапса» бик матур сүз икән. Иленура сүзе... Иленура хәзер рәхәтләнеп йоклап ятадыр инде»,— дип уйлады ул, үзен озатып куйган кыз туганын исенә төшереп. Бигрәк тә аның менә шул «лапса»сы исендә калган да, матур муенындагы матур муенсасы исендә калган. Кашлары да, тешләре, иреннәре дә матур Иленураның. Исеме генә әллә нинди. Чыны — Элеонора. Шуны бозып, Иленура, диләр. Дездемонаны кем уйлап тапкандыр инде? Диздекәй дигәндә әле ярый, ләкин «Дездемона» диделәрме, әллә нинди ямьсез нәрсәләр күз алдына килә. Барысыннан да матуррагы, әлбәттә, Былбыл! Сандугач! Шәп исем, искиткеч матур исем.

«Әһә, тагын йоклап китеп барам түгелме соң?»— диде ул үз-үзенә. Юк, болай ярамый. Кузгалырга кирәк, китәргә кирәк моннан — әллә су тартып алыр. Суны бит тарта диләр. Юк, юк, китәргә кирәк!

Күптән түгел печәнчеләр өеп куйган кибән кичүдән ерак түгел иде. Габделхәй туры шунда кибән ягына китеп барды. Әле ныклап басылмаган печән кибәнен актарып үзенә оя ясады һәм башы-аягы белән күмелеп шунда кереп утырды. Җылы һәм аулак иде монда. Ләкин яңа урында ул тиз генә йоклап китә алмады. Утыра торгач, картыйсы биргән күчтәнәчләрдән авыз итеп карамакчы булды. Башта бер бәрәңгене ашады, аннан икенчесен ашады бер уч тутырып җиләк капты. «Бүгенгә җитеп торыр»,— диде ул аннары үз-үзенә. Җитәр. Иртәгә дә көн бар.

## XI

Берзаман Габделхәй күзләрен ачып җибәрде һәм үзенең кайдалыгын чамалый алмыйча озак кына уйланып ятты. Баштарак аңа ул үзләренең лапас түбәсендә печәнлектә йоклап ята сыман булып та, Янтыкта чоланда ята сыман булып та тоелды. Шулай да бу рәвешчә йокылы-уяулы яту озакка сузылмады. Келт итеп кичәге күренешләр исенә төште. Котылгысыз сорау булып бөтен ихтыярын шундук рәхимсез чынбарлык биләп алды. «Ничек икән?»— дип уйлады ул, ташыган Бүәне күз алдына китереп.

Мүкәләп оясыннан чыкты, аягына басты. Яңгыр туктаган, көн яктырган иде. Бөтен табигатьтә бары тик яңгырдан соң гына була торган бер тынлык, сафлык һәм гүзәллек бөркелә иде. Үләннәр, агач яфраклары юеш. Кая карама

өзелеп төшәргә өлгермәгән яңгыр тамчылары асылынып тора, бөтен нәрсә җемелди, җир өстеннән җиңелчә бу күтәрелә. Кайдадыр аяк астында, куктә, тирә-якта көн туyына сөенеп, вак кошлар чыркылдый, әрәмә ягында моңсу да, шомлы да итеп ялгыз саескан шыгырдый.

Яңгыр туктагач, ташуның, һичшиксез, кире кайтачагына Габделхәй әз генә дә шикләнмәде. Ләкин ярга якынаю белән ул үзенең бик каты ялгышканлыгын аңлады. Бүәдә су әз генә дә кимемәгән иде. Бүә, ярларына сыеша алмыйча, кичәгедәй шаулап-ургылып, каядыр ага да ага, каядыр ашкына иде.

Габделхәй ярга якынрак килде һәм таң калып, куркып-шомланып аккан суга карап торды да торды. Кичә ничек карап торган булса, бүген дә шулай ук карап торды. Бүә дә, кичә ничек аккан булса, бүген дә шулай туктаусыз ага да ага. Әйтерсең, дөньяда берни үзгәрмәгән. Каян килә аңа бу кадәр су, бу кадәр көчкуәт? Гаҗәп бит бу. Иң гаҗәбе шул: елгада су әз генә дә кимергә уйламый иде бугай. Чыннан да, каян килә бу? Күрәсең, читтә, югарыда, Молотов өлкәсендә мондагыдан да көчлерәк яңгыр яугандыр. Анда әле, бәлки, һаман явадыр.

Суга карап торган арада Габделхәй шуңа да игътибар итте: кичәгенәк ул посып торган калку урындагы карама бөтенләй яр кырыенда калган иде. Бүә тагын берәр тәүлек тулып-артылып акса, карама агачы суга капланып төшәргә дә мөмкин иде.

«Әгәр шунда мин йоклап утырган булсам?!» — дип уйлады Габделхәй, караманың төбе-тамыры белән суга ишелеп төшүен күз алдына китереп. Куркып, ул тизрәк читкә китәргә ашыкты, калкурак җиргә килеп җитте дә тагын артына борылып карады — ул әле һаман суның сихереннән котылып җитә алмаган иде бугай.

Елга ягына караштыргалап ул төенчеген чиште һәм изелеп, укмашып беткән бәрәңгеләрне тәмләп кенә ашый башлады. «Нишләргә соң?» — диде ул үз-үзенә, аптырап. Кире Янтыкка кайтырга һаман аягы тартмады. Әгәр ул көтмәгәндә яңадан авылга кайтып төшсә бу һич тә җегетлек булмас иде, әлбәттә.

«Туктале, монда бит кайдадыр шушы тирәдә Җобанайның сыер фермасы булырга тиеш», — диде ул үз-үзенә, уйлана торгач. Кичүдән үрдәрәк, калку җирдә һәр елны аларның җәйге фермалары була. Көймәләре юк микән? Булырга мөмкин. Бик мөмкин.

Күңеле күтәрелеп, максаты ачыкланган Габделхәй яңадан кузгалып китте. Төш вакыты якынлашканда ул

арып-алҗып, киемнәрен җырттырып, чытыр аша Җобанайның җәйге фермасы турысына барып җитте. Ферма теге якта, текә ярдан читтәрәк утыра иде. Елга аша салам түбәле озын каралтылар, киртәләп алынган утарлар һәм тәбәнәк кенә йортлар аермачык булып күренеп тора иде. Фермадан арырак, тигез җирдә, әрәмә буенда таралып сыер көтүе йөри, ләкин якын-тирәдә беркем күренми иде.

Габделхәй Бүә ярына якынрак килде, ачыграк, калкурак җиргә басты да, кулын авыз турысына китереп, бар көченә кычкыра башлады.

Күпмедер вакыттан соң аны ишетеп алдылар. Янында ак бидоннар тезелеп торган бәләкәй генә өйдән берике хатын-кыз чыкты. Берни аңламыйча, аптырап, тавыш килгән якка карап тордылар-тордылар да ярга якынрак килделәр һәм соңлап булса да:

— Нәмә-ә?— диделәр.

— Чыгарың әле! Көймәгез юкмы?— дип кычкырды Габделхәй.

Хатыннар аңлап җитмәделәр, ахрысы — тагын «намә?» диделәр, яр кырыена ук килделәр һәм «кем соң бу?» дигәндәй, озаклап карап тора башладылар. Габделхәй Бүә аша чыгарга кирәклеген көч-хәл белән аңлатып бирде:

— Яңавылга кайтам,— диде,— Бүә ташыганны белмәдем, Янтыктан киләм,— диде.

Алар елга аша сөйләшкән арада, тәбәнәк өй ягыннан тагын бер-ике кеше килде. Берсе ир кеше, икенчесе хатын-кыз иде. Хатыннар Габделхәйгә төрле сораулар бирделәр, үзләренчә киңәш иттеләр. Берсе әйтте: «Син инде бу якка чыгалмассың — Бүәдә су кайтмаячак»,— диде. Икенчесе әйтте: «Күкнең төбе тишелгән — ишетмәдеңмени?»— диде. Арада чибәррәге, чаярагы: «Безнең янда калырга риза булсаң, үзем чыгып алам»,— диде.

Ярым солдат киемендәге яшь ир кеше хатын-кызлар шулай юк-бар сөйләнгәндә эндәшмичә генә тыңлап торды да, билгеле бер карарга килеп:

— Көтеп тор! Хәзер чыгарсың!— дип кычкырды. Тиз-тиз атлап, ул ферма ягына китеп барды. Бер ярты сәгать чамасы үткәч, җигүле ат килгәне күренде. Солдат киемендәге яшь ир кеше белән икенче бер олырак ир кеше яр кырына җиткәч, арбадан көймә төшерделәр. Дилбегә белән уратып бәйләнгән иске генә, бәләкәй генә көймәне ирләр җайлап түбәнгә, суга таба шудырдылар. Шуннан соң яшьрәк ир кеше көймәгә керде һәм кулындагы ишкәге белән ишә-ишә, Габделхәй ягына килә башлады. Исән-имин килеп җиткәч, яр буендагы талны эләктереп алды да көймәне коры җиргә якынрак тарттырды һәм:

— Әйдә, киттек,— диде.

Габделхәй, агач ботакларына тотынып, яр читенә төште, сакланып кына көймә янына килде.

— Мә кулымны, мулла абзый!— диде ярым солдат киемендәге ир кеше көлемсерәп, кулын сузып.

«Кем соң әле бу? Кайда күргән идем соң мин аны?» — дип уйлады Габделхәй, сабан туе батыры сыман таза ир кешенең көчле кулына тотынып.

Икенче як ярга килеп чыккач, җиргә аяк баскач ул куанычыннан елмаеп җибәрде һәм беренче сүзе итеп:

— Рәхмәт, абый!— диде.

— Рәхмәт булмыйча!— диде ир кеше.

Көймәгә җыеп салган дилбегә очын ул яр өстенә ыргытты. Яр башындагы ир кеше дилбегәне тотып алды. Бауга шундук хатын-кызлар килеп тотынды һәм шаулашып-көлешеп шундук көймәне югары тарта да башладылар.

— Утырыгыз — тартып мендерәбез!— дип кычкырды хатыннарның берсе, яшьрәге, чибәррәге.

— Утырмай торсыннар әле!— диде икенчесе, олырагы.

— Җегете генә утырсын — үземә булыр,— диде хатыннарның яшьрәге.

— Бар, үзең төш — икәүләп агып китәрсез,— диде хатыннарның олырагы.

Көймәне тартып мендергәч һәм көймәчеләр үзләре дә яр өстенә килеп менгәч, әлерәк кенә шаулашкан-көлешкән хатын-кызлар кинәт тынып калдылар. Барысы да кызыксынып Габделхәйгә карады. Арада берсе хәтта Габделхәйне таный булып чыкты.

— Гаптелхәй Мөхеттинеф түгелме соң син, бәбекәем?— диде бу.

Ул алай «ана» булыр дәрәҗәдә карт та түгел иде, киресенчә, шактый яшь һәм чибәр иде.

— Каян беләсең син мине?— диде Габделхәй, чын күңелдән гаҗәпләнеп.

— Бәт-тәч, белмәскә! Шагыйрь Гаптелхәй Мөхеттинефне генә беләбез без,— диде хатын елмаеп, матур ак тешләрен күрсәтеп.

Габделхәйнең йөрәге атылып чыгардай булып тибәргә тотынды. Шатлыктан һәм горурлыктан күз аллары томаланды. Шагыйрь! Аны, имеш, монда да... гап-гади кешеләр дә белә!

— Син үзең кем соң әле?— диде ул хатынга, үзеннән-үзе җырылган авызын йома алмыйча.

— Мин — Җәмиләнең апасы Кифая булырмын, бәбекә-

ем,— диде хатын.— Сине бу якка алып чыккан менә бу «командир»— Җәмиләнең җизнәсе Гали батыр булыр.

— Минем исемем — Талия,— диде барысыннан да яшьрәк, шаянрак хатын, кояштай балкып.— Син — Гаптелхәй, мин — Талия. Икебез дә пар килгәнбез!

Түгәрәк алсу битле, чем-кара кашлы һәм матур сынлы бу яшь хатынга Габделхәй башта ук игътибар иткән иде. Үзе шикелле исеме дә матур икән: Талия... «Былбыл» дигән кебек... Туктале, нинди Җәмилә турында сөйли соң бу Кифая дигәне? «Сеңлем» ди, «җизнәсе» ди...

Алар шулай сөйләнгәләп ферма өенә таба атладылар. Өй янына җиткәч, Талия ярым ачык калдырылган ишектән кереп китте. Бераздан ул сөт үлчи торган литрлы чүмеч белән сөт алып чыкты.

— Әйдәле, эчеп җибәр әле — булдыра алырсың микән?— диде сөтле чүмечне Габделхәйгә биреп.— Моннан соң көтүдән аерылып йөрмәссең. Чөмер-чөмер!

— Эч әйдә, эч — бездә сөт җитәрлек,— диде Җәмиләнең апасы Кифая да.

Габделхәй, үзенә карап торучы хатын-кызлардан бераз гына тартынып, куе сөт тулы чүмечне авызына якын китерде һәм... бер тында диярлек эчеп бетерде дә авыз читен сөртеп куйды, пошкырып куйды, рәхмәт әйтте.

— Укырга Казанга китәсеңдер ич инде?— диде бераздан Кифая, үзенең бөтенесен белгәнлеген сиздереп.— Безнең Җәмилә дә шунда китмәкче була. Медицинскийга.

— Җәмилә?!— диде кинәт Габделхәй, кайсы Җәмилә турында сүз барганын әле яңа аңлап алып.— Җәмилә... безнең Җәмилә! Әйе, Казанга без бергәләп китмәкче булабыз. Документлар гына әзер түгел. Менә шуңа ашыгып кайтам да. Авылда да озак торып булмады.

— Җегетләргә кытлык бездә. Әллә үзебездә генә каласыңмы?— диде Талия, елмаеп.— Икенче алай кибән төбендә куныл йөрмәссең. Өебез иркен. Иркәләп кенә йоклатырбыз

— Казанга барсаң, сәлам әйт — анда минем дуслар җитәрлек,— диде «командир» Гали батыр да, сүзгә катышып.

Ләкин Казанда кемгә сәлам әйтергә кирәклеген шулай да ачык кына итеп әйтмәде. Габделхәй исә төпченеп тормады.

— Җәмиләгә сәлам әйт... күрсәң,— диде Җәмиләнең апасы.

— Әйтермен,— диде Габделхәй.

Сыер таптап бетергән баткак юлдан ул Яңавыл ягына кузгалып китте. Фермадан беркадәр ераклашкач, артына

борылып карады. Өй янында җыелып торган хатын-кызлар аңа нидер кычкырган булдылар, кул болгаган булдылар.

— Рәхмәт! Сау булыгыз, сау булыгыз!— диде Габделхәй, шулай ук кул болгап.

Юл буена ул шат күңелле чибәр Талия турында, Җәмиләнең апасы, җизнәсе һәм фермадагы барлык мәрхәмәтле кешеләр турында уйланып кайтты.

## XII

Яңавылга, үзләренә Габделхәй кичке якта кайтып керде. Ул кайтканда инәсе өйдә иде, бәрәңге пешерелгән, самавыр куелган иде. Өйдәгеләр аны шаулашып каршы алдылар. Кайтып керү белән Габделхәй яхшылап юынды, киемнәрен алыштырды да гадәтенчә өстәл янына килеп утырды. Бер-ике сүз белән авыл хәлләрен сөйләп бирде. Шуннан соң комсызланып ашарга тотынды.

— Улымны туйдырып җибәргәннәр икән,— диде инәсе, аның зур-зур кабып ашавына игътибар итеп.

— Туйдырдылар,— диде Габделхәй.

— Юк, туйдырмаганнар,— диде Фидәил.

— Картый сезгә күкәй пешереп җибәргәние, юлда ашадым. Ачуланмассыз инде,— диде Габделхәй энеләренә, гафу үтенгән сыман.

— Хәердән булсын,— диде Фидәил, олыларча.

— Габделхәй абый — комсомол. Комсомолга хәер алырга ярамый,— диде Илгиз.

— Миңа ярыймы соң?— диде Фидәил.

— Утыр әле сөйләнеп!— диде Шәмсебанат апа, кырыс кына.— Авызыңнан җил алгыры. Хәер сорашасың гына калды.

— Алайса Габделхәй абый картый җибәргән күкәйне кире бирсен,— диде Фидәил.

— Ашадым дидем ич!— диде Габделхәй.

— Нигә безнекен ашадың?— диде Фидәил.— Картый аны безгә дип җибәргән!

— Күчтәнәч кирәк булса, үзең барырсың,— диде Габделхәй.

— Эшли башлагач та, иң беренче күчтәнәчне инәкәй белән сиңа алып кайтып бирермен,— диде Илгиз Фидәилгә.

— Эшкә алдылармы соң әле сине?— диде Габделхәй Илгизгә.

— Алдылар,— диде Илгиз.

— Котлы булсын,— диде абый кеше.

— Синең үзеңнең эшләрең ничегрәк соң?— диде инәсе, утыра торгач.— Паспорт та алмадың бугай.

— Алган булсам, иң элек сезгә күрсәткән булыры-ем,— диде Габделхәй.

— Тимер кызганда сугыла. Дәүләтгәрәй абзаң әйткәч тә барып кайтыргае,— диде инәсе, ничектер пошынган сыман.

— Иртәгә барам,— диде Габделхәй.— Паспорт начальнигы өйдә юк диделәр. Иртәгә булачак.

— Карале, абыйга язу бар бит. Военкоматтан,— диде Илгиз.

— Ә?!— диде Габделхәй, ашавыннан туктап.

— Кичә китереп киткәннәр,— диде Шәмсебанат апа, тыелып кына.— Иртәгә соңга сәгать тугызга килергә кушканнар.

— Армиягә алсалар, Казанга кителми дә калырсың әле,— диде Илгиз, абыйсын кызганып.

— Сугыш вакыты түгел. Ашаталар-эчертәләр, киемсалым бирәләр,— диде Шәмсебанат апа.

— Погон тагарсың, китель киярсең!— диде Фидәил һәм урыныннан торды да, кулларын хәрбиләрчә селтәп, идән әйләнеп килде.

Габделхәй өчен дөнья кинәт туктап калгандай булды. Бөтен өй эчен ниндидер куе караңгылык томалап алгандай булды, күз алдындагы әйберләр күренмәс, тавышлар ишетелмәс булды. Якындагы кешеләрнең сүзләре аңа каяндыр күктәнме, җир астыннанмы килгән сыман тоелды. Бары тик күкрәгендәге тынгысыз кошчык кына каядыр иреккә чыгып китмәкче булган кебек, туктаусыз бәргәләнә башлады. Армия. Кительләр, погоннар. Мылтык-автоматлар... Дөрес, сугыш бетте. Армиядә хәзер кеше үлми. Ләкин үлү генә мени? Армиядә шигырь язарга, филолог булырга өйрәтмиләр. Атарга, кеше үтерергә өйрәтәләр, гәүдәне төз тотып шап-шоп басып йөрергә өйрәтәләр. Шулай итеп, теләге булган кешегә шигырь язарга ярамый булып чыгамыни? Ник?! Әнә фермадагы хатыннар да аны шагыйрь дип беләләр. Бөтенесе аңа карап тора. Аны Казанга китәчәк дип, олы кеше, атаклы кеше булачак дип өмет итеп торалар. Солдатка китеп барса, аннан бит көләчәкләр!

— Сине алмаслар — курыкма!— диде Илгиз, өнсез калган абыйсын юатмакчы булып.

«Ник алмаслар икән мине?»— дип уйлады Габделхәй, ләкин шул фикерне сүзгә әйләндереп әйтергә нишләптер хәленнән килмәде.

— Әйтимме, әйтимме?— диде шул чакны Фидәил, Илгиз абыйсы белән инәсенә карап.

— Утырма инде кыланып,— дигән булды Шәмсебанат апа, кече улына ачуланып.

— Нәрсә... тагын?— диде Габделхәй.

— Син югында Сәкинә килде!— диде тишек авыз Фидәил.

— Сәкинә?!— диде Габделхәй, гаҗәпләнеп.

— Сәкинә белән Җәмилә,— диде инәсе.— Сине сораштылар. Казанга кайчан китә, диделәр, бергә китәриек, диделәр.

«Армиягә алсалар, Сәкинәне... Җәмиләне алдау да була бит әле бу»— дип уйлады Габделхәй, үзалдына.

— Күзгә-башка да күренми, югалды Габделхәй диләр,— диде Илгиз.

— Һы,— диде Габделхәй, картәтәсе кебек.

— Җәмилә әйтте, кереп чыксын әле безгә, диде. Нидер әйтәсе бар бугай,— диде Шәмсебанат апа.

— Сәкинә бернәрсә дә әйтмәде, авызын йомып тик торды,— диде Фидәил.

— Сөйләшәсе сүзләре бардыр — кереп чык, улым,— диде Шәмсебанат апа үтенгән, үгетләгән сыман ягымлы итеп.

Кайчагында Шәмсебант апа, күрәсең, балалар бакчасындагы, гадәтенчә, үз малайлары белән дә кирәгеннән артык ягымлы, йомшак итеп сөйләшә иде. Ләкин үзе белән мондый үгет-нәсихәт рәвешендә сөйләшкәндә Габделхәйнең еш кына ачуы килә торган иде. Хәзер дә инәсенең артык ягымлылыгына ачуы килеп куйды. «Керермен, күрермен менә, көтеп торсыннар!»— диде ул үзалдына, киреләнеп. Ләкин инәсенең кирәкмәгән ягымлылыгы өчен ачулануның Сәкинә белән Җәмиләгә бернинди катнашы булмаска тиешлеген шулай да аңламый булдыра алмады. «Чыннан да, сүзләре бардыр. Күрергә, сөйләшергә кирәк»,— дип уйлады бераздан. Ашап туйгач, корырак, рәтлерәк киемнәрен киенә башлады һәм мыштым гына чыгып та китте.

Урамга чыккач, ул Җәмиләләр ягына барыргамы, Сәкинәләр ягына барыргамы? дигәндәй икеләнеп калды. Бит ул Сәкинә белән очрашуга бармады! Хәзер очрашкач нәрсә диярга аңа? Ашыгыч эш чыкты дип ялганларгамы? Ләкин аны Сәкинә түгел, Җәмилә чакырган.

Теләр-теләмәс кенә ул кузгалып китте. «Апаң сәлам әйтте диярмен... җизнәңне күрдем диярмен»,— дип уйлады Җәмиләләр ягына баруына сәбәп табып. Аның, билгеле, өченче якка да барасы килде. Чынлыкта аның күңеле бары шул өченче якка гына тартты да. Шул ук вакытта Фәрхәнә апалар белән ике арада нindидер каршылык, нindидер киртә дә барлыкка килгән сыман иде. Иң туры, иң җиңел юл шулай да Җәмиләләр ягына илтә иде, ахрысы.

Көтеп кенә торган кебек, Җәмилә өйдә булып чыкты. Габделхәй бернинди икеләнү, уңайсызлану тоймыйча, туп-туры аларның өйләренә барып керде. Кычкырып исәнләште, кычкырып, авыз тутырып Җәмиләне белеште. Аның килүенә Җәмилә дә, башкалар да сөенделәр. Барысы да өстәл тутырып ашап-эчеп утыралар иде. Җәмилә тиз арада өстәл янынннан торып китте, киенде, ясанды да үзен көтеп торган Габделхәй янына килеп җитте.

Урамга чыккач, алар әкрен генә атлап станция ягына китеп бардылар.

— Сәкинәгә дә кереп чыгарбыз. Бергә-бергә күңелле булыр,— диде Җәмилә.

— Ярар,— диде Габделхәй.

Ләкин Сәкинәләргә борыла торган төшкә җиткәч, икесе дә нишләптер аны исләреннән чыгарып җибәрделәр һәм, сүзләренә мавыгып, юлларын дәвам иттеләр. Габделхәй үзенең Янтыкта булуын, кичү янында тоткарланып, печән кибәнендә төн кунуын сөйләде. Аннары бик тәмләп, көлә-көлә ферма турысында Бүә аша чыгуын, Җәмиләнең апасын, җизнәсен күрүен — берсен дә калдырмый сөйләп бирде.

— Мин дә булдым алар янында кичәгенәк. Очрашкан буласыбыз икән,— диде Җәмилә.

— Кызык буласы икән,— дип куйды Габделхәй. Ул үзенең кичәге, бүгенге маҗараларын сөйләп бетергәч тынып калды һәм алар беравык эндәшми бардылар да Җәмилә бик зур хәбәр әйткән сыман:

— Назиф килде,— дип куйды.

— Мәктәпкәме?— диде Габделхәй.

— Юк, безгә... өйгә килгән,— диде Җәмилә, ничектер серле итеп.

«Ә, шулаймыни? Назиф та Казанга медицинскига барырга җыена микәнни?»— дип уйлады Габделхәй, артык исе китмичә.

— Колхоз персидәтеле буласы килмәде микәнни?— диде ул Назиф турында, көлемсерәп.

— Кем аны персидәтел итсен!— диде Җәмилә.— Шахтага китмәкче була.

— Шахтага?— диде Габделхәй, төшенеп җитмәгән сыман.— Ник — шахтага? Кайчан, ничек?

— Авылдан дүрт-биш кеше китә ди. Вербовщик килгән ди. Губаха дигән җиргә. Ишеткәнең юкмыни? Молотов өлкәсендә. Авылдан гел шул якка китәләр. Кием-салым бирәләр ди, паек бирәләр ди, акча төшә ди. Шулай булгач...

— Киңәш сорарга килгәнмени?— диде Габделхәй.

— Киңәш сорарга,— диде Җәмилә.

— Син нәрсә диден соң — «кит» диденме?

— Юк, мин алай димәдем,— диде Җәмилә.— Шахтадан башка эш беткәнмени дөньяда?— дидем. Ул әйтә, шахтага китәсе кешегә паспорт бирәләр ди, армиягә дә алмыйлар икән ди. Армиягә киткәнче, шахтага китеп, бер-ике ел эшлим дә барыбер үзебезнең Эткенәвылга кайтам, ди.

— Персидәтел булу уеннан баш тартмаган алайса?— диде Габделхәй.

— Шулайдыр,— диде Җәмилә, икеле-микеле итеп.

## XIII

Беркадәр вакыт сүзсез баргач, Габделхәй, үзенә кагылмый торган бөтенләй чит нәрсә турында сөйләнгән сыман:

— Мине дә... армиягә алмакчы булалар ди бит әле,— дип куйды.

Моны ул мөмкин кадәр тыныч әйтергә тырышты. Ләкин бу турыда шулай да бик үк тыныч әйтә алмады — сугыш дәһшәте һәм армиягә алыну куркынычы әле булса аның канында саклана иде. Аның тавышы чак-чак кына калтыранып, кысылып чыкты. Мондый хәбәр Җәмиләгә аяз көнне яшен суккан кебек тәэсир итте. Ул хәтта туктап калды, ирексез бер хәрәкәт белән Габделхәйнең беләгеннән тотып алды. Аның кулы кайнар иде.

— Ни сөйлисең? Сине?!— диде ул.— Син бит... Казанга китәсе кеше!

— Шулаен шулай да,— диде Габделхәй.— Военкоматтан повестка килгән. Миңа да Назиф белән бергәләп шахтага китәргә туры килмәсен әле!

Шахтага китү, җир астына төшеп күмер чабу, күмер тузаны эчү турында ул, билгеле, беркайчан хыялланмады. Шуңа күрә кычкырып әйткән үз сүзләре аның үзенә үк ялган һәм ясалма булып тоелды. Көчәнеп кенә ул үзүзеннән көлеп куйган булды.

— Сез шахтага китәрсез дә... өйләнерсез. Без нишләрбез соң, Габделхәй? Без дә бар бит әле дөньяда!— диде Җәмилә әкрен генә, эчке бер әрнү белән.

Беркайчан төшенкелеккә, күңел йомшаклыгына бирелми сыман тоелган Җәмиләнең тавышында каушау һәм шомлану сизелде. Габделхәй аның янында үзен ни өчендер гаепле саный башлады.

— Үз гомеремдә Сарапулдан ары барганым юк. Куркыта. Ничек барырсың Казанга, кемнәргә юлыгырсың... барысын да уйларга туры килә,— диде Җәмилә, үзалдына сөйләнгән шикелле.— Синең белән булсак, ичмасам, бергә-бергә күңеллерәк тә, җиңелрәк тә булырые.

— Шахта турында мин шаярттым,— диде Габделхәй, Җәмиләне тынычландырырга кирәк табып.— Мин инде нык уйладым: шахтага да китмәячәкмен, армиягә дә. Бары Казанга гына, университетка гына!

— Тормышта синең максатың бар, юлың бар, Габделхәй,— диде Җәмилә, җиңел сулап.— Синең тәэсирдә, ахрысы, без дә Сәкинә белән үзебезгә юл ярмакчы булдык. Сәкинә нишләр, белмим. Мин барыбер медик булачакмын. Мин тырышачакмын. Җизнәй әйтте, ярдәм итәрбез, диде. Аңлы, акыллы кеше ул минем җизнәй.

— Шәп кеше ул синең җизнәң!— диде Габделхәй дә.

— Шахтага сине беркем мәҗбүр итә алмас, ләкин армиягә аласы булсалар, ничек котылырсың икән соң син, Габделхәй?— диде Җәмилә.

— Университетка керсәм, армиягә алмаячаклар,— диде Габделхәй.— Керү турындагы кагыйдәдә шулай дип язылган.

— Анысын мин дә беләм,— диде Җәмилә.— Безнең институтныкына да шулай дип язганнар. Ләкин сиңа иртәгә соңга военкоматка барырга кирәк дисең! Әгәр шунда ук алып калсалар?! Уйладыңмы шул турыда?

Мондый сүздән Габделхәй кинәт башына китереп суккандай булды. Чыннан да! Военкоматта күп сөйләшеп тормыйлар. Приказ диләр дә озәләр дә куялар. Бу турыда нишләптер аның әле уйлаганы юк иде.

— Ничек инде?.. Алай булмас... булырга тиеш түгел,— диде ул каушап, аптырап.

— Армия турында минем җизнәй әллә нәрсәләр сөйли,— диде Җәмилә.— Беләсеңме, котеп ятарга ярамый сиңа. Нәрсәдер эшләргә кирәк!

— Бармыйча, качып калыргамы?— диде Габделхәй, көлеп.

— Көлмә!— диде Җәмилә.— Кирәк булса, качып та калырсың. Җизнәйләр янына барып киңәшеп карасак ничек булыр икән?

— «Җизнәй» белән түгел, бәлки, Василий Михайлович белән киңәшеп карарга дыр?— диде Габделхәй, уйланып.— Минем ишеткәнем бар: военкоматтагы капитан Зверев белән безнең Василий Михайлович әшнә икән.

— Василий Михайлович түгел, Антонина Семеновна әшнә капитан Зверев белән, бик беләсең килсә!— диде Җәмилә.— Капитан Зверевнең хатыны — Ленинград марҗасы. Инәләре элек Антонина Семеновналар белән таныш булганнар ди.

— Син каян беләсең аны?— диде Габделхәй, исе китеп.— Җизнәң әйттемени?

— Җизнәй дә әйтте, үзем дә беләм,— диде Җәмилә, серле итеп.

— Кызык, син әллә нәрсәләр беләсең икән,— диде Габделхәй, күрәләтә мактау белдереп.

— Беләм. Син генә мине бернәрсә дә белми дип йөрисең,— диде Җәмилә.

— Алай түгел лә инде,— дигән булды Габделхәй.— Алайса мин Антонина Семеновна янына барам да әйтәм, шундый-шундый эшләр, Антонина Семеновна димен, капитан Зверев сезнең дустыгыз, танышыгыз икән, минем турыда бер-ике сүз әйтмәссезме димен...

— Юк, бара күрмә, Габделхәй!— диде Җәмилә туктап, һәм баягыча кайнар кулы белән юлдашының беләгеннән тотып алды.— Син әле бернәрсә дә белмисең икән, Габделхәй.

— Син беләсеңме?— диде Габделхәй, үчекләшкән сыман.

— Беләм!— диде Җәмилә, беркадәр күтәренкелек белән.— Антонина Семеновна сине яратмый. Ул безнең беребезне дә яратмый. Начар укыган өчен түгел, татар булган өчен, акцент белән сөйләшкән өчен яратмый.

— Син бераз арттырасың кебек,— диде Габделхәй, уйчан гына.— Син үзең аны яратмадың, шуңа күрә ул сине, безне яратмый кебек тоела сиңа. Минем белән ул гел ягымлы сөйләшә. Миңа ул гел яхшылык теләде.

«Син әле Антонина Семеновна белән Василий Михайловичның рус теленнән сочинениене яңабаштан яздырганнарын белмисең. Белсәң, болай сөйләнмәс идең»,— дип әйтәсе килде Габделхәйнең. Әйе, яздырдылар, төзәттерделәр, тик менә медален генә бирмәделәр.

## XIV

Габделхәйнең уйларын сизенгәндәй, Җәмилә кинәт тавышын әкренәйтә төшеп:

— Әйтимме бер нәрсә? Ачуланмассыңмы?— диде.

— Гаҗәп,— диде Габделхәй, каушагандай итеп.— Нәрсә икән ул? Нишләп ачуланыйм мин сиңа — әйт...

— Рус теленнән сочинениеңне күчереп яздыңмы?— диде Җәмилә, сорау алгандагы кебек.

Бу юлы инде Габделхәй туктап калды. Бу көтелмәгән яңалыктан ул кинәт телсез-өнсез калды.

— Син... каян белдең аны?— диде ул, бераздан карлыккан бер тавыш чыгарып.

— Белдем инде,— диде Җәмилә, җиңүче төс белән.— Менә, икенче минем белән уйлап сөйләшерсең. Бернәрсә дә белми икән бу дип хаталана күрмә.

— Мин сине алай дип уйламыйм,— диде Габделхәй. Җәмиләнең сүзләре, үз-үзен тотышы алдында аның мондый акланoccupy гына бик көчсез тоелды.

— Сатмасаң, мин сиңа барысын да сөйләп бирәм,— диде Җәмилә, ашыгып.— Җизнәй әйтә, Габделхәйгә барыбер медаль бирмәсләрие ди. Ни өчен? Татар булган өчен. Аннан соң... синең әтәң бит... ни булган.

— Юк!— диде Габделхәй, кызып китеп.— Ул бер дә «ни» булмаган! Аны аклаганнар! Ул сугышта яраланып кайтты, яңадан китте, шунда ятып калды... батырларча һәлак булды дип язуы килде!..

— Мин анысын да беләм,— диде Җәмилә, тыныч кына.— Мин бит әле бернәрсә дә әйтмәдем. Мин җизнәй әйткәнне генә әйтәм. Җизнәй әйтә, фронтта иң батыры татар булган. Ут эченә иң элек татарны җибәргәннәр... Шулай да «герой»ны да, орден-медальне дә күбрәк башкаларга биргәннәр.

— Сугыштан кайткан солдатлардан минем дә ишеткәнем бар андый сүзләрне,— диде Габделхәй.— Ләкин монда — фронт түгел. Фронтта төрле ялгышлар, хаталар булырга мөмкин.

— Билләһи газим! Беләсең икән!— диде Җәмилә, күрәләтә мыскыл белән.— Анда сугыш бетте. Сугыш хәзер монда бара... Сугышның тукталганы юк. Җизнәй шулай ди. Назиф шахтага китәргә мәҗбүр, сине армиягә алмакчы булалар. Авылларда — ачлык. Яшьләр, ирләр ничек тә читкә китәргә тырыша.

— Анысы миңа кагылмый,— диде Габделхәй.— Син әйтмәдең — сочинение турында каян белдең?

— Шуны да белмәгәч!— диде Җәмилә җиңел генә, күрәләтә өстенлек белән.— Халидә апа Эткенәвылныкы. Назифлар авылыннан. Халидә апаның авызында сүз тормаганлыгын белмисеңмени? Авылларына кайта икән дә монда нәрсә булган — түкми-чәчми сөйләп китә икән.

— Сиңа Назиф әйттеме?— диде Габделхәй, сизенеп.

— Әйтте,— диде Җәмилә.— Шигыреңә булашып син бернәрсә күрмисең дә, ишетмисең дә. Ул турыда бөтен класс белә.

— Алай икән,— диде Габделхәй, күңелсез генә. Аңа оят, хурлык иде. Аның үләсе, каядыр югаласы килде. Ул үзенең кем янына баруын да, кая баруын да сизмәде. Аңа ул ничектер җир белән күк арасыннан шуып барган сыман тоелды. Менә сиңа алтын медаль. Менә сиңа укытучылар. Чыннан да, ул берни белми икән шул. Чыннан да, ул көтүдән аерылып калган бозау кебек икән. Фермада теге телчән Талия шулай дигән иде.

— Туктале,— диде ул бераздан, үзе өчен сер булган нәрсәне яңадан исенә төшереп.— Ничек болай була соң бу? Сочинениене мин хаталы язганмын. Мин әле дә хәтерлим — кызыл кара белән Антонина Семеновна минем хаталарны төзәтеп чыккан. Мин кызыл кара белән төзәткәннәрне яңадан язып бирдем. Чип-чиста итеп. Шулай булгач, сочинениедә бер хата да булмаска тиеш иде бит!

— Синең башта язганыңда бернинди хата булмаган. Алар, юри төзәткән булып, хата ясаганнар!— диде Җәмилә, тантана белән.

— Юк, булмас! Ышанасы килми!— диде Габделхәй.

— Буласы булган инде,— диде Җәмилә.— Кая соң медалең — бирделәрме?

— Бу турыда мин күп уйладым. Василий Михайлович янына барам да барысын сөйлим дә бирәм!— диде Габделхәй, кайнарланып.

— Син мине сатмаска булдың,— диде Җәмилә.

— Ярар, сине сатмам,— диде Габделхәй.

— Мине сатмасаң Халидә апаны, Назифны сатачаксың. Эш зурга китәчәк,— диде Җәмилә.

— Мин беркемне дә сатмаячакмын!— диде Габделхәй, үртәлеп.

— Шулай булгач, аның янына барып торасы да юк,— диде Җәмилә.

Алар станциягә барып җиттеләр. Вокзалда, перронда, халык арасында йөренделәр дә кире кайтыр якка борылдылар. Бу вакытта инде җир өстенә төн куна башлаган иде. Озак кына сүзсез баргач, яңадан Габделхәй үзен борчыган нәрсәгә әйләнеп кайтты.

— Миңа барыбер Василий Михайлович янына барырга, яхшылап сөйләшергә кирәк,— диде ул.— Медальне... онытыйк. Булмаган икән, булмаган. Миңа хәзер военкоматтан котылырга кирәк... шахтага китмәс өчен. Антонина Семеновна булышмаса, Василий Михайлович булышыр. Укытучым ич ул минем!

— Медаль алырга булышмаган кебек, монда да булышмаячак,— диде Җәмилә.— Хәзер аңа безнең кирәгебез дә юк. Аттестатын бирде, чыгарып җибәрде. «Йөз процент өлгереш» булды. Аңа шул җиткән. Синең белән минем өчен кемнәргәдер барып, соранып, вакыт уздырып йөрмәячәк ул. Син бит аның Рамусын кыйнагансың, хур иткәнсең. Оныттыңмыни? Рамус кына түгел, Халидә апа да, Василий Михайлович та бик ачулы сиңа, бик беләсең килсә, иптәшкәем!

— Карале, син чыннан да әллә нәрсәләр беләсең икән!— диде Габделхәй, исе китеп.

Әйе, уңга карасаң да юк, сулга карасаң да юк. Дәүләтгәрәй абзыйлардан, Фәрхәнә апалардан башка чыннан да ярдәм итәрдәй, киңәш итәрдәй беркем юк икән шул.

— Әйтеп бетер — синең әле тагын әллә нинди яңалыкларың бардыр,— диде Габделхәй Җәмиләгә.

— Юк инде, җитеп торыр. Мине сөйләндерерсөйләндерер дә, көлерие бугай,— диде Җәмилә.

— Көлә торган түгел, җылый торган сүзләр бу, Җәмилә,— диде Габделхәй.

— Шулай шул,— диде Җәмилә дә.

Аның әле тагын «җылый» торган бер сүзе бар иде. Әйтәсе килсә дә, монысын ул әйтмәскә булды. Ул аны беркемгә дә әйтмәскә дип Назифка сүз бирде. Назиф аңа: «Миңа кияүгә чыгасыңмы?— диде. Әгәр риза булсаң, икәүләп китәриек шахтага диде. Мин бит медицинскига укырга китмәкче булам, Назиф, диде Җәмилә. Булсаңни! Өч-дүрт ел эшләрбез дә, өс-башны бөтәйтербез дә, акча туплarбыз да, икәүләп китәрбез Казанга — син медицина институтына, мин авыл хуҗалыгы институтына керербез, диде Назиф. Берәр атна уйлыйм әле, диде Җәмилә. Аның ничек тә сузасы һәм Габделхәйнең хәлен беләсе килде. Габделхәй чынлап торып Казанга китсә, аның белән ул теләсә кайчан китәргә әзер иде.

Ләкин әнә аның да хәле шәптән түгел. Җәмилә чыннан да бер атна көтәргә булды. Габделхәй иртәгә соңга военкоматта булгач, алар барыбер очрашачаклар бит!

Үзләренең урам яктагы агач бакчасы янында, капка төбендә аерылышканда, Җәмилә шулай да тыела алмады — күңеле тулып җылап җибәрде һәм онытылып, кайнарланып, шагыйрь дустын кочагына алды.

— Сау бул! Армиядән котылып кал!— диде ул, пышылдап.

## XV

Габделхәй төне буена уйланып чыкты. Күпме генә уйланмасын, берничек тә уеның очына-кырыена чыга алмады. Күзгә күренмәгән кешеләр белән, киләчәк язмыш белән тарткалашып, сугышып, бәргәләнеп ятты-ятты да искәрмәстән йокыга китте. Ул бик каты йоклады һәм иртән инде бөтенләй икенче кеше — сау-сәламәт һәм кайгысызборчусыз кеше булып торды. Бары тик көндәгечә барлыюклы калдык-постык ризыкларны ашаштырып, тамагын туйдыргандай иткәч, теләк тә, уй-фикерләр дә уянды һәм тынгы белмәс яшь җан яңадан талана башлады.

Бүген ул үз гомерендә бик зур эшләр башкарырга тиеш. Бүгенге көнне ул күптән, бик күптән көтте. Олы бәйрәм көткән кебек көтте. Бүген ул паспорт алачак. Бүген ул үзенең чын кеше, совет кешесе икәнлегенраслый торган документ алачак. Паспорты булган кешегә бу дөньяда яшәве мең рәхәт. Паспортлы, документлы кеше кая тели, шунда китә, эшкә керергә телиме, укырга керергә телиме — барысын да булдыра ала. Тик менә шагыйрь булырга теләгән кеше шагыйрь була ала микән, анысын әле ул бик үк белеп җиткерми. Паспортлыга Советлар иленең теләсә кайсы почмагына юл ачык. Шуңа да бит авыл кешесенә паспорт бирмиләр. Алар авылда яшәргә, иген игәргә, мал асрарга тиешләр. Аларга паспорт бирсәң, алар аннан качышып бетәчәк, бөтен ил ач калачак. Тимер юллар эшләмәячәк, заводлар эшләмәячәк. Сугыштан соң җимерелгән авыл-шәһәрләрне торгызып булмаячак. Паспортны аны тиешле кешеләргә генә, башкалардан яхшырак һәм кирәгрәк кешеләргә генә бирәләр. Шахтага китсә, Назифка бирерләр микән? Ул да бит авыл кешесе. Ярый әле ул — Габделхәй — авыл кешесе түгел. Яңавылда тумаса да, ул Яңавыл кешесе. Яңавыл — шәһәр тибындагы эшчеләр поселогы дип атала. Димәк, Габделхәйне шәһәр кешесе дип тә әйтергә була икән. Кызык. Бик кызык. Әллә ничекләр бүлгәләнеп беткән бу кешеләр.

Милиция бүлеге урнашкан йортка җиткәнче, Габделхәй шулай үзалдына масаеп, үзенең шәп кеше булуына куанып килде. Ләкин милиция йортына якынлашкач адымы да әкренәйде, масаюлы, куанычлы уйлары да юкка чыкты. Күңеленә бер дә юктан шик-шөбһә килеп керде һәм йөрәк турысында нидер борып, кымырҗытып үзенең барлыгын сиздерә башлады. Эче дә авырткандай булды. Тар һәм ярым караңгы коридорга килеп кергәч исә ул чын-чынлап курка башлады. Кемнән, нәрсәдән курыкканлыгын ул рәтләп төшенеп тә җитмәде, шулай да менә курыкты. Коридордагы тынлыктан, яктысызлыктан курыкты, бүрәнә стена буена тезеп куелган сынык-санык урындыклардан курыкты, каршыдагы тар, озынча ишектән курыкты. Дөресен әйткәндә, ишектән, урындыклардан да курыкмады — сораган нәрсәсен бирмәсләр, кире борып җибәрерләр дип курыкты.

Дәүләтгәрәй абзый белән сөйләшкәннән соң, ул инде монда булган иде. Ул чакта аңа әйттеләр, фото алып кил, диделәр. Фотосын алып килгәч, кирәкле язуга кул куярга начальниклары өйдә юк булып чыкты. Аны менә бүгенгә шушы вакытта чакырдылар. Юк, чакырмадылар. Шул көнне, шул сәгатькә килергә рөхсәт, диделәр.

Габделхәй таныш коридорга килеп кергәндә монда бер кеше утырып тора иде. Габделхәй аның ирме-хатынмы, яшьме-картмы икәнлегенә бөтенләй игътибар итмәде. Буш урындыкка килеп утырды да көтә башлады. Күпмедер вакыттан соң тар, озын ишек ачылып китте, аннан кызарынган, чәчләре тузгыган бер агай килеп чыкты. Сөйләшеп тормыйча ул үз юлы белән китеп барды. Шуннан соң Габделхәй янындагы кеше дә урыныннан торды, көттереп, кирәгеннән артык тыйнак кыланып, тар ишекне ачты, нидер әйтте һәм, керергә кыюлыгы җитмичә, шул килеш көтеп тора башлады. Эчтәге яшь хатын-кыз ачуланып, түземсезләнеп: «Керегез!» — диде татарча. Теге кеше кереп китте, артына борылып ишеген япты — ябылып бетми калган ишек ярыгыннан Габделхәй аның шулай артына борылуын, ике куллап ишекне ябарга азаплануын күреп утырды. Ләкин үзеннән дә куркаграк бу бәндәнең ирме-хатынмы икәнлеген шулай да аера алмады.

Бу кешенең куркаклыгы Габделхәйгә кыюлык биргәндәй булды. Аннан соң көтеп утырган арада, ул инде тынычлана төшкән иде бугай. «Ник куркам соң әле мин?» — дип уйлады ул, үз-үзен шелтәләп. Дәүләтгәрәй абзый сөйләшкән, фото бирелгән. Кире борып чыгарырга хәзер аның хакы юк. Нәрсә бу, нинди куркаклык бу? Шагыйрь буласы кеше, ун класс белеме булган кеше шундый куркак булырга тиешмени? Гел шулай начальниклар алдында кан калтырап төшә торган булсаң, киләчәктә ничек яшәрсең дә, ничек эшләрсең? Әгәр без барыбыз да теләсә кем алдында куркып кала торган булсак, фашистларны ничек җиңгән булыр идек?! Куркак булса, Александр Матросов атып торган автоматка каршы күкрәге белән каплана алган булыр иде микән? Менә бит ул эшләр кая таба бара, Габделхәй иптәш!

Уртасында зур гына өстәле булган кечерәк бүлмәгә килеп кергәндә ул, чыннан да, үзенең эчке каушавыннан котылган иде инде. Өстәл хуҗасы Вәсимә апа өченче ел унны бетергәч тә, милициядә эшләүче Галләмов абыйга кияүгә чыккан. Шуннан бирле менә шушында паспорт бүлегендә эшли. Вәсимә апаны Габделхәй ишетеп тә, күреп тә белә, хәтта яхшы белә. Вәсимә апа да аны белә булырга тиеш. Тик менә аның монда, бердәнбер тәрәзәсе тимер челтәр белән тотып алынган шушы бүлмәдә үзен элеккечә, кешеләрчә итеп түгел, ничектер коры һәм кырыс итеп тотуы гына гаҗәбрәк иде.

Габделхәйнең «исәнмесез»енә Вәсимә апа җавап та биреп тормады, яза торган язуыннан аерылып башын да калкытып карамады. Габделхәй, Вәсимә апаның эше бе-

түен, үзенә күтәрелеп каравын көтеп, өстәл янында катып тик торды.

Ике колагында да борчак бөртеге кадәр генә алтын алка, түшендә бакыргач сыман ап-ак брошка ялтыраган Вәсимә апа алдындагы калын дәфтәрне бер читкә этәрде дә Габделхәйгә кырын күзе белән генә карап:

— Утыр,— диде.

Габделхәй утырды һәм Вәсимә апаның һәрбер хәрәкәтен, һәрбер тын алуын күңеленнән кичереп, тыйнак кына көтә башлады. Вәсимә апа иелеп янындагы сейфтан язылмаган паспорт алды, калын дәфтәрен яңадан алдына җайлабрак куйды да, каләмен кара тушька манып, башын калкытмыйча гына сораулар бирә башлады: «Исемең, фамилияң ничек?— диде.— Кайсы елда, кайда тугансың?»— диде. Габделхәй ачык итеп әйтеп торды, Вәсимә апа туктамыйча яза барды.

Шулай ук башын калкытып карамыйча гына Вәсимә апа:

— Милләтең?— диде.

Бу сорауга Габделхәй беркайчан да тыныч кына җавап бирә алмады. Бу сорау исем-фамилия сораудан да, туган елыңны сораудан да кирәгрәк һәм әһәмиятлерәк иде. Бу сорау үзеннән-үзе горурлык та, сагаю һәм каушау да тудыра иде. Милләт турындагы сорауда кешенең җаны-рухы турындагы, атасы-бабасы һәм үзе белгән-аңлаган барлык уңай-кире яклары турында тулы мәгълүмат тупланган сыман иде. Бу сорауның монда, Яңавылда аның өчен тагын икенче бер мәгънәсе дә бар иде.

— Татар,— диде ул Вәсимә апаның соравына җавап итеп, ап-ачык итеп.

Вәсимә апа язып куйды, паспортның бүтән графаларын тутырып, эшен бетергәч, Габделхәйгә якынрак килергә, кул куярга кушты һәм паспорт өчен фәлән сум акча сорады. Акчасын алып, анысына да кул куйгач, өряңа катыргыны яшь җегеткә тоттырды.

— Менә, рәхәтен күр,— диде гади генә, авылча гына итеп.

— Рәхмәт!— диде Габделхәй.

«Вәсимә апа» дип өстәмәкче иде, әйтмәде — әллә ошатмас, хәтере калыр дип уйлады. Коридорга чыккач, ул яктыга килде һәм «милләте» графасындагы сүзләрне укый башлады — кабинетта өстәл янында утырганда аңа монда нәрсәдер шикле сыман тоелган иде. Аның шиге дөрес булып чыкты. «Татар» диясе урында аны «башкорт» дип язып куйганнар иде. Каушау, курку катыш сөенеч тойгысы хурлану һәм кимсенү белән алышынды.

Ишекне шакып-нитеп тормыйча, ул яңадан Вәсимә апа янына барып керде.

— Мин бит «татар» дип әйттем, Вәсимә апа!— диде ул ризасызлык белән, шулай да каты бәрелергә кыюлыгы җитмичә.

Вәсимә апа беренче мәртәбә күтәрелеп карады. Күзләрен зур ачып, гаҗәпләнеп карап торды да:

— «Татар» булса ни дә, «башкорт» булса ни, барыбер түгелмени?— диде.

— Барыбер түгел,— диде Габделхәй.

— Башкортстанда һәркем «башкорт» язылырга тиеш,— диде Вәсимә апа, аңлатырга кирәк табып.

— Урыс та, удмурт, мари дамы?— диде Габделхәй, шаккатып.

— Татар турында сүз бара!— диде Вәсимә апа.— Татар болай да күп.

— Төзәтеп языгыз, апа,— диде Габделхәй, бирешергә теләмичә.

Вәсимә апа түшен киерә төште һәм:

— Беләсеңме, энекәем?— диде, ниндидер усалрак сүз әйтергә җыенып.— Шулай да әйтмәде, тыелып калды.— Паспорттагы язу төзәтелми,— диде, тынычрак булырга тырышып.— Рәхмәт әйт тә... әйдә, алдыңнан артың!

Әйе, шулай диде. Габделхәй искәрмәстән тукмалган, мәсхәрә ителгән кебек, кызарынып-бүртенеп чыгып китте.

Хәтер калу һәм күңел тырналуга караганда паспорт шатлыгы шулай да көчлерәк булып чыкты. Бер-ике сәгатьтән инде ул Вәсимә апасы бүлмәсендә булган күңелсез сөйләшүне оныта башлады. Үз-үзенә урын таба алмыйча базарда, станциядә сугылып йөрде-йөрде дә, инәсенең эшләгән җиренә — балалар бакчасына юнәлде. Паспортны иң элек инәсенә күрсәтәсе, сөендерәсе килде. Инәсе чыннан да бик сөенде.

— Менә син дә кеше булдың, улым,— диде буяу исе килеп торган яңа паспортны караштырып. «Татар» урынына «башкорт» язылуына аның әллә ни исе китмәде.— «Башкырт» булуың әйбәт тә булган әле. Читтә урыс арасында кыерсытмаслар, ичмасам,— диде.

Шуннан соң ул каядыр китеп барды, яңадан килде һәм тар гына почмактагы бәләкәй генә өстәлгә җылы аш китереп куйды, аш янына «әлимин» кашык куйды.

— Аша иркенләп — заф ронога китте,— диде.

Габделхәй иркенләп тормады, алдына килгәнне күз ачып йомган арада ялт итеп куйды һәм шунда ук чыгып

китәргә дә җыена башлады. Монда ул биш-ун минуттан артык торырга күнекмәгән иде. Ул китәргә дип кузгалгач кына, өстенә ак халат кигән юан повар үз кулы белән сөтле кофе китереп бирде.

— Эч. Заф өйдә юк,— диде ул да, тынычландырып.

Паспортлы Габделхәй эчте, рәхмәт әйтте һәм чыгарга юнәлде. Инәсе озата чыкты.

— Дәүләтгәрәй абыең белән Фәрхәнә апаңа да күрсәт инде паспортыңны,— диде ул.— Рәхмәт әйтергә оныта күрмә. Алар тырышты. Алар тырышмаса булмасые.

— Әйтермен,— диде Габделхәй.

## XVI

Теге көнне Дәүләтгәрәй абзый белән Фәрхәнә апаның олы кунаклары таң алдыннан гына кайтып киттеләр. Дәүләтгәрәй абзый аларны ярты юл озата барды. Өчәүдән-өчәү генә калгач, олы кунакларның берсе — Нәҗия — шундук эчендәгесен тышка чыгара башлады.

— Бу кадәр җебегән булгач та булырсың икән, туганкаем!— диде Хәнифкә.— Ярый инде кеше алдында түзеп тордым, хәзер әйтәм, әйтмичә йөрәгем түзмәй — менә дигән кызны кулдан ычкындырдың.

Хәниф эндәшмәде, абыйсы эндәшмәде. Аларның эндәшмәвен үзенчә аңлап, Нәҗия аның саен узына бирде.

— Синең кебекләрнең инде укырга йөри торган балалары бар,— диде.— Кайчанга чаклы йөрмәкче буласың буй үстереп? Аның хәзер сына торган чагы, тотарга да сындырырга... Юк инде, ник телекәемне әрәм итеп сүләймендер? Ник шушыннан вакыт әрәм итеп йөримендер? Ул пагуннарыңны ник такканнардыр сиңа, туганкаем, шуңа да ярар җиреӊ булмагач?!

— Нәҗия!— диде иптәш Бикчурин, карлыккан тавыш белән янап.

— Нәрсә «Нәҗия»?— диде хатыны, аннан да усалрак итеп.— Тумыштан бирле мин — Нәҗия. Сүздән тыймакчы буласыңмы? Тыймый тор! Син эчкәнне мин дә эчкән. Мин сиңа ялынып килгән калхуз персидәтеле түгел. Тыймый тор! Булмады бу, туганкаем. Шаулатып бер туй ясарбыз дип хыялланганыем, булмады бу.

— Нәҗия, җитте сиңа!— диде ире, тагын да усалрак итеп.

Җиңгәсенең сүзләре Хәнифнең күңелен телеп-телеп алды, ачуын китерде. Шулай да ул авыз ачып бер сүз

эндәшмәде. Ул үзен көчсез итеп, чыннан да, җебегән һәм булдыксыз итеп тойды. Аның әле беркайчан мондый хәлгә тарыганы юк иде бугай. Шулай да өйгә кайтып башын мендәргә терәү белән, ул шундук йокыга китте. Ул алай күп уйланып, юкка-барга йөрәк бозып яшәргә күнекмәгән иде.

Ул көнне алар көне буена диярлек йокладылар һәм бары кичке бишләрдә генә уяндылар. Юынгач, өстәл янына якынлашкач Исмәгыйль абыйсы белән иң элек баш төзәттеләр. Сөйләшмичә, артык сүз куертмыйча гына ашап-эчеп алдылар да шуннан соң Хәниф төймәләрен ялтыратырга, күнитекләрен ышкырга-чистартырга тотынды. Шулай озаклап төзәнде-кырынды да, чистартынды-ялтыратынды да Фәрхәнә апаларга китеп барды.

Урам очындагы яңа өйгә бу юлы Хәниф бөтенләй үз кеше булып барып керде. Бусагадан атлау белән кычкырып сәлам бирде, хуҗаларның хәл-әхвәлен сорашты, Былбылны күреп алгач, кайгыртучан төстә:

— Сәламәтлегегез ничек?— диде.

— Ярый, рәхмәт,— диде Былбыл һәм тыныч кына шундук күздән югалды.

Ялт итеп торган күнитекләрен шыгырдатып, матур хәрби фуражкасын кул очына тоткан килеш Хәниф кыю гына түргә узды.

— Баш авыртмыймы, Дәүләтгәрәй абый?— диде хуҗага кичәгегә ишарәләп.

— Хикмәт, нишләптер беркайчан минем башым авыртмый, Хәниф,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

Хуҗалар якты йөз күрсәттеләр. Фәрхәнә апа шундук табын әзерләргә тотынды, Дәүләтгәрәй абзый өйдәгеләрнең — ягъни иптәш Бикчурин белән Нәҗиянең хәлен белеште. Юк-бар сөйләнгәләп утырганда, Хәниф күнегелгән гадәт белән чалбар кесесенә тыгылды, портсигар чыгарды, папирос алды һәм портсигарын шартлатып япты да икенче кесәсеннән зажигалка эзләргә тотынды. Аның һәрбер хәрәкәтен күзәтеп торган Дездемона:

— Өйдә тәмәке тартырга ярамый. Чыгып тарт!— диде һәм абый кешенең кулындагы папиросына үрелде.

— Нәрсә, нәрсә?— диде Хәниф, аңламыйча.

— Өйдә тартырга ярамый!— диде Дездемона. Бу вакытта Былбыл, тәрәзә төбендәге гөл савытларын күчергәләп, үзенчә тәртип урнаштырып йөри иде.

— Кара, нинди әдәпсез икән бу Диздекәй!— диде ул, кечкенә кызый өчен уңайсызланып.

Дездемонаның әдәпсезлегенә башкалар да игътибар иттеләр, шундук аны оялтырга тотындылар.

— Чорсызланма, кызым,— диде Дәүләтгәрәй абзый, тыныч кына.

Фәрхәнә апа исә, беркайчан булмаган бер җитезлек белән, тиз арада сөекле кызы янына килеп җитте һәм кулыннан эләктереп алып аны икенче якка алып чыгып китте.

— Кунак кешегә алай дип әйтмиләр, кызым,— диде ул.

— Кунак андый булмый!— диде Дездемона, кирелә-неп.

Хәнифнең бүген күңеле күтәренке иде, мондый вак-төяк нәрсәләрне күрер хәлдә түгел иде.

— Мин бүген Былбылны танцыга приглашать итмәкче булам әле,— диде ул кулындагы папиросын әвәләп.

Барысы да тынып калдылар. Беркемнең дә беренче булып сүз әйтәсе килмәде. Бу, билгеле, бик четерекле мәсьәлә иде. Моны бары Былбыл үзе генә хәл итә ала иде.

— Үзе ни әйтә инде,— диде Фәхәнә апа, елмаеп.

— Яшьләр арасына кысылып булмый,— диде Дәүләт-гәрәй абзый да.

— Белмим шул,— диде Былбыл.

Аның бу «белмим шул»ы «мин риза» дигәнне аң-латты. Фәрхәнә апа моны шундук сизеп алды һәм ашы-гып:

— Барыгыз, бар,— диде.— Болай да гел өйдә ятасың. Тансыларга йөрергә Йосыфның вакыты юк.

— Барыгыз әйдә,— диде Дәүләтгәрәй абзый да, риза-лык белдереп.

— И, чибәрттәй! Әйдә син дә!— диде Былбыл, көтел-мәгән бер куаныч белән.

— Әйдәгез!— дигән булды Хәниф тә. Фәрхәнә апа көлеп кенә куйды.

— Бик соңга калмагыз,— диде ул, шулай да кисә-теп.— Тансысы ошамаса киногa керерсез. Өйдә ята тор-ган чак түгел инде яшь кешегә. Безнең Йосыф кына ул һаман шул китабыннан аерыла алмый.

— Әйдә, Йосыф, син дә!— диде Былбыл китабыннан аерыла алмаган Йосыфка.

Йосыф «яшьләр» ягына күтәрелеп тә карамады, бары авыз эченнән нидер мыгырданып кына куйды. Габделхәй кебек ул да Хәнифне өнәп бетерми иде. Яшьләр исә, өйдәгеләрнең өнәвенә-өнәмәвенә карамастан, тиз арада җыенып, тиз арада чыгып та киттеләр.

Беренче кичне алар озак йөрмәделәр. Сталин клубында кино башланган, танцы булмаячак иде. Башкалар кебек

алар да тимер юл станциясенә таба юл тоттылар, юк-бар сөйләнделәр, икенче көнне иртәрәк килергә, килгәндә кинога билет алып килергә сүз биреп, яшь лейтенант Былбылны өйләренә кадәр озатып куйды.

## XVII

Габделхәйнең күңеле гел Фәрхәнә апаларга тартып торса да, шулай да анда бару өчен аны нидер тоткарлап та тора иде шикелле. Габделхәй бу «нидер»нең нәрсә икәнлеген дә белде сыман. Шуңа күрә анда бару өчен, һичшиксез, менә шул «нидер»не атлап чыгарга кирәк иде кебек. Паспорт алу аңа, әйтерсең, юл ачкычы бирде. Паспорт белән хәзер иркенләп Казанга китәргә, университетка керергә генә түгел, хәтта яңадан Фәрхәнә апаларга да барып керергә була иде. Шулай да, паспорт никадәр кыюлык һәм иркенлек вәгъдә итмәсен, Габделхәйнең күңелендә ямьсез бер тойгы торып калды. Ленин урамына килеп кергәч, әлеге ямьсез тойгы көчәя төште һәм аны инде паспорт шатлыгы да, ясалма горурлык та — берни дә җиңә алмас төсле иде.

Менә ул ерактан ук нурлар балкытып утырган таныш өйнең таныш капкасы янына килеп җитте, капканы ачып ишегалдына керде һәм никтер карыша башлаган аякларын авырлык белән генә атлап баскычка якынайды. Нәкъ шул чакта ул алар белән очрашты.

Өстенә ачык төстәге җиңел, сихри күлмәк кигән, чәченә зур итеп, күбәләк канаты сыман итеп ак тасма бәйләп куйган Былбыл, бик зур куанычы бар кеше сыман, коштай очынып баскычтан төшеп килә иде. Аннан беркадәр калышып, погоннарын, китель төймәләрен, күкрәгендәге гвардия значогын елтыратып озын буйлы чибәр лейтенант килә иде. Югарыда, баскыч өстендә тагын кемнәрдер бар иде — болары Дәүләтгәрәй абзый белән Фәрхәнә апа булды, ахрысы. Алар яшьләрне озата чыкканнар иде бугай.

Гөнаһ шомлыгына каршы, Былбыл белән алар тар баскычта очраштылар, бер-берсенә орынып алдылар. Былбыл, үзе дә сизмәстән, «а!» дип кычкырып җибәрде, учы белән авызын каплады да йөгереп тышка чыгып китте. Габделхәй юл биреп, читкә тайпылып калды. Үзе янынннан җиңүче төс белән узып киткән лейтенантны әллә күрде, әллә күрмәде — күз алдын томан каплады, аяк астындагы бар нәрсә тирбәлә, чайкала башлагандай булды.

Берзаман ул кайдадыр еракта, ниндидер калын кой-

ма артында кемнеңдер «Габделхәй» дигән тавышын ишеткәндәй булды. Бик авырлык белән генә башын калкытты. Аның каршысында гына бер-ике басма өстәрәк Фәрхәнә апа басып тора иде, ул аңа нидер сөйли, нидер аңлата сыман иде. Габделхәйнең күңелен: «Аның белән очрашканны ул күреп торган!» — дигән бер уй өтеп алды. Фәрхәнә апа алдында ул үзен нидер урлап тотылган сыман хис итте. Аның моннан тизрәк качасы, ереккә, иркенгә чыгып китәсе килде. Хәер, аны инде күрделәр. Аның турыда өйдәгеләр дә, тегеләр дә барысын белделәр. Хәзер инде качсаң да, качмасаң да барыбер түгелмени?!

Фәрхәнә апаның ягымлы итеп эндәшүенә буйсынып ул култыксага тотынды һәм әкрен генә атлап югары менде. Фәрхәнә апа һаман нидер сөйләнде, нидер аңлатты, ләкин Габделхәй әле булса берни аңлый алмады.

Өй эчендә беренче булып Дәүләтгәрәй абзый очрады.

— Әйдә, түрдән уз, Габделхәй,— диде ул, сузып. Кулларын җәеп, ямьсез чырылдап Дездемона килеп җитте, чандыр беләкләре белән аны кочып алды.

— Югалган мал, кайда йөрисең?— диде ул, шырыкшырык көлеп.

Фермада «бозау» дип атадылар, монда «югалган мал» дип уйлады Габделхәй үзе турында.

— Югалган мал шул,— дигән булды, Дездемона белән бергәләп көләргә тырышып.

— Фидәил өйдәме, ыштаны чөйдәме?— диде телмәт Дездемона, туктаусыз тәтелдәп.

Габделхәй ирексездән елмаеп җибәрде. Башкалар да тыелып кына көлемсерәп алдылар, ләкин шул ук вакытта әдәпсез кызыйны оялтырга да тырыштылар.

— Кит, бәйләнмә Габделхәй абыеңа!— диде Фәрхәнә апа.

— Чорсызланма, кызым,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Мин «кызым» түгел, мин — Дизде-муна!— диде кызый, кыланып.

Тәрәзәгә, яктыга якын җирдә, өстәлнең бер башында Йосыф китап укып утыра иде. Тавыш-тынсыз гына Габделхәй Йосыф янына килде, шундагы бер урындыкка утырды.

— Син укыйсың да укыйсың икән,— диде ул.

— Син укымыйсыңмы?— диде Йосыф.

— Юк,— диде Габделхәй.

— Безнең Габделхәйнең хәтере яхшы аның,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

Габделхәй аның шулай салпы якка салам кыстыруын яхшы аңлады, шулай да мактау сүзеннән җиңелрәк булып китте кебек.

— Синең әле онытылып та бетмәгәндер, Габделхәй,— диде Фәрханә апа, җайлап кына сүзгә кушылып.

— Онытылырлык вакыт та үтмәде бит әле, Фәрханә апа,— диде Габделхәй.

Өстәлдә самавыр чыжлап утыра иде, савыт-саба җыештырылмаган иде. Әллә соң хуҗалар ашарга да утырмаганнар иде микән? Фәрханә апа, ягымлы елмаеп, Габделхәйгә якынрак килергә кушты.

— Әйдәле, Габделхәй, утыр әле,— диде.

Габделхәйнең ашарга утырасы килмәде. Ул үзенең килгән саен монда ашка-суга юлыгуын исенә төшерде. Бүгенгесе өчен генә түгел, элеккеләре өчен дә оят, бик нык оят булды. «Юри ашаган чакта гына килеп керә дип уйлыйлардыр әле!»— диде ул, күңеленнән үз-үзен шелтәләп. Хәзер ул монда беркемгә, бернигә карата якынлык һәм күңел җылысы тоймады. Тиз арада аның моннан чыгып китәсе килде, чыгып китте исә, беркайчан бу өйгә килү түгел, хәтта әйләнеп тә карамас иде шикелле тоелды. Монда ул һәркайда, һәрнәрсәдә үзенә хыянәт иткән җилбәзәк кызны күргәндәй булды. Ул да... кыз да аны күрәдер сыман, никтер аннан көләдер сыман тоелды. Юк, ул үзе генә түгел, җиз төймәле лейтенант белән бергәләп көләләрдер сыман тоелды. Дәүләтгәрәй абзый белән Фәрханә апаның, шундый акыллы кешеләр була торып, күптәнге дуслар-танышлар була торып, ниндидер Уфа кызыннан аны мыскыл иттерүләре инде берничек тә аңлашылмый иде.

— Мин паспорт алдым, Дәүләтгәрәй абзый... Фәрханә апа, — диде ул, сүзгә башлап.— Бик зур рәхмәт инде сезгә. Сез булмасагыз, мин аны гомеремдә дә алалмаган булырыем. Инәкәй дә шулай диде. Рәхмәт әйт, диде.

Бөтенләй кирәкмәгәндә «инәкәй»не искә төшерүе өчен аңа оят булып китте. Әйтерсең, рәхмәтне ул инәкәсеннән башка әйтә белми! «Шагыйрь, имеш! Җебегән! Рәтләп кешечә сөйләшә дә белмисең!»— диде ул, күңеленнән үз-үзен мыскыл итеп.

— Яхшы булган, Габделхәй,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

— Менә син дә кеше булдың,— дип куйды Фәрханә апа.

— Инәкәй дә шул ук сүзләрне әйтте,— диде Габделхәй.

Аңа тагын оят булды. «Үзеңнең фикерең дә юкмыни? Инәкәң сүзләрен генә кабатлыйсыңмыни хәзер?»— диде ул үз-үзенә.

— Дөньяда иң кирәге — паспорт,— диде Дәүләтгәрәй абзый.

Дәүләтгәрәй абзый шулай ук: «Иң кирәге — акча»,— дияргә дә ярата иде. Аның мондый сүзләрен Габделхәй инде берничә мәртәбә ишеткән иде. «Кайсысы кирәгрәк соң — акчамы, паспортмы, Дәүләтгәрәй абзый?»— дип әйтәсе килде аның кисәк кенә. Ләкин күңеленә килгән уен сүзгә әйләндерә алмады — олы кеше, хуҗа кеше белән бәхәсләшү, аның йөзен җырту оят эш, хурлыклы эш булып тоелды. «Ярар, саубуллашам да чыгып китәм»,— дип уйлады ул, урыныннан кузгалып.

— Ярый, мин китим инде,— диде.

— Утырмадың, Габделхәй,— диде Фәрхәнә апа.

— Утырдым. Рәхмәт,— диде Габделхәй.

Шулай диде дә кинәт кызарынып куйды. Аңа хәзер үзенең сүзләре, сөйләшү рәвеше ошамый башлады. «Шуны аңлатып торалармыни?!»— дип уйлады ул, янә үз-үзен түбәнсетеп.

— Башка документларың әзерме соң, Габделхәй? Кайчан китәргә җыенасың?— диде Дәүләтгәрәй абзый.

«Документлар» турында сүз чыккач, Габделхәй тагын үзе дә сизмәстән йомшаклык күрсәтте.

— Военкоматтан повестка килгән бит әле миңа, Дәүләтгәрәй абзый... Фәрхәнә апа,— диде.

Бу турыда монда берни әйтмәскә дип ул инде күңеленә беркетеп куйган иде. Повестка турында әйтсә, бу, һичшиксез, Дәүләтгәрәй абзыйдан ярдәм үтенү һәм шул рәвешчә яңадан ялыну, түбәнсенү булыр сыман иде. Үзенең чын кеше, паспортлы кеше икәнлеген, үз язмышын үзе хәл итә ала торган, теләсә нинди хыянәтчеләрдән, коры куык калай әтәчләрдән өстен кеше икәнлеген исбат итү өчен, әлбәттә, горур һәм бәйсез булып калырга кирәк иде. Менә алай була алмады. «Җебегән! Булдыксыз!»— диде ул, үз-үзенә үртәлеп.

— Шулаймыни?— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Кайчан барырга? Укырга алмакчы булалар микән әллә?

— Ленинградка, военно-морской училищега алалар икән,— диде Йосыф, китабынан башын калкытып.

«Кара! Нинди белемле!»— дип уйлады Габделхәй яратмыйча.

— Каян ишеттең соң әле син аны?— диде Дәүләтгәрәй абзый Йосыфка.

— Рамус әйтте, аңа әтисе әйткән,— диде Йосыф.

«Кабахәт! Һаман шуның белән дуслашып йөргән була!»— дип уйлады Габделхәй Йосыф турында.

— Безнең ышкулдан да бер малай шунда китмәкче була,— диде Йосыф, китабыннан күзен алмыйча гына.

— Безнең Назиф та шахтага китә икән әле,— диде Габделхәй, бөтенесен шаккатырмакчы булып.

Чыннан да, Назифның шахтага китүе Йосыфның хәбәреннән тәэсирлерәк булып чыкты. Дәүләтгәрәй абзый такыр башын кашып куйды, Фәрхәнә апа өстәл янында нидер эшләвеннән туктап калды һәм тагын нәрсә әйтер икән бу? дигән сыман көтеп тора башлады.

— Япь-яшь көе... нинди шахта инде ул балакайларга?!— диде Фәрхәнә апа, Назифны кызганып.

«Назифны кызгана, мине кызганмый»,— дип уйлады Габделхәй Фәрхәнә апа турында.

— Мин дә китәрием әле Ленинградка,— диде Йосыф.

— Бар, минем өчен кит алайса,— диде Габделхәй.

Үзенчә ул моны усал итеп әйтәм дип уйлады, ләкин тавышы бер дә усал булып чыкмады. Йосыф аны әллә ишетте, әллә ишетмәде — күрмәгәндәй һаман шул үзенең «Физика»сына төртелеп утырды.

— Урман кисәргә бару түгел инде ул, Габделхәй,— диде Дәүләтгәрәй абзый, Йосыф өчен җавап биреп.

— Авиационный институтка китәргә җыенучыларның берсен дә алмаячаклар, алар болай да военный булачаклар дип әйткәннәр...— диде Йосыф.

«Мактана. Янәсе ул авиационныйга әзерләнә. Ул гына шәп кеше»,— дип уйлады Габделхәй.

— Алай икән,— диде Дәүләтгәрәй абзый.— Син, Габделхәй, бер дә кайгырма. Җайларбыз. Военкомат әллә кайда түгел — үзебездә генә, Яңавылда.

«Рәхмәт инде!— дип уйлады Габделхәй, кireләнәсе килеп.— Син гел җайларга күнеккәнсең, Дәүләтгәрәй абзый. Анда җайла, монда җайла. Болай да хәерче кебек күп теләндем сезгә. Моннан соң үзем сөйләшәчәкмен. Аяк терәп. Мин дә... кеше!»

Күңеленнән ул шулайрак дип уйлады, ләкин өйдәгеләр белән саубуллашканда шулай да тавышы зәгыйфь һәм мескен булып ишетелде.

— Сау булыгыз,— диде ул, ишеккә юнәлеп.

— Сау бул, Габделхәй,— диделәр аңа.

Фәрхәнә апа хәтта баскыч төбенә кадәр озата чыкты. Габделхәй, артына борылып карамыйча, алпан-тилпән атлап китте. Ябылып җитмәгән яңа капка, аптырап, моңаеп артыннан карап калды.

## XVIII

Көтмәгәндә Габделхәй белән очрашкач, Былбылның күңел күтәренкелеге кул белән алгандай юкка чыкты. Хәнифкә ул әз генә дә каршы да килмәде, юкка-барга киреләнмәде дә, шул ук вакытта аның белән ачылып, рәтләп сөйләшә дә алмады. Башын иеп, уйланып, күңелсез бер кыяфәттә янәшәдән атлап тик барды. Тиз арада җиңүгә ирештем дип хаталанган һәм шунлыктан башыкүзе әйләнә башлаган яшь лейтенант андагы бу үзгәрешкә бөтенләй игътибар итмәде. Ул моны кызларга хас бер оялчанлык кына дип белде. Юл буена Хәниф, кызның күңелен табам дип уйлап, башыннан кичкән кызык хәлләр турында сөйләде.

Икәүләп алар Сталин клубына бардылар, танцыга керделәр, бер сәгать чамасы әйләнгәләделәр дә яңадан урамга чыктылар һәм әлеге дә баягы станция ягына юнәлделәр. Хәнифнең төне буе йөрисе, урам таптыйсы һәм сөйлисе, мактанасы килде. Былбыл ярты юлдан ук кайту ягына каера башлады. Бары шул чагында гына Хәниф кызның бүген ул үзе уйлаганча ук ягымлы һәм якын түгеллеген чамалап алды. Бу, билгеле, аның кытыгына тиде. Алар кинәт сөйләшмәс-эндәшмәс булдылар.

Еракта чибәрттәләренең таныш йортлары күренгәч, Былбыл кызулый төште.

— Әллә янамы?— диде Хәниф.

— Әлегә янмый бугай,— диде Былбыл.

— Шулай булгач?— диде Хәниф.

— Арттан куа киләләр түгелме соң?— диде Былбыл, күрәләтә мыскыл белән.

— Сез һаман көләсез,— диде Хәниф.

— Озатып куюыгыз өчен рәхмәт. Мин кайтып җиттем,— диде Былбыл, туктап калып.

— Кайтып җитәргә әле тагын йөз дә илле бер адым калды!— диде Хәниф.

— Илле бер адым гына,— диде Былбыл.

— Юк, йөз дә илле бер адым!— диде Хәниф.

— Хушыгыз. Рәхмәт,— диде Былбыл, урыныннан кузгалып.

— Болай булгач, мин сезне тоткарларга мәҗбүрмен,— диде Хәниф, кызның беләгеннән тотып.

— Алайса, болай килешик: бер метр гына барыгыз да калган иллесен үзем генә кайтырмын,— диде Былбыл, артык каршылык күрсәтмичә.

Алар тагын кузгалып киттеләр һәм шулай килде-китте сөйләнеп таныш капка янына килеп җиттеләр.

— Соңгы кат сезгә рәхмәт. Мин кайтып җиттем,— диде Былбыл, капка тоткасына үрелеп.

— Мин сезне кертмим,— диде Хәниф, кызның юлына аркылы төшеп.

— Алайса мин кычкырам — өйдәгеләр чыгып алырлар,— диде Былбыл.

— Торыйк әле,— диде Хәниф үтенеп, хәтта ялварып.— Әллә ничек кенә булды. Сөйләшәсе сүз дә бар иде. Сөйләшеп тә булмады.

Ул тагын аның кулыннан тотып алды һәм каушаган-кабаланган хәлдә аны үзенә таба якынайта барды.

— Тотынмагыз миңа!— диде кыз, читкә тартылып.

— Ягез инде? Ул кадәр усал булмагыз инде?..— диде Хәниф, серле пышылдап.

— Юк, юк!— диде кыз.

Аның тәне уттай яна, калтырый башлады. Ул үзенең серле тавыштан йомшый башлавын тойды. Аның ачуы килде, ләкин үзен мәҗбүр иткән, ихтыярын биләп алган көчкә, вәсвәсәгә каршы торырга нишләптер кыюлыгы җитмәде. Яшь лейтенант аны якынрак китерде, искәрмәстән кочып алды, үбеп алды.

Кызның кинәт башы әйләнде, аяк астындагы каты җир чайкалып китте. Күпмедер вакыттан соң ул, ниһаять, җирне тойды, исенә-акылына килде. Якында гына ул ниндидер чит кеше барлыгын күрде, аның каты, тупас кулын, калай төймәле киемен тойды. «Ни хакы бар аның?!»— дип уйлады ул, нәфрәтләнеп. Ташып чыккан ачуына ирек биреп, каты кулны, каты киемне төртеп җибәрде. Хәниф чак-чак кына читкә авышты, аптырап китте. Авызын ачып ни дә булса әйтеп өлгергәнче, янындагы кыз юкка да чыкты.

Урам капкасы кебек үк чолан ишеге дә эчтән бикләнмичә калдырылган иде. Былбыл атылып ишектән керде, келәне эчке яктан бикләп куйды һәм, еш-еш тын алган хәлдә, бераз вакыт тыңлап торды — тышта бернинди тавыш ишетелмәде. Былбылның урыны чолан якка җәеп куелган иде. Өйдәгеләрне уятмаска тырышып ул мыштым гына үз урынына кереп ятты.

Берзаман, яңа көн тууын белдереп, әкрен генә таң ата башлады. Ишегалдында чүмәләдәй булып, тир исе, сөт һәм сыгрыйк исе аңкытып яткан олы сыер, таң атуын, һава алышынуын сизеп, уфылдап, пошкырып куйды. Лапас эчендәге әтәч, йокымсырыган тынлыкны бозып, шаулатып кычкырып җибәрде. Аңа җавап итеп, әле бер якта, әле икенче якта бүтән әтәчләр кычкырды. Тимер юл станциясе ягындагы паровоз тавышлары тонығрак,

көчсезрәк булып ишетелгәндәй булды. Көтмәгәндә авыр-авыр басып, такталарны шыгырдатып Дәүләтгәрәй абзыйның тышкы якка чыгып баруы ишетелде. Аннан соң күп тә үтмәде, Фәрхәнә апа да торып тышка чыкты. Буш бидерәгә чыжлатып якында гына сыер сауган тавыш ишетелде.

— Капка бүген ябылмый калган икән,— диде җизнәй, йокылы тавыш белән.

Шуннан соң берни ишетелми башлады. Былбыл, тынычланып, көтелгән йокыга чумды.

Йокыдан ул бик соң торды. Җизнәй инде күптән эшкә киткән, Йосыф шулай ук каядыр китеп барган. Өйдә бары чибәрттәй генә калган да аннан Дездемона әле булса йокы симертә иде бугай. Ашаганда да, аштан соң да Былбыл рәтләп сөйләшмәде. Ул сөйләшмәгәч Фәрхәнә апа да төпченмәде.

Ашап туйгач, кунак кызы ашыгып автовокзалга китте. Ләкин ул инде соңга калган булып чыкты. Уфага дигән автобус китеп барган, икенчесе бары кичке якта гына булачак иде. Былбылның кәефе кырылды. Аның хәзер үзе генә Яңавыл урамнарында йөрисе килмәде. Буш урамнардан китеп барды исә, кирәкмәгән кемнәрдер очрар, ямьле көннең ямен җибәрер шикелле тоелды. «Кичке автобуска билет алганчы шушында торам»,— дип уйлады ул һәм өченчеме-дүртенчеме кеше булып чиратка басты.

Шулай бер ярты сәгать чамасы басып торгач, көтмәгәндә автовокзал янынарак көл төстәге өр-яңа «Победа» килеп туктады. Өлкән яшьләрдәге шофер, ишекне яртылаш ачып:

— Кем Уфага?— диде.

Башкаларга караганда Былбыл машинага якынрак тора иде.

— Мин — Уфага! Мин!— диде ул, ашыгып һәм тиз арада шофер янына килеп тә җитте. Касса янындагы башка кешеләр урыннарынан кузгалмадылар. Кабинада, арткы урында, юан гына, олырак кына бер хатын-кыз утыра иде. Шофер Уфага кадәр күпме түләргә кирәк булачагын әйтте. Былбыл берсүзсез риза булды.

— Әйберләрең кая? Әйберләрең бармы?— диде шофер, үзара килешенгәч.

Былбыл үзенең кайсы урамда, ничәнче йортта торуын әйтте. Шофер, киңәш сораган сыман, арттагы хатынга борылып карады. Хатын үзенең ризалыгын белдерде.

— Әйдә, утыр менә бу яктан,— диде шофер. Былбыл,

урталай бөгелә төшеп, кабинага, йомшак урынга кереп утырды. Машина кузгалып китү белән ул үзен иркендә, Яңавылдан читтә һәм еракта итеп тойды. Аңа бераз гына моңсу-ямансу булып китте. Кабина тәрәзәсе аша күренгән йортларга, кешеләргә ул хәзер бөтенләй икенче күз белән, икенче уй-теләкләр белән карады. Аңа хәзер шулай кисәк кенә бөтенесеннән аерылып, киселеп китү, шушы таныш урамнарны, йортларны, күк йөзен һәм шушы яктылыкны ташлап китү бик авыр, бик кыен булып тоелды. Шул ук вакытта аның бу урамнардан, бу йортлар арасыннан тизрәк чыгып китәсе һәм тирә-ягында бары тик иген басулары, урманнар, болыннар гына булган киңлеккә, иркенлеккә барып җитәсе килде.

Военкомат турысына якынлашканда, юл читеннән башын иеп барган Габделхәйне күргәч, ул сискәнеп китте. Габделхәй военкомат ягыннан базар ягына таба китеп бара иде. Аның йөзе боек һәм кайгылы сыман тоелды. Югалган бик кадерле нәрсәне искә төшергән чактагы сыман, яшь кызның күңелен сагыш һәм әрнү тойгысы телеп алды.

«Победа» кинәт туктап калды. Алар Фәрхәнә апаларның капка төбенә килеп җиткәннәр иде. Былбыл ашыгып кабинасыннан чыкты, капкадан керде һәм йөгереп диярлек ишегалдыннан үтте дә атылып өйгә барып керде. Аның сулуы капты, аяк-куллары хәлсезләнде.

Куркып шундук аның каршысына Фәрхәнә апа килеп җитте. Ул, ахрысы, аның «Победа» белән кайтып керүен тәрәзәдән күреп торган иде.

— Ни булды?— диде ул.

— Мин кайтып китәм, чибәрттәй!— диде Былбыл, кабаланып һәм тыела алмыйча җыларга тотынды.

— Райком машинасы бит ул! Иптәш Сафинныкы,— диде Фәрхәнә апа коты алынып, әйтерсең, Былбылның кайтып китүенә шул машина гына гаепле иде.

— Кайтып китәм. Уфага, чибәрттәй,— диде Былбыл, тыңламыйча һәм ашык-пошык кием-салымнарын җыештыра башлады.

— Нинди эш соң әле бу?— диде Фәрхәнә апа, нишләргә дә белмичә.— Ничек утыртасы иттеләр?

— Ачуланма инде, чибәрттәй. Шулай туры килде,— диде Былбыл яшь аралаш.

Фәрхәнә апа, онлы куларын алъяпкыч итәгенә сөрткәләп, әле кече якка чыкты, әле олы якка чыкты, тәрәзә янына килде.

— Галия апа, Сафинның хатыны,— диде ул, үзалдына сөйләнгән сыман.— Кием кистерергә дә, чәч төзәтергә

дә Уфага йөри икән дип сөйлиләрие — дөрес икән. Нишләп болай булды соң әле бу?

Былбыл, анысын анда орып, монысын монда орып, үз әйберләрен эзләп тапты, чемоданын тутырды, җылады, яшь аралаш көлеп чибәрттәсен юатты. Шул ук вакытта башын иеп барган Габделхәйне дә уйлады. Бүә буендагы кояшлы көнне, кичүне, хуш исле болыннарны, су керүләрне уйлады. Чемодан капкачын бик нык басып, беравык аны ябарга азапланып карады, ләкин капкач нишләптер ябылмады. Капкачны ачып караса, нәрсәнеңдер тышкы якка чыгып, кысылып калганлыгын күрде. Капкачны яңадан япты да, чертләтеп бикләде дә, көчкә күтәреп-өстерәп ишеккә таба атлады. Нәкъ шул чакта шофер килеп керде.

— Буламы, кызым?— диде.

Чемоданны җиңел генә күтәреп шофер кире борылды. Шофер белән Былбыл аллы-артлы баскычтан төшеп барганда аларны Фәрхәнә апа куып җитте, Былбылның кулына зур гына төенчек тоттырды.

— Әллә ничек кенә булды бит әле бу,— диде һаман тынычлана алмыйча.

— Ачуланма инде, чибәрттәй,— диде Былбыл, сулкылдап.— Кайткач та хат язармын.

— Сәлам әйт инде... күп итеп... барысына да,— диде Фәрхәнә апа.

Капкадан чykканда аның күңеленә бер уй килде.

— Сорасалар, нәрсә әйтерсең соң?— диде ул.— Берәр сүз әйтимме синнән?

— Юк, юк, берни әйтмә!— диде Былбыл.

— Габделхәйгә? Йосыфка?— дигән булды Фәрхәнә апа.

— Аларга да... әйт... мә...— диде Былбыл, буталып.— Сау бул, чибәрттәй. Хуш, сау бул, хат язармын.

Шофер чемоданны артка, багажникка куйды, багажник капкачын япты да, бикләде дә үз урынына кереп утырды. Былбыл алга, шофер янына утырды. Тәрәзәдән капка төбендәге Фәрхәнә апага кул болгады, кош теледәй кулъяулыгы белән күзен сөртеп алды.

Тын урамда янган бензин исе калдырып, көлсу төстәге машина җиңел генә кузгалып китте һәм озакламый күздән югалды.

## XIX

Военкоматтан, капитан Зверев яныннан чыккач, балтасы суга төшкән сыман башын иеп кайтып килгәндә Габделхәй үз яныннан выжт! иттереп узып киткән «По-

беда»га игътибар итмичә булдыра алмады. «Победа»лар Яңавылда күп түгел, көл төстәгесе, яңасы бары бер генә кешедә — район патшасы иптәш Сафинда гына.

Ихтыярсыздан Габделхәй машинага карады һәм андагы кешеләрне күреп алды. Моннан берничә көн элек кенә өзелеп, сагышланып уйлаган, үләрдәй булып күрәсе килгән теге кызны күреп алды. Ләкин үзе теләгәнчә, үзе өмет иткәнчә ягымлы, аңлаешлы һәм дус кызны түгел, бәлки чит һәм дошман, хыянәтче кызны күрде. Кичәгенәк теге лейтенант белән бергәләп баскычтан төшеп килгәндә, ул әле башка кызлар кебек җилбәзәк кенә сыман тоелган иде. Аны әле күпмедер дәрәҗә аңлап та, аңа карата нәфрәтләнеп тә була иде кебек. Бүген, хәзер өр-яңа «Победа»да утырып барган кызны инде аңлап та булмый, аңа шулай ук ачуланып, нәфрәтләнеп тә булмый сыман иде. «Победа»га теләсә кем утыра алмый. «Победа»га бары шәп кешеләр — ике аяклы, ике куллы кешеләргә охшамаган, махсус рәвештә сайлап алынган, сайлап куелган һәм кара халык өстеннән хакимлек итәр өчен яратылган аксөякләр генә утыра. Алар шулай узучы-баручыларга йөзләрен дә ныклап күрсәтмичә, тузан туздырып, выжт! иттереп узып кына китәләр. Машинадан төшкәч алар аерым кабинетларда утыралар, боералар, кушалар, өйрәтәләр һәм, әлбәттә, һәркөнне туйганчы ипи ашыйлар, итле аш ашыйлар, кайнар бәрәңге белән салкын катык ашыйлар, ямаусыз яхшы ботинкалар, күн итекләр, шәп кительләр, затлы күлмәкләр кияләр. Алар таза, чибәр һәм итләч булалар. Андыйлар белән кешечә сөйләшеп-аңлашып та, дуслашып-ратышып та булмый. Кая ул! Аларга хәтта ялгыш кына кагылып китсәң дә, алар сине чәйнәп бөркәргә әзер. Алар шулай икән, син дә шулай.

«Мескен, мескен!..» — дип уйлады ул бераздан, үзүзен битәрләп. Синамы соң алар белән булашу, андыйлар турында хыяллану?! Оныт син аны... аларны...

Ул онытты. Юк, онытып ук бетерә алмады. Тик шулай да барлык хис-тойгысын, аңын-ихтыярын богаулаган сихри, тылсымлы көч күз алдында юкка чыккандай булды һәм ике арада, биек киртә булып, читләшү һәм дошманлык барлыкка килде. Үзеннән, үзе кебек үк барлык өлешсезләрдән, ач-ялангачлардан өстәрәк, югарыдарак торган һәммә тукларны, байларны, боеручыларны ул җен кебек күрде. Андыйларга карата аның күңелендә һәрвакыт кискен каршылык һәм кыргый бер кирелек тойгысы яшәде. Аларны ул гафу да итә алмады, алар белән килешүгә дә керә алмады.

Менә әле дә ул шундыйларның берсе янында булып чыкты. Чиртсәң кан чыгарлык кызыл йөзле, таза һәм зур гәүдәле капитан Зверев кабинетына ул, паспорт бирүче Вәсимә апа кабинетына керер алдынан булгандагы кебек, тыелгысыз каушау һәм курку тойгысы белән керде. Военкоматка килгәндә юл буена сүземне русча рәтләп сөйли алмам, фикеремне русча дөрес итеп аңлата алмам дип борчылды. Ярый әле түш кесәсендә яңа паспорты бар иде — шул гына әзме-күпме кыюлык һәм үз-үзенә ышаныч тойгысы биргән сыман булды.

— Мухутдинов, без сине Ленинградский военно-морской училищега укырга җибәрәбез. Әзер булып торыгыз,— диде көр тавышлы капитан Габделхәйгә беренче сүзе итеп.

Үз-үзенән канәгать капитан тарафыннан бернинди шәфкать, миһербанлык булмаячагын Габделхәй бөтен күңеле белән аңлады.

— Нишләп мине генә алырга булдыгыз, иптәш капитан?— диде ул.

Капитан Зверев, күрәсең, мондый сорау көтмәгән иде.

— Беренчедән,— диде ул, бераз уйлангандай иткәч,— беренчедән, армиядә хезмәт итү — һәрбер совет гражданының изге бурычы. Икенчедән, военно-морской училищега без бары яхшы укучыларны гына тәкъдим итәбез.

— Ләкин СССР Конституциясендә язылганча, һәрбер совет гражданы укырга, белем алырга хокуклы,— диде Габделхәй, барлык батырлыгын җыеп.

— Сезне миңа яхшы укучы, ләкин үзсүзле дип әйткәннәр иде — дөрес әйткәннәр икән,— диде капитан, йомшый төшеп.

Аңа Габделхәйнең СССР Конституциясе турында искә төшерүе тәэсир итте булса кирәк. «Кем әйтте минем турыда?»— димәкче булды Габделхәй, ләкин тыелып калды.

— Без Конституциягә каршы килмибез, без сезне укырга җибәрәбез,— диде капитан, «укырга» сүзенә басым ясап.

— Минем Ленинградтагы военно-морской училищеда укыйсым килми. Мин Казан университетына кермәкче булам,— диде Габделхәй, алдан ук әзерләп килгән сүзләрен исенә төшереп.

— Ярар, шулай да булсын. Университетны бетергәч кем булырга исәплисез инде сез?— диде капитан.

— Мин... шагыйрь булачакмын!..— диде Габделхәй, кызарынып.

— Шагыйрь...— диде капитан һәм бер дә юктан өстәлгә бармаклары белән барабан кагып алды.— Шагыйрь булу начар түгел, билгеле. Әнә Пушкин булган, Лермонтов булган. Шулай да әйтегез әле, сезнең телдә... татар телендә шигырь язып буламыни?

Мондый сорауга каршы Габделхәй нәрсә әйтергә дә белмәде. Капитанның мондый соравы туп-туры аның йөрәгенә, бәгыренә барып тиде. Бу аның үзен генә түгел, аның телен, халкын мыскыл итү булып тоелды. Кем соң бу — синең шулай иң нечкә җиреңә кагылып, сине кимсетүдән, мыскыл итүдән тартынмый торган, үзенең бөек халык вәкиле булуыннан тәм таба торган, масайган колонизатормы, әллә татарча шигырь язып булу-булмавын да аңлый алмаган берәр туң башмы?

— Минем мондый сорауга җавап бирәсем килми,— диде Габделхәй караңгы чырай белән, утлы күз карашын шешенке күз кабаклы капитанга төбәп.

— Минем беләсем килә — татарда шагыйрьләр бармы соң? Чын шагыйрьләр?— диде военком, ягымлы булырга тырышып.

— Тукайны ишеткәнегез юкмыни?— диде Габделхәй үзе дә сизмәстән.

— Да, да! Ишеткәнем бар икән... Такой...— диде капитан, үз хатасын танып.

— Такой түгел, Тукай!— диде Габделхәй.

— Токай икән Токай... Такой-сякой дигән кебек,— диде капитан көлеп, дусларча кыланып.— Шигырьне армиядә дә язарга була, училищеда... хәтта татар телендә дә! Анысы тыелмый. Өч мәртәбә ашау, кием-салым тулысынча дәүләт исәбеннән булачак. Укып чыккач, хәрби диңгез флотында хезмәт итәчәксез. Сез аңлы кеше — армия безгә һәрвакыт кирәк. Сугыш бетте, без җиңдек, дөньяда хәзер бер генә дошман да калмады дип уйласагыз, бик ялгышасыз.

— Минем алай дип уйлаганым юк,— диде Габделхәй, капитанга күтәрелеп карыйсы килмичә.

— Армиядә хезмәт итүдән баш тартуыгыз шуны күрсәтә,— диде капитан, ап-ачык итеп.

— Мин алай дип әйтмәдем, иптәш капитан!— диде Габделхәй, кызарынып.

— Алай дип әйтмәсәгез дә, тел төбегез шуңа бара,— диде капитан.— Без фашистларны җиңдек, ләкин киләчәктә безгә тагын да көчлерәк, тагын да зуррак армия кирәк булачак. Сез моны беркайчан исегездән чыгармагыз. Дөньяда ике лагерь, ике блок яши. Империалистик блок һәм социалистик блок. Ахыр чиктә социа-

лизм барыбер җиңәчәк! Сез укыган кеше, моны белергә тиеш. Кытай, Һиндстан, Африка колонияләре... империалистлар изүе астында интегә. Алар бездән ярдәм көтә. Шулай булгач, совет армиясен туктаусыз ныгыту, һәртөрле авантюрага тиешенчә отпор бирергә әзер тору — безнең изге бурычыбыз. Армиянең, хәрби флотның булачак кадрлары — сез, яшьләр. Бөтен нәрсәне кадрлар хәл итә, диде иптәш Сталин.

Соңгы сүзләрен капитан шулайрак тәмамлады, каршы әйтергә, каршы килергә бернинди чара калдырмый торган итеп тәмамлады. Капитан Зверев империализм-социализмны, иптәш Сталинны теленә алгач, Габделхәй үзенең бирелә башлаганлыгын тойды. Аның моңа каршы тору түгел, хәтта бу мәсьәләдә икеләнергә дә көче җитмәячәк иде. Иң куркынычы менә шул «империализм-социализм» иде. Моннан беркая качып котылып та булмый, моны шулай ук аңлап, аңлатып та булмый. Моңа бары башыңны иеп буйсынырга гына кала. Монда инде шигырьләр дә, мәхәббәт тә, ашау-эчү кайгылары да истән чыгып бетә иде. Бүре авызына керер алдыннан бичара сарык нәрсә кичерә торган булса, «империализм-социализм» һәм «иптәш Сталин» алдында да мескен адәм баласы нәкъ шундый ук нәрсә генә кичерә ала иде. Хәер, курку, кот алынудан башка нинди дә булса кичерешнең монда булуы да мөмкин түгел иде.

Шулай да кире һәм үзсүзле малай-җегет киң күкрәкле тук капитанга каршы сүз әйтергә батырчылык итә алды.

— Мин укырга... Казанга китәргә булдым, иптәш капитан,— диде.

Капитан беравык эндәшми утырды, һәр сүзенә басым ясап:

— Аңлашылды, Мухутдинов,— диде.— Мин сезгә өч көн вакыт бирәм. Өч көннән соң килерсез. Барыгыз, уйлагыз. Карагыз аны, ныклап уйлагыз!

Габделхәй уйланды, туктаусыз уйланды. Ләкин чынында инде ул җиңелгән иде. Бит аның өчен барысы да алдан ук уйланып, хәл ителеп куелган иде.

«Победа»ның алгы утыргычында утырып барган күптәнге танышын күрү белән, кинәт анда яңа бер көч барлыкка килде. Шундук ул башын күтәрде, күкрәген киерә төште һәм тапталган каты, кара җиргә нык-нык басып бара башлады.

Ул һаман уйланып барды. Ирексездән ул үзен диңгезчеләр кебек озын буйлы, төз гәүдәле һәм өр-яңа киемнән итеп күрде. Аның белән бергә тигез атлап, штык-

лы автоматларын нык тотып, яшь моряклар колоннасы барды. Күз алдыннан каскалы солдатлар узды. Бөтен урамнар, кырлар-басулар калканлы һәм сөңгеле, тәреле һәм йолдызлы сугышчылар белән тулды.

Если завтра война, если завтра в поход... дип җырладылар сугышчылар, җирне-күкне дер селкетеп. Якыннан гына дөбердәп, каты үкереп корыч танклар, ракеталар барды. Күктә, түбә өстендә кара болыт булып самолетлар очты. Шул чакны ил өстендә якты кояш балкып китте — трибунадан иптәш Сталин бәхетле Габделхәйгә аталарча кул болгады.

Ләкин көтмәгәндә кемдер бәхетле җегетнең яңагына китереп сукты. Габделхәйнең күзеннән утлар чәчрәде, йөрәге әрнеп сулкылдарга тотынды. «Казан балшой, балшой, Масква малинки!»— дип, «Бей татар!»— дип кычкырдылар караңгы урамда малай-шалайлар, маймул-рамуслар. «Такой-сякой!» диде капитан, мыскыллап.

«Юк, таварищ капитан, без такой-сякой түгел. Без... без сугышта юлбарыстан көчлебез, без тынычта аттан артык эшлибез! Без әле моряк та булырбыз, шигырь дә язарбыз!»— дип уйлады Габделхәй, эчке бер киеренкелек белән Яңавылның каты-коты урамыннан алга атлап.

*1956—1962 һәм 1988—1990 еллар.*
*Казан*

# КЫРЫК ДҮРТНЕҢ МАЙ АЕНДА

*(Артта калган юллар)*

## I

Су өстендә тирбәлеп торган көймәгә Хәмдия иплэп кенә, курка-курка гына керде. Керде дә борындагы аркылы тактага утырды.

— Менә монысына... уртага утыр,— диде көймәче карт.— Көймәгә утырганың юкмыни?

— Юк шул, бабай,— диде Хәмдия.

Башына командирлар фуражкасы, аягына ыштыр урап чабата кигән көймәче карт Хәмдиянең урнашуын гамьсез генә көтеп торды. Балалы хатын җайлап утыргач, ул ишкәк очы белән яр читенә төртеп алды, һәм балык исе, сумала исе аңкытып торган иске көймә җиңел генә, шома гына кузгалып китте.

Алар кыйгачлап, агым уңаена бардылар. Көймәче карт, кыска саплы ишкәген бер кулыннан икенче кулына күчергәләп, салмак кына иште дә иште. Уң яктагы яр сул яктагасына караганда текәрәк иде. Уң яктагы яр өстендә, бер-берсенә сыенып, күккә таба үрелеп, биек агачлар утыра иде. Шуңа күрә елганың уң як чите тагын да биегрәк, тагын да шомлырак булып тоелды. Бөтен киңлегендә елга аермачык булып күренмәде, шулай да якында гына салкын, тыгыз су барлыгы, аның каядыр ашкынып акканлыгы һәм бик тирән икәнлеге сизелде.

Хәмдиянең баштагы шүрләве тиз арада юкка чыкты. Менә шулай кара ярлар арасыннан, салкын су өстеннән әкрен генә тирбәлеп бару аңа хәтта күңелле булып, сәер һәм рәхәт булып тоелды. Искәрмәстән көймә борыны белән җиргә төртелде, алга таба бераз шуышкандай итте дә тукталып калды.

— Менә, чыгып та җиттек, кызым,— диде карт, басынкы гына.— Карабрак атла. Ботакка тотынып мен. Шунда сукмак булыр.

— Рәхмәт инде, бабай... рәхмәтләр яусын,— диде Хәмдия, кинәт авырайган тәнен көчкә кузгатып.

Учына йомарланган бер сумны ул көймәчегә сузды, шәлгә төреп җилкәсенә аскан баласын яхшылап тотты да ярга таба атлады.

— Рәхмәт инде, бабай, рәхмәтләр яусын!— диде ул тагын да, көймәчегә борылып.

— Сау бул, кызым. Юлың уң булсын,— диде көймәче карт.

Ул янә дә ишкәге белән яр читенә төртеп алды. Көймә кире шуып китте, һәм бераздан караңгы елга өстендә көймәченең алмаш-тилмәш селтәнгәне, ишкәк очына шап-шоп бәрелгән су тавышы ишетелде.

Хәмдия бераз вакыт яр буенда тын гына басып торды, бары шуннан соң гына, агач ботакларына тотына-тотына, югары менеп китте. Менеп җиткәнче аның сулуы капты, аяк буыннары хәлсезләнде — ни әйтсәң дә, бала авыр иде, шуның өстәвенә аркасында капчыгы да бар иде. Менгәч ул яр өстендәге юан гына карамага сөялде дә киң итеп, озын итеп бер тын алды һәм төз, юан кәүсәләр арасыннан чак-чак кына беленеп яткан елгага карап тора башлады. Сихерләнгән кебек бик озаклап карады, яратып, сокланып карады.

Аның өчен иң авыры, иң куркынычы менә шушы елга иде. Тегендә ерак юлга әзерләнә башлаган чакта аның өчен язгы Бүә соңгы киртә булып, киртәләрнең дә иң биеге, иң яманы булып тоелган иде. Язгы Бүә белән, ярларына тулып аккан кыргый дәрья белән чагыштырганда, кайтасы юлның озынлыгы да, юлда көтелгән һәртөрле азаплар, мәшәкатьләр дә аның өчен, әйтерсең, берни түгел иде.

Менә хәзер ул Сакат ягында. Ул Бүәне кичте! Хәзер инде аны кайтып җитте дияргә дә була. Менә моннан, менә шушы текә ярдан аның туган җире башлана. Җир шарының менә шушы өлешендә, тулып аккан шушы елга үзәнендә ул дөньяга килгән. Монда аның әбиләре-әниләре туган, аталары-бабалары туган. Бала чактан аның барлык әгъзасына шушы якның суы сеңгән, тыны сеңгән; бала чактан зиһененә шушы якның гореф-гадәтләре сеңгән; күңелендә шушы якның сурәтләре: язы-көзе, җәе-кышы, урманнары, болыннары, зәңгәр күге...— барысы да, барысы да катлам-катлам булып сеңеп калган; бала чактан аның барлык тамырлары шушы җирнең туфрагына берегеп үскән.

Менә ул чит җирләрдән, чит илләрдән үз җиренә, үз иленә кайтып төште. Мәңгегә, гомергә кайтты. Инде хәзер беркайчан да аерылмаска, беркайчан да чит якларга китмәскә дип кайтты. Алда җәелеп яткан карурманны чыгасы да, Сакат тавын менәсе дә, кырлар-басулар

аша, чокыр-чакырлар аша, такыр юлдан, такыр сукмактан туган өйгә кайтасы да керәсе...

Нинди иркенлек, нинди гүзәллек! Никадәр хыялланды ул менә шулай яр буенда... урманда... караңгыда ургып аккан Бүә суына карап торырга! Никадәр хыялланды ул туган якның татлы һавасын суларга!

Менә ул монда... менә җиргә аяклары тиеп тора. Күрәсеңме, урман, күрәсеңме, Бүә? Баба-ай!.. Баба-кай, ишетәсеңме?— Хәмдия иленә кайтты!

## II

Хәмдия яр буендагы бер ауган агачка килеп утырды. Утырды да аркасындагы авыр капчыгын салып җиргә куйды, баласының «бишеген» ычкындырды. Шул рәвешчә туарылгач, ана кешегә тагын да җиңелрәк булып китте. Изрәп йоклаган баласын ул күкрәк турысыннан аскарак шудырды, аны тәгәрәп төшмәслек итебрәк урнаштырды да аркасы белән агач ботагына сөялде.

Аны шундук йокы басты. Ул тынычлап, онытылып йоклады. Яр буендагы ауган агачка терәлгән килеш, язгы салкынча һавада, урманда, Бүә буенда ул шушылай, ихтимал, төн-көн йоклый алган булыр иде, кырын ятып кына түгел, баскан килеш тә, теләсә нинди рәвештә, теләсә нинди урында йоклый алган булыр иде. Ләкин аның баласы бар. Бала өчен исә аның гүя аерым нервылары, аерым йөрәге, аерым зиһене бар иде. Шул аерым нервылары ярдәмендә ул йокы аралаш улының көйсезләнә башлаганын сизеп алды. Сизеп алды да күзләрен ачып җибәрде. Бала уянган һәм үзен чорнаган чүпрәк эченнән кулларын-аякларын чыгарырга тырышып азаплана иде.

Хәмдия башын калкытты, агачка җайлабрак утырды да «бишек» бавын чишеп җибәрде, баланы кулына алды. Баланың асты юеш иде.

«Булдыксыз әннә! Оныткан бит карарга, улын оныткан!» диде ул күңеленнән үз-үзен тиргәп. Тышта, төнге салкын һавада баланың астын алыштыру никадәр кыен булмасын, шулай да ул аптырап тормады. Башына иске шәлен бөркәнде, бала өстенә иелеп, чатыр сыман нәрсә әмәлләде. Чатыр эчендә баланың тәпиен тотты, киемнәрен алыштырды, аннан соң аны җылыга — куенына алды, мәммәм бирде. Бала, песи кебек мыр-мыр килеп, ашыгып-кабаланып имәргә тотынды.

Төн уртасы инде узган иде бугай. Агач араларындагы караңгылык сыеклана төшкән, ләкин шул ук вакытта агачлар тагын да караебрак, бер-берсеннән аерылыбрак

күренә иде. Өстә, ботаклар арасында, йолдызлар җемелдәшә, аста, кара кәүсәләр артында беркайчан да йокы белми торган, тынгы белми торган тере елга ага. Пыяладай салкын, чиста һава шундый тын, тыныч — суның яр читенә бәрелеп-сугылып агуы да, аяк астындагы коры чыбык-чабык сынганы да, баланың авызын чупылдатып-чупылдатып имүе дә олы тавыш булып ишетелә иде.

Бала имгәч ананың да ашыйсы килеп куйды. Кузгалып киткәнче әзме-күпме көч җыярга кирәк иде. Капчыгын актарып ул бер сынык ипи алды... солдат ипиен... Куяды станцасында баласын кызганып аны солдатлар үзләре янына утырттылар. Яңавылга чаклы ул алар белән бер вагонда кайтты. Татарча аңлый торган казакъ солдаты төшеп киткәндә бер телем ипи белән бер шакмак шикәр бирде. «Минем дә шундый балам калды гуй»,— диде казакъ солдаты, Хәмдиянең улын сөеп.

Ипинең яртысын Хәмдия Яңавылда ашады, яртысы менә капчык төбендә. Үзенә бер төрле хуш ис аңкып торган йомшак ипи. Бераз катысы да бар... Элек ул ипинең йомшагын бер дә яратмый торган иде. Бер вакытны бәләкәй чагында яңа пешкән бер бөтен ипинең катысын ашап бетерде. Күргәч әнисе бик ачуланды, әтисе көлеп кенә куйды. Балаларның шуклыгыннан ул шулай көлеп кенә куя торган иде. Икенче бер вакытны әнисе кибән башын бирмәгәч, күз яшьләрен агызып җылап утырган иде. Бар иде дивана чаклар. Нинди тәмле, нинди кадерле икән ул йомшак булып пешкән арыш ипие!

Кулындагы сыныгын озаккарак җиткерергә тырышып, ул ашыкмыйча гына, тәмен белеп кенә ашады. Ләкин сынык күз алдында кечерәя барды. Ниһаять, ул соңгы кабымын йотты да, авызындагы ипи тәменнән аерыласы килмичә, күпмедер вакыт тып-тын гына утырды.

— Әзрәк булды шул, улым,— диде аннары, улына эндәшеп.

Күрәсең, балага да әзрәк булды — «имезлеген» авызыннан чыгарды да шыңшып, ашыгып яңадан эзләнергә тотынды.

— Син дә туймадыңмыни?— диде яшь ана, борчылып.— Туймассың шул — әннә ач бит. Ничә көн инде без ачлытуклы. Түз инде, түз, бәпчегем. Күп калмады, түз. Үзебезгә кайтып җыгылсак, беләсеңме, кытлык дигән нәрсә кырык чакрым артта калачак. Кырык чакрым дип, улым, болай гына әйтелә ул. Кырык чакрым гына түгел, биш йөз чакрым артта калачак. Калды инде. Кытлык та, барысы да артта калды. Менә, улым, без Бүә буенда. Үзебезнең Бүә буенда. Син йоклап калдың, бернәрсә дә күрмәдең.

Без көймә белән чыктык. Кайткач, без, беләсеңме нәрсә ашарбыз? Кү-үп итеп ит ашарбыз, ипи ашарбыз, бәрәңге ашарбыз. Их, шундый иттереп ашарбыз! Тавыклар күкәй саладыр — күкәй ашарбыз. Картыкай синең белән мин кайтуга, бәлки, берәр тавыгын кых! итәр. Картый бик юмарт ул. И ашарбыз тавык ите, и ашарбыз тавык шулпасы! Инде синең үзеңә дә ашарга вакыт. Әннәгә генә салгашырга ярамый. Тегендә булмады, монда булыр. Монда инде син үзең ашый башларсың. Бит әннәгә монда да эшкә йөрергә туры киләчәк, улым. Без икәүләп синең белән җиләккә барырбыз. Җиләк пешүгә син тәпи йөри башларсың. И күңелле булыр шул чагында, улым!

Сөйләнә-сөйләнә ул аның йөзенә иелде, күзләренә карады. Бала инде йоклый иде. Ана кеше шундук тынып калды һәм юлга әзерләнә башлады: аркасына капчыгын асты, алгы яктан «бишеген» асты. Шуннан соң ул таяк алды. Бу вакытта чит кеше Сакат урманына аяк басарга да куркыр иде. Хәмдия курыкмады. Уйлап та бирмәде. «Әлли-бәлли бәү итте, улым йокыга китте. Аюбүре, килмәгез — улым йокыга китте»,— дип такмаклады ул күңеленнән, тар сукмактан атлап.

## III

Сакат тавын, калын урманнарны артта калдырып, таң беленә башлаганда ул ялан кырга килеп чыкты. Күк йөзе ачылып китте, дөнья иркенәйде һәм тапталмаган каты юл да кинәт тураеп, киңәеп калгандай булды.

Кояш әле чыкмаган иде. Туган җир — кырлар-басулар, әрәмәләр, калкулыклар... томансу элпәгә төренеп, тын гына йокымсырап, оеп ята иде. Табигать әлегә соргылт-кара төстә. Күктә әлегә бернинди зәңгәрлек юк, җирдә әлегә бернинди яшеллек юк. Хәер, беренче карашка гына шулай иде, ахрысы.

Як-ягына карана торгач, Хәмдия Нуркай бакчасы ягында, калкулыкта яшел уҗым басуы күреп алды. «Арышны менә кайда урачакбыз икән»,— дип уйлады ул. Бераздан, әрәмәләрне үтеп, тагын да иркенрәк җиргә килеп чыккач, күз алдында икенче төрле күренешләр ачылды. Алда, еракта, әле анда, әле монда яңа сөрелгән җирләр караеп күренде. Сөрелгән җир нишләптер бик әз булып тоелды. «Соңлап тотындылар микәнни?»— дип уйлады ул гаҗәпләнеп. Дөрес, Урал якларында да... ул узган авылларда да әле яңа гына сөрә башлаганнар иде. Ләкин аларда язы да соңгарак калып килә бит.

Аннары аны шунысы гаҗәпләндерде: күз күреме

җиткән бер генә җирдә дә ул трактор күрмәде. Шулай ук беркайда аның тавышы да ишетелмәде. Кырларда-басуларда — сөрелгән һәм сөреләсе җирләрдә, әрәмә өсләрендә, чокыр-чакырларда, калкулык башларында — бөтен тирә-якта серле бер тынлык, торгынлык саклана иде. Бу минутта хәтта тургайлар да сайрамый, хәтта чыпчыклар да чыркылдамый иде. Күңелле дә, күңелсез дә тынлык иде бу.

Сугышка чаклы бу вакытта басуларда көн-төн тракторлар гөрли торган иде. Сугышка чаклы гына түгел, кырык икенче елны — Хәмдияләр ду китереп соңгы мәртәбә колхозда эшләгән язны да — басуларда корыч атлар сөрә иде. Исең китәр, аларны да сугышка алдылар микәнни? Уйлап карасаң, аз гомер үтмәгән шул. Кырык дүртенче ел бит хәзер. Кырык дүртнең мае. Шул вакыт эчендә ниләр генә булмагандыр монда!

Хәмдия авылга якынлашып килгәндә, Вәрәшнең Чаган тавы артыннан, аксыл күк кырыеннан беренче кызгылт-алтын нурлар тишелеп чыкты. Әкрен генә җил исеп куйды, авыл ягында сузып-сузып әтәчләр кычкырган тавышлар ишетелде. Хәмдия туктады, авыл ягыннан күзен алмыйча, елмаеп җибәрде.

— Улым, карале, без авылга кайтып җиттек!— диде ул, тәэсирләнеп. Иртәнге саф һавада алсуланган битләренә кайнар яшьләр тамып төште.— Әннәнең туган авылы менә шушы инде, улым. Синең әле күргәнең юк. Син, улым, күп авыллар күрдең, шәһәрләр күрдең. Үз авылыңны гына күргәнең юк. Ул синең дә туган авылың, улым. Әнә безнең йорт күренә, әнә безнең яшен суккан карт чыршы утыра. Әнә безнең ындыр артта, чокыр аръягында Корт-бакчабыз. Корт-бакча астында — Салкын чишмә. Вәрәш якта, юл буенда әнә ялгыз нарат. Ач күзеңне, күр дөньяны, улым!

Үзалдына шулай сөйләнә-сөйләнә, дөресрәге, шулай уйлана-уйлана Хәмдия такыр юлдан бераз җир барды да читкә чыгып сөрелмәгән җиргә керде. Үзләренә ул әйләнгечтән — чокыр эчләп, болын буйлап, ындыр артлап кайтып кермәкче булды. Аңа әле туры юлдан йөрергә бик үк ярамый иде.

## IV

Салкын чишмә чокырыннан менеп килгәндә, үзләренең бакча капкасы янында нindидер сәләмә хатынны күреп, Хәмдия ирексездән туктап калды. «Кем булыр бу? Нишләп йөри икән бу безнең бакча тирәсендә?»— дип уйлады ул, аптырап. Шул ук вакытта диярлек сәләмә

хатын да аны күреп алды һәм шулай ук танымыйча, аптырап, исе китеп карап тора башлады.

Шулай да алар бер-берсен таный алдылар. Танып алдылар да, тагын да ныграк гаҗәпләнеп, куркып һәм шатланып, икесе дә берьюлы аһылдап җибәрделәр.

— Хәмдия!— диде сәләмә хатын, зәгыйфь бер ыңгырашу белән.

— Әнкәй... әнкәчкәем!— диде Хәмдия, йөрәк өзгеч бер өн чыгарып.

Алар кабаланып бер-берсенә каршы атладылар.

— Әнкәй, бәгърем!— диде Хәмдия.

— Кайттыңмыни, кызым?— диде әнисе.

— Әнкәй... әнкәчкәем!— диде Хәмдия, еламсырап. Ул аны кочаклый алмады, улы белән икәүләп ул бары аңа сыена гына алды. «Нинди беткән, нинди бетәшкән!»— дип уйлады ул, әнисенең йөзенә карарга да куркып. Өстенә әнисе кырык ямаулы иске сырма кигән, башына чүпрәк сыман ниндидер яулык бәйләп куйган, яулык өстеннән иске бүрек кигән иде. Аягында — чабата, кулында — капчык. Яңаклары, борыны, ияк очлары тире белән сөяктән гыйбарәт. Кайчандыр шаян очкыннар чәчеп торган коңгырт күзләре хәзер нурсызланып эчкә — сөяк куышына кереп поскан.

— Киткәч бер хатыңны алдык та, хат язмадың,— диде ул, иреннәрен әкрен генә кыймылдатып.— Ут булдың да су булдың. Исәнсең икән ләбаса.

— Язмадым шул, әнкәй. Шундый җирдә эшләдем,— диде Хәмдия.

— Ярый инде, үзең кайткансың — анысына шөкер,— диде әнисе, тыйнак кына.

Корышкан бармаклары белән ул күз төпләрен сөртеп алды, аннары кызының кулындагы баласына карады да, тотлыккандай итеп тынып калды. «Нинди бала? Кем баласы?»— диде аның аптыраулы күз карашы. Хәмдия эндәшмәде. Ул эндәшмәгәч, әнисе дә төпченеп тормады — кире борылды да сукмак буйлап бакча капкасына таба юнәлде.

— Бу вакытта кая барырга чыктың, әнкәй?— диде Хәмдия, аның артыннан атлап.

— Көшләбидә кибәк бар,— диде әнисе, капка янында артына борылгандай итеп.— Кеше сизенгәнче барып кайтыйм дигәнием.

— Нинди кибәк, әнкәй?— диде Хәмдия.

— Карабодай кибәге,— диде әнисе.

Хәмдия берни аңламады һәм кинәт туган бер шомлану белән, борчылу һәм пошыну белән, әкрен генә әнисе артыннан атлавында булды.

Өй эчендә якты гына иде. Түрдә, зур сикедә, искемоскыга төренеп, кемдер йоклап ята. Мич башында иренеп кенә соры песи юынып утыра. Барлык почмаклардан, барлык кием-салымнардан, савыт-сабалардан гади, аңлаешлы бер җылылык һәм туганлык исе бөркелә. Шул ук вакытта барлык почмаклардан, барлык кием-салымнан, барлык савыт-сабадан, котсыз күзләрен зур ачып, мохтаҗлык һәм ярлылык карап тора иде.

Бусагадан атлау белән, өй эченең әчкелтем, җылымса һавасын сулау белән, Хәмдия моны бик яхшы сизеп алды. Бу сизенү әнисе белән очрашканнан соң туган шомлану, аптыраш тойгысын тагын да ныграк көчәйтеп җибәрде. Шулай да сагыну һәм ярату тойгысы әле андагы барлык башка тойгылардан көчлерәк тә, чыдамрак та иде. Ул әле күңелен төшерергә ашыкмады. Җиңел генә атлап түргә узды, баласын сикегә яткырды да чүпрәкләрен таратып ташлады. Шуннан соң аркасындагы капчыгын салды, өстен-башын салып ташлады һәм җиңеләеп, иркенләп үзенең яраткан урынына — түр почмакка, өстәл янына терәп куелган сандык өстенә утырды. Элекке чаклардагы кебек аркасын стенага терәде, аякларын сандык өстенә сузып җибәрде. Чүпрәк-чапрактан, авыр киемнәреннән арынгач, ул яшәреп, чибәрләнеп киткәндәй булды. Юлдан алып кайткан алсулыгы әле булса бетеп җитмәгән иде. Гәүдәгә ул калку иде, әнисе кебек үк эре сөякле иде. Аның тере коңгырт күзләреннән, күлмәк аша беленеп торган чандыр, ләкин таза иңбашларыннан, беләкләреннән көч һәм яшьлек ташып тора иде.

Игътибар белән ул тагын бер мәртәбә өй эчен күздән кичерде, башын борып тәрәзәгә карап алды һәм, аякларының рәхәт сулкылдавын тойган хәлдә, тып-тын гына шулай утыра бирде.

Менә сиңа туган йорт... сандык өсте, тәрәзә төбе. Барысы да артта калды, еракта, бик еракта калды. Мең тугыз йөз кырык икенченең октябрь таңында Яңавыл вокзалында елашып аерылышулар да, Урал таулары һәм Урал урманнары да, такта бараклар һәм торф сазлыклары да — барысы да, барысы да кайчандыр төштә күргән кебек кенә булып калды. Әллә булган, әллә юк. Чыннан да, әллә булган, әллә юк. Күз алдында шул ук түшәм, шул ук мич, шул ук җиз самавыр, шул ук тынлык һәм шул ук исләр. Шул ук уйлар... Юк, юк, уйлар шул ук түгел. Менә нәрсә генә үзгәргән икән бу өйдә.

Үз-үзен онытып утырган яшь хатынны айнытып шул чакны түр сикедә бала шыңшып куйды.

## V

Хәмдия энисенең төпченүен көтте. Ул инде аны күптән көтте һәм үзенчә моңа әзерләнеп тә куйды. Ләкин энисе нишләптер берни сорашмады. Бөтенесен алдан белгән кебек, гомумән, берни белән кызыксынмады һәм, авыр гына кыймылдап, казан тирәсендә булашты.

«Әллә дөресен әйтергәме?» — дип уйлады Хәмдия, энисе тышка чыгып киткәч. Ник әйтмәскә — ана ич ул аңа. Аңа да әйтмәгәч, тагын кемгә әйтергә? Әмма тыштан чыбык-чабык күтәреп кергән энисенең йончылган, кызганыч йөзен күрү белән, фикере шундук кирегә үзгәрде. «Болай да беткән кешене тагын нигә бетерергә?» — диде ул үз-үзенә. Шулай да нәрсә булган аңа? Авырыймы, әллә тормыш авырлыгы басканмы?

— Син нәрсәдер пешерергә йөрисең бугай, энкәй? — диде ул, йомшак кына итеп.— Мин бик арыдым, йокы килә. Минем өчен булса, мәшәкатьләнмә хәзергә.

— Ярар алайса,— диде энисе, бик тиз килешеп.

Шулай диде дә, тамырлары бүртеп торган ябык кулларын салындырып, сикегә, бала янынарак утырды. Утырды, ләкин бөтенләй күрмәгәндәй балага кырын күз дә ташламады. Энисенең мондый кыланышы Хәмдиянең эчен тырнап куйды. Берни эндәшмичә ул сандык өстенә урын җәйде һәм баласын алырга дип сике янына килде.

— Җитәр инде, күп йокладың,— дигән булды.— Әйдә, тор, энә картый белән исәнләш.

Картый исә авыр гына борылды да, ниһаять, балага карагандай итте һәм нык кысылган иреннәрен көчкә ачып:

— Икәү булдыгызмыни, кызым? — диде.

— Икәү булдык, энкәй,— диде Хәмдия.

— Ярый инде. Каяле, күрсәт әле — кем соң ул? — диде ана кеше, кызыксына төшеп.

Хәмдия биләүләрне таратып ташлады.

— Сөбханалла! Җегет кеше икән ләбаса!— диде картый, елмайгандай итеп.— Күз генә тимәсен, тфү-тфү! Бәхетле сабый булсын.

— Исәнләш инде, исәнләш картый белән, улым,— диде бәхетле ана, елмаеп.

— Исәнме, улым, исәнме,— диде картый, күзләрен ачарачмас яткан сабыйга эндәшеп.— Исән-сау кайтып җиттеңме? Тфү-тфү! Күз тимәсен. Ярый инде. Бәхетле бала булсын.

Шулай да ул карау белән генә дә канәгатьләнмәде — баланы иплэп кенә күтәреп алды, хәлсез куллары белән аны күкрәгенә кысты, яратып, тансыклап аның чүпрәкләрен иснәде, битен, кулын үпте.

— Бигрәк тәмле икән шул, бигрәк татлы икән шул!— диде такмаклап.— Бәхетең-куанычың белән... иминлек-тынычлык белән... Ярый инде. Үзеңә охшаган икән. Ир бала анасына охшаса, бәхетле була диләр. Бәхетле генә булсын инде.

Селкетә-тирбәтә торгач, бала ныклап торып уянып китте, дәү әнисенә исе китеп бер карап алды да авызын зур ачып җыларга тотынды. Тын, моңсу өй әче сәер тавышка тетрәнеп китте.

— Менә шулай, менә шулай!— диде картыйсы, кет-келдәп.— Шайтаннарны качыр! Качыр мәлгуньнәрне!

Хәмдия, куанычыннан нишләргә белмичә, елмаеп әле балага, әле әнисенә карады.

— Ничә айлык?— диде картый, баланы кызына тоттырып.

— Сигез ай тулды,— диде Хәмдия. Чынында бала ун айлык иде, ләкин ана кеше бераз гына ялганларга кирәк тапты.

— Исеме ничек соң?— диде әнисе.

— Мин аңа Ирек куштым, әнкәй,— диде Хәмдия.

— Үзең генә куштыңмыни, кызым?— диде әнисе, бераз тынлыктан соң.

Хәмдия тотлыгып калды.

— Анда аңа кемнәр шартына туры китереп исем куш-сын инде, әнкәй,— диде ул, күңелсез генә.— Әттәсе белән ярты ел гына тордык та, сугышка алдылар.

— Ярый инде, хәерле булсын,— диде карт ана, авыр көрсенеп.— Агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри. Исән-имин кайткансың — шунысына шөкер. Хаты киләме соң?

— Кемнең?

— Кияүнең хаты киләме?— диде әнисе.

Һы, кияүнең! Кызык, кияү, имеш...

Хәмдия бу турыда уйлап җиткермәгән иде. Ул бары үзенең алдануын гына белә, ул бары үзенең җилдән тапкан бала белән кайтуын гына белә иде. Аның барлык ихтыяры, барлык осталыгы, хәйләсе, омтылышы әнисеннән, күршеләрдән, барлык кешеләрдән шуны яшерүгә генә юнәлтелгән иде.

— Хаты килми шул, әнкәй,— диде ул, кыюсыз гына.— Баштарак атна саен килде. Икенче ай инде — берни юк.

— Алай икән,— диде әнисе.— Кайсы якныкы соң... үзебезнең якныкымы дигәндәй?

— Юк, читтән, Көңгер ягыннан.

— Алай икән,— диде әнисе, тагын коры гына.

## VI

Ана кеше уйга калды. Шулай бернинди хәрәкәтсез тын гына утырды-утырды да, ике куллап битен сыйпап алды һәм, юри генә кыланган сыман, бер дә юктан борын тарта башлады.

— Әтәңнең дә хәбәре юк, кызым,— диде.— Синең кебек китте дә югалды.

— Мин югалмадым бит, әнкәй,— диде Хәмдия.

— Син дә бер-ике хат яздың да юкка чыктың, ул да бер-ике хат язды да юкка чыкты,— диде әнисе.

— Ул да минем кебек кайтып килер әле, әнкәй,— диде Хәмдия.

— Югароч Мәттин малае язган... Җәгъфәр... Нигъмәт абзый белән бергә кердек сугышка дигән, бунбы төште өстебезгә дигән... Шуннан соң Нигъмәт абзыйны күрмәдем, үлеп калды бугай дигән...

— Язганыегыз шул, әнкәй,— диде Хәмдия, авыр тынлыкны бозып.— Шул язганнан бирле берни юкмыни?

— Юк. Китте дә юкка чыкты. Ут булды да су булды. Кешеләрнең ичмасам хатлары килә. Аяксыз-кулсыз булса да, тере сөяге кайтса да...

Әйтәсе сүзен әйтеп бетермичә ул тагын тынып калды.

— Абыйныкы киләме соң?— диде Хәмдия, беравык эндәшми утырганнан соң.

— Син әле белмисеңмени — синтәбернең өчендә җылы тула үле хәбәрен алганга,— диде әнисе.— Сиңа язмаганбыз икән шул. Хатың килмәде бит — кая язасың? Сине дә үлгәндер дидек. Исән булгач кайттың менә. Абыең инде кайтмас, әтәң дә. Узган көзне Зарифҗанны да алдылар.

— Зарифҗанны?! Сикедә ул кем ята соң — Зарифҗан түгелмени?— диде Хәмдия.

— Анысының хаты килә,— диде әнисе, тыңламыйча.— Озакламам, кайтырмын дигән, аякны кистеләр дигән.

— Аягын?!— диде Хәмдия, коты алынып.— Аягын дисеңме, әнкәй? Зарифҗанның?! Юкны сөйләмә, әнкәй!

— Хаты килде. Үз кулы белән язган... укырсың...

— Кая, күрсәт! Булмас, ышанмыйм!— диде Хәмдия, урыныннан атылып торып.

Баласын кочаклаган көе, үз-үзенә урын тапмыйча ул ишекле-түрле йөренергә тотынды. Зарифҗанның аягын кискәннәр! Шундый яшь, шундый таза Зарифҗанның! Бала гына бит әле ул, сабый гына. Ул бит аның куенында — апасы Хәмдия куенында үсте. Зарифҗанкаем, энекәчкәем, туганкаем! Кемнәр шулай итте сине, кемнең кулы барды?!

Карт ана да урыныннан торды, көчкә кыймылдап, иске шүрлек янына килде, шүрлек башына үрелде.

— Менә, укы,— диде, саргаеп беткән өчпочмаклы хатны сузып.— Пуле тиеп яраладылар да, шешә башлады дигән, шуннан соң кисәргә булдылар дигән.

— Укымыйм, әнкәй, укый алмыйм,— диде Хәмдия, пышылдап, хәлсезләнеп.

Көйсезләнә башлаган баласын ул сандык өстенә илтеп салды.

Ташкын булып, дәрья булып аның күкрәгенә яшь килде, әрнү килде, ачу һәм нәфрәт килде.

Сугыш! Нишләттең син безне?! Ләгънәт төшсен сиңа! Ләгънәт кенә төшсен...

Тыела алмыйча, үксеп җылый-җылый ул йөзе белән өстәлгә капланды. Әнисенең җылавыннан куркып, бала да шыңшырга тотынды. Картый аны тиз генә кулына алды, яңадан үзенең сикедәге урынына килеп утырды, кызының тынычлангандай итүен көтеп торды да әүвәлгечә шомлы бер тынычлык белән яңалыкларын тезә бирде.

— Җиңгәң төрмәдә,— диде бала тирбәткән уңайга.— Биш җылга утырттылар.

— Ник?!

— Бер кесә яшел кузак өчен. Урактан кайтканда кесәсенә яшел кузак салган. Баласы өчен инде. Юлда тикшереп торганнар. Тотканнар да утыртып та куйдылар. Былтыр җәй. Әлтәфне үз яныма алдым.

— Әлтәфмени ул?

— Әлтәф. Тор, улым, менә Хәмдия апаң кайтты. Башыннан иске юрган ябынып яткан малай, үз исемен ишетү белән, шундук торып утырды. Ул, күрәсең, күптән инде уяу иде, бары тик әдәп сакларга мәҗбүр булган өчен генә торырга кыймыйчарак ята иде. Йомшак кыска чәчле, караеп килгән матур кашлы чандыр малай яланаяклары белән туп итеп идәнгә басты да, йокылы күзләрен уа-уа, Хәмдия апасы янына килде, күрешмәкче булып чыбыктай беләген сузды.

— Әлтәфкәем, җаныкаем!— диде Хәмдия, унике-унөч яшьлек малайны күкрәгенә кысып.— Нинди үскән, нинди зур булган!

— Үсәсең инде дөнья булгач,— диде малай, белдекле генә.

— Нишләсен ул анда берүзе?— диде карт ана, башлаган сүзен дәвам итеп.— Менә шулай торып ятабыз. Җиңгәңнең өенә бик салдылар, әйберләрен кәнфискәйт иттеләр. Баланы каядыр озатмакчы булганнарые — бирмә-

дем. Ярый инде, рәхмәт — укытучы апалары булышты. Яңавылга ул барды бала хакында.

## VII

Хәмдия телсез-өнсез калды. Ярсыган, аптырашлы уйлары белән ул сандык өстендә тораташтай катты да калды.

— Китим әле, вакыт үтә,— диде әнисе бераздан, урыныннан кузгалып.— Бер ниятләгәч барып кайтыйм әле. Син, алайса, йокла. Әлтәф үзен үзе карар.

Хәмдия эндәшмәде. Эндәшә алмады. Аның теле бәйләнде, аның барлык ихтыяры, барлык яшәү сәләтләре тоткарланып калды. Башыннан бөркәнде дә, әнисенең сүзен тыңлаган сыман, йомшак урынга сузылды да ятты. Чыгып киткәндә әнисе Әлтәф белән нәрсә турындадыр чыш-пыш килде, аннары ишек ачып япкан тавышлар ишетелде, аннары Әлтәф идәнгә калай чүмечне төшереп җибәрде, ашарга сорап йөдәткән песигә кычкырып алды. Хәмдия барысын да ишетеп ятты.

Моңарчы ул җилдән туган улы белән яшәде. Әтисе-әнисе алдында, туганнары алдында ул үзен коточкыч гаепле итеп тойды. Алар алдында гына түгел, һәрбер авылдашы алдында, һәрбер танышы алдында үзен төзәлмәслек җинаять эшләгән кеше кебек итеп тойды. Әтисе-әнисе, туганнары турында ул уйларга да курыкты. Аларны ул бары төшләрендә генә күрә алды һәм еш кына йокысыннан кызарынган күзләр белән торды.

Баштарак шулай булды. Тора-бара бүтән төрле кайгы-мәшәкатьләр күмеп китте. Анда инде юк-бар нәрсә уйланырга вакыты да, мөмкинлеге дә булмады. Аның өчен хәзер бөтен дөнья, бөтен галәм үзенең улы булып, йодрыктай кечкенә, нәни генә булып калды.

Әйе, ул бары аның өчен генә яшәде. Шуның өчен дуслары белән бозылышты, шуның өчен мең төрле азаплар кичерде. Дөньяга килүенең беренче көннәрендә бала барактагы һәркем өчен тансык булып тоелды. Аны яраттылар, кулдан-кулга йөрттеләр. Ләкин озакламый аның тавышы да ишетелә башлады, кибәргә эленгән чүпрәк-чапраклары да күренә башлады.

Аһ, никадәр телгәләнде ул чакларда ана йөрәге! Никадәр йокысыз төннәр, никадәр әрнүле, газаплы көннәр кичерде ул аның өчен! Артык түзәр чамасы калмагач, шунда конторада идән себереп, су җылытып торучы бер карчыкны белеште. Баланы фәлән сәгать карап торган өчен карчык көненә өч йөз грамм ипи сорады. Өч йөз

грамм ул алты йөз граммның яртысы дигән сүз. Алты йөз граммның, ягъни олы кешегә — көне буе кар ерып, хәлдән таеп эшләгән кешегә бирелә торган көнлек паекның яртысы дигән сүз. Ул риза булды. Калган өч йөз грамм аның кече теленә дә йокмады. Хәлсезлектән башлары әйләнде, күз аллары караңгыланды. Беркөнне ул аңын югалтты. Эштә. Шунда бүрәнәләр арасында. Аннан да яманрагы шул булды — аның сөте кимеде. Бала туймый башлады. Ябыкты, начарланды. Өстәвенә, карчыгы да аждаһадай явыз нәрсә булып чыкты. Ярты гомере төрмәләрдә узган, кешелек дигән нәрсәнең тамчысы да калмаган аждаһа карчык бары үзенең өч йөз граммын гына кайгыртты, баланы алырга килгәндә ярты минутка соңгардымы, кырык төрле сүзгә җитеште.

Кая анда сиңа өй турында, ата-ана, туганнар турында уйланулар! Төннәр утырып ул иске-москыдан баласына күлмәк-ыштан текте, качып-посып аның еш чылана торган чүпрәкләрен юды, качып-посып киптерде, кайчагында... кайчагында... Йа Алла,ниләр генә эшләмәде дә, нинди генә хурлыкларга төшмәде ул аның өчен!

Быел язга таба аның хәле чамадан тыш көйсезләнеп китте. Аждаһа карчык баланы караудан баш тартты, баракта калдырып йөрү кыенлашты. Аерым бүлмә даулау турында башка да китерерлек түгел иде. Көннәрдән бер көнне яшь ана бәхетсез улы белән упкын кырыена килеп терәлде. Андагы шартларда упкыннан котылу өчен бары бер генә юл бар иде: олырак хатыннар аңа баланы балалар йортына бирергә киңәш иттеләр. Бу инде аннан мәңгегә аерылу дигән сүз булачак иде. Хәмдиянең бу турыда ишетәсе дә килмәде.

Уйлана торач, ул моннан башка тагын икенче бер юл эзләп тапты. Сугыш елы законнары никадәр каты булмасын, атасыз туган бала белән халык күзенә күренү никадәр хурлыклы булмасын, бер нәрсәгә карамыйча, качарга булды. Бу турыда ул бары дусты, сердәше Кәшифәгә генә әйтте. «Безне монда көчләп тоталар. Үз авылыгызга кайтып егылсаң, колхоз сине яклар,— диде Кәшифә, аның бу ниятен хуплап.— Колхозда да кеше бик кирәк хәзер. Юлда гына тотыла күрмә».

Шулай итеп ул качты. Баласын, киемен-салымын күтәреп, караңгы бер төндә, шау-шулы, сасы һәм явыз барактан иркен кырга чыгып китте. Гомергә белмәгән-күрмәгән юллар белән кайтты, гомердә белмәгән-күрмәгән авыллар, шәһәрләр аша кайтты. Кайбер җирдә поездга утырды, кайбер җирдә җәяүләп элдерде. Рәхмәтле бәндәләр кайвакытта үзләре бирделәр, кайвакытта сорап

алырга туры килде. Ничек итсә итте, шулай да менә туган йортына кайтып егылды.

Йорттагы хәлләр турында ул берни белмәде. Баксаң, әнәниләр бар икән дөньяда!

Ләкин дөньяда ул белмәгән тагын бик күп нәрсәләр бар иде әле. Әнисе белән икенче сөйләшүендә аңа тагын да күңелсезрәк яңалыклар ишетергә туры килде.

## VIII

Хәмдия көне буе йоклады һәм кич караңгы төшкәч кенә уянды. Авыр күз кабакларын ачу белән, чатнап башы авыртканлыгын тойды. Аннары аның өзелеп-өзелеп ашыйсы килеп куйды. Түзсә дә түзә икән адәм баласы — кайчаннан бирле ашаганы юк инде аның! Туктале, улы нишләде икән соң әннәсе югында?

Ана кешенең йөрәге жу итеп китте. Ул шундук башын калкытты, як-ягына каранып алды. Учакта дөрләп ут яна. Түр сикегә, идәнгә һәм идән уртасындагы аркалы урындыкка кызгылт ут яктысы төшкән. Сикедә дәү әнисе белән Әлтәф утыра. Алар арасында — улы! Өчесе дә нәрсәдәндер көлгән булалар.

Улын күрү белән, аның шат тавышын ишетү белән, Хәмдиянең күңеле тибрәнеп куйды. «Ярый әле Зарифҗанкаебыз исән калган,— дип уйлады ул, гаҗәеп бер канәгатьләнү белән.— Сугыш бит. Нишлисең, бер ул гына түгел».

Мыштым гына торып ул сике янына килде.

— Минем улым әннәсеннән иртәрәк өлгергән,— дигән булды.

— Менә икәү булдылар инде... ике малай,— диде әнисе, балаларның аркаларыннан сөеп.

— Ике туган... ике бертуган,— диде Хәмдия, әнисенең сүзен төзәтеп.

— Әткәйгә алмашка! Үскәч мин әткәй урынына сугышка китәм,— диде Әлтәф, мактанып.

— Әзерлән!— диде картый, ачуланып.— Син генә калдың хәзер менә. Инде сугышны бүтән ишетергә дә туры килмәсен диген, әйттем исә кайттым диген!

— Әлтәфләр, Иреkләр үсеп җиткәнче әле!— диде Хәмдия һәм кинәт үзенең улын Әлтәф кадәр үскән итеп күз алдына китерде дә көлеп җибәрде.

— Тиресен тегеп куймаган,— диде әнкәсе.— Аларның үскәнен күрми дә каласың. Үсәләр дә, китеп юкка да чыгалар.

Шулай сөйләнгәләп ул авыр гына торды, казан яны-

на килде. «Нәрсә пешә икән соң анда?» дип уйлады Хәмдия, өйгә чыккан буны иснәштереп. Тавык шулпасы микән, каклаган ит кенә микән? Ләкин казаннан чыккан аш исе нишләптер тавык шулпасы исенә охшамаган кебек тоелды. Бу ниндидер әчкелтем, буш һәм тәмсез ис иде. Хәмдиянең бер дә юктан эче пошып куйды. Өстәл янына утыргач һәм энисе казаннан бүлеп китергән күбәтәне болгатып карагач, аның чын-чынлап кәефе кырылды. Аның... аларның кайтуы хөрмәтенә энисе... умач пешергән иде. Чынында бу умач та түгел иде — бу бары кайнар су гына иде һәм шул кайнар суга беркадәр бәрәңге дә, беркадәр он сыман нәрсә уып салынган иде.

Хәмдия теләр-теләмәс кенә «тавык шулпасын» ашарга тотынды. «Күрәсең, хәлләре шәптән түгелдер»,— дип уйлады ул, мондый ярлылыкка үзенчә аклану эзләп.

Аш янында беркем сөйләшмәде. Аларның өендә гадәт шундый иде. Ашаганда сөйләшмәгез — туймассыз ди торган иде әтиләре. Тик шулай да утыра торгач, мондый изге гадәт истән чыгып китте. Әлтәф үзенә бүлеп бирелгән күбәтәне ялт итеп куйды да ач күзләрен елтыратып картыйсына карады.

— Бетердең дәмени әле?— диде картыйсы.

— Ы-ы,— диде малай, тирләгән маңгаен сөртеп.— Куерагын сал әле, картый.

— Куесы Алла кулында,— диде картый, гамьсез генә.

Иренеп кенә ул урыныннан торды, иренеп кенә казаннан аш бүлеп китерде. Хәмдия, йөрәге әрнеп, караңгы чырай белән бәрәңге суын болгаткалавында булды. Юк, ни генә булмасын, үзләре өендә ул һич тә мондый болганчык су эчәрмен дип уйламаган иде. Хәтта тегендәге кәбестә суы да, юлда авыз итәргә туры килгән башка кәбестә сулары да, бәрәңге сулары да моннан куерак һәм туклыклырак иде бугай. Бөтен илдә ачлык, ялангачлык хөкем сөргәнлеге аның өчен сер түгел иде, ләкин шулай да ул ачлыкны бары иген үсмәгән җирләрдә генә — шәһәрләрдә, Урал якларында — урманнарда, сазларда гынадыр дип уйлый иде.

— Нәрсә, шулай Алла кулына калдыгызмыни, әнкәй?— диде ул, киеренке бер тынлыктан соң.

— Калдык, кызым. Менә шушы көнгә калдык,— диде әнкәсе.— Күрмисеңмени — коры таякка калдык. Яр якасына җиттек инде, аяк сузасы гына калды.

— Нишләдегез? Ни булды?!— диде Хәмдия, ачынып.— Син бит бер дә мондый түгелиең, әнкәй! Каклаган итең дә буладырые, балың да, маең да... Нишләдең, чирләдеңмени? Эшкә йөрер рәтең калмадымыни?

— Белмәссең инде,— диде әнкәсе.— Чирләгәнеңне дә белмәссең — ярым үлек кебек мыштырдыйсың шунда. Эшкә йөрим анысы.

— Мин былтыр тырмага йөрдем, Хәмдия апа!— диде Әлтәф.

— Менә хәзер мин дә йөри башлармын,— диде Хәмдия, әнисен сөендермәкче булып.— И сагындым, әнкәй, басу эшләрен! Тегендә бернинди болын юк, иген чәчкән басу юк. Саз да урман, урман да саз. Җәй дә шунда, кыш та шунда. Тоткындагы кебек.

— Күрә инде адәм башлары,— диде әнисе уфтанып, беркемгә дә карамыйча.— Алда тагын ниләр күрәсе бардыр — бер Алла белә. Менә шушы көнгә калдык, кызым. Сез киттегез дә югалдыгыз. Хат та язмадыгыз. Сезгә рәхәт... ялгыз башка... Менә монда барысы миңа өелеп калды. Җитмәсә, сорап утырган буласың. Күктән төшмәгәнсеңдер ич — күргәнсеңдер, ишеткәнсеңдер...

Аның сүзләрендә, әрнүле, сыкранулы тавышында Хәмдиягә шелтә һәм үпкә сизелде. Үзенә карата белдерелгән бу үпкә һәм шелтәнең хаксыз, урынсыз икәнлеген бик яхшы белсә дә, шулай да ул әнисенә әз генә дә ачулана алмады.

— Әйтеп торам бит, әнкәй, мин анда тоткындагы кебек яшәдем,— диде ул, мөмкин кадәр йомшаграк булырга тырышып.— Анда бернинди авыл юк, колхоз юк. Урман эче. Сазлык. Җәй көне торф чыгардык, кыш көне урман кистек. Эт кермәс, кош җитмәс җир.

— Күрә инде адәм башлары,— диде әнкәе тагын да.— Мин дә шушы көнгә калырмын дип уйламаганыем, кызым. Өйдә күзгә кырып салырлык бер уч он юк. Орлыкка дип калдырылган ике-өч поттай бәрәңге барые, хәзер шуңа тотындык. Менә шулай, кызым. Яшерен-батырын түгел. Каклаган итләр хәзер сагынып сөйләргә генә калды.

— Сыер бозауламадымыни? Мал-туар, кош-корт... исәнме?.. бармы?

— Юк, кызым, берсе дә калмады. Бетте,— диде әнисе әкрен генә, кырые кителгән агач кашыгын ялтыратып.— Быел көз өч тавык белән бер әтәч куйганыем. Бичаракайларым, туңып үлделәр. Ашарларына да булмады, абзар да суык булды. Дүртесе бер көнне үлгән. Утырып җыладым. Кисәк суытты. Кырык биш градуска җиткән диделәр. Бүрәнәләр шартлады. Былтыр көз ике сарыкны ит планына бирдем. Салымга. Калдырмадым. Каравы да авыр. Быел килеп менә сыерга чират җитте. Саклый алмадым, кызым, булмады. Колак кактым... колак кактыгыз, балакайларым! Сыер барында болай ук түге-

лие, акмаса да тамадырые. Бичаракаемның бозавын фермага биргәнием. Пот ярым арышка. Озак тормады — үзеннән дә колак кактым. Саттым. Ит планына, заемга, налукка, страхка... маена, тиресенә түләдем. Барысын да шул каплады. Котылдым бурычлардан.

Хәмдиянең тәмам төсе качты, аптыраудан, коты алынудан авызы ачылып калды.

— Әнкәй!— диде ул тыны бетеп, пышылдап.— Әнкәй, чынмы?!

## IX

Ул төнне беркемнең дә күзенә йокы кермәде. Алар төне буе сөйләшеп, кайгырышып чыктылар. Әнисе сөйләгәннәрне Хәмдия куркыныч әкият кебек тыңлады. Базарда онның поты өч мең ди, бәрәңгенеке биш йөз, алты йөз ди. Кесәдә нибарысы өч сум чамасы акча бар. Ел ярым вакыт эчендә эшләп алган акча. Колхоз күтәрәмдә ди. Җирне сыер белән сөрәләр ди. Басуда утырып калган ашлыкны ашаучылар агуланып үләләр ди. Авылда инде уч-дүрт кеше үлгән. Бәрәңге басуларын актарып бетергәннәр... бер черек бәрәңге табарлык түгел ди...

Туган авылы, туган колхозы тегендә чагында Хәмдия өчен байлык, муллык чыганагы булып, барлык газаплардан, барлык михнәтләрдән котылу урыны булып тоела торган иде. Караңгы төндә такта баракны ташлап чыгып киткән минутта да, баласын кочаклап салкын, шыксыз вокзалларда төн уздырган чакларда да, ашханәләрдә, рестораннарда кешеләрдән калган тәлинкәләрне ялап йөргәндә — һәркайда, һәркайчан туган өе, туган авылы аңа бик еракта җемелдәгән өмет йолдызы булып күренә иде. Авыр юллар, авыр көннәр хәзер инде артта калды, хәзер инде алда юллар да юк, үзенә өндәп җемелдәгән йолдыз да юк. Йолдыз түгел, хәтта тычкан уты да күренми. Ничек яшәргә, ничек җан асрарга болай булгач?

— Әнкәй, Көшләбигә бардыңмы?— диде ул, караңгыда әнкәсенә эндәшеп.

— Бардым. Бетергәннәр. Кемдер җитешкән миңа кадәр,— диде әнкәсе.

— Әнкәй, әйдә икәүләп барабыз. Ындыр табаклары бардыр әле бүтән җирдә.

— Әйбәт булырые да соң,— диде әнисе, теләр-теләмәс кенә.

— Рөхсәт итмиләрмени? Тоталармыни?— диде Хәмдия, сагаеп.

— Әлегә тотканнары юк,— диде әнисе.

Беравык тынып ятты да ничектер шикле итеп, шомлы итеп сорап куйды:

— Син соң, кызым, ничек кайттың?— диде.— Берәр төрле язу беләнме дигәндәй, әллә болай гынамы?

Хәмдия тып-тын калды. Бала кебек бу да аның өчен иң авыр мәсьәлә иде. Авыр гына түгел, томанлы да иде.

Авылдан алар дүртәү киттеләр. Өч кыз, бер егет. Кәримне ике-өч ай эшләгәч тә армиягә алдылар. Мәрхәбә белән Нурия, язга чыгу белән, чыдамыйча качып киттеләр. Ул калды. Ул түзәргә булды. Ул авырлы иде, аның кайтыр юлы болай да киселгән иде. Төптән уйлап караганда, чынында ул качып та кайтмады. Чынында ул үзенекен эшләп, тутырып кайтты. Моннан киткәндә аларны алты айга дип алдылар. Ләкин алты ай эшләгәч, тагын алты айга калдырдылар, көчләп, мәҗбүри рәвештә. Анысын да тутыргач, әйттеләр: сез монда сугыш беткәнче эшләячәксез, диделәр.

Ул үзенекен эшләде. Җәй көне торф чыгарды, кыш көне урман кисте. Кыш көне. Чатлама суыкта, буранда. Кар ярып. Кулларын-аякларын туңдырып. Ирләр аудармастай агачларны аудардылар. Башта авырлы көе азапланды, аннары балалы көе. Җәй җиткәч торфка кудылар. Сазга, черки арасына. Ул үзенекен тутырды. Бише белән тутырды. Аны хәзер беркем дә «эшләмәде» дип әйтә алмаячак. Үзенә тиешлесен ул көн дә бер ярымга, икешәргә тутырып барды. Аның кебек таза, көчле беркем дә юк иде анда. Аңа хәтта ирләр дә көнләшеп карыйлар иде. Ул анда үзен-үзе аямыйча эшләде, аттай эшләде. Ләкин киткән чакта аңа бернинди язу бирмәделәр. Язуны ул сорап та тормады. Шулай туры килде.

— Күңелем сизенгәние лә аны!— диде әнисе, көрсенеп.— Ярый әле башта ук малайны нгытып куйдым сүләнеп йөрмә дип. Нишләрбез инде, кызым?

— Нәрсә «нишләрбез»?— диде Хәмдия.

— Сине әйтәм. Алай качып та кайткач, балаң да булгач, нишләрбез икән димен шул.

— Мин инде күп уйладым, әнкәй,— диде Хәмдия, гамьсез булырга тырышып.— Иртәгәдән кантурга барам, сөйләп бирәм барысын да. Эшкә йөри башлыйм. Баланы син карап торырсың. Нинди эшкә кушсалар, шуңа. Сагындым, әнкәй. Ни әйтсәң дә, ударник Хәмдия бит әле мин! Ни әйтсәң дә, үз авылым, үз колхозым.

— Белмим шул,— диде әнисе.

— Нурия белән Мәрхәбә кайтып җиттеләрме соң? Алар нишләде икән?— диде Хәмдия.

— Кайттылар,— диде әнисе, авыр гына.— Синең ту-

рыда сораштырыйм дип барганыем, туры китерә алмадым. Алып киткәннәрие.

— Кая?

— Кая булсын — Яңавылга! Җиде елга утырттылар бичаракайларымны.

— Җиде елга?!

— Җиде елга,— диде әнисе.— Карт башыма ялганлап ятар хәлем юк: җиде елга.

— Алар эштән качтылар, эшлиселәре килмичә!— диде Хәмдия, үртәлеп.

— Син нәрсәдән качтың соң, кызым?— диде әнкәсе.

## X

Шулай итеп, көтелгән оҗмах көтелмәгән тәмугка әйләнде. Бала мәсьәләсе, бала хурлыгы рәхимсез чынбарлык каршында бик кечкенә булып калды. Бер көн эчендә бер-бер артлы ишелеп төшкән коточкыч яңалыкларга, шулай итеп, тагын бер яңалык өстәлде. Монысы да шулай ук искәрмәстән ишелеп төште, күмеп китте, изеп ташлады һәм бәхет, куаныч турындагы татлы хыяллар мәңге упкынга атылды.

Инде нишләргә хәзер? Туктале, чынлап та нишләргә соң хәзер? Күрәләтә башыңны төрмәгә илтеп тыгаргамы, әллә соң әнкәсе әйткәнчә, сугыш беткәнче өйдә качып ятаргамы? Ярый ла сугыш тиздән бетсә! Быел көзгә, кышка бетмәсә, ничек түзәргә? Гомумән, мөмкинме ул өйдә качып яту? Таза баштан, бер гаепсез көйгә... карак кебек... үз өеңдә, үз авылыңда качып яту мөмкинме ул?! Тирә-якта күршеләр бар, өйдә балалар бар. Берсе кермәсә икенчесе керер, берсе күрмәсә икенчесе күрер. Хәмдия качып кайткан, диярләр, өендә яшеренеп ята икән, диярләр. Кайсы Хәмдия? Соң теге ... сугыш алдыннан Мәскәүгә күргәзмәгә барам дип масаеп йөргән Хәмдия! Бичаракаем, күрә инде адәм башлары, диярләр. Аны бит уйнаштан тапкан баласы белән кайткан дип сөйлиләр, диярләр.

Менә ул кайда мәсхәрә, менә ул кайда хурлык!

Ләкин хурлыктан да зуррак, хурлыктан да яманрак иконче бер нәрсә бар. Ул да булса — балаң белән, карт анаң белән, бөтен өй эче белән ачтан үлү куркынычы. Бетеп беткән бер әнисе ничек туйдырсын аларны?!

Шулай да бернәрсә дә эшләп булмый микәнни соң? Юк, нәрсәдер эшләргә кирәк. Качып ятарга ярамый! Таза баштан, бер гаепсез көе...

Хәмдия төне буе уйланып чыкты.

Таң алдыннан аны йокы басты. Урам якта ниндидер

шакылдавык тавышы ишетеп, кисәк кенә уянып китте. Тавышка әнисе дә уянды һәм йокылы күзләрен кочкә ачыштырып, битенә төшкән чәч бөртекләрен сыпырыштырып тәрәзә янына килде.

«Алырга килделәрме әллә?»— дип уйлады Хәмдия телсез-өнсез калып.

— Камиләттәй! Камиләттәй!— дип кычкырды тышта нindидер таләпчән хатын-кыз.

«Кем соң әле бу?— диде Хәмдия, үзалдына.— Тавышы таныш. Тукта, Факия түгелме соң? Кара, нинди кычкыра? Гомергә Факия дип уйламассың».

— Тәмле йокы вакытында килә дә уята шул нәрсә,— диде Камиләттәй, үзалдына сукранып.

«Бригадир микәнни?— дип уйлады Хәмдия.— Исең китәр — ялкау Факия бригадир булган, имеш».

— Нәрсә бар, ни булды, Факия?— диде Камиләттәй.

— Хәзер үк киен, амбар алдына бар,— диде Факия.— Капчык алырга онытма. Яңавылга барачаксыз.

— Яңавылга? Бүәгә күпер салынмаган диләр бит әле, Факия.

— Күпер салынганны көтеп ята торган чак түгел. Кимә белән чыгарсыз. Ике тәңкә акча да алыгыз... кимәчегә. Баруына-кайтуына.

— Белмим шул, Факия,— диде Камиләттәй, теләмичә генә.— Нәрсә алып кайтырга соң?

— Бодай алып кайтырсыз. Чәчү орлыгы. Кеше башына җегерме кила. Бездән ун кеше бара.

— Җегерме кила!— диде Камиләттәй, шаккатып.— Беткәнмени яшьләр? Шул тикле җирдән... җегерме кила ашлык күтәреп... Аяк атлар хәлем дә юк, Факиякәем.

— Кеше юк,— диде бригадир.— Яшьләр дә бара, картлар да: Газимәләр, Санияләр, Хәким кызлары... Атларга салгашып ята торган заманнар узды инде, үзең беләсең. Ул җирне чәчми калдырыйкмыни? Кичәгенәк Яңавылдан хәбәр алынды: бер көн эчендә ташып бетерергә дигәннәр. Хөкүмәткә рәхмәт инде, иптәш Сталинга — ул бирмәсә, каян алырыең бу вакытта?!

— Рәхмәт инде, рәхмәт,— диде Камиләттәй ашыгып, ярарга тырышып.

— Күп сөйләнмә, хәзер үк киен,— диде Факия нык итеп.

— Һай Алла, бер дә хәлләрем юк бит әле, Факиякәем,— диде Камиләттәй, нишләргә белмичә.— Ничек соң, ичмасам, бераз он-фәлән бирмиләрме... аяк ялына булса да?

— Булыр, диделәр. Кеше башына ике йөз грамм он булыр, диделәр.

— Бигрәкләр юк икән шул,— диде Камиләттәй.— Ярар, барырмын инде алайса. Аяк атлар хәлем дә юк шул, Факиякәем.

— Менә минем дә аяк атлар хәлем юк — шулай да йөрергә туры килә,— диде бригадир һәм амбар янына хәзер үк барып җитү турында тагын бер мәртәбә кисәтте дә китеп барды. Ләкин бераз җир киткәч, нәрсәдер онытып калдырган сыман, кире борылды, яңадан тәрәзә каршысына килде.

— Карале, Камиләттәй!— диде кычкырып.— Кайтканда кесәгезгә-нигә сала күрмәгез. Бодае агуланган. Аннары, тотыла калсагыз...

— Аллам сакласын!— диде Камиләттәй.— Бөртеге дә кирәкми. Безгә харам мал килешәмени?! Ачтан үлсәм үләрмен, кешенекенә кул сузмам.

Факия китеп баргач, ул лып итеп урынга утырды һәм ябык кулларын тез өстенә салган килеш аптырап тынып калды.

— Яңавылга түгел, теге очка барып кайтканчы да аяк буыннарым калтырый,— диде ул, үзалдына сөйләнеп.— Сигез чакырым бит әле ул. Барасы, кайтасы белән уналты чакырым. Тау менәсе, тау төшәсе. Җитмәсә, кесәңнән ике тәңкә чыгарып түлә!

— Әнкәй, синең өчен үзем барыйм микән әллә?— диде Хәмдия, башын калкытып.— Үзем теләп эшләп китсәм... кайткач та кеше күзенә күренә башласам?..

Камиләттәй корышкан куллары белән битен сыйпап, алды һәм авызын кыйшайтып җыламсырагандай итте.

— Күрсәттеләр болар безгә... картаймыш көнемдә...— диде.

— Әнкәй, чынлап, барыйм әле үзем?— диде Хәмдия дәртләнеп, урыныннан торып.

— Рәхмәт, кызым,— диде әнисе, коры гына.

## XI

Камиләттәй шулай бер урында һушы китеп утырды-утырды да, аякларын көчкә кузгатып, тышка чыгып китте, утынлыктан чыбык-чабык алып керде һәм көндәгечә казан астына ягып җибәрде. Бераздан Әлтәф тә сикереп торды.

— Улым, бар әле су алып кайт,— диде картыйсы.

Малай, битен дә юып тормыйча, ашык-пошык чыгып та китте.

— Ярый әле бу бала бар,— диде Камиләттәй, Әлтәф чыгып киткәч.— Ул да булмаса, нишләриең? Чишмәдән кайтканда тыным кысыла, аяк буыннарым калтырый.

Әлекке әнкәң юк инде ул хәзер, кызым. Сезнең кайгыдан агармаган чәчләрем агарды, саргаймаган йөзләрем саргайды. Зарифҗанымны исән-сау күрсәм, инде үлсәм дә үкенмәм.

Ул әле һаман тынычлана алмаган иде, ул әле һаман да күңеленнән ярсый, үртәлә иде, ләкин шул ук вакытта аның эчендәгесен тышка түгәргә дә әлләни теләге юк иде шикелле. Бәрәңге пешеп чәй кайнагач һәм барысы да өстәл тирәсенә җыелгач, ул бөтенләй юашланып калды.

— Ике йөз гырам он бит әле ул, кызым!— диде Хәмдиягә аңлатып, үзенчә бик канәгать төс белән.— Ике йөз гырам күктән яумый хәзер. Җылап эзләсәң да табалмыйсың аны. Атлар, бичаралар, аякларына да басалмыйлар. Дөрес сүзгә җавап юк — җирне шул көе калдырасыңмыни?! Ярар, Аллага тапшырдык, балалар.

Иртәнге ашыннан канәгатьлек белдереп, ул амин тотып куйды, яулыгын рәтләде дә юлга әзерләнә башлады.

— Әнкәй, Әлтәфне иярт, ичмасам,— диде Хәмдия.— Икегезгә бүлеп күтәрерсез.

— Ярар, шулкадәр җиргә бала интектереп йөрисем генә калды!— диде әнисе, кинәт ачуланып.

Үзе югында нишләргә кирәклеге турында киңәшләр бирде дә, үзе өчен кайгырмаска, борчылмаса кушты да, кичәгенәк Көшләбигә алып барган капчыгын биленә кыстырып Камиләттәй амбарга китеп барды. Хәмдия аны тәрәзәдән карап калды. «Нинди беткән! Нинди беткән!» — дип уйлады ул, әнисенең ничек атлавына игътибар итеп.

Картыйсы китеп күп тә үтмәде, Әлтәф тә мәктәпкә җыена башлады. Ул киткәч, Хәмдия улы белән өйдә үзе генә калды. Аның бернәрсәгә кулы бармады, бернәрсәгә күңеле бармады. Бер дә юктан ул үзен монда чит итеп, кирәксез һәм ни өчендер гаепле итеп сизә башлады. Бераздан аны тиктомалга курку-өркү биләп алды. Кемдер көтмәгәндә килеп керер дә, йөзен җыртып, «Менә тотылдыңмы?!»— дип кычкырыр шикелле тоелды.

Укырга киткәндә Әлтәф ишекне тыштан йозак белән бикләп киткән иде. Аңа гына ышанмыйча Хәмдия чолан ишеген дә, өй ишеген дә эчтән бикләп куйды, әледән-әле урам якка, ишегалды ягына карап-карап алды. «Йа раббым, үз өеңдә үзең куркып яшә икән!» дип уйлады ул әледән-әле, үзенең мондый хәленнән чиксез уңайсызланып.

Баласын кочаклап ул тәрәзә янынарак килеп утырды. Менә капчык тотып урамга Газимә дә чыкты. Аның артыннан диярлек Шакир бичәсе күренде. Болар әллә ни ашыкмыйлар. Аның әнкәсе барысыннан алданрак кузгалды. Ул һәрвакыт шундый булды. Үлмә хәлендә дә

аяк өстендә, эштә, кырда-басуда булды. Ул һәрвакыт шундый. Аларның заты шундый.

Капчыклы хатыннар күздән югалгач, елга буенда, ат фермасында да хәрәкәт башланды. Ат караучыларның кем беләндер кычкырышканнары ишетелде, ат чакырганнары ишетелде. Кемдер янбаш сөякләре очлаеп торган ябык сыерын җитәкләп түбән очка таба юнәлде. «Шәрифә ахрысы»,— дип уйлады Хәмдия. Дөрес икән, чыннан да сыер белән сөрәләр икән. Бичараның муенына камыт кидергәннәр, сыртына ыңгырчак салганнар. Ферма утарында биш-алты аттан башка берни күренми. Алары да селтәр генә.

Озакламый урамда басу якка таба кыймылдаучы көтү күренде. Сыер, сарык бер көтүдә. Алар да кешеләр кебек, атлар кебек, хәлсез, ябык күренәләр. Бөтенләй тавыш-тынсыз диярлек өй турысыннан шыбырдашып уздылар да ары китеп күздән югалдылар. Бары тик көтүче малайның «Чыгарың!»— дип кычкырган моңсу тавышы ишетелде дә кайдадыр авыл читендә эт өргәне ишетелде.

## XII

Хәмдиянең котын алып, җанын өшетеп, күңеленә әледән-әле дәһшәтле сораулар килде.

Нишләргә? Ничек яшәргә, ничек җан асрарга да ничек балаңны карарга?

Көн дә шулай була торган булса, нишләргә, ни кылырга, Ходаем?

Әнисенең сүзләренә ышанмаска аның хакы юк. Ул сиңа юри әйтмәс. Шулай булгач кеше күзенә күренү турында, колхоз председателенәме, авыл советынамы барып ялыну турында уйларга да мөмкин түгел. Шулай булгач аңа чыннан да... качып, яшеренеп ятарга гына кала. Ләкин ничек торырга, нәрсә белән туенырга? Карт анаңның соңгы сыныгына өлешкә кереп, әрәмтамак булып күпме яшәргә? Таза баштан, бер гаепсез көе...

Әллә соң сиздермичә генә кире тегендә китеп барыргамы? Эше таныш, җире таныш, кешеләре таныш.

Ләкин анда яңадан эшкә алырлармы? Качып киткән өчен судка бирмәсләрме? Бирмәгән кая ул! Бер көн эшкә чыкмаган өчен дә удмурт малае Илчебайны өч елга хөкем иттеләр. Бер көн өчен өч ел. Бер ай өчен күпмегә утыртырлар? Бер көн өчен өчәр ел бирсәләр, бер ай өчен гомереӊ буе төрмәдә черерсең. Аннан соң... баланы нишләтергә? Аны монда калдырып булмый. Ул монда юкка чыгачак. Монысы инде көн кебек ачык. Шуның өстенә

ул монда карт анаңа чиксез авыр йөк һәм газап булачак. Шулай ук аны тегендә дә алып китеп булмый. Ул анда да юкка чыгачак.

«Әллә бөтенләй икенче бер җиргә китеп барыргамы?» — дип уйлады ул бераздан, үзенең хәленә башка яктан карарга тырышып. Илдә чыпчык үлми. Берәр җиргә эшкә керер иде. Ләкин тагын шул ук балык башы: язу юк. Язусыз кем сине эшкә алсын?! Кайда да язу кирәк, паспорт кирәк. Аның берние дә юк. Тегендә аларга паспорт бирмәделәр. Паспорт булса кеше тизрәк качу ягын карый. Авыл советы биргән язу да аларда калды.

Шулай булгач... шулай булгач аңа кайда да юл юк. Кайда да төрмә.

Төрмә...

Ул инде күрде. Чын төрмәне күрде. Үз күзләре белән. Көн саен. Тегендә, урман эчендә. Аларның бараклары янында гына, йөз метр чамасы җирдә генә... биек койма белән, тимер чыбыклар белән уратып алынган төрмәне күрде. Аларның барагы да башта төрмә өчен салынган булган. Ләкин нишләптер анда менә аларны китереп тутырдылар. Барысы да авылдан, барысы да юаш. Татар, удмурт, мари, мукшы... Ни кушсаң шуны эшлиләр, кая кусаң шунда баралар. Барысы да диярлек хатын-кыз. Ир затыннан ике-өч бүлтерек тә, солдатка ярамаган гарип-гораба. Күршедә, тимерчыбык артында — барысы да ирләр. Эшкә еш кына янәшә атлап бардылар. Ирекләр аерым төркем-төркем булып бара, алар — җыелып, команда белән. Алдан, арттан сакчылар бара. Яннан да сакчылар. Бүре чаклы этләр белән, автоматлар белән. Барысы да ябыклар, хәлсезләр. Коры сөяк тә тире. Аякларын көчкә өстериләр. Чыкмаган җаннары гына. Урман кисәләр, вагоннарга бүрәнә төйиләр. Баракларын җылытырга үзләре йомычкалап утын ташыйлар. Куеннарына тыгып, күрсәтмичә. Койма почмакларында, каланчаларда төне буе ут яна, автомат белән сакчылар йөренеп тора. Төннәрен шарт-шорт аткан тавышлар ишетелә. Барактагы кызлар котлары алынып уяна торганнар иде. Иртән, томанланып торган чатлама суыктан, чанага салып биек капкадан үлекләрне алып чыгалар. Таш булып, агач булып каткан, башларында чәчләре җилфердәп торган кешеләрне ... ничек туры килә, шулай салып... өсләренә чыбылдык та япмыйча... туп-туры бараклар арасыннан, котлары алынган хатын-кызның күз алдыннан... шыгырт-шыгырт алып китеп баралар. Аларны кайдадыр урман эчендәге тирән чокыргамы, сазгамы илтеп ташлыйлар икән дип сөйлиләр иде.

Менә шундый андагы төрмә. Үз күзләре белән күрде. Инде тагын күрергә язармы? Тфү-тфү, шайтан колагы саңгырау булсын!

## XIII

Камиләттәй Яңавылдан кичкә таба гына кайтып җитте. Ишектән керде дә ян сикегә ауды.

— Картый үлгән!— диде Әлтәф һәм кычкырып җыларга тотынды.

Хәмдия тиз генә әнисенең изүен, яулыгын чишеп җибәрде, биленә буган капчыгын чиште.

— Үлмәдем әле, балалар,— диде Камиләттәй, күзләрен ачкандай итеп.

Шуннан башка ул бүтән берни дә әйтә алмады — башын артка ташлап, кулларын, аякларын хәлсез салындырып, как сикедә хәрәкәтсез ята бирде. Хәмдия түр сикегә тиз генә урын җәйде, әнисенең өстен чишендерде дә күтәреп диярлек аны урынга яткырды.

— Әнкәй, бәгърем, нишләдең?— диде өзгәләнеп.

Ул аның кан тамырларын тотып карады, әле күкрәгенә, әле йөзенә колагын куеп тыңлап карады, хәрәкәтсез калган аякларын, кулларын сыйпалады. Кисәк курку аның башына чыкты. Әнисе чыннан да үлгәндер шикелле тоелды.

— Әнкәй! Ач күзеңне, әнкәй!— диде ул, нишләргә белмичә.

— Кызым, синмени?— диде бераздан Камиләттәй.— Чәй бир... кайнар чәй.

Хәмдия, күзенә ак-кара күренмичә, җилтерәтеп сикедән җиз самавырны алды, өстендәге тузанын өрде дә шап итеп идәнгә, мич алдына утыртты, шаулатып су салды, күмер салды. Күп тә үтмәде, күңелсез өйгә җан кертеп, самавыр гөрләргә тотынды. Беркадәр тынычлангандай иткәч, Камиләттәй яңадан күзләрен ачты, тормакчы булып башын калкытты. Хәмдия шундук аның янына килеп җитте — ике куллап тотты да урынга утыртты, утырырга җайлы булсын өчен аркасына мендәр кыстырып куйды.

— Баш әйләнә,— диде әнисе.

Озакламый чәй дә кайнап чыкты. Хәмдия тиз генә әнисенә кайнар чәй китерде. Карагат яфрагы, мәтрүшкә, бөтнек кебек үләннәр, яфраклар катнаштырып киптерелгән чәй эчкәч, Камиләттәйнең йөзе яктырып китте.

— Ярый әле син бар, кызым,— диде ул, беренче сүзе итеп.— Рәхмәт. Болай булгач рәтләнермен инде.

— Алып кайттыгызмы соң?— диде Хәмдия.

— Кайттык,— диде Камиләттәй.— Бөртекләп тутырдык, кызым. Кимә тоткарлады. Шунда вакыт үтте. Чәчәрбез, иншалла. Җиркәй кысыр калмас. Бөртеген дә калдырмадык.

— Картый, Хәмдия апа! Әйткәние диярсез — быел сугыш бетә!— диде Әлтәф кинәт кенә, утыра торгач. Күрәсең, аның да олылар сүзенә катышасы килә иде.

— Син нәрсә... каян ишеттең?— диде Хәмдия, каушагандай итеп.

— Рәхмәт яугыры,— диде картыйсы, Әлтәфне мактап.

— Ишеттем инде,— диде малай.— Баягынак Матнур бабай әйтте. Безнекеләр кичә Севастопольне алганнар. Куалар Гитлерны! Телефоннан наушниктан тыңлаганнар. Матнур бабай әйтте: быел көзгә сугыш бетәр, диде.

— Ә-ә, алай икән,— диде Хәмдия, мәсьәләгә төшенеп.— Чынлап әйтәләрме әллә дип торам.

— Нишләп чынлап әйтмәсен, чынлап әйтте!— диде малай.— Матнур бабай кантурда ишеткән. Авыл буенча ялган таратып йөрмәс инде.

Алар шулай сөйләнгәләп утырганда, кемдер килеп, иртәнге кебек урам як койманы шакылдата башлады.

— Камилә! Камилә килен!— дип кычкырды ниндидер ир кеше.

— Әнә ич Матнур бабай!— диде Әлтәф, урыныннан сикереп торып. Ул тиз генә тәрәзә каршысына килде.— Нәрсә, Матнур бабай? Нәрсә бар?— диде.

— Камилә килен!— диде шул ук ирләр тавышы ашыкмыйча гына, шулай да таләп итеп.— Кантурга чакыралар. Яңавылдан кеше килгән. Заем хакында. Хәзер үк килергә куштылар, Камилә килен!

— Ярар, барырбыз!— диде Әлтәф картыйсы өчен, бар тавышына кычкырып.

— Кат-кат әйттермәгез, килен. Барып кайтырга кирәк,— диде Матнур бабай, һаман китәргә җыенмыйча.— Миннән әйтү, сездән бару, Камилә килен.

— Ярар, ярар!— диде Әлтәф.

Матнур бабай «килен»енең барырына шулай да ышанды бугай — бүтән кычкырмады, өрәк кебек тавыш-тынсыз гына күршеләр ягына китеп барды.

— Әнә Матнур бабаңның хәбәре!— диде Камиләттәй Әлтәфкә.— Туксан ике тәңкә түлисем калганые. Өстә һаман бурыч булып тора. Болай гына булса да барып кайтмый булмас.

— Барырсың менә!— диде Әлтәф, картыйсына кычкырып.— Күзен дә ачалмый утыра үзе. Барырсың менә!

— Бармый ярамас шул, улым,— дигән булды картый-

сы көндәм генә.— Бармасаң тагын килеп җитә инде ул. Дуамалга кеше интектереп йөрү дә эш түгел. Әлерәк кенә чакыртканнарые да соң, бер атнадан акчаңны әзерләп тор дигәннәрие. Бурыч бит, барып күренми ярамас.

— Иртәгә барырсың, әнкәй,— диде Хәмдия дә, киңәш итеп.— Миндә бераз акча бар — илтеп бирерсең.

Ләкин мондый сүз ишеткәч, Камиләттәй чын-чынлап җанланып китте.

— Һай, кызым! Шул туксан ике тәңкәне каян алыйм икән дип башым катты. Илтеп түлим тизрәк. Өннәре тыгылсын,— диде ул урыныннан торып.— Котылыйк, кызым. Өстә бурыч булып тормасын. Хәл керде инде.

Мыштырдап кына ул өстенә киенә дә башлады.

— Мин дә синең белән барам!— диде Әлтәф, еларга җитешеп.— Үзеңне генә җибәрмим. Әнә шундый инде ул, Хәмдия апа, һич кеше сүзен тыңламый.

## XIV

Өйгә кайтканнан бирле баланың рәтләп тамагы туймады. Ана кешенең бөтенләй диярлек сөте юкка чыкты. Күкрәккә кушу белән бала шундук комсызланып имәргә тотынды, ләкин шундук үртәлеп, ачуланып «имезлеген» ташларга мәҗбүр булды. Аптырагач Хәмдия бәрәңге суы биреп карады, ләкин ят азыкны Ирек яратмады. Бала күзгә күренеп начарланды. Аның хәзер җылавы да җылауга түгел, хәлсезләнеп шыңшуга, ыңгырашуга охшап калды.

Үзенең куркыныч хәле турындамы, әнисе турындамы, әллә баласының күз алдында әкренләп үлә баруы турындамы — Хәмдия нәрсә турында кайгырырга да белмәде. Бер кеше өчен бу күп иде, чамадан тыш күп иде. Шулай да аның өчен иң якыны, иң газизе бала иде. Төрлечә уйлангач, ул бер карарга килгәндәй булды. Икенче көнне әнисе белән аның арасында шундыйрак сүз ялганып китте.

— Әнкәй, карале,— диде Хәмдия,— минем сырмага күпме бирерләр икән?

— Нинди сырма?— диде әнисе.

— Тегеннән киеп кайткан сырма соң. Ничә литр сөт бирерләр икән шуңа?

Әнисе аңлап алды, берни әйтмичә чөйдәге сырманы кулына алды да аның эчен-тышын әйләндергәләп карады, кесәләрен актарды. Сырма яңа иде, юлда кайтканда бераз керләнгән генә иде.

— Бигрәк җиңел. Мамык белән сырган бугай,— диде әнисе, сырманы мактап.

— Мамык белән,— диде Хәмдия.

— Әрәм инде сатсаң да,— диде әнисе.— Сөт дип... кем сиңа сөт кенә бирер икән хәзер?

— Әрәмен әрәм дә, нишлисең?— диде Хәмдия уйчан гына.— Балага сөт кирәк. Ашата башларбыз. Болай булмый, әнкәй.

— Бүтән нәрсәң юкмы соң?— диде әнисе, сырманы кызганып.

Хәмдия әнисенең тел төбен бик яхшы сизенде. Өченче көнне дә ул сырманы мактый-мактый караштырып торган иде. «Бүтән нәрсәм бар соң кирәкмәгән?»— дип уйлады ул, күңеленнән кием-салымын барлап. Күлмәкнең рәте юк. Аякка киеп кайткан ирләр ботинкасы да сырган чалбар кала. Анысы да ирләрнеке. Урман кискәндә биргәннәр иде. Ләкин алары искерәк шул.

— Ярар, әнкәй сиңа булсын сырма,— диде ул, тәвәккәлләп.— Җылы өстеңдә тузсын. Рәхәтен күр. Мин инде сырган чалбарлар, ботинкалар киеп йөрмәм — шуларны сатарбыз.

— Рәхмәт яусын инде, кызым,— диде әнисе, балаларча куанып.— Саклап кына тотармын инде, кадерен белеп кенә. Өстемә бернәрсәм калмады бит, кызым, кеше арасына чыгарга оят.

— Ник сакларга? Киярсең, әнкәй,— диде Хәмдия.

— Белмим шул, кызым,— диде әнисе, кинәт сүрелеп.— Белмим шул. Дөньялар иминләнмичә киеп булыр микән? Күрсәләр шикләнүләре бар.

Хәмдиянең шундук йөзе караңгыланып китте. Бала онытылды, әнисе онытылды һәм йөрәкне урталай ярырдай булып бөтен дәһшәте белән икенче бер хакыйкать килеп басты.

— Юкка куркасың син, әнкәй!— диде ул, ачынып.— Котың алынып беткән синең. Үз киемеңне үзең киеп йөрергә дә куркып яшә икән! Нинди тормыш бу?! Нинди замана бу?! Менә күрерсең, хәзер үк урамга чыгып китәм, хәзер үк кантурга барам, фермага төшәм! Нинди эш бу?! Сабый балам белән ачтан үләргә тиешмени мин?!

— Кызмале син,— диде әнисе, ачусыз гына.— Өй турысыннан кеше узган чак булыр.

— Булсын!— диде Хәмдия, ярсып.— Узсын, теләсә кем узсын!

— Яңавылга барсаң он-фәлән алып кайтырга булырые да, юлга чыгарга йөрәгем җитми,— диде әнисе, тыныч кына.— Кем алыр икән соң боларны? Мәликә корткага барып карыйм микәнни?

— Теләсәң кемгә бар, әнкәй,— диде Хәмдия, басыла төшеп.— Сөт сора, сөт... Балам бетә, балакаем бетә бит, әнкәй!

## XV

Мәликә кортка әйберләрне теләмичә генә алды, кирәкми, диде, иске, диде. Ялына торгач шулай да риза булды. Алып барган әйберләр өчен «кызганып» бер пот бәрәңге, биш кадак он һәм бер литр сөт бирде.

Кичен ярлы өйдә ярлы гына, тыйнак кына бәйрәм булды. Бу бәйрәм күбрәк балаларга кагылды. Күңеле күтәрелеп киткән Әлтәф картыйсы белән Хәмдия апасына көндәгечә сугыш яңалыклары сөйләде һәм кичәге хәбәренә үзенчә төзәтмә ясап, сугыш быел көзгә дә калмас, җәй урталарына бетәр дип куйды. Ирек җылыткан сөтне яратып эчте һәм тамагы туйгач кинәт кенә үзгәреп китте: көлде, «әннә», диде, «мәммәм», диде, кулларын бутап, идәнгә төшәргә сорады.

Балаларның куанычы олыларга да йокты. Ашап туйгач алар, өстәл яныннан кузгалып китәргә иренеп, канәгать бер кыяфәттә елмаешып балаларны күзәттеләр.

— Менә ул кемнәр яши!— диде Камиләттәй, үзалдына сөйләнеп.— Барып кердем өйләренә — яңа пешкән ипи исе чыккан. Сикедә ипи, өстәлдә ипи. Күзгә алучы да юк. Мәликә кортка ашамый, кем ашасын? Факиясе бригадир, чулак малае амбарда эшли, ире — ат караучы. Менә шуларны утыртыргае да төрмәгә, юк — көчленеке замана.

— Сөйләмәле, әнкәй, шул төрмәләр турында,— диде Хәмдия, чырае бозылып.— Болай да инде... Дошманыңа да күрсәтмәсен диген.

— Дошманыңны да утыртмагач, ник ясаганнар аны?— диде Камиләттәй.— Син менә монда ачка шешенеп ят, ул анда калхузныкын урлап баеп ятсын — алай да тигезлек түгел шул, кызым.

— Шулаен шулай да...— диде Хәмдия, килешкән сыман итенеп.

Шуннан башка ул төрмәләр турында сүз озайтып тормады. Хәзер аның бәхәсләшәсе дә, зарланасы да килмәде. Аның шулай тыныч кына, оеп кына өстәл янында балаларга карап утырасы килде. Бер уйлаганда, адәм баласына әллә ни күп тә кирәкми инде. Өстәл янына утырган саен көн дә шулай тамагың туйганчы ашый алсаң, көн дә шулай аяк астында куанышып балаларың уйнап йөрсә, шуннан башка тагын ни кирәк? Һәрвакыт шулай булсачы!

Ләкин һәрвакытта да алай була алмады шул. Ярлы өйдәге ярлы бәйрәмнәр тиз арада юкка чыкты. Базда бары орлыкка дип кадерләп саклаган, уршып беткән, үреп беткән өч-дүрт бидерә чамасы бәрәңге калды да өй эчендә һич туя белми торган олы-кече өч-дүрт тамак калды.

Ул көнне Әлтәф укырга кайнар су гына эчеп китте. Бер-ике сәгать үтмәде, ашыйсы килә дип, баш әйләнә дип кире кайтты. Ирек исә әнкәсенең буш янчыкларын суырды-суырды да, берни килмәгәч, гадәтенчә җыларга тотынды. Бик озак җылады — әле усалланып таләп итте, әле хәлсезләнеп үксергә тотынды, әле күзләрен ярым йомган килеш, ярым йокыга киткән килеш, уймак кадәр иреннәрен чупылдатып-чупылдатып алды.

Хәмдия нишләргә, нәрсә кыларга да белмәде. Ул акылдан шашуга якын бер гамьсезлек һәм өметсезлек кичерде. Эчтән аның йөрәгенә кан сауды, күкрәгендә ялкын дөрләде, тау-ташлар актарылды, тыштан исә ул катып калган шикелле күренде.

Ул бернәрсә дә эшли алмады. Улына да, Әлтәфкә дә, әнисенә дә берничек ярдәм итә алмады. Үзе турында ул уйламады да.

— Туктале, кантурга барып карыйм әле булмаса,— диде Камиләттәй, үзенчә бер фикергә килеп.

— Барып кара,— диде Хәмдия, дәртсез генә.

Камиләттәйнең кантурга барганы бар иде инде. Көн саен бармаса да, атна саен бара иде. Әмма монысында ул иң соңгы өметләр белән, иң изге догалар белән китте. Ләкин дога да, берни дә ярдәм итмәде. Гадәттәгечә, көченнән килмәде. Колхоз идарәсендә җавап кыска булды: юк, берни юк, диделәр.

Камиләттәйнең кире өйгә кайтасы килмәде. Сөмсере коелып, күңеле кырылып ул шунда идарәгә җыелган хатын-кыз арасында таптанып тик торды. Шулай тора торгач, үзе өчен бер яңалык белде.

— Түбән очлар элмә кабыгы ашыйлар икән,— диде ул өйгә кайткач.— Мин дә барып карыйм әле.

— Бар, әнкәй,— диде Хәмдия, дөньядан ваз кичкән бер гамьсезлек белән.

Камиләттәй кулына балта алды, Әлтәфне ияртте дә урманга китте. Бер-ике сәгатьтән алар чыбыклары боталмаган яшь элмә агачлары өстерәп кайтып та җиттеләр. Агачларны кискәләп туп-туры өйгә алып керделәр, җыйнаулашып кабыгын телделәр, вакладылар. Юдылар да казанга салдылар.

Элмә боткасы бик озак пеште. Кайный-кайный чыннан да ботка сыман аксыл нәрсәгә әйләнде. Ләкин ул ботканы ашап карагач, лайлалы кабык тәменнән башка бернинди туклыклы тәм килмәде.

— Кеше белми ашамыйдыр әле,— диде Камиләттәй, балаларның күңелен күтәрмәкче булып.

«Элмә кабыгын бәрәннәр дә ашый бит... сарыклар

да...»— дип уйлады Хәмдия, үз-үзен ашарга мәҗбүр итеп. Алар ашагач, ник кеше ашамаска тиеш? Барыбер тамак, барыбер җан иясе.

## XVI

Әлмә боткасы ашалды, әмма кешеләрне ачлыктан коткара алмады. Кичкә Камиләттәй орлык бәрәңгесен алып чыкты. Бәрәңге пешкәнче беркем берни сөйләшмәде. Һәркем түземсезлек белән казан ягына караштырды. Хәтта Ирек тә, олыларның хәлен аңлагандай, шыңшуыннан туктап торды. Хәер, аның инде тавыш чыгарырлык хәле калмаган иде. Ул, әйтерсең, бары әнисенең тән җылысы белән генә җан асраштырып тора иде. Әмма олылар өстәл янына җыелгач, бала шыңшырга тотынды.

— Хәзер, улым, хәзер,— диде яшь ана.

— Үлсә, ичмасам, оҗмах кошы булырые,— дип куйды шул чакны Камиләттәй.

Бу ничектер бөтенләй көтмәгәндә, уйламаганда әйтелде. Хәмдия яшен суккандай калтыранып китте. «Карале, нинди дошман икән бу әнкәй! Юри генә яраткан булып кылана икән баланы»,— дип уйлады ул, күңеле өшеп.

— Син нәрсә... әнкәй... уйнап сөйлисеңме, уйлапмы?— диде ул тыелып кына, ләкин усал һәм явыз итеп.

Өйгә кайтканнан бирле бу аның әнисенә беренче мәртәбә каты орынуы булды.

— Шулкадәр газапланганчы...— диде әнисе, ачу китергеч бер гамьсезлек белән.

— Әнкәй, ишетсен колагың, икенче әйтәсе булма!— диде Хәмдия, бурлаттай кызарынып.

— Күз алдында үлеп бара бит сабыкаем,— диде әнисе...

— Әнкәй!— диде Хәмдия.— Әйтмә! Әйтмә шул сүзне!

— И, кызым,— диде әнисе.— Үлсә, ичмасам, котылырыең. Ничек күмәрбез — менә шул турыда кайгырам мин.

— Әнкәй!— диде Хәмдия, тагын да дәһшәтлерәк итеп.— Кансыз! Оятсыз! Шул сабыйны... бичараны... ничек? Ничек?..

Әйтәсе килгәнен әйтергә ул сүз тапмады, сүздән бигрәк көч-куәт тапмады. Кинәт килеп койган яңгыр булып, кинәт ишелеп төшкән кыя булып күңеленә ярсу һәм тилелек килеп ябырылды. Баласын кочаклады да, урыныннан атылып торды да, тыелудан тәмам тәкатьсез ка-

лып, читлектәге җанвар сыман, әрле-бирле идән буйлап йөренергә тотынды.

«Юк, юк, болай булмый! Булмый!— диде ул үз-үзенә, күз яшьләренә буылып.— Мөмкин түгел. Туйдым-җиләдем... Җитәр! Ярамый болай. Нәрсәдер эшләргә кирәк. Нәрсәдер уйлап табарга кирәк!»

— Ярар, утыр инде,— диде әнкәсе юаш кына, иплә кенә.— Аптыраганнан әйтәм, кызым. Утыр, аша. Аптыраганнан...

— Хәмдия апа!— диде шул чакны Әлтәф.— Хәмдия апа! Сукачыларга ике йөз грам ипи бирәләр, аш пешерәләр. Иртәгә үзем сукага китәм! Ипи алып кайтырмын. Иреккә чәйнәп ашатырбыз.

— Һай, рәхмәт яугыры!— дигән булды Камиләттәй, улын мактап.— Сукага сыерлы кешеләр генә йөри шул. Сыер урынына мине җигәрсең микәнни соң?

Мондый сүзгә малай аптырабрак калды.

— Актауда әнә хатыннар җирне көрәк белән казыйлар икән,— диде ул шулай да җавапсыз каласы килмичә.

— Бәрәңге бакчасын казыйсы да бар әле,— диде Хәмдия, сүзгә катышып.

— Белмим инде,— диде Камиләттәй.— Бар карап торган шул бакча. Ходай ни язды инде — утырта алырбызмы, юкмы.

Шулай сөйләнгәләп утырганда, алар чолан ишегенең дә, өй ишегенең дә ачылганын ишетмичәрәк калдылар.

— Исәнмесез. Нәрсә шаулашасыз?— диде кинәт ишек төбендә нindидер ят кеше.

Өйдәгедер куркып, котлары алынып, шундук ишек ягына борылып карадылар һәм шул чакны ярым караңгыда елмаеп басып торган юантык кына, тәбәнәк кенә бер хатын-кызны күреп алдылар.

— Ә-ә... Бибихәят икән!— диде Камиләттәй, каушавын сиздермәскә тырышып.— Әйдә, түрдән уз.

Әлтәф күзләрен акайтып картыйсына бер карап алды да уктай атылып тышка чыгып китте. Тиз арада чолан ишеген бикләп тә керде һәм авызын күптереп:

— Бикләмәгән! Үзе арттан керде — бикләмәгән!— диде картыйсына.— Ышан сиңа!

— Җә, утыр урыныңа, ташбаш!— диде Камиләттәй, малайга ачуланып.— Кеше кергәч шулай сөйләнәләрмени?

— Нәрсә булган? Әллә караклардан курка Әлтәф?— диде шат күңелле Бибихәят апа, берни аңламаган булып.

— Йөри шунда!— диде Камиләттәй.— Утыр урыныңа, ташбаш.

— Кара! Үзләре әйттеләр!— диде малай, үпкәләп. Шул чакны күрше хатыны ишеккә арты беләнрәк, башын иебрәк торган Хәмдияне күреп алды. Күреп алды да, улмы, түгелме дигән сыман беравык күзләрен зур ачып карап торды һәм бары шуннан соң гына түргәрәк узды һәм:

— Хәмдия түгелме соң?— диде.— Исәнме, Хәмдия. Кайчан кайттың? Исәнме-саумы...

— Исәнме, Бибехәяттәй?— диде Хәмдия, кызарынып.

Башын калкытты да, күрешер өчен, керүчегә таба атлап куйды.

— Дөнья булгач, югалган кешеләрне дә күрәсе бар икән,— диде Бибехәяттәй.

Шулай диде дә, телен йоткандай, кисәк кенә сүзсез калды, каушап калды. Тәрәзә янындагы артсыз урындыкка утырды да, ак төшкән уң күзен яулык очы белән сөрткәләп, җыларга ук кереште.

— Исән булса, Азатым да кайтырые,— диде борынын тарткалап.

Өй эчендә авыр тынлык урнашты. Барысы да, күршесенең кайгысын уртаклашып, әдәп саклап тын гына утырдылар.

— Язмыштыр инде, Бибехәят,— диде Камиләттәй көрсенеп, тынлыкны бозып.

Бибехәяттәй бераз гына балавыз сыгып алды да язгы кояш кебек ачылып та китте — ул алай озак кайгырып утыра торган кешеләрдән түгел иде.

— Карале, әллә баласы да бар?!— диде ул, исе китеп.

— Дүртәү булдык, Бибехәят,— диде Камиләттәй, ясалма бер куаныч белән.

— Бигрәк матур сабый икән! Күз тимәсен!— диде Бибехәяттәй, балага якынрак килеп.— Бала белән юлда кыен булгандыр? Ничек кайттың соң? Син безне онытсаң да, без сине онытмадык. Камиләдән белешеп кенә тордым. Хат та язмадың. Нәрсә булды? Әйдә, тормале шулай каш астыңнан карап. Син белмәгән Хәмдия түгел, мин белмәгән Бибехәят түгел.

— Нәрсәсен сөйлисең инде аның, Бибехәяттәй?— диде Хәмдия, теләр-теләмәс кенә.— Менә... улым белән кайттым. Икәү без хәзер.

— Бибехәят, әйдәле ашарга утыр әле,— диде шул чакны Камиләттәй, күршесен табынга чакырып.

## XVII

Ул кичне Бибехәяттәй күршеләрендә шактый озак утырды. Сөйләшә торгач, үзе өчен күп кенә яңалыклар белде. Аннан да бигрәк, яңалыкларны ул үз күзләре белән күрде. Аның йөрәге әрнеде, аның йөрәге сызланды.

— Башта ук үземә керсәгез, нәрсә булгандыр!— диде ул, хуҗаларны шелтәләп.— Күрәләтә бала үтереп яталармыни?! Без ничек тә түзәрбез. Без инде карт агачлар... кештер-кештер, мыштыр-мыштыр йөрештерербез. Сабый ничек түзсен? Сыерым әле сөт бирә. Теләп кенә торыгыз... сабый бәхетеннән... тамчысы да җәл түгел.

— Рәхмәт инде,— диде Камиләттәй, куанычыннан нишләргә белмичә.— Сезнең үзегезнең дә балаларыгыз җитәрлек. Рәхмәт инде.

— Безнең балалар аякка баскан инде,— диде Бибехәяттәй, бер дә исе китмичә.— Аларга хәзер сөт эчәргә ярамый. Ашасыннар әнә черек бәрәңге! Көн дә кереп алыгыз. Кермәсәгез үзем кертермен. Тамчысы да җәл түгел.

— Рәхмәт, Бибехәяттәй,— диде Хәмдия дә, тыелып кына.

Бибехәят апа өйдәгеләрне шулай куандырды да шаулап, уен-көлке сөйләнеп кайтып китте һәм күп тә үтмәде, ярты литрлы пыяла банка белән сөт күтәреп, алъяпкыч итәгенә беркадәр бәрәңге салып, яңадан кереп җитте.

Сөт эчергәч баланың тамагы туйды. Тынычлап ул шундук йокыга китте. Олылар да ул көнне үзләрендә беркадәр тынычлану, иркенәю кебек бернәрсә тойдылар.

— Андый тишек авыз! Бөтен авылга сөйләп йөрер әле,— диде Әлтәф кенә, Бибехәят әбисенең шулай җиңел генә кереп-чыгып йөрүен бик үк ошатмыйча.

— Сөйләмәс,— диде Камиләттәй.— Бибехәят андый түгел. Карты да, балалары да сөйләмәс. Алтын кешеләр алар!

«Әйе, алтын кешеләр»,— дип уйлады Хәмдия, әнисе белән килешеп. Бит кайчандыр ул аларның килене булырга ниятләнеп йөрде. Юк, Хәмдия турында ул берни сөйләмәс! Күрше буларак та гомер-гомергә дус-тату яшәделәр: бер-берсенең гайбәтен сатмадылар, телгә-тешкә килмәделәр. Көннәрдән бер көнне, Азат белән Хәмдиянең үзара мөнәсәбәте ике якка да мәгълүм булгач, элекке дуслыкка-татулыкка тагын да җылырак тойгылар

өстәлде. Һәр ике як аларның дуслыгын хуп күрде, һәр ике як яшьләргә бәхет-куаныч теләде һәм әкренләп-әкренләп кенә, артык шауламыйча гына, булачак туйга әзерләнә башлады. Ләкин туй була алмый калды. Туй урынына мәхшәр башланды. Бөтен илдә мәхшәр башланды.

«Нинди кыска булды синең гомер, бәгырем!»— дип уйлады Хәмдия, төн карасы аша үткәннәргә күз салып.

Кыска булды, бик-бик кыска булды. Азатны сугышның беренче көннәрендә үк алдылар. Ул китеп күп тә үтмәде, сугыштан кайгылы хәбәр килде.

Шулай Мулланұров Азат сугышта үлде, батырларча үлде. Ул инде күптән җир куенында ята.

Шулай ук аларның мәхәббәте дә бик кыска булды, үкенечле булды.

Кырык беренченең бөркү июнь төне Хәмдиянең хәтеренә мәңге сеңеп калды. Бүә буенда, Очлы тау итәгендә... тирә-якта тоташ кара урман... һавада бал исе, яңа чабылган печән исе. Аяк астында елкылдап, пышылдап әкрен генә Бүә ага. Сандугачлар сайрый, чикерткәләр чекелди. Яр буенда караеп шалашлар күренә. Ул вакытта алар болында төн кунып эшлиләр иде. Авылга кайтырга ерак. Берәүләр печән чаба, икенче берәүләр печән җыя. Эш тә түгел инде ул — бәйрәм, сабан туе.

Олыраклар йоклап беткәч алар төне буе яр читендә утырдылар. Аста Бүә ага... түбә өстендә йолдызлар белән тишкәләнеп беткән кара күк табагы капланып тора. Нинди гүзәл, нинди татлы иде ул төн!

«Мин гаепле, Азат, синең алда, бик гаепле»,— диде ул, ерактагы изге хатирәләргә эндәшеп.

Бик гаепле... Шул чакта ул ахмак булды. «Минеке бул!»— диде аңа Азат. Сузма, өйләнешик, бергә-бергә тормыш корыйк, диде. Хәмдия ул чакларда бераз гына кырыс булды, кыргый булды. Үзе дә аңламастан, бер дә юктан сузды, соңгы сүзен әйтмәде. Татар кызы гомергомергә бераз гына кырыс булган, горур булган. Татар кызы гомер-гомергә тыйнак булган, турылыклы булган. Ул да тыйнак булды, горур булды һәм... соңгы сүзен әйтә алмый калды. Кем белгән соң аның менә болай булып бетәсен!

Азатның үле хәбәре килеп биш-алты ай узмады, яраланып Сәлим кайтып төште. Хәмдиягә Сәлим якын дусты турында, аның кайчан, ничек яралануы, кайчан, ничек күмелүе турында сөйләде. Сәлимнең кайбер гадәтлә-

рен — аумакайлыгын, вәгъдәсезлеген Хәмдия элек бик үк өнәп бетерми иде. Алар арасында элегрәк үзара әйткәләшеп алулар да булгалый иде. Шулай да алар дошман түгелләр иде. Уртак кайгы аларны якынайткан сыман булды. Көннәрдән бер көнне Сәлим үзенең мәхәббәтен белдерде. Үлгән артыннан үлеп булмый, диде, минеке булсаң, мин сине уч төбендә генә йөртермен, диде. Тагын әллә ниләр сөйләп бетерде.

Ул риза булды. Башы-күзе әйләндеме, күрәчәге булдымы... ул риза булды. Кем белә, бәлки, сугыш шаукымы да тәэсир иткәндер — Сәлим кебекләр авылда бармак белән санарлык та юк иде бит! Аның урынына кызлар — буа буарлык. Оялары-оялары белән торып калдылар... яшь-яшь чибәр кызлар, күз яшьләрен түгеп, ялгыз калдылар.

Ул риза булды. Бары тик Сәлимнең анасы гына риза булмаган. Бердәнбер улына күрше Ушия-таудан үзенә ошаган «булдыклы» кыз ярәшеп куйган булган. Сәлим үзе дә Ушия-тауга барып йөргән. Бер көнне Хәмдия белән очрашса, икенче көнне Рабига белән очрашкан. Хәмдиягә анасы соңыннан сүз ишеттерде: Камилә кызы усал дигән, телчән дигән.

Нинди оят, нинди хурлык булды шул чагында! Кем уйлаган аны шулкадәр икейөзле булыр дип, кем уйлаган аны шулкадәр үк оятсыз булыр дип?!

Менә шул. Барысы да билгеле булгач, бер атнадан аларны читкә озаттылар.

## XVIII

— Мин бернәрсә уйладым әле, кызым — син нәрсә әйтерсең тагын,— диде Камиләттәй икенче көнне йокыдан торгач.— Сырманы сатарга туры килер. Башка чара калмады.

— Мәликә корткагамы?— диде Хәмдия.

— Хәзер базарга китәм, Яңавылга,— диде әнисе.

— Тагын үлеп кайтыргамы? Юк, әнкәй, җибәрмим. Синсез нишләрбез монда без?!— диде Хәмдия.

— Мәликә корткага бер дә аягым тартмый,— диде Камиләттәй.— Карун... ачкүз. Мыскыл итеп тагын бер пот бәрәңге биреп җибәрер. Үлмәм әле, кайтырмын. Базар үзенекен әйтер. Озакламый кузгалак чыгар. Баланың кайгысы китте. Ничек тә яңа ашлыкка барып җыгылырбыз әле. Кайтканда Уразы аша кайтырмын. Кичтән Уразыда кунармын, иртән иртүк үзебезгә кайтып төшәрмен. Мине алай югалтып ятмассыз.

— Белмим шул, әнкәй,— диде Хәмдия, икеләнгәндәй итеп.

Сырма турында инде ул үзе дә уйлаган иде, тик әлегә әнисенең хәтерен калдырасы гына килмәгән иде.

— Уразыга керәсе булгач, барырсың инде, әнкәй,— диде ул, килешергә мәҗбүр булып.

Камиләттәй әзерләнде дә «Аллага тапшырып» китеп тә барды.

Әлтәфне мәктәпкә озаткач, баласын туйдыргач, Хәмдия урыннарын җыештырды, чоланга чыгарып әйберләрнең тузаннарын каккалады. Барлы-юклы эшләрен бетерде дә улын кулына алды. Менә алар тагын икәү генә калдылар. Әннәдән башка кеме бар аның? Беркеме юк. Тегендә дә икәү генә, монда да икәү генә. Юлда да икәү, өйдә дә икәү. Нинди кансыз була кайчагында карт кешеләр, улым! Ничек әйтә алды икән картый шундый коточкыч сүзләрне? Юри генә әйтте микән, кызганып кына? Тегендә дә әйтәләр иде андый сүзләрне. Баштарак әннә үзе дә шулайрак уйлаштырган иде. Әйе, әйе, исең китмәсен — ул үзе дә... Авырга калганлыгын белгәч ул үз-үзенә кул салмакчы булган иде. Чын-чынлап. Берни уйламыйча, икеләнмичә. Аның өчен кояш инде сүнгән, дөнья тәмам беткән иде. Рәхмәт яусын мукшы хатынына. Агач арасында ул очрады. Сизенгән... арттан килгән. Кулдан бауны тартып алды. Рәхмәт яусын аңа!

«Менә шулай саклап калдым... саклап килдем сине, улым,— диде ул күңеленнән, улы белән сөйләшеп.— Инде шулкадәр карап үстергәч, инде сине кеше иткәч... Картый ахмак!» Ләкин хәзер инде аңа беркем андый сүзне әйтмәячәк. Хәзер аның ике картыйсы бар. Бер әннәсе, бер абыйсы, ике картыйсы бар. Нинди бәхетле ул хәзер! Аның өчен картыйлар ике яклап тырышалар. Әнә берсе үлмә хәлендә ерак юлга сәфәр чыгып китте, икенчесе янда гына... ике-өч өй аша гына. Кирәк икән, хәзер керәп җитәчәк.

Көне буена Хәмдия шулай үз-үзе белән сөйләште, улы белән сөйләште. Кинәт кенә идән уртасында йә булмаса тәрәзә каршысында туктап калды да онытылып уйланырга тотынды. Уйлары, йөгерек җил кебек, тиз арада Урал артындагы сазлы урманнарга барып кайтты, Бүә буйларында йөрде, күршеләрендә тукталгандай итте дә каядыр читкә — иркен басуларга, кырларга юнәлде. Ул хәзер элеккегә караганда төплерәк, тирәнрәк итеп уйлады. Көтмәгәндә Бибехәяттәйнең килеп керүе, көтмәгәндә аңа шулай ярдәм кулы сузуы аның берничә көн эчендә ныгып җиткән кайбер карашларын, фикер-

ләрен юкка чыгарды. Ул дөньяга киңрәк, ачыграк күз белән карый башлагандай булды. Анда үз-үзенә карата, дөньяга, киләчәккә карата өмет, ышаныч барлыкка килә башлагандай булды. Ул үзенең болай качып-посып, яшеренеп яшәвенең бөтен мәгънәсезлеген төшенгәндәй булды. Шулай булмыйча! Илдә каты сугыш бара, кайда да эш кешесе кирәк. Тегендә эшләсә ни, монда эшләсә ни — барыбер түгелмени? Ул бит юри кайтмады монда, эшлисе килмәгәннән кайтмады. Ул кайтырга мәҗбүр булды. Баласы өчен кайтты. Аңларга тиешләр ләбаса шуны!

Кичкә таба, вәгъдә иткәнчә, балага сөт күтәреп Бибехәят апа килеп керде. Бу юлы ул Хәмдия янында озаграк, иркенләбрәк утырды. Азатын искә төшереп, бер-ике мәртәбә күз төпләрен юешләтеп алды. Яратып, үз итеп баланы сөйде, Хәмдияне сөйде.

Күршесе чыгып киткәч, Хәмдия үзендә гаҗәеп бер күтәренкелек тойды. Аның җылыйсы килде, шул ук вакытта җырлыйсы йә булмаса сузып-сузып кычкырасы килде. Улын йоклатты да ашкынып, җиңел-җиңел атлап, Салкын чишмәгә суга китеп барды. Караңгы төшү белән, ул һәркөнне шулай чишмәдән су алып кайта башлаган иде. Бүген ул ныклап торып караңгы төшкәнне дә көтмәде. Бүген ул, ниһаять, тиешле бер карарга килде.

## XIX

Урамда аңа беркем очрамады. Авыл инде йокыга яткан. Бик сирәк йортларда гына җемелдәп кызгылт утлар күренә дә бик сирәк ишегалларында гына эт өргәне, песиләр кычкырганы ишетелә. Элегрәк кичләрен шаулап-гөрләп торган клуб ягында да хәзер тынлык һәм караңгылык хөкем сөрә.

Шулай да югары урамдагы биек йортның зур тәрәзәләрендә әле булса балкып ут яна. Бу элекке мәчет йорты, анда хәзер колхоз идарәсе. Караңгы урамнан, караңгы өйләр яныннан шундый якты җиргә килеп чыккач, Хәмдия кинәт каушап калгандай булды. Ары барыргамы-юкмы икәнлеген белмичә беразга койма буенда туктап торгандай итте.

Димәк, кайтып китмәгәннәр. Нишләп утыралар икән — җыелыш микән, болай гына утыралар микән, нәрәт алып, нәрәт биреп, иртәгә эшлисе эшләр турында сөйләшеп? Кемнәр булыр хәзер анда — бригадирлар, ферма мөдирләре, хисапчылар? Ләкин бит аңа председатель

генә кирәк, баш кеше генә, иң олы кеше генә. Ничек итеп аның үзен генә күрергә икән?

Урам яктагы ишектән чыгучы-керүче күренмәде. Шулай ук якын-тирәдә дә бернинди җан әсәре сизелмәде. Хәмдия беркадәр тынычлангандай булды, койма яныннан кузгалып китте дә бер-ике атлауда биек баскыч янына килеп тә җитте. Баскычтан менде. Ишек каршысында яңадан туктап калды. «Керергәме, юкмы?»— диде.

Моннан ике-өч еллар элек бу ишекләрне ул орыпбәреп кенә йөри торган иде. Аның бу йортта ярты төнгәчә төрле җыелышларда утырганы бар. Ул чакларда аңа сөйләргә, «тәнкыйть итәргә» үзләре куша торганнар иде. Ул үзе дә алай ялындырып тормый торган иде — кемнең кем булуына карамастан, йөзенә бәреп әйтә торган иде.

«Керим әле»,— диде ул үз-үзенә, күпмедер вакыт шулай икеләнеп торганнан соң. Тышкы ишекне тартып җибәрде дә ишек төбеннән үк башланган тар, биек баскычтан югары менде. Өстә чолан сыман зур гына бүлмә бар иде. Берничә адым атлагач, ул икенче бер ишек алдында туктап калды. Монысы инде туп-туры эчке залга керә торган ишек иде.

Икенче ишек янында ул шактый озак басып торды. Куркудан, шүрләүдән аның еш-еш йөрәге типте, колагы шаулады. «Әллә беркем дә юк инде?»— дип уйлады ул бераздан, ишек артына колак салып. Шыгырдатмаска тырышып, иплэп кенә, сакланып кына ишекне үзенә табарак тартты. Капка кебек зур, авыр ишек җиңел генә, әкрен генә ачыла башлады. Шул чакны Хәмдиянең йөзенә эчтән яктылык бөркелде.

Ул уйлаганча монда бернинди җыелыш та юк, шаулашып, тәмәке тартып утырган кешеләр дә юк иде. Кантур эче буп-буш иде. Бары тик түрге яктагы озын өстәл янында иелеп нидер язып хисапчы утыра да аның каршысында, ишек ягында, бер ир кеше басып тора. Хисапчының эше беткәнен көтәме, берәр язу язып биргәнен көтәме. Председатель утырырга тиешле өстәл янында беркем юк. Таралышканнар, кайтып киткәннәр.

Хәмдия җиңел сулап куйды, ишекне иплэп кенә япты да кире чыгып китте. «Ярый әле күрмәде!» диде ул үзүзенә, ниндидер бәла-казадан котылган кебек.

Әйе, күрмәде, күрмәделәр... Сизмәделәр дә, ишетмәделәр дә. Ир кешесе кем булгандыр — таный алмады. Хисапчысын таныды. Элекке дус кызы, сабакташы Сабира. Теге елны аны да урман кисәргә язганнар иде. Факия кебек ул да гап-гади колхозчы иде. Әтисе Яңавылга

Низамовка бер сарык, Мраморнаяга бер сарык илтеп биргән. Шуннан калды. Ике сарык бәясенә тора аның башы. Хәмдиянең әнисе дә берәр сарыкларын корбан итәргә булган иде дә, Хәмдия үзе риза булмады. Ул вакытта Хәмдия җир читенә дә китәргә риза иде.

Сабираны күргәч, анда үзеннән-үзе кемгәдер ачу кабара башлагандай булды. Үзенең болай качып-посып йөрүе, нәрсәдер теләнеп йөрүе бик тә хурлыклы булып, түбәнлек һәм әшәкелек булып тоелды. Шул ук вакытта аның күңелендә бәхетле сабакташыннан көнләшү хисе уянды. «Кара, нинди киенгән-ясанган!»— дип уйлады ул, Сабираны күз алдына китереп. Өстендә яхшы пинжәк, иңбашында чуклы шәл, колакларында алка. Бите күмәчтәй. Баш булып утыра. Ялганчы Сабира, биремче Сабира начальник булып утыра! Ялкау Факия — бригадир, ударник Хәмдия — теләнче. Менә ул нинди замана! Туктагыз әле, күрәселәрегез алда әле. Сугыш кына бетсен, чын хуҗалар гына кайтсын — типкәләп төшерерләр әле җылы урыннарыгыздан!

Үзалдына шулай ярсып бара торгач, ул үзенең бу очка ни өчен килгәнлеген исенә төшерде. «Күренмичә, сөйләшмичә кайтырга ярамый»,— дип уйлады ул, кискен бер карарга килеп.

## XX

Председатель Галиәхмәт абзый йортында да ут сүнмәгән иде, ләкин капка эчтән бикле булып чыкты. Хәмдия, аны-моны уйлап тормыйча, бар көченә шакырга тотынды. Күп тә үтмәде, шыгырдап өй ишеге ачылды.

— Кем бар анда?— дип кычкырды чәрелдек тавышлы хатын-кыз.— Көндез вакыт беткәндер — киләләр дә җитәләр! Әле кайтып аягын салырга да өлгермәде.

— Ач әле, ач, Мөнирәттәй!— диде Хәмдия.

Мөнирәттәй, күрәсең, таләпчән тавышка алданып, баскычтан җиргә төште, капка янына килде дә сукранып аркылы агачны этеп җибәрде. Керүченең кемлеген төпченеп тормастан, соңлап йөргән теләсә кемне санга сугарга исәбе юклыгын сиздереп, көтмичә генә өенә кереп китте.

Мөнирәттәйне дә, Галиәхмәт абзыйны да Хәмдия бик яхшы белә иде. Янбашы гарип Галиәхмәт абзый гомере буена көтү көтте. Баштарак авыл көтүен көтте, аннан колхоз фермасында мал карады. Хатыны гел ире белән бергә булды. Сугыш башланып, ферма мөдирен армиягә алгач, Галиәхмәт абзыйны мөдир итеп билгеләделәр.

Менә шуннан үрли башлады инде ул. Былтыр көз колхоз председателе итеп куйганнар. Ямалов дигәне уракка төшү белән колхозчыларга йөз илле граммнан арыш таратып, «дәүләт милкен әрәм-шәрәм иткән» икән дә, аны шундук Яңавылга алып киткәннәр, утыртып куйганнар.

Председатель Галиәхмәт абзый элегрәк бик ягымлы, кечелекле, хәтта кирәгеннән артык ягымлы кеше иде. Хатыны да ягымлы иде. Шуңа күрә Мөнирәттәйнең шундый усал, чәрелдек тавышы, үзен шундый эре тотуы Хәмдияне шактый гаҗәпкә калдырды. «Ай-йай... Эт оясында көчле дигәндәй, үз өендә нинди икән бу!» — дип уйлады ул, председатель хатыны артыннан ашыгып.

Өйгә килеп кергәч тә, Хәмдия иң әүвәл түшәмдәге утызлы лампага игътибар итте. Бу клуб лампасы иде — Хәмдия аны бик яхшы хәтерли. Утызлы лампадан башка монда тагын берничә клуб әйберсе бар иде. Түр почмакка бастырып куелган пыялалы шкафта элек китапханә китаплары саклана иде. Арты бөгеп эшләнелгән җиңел урындыклар да элек клуб милке булып исәпләнелә иде.

Галиәхмәт абзыйның өе башка яклары белән дә клубнымы, конторанымы хәтерләтә иде. Ишектән кергәч тә, каршыда, ике тәрәзә арасында маршал кителе киеп төшкән Сталинның мәһабәт портреты элеп куелган. Портреттан астарак язгы чәчүне вакытында башкарып чыгарга өндәгән кечкенә лозунг кадакланган. Стенаның уң ягында исә — шулай ук тәрәзә араларында — немецларны юк итәргә, заемга язылырга өндәгән, басуда кышлаган ашлыкны ашамаска кушкан, нәсел үгезләрен күрсәткән плакат-лозунглар ябыштырылган. Шул ук вакытта түшәм астыннан өй әйләнә суккан кашага эленгән, тәрәзә араларыннан борынгы сөлгеләр салынып тора. Бизәгән өен Галиәхмәт абзый!

Сөякләреңә эрерлек җылы өйгә итле аш исе, суган исе чыккан. Галиәхмәт абзый, гарип иңбашы белән сул яккарак янтайган көе, саргылт мыекларын салындырып, тирләп-пешеп, түрдә өстәл янында аш ашап утыра. Җылы өйгә тагын да ныграк җылылык, рәхәтлек, туклык тойгысы өстәп, идәндә мич алдында ак самавыр гөрләп утыра. Хәмдия капка шакыган вакытта, Мөнирәттәйнең дә ашап утырган чагы булган, ахрысы — өстәлдә буларын бөркеп, Галиәхмәт абзыйныкыннан башка тагын бер күбәтә тора. Шунда ук ялтырап, путаллы яңа агач кашык ята. Ләкин кеше ияртеп кергәч, хуҗа хатын яңадан өстәл янына барып утырасы итмәде — ишектән керү белән сулга, мич арасына узды да, нинди-

дер бик кирәк эше бар сыман, кыштыр-мыштыр шунда маташа башлады.

— Исәнмесез,— диде Хәмдия, түргә узгандай итеп.

— Исәнмесез,— диде хуҗа, керүчегә таба чак-чак кына башын борып.

Ләкин аның игътибары шуннан ары узмады. Бик бирелеп ул һаман ашавында булды. Шулай ук мич артындагы Мөнирәттәй дә эндәшмәде. Ичмасам, сүз битлеге өчен булса да, «түргә уз» димәделәр, «ашарга утыр» да димәделәр. Өйдәге шундый җылылыктан, исерткеч туклыклы аш исеннән һәм хуҗаларның шул дәрәҗәдәге салкынлыгыннан Хәмдиягә әллә ничек булып китте. Аның кинәт башы әйләнде, күз аллары томаланды. Түшәмдәге утызлы лампа берьюлы өч-дүрт булып күренә башлады. Ул кире ишек төбенә чигенде, егылып китмәс өчен ишек яңагына сөялде дә өстәлдәге зур агач табактан, Галиәхмәт абзый кулындагы ялтыравык агач кашыктан күзен алмыйча, төкерекләрен йотып, беравык хәл җыеп торды. Болай тынып тору бик озакка сузылгандай булгач, тамагын кырды һәм ялынычлы бер өн чыгарып:

— Галиәхмәт абзый...— диде.

## XXI

— Ыһым... Сүләп кара,— диде хуҗа көттереп, башын калкытмыйча гына.

— Мин сиңа йомыш белән килгәнием, Галиәхмәт абзый,— диде Хәмдия.

— Йомыш белән кантурга киләләр,— диде хуҗа.

— Әйтмә!— диде Мөнирәттәй мич артыннан, тузынып.— Тапканнар! Кешегә иркенләп ашарга да вакыт юк. Болай да көне-төне чаба, инде өеңә басып керәләр.

— Ачуланма инде, Мөнирәттәй,— диде Хәмдия, күңеле кырылып.— Көндез туры китерелмәдем. Йомышымны әйтәм дә китәм. Сезгә килми кемгә килим?

— Ыһым... Сүләп кара,— диде тагын да Галиәхмәт абзый.

— Эш сорап килгәнием мин, Галиәхмәт абзый,— диде Хәмдия.

Хуҗа кеше авызына китергән кашыгын кире алды, башын калкытты да кызарган, тирләгән йөзен керүчегә таба борды.

— Ниндәен эш: кул эшеме, йорт эшеме?— диде ул, аптырау катыш бер дорфалык белән.

— Калхуз эше,— диде Хәмдия.

— Калхуз эше?! Эш бирмәйләрмени?!— диде Галиәхмәт абзый көлеп, кычкырып.— Мин тагын эшләргә кеше юк дип йөрим, эш тә җитмәй икән әле болай булгач.

Шырпы белән тешен казыштырып, күзен шардай итеп шул чакны Мөнирәттәй дә мич артыннан — гөлбәчтән килеп чыкты. Килеп чыкты да идән уртасына баскан килеш аю күргән кебек Хәмдиягә карап тора башлады.

— Кем дип әйтим — Вәрәш оч Камилә кызы түгелме соң әле син?— диде ул, хәтеренә төшерергә тырышып.

— Шул инде, шул, Мөнирәттәй!— диде Хәмдия, сөенгәндәй итеп.

— Зариф Хәмдиясеме?— диде Галиәхмәт абзый.

— Нишләп Зарифныкы булсын!— диде Мөнирәттәй, иренә кычкырып.— Зарифныкы — Хәмидә. Яңавылда чуен юлда эшләй. Нигъмәт Хәмдиясе. Ысбирлауга урман кисәргә җибәргәннәрие түгелме соң әле сине, апаем?

— Менә шуннан кайттым инде мин,— диде Хәмдия, җиңел сулап.

— Алай икән,— диде Мөнирәттәй үзгәргән, сүлпәнләнгән бер тавыш белән һәм беренче мәртәбә тәкәллефсез генә керүченең өс-башына күз йөртеп чыкты.

— Өченче көнне генә кайтып төштем. Бер дә кайта торган кеше түгелием... иремне сугышка алдылар. Яшь бала белән бик кыенга туры килде, Мөнирәттәй... Галиәхмәт абзый,— диде Хәмдия ашыгып, буталып.

— Яшь балаң да бармыни?— диде Мөнирәттәй, кызыксынган булып.— Бала белән кыендыр шул.

— Кайтып төштем — өйдә шыр! Ашарга юк. Эшкә чыгыйм дигәнием, Галиәхмәт абзый. Сукагамы анда, чәчүгәме. Нинди эшкә дә риза.

— Ыы шул, ыы,— диде Мөнирәттәй, килешкән сыман итенеп.— Эш кешесенә эшсез ятуы кыен инде ул. Балаң бик яшьмени шулай?

— Яшь шул, Мөнирәттәй,— диде Хәмдия.

Галиәхмәт абзый хатыннарның сөйләшкәнен эндәшмичә генә тыңлап торды да чүпрәк белән майлы авызын сөртеп куйды, аягына басты, бил каешын рәтләде — сугыштан кайткан кешеләр кебек ул да гимнастерка киеп, биленә киң каеш тагып йөри иде.

— Ыһым, ничек соң, язу белән кайттыңмы?— диде ул Хәмдиягә.

— Юк шул, Галиәхмәт абзый,— диде Хәмдия.

— Ә, алай икән,— диде Мөнирәттәй, беркадәр тынлыктан соң.

— Ыһым,— диде тагын да Галиәхмәт абзый, тамагын кырып.— Алайса сүләшеп тә торасы юк, сеңлекәем. Дүкәмит кирәк. Хәзер баенный бримә, закун каты, ыһым... Язу алып кил, шуннан сүләшербез.

— Галиәхмәт абзый!— диде Хәмдия, эшнең болайга китүенә коты алынып.— Хәзер генә каян язу алып килим?! Шушы калхуз кешесе ич мин!

— Белмәймен, бернәрсә белмәймен,— диде хуҗа, коры гына.— Сүзгә генә ышана торган заман түгел — каян белим мин сине? Әллә күрше авыл син, әллә изәртил, әллә ышпиун!

— Галиәхмәт абзый! Мөнирәттәй!— диде Хәмдия шаккатып, урыныннан кубып.— Ни сөйлисең, Галиәхмәт абзый?! Нинди ышпиун ди ул?! Шушы Янтыкта туып үскән... шушы калхуз кешесе... Сез дә якламагач, кем якласын мине?!

Мөнирәттәй, бәладән баш-аяк дигәндәй, яңадан мич артына кереп югалды. Галиәхмәт абзый да, артык сөйләшеп торасы килмәгәнлеген сиздереп, пыялалы шкаф янына килде дә аннан нидер актара башлаган булды.

— Безне алты гына айга дип җибәрделәр,— диде Хәмдия, үзенең иң ышандыргыч дәлиленә тотынып.— Алты ай урынына мин ел ярым эшләдем. Безне көчләп тоттылар. Ел ярым бит ул, Галиәхмәт абзый! Җәй көне торф чыгардык, кыш көне урман кистек. Мин теләсә нинди эшкә риза, сукага, чәчүгә... утауга, уракка... Чәчем белән җир себерергә риза, Галиәхмәт абзый! Балам ач, үзем ач. Ничек карыйм мин аны? Ничек карыйм?! Сөт юк, ачтан үлә... Мөнирәттәй! Әйт, ичмасам, Галиәхмәт абзыйга — син бит хатын кеше!

— Нәрсәсен әйтәсең аның?— диде Мөнирәттәй, мич артыннан чәрелдәп.— Синең балаң өчен кеше минават түгел. Баланы песи дә таба — тапмаска кирәгие!

— Мөнирәттәй!— диде Хәмдия, әрнеп һәм тыела алмыйча кинәт сулкылдарга тотынды.— Ничек оялмыйсың?! Ничек телең бара?

— Бер дә ояласы юк!— дип кычкырды председатель хатыны, тагын да яманрак итеп.— Кеше өчен катер китәсе юк монда. Кемгә дә баш кадерле.

— Ыһым...— диде шул чакны хуҗа, яңадан Хәмдиягә борылып.— Монда җылап эш чыкмас, сеңлем. Үзең беләсең, баенный бримә. Син, булмаса, иртәгә төшкә таба кантурга кил, эш беткәчрәк. Шунда сүләшербез, элекке

дүкәмитләрне карарбыз. Исемең чыга икән — баш өсте! Калхузда эш җитәрлек — көрәгең генә нык булсын. Ыһым, менә шулай. Сүләшербез... иртәгә...

Хуҗаларның баштагы кыланышлары никадәр көтелмәгәнчә булса, председательнең бу йомшаруы да шул ук дәрәҗәдә көтелмәгәнчәрәк булды. Хәмдия ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Аның икеләнүен күреп, Галиәхмәт абзый янә өстәп куйды:

— Дисбителнә калхуз члине булсаң, кантурда нык-лап сүләшербез,— диде.

Хәмдия башын югарырак күтәрде, яшь аралаш елмаеп, тәэсирләнеп:

— Рәхмәт, Галиәхмәт абзый,— диде.— Гомергә онытасым юк бу яхшылыгыңны!

## XXII

Икенче көн бик матур башланды. Иртүк елмаеп кояш чыкты. Кояш чыгу белән өй эченә якты нур тулды, тышта тәрәзә түбәсендә сыерчыклар, чыпчыклар чыр-чу килә башлады. Күршеләр ягында, ике-өч өй аша, сузып-сузып әтәч кычкырды. «Бибехәяттәйләрнеке, ахрысы»,— дип уйлады Хәмдия. Нинди шәп кешеләр алар! Аларның әнә әтәчләренең тавышы да нинди моңлы, нинди яңгыравыклы. Чыпчыклар, сыерчыклар тавышы да моңлы, матур.

Күңеленнән ул шулай тыштагы кошларга сокланды, улына сокланды, шул ук вакытта бүген башланачак яңа тормыш турында хыял йөртте. Әлегә ул бернәрсәне дә ачык кына күз алдына китерә алмады. Әлегә ул моннан соң үзенең ябылып ятмаячагын гына белде, бүтәннәр кебек үк иртән иртүк торып эшкә китәчәген генә, кешеләр белән аралашачагын, гомумән, элеккечә шаушулы тормышка кереп китәчәген генә белде. Аннан соң ул үзенең улын күз алдына китерде. Ул аны үзе сукадан кайтканда атка атланган итеп йә булмаса җир сөргәндә үзе яныннан теркелдәп барган сыман итеп күз алдына китерде. Әлегә аның хыяллары шуннан ары узмады. Шулай да аның күңелен берөзлексез шатлык һәм куаныч тойгысы тутырып торды. Колхозның элекке исемлекләрендә үзенең барлыгына, үзен Янтык Нигъмәт кызы Хәмдия дип таныячакларына ул әз генә шикләнмәде.

Йокысыннан торып аягына басу белән, ул тышка чыгып китте, күршеләре күрүдән шүрләмичә, курыкмыйча, озак кына утынлыкта булашты, аннары, су кирәкмәсә

дә, Салкын чишмәгә суга китте. Чишмә янында Гафияне очратты, аның белән озак кына серләшеп-гөрләшеп торды, үзенең кайчан кайтканлыгын, ничек кайтканлыгын сөйләде, хәтта үзенең баласын да телгә алды. Гафия исе китеп тыңлап торган булды, ләкин үз-үзен тотышы буенча, кайбер сүзләре буенча Хәмдия аның күптән инде барысын да белгәнлеген аңлап алды. Белмәс сиңа күршеләр! Шулкадәр кеше арасында ничек яшеренеп ятмак кирәк? Ярый инде, рәхмәт, беркем барып чакмаган. Чаксалар, кем белә, күптән инде «изәртил» итеп, «ышпиун» итеп... Аллам сакласын! Хәзер ул үзе барып күренде. Хәзер аңа беркем андый исем тага алмас!

Судан Хәмдия шат күңел белән кайтты. Ул өйгә кайтып керүгә Әлтәф тә тышка чыккан иде. Хәмдия апасын көпә-көндез ишегалдында күреп Әлтәфнең ике күзе дүрт булды.

— Хәмдия апа!— диде ул, ачуланып.— Онытгыңмыни?! Картый кайтсын әле, күр дә тор менә — барыбер әйтәм!

— Әйтсәң әллә,— дигән булды Хәмдия, көлеп.

Суын өйгә кертеп куйгач ул, тузанын кагарга дип, кием-салымнарны, ястык-мендәр ише нәрсәләрне тышка алып чыкты. Малай берни аңламады һәм «баш күтәргән» апасына ничек тәэсир итәргә дә белмичә кашларын җыерып баскычта басып тик торды.

Нәкъ шул чакта аркасына капчык күтәреп Камиләттәй кайтып керде.

— Нәрсә булды, кызым?— диде ул, киртәгә эленгән чүпрәк-чапракларга шикле караш ташлап.

— Берни булмады, әнкәй, җилләтәм,— диде Хәмдия.— Ничек кайттың? Юлын уңган, ахрысы? Көне бигрәк матур, әнкәй.

— Юлым уңды,— диде Камиләттәй, өйгә таба юнәлеп.

Әлтәф аның җилкәсендәге капчыкны күтәреп алды. Алар шаулашып, куанышып өйгә керделәр. Хәмдия әнисенә чишенергә булышты, аннары тиз генә казан астына ягып җибәрде. Арып, шулай да канәгать бер кыяфәттә, Камиләттәй сикегә утырды, юл хәлләрен, базар хәлләрен сөйләде.

— Ярый инде, бәхетегез бар икән, балалар,— диде.— Ярты пот онны, ипләп тотканда, күпкә җиткерергә була... Яңавылда да шул ук сүзне сөйлиләр: быел көзгә сугыш бетә икән, диләр. Иншалла, фирештәләрнең амин дигәненә туры килсен инде.

— Син гел шулай дисең дә соң, бер дә туры килми шул әле,— диде Әлтәф, картыйсының динлелеген тәнкыйть итеп.

— Җә, тик кенә утыр, ташбаш,— диде картыйсы, ачусыз гына.— Сиңа, кызым, ни булды? Нишләп йөрисең анда?

— Бер дә әйткәнне тыңламый, картый!— диде Әлтәф, әләкләшеп.

— Мин югында нишләп ятасыз сез монда?— диде картый, пошынып.

Хәмдия, «ни әйтсәгез дә, нәрсә эшләтсәгез дә хәзер инде соң» дигән сыман, җиңүче кыяфәттә беравык елмайгандай итеп утырды да барысын түкми-чәчми сөйләп бирде. Әнисен ул һичшиксез сөенер дип уйлады. Ләкин әнисенә игътибар беләнрәк караган иде, аның үзгәргән, төсе качкан йөзен күреп тынсыз калды.

— Булдыргансың икән, кызым,— диде Камиләттәй.

— Һи, бигрәк куркак инде син, әнкәй!— диде Хәмдия, көлгән булып.

— Батырлар, кызым, сугышка китеп беттеләр,— диде Камиләттәй.— Монда шул минемише куркаклар гына калды да инде.

## XXIII

Бераздан казанда су кайнап чыкты. Кайнар суга күп итеп, мул итеп умач уып салдылар. Умачлы аш куе булып, тәмле булып пеште. Өйгә чын аш исе таралды. Барысы да өстәл тирәсенә утырышкач, Камиләттәй, бисмилласын әйтеп, иплэп кенә аш бүлә башлады.

— Карале, картый, кем килә ул безгә таба?— диде Әлтәф ашарга утыргач кына, урам як тәрәзәгә күрсәтеп.— Сәлим абый инде әллә?

Камиләттәй дә, Хәмдия дә икесе берьюлы дерт итеп киттеләр, икесе дә берьюлы урам як тәрәзгә үрелеп карадылар.

— Һай Алла!— диде Камиләттәй.— Кызым, җыен! Төш базга!

Гомердә булмаган бер җитезлек белән ул урыныннан торды, мич каршындагы баз капкачын ачып җибәрде дә күзенә күренгән бала чүпрәкләрен, кызының кием-салымын — барысын шунда ыргытты.

— Ишетәсеңме, төш тизрәк!— диде, кузгалмыйча утырган кызына кычкырып.

Сәлимнең килүе Хәмдиягә бөтенләй икенче яктан тәэ-

сир итте. Сәлимнән ул әз генә дә курыкмады. Шыртламады да, ичмасам! Бу минутта аның күңелендә дулкын-дулкын булып бөтенләй икенче төрле хисләр калкып чыкты. Бу минутта аның күңелендә, барыннан да элек, үч алу теләге калкып чыкты.

Килүчегә ул җентекләбрәк карады. Бу чыннан да ул иде. Озын кунычлы яхшы күн итек кигән, куе зәңгәр галәфи чалбар кигән, иңбашына шәп каешлы шәп сумка таккан, фуражкалы, кобуралы. Тормышыннан туйган чакларында, бар нәрсәгә җен ачулары килгән чакларында еш кына ул аны исенә төшерде. Андый чакларда кайчан да бер аның белән очрашу турында, очрашкач ныгытып, усал итеп үч алу турында хыялланды. Үзенчә ул аңа инде мең төрле җәза уйлап тапкан иде.

Әйе, бу — ул... аннан көлгән, аны мыскыл иткән бәндә. Иң явыз дошман. Аның белән бу дөньяда да, теге дөньяда да — беркайда, беркайчан килешү дә, аңлашу да булырга мөмкин түгел. Менә шул бәндә хәзер аны... Хәмдияне кулга алырга килә!

— Кызым, Хәмдия! Ишетмисеңмени?!— диде әнисе, ялварып, җыларга җитешеп.— Безгә килә бит! Әнә капкадан керә!

— Керсен,— диде Хәмдия, усал итеп.— Өйдәме балта — башын сугып ярам. Кереп кенә карасын, аягын гына атласын!

— Әстәгафирулла тәүбә!— диде әнисе, коты алынып.— Балаң турында уйла, безнең турыда. Харап итмә, кызым!

Җилтерәтеп ул Хәмдияне җиңеннән тотып алды. Сандык өстендәге баланы чүпрәкләре белән бергә җыеп төрде дә кызының кулына тоттырды һәм этеп-төртеп икесен дә баз капкачы янына китерде. Баласын кулында тою белән Хәмдиянең кинәт зиһене яктырып киткәндәй булды. «Төшмичә ярамый,— дип уйлады ул гаҗәеп бер тынычлык белән.— Чыннан да... әнкәй, Әлтәф...»

Җайлап кына баскычның беренче басмасына басты — өйнең идән асты биек иде һәм базга төшү өчен, капкач кырыена терәп, бер-ике басмалы баскыч куелган иде. Еламасын өчен улына «ашарга» бирде, каушамыйча-кабаланмыйча аны әйбәтләбрәк төрде дә икенче басмага басты.

Хәмдия баз авызында күздән югалганда чоланда аяк тавышлары ишетелде. Камиләттәй ул арада тиз генә капкачны ябып куйды, ашыгып өстәл янына килде һәм ку-

лына кашык алды. Өстәлдә ашлы өч күбәтә торуына ул бөтенләй игътибар итмәде.

Өй ишеге кисәк кенә ачылып китте һәм ажгырып, газраил булып, тук һәм үз-үзеннән канәгать кыяфәтле, киң күкрәкле, буйчан милиционер килеп керде. Килеп керде дә, дагалы итекләре белән агач идәнгә шак-шок басып, туп-туры түргә узды.

— Исәнмесез,— диде көттереп, коры гына.

— Бик исәнбез, Сәлим улым,— диде Камиләттәй, урыныннан кубып.

Милиционер аның урынына сикегә утырды, өй эчен күздән кичерде дә өстәлдәге табак-савытларны читкәрәк сыпырды һәм иңбашындагы сумкасын салып актарына башлады. Камиләттәй белән Әлтәф, телсез калып, аның беренче сүзен көттеләр. Сәлим никтер чамадан тыш әкрен кыланды. Өстәл өстенә сузып салынган сумкасыннан, ниһаять, кирәкле язуын табып алды.

— Менә нәрсә, гражданка Ахмитуа,— диде башын калкытып.

— Нишләп мин граштанка булыйм, Сәлим улым?— диде Камиләттәй, хәтере калып.

— Тыңлап тор!— диде Сәлим, каты гына.— Кызың качып ята икән синең. Так как сугыш вакыты немескә каршы, нәрсә була ул, беләсеңме? Кая кызың?

— Кызым?— диде Камиләттәй, теле көрмәлеп.— Туктале син, Сәлим улым... ни бит әле...

— Кая качты?— диде Сәлим.— Качалмас, барыбер табарбыз!

— Бу ни эш бу?— диде Камиләттәй, исен-акылын җыя башлап.— Кем әйтте аны качып ята дип? Үз өендә кеше качып ятамыни?! Менә син агай! Нинди сүз бу? Сорау юк, нитү юк — кеше өенә басып керәсең.

— Ярар, күп сөйләнмә!— диде милиционер, тупас кына.— Мин үз эшем белән йөрим. Закун кушканча йөрим. Кая кызың?

— Минекеләр дә закун өчен йөриләр,— диде Камиләттәй, теле чишелгәннән-чишелә барып.— Икесе сугышта башын салды, берсе әнә аяксыз калган. Ятим дигәч тә, нигә мыскыл итәсең алай?

— Телең озын, Камиләттәй,— диде Сәлим, йомшаргандай итеп.— Сине беркем мыскыл итми. Кызың кая? Хәмдия кая?

— Кая булсын — әле генә Уразыга китте. Төшкә кайта. Качып ятырга монда!

— Ярар,— аңлашылды,— диде Сәлим.

Шулай диде дә, башка бер сүз әйтмичә тышка чоланга чыгып китте. Дөбер-шатыр килеп төрле почмакларны, аулак урыннарны карады, эзләгән кешесен бер җирдә дә таба алмагач, чормага менеп китте. Аннан тузанга буялып төште дә абзар ягына юнәлде. Ләкин анда да ул Хәмдияне тапмады һәм үзенең уңышсызлыкка очравына әз генә дә кәефе кырылмыйча, шулай да рәсми дәрәҗәсен сакларга тырышып, кире өйгә керде, яңадан өстәл янына утырды. Озак итеп, бер бит тутырып акт язды һәм Камиләттәйгә эндәшеп:

— Кил, шунда кулыңны куй,— диде.

— Әнә Әлтәф куйсын — мин сезнеңчә белмим,— диде Камиләттәй.

Әлтәф җитез генә өстәл янына килеп басты һәм, әйткәнне дә көтмәстән, тиешле урынга үз фамилиясен язып куйды. Милиционер акт язуын бөкләп сумкасына салды, сумкасын шартлатып бикләде дә саубуллашып ишеккә таба атлады.

— Кайткач әйт, кешегә күзекмәсен. Бигрәк тә минем күзгә чалынмасын,— диде ул чыгып киткәндә Камиләттәйгә, тавышын әкренәйтеп.

Милиционер урамга чыгып беркадәр ераклашкач та, Камиләттәй шундук баз капкачын ачты.

— Чыгыгыз, китте!— диде кызына эндәшеп.

Ләкин идән астыннан нишләптер җавап кайтаручы булмады, шулай ук чыгып килүче кеше дә күренмәде. Камиләттәй тагын эндәште. Монысында да берни ишетелмәгәч, базга үзе төште һәм шул чакны караңгы идән астында көн яктысы күреп, аптырап китте.

— Баз ишеге ачык лабаса,— диде ул, үзалдына сөйләнеп.

Чыннан да, идән астындагы кечкенә ишек яртылаш ачык тора иде. Хәмдиядән җилләр искән иде.

## XXIV

Аның баздан ничек чыгып китүен беркем сизмәде дә, күрмәде дә. Якты җиргә аяк басу белән ул абзар ягына китеп барды, бакча аша чыкты да яр астына төште. Монда ул беравык тыңлап торгандай итте. Шул ук вакытта кая, кайсы якка китү турында да уйлап алды. Ул чишмә чокыры буйлап түбән төшәргә булды. Болай иткәндә елга буена барып чыгарга була иде. Елга аръягында исә урманнар да, чокыр-чакырлар да җитәрлек иде.

Абына-сөртенә ул яр астыннан китеп барды. Арттан

куа килмәсәләр яки алга төшмәсәләр, аны монда беркем күрә алмаячак. Чокыр эче тайгак, юеш иде. Аның аяклары әледән-әле таеп китте, бер-ике мәртәбә ул ялгыш суга басып алды, бер мәртәбә абынып чак-чак кына егылмыйча калды. Бала куркып җыларга тотынды, ләкин ана кеше шундук аның авызын шәл очы белән томалады да, пычранган кулын итәгенә сөртештерде дә ашыгып һаман алга атлавына булды.

Исән-имин елга ярына килеп җиткәч, янә тирә-ягына колак салып торгандай итте. Аны чынлап та беркем дә куа килми иде, ахрысы. Шулай да ул үзенең тулысынча котыла алуына ышанып җитә алмады һәм, анымоны уйлап тормыйча, туп-туры елгага ташланды — өчдүрт метр киңлегендәге боздай салкын су аша чыкты һәм тагын яр буйлап китеп барды. Күлмәк итәкләреннән шыбырдап су акты, маңгаеннан шыбырдап тир акты.

Хәзер ул үргә таба барды. Яр читендәге куе талларны, баткак урыннарны узгач, икенче бер чишмә чокыры турысына килеп чыкты. Авыл уртасыннан ага торган елгага сул яктан килеп кушыла торган бу чишмә чокыры үргә, калкулыкларга таба сузыла иде. Ул шунда борылды һәм адымнарын әз генә дә әкренәйтмәскә тырышып, кырлар-басулар ягына үрмәләвендә булды. Бераздан ул куе таллыкка килеп керде. Тал арасыннан баруы шактый кыенлашты. Таллыктан чыгып яр өстенә менде, яр кырыена утырды да куаклар арасыннан артка, авыл ягына әйләнеп карады.

Юк, аны беркем дә куа килми. Ул, ахрысы, чынлап та котылды.

Ул тынычлангандай булды. Ләкин монда барыбер озаклап утырырга ярамый иде. Аны һаман нидер әйдәп, каядыр куалап торды. Ул яңадан кузгалып китте. Астагы тал куакларына ышыкланып ул хәзер яр өсләтеп барды. Чокыр төбендәге куаклар беркадәр җир киткәч өскә дә менделәр, әледән-әле аның каршысына чыгып утырдылар. Тал куаклары җирек, шомырт, миләш белән алышынды. Әрәмә никадәр киңәймәсен, Хәмдия һаман читтән генә барырга тырышты һәм шулай бара торгач берзаман тигез, такыр җиргә килеп чыкты. Монда ул үзен беркадәр дәрәҗәдә иректә итеп сизде. Уң яктан, авыл ягыннан аны әрәмә каплый, сул якта, алда, артта туган кырлар-басулар җәелеп ята. Көн кояшлы, күктә тургайлар сайрый. Язгы хуш исләр аңкытып яткан басу өстендә беленер-беленмәс кенә булып рәшә тирбәлә. Алда,

үр буйлап күтәрелә барган басу читендә, караеп иkенче бер әрәмәлек күренә. Әрәмә артында исә — төпсез-зәңгәр күк астында — иксез-чиксез бушлык һәм иркенлек барлыгы сизелә.

Хәмдия туп-туры күк читендәге, ерактагы әрәмәгә карап китте. Аны хәзер инде авыл ягыннан күрүләре дә мөмкин түгел. Күрсәләр дә ул бары бер нокта гына булып күренә торгандыр. Битләрендә кояш җылысын, як-ягында туган якның киңлекләрен тойган хәлдә ул туктаусыз барды да барды. Аңа никтер бар куркыныч өйдә һәм тегендә — чокыр-чакыр эчендә, таллыкта торып калды шикелле тоелды. Ул хәзер артына да борылып карамады, куа килү мөмкинлеге турында да уйламады. Ул бары күк читендәге каралҗым әрәмәгә барып җитәргә генә тырышты.

Әрәмә буена барып җиткәч тагын утырды, улының тәпиен тотты, өстендәге киемнәрен рәтләде, оекларының корымы, түгелме икәнлеген тикшереп карады. Шуннан соң ул баланы үзенең алдына утыртты. Әннәсе белән уйнарга Ирек бик тә ярата иде. Берни булмаган кебек бала шундук шаярырга тотынды: көлде, нәни генә куллары белән әнисенең борынына үрелде, үзе һаман нидер сөйләнергә азапланды. Борын тарту аның иң яраткан һөнәре иде. Борыннан башка ул тагын колакны, чәчне тарта белә. У-у, аның һөнәрләрен әйтеп-сөйләп бетерерлек түгел! Күңеле күтәренке чакларда ул качышлы уйнарга да ярата — битенә яулык каплый да качып тора, аннары яулык читен күтәреп карый. Үзе шундый шат, үзе елмая, «һайт!» дип сине үчекләп маташкан була. Аннары өстәл астына керергә, арттан урындыкны этеп йөртергә ярата. Бик үскән инде ул, тәти инде аның Иреге!

— Нишләргә соң хәзер, улым?— диде Хәмдия, улының күзләренә карап.— Безгә бит кайтырга ярамый. Безне тотып алачаклар, аңлыйсыңмы? Без көчкә котылдык. Ярый әле әннә исенә килеп өлгерде. Син коткардың мине, улым. Тагын син коткардың. Син булмасаң, улым, әннә-дивана туп-туры бүре авызына барып кергәние. Беләсеңме, ул кем? Ул дөньяда иң кабахәт кеше. Юк, ул синең... әтиең, улым. Ни хәл итәсең! — ул сиңа ата кеше. Миңа әллә нәрсә булды әле, улым. Никтер минем аңа ачуым килми башлады кебек. Ник ачуланырга? Нигә гомер буена күңелеңдә таш йөртергә? Ни әйтсәң дә, ул бит сиңа ата кеше. Син минем улым. Без дөньяда икәү генә. Безгә хәзер беркем кирәкми. Кара әнә тирә-ягыңа:

әнә безнең авыл, әнә безнең җирләр, әрәмәләр, чокыр-чакырлар. Әнә уңда Көшләби чокыры, әнә сулда, бик еракта — Очлы тау. Очлы тау астында Бүә буйлары зәңгәрләнеп күренә. Авыл читендә әнә калкулыкта безнең зыярат. Дүрт почмаклы урман булып утыра. Анда синең бабаларың йоклый, әбиләрең йоклый. Анда безнең барлык нәселебез ята. Әйдә, улым, ачуланмыйк аңа. Син инде тудың, син чын кеше, хуҗа кеше. Йөре шушы җирдән, туп-туры басып йөре, курыкмыйча, яшеренмичә йөре — бу безнең җир, улым! Синең бабаң, абыең... абыйларың шушы җирне саклап кан койдылар... кан коялар, улым!

Шулай сөйләнеп ул аны алдыннан төшерде. Иске үлән сабакларына абынып, басылган иске яфракларны, үләннәрне таптап, бала әнисеннән читкә үрмәләде. Ул әле ике аяклап йөри белми иде. Ул әлегә дүрт аяклап кына китте. Беләк буе җир китте дә туктап артына борылды, елмаеп әннәсенә карады.

— Бар, бар, улым, нык басып бар!— диде әннә, аны дәртләндереп.

## XXV

Әрәмәне чыккач, Хәмдия иске арба юлына төште. Юл аны каядыр читкә, еракка алып китте. Хәер, юлның кая барып чыкканлыгын ул бик яхшы белә. Бу тар гына арба юлы Яңавылга бара торган олы юлга тоташа. Яңавылга бара торган олы юл тагын да олырак, тагын да тапталганрак юлларга барып ялгана. Ул аларны белә, ул инде шактый күп юллардан узды. Алар кайда да бертөсле, тик менә юл читендәге кырлар-басулар гына, әрәмәләр, урманнар гына бүтәнчәрәк, чит һәм җансыз. Юк, беркайда да җирнең өсте мондагыдай гүзәл, мондагыдай якын түгел.

Кая барганлыгын ул бик үк аңлап та җитмәде. Ул бары бер урында туктап тора алмаган өчен генә барды бугай. Ләкин туган авылыннан, туган кырларыннан ераклаша барган саен аның аяклары үзеннән-үзе әкренрәк атлый башлагандай булды. Шул ук вакытта ул үзен куа килүчеләрдән бөтенләй курыкмый башлады. Әллә аңа яңадан көч-куәт, гайрәт кайтты, әллә нидер башка нәрсә булды. Олы юл аны тимер юлга, вокзалга илтеп куячак. Вокзалга барып җитә алдыңмы, анда инде ничек тә исән калырга була. Уңга, сулга поездлар китеп тора. Берәрсенә эләгәсең дә китәсең дә барасың күз күрмәгән, ко-

лак ишетмәгән якларга. Теләнергә, соранырга була. Кайтты ич әллә кайлардан. Кайткан җиргә кире китәргә дә була. Көзгә кадәр, сугыш беткәнчегә кадәр түзсә, анда инде күз күрер.

Әледән-әле ул шулайрак фикер йөртте. Ләкин әлегә бернинди карарга да килә алмады. Туган ягы, авыр йөк булып, адым саен аның аягына урала барды.

Бара торгач, юлда — арба юлы олы юлга тоташа торган турыда, юл буендарак ябулы ындыр табагы күренде.. Ындыр табагы янында былтыргы салам өеме дә бар иде. «Шунда утырып ял итим әле»,— дип уйлады Хәмдия. Ул бик арыды. Ул бит иртән рәтләп ашый да алмады. Ярый әле улына сөт эчерергә өлгерде.

Салам өемен ул төрле яктан карап чыкты. Шуннан соң ындыр табагын караштырды. Кибәк өеме янына килеп, кибәкнең яңадан җилгәрелгәнме, юкмы икәнлеге белән кызыксынды. Кибәк өемен актарып, яңабаштан җилгәреп бетергәннәр иде. Эскерт калдыгы да як-яктан таланып беткән — аскы ягы куенланып, батынкы булып калган. Хәмдия шул куенланып торган өем итәгендә җайлырак бер урын карады да оя ясап шунда кереп утырды. Аякларын иркенләп сузып җибәрде. Шул чакны ул үзенең бер кат йон оекбаш белән генә булуын күреп алды. Гаҗәп, ул аны чокырда килгәндә дә күрмәде, әрәмә буенда утырганда да күрмәде.

Бала йоклаган иде. Ул аны уятып тормады — чүпрәкләрен баш астына җайлабрак куйды да саламга яткырды һәм өстенә иске шәлен ябып куйды. Шуннан соң, тәмам онытылмакчы булып, үзе дә күзләрен йомды.

«Әгәр шушында гына торып калсам... менә шушылай?»— дип уйлады ул, яңадан үзенең котылгысыз хәленә кайтып. Элек качкыннар яшәгән бит... менә шулай салам, печән кибәннәрендә, урман эчләрендә. Хатын-кыз да качкын була алмыймыни? Һич югы сугыш беткәнче? Очлы тау ягында, Сакат тау якларында әллә нинди урыйн җирләр бар дип сөйлиләр... Юк, анда куркынычрак. Авыл тирәсендәрәк, өйгә якынрак кирәк. Төннәрен өйгә кайтып килергә була.

Мондый уй аңа бик тә мавыктыргыч булып тоелды. Ул салам арасында күренгәләгән башакларны тотып-тотып карады, ләкин бер генә тук башак та тапмады — башакларның барысы да сугылган, барысы да җиңеләеп калган иде. «Юк, әлегә иртә»,— диде ул үз-үзенә, баштагы уйларыннан суынып. Урманда, басуларда әлегә ашардай

бернәрсә дә юк. Иң кытлык чак, иң өзек чак. Өйгә кайтсаң, өй тирәсендә сагалап торулары бар. Булмый, берничек тә булмый. Булмый икән шул. Карале, берничек тә булмый икән ләбаса!

Хәмдия шулай артык пошынмыйча, кайгырмыйча гына уйланып утырганда, еракта, олы юлда җигүле ат күренде. Атлы кеше Яңавылга таба бара иде. Кызу килә, күрәсең, аты яхшыдыр. Хәзерге вакытта колхоз атлары алай кызу йөри алмас. Кем булыр бу? Яхшы атка утырып йөрергә хакы булган берәр олы начальниктыр йә булмаса колхоз председателедер. Хәзер яхшы атка алар гына утыра. Дөнья аларныкы. Көтүче Галиәхмәт менә нинди кеше булып чыкты! Икейөзле, куркак. Димәк, Шүрәле турысында Бүәгә күпер салганнар. Әллә Уразыга гына барамы соң бу бәндә?

Хәмдия аягына басты, салам артына посыбрак торган килеш, атлы кешенең якынлашканын көтә башлады. Аты моның чыннан да яхшы иде. Киң, таза күкрәкләре, янбашлары ерактан ук йомрыланып күренә, йөгәнендәге, эшлиясендәге җизләре иртәнге кояшта ялт-йолт килә.

...Начальник халкы ач түгел. Утырган саен авыз тутырып ипи ашый, ит-май ашый. Атлары да тук, балалары да тук...

...Әнкәсе дөрес әйткән. Ул күпне күргән. Аның сүзен тоткан булса, алар менә шушы хәлгә дә төшмәгән булырлар иде. Олы сүзен тотмаган, олыгайганчы игелек күрмәгән.

...Ул әнә бөтенләй якынлашып килә. Нидер эшләргә кирәк. Болай булмый. Болай була алмый.

...Башка чара юк. Юл бикле, юллар бикле. Рәнҗемә. Үскәч әле аңларсың, барысын да аңларсың, улым. Алар бай, алар тук...

## XXVI

Атлы кеше якынайганнан-якынайды. Озакламый ул юлында аркылы сузылып яткан киң чокырны чыгар да үр менәр, ындыр табагы янына килеп җитәр. Килеп җитәр дә, як-ягына карангалап, эре генә шушы төштән узып китәр. Юк, ул тиз генә узып китмәс. Китә алмас. Моннан китми, каян китсен — юл бит бер генә.

Кызу чабып килгән ат тиздән киң чокырның теге як кырыена якынлашты һәм, тагын да ныграк кызулап, аска төшә башлады. Атлы кешенең күздән югалуы булды,

Хәмдия ашыгып баласына иелде, ике куллап аны күтәреп алды да юлга таба йөгерде.

Бала һаман йоклый иде. Әннәсе күтәреп киткәч тә ул уянмады. Шулай ук җиргә, юл буендагы басылган кибәк өеменә китереп салгач та керфеген дә селкетмәде — иртән туйганчы сөт ашаганга, ахрысы, татлы төшләр күреп йоклавында булды.

Соңгы кат Хәмдия аның саф һавада алсуланган нәфис йөзенә күз төшереп алды. Ул аны үпмәкче дә булды, ләкин уятудан куркып, мондый уйдан шундук баш тартырга мәҗбүр булды.

Бала йоклап калды. Үзалдына татлы төшләр күреп, сабый бала юл буенда йоклап калды.

Ана кеше, алдын-артын карамыйча, салам өеменә таба йөгерде. Салам янында ул абынып китте, җиргә капланды, аягына басты да тагын йөгерә башлады.

Якында гына, бик якында гына аны урман көтеп тора иде. Бик озак тоелган күпмедер вакыттан соң ул шунда барып җитте. Шомырт, чикләвек куаклары, килүчегә юл биреп, ботакларын аерып җибәрделәр. Карт чыршы, пошынып, сагышланып, әкрен генә шаулап алды. Ул да аңа үз яныннан юл бирде һәм, арттан куанитә калсалар дип, ботакларын сузып аны каплап калды.

Күктә тургайлар сайрады. Күктә олы кояш карап торды. Җир өстендә, юл буенда берни белми сабый бала йоклап калды.

Кибәк арасында тычканнар кыштырдады, саламнарда бөҗәкләр йөрделәр, юл өстендә чыпчыклар сугышты. Әннәсенең иске шәленә төренеп, җылыда, йомшакта ятим бала йоклап калды.

Ана кеше тыны бетеп, хәле бетеп, һаман еракkарак качты. Көтмәгәндә усак аңа аяк чалды. Ана кеше йөзтүбән җиргә капланды. Кайгырудан, сызланудан җирнең өсте тетрәп китте. Карамалар, ак чыршылар, аһылдашып, кайгырышып чал башларын чайкадылар.

Ана кеше күзләрен ачты. Яткан килеш юл ягына борылды да, уттай янган күз карашын чыбык-чабык арасыннан бер ноктага юнәлдерде.

Атлы кеше туктаган иде. Ул нәкъ кибәк өеме турысында туктап калган иде. Күн итекле озын аякларын аерып баскан килеш, кулларын кобуралы биленә таянган килеш кибәк өеменә карап тора иде. Кибәк өстендә йоклап яткан кешене танымакчы булып азаплана иде бугай ул. Әллә аны үле дип белде микән? Күрәсең, шулай

дип белгәндер, чөнки... итек очы белән ул аңа төртеп карады.

Шул чакны җирне-күкне дер селкетеп, үзәкләрне өзеп, ярдәм сорап тере кеше бар дөньяга сөрән салды.

— Аһ!— диде ана кеше ыңгырашып, күкрәгенә тотынып.

## XXVII

Хәмдия күзләрен ачканда, көн инде төнгә әйләнгән иде. Ята-ята ул үзенең кайдалыгын исенә төшерергә тырышып карады, ләкин бернәрсә дә хәтерли алмады. Торды, алпан-тилпән атлап, битен-кулын ботакларга сыдырттырып юлга чыкты. Бары шунда гына ул кибәк өемендә йоклап калган улын исенә төшерде.

Кибәк өеме янына ул елмаеп, куанып килде. Бала йоклап ятарга тиешле урынны капшап карагач исә берни тапмады. Куаныч тойгысы шундук юкка чыкты. Шулай да ул өметен өзмәде — ашыгып салам өеме янына килде. Ләкин кулга кадала торган саламнан башка, бушлыктан, салкынлыктан башка анда да берни тапмады. Шуннан соң ул үзенең саламдагы оясына кереп утырды һәм уйлана башлады.

Кайда булыр ул? Бит ул аны шушында гына калдырып китте. Кая булган ул, ә, кая булган?! Аюлар-бүреләр алып китте микәнни? Ул бит аны йокларга гына яткырган иде. Йоклаган баланы аюлар, бүреләр алып китәргә тиеш түгел ләбаса!

Оясында ул озак утыра алмады. Торып яңадан кибәк өеме янына килде. Йелде дә бала ятып калган урынны ипләп кенә сыйпалап карады, аннан соң кибәкне уып, учында җилгәреп карады. Юк булгач юк. Буш кибәкләр арасында, ичмасам, бер генә тугы да табылмады. Кулларын, тузгыган чәчләрен салындырып ана тораташтай катып торды-торды да ындыр табагы уртасына таба китеп барды, түбә астына керде, багана төпләрен, чүп-чар өеме тирәләрен караштыра башлады.

Кинәт аның аягы ниндидер йомшак нәрсәгә тиеп китте. Ирек! Бу аның улы камыл арасында йоклап ята иде. Акылыннан шашкан ана чырылдап кычкырып җибәрде, тычканга ташланган песи кебек бар көченә камыл арасына ыргылды. Ләкин тоттырмас бала тагын юкка чыкты һәм көлә-көлә каядыр йөгереп китте.

Йөгергән улын тотмакчы булып ул яңадан салам өеме янына килеп чыкты, яңадан үзенең яраткан оясы-

на кереп утырды да күзләрен йомып уйланырга тотынды.

Чыннан да, кая куйды икән соң ул аны? Әнә түгел лә инде ул югалып ятырга!

Күпмедер вакыттан соң ул үзенең туңа башлаганлыгын тойды. Язгы төн салкын иде. Күлмәкчән кешегә исә бигрәк тә салкын иде. Аның кинәт зиһене яктырып китте. Ул шундук урыныннан сикереп торды һәм ашыгып, тыны бетеп авыл ягына таба йөгерә башлады. Үзендә ул бик нык хәлсезлек тойды, ачыгу тойды. Аның хәзер аяк кузгатырлык та хәле юк иде. Шулай да ул туктаусыз каядыр атлавында булды.

Бераздан кемдер аны арттан куып килә шикелле тоелды. Аңа һич тә тоттырырга ярамый иде, аңа ничек тә өйләренә, әнисе янына, Әлтәф янына кайтып җитәргә, базга кереп яшеренергә кирәк иде. Ләкин көндез, утырып торган әрәмә янына килеп җиткәч, куа килүчеләрнең артта түгел, бәлки алда, авыл ягында булулары билгеле булды. Коты алынып ул кире борылды.

Бераздан ул яңадан ындыр табагы янына килеп чыкты. Аның улы, берни булмагандай елмаеп, юл буенда йоклап ята иде! Шатлыгыннан ул кычкырып җибәрде, юлга тезләнде дә, улын кочагына алды да... тез капкачының бик нык авыртканлыгын тойган хәлдә шашынып яңадан аягына басты.

Ул тагын аңына килде. Куркуыннан, хәлсезлектән шыбыр тиргә батып тагын авыл ягына китеп барды. Төн урталарында, ниһаять, авылга кайтып җитте.. Капкалары янына килеп туктады, керергәме-кермәскәме белмичә, икеләнеп калды. Аның тагын башы әйләнде, зиһене буталды. Кемдер аны өйдә көтеп, сагалап тора шикелле тоелды. Капка келәсенә тотынган кулын кисәк кенә тартып алды да алдын-артын карамыйча якындагы чокыр ягына китеп барды.

Көтмәгәндә ул Салкын чишмә янына килеп чыкты. Түмәргә утырып, чишмә тавышына колак салып карады. Ләкин берни ишетмәде. «Чишмәләр төнлә йоклый дип сөйлиләр иде, дөрес икән»,— дип уйлады ул, тыныч кына. Иелеп салкын суда кулын юды, битен юды, шуннан соң оекларын салып аягын юды. Юынгач, тазарынгач, чыклы чирәмдә эз калдырып, җырлый-җырлый болын буйлап Очлы тау ягына, Бүә буена печән чабарга китеп барды. Бүген анда Азат та килергә тиеш. Тизрәк, тизрәк барып җитәргә кирәк!

Сүз тыңламас аяклары аны чокыр аша, елга аша ниш-

ләптер юл буендагы ындыр табагы ягына алып китте. Әһә! Анда бит аның улы көтеп ята! Ул бит анда берүзе. Җылап кына ятмаса ярар иде! Азат та шунда гына булса ярар иде, Ходаем!

Җанлы кара шәүлә булып, акылыннан шашкан хатын ындыр табагына килеп җиткәндә төн авышкан иде инде. Тик шулай да күктә йолдызлар яна иде. Тавышланмаска тырышып, шыпырт кына ул үзенең куышына кереп утырды, песи кебек бөгәрләнде дә куа килүчеләр күрмәсен өчен күзләрен йомды, кулы белән битен каплады.

Юк, хәзер аны беркем күрмәде. Күрә алмады. Үзе ул бөтен җир өстен, бөтен күкне күреп ятты. Якында гына караеп юкәләр, чыршылар утырды, еракта башы йолдызларга тигән Очлы тау күренде, аяк астында гына йомшак кына шуышып серле Буә акты. Акты да акты. Тирәякта — җәйге тын, бөркү һавада яңа чапкан печән исе, бал исе, чичкә исе аңкыды. Кемдер аның башыннан-чәченнән сыйпады. Азат бугай. Әллә Ирекме соң? Ә, көймәче карт икән.

— Хуш, кызым, юлың уң булсын,— диде көймәче карт.

— Рәхмәт, бабай... рәхмәтләр яусын сиңа, бабакай!— диде ул пышылдап, үзалдына елмаеп.

* * *

Ике-өч көннән, таң алдында, бәләкәй арба тартып, югары оч хатыннары салам урларга килделәр. Салам эчендә бөгәрләнеп яткан күлмәкчән хатын-кызны күреп каракларның коты алынды. Арбаларын ташлап болар качыша башладылар.

— Кая качасыз, үлгән ич ул!— диде шунда берсе, батыррагы.

Куркакларга җан керде. Кире килделәр дә салам оясында бөгәрләнеп мәңге тынып калган ят хатынны читтән генә караштыра башладылар. Арадан берсе танып алды.

— Хәмдия түгелме соң?! Уф, Алла!— диде йөрәк яргыч итеп.

— Кем Хәмдиясе? Сабирәттәйнекеме?— диде икенчесе.

— Камиләттәйнеке. Качып кайткан икән дигәннәрие аны,— диде таныган хатын.

Төштән соң ындыр табагына авыл советыннан кешеләр килде, кобуралы, фуражкалы милиционер килде. Ачлык-

тан кабыргалары беленеп торган колхоз аты арбага сузып салынган яшь хатын мәетен авылга, аннан соң зыяратка чаклы тартып алып кайтты. Авыл читендәге, калку урындагы урман сыман зыяратта гарип-гораба, хәлсез ирләр, картлар кабер казып куйганнар иде. Арбадагы Хәмдияне шунда күчерделәр. Бабалары янында, әбиләре янында ул мәңге йокыга талды.

*1965, Казан*

# ХИКӘЯЛӘР

## ӘТТӘ!

Дебаркадердан пароход палубасына салынган сырлы басма буенча соңгы пассажир йөгереп үтте. Матрослар, бик җитез кыланып, басмаларны тартып алдылар; трослар ычкындырылды; иннек ябылды, һәм канатлы тәгәрмәчләр, суга шап-шоп бәреп, башта әкрен генә, аннары һаман ныграк, кызурак әйләнә башладылар. Пароход сиздермичә генә дебаркадердан аерылып китте, бер йөз метр чамасы үргә менде дә, бик зур әйләнгеч ясап, түбәнгә таба борылды.

Мин, палуба кырыена таянып, ерагая барган яр читенә, андагы каралтыларга, йортларга һәм су өстендә кыймылдашкан пароход-катерларга, көймәләргә бераз гына карап тордым да салкын җил исә башлагач та кереп киттем. Вакытны тизрәк үткәрү өчен, мин, өченче класстагы үз урыныма утырып, китап укырга тотындым.

Мин терсәкләр белән тез башына таянган көе, китапны бик түбән тотып, бөтен гәүдәм белән иелеп укыдым. Шулай утыра торгач, көтмәгәндә минем китапка бармак очлары әз генә пычранган бер бәләкәй генә ак кул килеп тотынды. Мин укудан аерылып, башны күтәреп карарга мәҗбүр булдым. Минем каршыда яшь ярым-ике яшь чамасындагы бер ир бала басып тора иде.

Башына аның ак кәҗә мамыгыннан бәйләнгән йомшак җөнтәс башлык, өстенә бик зур ике кара төймә белән каптырылган кыска гына карасу сырма кидерелгән иде, аякларында исә өр-яңа нәни генә кызгылт чүәк иде. Аның тулып, бүлтәеп торган матур бит очлары, шулай ук авыз читләре, бармаклары кебек үк, ниндидер нәрсәгә пычранган иде, ләкин түгәрәк кара күзләре искиткеч чиста, гүзәл иде.

Аның шулай бер дә юктан мине укудан бүлдерүенә бик үк канәгать булмасам да, мин аны янымнан куып җибәрергә яисә аның кулын китаптан сыпырып төшерергә ашыкмадым, киресенчә, саран гына булса да елмайгандай итеп:

— Әллә укыйсың килә?— дидем.

Бала, минем ачусыз тавышымны ишетеп, тагын да ныграк кыюланып китте — китапка ике куллап тотын-

ды да, минем сорауга җавап биргән кебек, китапны бар көченә үзенә таба тарткаларга тотынды. Шул ук вакытта ул чатнап торган көр тавыш белән:

— Титап! Титап!— дип кычкырды.

— Китап шул, китап,— дидем мин.

Малай, авызындагы берничә ак тешен күрсәтеп, куанычлы төс белән елмаеп җибәрде, китапны ычкындырды да, кисәк кенә борылып, читкә йөгереп китте һәм каршыдагы бер зур чемоданның тимерле тоткасын шалтыратырга кереште.

— Тәтәй! Тәтәй!— диде ул, күрәсеңме минем нинди зур һөнәрем бар дигән шикелле, әледән-әле минем якка карап.

Мин, уку турында бөтенләй онытып, бу тиктормас, әрсез танышымның кыланышларын ниндидер бер соклану белән, ярату белән күзәтеп утыра башладым.

Чемодан тоткасын шалтырату аны тиздән туйдырды, ахрысы, ул йөгереп яңадан минем каршыма килде дә, минем күзгә карап:

— Таз! Сәлам, таз!— диде.

— Нәрсә, нәрсә?— дидем мин, берни аңламыйча.

— Таз, таз!— диде минем дус, минем кулдагы карандаш кисәгенә үрелеп, һәм мин аны-моны искәреп өлгергәнче, карандашны эләктереп алды да китап битенең бер почмагыннан икенче почмагына кәкре-бөкре сызык сызып җибәрде.

— Ах, сине!— дидем мин, ачуланган булып.

Малай, үзенең бик үк ярап җитмәгән эш эшләвен шәйләп алып, көлә-көлә чемодан ягына йөгереп китте. Мин, аның артыннан кул чабып:

— Тотыгыз каракны, тотыгыз!— дигән булдым.

Шул чакны якында гына ниндидер хатын-кызның:

— Мәҗит!— дип эндәшкән тавышы ишетелде.

Ак яулыгын артка җибәреп бәйләгән, чандыр гына, озын гына гәүдәле, илле-алтмыш яшьләр чамасындагы бер карчык аяк астына куелган чемоданнар, капчыклар һәм тыгызланып утырган кешеләр арасыннан үтеп, малай янына килде дә аның кулыннан тотып алды.

— Абыең укысын. Әйдә,— диде ул, баланы үз артыннан ияртергә итеп.

Мәҗитнең куанычлы кыяфәте кинәт үзгәреп китте, беленер-беленмәс кенә сызылып торган ике-өч бөртек кашлары тартышып куйды, йөзе шундук ачулы-ризасыз төс алды. Ул елак тавыш белән киреләнеп кычкырырга, карчыкның (күрәсең, әбисенең) сөякчел зур кулын кыйнарга тотынды. Аның моннан китәргә теләмәве ачыктан-ачык күренеп тора иде.

— Уйнасын әйдә, уйнасын. Миңа аның бернинди зыяны тими,— дидем мин карчыкка, ә үзем күңелдән: «Бик чорсыз өйрәткәннәр балаларын»,— дип уйлап куйдым.

Әллә малайның теләгенә бик үк каршы килмәскә теләп, әллә инде минем сүзгә колак салып, карчык Мәҗитне башка кыстап тормады, кулын ычкындырды да, нишләтәсең инде сине дигән бер кыяфәт белән, усал малаена көлемсерәп карап тора башлады.

Мәҗиткә мин нәрсәм беләндер бик мәхәббәтле күрендем, ахрысы. Ул йөгергәләп тагын минем каршыма килеп җитте, ләкин монысында китапка әйләнеп тә карамады — утыргыч читенә тотынды да, боерган, таләп иткән бер тавыш белән:

— Мен! Мен!— диде, көчәнеп.

Мин аның утыргычка менәргә теләгәнлеген аңлап алдым. Китапны бер читкә куйдым да, ипләп кенә аның ике култык астыннан тотып, үз яныма күтәреп алдым.

Үз теләгенә ирешкәч, аның куанычы, әйтерсең, эченә сыймады — ул авызын ерып көләргә, кычкырырга тотынды, бераз гына кәкре аякларын, биегәндәге кебек итеп, селкетеп-селкетеп алды. Аннан соң сизмәстән китапны күтәреп минем тез өстенә ташлады да, үзенең һаман бер үк сүзен кабатлап:

— Таз, сәлам таз!— диде.

— Яз, сәлам яз,— диде әбисе, ул әйткәнне олылар теленә күчереп.

Ут бөрчәседәй тере, күңелле бу бала миңа торган саен ныграк ошый барды. Минем аңа ни дә булса бүләк итәсем килде, һәм, аңа бирердәй нәрсә булса да тапмакчы булып, кесәләремне актарырга тотындым. Чалбар кесәсендә торып калган бер биш тиен бакырны суздым да:

— Нәрсә бу?— дидем.

— Акса!— диде Мәҗит, бер дә аптырап тормыйча.

Биш тиенне ул тиз генә учына алып йомды. Аның учы шундый бәләкәй иде, ә бу бәләкәй уч төбендәге биш тиен бакыр шундый зур иде — уч төбен акча бөтенләй каплады һәм бармак араларыннан ялтырап күренеп калды.

Мәҗит кинәт акчаны бәреп җибәрде, һәм бу вакытта ул, әлбәттә, һич тә кычкырмый булдыра алмады. Биш тиен бакыр чылтырап идәнгә барып төште, дуга сыман сызык ясап әз генә тәгәрәп барды да, кемнеңдер калын табанлы күн итегенә бәрелеп, капланып калды. Мәҗит минем тез буенча идәнгә шуышып төште, биш тиенне барып алды да аны тагын бәреп җибәрде.

Болай акча бәреп уйнау аңа бик кызык тоелды, ахрысы,— биш тиенне ул бер бәрде, бер алды, акча эзләп

утыргычлар астына кереп чыкты, акчасы ераграк тәгәрәсә яисә берәр әйбер арасына кереп кысылса, шундук аңа олылар ярдәмгә килде.

Акча белән уйнауның да, ниһаять, кызыгы бетте. Мәҗит бер-ике мәртәбә минем тирәдән әйләнеп китте дә аяк астында аунап яткан биш тиен бакырга да, бернигә дә, беркемгә дә карамыйча, әбисе алдына барып утырды.

Минем кич шулай узып китте. Мин, палубага чыгып, саф һава иснәп кердем һәм өске сәндерәгә урын җайлап, йокларга яттым.

Күпмедер вакыт уткәч, төн урталарында, йокы аралаш ниндидер бала елаганын ишетеп, мин кисәк кенә уянып киттем. Төнлә ниндидер ят тавыш ишетеп, бигрәк тә бала елаганны ишетеп уянып китүдән дә күңелсезрәк нәрсә юктыр. Мин, елаучы балага үртәлеп, яңадан йокыга китә алмыйча бик озак яттым.

Шулай күпме ятканмындыр — хәтерләмим. Тик яңадан күзләремне ачып җибәргәндә, инде бернинди елау тавышы ишетелми иде, таң аткан иде, һәм бөтен дөнья ничектер бик сәер рәвештә тынып калган иде.

Мин башымны калкытып тирә-ягыма каранып алдым: сәндерәләрдә беркем калмаган иде. Мин пароходның Тәтешкә килеп җиткәнлеген аңлап алдым, идәнгә сикереп төштем дә, авыз ачып иснәнә-иснәнә, чыга торган ишеккә юнәлдем. Пароходтан мин иң соңгы пассажирларның берсе булып чыктым.

Баскыч буенча мин өскә — вокзал бинасына мендем. Ләкин бу әле ярның иң өстенә менеп җиттем дигән сүз түгел иде.

Тәтешкә беренче мәртәбә килеп төшкән кеше барыннан да элек монда Идел ярының биеклегенә игътибар итә. Бернинди агач-фәлән үсмәгән һәм кайбер җирләрендә катлам-катлам булып аксыл, яшькелт ташлар, таш сыман ком кисәкләре күренеп торган шәрә кызыл яр елгага бик текә булып төшә. Өстә яр кырыеннан ук шәһәр урамнары башланып китә, ләкин дебаркадердан яисә вокзал йортыннан үрелеп карасаң, анда бер-ике бәләкәй өйдән, бакча киртәләреннән башка берни күрмисең, һәм, киресенчә, өстәге яр читенә басып аска карасаң, елга кырыена сыенып утырган дебаркадер да, аның янындагы көймәләр-фәләннәр дә, пароходлар да, яр читенә елышкан йортлар да бик еракта гы кебек бәләкәй генә булып, уенчык кына булып күренәләр.

Менә шушы таудай биек, кыядай текә ярга агач баскыч салынган. Югарыга таба туры гына сузылмыйча, боргаланып-сыргаланып менгән бу җәһәннәм баскычы шундый озын һәм аның басмалары шундый күп, шәһәргә юл

тотучы кайбер кешеләр, аның очына чыкканчы, гадәттә, икешәр-өчәр мәртәбә туктап-туктап ял итеп алалар.

Минем кулда газетага төреп тоткан әлеге китаптан башка бүтән берни юк иде, шуңа күрә мин, вокзалда әз генә дә тукталып тормыйча, шәһәргә менә башладым. Озакламый мин баскычның буеннан-буена сибелгән һәм әкренләп-әкренләп югарыга таба үрмәләгән кешеләрнең иң арттагыларын куып та җиттем.

Шул чакны мин баскычтагы кешеләр арасында кичәге карчыкны күреп алдым. Уң кулына ул Мәҗитне күтәргән иде, ә сул кулы белән баскыч култыксасына тотынып бара иде. Ул бик хәлсезләнгән иде.

— Әби!— дидем мин, аннан бер-ике басма алга чыгып.

Карчык туктап калды. Мин кулдагы китапны аңа тоттырдым да:

— Каяле, әби, Мәҗитне үзем күтәреп меним,— дидем.

Ул, мондый тәкъдимгә бик риза булып, Мәҗитне миңа бирде. Малай да миңа килмәскә итеп киреләнеп-нитеп тормады, киресенчә, мин аны күтәреп беләгемә утырткач та, балаларга гына хас эчкерсез бер ярату белән минем муеннан кочаклап алды.

— Син, әйдә, әби, үз җаең белән генә менә тор,— дидем мин, кузгалып.

Мәҗит башта миңа бик җиңел тоелды, ләкин менә-менә ярыйсы гына авырая башлады. Мин еш-еш тын алдым, баланы әле сул як беләгемә, әле уң як беләгемә алыштырдым. Баскычның бер борылышындагы киң генә идәнгә килеп менгәч тә, утырып хәл җыяр өчен ясалган утыргычка утырдым да, Мәҗиткә эндәшеп:

— Әбиеңне көтик инде... артка калды...— дидем.

Карчык чыннан да бик артка калган иде. Бер ун минуттан ул, ниһаять, безнең янга менеп җитте дә, сул кулы белән эченә тотынган көе, утыргычка килеп утырды.

— Ай... шушы баскычлар булмаса...— диде ул, тыны бетеп.

— Баскыч булмаса, әби, бөтенләй менеп булмас иде моннан,— дидем мин, көлеп.

— Ай... мең-мең рәхмәт инде...— диде карчык, минем сүзне ишетмәгән кебек.— Каян килеп чыктың... рәхмәт яугыры...

Мин, башын күкрәгемә салып, тын гына минем тез өстендә утырган Мәҗиткә иелдем дә, аның белән сөйләшкән сыман:

— Абыйсын онытмаган,— дидем.

— Кичә... сине эзләп... теңкәгә тиеп бетте...— диде карчык.— Төне буе... көйсезләнеп... җылап чыкты...

Мин төнлә бала елаган тавышка уянып китүемне искә төшердем һәм бераз сүзсез утыргач:

— Кем малае соң бу, әби?— дидем.

— Кемнеке дип әйтергә дә белмим инде...— диде карчык, көттеребрәк. Аннан соң, бала үзе ишетә-нитә күрмәсен тагын дигән сыман, әкренрәк тавыш белән: — Кызымныкы... кызымның малае,— дип куйды.— Казаннан алып кайтам... бөтенләйгә инде. Карт белән без икәү генә, тагын унбер яшьлек бер кызыбыз бар. Артмас әле үзебездән. Моңа берни сиздермәбез дибез инде, үзебезнең бала итеп үстерербез дибез инде... Тынышып торалмадылар шул, тынышып таралмадылар — нишләтәсең аларны... Язмыштыр инде... язмыштан узмыш юк. Былтыр гына аерылыштылар. Болай бик әйбәт кеше ие үзе, бардың исә: «Әби!» дә «Бабай!» дип кенә торадырые. Тынышалмадылар шул, тынышалмадылар. Төсе-бите белән сиңа тартымрак ул. Аерылышкачтын озак тормады — бер яшь кызга өйләнде. Баланы үзенә алырга иткәние дә — бирмәдек. Хатыны да якын да җибәрмәгән: балаңны алдың исә, бер көн тормыйм, китәм, дигән. Шуннан соң тынды, бүтән сорамады. Акчасы килеп тора... Әле менә картка бишмәт тектердек шуңа, кыз үзенә күлмәк ясатты... Яшь кешегә авыр шул, авыр. Җиләктәй чагы дигәндәй... Бик чибәр минем кыз, бик чибәр!.. Гомер буе бер балага карап кына да утырып булмый. Яхшы кеше туры килгәч, үзебез дә каршы килмәдек. Казанда үзенең йорты бар, бакчасы бар, аена меңгә якын акча ала. Ул байлык дисеңме, ул кием-салым дисеңме — өстеңә ишелерлек, бүлмәләренә керсәң, әйләнеп чыккысыз... Балалы кеше бер җирдә дә сыймый шул, сыймый... Этле кунак өйгә сыймас, дип белми әйтмәгәннәр. Балаңны калдырып киләсең дип әйтте, ди, балаң белән килер булсаң — булмый дип әйтте, ди. Шәйхулла исемле, Бауман урамында таш кибеттә сату итә, беләсеңдер дә әле?.. Беренчесе забутта эшлидерие... Монысы белән тигез торсын инде. Бала кая китә соң ул! Тамыры Бохарада түгел әле! Тигез тору кирәк, тигез тору... Һай, тигез торуларга ни җитә!..

Карчыкны мин бүлдермичә тыңлап тордым. Бу минутта мин Бауман урамында сату итүче Шәйхулла турында да, карчыкның икенче кияүгә, бай кияүгә чыгып бәхетле булачак кызы турында да, аның төсе-бите белән миңа тартымрак булган беренче ире турында да уйламадым. Бу минутта мин ике атасы, ике анасы булган, ләкин шулай да ятим булган, чын ата-анадан гомерлеккә мәхрүм калган гөнаһсыз сабый турында уйладым. Ул миңа хәзер әллә ничек якын булып, ифрат дәрәҗәдә якын, кызганыч булып тоелды. Мин аны ныгытып күкрәгемә кыс-

тым, аның әз генә пычранган татлы, йомшак бит алмасын үбеп алдым, аның ышанучан, чиста күзләренә тутырып карадым, һәм, гаҗәп хәл, аның шушы ачык карашлы сабый күзләрендә миңа ниндидер моң-сагыш бар шикелле тоелды,— әйтерсең, ул әбисе сөйләгәннәрнең барысын да аңлап, йөрәгеннән кичереп утыра иде.

Мин, карчыкка бер сүз дә әйтмичә, урынымнан тордым. Минем арттан ул да кузгалды.

Мин хәзер баскычның текәлеген дә, кулдагы баланың авырлыгын да тоймадым һәм яр өстенә менеп җиткәнче бер генә мәртәбә дә туктап тормадым. Урам читенә салынган такта басма буенча бераз җир бардым да артка калган карчыкны көтеп алдым.

— Ярый әле син очрадың... Аягың-кулың сызлаусыз булсын,— диде карчык, тагын миңа рәхмәт укырга тотынып.— Машина гына очрасын инде...

— Ярар, әби, сау бул,— дидем мин, китапны кире алып.— Син дә исән-сау үс, Мәҗит, батыр булып үс...

Мин Мәҗитне карчыкка суздым. Ләкин шул вакыт көтелмәгән хәл булды. Бала, минем муенны кочаклап алган кулларын ычкындырырга теләмичә, кинәт чырылдап кычкырып җибәрде.

Мин аптырап калдым. Карчык исә, баланың елавына әз генә дә игътибар итмичә, сөякчел каты куллары белән ничектер бик саксыз, бик тупас кыланып, аны миннән тартып алды.

Малай, шәфкатьсез куллардан ычкынырга теләп, аяклары белән тыпырчынды, бөтен гәүдәсе белән каерылып, ике кулын бергә сузып, һаман миңа таба омтылды. Елаудан аның сыны катты, сулышы тукталды, һәм ул кисәк кенә тынсыз-өнсез калды. Мин, аның бозылган кызганыч йөзен, ике як бите буенча агып төшкән күз яшьләрен күрмәскә теләп, тиз генә артыма борылдым, һәм минем борылуым булды, бала тирән итеп бер тын алды да җан ачысы белән тагын да ныграк кычкырып елап җибәрде. Шул чакны мин колак төбендә генә аның өзелеп:

— Әттә!— дип кычкырган тавышын ишеттем.

*1956*

## САРАПУЛДАН КАЙТКАНДА

*(Истәлек-хикәя)*

Миң тугыз йөз кырык өчнең язгы бер көнендә, сигезенчедә укыганда, без — өч малай ерак сәфәргә чыгарга булдык. Малайларның берсе — Касим, икенчесе —

Мәгъсүм, өченчесе мин. Өчебез дә бер мәктәптә, бер класста укыйбыз. Арада иң шомасы, иң булдыклысы Касим. Безне ул котыртты. Әйдәгез, малайлар, Сарапулга барабыз, ди. Сарапулда аракы заводы бар икән. Аракы анда бик очсыз икән. Биш-алты чирек алып кайтып саттың исә, миллионер буласың икән. «Чирек» дигәне аның яртының яртысы, ягъни бернең чирегe була. Баю мәсьәләсенә килгәндә, иң беренче теләгем — баю. Баесам, иң элек мин базардан бер бөтен арыш ипие алыр идем дә, туйганчы бер утырып ашар идем. Юк, инәкәйгә алып кайтып бирер идем, аны сөендерер идем.

Сөйләштек, киңәштек тә, беркемгә берни әйтмичә, киттек тә бардык. Пассажирскида. Билет-фәлән алу юк — вагон тоткасына тотындык та, җилгә битне куеп, чакчак кына куркып, чак-чак кына батыраеп барабыз шулай билгесез якка.

Барып җиттек Сарапулга, шәһәр үзәгенә, базарга. Кая карама — биек-биек йортлар. Урамнарына агач бүкән тезеп чыкканнар, юл читләренә такта түшәгәннәр. Безнең Яңавылның баткак урамнары белән чагыштырганда, оҗмах инде, оҗмах!

Базарда Касим өч-дүрт чирек аракы алды. Мәгъсүм белән мин берни дә алмадык. Анда сугылып, монда сугылып йөрдек тә, кичкә таба станция ягына юнәлдек. Караңгы төшкәндә барып җиттек. Хәзер инде теләсә нинди поездга утырасың да, ике сәгатьтән кайтасың да җитәсең Яңавылга. Теләсә нинди дигәч тә, безнең өчен иң яхшысы — товарный.

«Яхшы» поезд килгәнне төн урталарына кадәр көтәргә туры килде. Буш вагоннардан теркәлгән бик озын состав иде бу. Көнбатышка күмер, агач-таш төяп алып барган да, хәзер менә яңадан Себер якларына кайтып бара. Нидер көткән сыман, станциядә бераз гына тынып торды да, әкрен генә кузгалып куйды. Без шундук вагоннарның берсенә сикереп мендек, тотка-баскычтан югары үрмәләп, эчкә, тимер идәнгә шуышып төштек.

Китте поезд. Станция йортлары, вокзал утлары, будкалар артта кала башлады.

Перронда, поезд көткән арада, ыспай киенгән моряк белән солдат сыман берәү күзгә чалынып калган иде. Морягында кара бушлат, озын кара чалбар, башында тасмалы бескозырка. Солдат дигәне яшькелт кительдән, яхшы күнитектән. Башында фуражка. Икесе дә өр-яңа погонлы. Безнең өчен иң кызыгы шул, погон. Ул вакытта погоннарның яңа чыккан чагы. Кемнәр соң болар? Солдат дисәң солдат түгел, командир дисәң, командир түгел. Гаҗәп инде.

Иң гаҗәбе шул булды — без утырган вагон артындагы тузанлы «пульман»га болар да утырдылар. Безнең кебек тимер тоткага тотынып югары үрмәләделәр дә, тимер идәнгә сикереп төштеләр. Шәп булды әле бу. Погонлы хәрбиләр белән бер поездда кайтачакбыз. Мәктәптә малайларга «Погон күрдек!» дип сөйләве үзе ни тора!

Поезд кызулаганнан-кызулый. Поезд чаба! Төн уртасы булса да, артык караңгы да түгел сыман. Күз дә ияләшкән. Барабыз селкенеп, шакы-шокы килеп.

Йокы белән, хәлсезлек белән тартышып барганда, күрше вагон ягыннан көтмәгәндә тегеләр килеп чыкты. Без хәтта куркырга да, сөенергә дә өлгерми калдык. Безнең янга килеп җиткәч, берсе кинәт кесә фонарен кабызды, икенчесенең кулында финка ялтырап китте. Аптырап калдык, каушап калдык. Шундый шәп погонлы моряк белән солдатның безнең өше малай-шалайны таларга, кадарга җыенуы мөмкин нәрсә түгел сыман тоелды. Чын солдатлар тегендә, көнбатышта фашистлар белән сугыша. Аларга карата безнең хөрмәтебез зур, ышанычыбыз чиксез.

Финкалысы Касимны, фонарьлысы Мәгъсүмне эләктереп алды. Мин ничектер читтәрәк калдым. Касимның аракысын, акчаларын алдылар. Мәгъсүмнән берни тапмадылар.

Вагонның алгы ягында тар гына ярык бар иде. Ябылып бетмәгән ишек сыман әлеге тар гына ярыктан чыктым да, тамбур аша икенче вагонга кереп киттем. Шул чакны минем яннан гына ашыгып Касим белән Мәгъсүмнең китеп барганы күренеп калды. Алар артыннан иярмәкче булган идем, үкчәгә басып тегеләр килеп җитте. Аларны күрү белән, песи кебек үрмәләп каядыр өскә менеп киттем. Карасам, тимер вагонның тышкы ягына барып чыкканмын. Ул да булмады, тегеләрнең берсе минем арттан ук менә башлады.

Минем хәл яман. Әле өскә, әле аска карыйм. Аста аермачык булып җир шәйләнә, юл буенда телеграф баганалары утырып кала, ярым-караңгыда шомлы урман чайкала. Кайчагында җир өсте бик якын булып, якты булып күренә, вагоннар да кызу бармый шикелле тоела башлый «Сикеримме? Сикеримме?!» дип кычкырам җан ачысы белән. Сикерергә үземнең йөрәк җитми. Иң дөрес киңәшне Касим белән Мәгъсүм генә бирер кебек.

Өстә — теге. Зур гәүдәле, күн итекле. Күн итеге белән башка тибә, тимер тоткадагы чандыр кулларга тибә.

Яңавылга җитәрәк таң беленә башлады. Тегеләр каядыр китеп бардылар. Алар юкка чыккач та, вагоннан вагонга күчеп, алга, паровозга таба киттем. Малайлар да

шунда. Тендерда, паровозның күмер төялгән бүлемендә, күмер өстендә утыралар. Паровоз мичендә кып-кызыл булып күмер яна. Күмер ташлаучы урыс малае әледән-әле мич капкачын ача да, озын саплы тимер көрәк белән мичкә юеш күмер ташлый.

Таң атканда Яңавылга килеп кердек. Төштек. Җир өсте яп-якты. Инәкәй төне буе йокламыйча көтеп утырган. Макаронлы ашы суынып, боткага әйләнеп беткән. Күзгә, колакка, борын тишекләренә күмер тузаны тулган. Үзем суынган макоронлы аш ашыйм, үзем әкрен генә сөйлим дә сөйлим. Инәкәй күз яшьләрен сөртә.

Мин әле дә төшләремдә каядыр ыргылган буш вагоннар күрәм, тимер тоткаларга чытырдатып ябышкан таныш малайны күрәм. Әле дә ул үрсәләнеп, нишләргә белмичә, «Сикеримме? Сикеримме?!» дип кычкыра сыман.

Үсә төшкәч, тормыш арбасына утырып чапкан чакта, төрле хәлләр булды. Башка да типтеләр, кулга да суктылар. Кыен, бик кыен минутларда, дөньяда инде бернинди яшәү әмәле калмаган мизгелләрдә, «Сикеримме? Сикеримме?!» дигән уйлар килгәләде. Шул чагында келт итеп мең тугыз йөз кырык өченең язгы төне, бар көченә туң тимергә берегеп калган берәү искә төшә. «Сикермә! Сикерсәң — бетте!» дип кычкыра малай, шашып, коты алынып.

Сикермәдем.

Ярый әле сикермәгәнмен!

*29 ноябрь,1998*

# ТЕГЕРМӘНДӘ

## I

Үрне менеп җиткәч тә атка җиңеләя төште. Җирәнкәй, башын чайкый-чайкый, шәбрәк, иркенәебрәк атлый башлады. Арбада тыгыз капчык өстенә атланып утырган Җәмил, атны тагын да ашыктырмакчы булып, кулына чыбык алды.

— На-а, на-а!— дип кычкырды ул. Аннан соң артына борылып карады да, арба артыннан, такыр юлдан салмак кына атлап килгән эткәсенә эндәште: — Әткәй, утыр тизрәк! Каласың!..

Ләкин аның чыбык белән селтәнүенә Җирәнкәй койрыгын да селкетмәде. «Мин никадәр йөк тартып барам, җитмәсә, син дә анда җәелеп утырасың!»— дип шелтәләгән шикелле, зур, матур кара күзләре белән аңа кырын гына карап алды да, колакларын шомартып һаман

үз адымы белән атлавында булды. Җәмил, атны ничек кенә булса да чаптырырга теләп, капчыклар арасына кыстырып куелган дилбегәне тарткаларга тотынды.

— Улым, интектермә атны, атласын үз көенә,— диде әткәсе.

Җирәнкәй, хуҗасының таныш тавышын ишетеп, җиңелчә генә кешнәп куйды, әйтерсең үзе турында сөйләгәннәрен ул аңлап бара иде.

Берүзе генә утырып бару Җәмилгә кинәт күңелсез булып китте.

— Әткәй, мин дә төшимме?— дип кычкырды ул.

— Төш,— диде әткәсе.

Җәмил, арба артыннан чыгып торган үрәчә башына басып, җиргә сикереп төште, әткәсен көтеп алды да, зурларча кулларын селти-селти, аның яныннан атлап бара башлады. Тик әткәсе бер адым атлаганда аңа ике адым атларга һәм артка калмас өчен әледән-әле йөгергәләргә туры килде. Шулай да әткәсенең озын кунычлы зур күн итекләре яныннан баруы аңа бик күңелле тоелды.

Алар әткәсе белән бик еракка, тегермәнгә баралар. Бу әле аның үз гомерендә беренче мәртәбә юлга чыгуы. Моңарчы әле аның беркайчан да үзләренең басу капкасыннан ары киткәне булмады. Басу капкасы дигән җир авыл читендә генә ул, бер чакрымнар булыр.

Бөтен җәйне ул шунда үткәрде. Әлтәфләр, Хисамнар белән алар анда каз, бозау көттеләр, яшел, йомшак чирәмдә аунадылар, каз канатлары җыеп аткый ясадылар. Аннан соң алар анда качышлы уйнадылар, тәләкә уйнадылар, йөгерештеләр. Ул анда кабак зурлыгындагы бер ак гөмбә тапты. Гөмбәнең эчен куышлады да, бүрек кебек итеп аны башына киеп йөрде. Аннан соң алар аны елгага агыздылар.

Ә елга буенда бигрәк тә күңелле. Яр буенда кызыл балчыктан, юеш комнан алар йортлар салдылар, юллар, буалар төзеделәр. Кояш бик нык кыздыра башласа, өсләрен чишенеп ташладылар да, чыр-чу килеп суга сикерделәр, берберсенә су сибештеләр, елга өстеннән җәенке ташлар чәпчеттеләр. Ә бервакытны бөтен тәннәрен, битләрен кара ләмгә буядылар да, шүрәле булып яр өстендә сикергәләп йөрделәр, бозауларны, шундагы казларны куркыттылар.

Анда, басу капкасы янында, аңа бөтен нәрсә таныш. Ә бу якта — бөтенесе дә ят, чит, ләкин монда барысы да кызык, бик кызык.

Авыл инде күптән күренми башлады. Җәмилнең җилкәсен авыр сырма якасы кырды, бүреге күзенә төште, аның тәне кызды. Ул ешрак артка кала башлады.

— Арыдыңмы әллә?— диде әткәсе, артына борылып.

— Юк!— диде Җәмил, сер сынатасы килмичә.— Шунда да арып торсаң!

Арба юлы тигез, киң таш юлга килеп кушылды.

— Әйдә, утырыйк, улым,— диде әткәсе, кызулый төшеп.

Таш юлда әледән-әле җәяүлеләр, атлылар очрады, тузан туздырып автомашиналар узып китте. Машиналарның кайсына капчыклап ашлык төялгән иде, кайсыларына, каршы яктан килгәннәренә, йә кешеләр утырып бара иде, йә юан-юан тимер мичкәләр салынган иде.

Тиздән Җәмилнең күзләре тала башлады, гел артка борылып караганга муены авыртты.

Аның кинәт бернәрсәгә дә, беркемгә дә карыйсы да, беркем белән сөйләшәсе дә килми башлады. Күз кабаклары авырайды, аяк-куллары — бөтен тәне әллә ничек йомшарып, көчсезләнеп китте.

Ул үзенең әткәсе алдына авып киткәнен сизми дә калды. Колак төбендә генә ул әткәсенең:

— Йокың киләме?.. Йокла... йокла...— дигән ягымлы, йомшак тавышын ишетте.

Нинди рәхәт! Әткәй алдында баргач, арба да әллә ни тирбәлми, баш та селкенми кебек — мамык мендәр өстендә ятасыңмыни! Түбәндә, тәгәрмәчләр астында, арбаның тик тормаганын сиздереп, кыштырт-кыштырт вак ташлар изелде, арбаның кай җиредер әллә нинди моңсу тавыш чыгарып, шыгырдап-шыгырдап куйды һәм әледән-әле ат авызлыгы чылтырап-чылтырап алды.

Менә аның колагына әткәсенең бик моңлы тавыш белән сузып кына, әкрен генә җырлаганы ишетелә башлады. Җыр тавышыннан аның күз кабаклары тагын да ныграк йомылды, авырайган тәнен нидер иркәли, сыйпалый кебек тоелды.

Шул чакны каяндыр, томан арасыннан Хисам килеп чыкты. Кулына бик зур җәенке таш тоткан көе ул, елга читеннән су чәчрәтә-чәчрәтә, аның артыннан йөгерергә тотынды, үзе нигәдер кемгәдер: «Тот! Тот! Качма!»— дип кычкырды. Көтмәгәндә каңгылдашып, ысылдашып казлар килеп чыкты.

Ә җыр тавышы бөтенләй әкренәйде, көчсезләнде һәм тәгәрмәчләр астында кыштырдаган тавыш та, кемнеңдер теш шыгырдатканы шикелле, нечкә генә, тонык кына булып ишетелә башлады. Бераздан җыр да, теш шыгырдату да бергә кушылып юк булды. Колак төбендә нидер чыңлады да, кинәт черт итеп өзелеп китте.

Җәмил татлы йокыга талды.

## II

Эткәсенең Җирәнкәйгә:

— Әй-лә, нәрсә тагын!— дип кычкырган тавышына Җәмил уянып китте. Башын күтәреп караган иде, үзләренең ниндидер караңгы җиргә килеп кергәнлекләрен күрде. Юлның ике ягында да өскә авардай булып биек наратлар тезелеп утыра иде. Ачык кызгылт кабыклы наратлар шундый төз иде, шундый зифа иде. Тирә-якта ниндидер сәер, җиңел ис — ылыс исе аңкый иде.

Алда, наратлар арасында, бөтен юлны каплап, як-якка чайкала-чайкала килгән автомашина күренде.

— Эткәй, читкә чык!— дип кычкырды Җәмил.

— Ә-ә, уяндыңмыни?— диде эткәсе һәм машинага юл бирү өчен атны читкә борды.

Онлы капчыклар төялгән автомашина, авыр гыжылдап, әчкелтем төтен таратып, арба яныннан гына узып китте.

Күп тә үтмәде, нарат урманы ике якка ачылып китте. Алда бер-берсенә сыенып утырган бәләкәй генә йортлар, каралтылар калкып чыкты, болын уртасында киртәләп алынган кәбестә, бәрәңге түтәлләре күренде. Тагын бераз гына барганнар иде, әлеге йортлардан сул яктарак, кызыл яр астында, тип-тигез зур су өсте ялтырап китте. Су өсте һаман киңәйде, озынайды, тармакланып ерактагы әрәмәләр, яшел камышлы утраулар арасына сузылды. Җәмил аның тегермән буасы икәнен аңлап алды.

Ул яктан, буа ягыннан, бер генә минутка да тынып тормый торган гаҗәп бер гөрелдәү тавышы — арыктан шаулап аккан су тавышы ишетелеп тора иде.

Алар чишмә аша салынган күпердән чыктылар. Арба тәгәрмәчләре астында дөбердәшкән күпер бүрәнәләре арасыннан арык өстенә чүп-чар коелып калды.

Тегермәнгә кеше бик күп килгән иде. Теләсә кайда атлар туарылып куелган, капчыклар өеп ташланган иде.

Җәмилнең эткәсе арбаны бер җайлы урынга китереп туктатты да Җирәнкәйне туара башлады.

Кыска итеп кистерелгән аксыл-саргылт чәчле, яланаяклы бер кыз су буенда үрдәкләр куып йөри иде. Ул аларны су буена төшермәскә, ярдан читкә алып китәргә итә иде бугай. Ләкин калын борынлы симез үрдәкләр, бакылдаша-бакылдаша, һаман читкә таярга тырышалар иде.

Шул чакны яшькелт түшле бер үрдәк, иптәшләреннән аерылды да, муенын сузып, бик мәзәк аунаклый-аунаклый, качарга тотынды. Аннан күрмәкче бүтәннәре дә таралыша башладылар. Кыз, нәрсәдер кычкырып, кулла-

рын канат кебек селти-селти, әле бер үрдәк артыннан, әле икенче үрдәк артыннан йөгерде, әрле-бирле килде.

«Әй, җебегән!» — дип уйлап алды Җәмил, күңеленнән кызны мыскыллап. Шундук арбадан сикереп төште дә, су буена йөгереп китте.

— Куркытма! Кит аннан!— дип кычкырды кыз, кинәт килеп чыккан малайга ачуланып.

— Куркытмыйм ич!— диде Җәмил һәм су янына ук килеп җиткән яшел түшле үрдәкнең юлына аркылы төште.— Бүл әнә тегеләрен, бүл инде!..

Алар үрдәкләрне икәүләшеп абзарга таба куып алып киттеләр.

— Бер дә судан чыга белмиләр,— диде кыз, зарланып.— Әлерәк кенә көймә белән куып алып кайттым — кибән янындагы камышларга кадәр барып җиткәннәр. Берәрсе кыр үрдәге дип атып алып китсә, күрерсез әле менә!.. Йөрегез әле, әйдә, йөрегез... Баягынак та шарт-шорт мылтыктан аттылар.

Җәмил, кызның сөйләгәннәренә бик үк ышанмыйча, кызыксынып, аның әз генә алсуланган йөзенә күтәрелеп карады.

— Әллә син көймәдә йөри беләсең?— диде ул, шикләнеп.

Кыз, тапкансың сорар нәрсә, дигән кебек, кычкырып көлеп куйды.

— Ник белмәскә! Бер ишә башласаң, җиңел ул — шуып кына бара. Мин әле су да алып кайтам. Өйдә су бетте исә, чишмәгә йөгерәм. Минем су белән беркөн әнкәй Латыйф бабайга чәй кайнатып эчерде... Көш-көш!..

Кызның үзе турында мактануы Җәмилгә бер дә ошамады, шулай да ул аның белән танышуына сөенеп куйды. Ул, кызның үрдәкләрне ябып куйганын да көтеп тормыйча, әткәсе янына йөгереп китте.

## III

Әткәсе атны туарып бетергән иде. Ерак юл килгәнгә эче шиңә төшкән, тирләгән Җирәнкәй, башын салындырып, арба янында тын гына басып тора иде.

Алар камыт-ыңгырчакларын, ашамлык салынган төенчекләрен алдылар да, якындагы бер йорт ишегенә карап китеп бардылар. Әйберләрен чоланда калдырып, өй эченә керделәр. Өйдә бик җылы иде, әллә пешкән балык исе, әллә кайнар шулпа исе килә иде. Җәмил, ашыйсы килеп, төкерекләрен йотып куйды.

Өйдә, ахры, беркем дә юк иде. Җәмилнең әткәсе, битләрен бармаклары белән сыйпалап, тамак кырып куйды.

— Өйдәме хуҗалар?

Ул, җавап-фәлән бирүче булмагач, сак-сак кына басып түргә, такта белән бүленеп алынган икенче якка узды. Анда кемнеңдер ризасызлык белдереп мыгырданганы, койка тактасын шыгырдатып урыныннан кузгалганы ишетелде. Шуннан соң бик калын тавышлы берәү:

— Кем ул анда?— диде.

Ишек урынына элеп куелган бизәкле ситсы чаршау арасыннан йокылы кыяфәтле, юан гына, таза гына бер кеше килеп чыкты. Аның тотам-тотам булып укмашып беткән чәчләренә бер-ике бөртек ак мамык ябышып калган иде. Аның бер аягы аксак иде.

Җәмилнең әткәсе, елмаеп, аксак кешегә кулларын сузды.

— Исәнме, Батыр! Сау-сәламәт кенә ятасыңмы?

— Ә-ә, кунак килгән ләбаса! Әйдә, әйдә, Хәким туган!

Җәмил, кузгалырга да, нишләргә дә белмичә, баскан урынында катып тик торды. Кинәт анда бер шикле уй туды. «Нигә әткәй аны «батыр» дип әйтә икән?»— диде ул күңеленнән. Тегермән ташын бармагына балдак итеп кия торган, уникешәр башлы диюләрнең башын кылыч белән бер селтәүдә өзеп төшерә торган батыр әллә соң шул үзе микән? Булмас дисеңмени!— Үзе тегермәнче, үзе шундый таза. Җитмәсә тагын, аягы да аксак. Кем белә аны, әллә ул дию пәриләре белән сугышканда шулай яралангандыр, бәлки, аның мич астында дию башлары да аунап ятадыр әле...

Әткәсе тегермәнче белән таныш булса да, аның белән шулай курыкмыйча сөйләшсә дә, Җәмил чын-чынлап шүрли башлады. Аның тизрәк әткәсе янына йөгереп барасы, аны моннан алып чыгып китәсе килде. Ләкин, һаман хуҗадан күзен ала алмыйча, авызын йомып тик торды.

Батыр исә шундук Җәмилне күреп алды, аксый-аксый ишек янына килде дә, берни әйтмичә, кытыршы, юан бармаклары белән аның иягеннән тотып алды. Бер бармагы белән генә малайның башын өскә калкытты да:

— Шушымы инде синең үскән егет?— диде, көлемсерәп.— Кара син аны, тегермәнгә йөрерлек булган!

— Шул инде, шул... Әйдә, чишен, улым, нишләп анда торасың...

— Хатын авылга киткән иде, кайтып җитәр инде,— диде тегермәнче бераздан һәм аксаклап икенче якка чыгып китте.

Ул якта аның шаулатып самоварга су салганы ишетелде.

Җәмил куркып кына әткәсе янына, өстәл артына ки-

леп утырды. Йорт хуҗасының икенче якта булуыннан файдаланып, әткәсенең колагына үрелде дә, пышылдап кына аңа үзенең әлеге шиген әйтте.

— Нәрсә, нәрсә?— диде әткәсе, тиз генә аңлый алмыйча. Аңлап алды да, шаркылдап көлеп җибәрде. Шундый нык шаркылдады, аяк очында сырпаланып йөргән соры песи баласы куркып шундук шкаф артына чабып кереп китте. Җәмилнең кәефе кырылды, оялуыннан аның хәтта елыйсы килде.

— Һәй, улым, улым!.. Әллә нәрсәләр уйлап табасың!..— диде әткәсе, Җәмилнең аркасыннан сөеп.

Көлү тавышын ишетеп тегермәнче дә килеп чыкты.

— Нигә, Җәмил бик дөрес әйтә,— диде ул, Хәким агайның ни өчен көлгәнен белгәч.— Соң, Хәким туган, әз кырдыкмыни без синең белән фашист диюләрен! Белеп сөйли ул, белеп...

— Күкрәк тулы орден-медаль алып кайт та, батыр да булма, ә?!

Менә ничек икән! Җәмил мәсьәләгә хәзер генә төшенә башлады. Әткәсе гел сөйли торган иде шул... Кайчандыр, Җәмил әле дөньяга бөтенләй тумаган чакта, безнең җиргә фашист дигән ерткычлар басып кергән. Алар безнең кешеләрне үтергәннәр, безнең йортларны яндырганнар. Алар үткән бөтен җир каралай көеп калган. Фашистлар Җәмилләрнең авылына кадәр килеп җитә алмаганнар. Җиткән дә булырлар иде — әткәләре ирек бирмәгән. Килгән җирләренә кире борганнар да, тукмый-тукмый куып алып киткәннәр. Һәм шунда дөмектереп тә куйганнар.

Әткәсенең Батырша исемле бер дусы булган. Алар бөтен сугышны бергә үткәннәр, бер кашык ашларын да бергә бүлеп ашаганнар. Шушы микәнни инде ул Батырша?

Өй эче караңгылана башлады. Тегермәнче чәй әзерләде. Шул вакыт өй ишеге ачылып китте.

— Әткәй, үрдәкләрне дә, тавыкларны да ябып куйдым!

Җәмил, таныш тавыш ишетеп, керүче кешегә борылып карады.

— Булдыргансың, кызым,— диде тегермәнче. Шуннан соң Җәмилнең әткәсенә карап: — Ә менә монысы — минем кыз,— диде.

— Каяле, кая?— диде Хәким агай, караңгыда әлеге кызның йөзен ныграк аерырга тырышып.

Кыз кыю гына аның каршысына йөгереп килде.

— Менә мин!— диде ул, Хәким агайның күзенә туры карап.

Бу — бая үрдәкләр куып йөргән кыз иде. Ул Җәмилне әллә бөтенләй күрмәде, әллә юри күрмәмешкә салынды — аның ягына, ичмасам, борылып та карамады. Җәмилнең моңа хәтере калды һәм ул үзе дә, аңа берни әйтмичә, әткәсе артына яшеренеп, тын гына, шым гына утыруында булды.

— Җә инде, кызым, утны да яндырып җибәр,— диде хуҗа.

Кыз стена янына йөгереп килде. Кулы белән нәрсәгәдер үрелгән иде, кинәт өй эче гөлт итеп яктырып китте. Җәмил ирексездән күзләрен йомды. Менә кызык! Лампасы да юк, берни дә юк — кыяр төсле утлы шар янып тик тора. Шундый якты, шундый якты — кояш чыкты диярсең!

Җәмилнең мондый якты лампа турында ишеткәне бар иде, әлбәттә. Аларның авылына да шундый ук ут китертәчәкләр икән, дип инде күптән сөйләнәләр дә соң сөйләнүен, тик менә һаман җитешмиләр бит әле.

Әткәсе дә, мондый көчле яктылыкка бик кәефләнеп, күзләрен кыскалады, кытыршы битләрен сыйпаштырып куйды. Бик ягымлы итеп аңа карап алды да:

— Мондый электрлар янганда, улым, тегермәндә нинди дию пәриләре калсын!— диде.— Күптән үлеп беттеләр инде алар...

Җәмил, үзеннән күзен алмый карап торган кызны күреп, ничектер уңайсызланып китте.

— Нигә күрешмисең кунак егете белән?— диде тегермәнче үзенең кызына.

— Әткәй, мин аны беләм!— диде кыз, шатланып.

— Беләсең?! Кайчан күрдең әле син аны?— диде Батырша, гаҗәпләнгәндәй итеп.— Исеме ничек соң аның?

Кыз аптырап калды.

— Белмим.

— Мин — Җәмил,— диде малай, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.

— Мин — Фәридә!— диде кыз кычкырып һәм кисәк кенә урыныннан кузгалды да күрешер өчен аңа балчыкка буялып беткән бәләкәй генә кулын сузды.

## IV

Җәмил күзләрен ачып җибәрде. Инде таң аткан, өй эче яктырып беткән иде. Үзләренең өендә чакта ул йә бәйрәм булыр алдыннан, йә әнкәсе бирәр тәмле нәрсә пешерер көнне йокыдан сөенеп, куанып уяна торган иде. Шундый чакта аның тизрәк торып юынасы, тизрәк өстәл янына барып утырасы килә торган иде.

Менә бүген дә шулай булды. Аны торгач та ниндидер әйбәт, күңелле нәрсә көтеп торадыр шикелле тоелды. Ләкин ул шундук бүген бернинди бәйрәм дә булмаячагын, әнкәсенең бернинди тәмле әйбер дә пешермәячәген аңлады. Чөнки ул бөтенләй үзләрендә дә түгел иде, үзләренең туган авылларыннан бик еракта булган ниндидер урманнар, таулар арасындагы тегермәндә, ят кешеләрдә иде. Тәрәзә артында туктаусыз шаулап торган арык тавышын ишеткәч тә, ят бүлмә эченә күз йөртеп чыккач та ул бу турыда шәйләп алды, һәм аңа кинәт нигәдер куркыныч булып китте.

Нишләп монда берүзе генә ята соң әле ул? Әткәсе кая соң аның, кая ташлап киттеләр икән соң аны?

Шул чакны ул икенче якта әткәсенең тавышын ишетеп алды. Аңа шундук җан кереп китте. Анда, өстәл янында, үзара сөйләшә-сөйләшә, зурлар чәй эчеп утыралар иде.

— Килеп җитмәс борын кайту турында уйлап утырма әле, Хәким туган,— диде тегермәнче.— Чират та тиз генә тиярлек түгел...

— Миңа да чират дип торсаң инде, Батыр,— диде Җәмилнең әткәсе.— Икенче мәртәбә иркенләп килербез... Чынлап әйтәм... Колхозда да эш бетмәгән бит әле...

Әһә, әткәсе бүген үк ашлыкны тарттырып кайтып китмәкче була икән. Бу турыда белгәч, Җәмилгә нишләптер күңелсез булып китте. Аның хәзер моннан тиз генә кайтып китәсе килми башлады. Аның Фәридәне күрәсе, аның белән уйныйсы, тагын үрдәкләр куып йөрисе килде.

Ул, колагын үрә торгызып, тегермәнченең ни әйтәсен көтте. Тегермәнче аңа әкрен генә көлә шикелле тоелды.

— Аерылышканга ничә ел — күзгә-башка да күренгәнең юк. Теләсәң нишлә, Хәким туган, барыбер кунак итми җибәрмим...

Тегермәнчегә тагын ниндидер хатын-кызлар тавышы кушылды:

— Кая ул, авызыңны да ачма!.. Бер ике-өч көн дә тормагач...

Шуннан соң икенче бер ир кеше, үзалдына сөйләнгән кебек, карлыккан тавыш белән иренеп кенә әйтеп куйды:

— Кеше күп килә быел, әйе... Күп килә, тарттырып кына өлгер...

Җәмил, башын калкытты да, өстәл янындагыларны күрәсе килеп, тактадагы ярык аша икенче якка күз төшерде. Нәкъ шул чакта бүлмәгә бер хатын килеп керде. Җәмил, аның аяк тавышын ишетеп, шундук башын юрган астына яшерде. Нигәдер аңа ул хатын аны ярыктан караган өчен тиргәр, ачуланыр шикелле тоелды.

Ләкин хатын аны тиргәмәде дә, ачуланмады да, киресенчә, бик йомшак, бик ягымлы тавыш белән:

— Уяндыңмы, кунак егете?— диде һәм Җәмилнең үз әнкәсе кебек итеп, иплəп кенә аның чәченнән сыйпап куйды. Бераздан аның тавышы тагын ишетелде.

— Тор, кызым, тор! Тор-торайдан хәбәр килде, эшчән кызың торсын, диде...

Фәридә уянгач көттереп-нитеп тормады, шундук күзләрен ачты һәм үзеннән якында гына сандык өстендә яткан Җәмилне күреп алды да, кычкырып та җибәрде:

— Кем алдан?

Алар икесе дә тиз генә сикерешеп тордылар.

— Мин алдан!— дип кычкырды Фәридә, яланаяклары белән идәнгә сикереп төшеп.

— Юк, мин алдан!

— Икегез дә алдан!— диде Фәридәнең әнкәсе, көлеп.— Барыгыз, тизрәк юыныгыз да ашарга утырыгыз.

Алар чыр-чу килеп юындылар, бер-берсенә су сибештеләр, юынгыч тирәсен, идәнне күл итеп бетерделәр. Җәмилнең күзенә сабын керде. Өйләрендәге кебек шыңшымакчы булган иде дә, Фәридә алдында кыймады.

Өстәл янындагы зурларның барысы да кузгалып киткән иде, ак самовар бары балаларны гына көтеп утыра иде. Фәридәнең әнкәсе аларның икесе алдына бәләкәй генә табада кыздырылган балык китереп утыртты. Пешеп таралган, күзләре тонган ике зур балык бөтен табаны тутырып ята иде.

— Их!— диде Фәридә, кулларын чәбәкләп.— Латыйф бабай тотканмыни, әнкәй?

— Әйе... иплəп кенә ашагыз, тамагыгызга кылчыгы кадала күрмәсен,— диде Фәридәнең әнкәсе һәм өстәл яныннан торып ук китте.

— Минем эшем бар,— диде ул аннан соң кызына.— Сыйла кунак егетен. Чәй ясаганда пешә күрмә...

Әнкәсенең самоварларны, чәйнек, тәлинкәләрне — бөтен өстәл өстен үзенә ышанып тапшыруына Фәридәнең бик кәефе килде, һәм ул табаны Җәмилгә табарак этеп куйды да, көлмәскә тырышып:

— Аша, аша, кунак егете!— диде.— Кылчыгы гына кадала күрмәсен.

## V

Тегермән бик зур иде. Аның тышкы ягына да, эчке ягына да — бүрәнәләр өстенә бер карыш соргылт он тузаны утырган иде.

Алдан Фәридә китте, аның артыннан Җәмил атлады. Алар буа өстенә килеп менделәр.

Буа артына салынган тегермәнгә киң, тирән улак сузылган иде. Улакның өсте калын такта белән капланган, һәм аның буенча, басмадан йөргән кебек, тегермәнгә кереп-чыгып йөрергә була иде. Су, улак эченнән агып килеп, тегермән идәне астындагы зур тәгәрмәчнең бүлем-бүлем тартмаларына коела, һәм шуннан соң авыр тәгәрмәч әкрен генә хәрәкәткә килә иде. Зур тәгәрмәч исә бәләкәй тәгәрмәчләрне, ә алары — җәенке, түгәрәк ташларны әйләндерә иде. Идән астында бөтен нәрсә зырылдап әйләнгәнгә, туктаусыз хәрәкәтләнгәнгә, сайгаклар, тәрәзә пыялалары, стена буена таудай өеп куелган капчыклар, кешеләр бертуктаусыз калтыранып, селкенеп тора иде.

Мондый туктаусыз, тыелгысыз дереддәүне тою рәхәт тә, шул ук вакытта бик куркыныч та иде. «Әгәр тегермән җимерелеп китсә!»— диде Җәмил күңеленнән. Аның тизрәк тышка, тирбәлми-селкенми торган каты җир өстенә йөгереп чыгасы килде. Ләкин Фәридә аның кулын һаман ычкындырмады, йөгергәләп әле капчыклар арасына кереп китте, әле бик кызып, ашыгып, үзалдына нәрсәдер мыгырдап әйләнгән таш янына килеп җитте. Алар икесе дә, онытылып, кызау астындагы агач соскының шакылдый-шакылдый як-якка суккалануын, соскы очыннан таш уртасына, түгәрәк уемга шыштырдап саргылт бодай коелуын карап тордылар.

Шул вакыт Фәридә әнкәсенең кемгәдер кычкырган тавышы ишетелде.

— Мине чакыра!— диде Фәридә, ишеккә таба йөгереп.— Әйдә, берәр йомышы бардыр.

— Барыгыз әле утын алып килегез сарайдан, коймак пешерәбез...— диде Фәридәнең әнкәсе, аларны каршы алып. Балалар утын сарае ягына борылдылар.

— Әнкәй коймак пешерә, әнкәй коймак пешерә!— диде Фәридә, такмаклап.— Әнкәйгә тагын су да кирәк булыр әле. Хәзер суга барырбыз, яме? Аннан соң икәүләп көймәдә йөрербез... Аннан соң авылга барырбыз... Гыйлмулла бабайларны ашка чакырырга.

Өйдә чыннан да нәрсәдер пешерергә әзерләнәләр иде. Мичтә дөрләп ут яна, мич янында, урындыкта, өсте калдаулы күәс утыра иде, һәм Фәридәнең әнкәсе, яулыгын артка җибәреп бәйләгән көе, күәс тирәсендә кайнаша иде.

Җәмил коры утын агачларын мич алдына ташлады да баскан урынында беразга тукталып калды. Үзләренең өендә ул әнкәсенең кызган табага кашыклап-кашыклап апара салганын, аннан соң табадан кызарып пешкән

түгәрәк, кайнар коймаклар алганын карап торырга ярата торган иде. Беренче табаны әнкәләре иң элек гел абыйсы белән аңа майлап ашата торган иде.

— Хәзергә утын җитеп торыр,— диде Фәридәнең әнкәсе.— Кызым, өйдән ерак китмәгез — кирәк булырсыз.

— Ярар, әнкәй!— диде Фәридә.

Шуннан соң ул бер калай чиләк күтәреп Җәмил янына килеп җитте.

— Әйттем бит! Хәзер чишмәгә киттек,— диде, чиләк тоткасының икенче ягын малайга тоттырып.

## VI

Юлда аларга Латыйф бабай малае Рәхим очрады. Ул үзенең авылдагы дусы, классташы Сабит белән каядыр барырга чыккан иде бугай. Малайлар икесе дә кулларына капчык тотканнар иде.

Фәридә аларны күргәч тә шундук туктап калды.

— Кая барасыз?— диде ул.

Малайлар борылып та карамадылар. Шулай да, Рәхим көттереп булса да:

— Кайманга карама каезларга!— дип җавап бирде.

Элек ул гел Фәридә белән бергә уйный торган иде, буа артыннан аңа чабаклар каптырып бирә, аның өчен су буеннан төрле төстәге матур, шома ташлар җыеп алып кайта торган иде, аны хәтта урманга җиләккә-фәләнгә дә ияртеп алып бара торган иде. Мәктәпкә йөри башлагач та бигрәк борынын күтәрде, рәтләп сөйләшми дә. Тегермәндә күренгәне дә юк — гел авылда ята.

Шулай да, кая баралар икән соң алар? Балангамы, әллә колмаккамы?

Фәридә бәйләнә калды.

— Безне дә алып барыгыз әле!— диде ул, ялынып.

— Кая?

— Үзегез барган җиргә.

Рәхим туктарга кирәк тапты.

— Беләсеңме соң без кая барабыз?— диде ул.— Без чикләвеккә барабыз. Сезгә анда берни калмаган. Ияреәсе булмагыз!

Җәмилгә әле беркайчан да чикләвек җыярга да, хәтта аның агачын күрергә дә туры килгәне юк иде. Зур малайларга ияреп чикләвеккә бару аңа бик кызык булып тоелды. Фәридә исә аның саен ныграк бәйләнергә тотынды.

— Барыйк әле,— диде ул, еларга җитешеп.— Сезнең өчен чикләвек җыярбыз...

Шул сүзне ишеткәч, Сабит бераз йомшый төште.

— Нишләтәсең инде ул елакларны — барсыннар әйдә!— диде ул үзенең дусына.— Үзебез өчен әйбәт кенә булыр.

— Кызлар белән генә пычранып йөрисе калган иде!— диде Рәхим, авызын кыйшайтып.— Алып тау диләр аны! Анда барып җиткәнче үзең дә телеңне салындырырсың әле!

— Алып тау?!

Фәридә чиләкне чак-чак кына кулыннан ычкындырып җибәрмәде, йөзенә чиктән тыш гаҗәпләнү билгесе чыкты, һәм ул, ни әйтергә дә белмичә, беразга аптырап калды.

— Алып тау?!— диде ул тагын да, пышылдап.

Ул тиз генә урыныннан кузгалып куйды, ләкин бу вакытта малайлар арык аша чыгып баралар иде инде, Фәридә Җәмилгә якынрак килде дә, ниндидер серле тавыш белән:

— Алып тау турында ишеткәнең бармы синең?— диде.

Бу турыда аңа Латыйф бабай сөйләгән иде. Ә ул сөйләргә бик оста — теле генә чишелсен!

Борын-борын заманда безнең җирдә элек, имеш, бик зур, бик дәү кешеләр яшәгән. Аларның башлары печән кибәненнән дә зуррак булган, куллары сузгач болытларга кадәр җиткән. Алар бер атлаганда бер чакрым җир атлаганнар, тамаклары кипкәндә берәр елганың суын эчеп бетергәннәр. Аларның аяк эзләренә хәзерге күлләр җыелып калган, чабаталарыннан каккан балчыктан хәзерге таулар өелеп калган. Алар шундый көчле булганнар — икешәр потлы герләрне бармак башлары белән кысып, камыр урынына әвәләгәннәр, тау-ташларны урыннарыннан күчерә алганнар.

Алар шундый бай яшәгәннәр — дөньяда аларның байлыгына беркем дә тиңләшә алмаган. Аларның аш пешерә торган казаннарына кадәр, җир сөрә торган сабаннарына, көрәк-сәнәкләренә кадәр алтын-көмештән булган. Ул борынгы бабайлар асыл ташлардан салынган искиткеч гүзәл, якты сарайларда яшәгәннәр.

Ләкин бервакытны коточкыч давыл купкан. Диңгезләр ярларыннан чыккан, бөтен җирне су баскан. Тау-ташлар җимерелгән, шәһәрләр, авыллар кырылган. Бөтен халык үлеп беткән.

Бик күп еллар үткәч, диңгез суы кире чигенгән. Җир яңадан элекке хәленә кайткан. Ләкин борынгы бабайларның барлык алтын-көмеш сарайлары, булган бөтен байлыклары җир астында күмелеп калган.

Һәм менә хәзерге көндә Алып тау дип атала торган тау астында шул дәү бабайларның байлыклары күмелеп ята, ди, имеш. Аны инде бик күп кеше төрле төштән казып та караган, ди, ләкин әле дөньяда моңарчы беркем дә элекке

алтын шәһәрләргә кадәр казып төшә алмаган, ди. Бары тик бер ятим кыз гына яз көне су белән җир өстенә юылып чыккан бер алтын табагач башы тапкан, ди, имеш.

Шулай да кайчан да булса бер шул тауның төбенә кадәр төшә алачаклар икән. Тик моның өчен, тау астындагы исәпсез-хисапсыз алтын-көмешләрне казып алу өчен, борынгы бабайлар кебек бик көчле булырга кирәк икән.

Фәридә Латыйф бабайдан да, әткәсеннән дә никадәр генә үзен Алып тауга алып баруларын сораса да, аның әле һаман бу теләгенә ирешә алганы юк иде. Менә хәзер Рәхимнәр шунда киттеләр.

Фәридә шундук бер кыю фикергә килде.

— Әйдә, артларыннан иярәбез!— диде ул Җәмилгә.— Күренмичә генә барырбыз... арттан гына... Борылып карасалар — качарбыз. Киттекме? Алып тауга барып җиткәч, үзләре дә куалап кайтармаслар. Куаласалар — еларбыз.

Җәмил икеләнеп калды. Аның бер дә пешеп яткан коймакны ташлап китәсе килмәде. Ләкин шул ук вакытта Алып тауга барсаң да бик кызык, бик күңелле булыр кебек иде. Күпме йөрергә туры килер икән соң анда? Әгәр алар кайтып җиткәнче коймакны ашап бетерсәләр? Аннан соң, сорамый-нитми киткән өчен әткәсе ни әйтер дә, Фәридәнең үзенең әнкәсе ни әйтер?

Ләкин бу турыда ул Фәридәгә берни сиздермәде. Кыз исә, аның бик үк риза түгеллеген күреп, ашыктырырга тотынды.

— Әйдә тизрәк! Берәр алтын табак тапсак!.. Ох, аннан соң!.. Әнкәйгә алып кайтып бирербез дә, ул шундый сөенер! Рәхмәт, кызым, диер, табагым бик искергән иде, базарга барып торасы булмады инде, диер. Сиңа нәрсә кирәк? Казан тапсак, анысы сиңа булыр, яме?

— Безнең казан бар.

— Ярар, алайса, табагы сиңа булыр!

— Бернәрсә дә тапмасак?— диде Җәмил, аның сүзләренә ышанырга да, ышанмаска да белмичә.

— Тапмасак — чикләвек җыярбыз, чикләвек ашарбыз,— диде Фәридә, бер дә аптырап тормыйча.

Чикләвек турында сүз чыккач, Җәмил шундук риза булды.

Малайлар буаның аргы башына, әрәмә авызына барып җитә язганнар иде инде. Алар, артларына әйләнеп карау турында башларына да китермичә, нәрсә турындадыр үзара кычкыра-кычкыра сөйләшеп баралар иде.

Балалар кулга-кул тотыныштылар да малайлар артыннан йөгерделәр. Юл уртасында буш чиләк кенә торып калды.

## VII

Бүген көн бик матур иде. Тып-тыныч, тип-тигез буа өсте кояш нурында көзге кебек ялтырап, җемелдәп ята иде, һәм күктәге ак болытлар да, буа читенә бик якын килеп утырган тегермән йортлары да, яр буендагы агач ботаклары, камыш очлары да суда шул көе чагылып күренә иде.

Озакламый буа да, тегермән дә артта калды, арык артына коелган су тавышы да бик тонык булып ишетелә башлады.

Балалар әрәмә эченә килеп керделәр. Малайларга якынлашканчы ярыйсы гына йөгерергә туры килде. Ара бик нык кыскаргач, алар, Рәхимнәрне күздән югалтмыйча, әкренрәк атлап бара башладылар.

Әрәмә беткәч тә балалар кисәк кенә куе урман эченә килеп керделәр. Кояш яктысы бөтенләй күренмәс булды, арык тавышы да кинәт биек, куе агачлар артында томаланып, тынып калды.

Урман эчендә бик тын, искиткеч тын иде. Тар юл өстенә бакыр тәңкәләр шикелле сары яфраклар сибелгән иде.

Малайлар артларына әйләнеп тә карамадылар, урман юлы белән бардылар да бардылар. Кайчакта алар бөтенләй агачлар арасына күмелделәр, һәм арттан шыпырт кына атлап барган балалар шундук адымнарын кызулата төштеләр.

Шулай бара торгач, көтмәгәндә алар якты бер болынга килеп чыктылар, йомшак, яшел курпы белән капланган болынның әле бер җирендә, әле икенче җирендә берән-сәрән шомырт, кара зелпе куаклары үсеп утыра иде. Кайбер агачларның яфраклары саргая башлаган, кайберсенеке ямь-яшел иде, ә бер зелпе куагы бөтенләй миләүшә төсенә кергән иде, әйтерсең аны шундый төстәге елгада манчып алганнар иде.

Җәмил белән Фәридәгә болын бик матур, искиткеч матур булып күренде. Юл читендәрәк янып, кызарып утырган гөлҗимеш куагына күзләре төшкәч, икесе дә берьюлы куанып, бер-берсенә:

— Карале!— диештеләр.

Алар шундук юлдан читкә чыгып, куак янына йөгерделәр. Гөлҗимеш инде өлгергән, кып-кызыл булып, йомшарып пешкән иде, гәрәбә кебек җимешләр шундый күп иде — ботакларда бер генә яфрак та юктыр дип уйларга мөмкин иде.

Беренче булып гөлҗимешкә Җәмил барып тотынды һәм кинәт:

— Ай!— дип кычкырып җибәрде.

Гөлҗимешнең һәрбер чыбыгында кыска-кыска гына каты, очлы бик күп энәләр тырпаешып тора иде — җимешенә тимәсеннәр өчен юри шулай кадап куйганнар диярсең!

Фәридә Җәмилнең кычкыруыннан көләргә иткән иде дә, аның сытылган йөзен күреп, тиз генә авызын йомды. Җәмилнең энә кадалган бармак битеннән кан тибеп чыкты. Кыз аның кулын ипләп кенә тотып алды да, канаган бармагын авызына китереп өрергә тотынды.

— Өф-өф! Өфәй-өф!.. Бетте дә инде... Аны чыбыгыннан тотмыйлар. Өф-ф!.. Әйдә, гөлҗимеш ашыйбыз! Бөтен көе кабып җибәрә күрмә тагын.

Фәридә ботак очыннан сакланып кына берничә җимеш өзеп алды да, аларны урталай ярды.

— Эчендә аның орлыгы бар,— диде ул, Җәмилне өйрәтеп.— Орлыгын ташла, чүбен дә... Кабыгын гына аша.

Гөлҗимеш балаларга бик тәмле тоелды.

Гөлҗимеш ашаганнан соң алар болында чикерткә тоттылар. Чикерткәләрнең кая сикереп төшкәннәрен күзәтеп тордылар да, арттан әкрен генә килеп, өсләренә учларын капладылар.

Чикерткә куып йөри-йөри алар болынның икенче ягындагы бер бәләкәй генә куаклык янына килеп җиткәннәрен сизми дә калдылар.

Куаклык тирәсен кара бөрлегән яфраклары каплап алган иде. Фәридә, иелеп, кытыршы яфраклар арасыннан бөрлегән эзләргә тотынды. Хәер, эзләп торырга да туры килмәде: һәрбер яфрак астыннан изелеп пешкән зәңгәрсу-кара сусыл бөрлегәннәр ялтырашып ята иде. Кап та йот, кап та йот,— үзләре үк авызга керергә тора!

Кара бөрлегән гөлҗимешкә караганда да тәмлерәк булып чыкты. Аны бер дә сакланып өзәргә дә, эчен-ниен чистартып торырга да туры килмәде.

Бөрлегән белән балалар шундый нык мавыгып киттеләр, хәтта башларын да калкытып карамадылар.

## VIII

Ашана-ашана Җәмил куаклыкның икенче ягына килеп чыкты.

Аның каршысындагы ботакка бер яшькелт-сары кош килеп кунды. Җәмил ашавыннан туктап калды. Кошчык, бәләкәй генә башын як-якка боргалап, бик белдекле төс белән нәрсәдер чыркылдады да, яфраклар арасына кереп тә югалды.

Кош очып киткәннән соң тирбәлеп калган чыбык очы селкенүеннән туктарга да өлгермәде, серле тынлыкны бозып, урмандагы кайсыдыр агач башыннан, биектән, җир өстенә шапылдап нииндидер авыр нәрсә килеп төште. Җәмил, үзе дә сизмәстән, дерт итеп китте һәм бик нык игътибар белән якындагы урман ягын тыңларга тотынды.

Корыган яфракларны шыштырдатып куак төбеннән тычкан йөгереп үтте. Әкрен генә искән җилгә яшел нарат ылыслары шаулап алдылар. Малайның колак төбеннән генә ачы безелдәп шөпшә очып китте.

Беренче караштa тынсыз-өнсез булып күренгән биек агачлар, болын, куаклар — бөтен нәрсә, әйтерсең кинәт кенә җанланып китте. Җәмилгә әйләнә-тирәдә моңарчы ул башына да китереп карамаган нииндидер нәрсәләр кыймылдаша, кыштырдый, чыелдый шикелле тоелды.

Ул тиз генә артына борылып карады. Аның янына Фәридә якынлашып килә иде. Җәмил җиңеләеп киткәндәй булды.

— У-у, карале!— диде Фәридә, урман эченә төртеп күрсәтеп. Анда, агачлар арасында, чүмәлә кебек нииндидер нәрсә калкып күренә иде.— Кызык, нәрсә икән ул?

Балалар «чүмәлә» янына килделәр. Бу — кырмыска оясы иде. Ләкин нинди зур иде ул кырмыска оясы! Чыршы яисә нарат үскән урманнарда кырмыска оясы һәрвакыт шундый зур була.

Балалар чүгәләделәр дә, исләре китеп, үзләреннән икеөч мәртәбә биегрәк булган кырмыска оясына карап тора башладылар.

Җир өстен ергалап бетергән шома, тирән юлларда зурзур йөкләр күтәреп ташучы эре-эре кара кырмыскалар мыжлап тора. Алар каяндыр ераклардан коры үлән сабаклары, ылыслар, корт үләксәләре, чебеннәр алып кайталар, үрмәләп «чүмәлә» өстенә менәләр дә, әйберләрен шунда калдырып, тагын кире йөгерәләр, аркылы яткан чыбыклар аша чыгып, үз юлларындагы бәләкәй генә тауларны, үзләре өчен бик тирән булган чокырларны әйләнеп үтәләр. Кырмыска елгалары туктаусыз агып кына тора, тик бу «елгалар», сулы елгаларга капма-каршы буларак, бер үк вакытта ике якка да агалар иде.

Кырмыскалар балаларның шәрә аякларына килеп мендeләр, кытыкладылар, ачыттырып тешләп-тешләп алдылар.

Кинәт бик каты шакылдап, каршыдагы карама буенча өскә, агач башына, очлы тырнаклы нииндидер нәрсә менеп китте. Балалар шундук башларын күтәреп карадылар. Сәер тавыш яңадан кабатланмады.

Агач башыннан аларга борчак кебек түгәрәк күзләрен

елтыратып озын койрыклы соргылт бер җәнлек карап тора иде.

— Тиен! Тиен!— диде Фәридә.

Тиен беравык шым гына утырды да, балалардан үзенә бернинди куркыныч юклыгын сизеп, шаянланып, җиңел генә икенче агач башына сикерде.

Җәмил тиз генә җирдән таяк эзләп алды да аны тиенгә төбәп ыргытып җибәрде. Ләкин таяк, агач ботакларына бәрелеп, шапылдап җиргә килеп төште. Тиен исә, малайны үчекләгән шикелле, шундук икенче ботакка сикерде. Ул шундый бәләкәй, шундый матур иде һәм шундый юаш кебек күренә иде, Җәмил кызыгып:

— Әйдә, тотабыз!— диде.

— Әйдә!— диде Фәридә.— Без аны өйгә алып кайтырбыз...

Аларга, чыннан да, әгәр таяк белән тидереп булса, тиен шундук егылып төшәр шикелле тоелды. Тик менә таяк тигәч яисә җиргә егылып төшкәч үлә генә күрмәсен!

Тиен икенче агачка сикерде. Балалар, бертуктаусыз таяк ыргыта-ыргыта, тоттырмас шаян җәнлек артыннан киттеләр. Җәмил, ичмасам, бер генә мәртәбә дә тидерә алмады. Тиен дә егылып төшмәде — канатлы кош кебек җиңел генә агачтан агачка, ботактан ботакка сикерә-сикерә, һаман урман эченәрәк керде. Балалар ул хәйләкәр тиенне никадәр генә куып барсаң да, никадәр генә бәреп төшерергә тырышсаң да, барыбер берни дә барып чыкмаячагын аңладылар. Алар, өметләрен өзеп, күңелсезләнеп туктап калдылар.

Шунда гына Фәридә Алып тау турында исенә төшерде.

— Рәхимнәр әллә кая җиткәннәрдер инде,— диде ул, борчылып.

Хәзер үк болын ягына кире борылырга, юлга чыгып, малайлар артыннан куып китәргә кирәк иде. Балалар, зур кырмыска оясын күрмәкче булып, як-якларына карандылар — болын аңа якын гына булырга тиеш иде. Әмма әйләнә-тирәдә кырмыска оясы күренмәде. Уңнан да, сулдан да, арттан да, алдан да аларны бары тик җансыз, тынсыз һәм шомлы агачлар гына уратып алган иде.

## IX

Балалар аптырашып бер-берсенә карап алдылар.

Нишләргә хәзер? «Әнкәй!» дип, «Әткәй!» дип кычкырыр идең, йә булмаса елар идең — кем ишетсен монда сине?

Тегермәндә үскән Фәридәгә урман шулай да бик үк ят нәрсә түгел иде. Ул Җәмилнең кулыннан тотып алды да, кыю гына:

— Әйдә,— диде.— Мин юлны беләм.

Ләкин ул да, Җәмил кебек үк, юлны да, үзләренең кайдалыгын да белми иде. Алар ун-унбиш адым да китә алмадылар, түбә өстен кисәк кенә кара болыт каплап алды. Урман эче тагын да ныграк караңгылана төште. Көчле җил исте. Урман ачуланып шауларга тотынды. Югарыда кош көтүе кебек саргылт яфраклар очты.

Балалар бик нык куркуга төштеләр. Хәзер менә тизрәк өйгә йөгереп кайтасы иде дә, берәр җылы, караңгы урынга кереп посасы иде. Ләкин кайда соң ул өй? Кайсы якта?

Бик үк ачык булмаса да, аларның күңеленә шундый шомлы уйлар килде.

Җил көчәйгәннән-көчәйде, юан усаклар, юкәләр бер-берсенә ышкылып, ыңгырашып-ыңгырашып чайкалдылар. Көтмәгәндә салкын яңгыр сибәли башлады.

Балалар елый-елый шундагы бер зур чыршы янына килеп сыендылар. Чыршы бик таралып, җәелеп үскән иде. Аның калын ботаклары астында җил дә, яңгыр да үтәрлек түгел иде.

Балалар чыршы төбенә җайлап утырдылар. Фәриданең өстендә бер кат ситсы күлмәк кенә иде. Җәмил бишмәт төймәсен ычкындырып җибәрде дә аның итәге белән кызның аркасын каплап алды. Аларга бик җылы, бик рәхәт булып китте. Хәтта елауларыннан да туктадылар.

Ләкин бераздан тагын күңелсез була башлады. Фәридә үзенең әнкәсе турында, аның өйдән ерак китмәскә кушуы турында һәм үзләренең болай адашып, интегеп йөрүләренә бары тик үзенең генә гаепле булуы, Җәмилне бары тик үзе генә котыртып алып китүе турында уйлады. Шулай тик кенә утырганда ул кычкырып еларга тотынды.

— Әнкәй нәрсә әйтер инде-е?.. А-а-а!.. Адашты-ык!.. Ничек кайтырбы-ызз!..

Җәмил инде тәмам тынычланган иде, шуның өстенә — ул малай кеше бит. Фәриданең елавын күреп ул кыюланып китте. Ул җиң очы белән кызның битендәге күз яшьләрен сөртеп алды да, аны юатырга тырышып:

— Тукта, елама!— диде.

Алар, коеп яуган яңгыр тавышына колак салып, икесе дә тынып калдылар.

Шул вакыт чыршы артында кемнеңдер авыр-авыр басып килгән аяк тавышы ишетелде.

## X

Урман эченнән бер кеше бара иде. Ул аягына бик зур күн итек, өстенә зур башлыклы плащ кигән, ә кулына ике көпшәле мылтык тоткан иде.

Ят кеше, балаларны күреп алды да, алдындагы ботакларны як-якка аерып, чыршы янына килде.

— Нишләп утырасыз монда?— диде ул.

— Адаштык!— диделәр балалар, бер-берсен бүлеп.

— Адаштыгыз?— диде кеше, гаҗәпләнеп.— Тегермән артында адашып торалармыни?!

Чыннан да, балалар яңгыр туктагач чыршы астыннан чыгып, ят кеше артыннан кузгалып кына киткәннәр иде, кинәт урман да бетте, алда, якында гына, тегермән йортлары да күренде. Балалар шатлыкларыннан кычкырып җибәрделәр.

— Һи-и, моннан инде без үзебез дә кайтабыз!— диде Фәридә, алга йөгереп чыгып.

Җәмил белән Фәридәгә очраган бу кеше шушы тирәдә нефть эзләүче геологлар экспедициясеннән иде. Ул, буш вакытыннан файдаланып, урманга ауга дип чыккан иде. Ул тегермәнче Батыршаны бик яхшы белә иде. Һәм ул, үзләренең урман эчендәге палаткаларына кайтышлый, тегермәнгә кереп чыкмакчы булды.

Аның каршысына Фәридәнең әнкәсе килеп чыкты.

— Зәйнуллин иптәш ләбаса!— диде, аның белән күрешеп.— Исән-сау гына йөрисезме? Безнең балаларны сез очраттыгызмыни? Без тагын, авылга киткәннәрдер инде, дип торабыз... Мылтыклы абый белән кайттык, диләр...

Каяндыр аксаклап тегермәнче килеп җитте, аның артыннан Хәким агай күренде. Алар бер-бер артлы геолог Зәйнуллин белән күрешеп чыктылар. Аннан соң аны өйгә алып керделәр, өстәл янына коймаклап чәй эчәргә утырдылар. Сөйләшә торгач, тегермәнче, ничектер бик серле итеп:

— Тишеп карадыгызмы соң әле, Зәйнуллин иптәш?.. Ничегрәк? Булырлыкмы?— диде.

Зәйнуллинның җил кисеп тупасланган кырыс йөзе ачылып китте.

— Алып тауны өч-дүрт җирдән бораулап карадык. Нәтиҗә яхшы күренә,— диде ул.— Бик зур запас табылды.

Җәмил дә, Фәридә дә зурларның сүзеннән башта берни дә аңламадылар. Ләкин «Алып тау» сүзен ишеткәч тә икесенең дә колаклары үрә торды. Гаҗәп, нигә бораулыйлар, нигә тишеп карыйлар икән ул җирне, нәрсә эзлиләр икән анда?

— Әһә, белдем! Белдем, Җәмил!— диде Фәридә.

— Нәрсә белдең, кызым?

— Белдем! Алтын тапканнар, алтын! Алып тау астыннан теге алтынны тапканнар!..

Геолог башта аптырап калгандай булды, аннан соң

Алып тау турында халыкта йөргән сүзне исенә төшереп, ирексездән елмаеп куйды.

— Дөрес,— диде ул һәм зур, көчле куллары белән балаларны үзенә якынрак китерде,— дөрес, алтын таптык. Алып тау астында бик күп алтын ята, нефть ята. Ләкин ул сары да түгел, тимер кебек каты да түгел. Кара алтын, сыек алтын диләр аны... Менә нинди алтын таптык без!..

## XI

Җәмилләр, ашлыкларын тарттырып, авылларына кайтырга чыктылар.

Иртәнге дымлы һава салкынча иде.

Әткәсенең җылы сырмасына төренеп утырган Җәмил аксыл томан белән капланган буа ягына, томан аша шәүлә генә булып күренгән агач башларына, яр читендәге көймәгә, йокымсыраган йортларга һәм бертуктаусыз дөбердәп, шаулап утырган тегермән ягына бик озак карап барды.

Тегермәндә ул ике көн торды, яңа кешеләр белән, яңа җирләр белән танышты, моңа кадәр төшендә дә күрмәгән искиткеч кызык, гаҗәеп нәрсәләр күрде.

Ул берни белми йоклап калган Фәридә турында, аның белән урманда адашып йөрүләре турында, Алып тауны тишеп алтын тапкан кырыс чырайлы геолог абый турында уйлады. Аңа бик моңсу, бик күңелсез булып китте. Аның күзләренә яшь килде.

— Җә, улым, сагындыңмы үзебезнең авылны?— диде әткәсе.

Җәмил бер сүз дә кайтармады. Бераз баргач, әле һаман наратлар арасыннан күренеп торган еракталы аксыл томан кисәгеннән күзен алмыйча, әкрен генә:

— Әткәй, тегермәнгә тагын кайчан киләбез?— диде.

# БЕЗНЕҢ БАБАЙ

Бәләкәй Рөстәм җәй көне әнисе белән авылга — дәү әниләренә кунакка килде. Алар үзләре бик еракта, бер зур шәһәрдә торалар. Рөстәмнең әле беркайчан да авылда булганы юк иде. Дәү әнисе аны бик ягымлы йөз белән каршылады, тәмле әйберләр белән сыйлады.

Дәү әни үзенең олы улында тора. Ә аның улының хәзер үзенең дә бәләкәй балалары бар. Рөстәм алар белән бик тиз дуслашып китте.

Ул аларга үзләренең матур шәһәрләре турында, ишек-

ләре үзеннән-үзе ачылып ябыла торган трамвайлар, троллейбуслар турында, зоопарктагы маймыллар, юлбарыслар турында сөйләде. Балалар аны исләре китеп тыңлап тордылар.

— Бездә андый кызык нәрсәләр юк шул,— диде Хәлим.— Безнең авылда сиңа күңелсез булыр инде.

— Бар! Бар!— дип кычкырып җибәрде шул вакыт бәләкәй Фәһимә.— Бездә саескан оясы бар! Менә!.. Абый, әйдә Рөстәмгә саескан оясын күрсәтәбез!

— Әйдә!

Балалар җитәкләшеп ындыр артына таба йөгерделәр. Саескан оясы авыл янындагы урман эчендә иде.

Хәлим, бөтенесеннән дә зуррак булганга, алдан китте.

Алар болынга килеп җиттеләр.

Еракта, урман буенда, сыер көтүе утлап йөри иде. Хәлим мактанып:

— Әнә безнең көтү!— диде.

— О-о, нинди күп икән сезнең сыерларыгыз!— диде Рөстәм, гаҗәпләнеп.

Шундук Фәһимә сүзгә кушылды:

— Әйе, безнең сыерлар бик күп. Менә!..— диде.— Сарыклар да күп безнең. Бөтенесенекеннән дә күбрәк, Саттар бабай үзе әйтте.

Якындагы юлдан тузан туздырып автомашина узып китте.

— Безнең машинамы бу?— диде Фәһимә, кулын маңгаена куеп.— Ә, безнеке икән!

Урманга килеп җиткәч, балалар саескан оясын бөтенләй исләреннән чыгардылар. Күп сөйләргә яратучы Фәһимә:

— Абый, әйдә умарталыкка барабыз?!— диде. Аннан соң Рөстәмгә,— Бабай безгә бал ашатыр... Безнең бабай бик юмарт ул. Менә... күрерсең әле!..— диде.

Умарталык урман эчендә иде.

— Әйдәгез,— диде Хәлим.— Рөстәм безнең умарталыкны күрер, бал кортларын күрер.

Балалар тиздән умарталыкка килеп җиттеләр. Аларның каршысына умартачы бабай килеп чыкты.

— Минем кортларның хәлен белергә килдегезме?— диде бабай, елмаеп.

Ул аларны тәбәнәк кенә бер өй эченә алып керде дә, өстәл янына утыртты, һәрберсенең алдына берәр тәлинкә бал куеп чыкты, берәр балкашык белән берәр телем күмәч бирде.

Рөстәм хуш исле сыек балны бик яратып ашады.

— Ашагыз, ашагыз, улларым, кызларым,— диде бабай.— Кортлар бу балны бүген иртән генә җыеп алып

кайттылар. Бал ашарга балалар килсә, безнең балны кызганмый ашат, диделәр. Тәмлеме, туйдыгызмы? Туйгач бал да ачы... Ачы була башладымы әле?..

Балалар, бал ашап туйгач, бабайга, бал кортларына бик зур рәхмәт әйттеләр дә, килгән юллары белән кире кайтып киттеләр. Бабай аларны урман авызына кадәр озатып куйды.

— Сездә бик күңелле, мин гомергә авылда яшәр идем!— диде Рөстәм.

Алар өйгә кайтып җиткәндә кич булды. Тиздән зурлар да кайтты. Бөтен гаилә ашарга утырды. Барысы да ашарга тотындылар.

Шул чакны дәү әнисе Рөстәмнең нәрсәдер көтеп ашамыйча утыруын күрде.

— Нигә ашамыйсың, улым? Әллә яратмыйсың?— диде ул.

— Мин бабай кайтканны көтәм,— диде Рөстәм.— Нигә сез дә көтмисез, кайтып җитәр инде ул.

Барысы да, гаҗәпләнеп, ашаган җирләреннән туктап калдылар.

— Нинди бабай?— диде Рөстәмнең әнисе, улының ни сөйләгәнен аңламыйча.

— Бабаңның үлгәненә ун ел була инде, улым. Исемә төшердең мәрхүмне,— диде дәү әнисе, яулык очы белән күз яшьләрен сөртеп.

Рөстәмгә бик уңайсыз булып китте.

— Безгә бал ашаткан бабай соң...— диде ул, ни әйтергә дә белмичә.

Хәлим белән Фәһимә кычкырып көләргә тотындылар. Рөстәм кып-кызыл булды.

— Кортчы Галләм бабайны әйтә ул,— диде Фәһимә.— Бүген ул безгә бал ашатты.

— Нишләп ул синең бабаң булсын?— диде Рөстәмнең әнисе, тагын да ныграк гаҗәпләнеп.

— Үзләре «безнең бабай», «безнең умарталык» диделәр, үзләре көләләр...— диде Рөстәм, үпкәләп.

— Кемнәр? Рөстәм Хәлим белән Фәһимәгә төртеп күрсәтте.

— Алайса, көтү дә, машина да сезнеке түгелмени? Хәлимнәрнең әтисе балаларына ачулы гына карап алды.

— Нәрсә алдашып йөрисез сез?— диде ул аларга.

— Юк, без алдашмадык, әти. Нигә безнеке булмасын — безнеке! Сыер көтүе дә безнеке, автомашина да, умарталык та безнеке, безнең колхозныкы. Без алдашмадык,— диде Хәлим.

Аның сүзеннән беркем дә көлмәде.

# БАЛЫКЧЫЛАР

Бер матур көнне, иртән, өч малай елгага балык каптырырга китте. Малайлар, яр буена килеп җиткәч, эссе ком өстенә утырыштылар да, кармакларын суга ташлап, балык чирткәнен түземсезлек белән көтә башладылар.

Озак та үтмәде, Әдһәмнең калкавычы су астына чумды. Әдһәм шундук кармагын тартып та җибәрде, көмештәй ап-ак чабакны яр читенә алып та ташлады. Малайларның күңелләре күтәрелеп китте. Тагын бераз утырганнар иде, Сабирҗан да бер алабуга тартып чыгарды.

Тик Вәлигә генә берни дә капмады. Ул калкавычының тирәнлеген дә үзгәртеп карады, әле бер урынга, әле икенче урынга күчеп утырды, балыкларны чакырып, авыз эченнән генә теләкләр теләде. Ләкин берни дә ярдәм итмәде.

— Син, Вәли, тыныч кына утыр, ашыкма,— диде Әдһәм аңа.

Әмма Вәлинең бүтәннәр кебек көтеп утырырга түземлеге җитмәде. Балык тоту аңа тиздән бик күңелсез, бик ялыктыргыч эш булып тоела башлады.

Икенче як ярдан елгага бер чишмә килеп кушыла иде. Вәли шул чишмә авызында, су өстендә тырпаеп торган ниндидер баганаларны күреп алды. «Мурда ич!— диде ул күңеленнән, сөенеп.— Садри бабайныкы, ахры. Булса ни! Мөгаен ул аны карарга өлгермәгәндер әле».

Малай шатлыгыннан нишләргә дә белмәде. Менә, ичмасам, балыктыр инде анда! Беләк буе кушбашлар, чуртаннар бардыр... Табан балык булуы да бик мөмкин — күлдән агып чыга бит ул чишмә. Әй, кызар иде соң малайларның күзе! Әйдә, алар утырсыннар бармак башыдай чабак каптырып, ә мин чыгып бушатыйм әле шул мурданы.

Шулай дип уйлады да малай, кармагын тиз генә җыештыра башлады.

— Кая?

— Әллә кайтып китәсеңме?— диештеләр иптәшләре.

Вәли берни дип тә җавап бирмәде, серле итеп елмаеп кына куйды.

Ләкин ничек чыгарга соң теге якка? Йөзеп чыгарга куркыныч — елга тирән, киң. Бая килгәндә ул яр өстендә язгы ташу вакытында утырып калган бүрәнә кисәкләре күргән иде. Вәли шулардан сал бәйләмәкче булды. Салың булса, әллә кайларга йөзеп китсәң дә берни түгел!

Вәлинең пәкесе бар иде. Ул, күп итеп карама кабыгы суеп алды да, бау иште.

Озакламый сал да әзер булды, ишкәк өчен яраклы такта да табылды.

Бер-берсенә беркетеп бәйләнгән бүрәнә кисәкләренә аякларын аерып баскан көе, ишкәге белән яр читенә терәп этә-этә салда йөзеп килгән Вәлине күргәч, иптәшләре шаккатты.

— Карале Вәлине!..— дип кычкырды Сабирҗан.

— Нинди сал ул? Кая киттең?— диде Әдһәм.

Вәли эре генә:

— Күрерсез әле!— диде дә, артык сөйләшеп тормыйча, елга уртасына таба ишә башлады.

Ләкин малайлар аның нишләргә уйлаганын шундук аңлап алдылар.

— Маташма, Вәли! Садри бабай күрсә...— диде Сабирҗан.

Вәли җавап та бирмәде.

Елга бу турыда әкрен ага иде — икенче як ярга ул бик тиз барып чыкты. Иптәшләре аны тыннарын да алмый карап тордылар.

Вәли, яр читенә килеп туктагач, җиргә сикереп төште дә мурда янына йөгерде.

Мурданы алыйм дип кулын гына сузган иде, кисәк кенә туктап калды. Башын күтәреп караса, куркуыннан чак-чак кына егылып китмәде.

Өстә, яр кырыенда, Садри бабай басып тора иде.

Садри бабай аңа нәрсәдер әйтте. Ләкин ул аны рәтләп ишетмәде дә, тизрәк таю ягын гына карады. Атылып сал янына килеп җитте дә, кабаланып, бүрәнә кисәкләре өстенә сикерде.

Куркудан Вәлинең йөзе агарынды, куллары калтыранды. Ул, тизрәк яр читеннән, Садри бабайдан ераклашырга теләп, ашыгып ишәргә тотынды.

Вәли кая таба ишкәнен дә, ничек ишкәнен дә сизмәде. Бөтенесен күреп торган Сабирҗан белән Әдһәм куркып кычкырып җибәрделәр.

Бар көченә тырышып ишкәндә Вәлинең бер аягы таеп китте. Малай кинәт башы белән кадалып елгага барып төште. Ул йөзә белми иде. Су өстендә аның аяклары гына күренеп калды.

Сал, үз юлыннан аз гына читкә тайпылып, әкрен генә агып китте. Бераздан Вәли өскә калкып чыкты һәм ике куллап су эчендә пычтырдарга тотынды.

Әдһәм тиз генә өстен чишенеп ташлады да суга сикерде. Аның артыннан Сабирҗан да йөзеп китте. Алар бөтенләй хәлсезләнгән Вәлине яр читенә алып чыктылар.

Вәлинең башыннан, күлмәкләреннән шыбырдап су ага иде.

— Сал киемнәреңне,— диде Әдһәм, иптәшенә өстен чишенергә булышып.

Әдһәм белән Сабирҗан күп кенә балык каптырганнар иде. Малайлар, яр буена учак яктылар да, кечкенә калай чиләк белән балык пешерергә куйдылар. Вәли юеш күлмәк-ыштаннарын сыгып кибәргә элде.

Шул чакны яр читенә бер көймә килеп туктады. Көймәгә Садри бабай утырган иде.

— Курыкма, курыкма, тимәм,— диде бабай, Вәлинең куркынган күз карашын күреп.

Ул малайларга көймәдән ике зур тере кушбаш алып бирде.

— Мәгез, пешерегез. Берсе Вәли өлеше булыр, берсе минем өлеш булыр,— диде Садри бабай.

Бераз тын гына утыргач, Вәлигә карап алды да, җитди генә:

— Шулай шул, улым,— диде,— балыкны да җиңел генә тотып булмый... Ә теге мурдада бернәрсә дә юк. Яздан калган ташландык мурда ул...

## ВЕЛОСИПЕДЛЫ МӨНИР

Мөниргә әтисе магазиннан өр-яңа велосипед сатып алды. Мөнир велосипедын җитәкләде дә урамга чыкты. Аның тирәсенә шундук иптәш малайлары җыелды.

— Мөнир, йөреп торырга миңа да бирерсең әле велосипедыңны?— диде Илдус.

Бүтән малайлар да:

— Эх, нинди ялтырап тора!

— Бер генә тотып карыйм әле?

— Мөнир, мин дә йөрермен әле?— диештеләр. Мөнир велосипедын бик кызганды. Аның үз әйберсенә беркемне дә кагылдырасы килмәде.

— Теләнмәгез дә, берегезгә дә бирмим,— диде ул, кырт кисеп.

Ләкин Мөнир велосипедта йөри белми иде. Шуңа күрә аны, велосипедка утыргач аумас өчен, арттан кем дә булса тотып барырга тиеш иде.

— Ярар инде алайса, син генә йөреп карарсың,— диде ул Илдуска.— Тик мин утыргач син велосипедны тотарсың... Ычкындыра күрмә... Басуга чыгып, әнә теге чыршы турысына җиткәч, мин төшәрмен дә, син китәрсең.

Илдус бик шатланып риза булды. Мөнир киртә янына килде дә, велосипедның ияренә атланып утырды. Илдус велосипедны тотып торды.

Менә алар әкрен генә кузгалып киттеләр. Велосипед баштарак әле бер якка, әле икенче якка кыйшайды. Әгәр Илдус ныгытып тотмаган булса, Мөнир шундук егылып төшкән булыр иде. Шулай да ул бераздан тигезлеген саклый ала башлады, һәм велосипед такыр юлдан җиңел генә тәгәрәп китте.

Тиздән иптәшләре дә, авыл да артта калды. Алар юл буендагы чыршы турысына да якынлаштылар. Илдус бик кызу йөгерүдән тирләп төште, кызарды.

— Тукта инде, Мөнир...— диде Илдус, ялгыз чыршыны узып киткәч.

Мөнир туктамады, киресенчә, тагын да кызурак бара башлады.

— Мөнир, йөрерсең дип үзең әйттең ич... тукта инде,— диде Илдус, кызганыч тавыш белән.— Туктамасаң ычкындырам. Кит үзең генә.

— Ычкындырсаң әллә! Бар, китә бир,— диде Мөнир, бер дә исе китмичә.— Мин инде синнән башка да йөри алам.

Илдус бик хурланды. Мөнирнең велосипедын ычкындырды да, кире борылып, авылга таба йөгерде. Мөнир, иптәшеннән котылуына сөенеп, тагын да кызурак китте.

Бара торгач, юл кисәк кенә түбәнәя башлады. Велосипед, тигезсез юлда дыңгырдап, һаман шәбрәк тәгәрәде. Хәзер инде педальгә басарга да кирәкмәде. Мөнирнең колак төбендә җил сызгырды, йөрәге куркудан «жу» итеп китте: ул велосипедның йөрешен әкренәйтү өчен тормозга басарга кирәклеген белми иде.

Велосипед очты гына. Мөнир үз алдында берни дә күрмәде, куллары, аяклары тыңламас булды, һәм коты алынган малай, үзе дә сизмәстән:

— Илдус! Тот, ычкындырма!— дип кычкырып җибәрде. Зырылдап әйләнеп барган алгы тәгәрмәч кинәт читкә кереп китте, һәм Мөнир велосипеды-ние белән юл читендәге чокырга мәтәлеп төште.

Аның янында беркем дә юк иде.

## ИРЕК, АЛМАЗ ҺӘМ ҖӘЛИЛ

Ирек комлыкта уйнап ята. Үзе генә уйный. Аның кечкенә автомашинасы бар. Автомашинага ком тутыра да бер җирдән икенче җиргә илтеп аудара. Комны бушаткач, кире килә, тагын ком тутыра, тагын илтеп аудара. Ул үзенчә чокырлар казый, юллар сала, буалар буа.

Ул шулай уйнап ятканда, аның янына Алмаз белән Җәлил килде. Ирекнең күңелле итеп уйнавын күрделәр дә кызыктылар болар. Аларның да юллар салып, чокырлар казып уйныйсылары килде.

— Ирек, әйдә бергә уйныйбыз?— диде Алмаз.

— Мин синең машинаңа ком төярмен, син шофер булырсың,— диде Җәлил.

Ләкин Ирекнең аларны уенга катыштырасы килмәде.

— Кирәкми, мин үзем генә уйныйм,— диде ул. Малайлар аның сүзенә карамадылар, шунда комлыкта уйнарга да керештеләр. Комнан юллар салдылар, буалар будылар, таулар өйделәр. Ләкин алар комны куллары белән ташыдылар. Чөнки аларның машиналары юк иде.

Ирек машинасын аларга бирмәде, һаман үзе генә уйнады. Алай гына да түгел, Алмаз белән Җәлил килгәч, аңа комлыкта урын тар булып күренде.

— Минем комны алмагыз!— диде ул, шыңшып.

— Синекен алмыйбыз бит!— диде Алмаз. Ирек барыбер тынычланмады.

— Минем юлны таптамагыз! Минем чокырны бозмагыз!— диде ул, бәйләнчекләнеп.

— Синеке түгел, үзебезнеке!— диде Җәлил.

— Юк, минеке! Бу минем юл, минем буа!— диде Ирек.

Шулай диде дә иптәшләре ясаган юлны аягы белән бозып та ташлады. Алмаз белән Җәлилнең моңа ачулары килде. Шулай итеп малайлар ачуланыштылар та киттеләр.

Ирек еларга тотынды. Автомашинасын күтәрде дә, «әни!» дип кычкыра-кычкыра, үзләренә йөгерде.

Ләкин Ирек өйләренә кайтып җитә алмады. Тыкрыкта аңа кара эт очрады.

Юлга аркылы баскан да тик тора карап! Үзе зу-ур, бозау чаклы. Авызы ачылган. Ачык авызыннан очлы тешләре күренә, очлы тешләре арасыннан озын теле салынып тора. Котың алыныр!

Чыннан да, Ирекнең коты алынды. Ул шундый курыкты,— куркуыннан хәтта елавыннан да туктады.

Нишләргә хәзер? Эт янына барып булмый. Барсаң, кабар да йотар! Шулай ук аны читләтеп үтәргә дә мөмкин түгел — ике якта биек коймалар.

Малай, нишләргә белми карап торды-торды да, кире йөгерергә тотынды. Ул, тыны бетеп, Алмаз белән Җәлил янына килде.

— Ник килдең, елак?— диде Алмаз. Ирек рәтләп сүзен дә сөйли алмады.

— Э-эт... э-эт бар!— диде ул, тотлыгып. Җәлил белән Алмаз уйнауларыннан туктап калдылар. Ирек янынарак килделәр.

— Кайда ул?! Кайда?— диделәр алар.

— Те... те... тегендә... тыкрыкта,— диде Ирек.

— Әйдәле!— диде Алмаз, Ирекне үз артыннан ияртеп.

Малайлар тыкрыкка таба китеп бардылар. Карасалар, кара эт һаман шунда басып тора. Юл уртасында, эттән читтәрәк, Ирекнең автомашинасы аунап ята.

Батыр Алмаз кулына таяк алды, кыюланып эткә таба атлады. Хәзер инде Ирек тә курыкмады. Өчәү булгач, нишләп куркып торырга!

Эткә якынлашкач, Алмаз таягын ыргытты. Ирек белән Җәлил этне куркытып кычкырырга тотындылар.

Кара эт малайларга гаҗәпләнеп бер карады да койрыгын болгап алды, башын иде һәм иренеп кенә китеп барды. Тыкрык бушап калды.

— Кайтасыңмыни? Бар инде, кит,— диде Алмаз Ирекка.

— Юк, мин сезнең белән уйныйм,— диде Ирек. Малайлар юлдагы автомашинаны алдылар да, өчәүләшеп, яңадан комлыкка йөгерделәр.

## ӨЧ ТУГАН

### I

Габдулла абзый, эштән кайткач, Чулпан белән Әхәтне үз янына чакырып алды.

— Безнең бозау кайда йөрде бүген?— диде ул балаларга.

Бу сорауга Әхәт тә, Чулпан да аптырап калдылар. Бүген аларның бөтен вакыты уен белән узды. Бозау турында алар уйлап та карамадылар.

— Белмисезме? Белмәссез шул!— диде Габдулла абзый, балаларының берни эндәшми торуларын күреп.— Безнең бозау колхоз ашлыгына кергән. Шуның өчен минем биш хезмәт көнемне кистеләр. Менә, күрдегезме! Сезнең гамьсезлек аркасында никадәр эшләгән эшем юкка чыкты.

Мондый сүзне ишеткәч, балаларга бик уңайсыз булып китте. Алар икесе дә әтиләре алдында үзләрен бик гаепле итеп сизделәр. Ләкин аларның берсе дә бу туры-

да ачыктан-ачык әйтергә кыймады. Киресенчә, алар шундук бер-берсен гаепләргә, бер-берсеннән зарланырга тотындылар.

Әхәт әйтте:

— Бозауны кичә мин карадым, бүген Чулпан чираты,— диде.

Чулпан әйтте:

— Әни эштән кайтуга мин су китердем, абый берни эшләмәде,— диде.

Зарланганны, әләкләшкәнне Габдулла абзыйның җене сөйми иде. Ачудан аның кашлары җыерылды.

— «Гали Вәлигә, Вәли Галигә»,— дип менә сезнең ишеләр турында әйткәннәр инде,— диде ул.— Мондый чакта тагын: «Эт эткә, эт койрыкка»,— дип тә әйтәләр. Кыскасы, икегез дә гаепле. Бүтән көнне мондый нәрсә булмасын өчен, шулай итәрбез: бозауны, Әхәт, сиңа тапшырам...

— Ничек миңа тапшырасың?— диде малай, аңламыйча.

— Менә ничек: көн дә иртән син аны урамга куалап чыгарасың, чишмә буена алып барасың, кич, көтү кайтыр алдыннан, өйгә куып алып кайтасың... беркайчан да колхоз басуы ягына җибәрмисең. Аңлашылдымы?

— Аңлашылды,— диде Әхәт, теләр-теләмәс кенә, борынын тартып.

— Чулпанга — каз бәбкәләре!— диде Габдулла абзый, кызына борылып.

— Әйе шул! Каз бәбкәләре алар үзләре дә кайта. Кирәкми! Карасын әнә Чулпан бозауны!— диде кинәт Әхәт, киреләнеп.

— Син абый кеше, шуңа күрә сиңа авыррак эш бирелә,— диде Габдулла абзый.— Шуны да онытма, Чулпан көн саен чишмәдән икешәр мәртәбә су алып кайта.

— Мин дәү әнигә утын кисеп кертәм!— диде Әхәт.

— Бик әйбәт!— диде әтисе, улын мактап.— Алай үзең белеп эшләгәч, рәхмәттән башка сүзем юк. Ә инде бозау карауны мин үзем кушам. Шулай ук Чулпанга да... Әгәр үз эшегезне иренмичә эшләсәгез — бозауны да, каз бәбкәләрен дә көзгә чаклы, мәктәпкә йөри башлаганчы исән-сау карап-саклап үстерсәгез, ул чагында...— Габдулла абзый, серле генә елмаеп, балаларына күз кысып алды,— ул чагында Чулпанга яңа күлмәк, Әхәткә яңа бүрек алып бирермен!

Мондый тәкъдимгә балалар берсүзсез риза булдылар.

## II

Идән уртасында песи баласы белән уйнап утырган бәләкәй Таһир кинәт башын калкытып карады. Ул әтисенең соңгы сүзләрен ишетеп калды. Бит аның да яңа күлмәк, яңа бүрек киясе килә! Аның әле кышка чанасы да юк, яңа киез итеге дә юк. Нишләп әле алар аны гына читтә калдыралар?

Таһир йөгереп әтисе янына килде.

— Әти, әти, миңа да бирәр эш куш әле?— диде ул, ялынып.

Әтисе, гаҗәпләнеп, төпчек улына карады, кулыннан тотып аны күтәреп алды да үзенең тез башына утыртты.

— Сиңамы? Нинди эш кушарга икән соң сиңа?— диде ул, уйланып.

— Мин бөтен эшне дә булдыралам!— диде Таһир.— Песи баласын ашатам, чебиләргә җим бирәм, абый кискән утынны кертәм... Мин әле барысыннан да күбрәк эшлим!

Улының яхшы теләге Габдулла абзыйга бик ошады. Ләкин ул, никадәр генә уйласа да, аңа кушардай берни дә таба алмады. Шуннан соң ул Таһирның әнисенә эндәште.

— Бик әйбәт булыр!— диде әнисе дә, куанып.— Карасын әнә Сары тавыкны. Теңкәгә тиде шул Сары тавык: бакчага керә, түтәлләрне тибә. Үзе гел бүтән тавыклардан аерым йөри. Анысы гына җитмәгән, күкәен теләсә кая сала. Ярый әле бүген оясын таптым: лапас түбәсендәге печәнлеккә ияләнгән.

— Алайса, менә шул,— диде әтисе Таһирга,— Сары тавыкны сиңа бирәбез: бакчага кертмисең, керсә куалап чыгарасың. Салган бер күкәен югалтмый җыеп барасың. Җәй буена Сары тавыктан йөз күкәй ала алсаң...

Таһир, әтисенең әйтеп бетергәнен дә көтмәстән, бербер артлы тезеп тә китте:

— Яңа бүрек, яңа күлмәк, итек, чана!..

— Нәрсә, нәрсә?!— диде әтисе, көлеп.— Алай бик күп булыр бит, улым. Син инде берсен генә әйт. Иң кирәген генә.

— Чана!— диде малай, күп уйлап тормыйча.

## III

Икенче көнне Әхәт гадәттәгедән иртәрәк торды. Торды да шундук ишегалдына йөгереп чыкты. Көрән кашка бозау капка янында мөгрәп, моңаеп тора иде. Әхәт,

капканы ачып, бозауны урамга чыгарды. Бозау, үзен иректә сизгәч тә, колхоз басуы ягына борылмакчы булды. Ләкин Әхәт аны чишмә буена, яшел чирәмлеккә куып җибәрде.

Чулпан, йокыдан күзен ачкач та, иң элек каз бәбкәләре турында уйлады. «Миңа кадәр ашатмаган гына булсалар ярар иде»,— диде ул, борчылып.

Каз бәбкәләрен әле беркем дә ашатмаган иде. Чулпан шатланып бәбкәләре янына чыкты, пешкән бәрәңге катыштырып, иске табага көрпә белән җим болгатты. Җимне ул бәбкәләр алдына китереп утыртты.

Йомшак, яшькелт мамыклы бәбкәләр, пипылдашып, ашыгып, табадагы җимне сосарга керештеләр. Аларның бер ягында, кулына чыбык тотып, Чулпан басып торды, икенче ягында, муеннарын сузып ысылдый-ысылдый, ата каз белән ана каз йөренде.

Бәбкәләр ашап туйгач, Чулпан аларны шулай ук урамга чыгарды, чишмә буена куып җибәрде.

Бераздан Таһир да уянды. Абыйсы белән апасы кебек ул ишегалдына чыгып тормады, тәрәзә янына килде дә бакчага карады. Бакчада тавыклар юк иде. «Әллә чыгып ояны карап керим микән?»— дип уйлады ул. Ләкин никтер ирендергән кебек булды. «Ярар, ашагач чыгармын әле»,— диде малай, үз-үзен тынычландырып.

Өстәл өстендә самовар шаулап утыра иде. Зурлар чәй эчәләр иде, аларның алдына ак күмәч, май, шикәр куелган иде.

Шикәрне Таһир бик тә ярата иде, шундый ярата иде — әгәр мөмкин булса, көне буена бертуктаусыз шикәр генә суырып торыр иде һәм авызына бер генә валчык икмәк тә, бер генә бәрәңге дә капмаска риза булыр иде! Ләкин шунысы яман, шикәрне әнисе беркайчан да теләгәнчә бирми, күбрәк сорый башладың исә: «Шикәргә быел кырау төшкән, шикәр уңмады быел»,— ди. Алдый ул, билгеле. Шикәргә кырау төшми, бәрәңгегә генә төшә. Шуны да белмәгәч!

Таһир тиз генә өстәл янына килеп җитте. Абыйсы белән апасы кергәнче, аның әнисеннән берәр зуррак шакмак шикәр сорап аласы килде. Хәер, бүген бик үк сорап торырга да туры килмәде. Кече улын күргә, әтисе аны үз янына утыртты. «Төпчегем дә эшкә ярады!»— дип мактап алды һәм аның алдына зур гына бер шакмак шикәр белән бер телем ак күмәч куйды. Әнисе чәй ясап бирде.

## IV

Олылар чәй эчеп туйганчы, Таһир әтисе белән әнисе арасында утырды. Өстәл яныннан ул иң соңгы кеше булып кузгалды.

Шуннан соң ул ишегалдына чыкты, Сары тавыкның яшерен оясын эзләп тапты. Ул инде тавык күптән күкәй салгандыр дип уйлаган иде. Ояда маяга калдырылган иске күкәйдән башка берни тапмагач, аның кәефе кырылды.

Сары тавык, түл өчен азык эзләп, тиреслектә тибенеп йөри иде. Таһирның шундук аны оясына куып кертәсе, тизрәк күкәй салдырасы килде. Ул тавыкны лапаска куа башлады. Үзен эштән бүлдерүләренә Сары тавыкның бик нык ачуы килде. Ул дөнья бетереп кычкырырга, тавышланырга тотынды. Аннан күрмәкче бүтән тавыклар да кыткылдаша, чыр-чу килә башладылар. Тавышка өйдән Таһирның дәү әнисе килеп чыкты.

— Нишлисең, ник куасың аларны?— диде ул.

Таһир аңлатып бирде.

— Үз вакыты җиткәч салыр әле, кума,— диде дәү әнисе.

«Кайчан икән соң аның үз вакыты?»— дип уйлады малай, аптырап.

Сары тавык качкан җиреннән — чыбык-чабык арасыннан чыкты да, башын бик мәзәк боргалап, тары бөртегедәй күзләрен елтыратып, як-ягына каранып торды. Аннары ул җиргә ышкып томшыгын чистартып алды. Тирә-якта куркыныч берни дә, беркем дә юклыгына ышангач, канатларын бик нык җилпеде дә, муенын сузып, бар көченә кычкырып җибәрде. Күрәсең, үзенчә аның: «Мин хәзер беркемнән курыкмыйм!»— дип мактануы булгандыр инде.

Шушы эшләрне башкаргач, бераз вакыт Сары тавык җилфердәп торган озын купшы койрыклы, зур кызыл кикрикле әтәч тирәсендә, бүтән тавыклар тирәсендә тибенде һәм, ниһаять, тырт-тырт басып, абзарга таба юнәлде.

Шул вакыт утынлыкта нидер эшләп маташкан бәләкәй малай аның кая барганын күреп калды. «Әһә, оясына китте!»— дип уйлады ул.

Әмма Сары тавык бик тә хәйләкәр җанвар иде. Ояга менү турында ул уйлап та карамады. Абзар читәне арасында ул үзе генә белә торган бер ярык бар иде. Шул ярыктан ул бакча ягына чыкты. Анда чыккач инде нишләсәң дә, кая барсаң да ирек! Куе әрекмән яфракла-

ры, бәрәңге сабаклары арасында аны беркем күрми. Ул анда җаны теләгәнчә тибенә, кортлар, бөҗәкләр чүпли, бакчаны иңләп-буйлап йөри.

Сары тавык бүген дә шулай иркенләп тибенермен дип уйлады. Әмма ул ялгышты.

Таһир, кулына озын чыбык алды да, капкадан көтмәгәндә бакчага килеп керде, Сары тавыкның юлына аркылы төште һәм аны пыр туздырып куарга кереште. Сары тавык, кычкырмый-нитми, мыштым гына кире йөгерде.

Малай исә аны куып җитте дә чыбыгы белән аңа берике мәртәбә эләктереп алды. «Харап булдым! Үтерде, үтерде!» — дип кычкырды Сары тавык, коты алынып. Абзар ягына ул көчкә чыгып котылды.

Читән ярыгына Таһир чыбыгын кыстырып куйды. Сары тавык белән аның беренче мәртәбә ныклап танышуы шулай булды.

## V

Сары тавык, куалап куркытылганга, тынычлап түл җыя алмады. Шуңа күрә ул күкәен бүтән көндәгегә караганда бүген соңрак салды. Салды да, шатланып, канатларын кагып кытакларга тотынды. Аның тавышын ишетеп, абзарга Таһир килеп керде. Таһирны күргәч, Сары тавык печәнлектән ничек очып төшкәнен дә сизми калды. «Каравыл! Талыйлар, үтерәләр!» — дигән сыман, кычкыра-кычкыра тизрәк ишегалдына чыгып йөгерде.

Таһирга шул гына кирәк тә иде. Баскыч буенча ул печәнлеккә менде. Ояда хәзер ике күкәй ята иде. Күкәйләрнең берсе суык, икенчесе җып-җылы иде.

Малай җылы күкәйне алып түбәтәенә салды. Аннары түбәтәен бөкләп кулына тотты, сакланып кына аска төште дә, алдын-артын карамыйча, шундук өйгә чапты.

— Күкәй! Күкәй!— дип кычкырды ул, бөтен өй эчен шаулатып.

Ул шундый куанды, шундый сөенде, әйтерсең түбәтәйдәге шома кабыклы ап-ак күкәйне Сары тавык түгел,— үзе салган иде! Күкәйгә дәү әнисе дә шатланды, Сары тавыкны мактады, Таһирны мактады.

Таһир, мондый мактауга гына канәгать булмыйча, сикергәләп тышка чыгып йөгерде. Аның тагын абыйсына, апасына күрсәтәсе килде, алардан да мактау сүзләре ишетәсе килде. Ләкин абыйсы да, апасы да якын тирәдә күренмәде. Аларны эзләп малай урамга чыгып китмәкче булды.

Аның артыннан шундук дәү әнисе килеп җитте. Аның

кулындагы түбәтәен алды да күкәйне өйгә кертеп куйды. Таһир шыңшырга, хәтта еларга кереште.

— Күкәй күргәнең юкмы әллә!.. Бала-чага кебек...— диде дәү әнисе, Таһирны оялтып.

## VI

Кичкә таба, уйнап туйгач, Әхәт чишмә буеннан бозауны алып кайтты. Чулпан башта суга барды, аннары каз бәбкәләрен эзли китте. Ул арада Әхәт казан асты өчен балта белән утын чапкаларга кереште. Таһир: миңа утын кертергә куша күрмәсен бу тагын дип, тизрәк урамга чыгып тайды.

Ашар вакыт җиткәндә Габдулла абзый белән хатыны эштән кайтып керде.

— Ягез әле, сөйләгез: ниләр эшләдегез бүген?— диде Габдулла абзый, өстәл янына утыргач.

Әхәт белән Чулпан, бер-берсен бүлдереп, үзләренең көндез нишләүләре турында сөйләп бирделәр. Таһир оядан үзе алып төшкән күкәйне китереп күрсәтте.

Бүтән көннәрне дә шулай булды. Балалар көне буе уйнадылар, су керделәр, чишмә буендагы әрәмәлеккә бардылар, ләкин шул ук вакытта үзләренең эшләрен дә онытмадылар. Көрән кашка бозауның да, каз бәбкәләренең дә хәзер вакытында өйгә кайтмый калган чаклары булмады. Шулай ук аларның кеше бакчасына яисә колхоз басуына керүе турында да ишетергә туры килмәде.

Көн саен Таһир Сары тавык оясыннан бер күкәй алып төште. Сары тавыкны ул хәзер бер дә кумады да, куркытмады да. Киресенчә, аны күргән саен ул аңа җим сипте, икмәк ваклап бирде. Сары тавык малайга бик тиз ияләште һәм ерактан аны күреп алдымы, ашарга сорап, шундук аның янына йөгереп килә торган булып китте. Сары тавык оясыннан алып кергән һәрбер күкәйне Таһир аерым бер табакка җыеп барды.

Әхәт тизрәк көз җитүен, көрән бозауның зур булып, көр булып үсүен теләде. Чулпан, түземсезләнеп, бәбкәләрнең тизрәк ап-ак каз булып җитешүләрен көтте. Ә Таһир Сары тавыктан йөз күкәй салдыру турында гына уйлады.

## VII

Беркөнне Таһир үзе җыйган күкәйләрне санап карамакчы булды. Табакта биш күкәй дә ике күкәй бар иде. Малай никадәр генә баш ватса да, бишкә икене кушкач

ничә булганлыгын белә алмады. Чөнки ул биштән артык саный белми иде.

Табак янына ул әнисен алып килде.

— Әни, сана әле, йөзгә тулгандыр инде!— диде Таһир.

— Юк, улым,— диде әнисе.— Монда әле җиде генә. Җидедән соң сигез була, сигездән соң тугыз була, тугыздан соң ун була. Ун мәртәбә унның йөз була. Йөзгә әле бик күп кирәк.

Мондый сүзне ишетеп, малайның күңеле төште. «Болай булгач, беркайчан да йөзгә тутырып булмас»,— дип уйлады ул, пошынып. Аңа хәзер бу эш бик кызыксыз булып тоелды. Моннан соң ул Сары тавык оясына менеп йөрмәскә дигән карарга килде.

Әмма икенче көнне һәркемнең исен китәргән бер вакыйга булды. Сары тавык ике күкәй салды! Күкәйләр инде суынган иде, тик шулай да икесе дә өр-яңа иде, икесе дә бүген генә салынган иде.

Бу турыда Таһир иң элек дәү әнисенә әйтте, аннары абыйсы белән апасын эзләп тапты. Дәү әнисе берни әйтмәде, бары көлеп кенә куйды. Чулпанның исә күзе дүрт булды. Бары тик Әхәтнең генә моңа һич тә ышанасы килмәде.

— Тавык көнгә бер генә күкәй сала,— диде ул, бик белдекле булып.

— Минем Сары тавык икене сала!— диде Таһир, бирешергә теләмичә.— Мин аңа бүген шикәр ашаттым, май ашаттым. Шуңа күрә ул икене салган. Хәзер мин шикәрне бер дә үзем ашамыйм, Сары тавыкка гына бирәм.

Ләкин моңа карап кына Әхәтнең барыбер ышанасы килмәде. Ышану түгел, хәтта ул: «Тавык шикәр ашамый!»— дип бәхәсләшергә үк тотынды. Шундый ачу китергеч кеше булгач та булыр икән!

Бәхәсне үзара гына хәл кыла алмагач, балалар дәү әниләре янына бардылар. Ләкин дәү әниләре дә ачык кына берни дә әйтмәде, серле генә итеп бер көлемсерәде дә: «Салгач саладыр инде, Сары тавык ич ул!»— диде.

— Менә, күрдеңме!— диде Таһир, куанып.— Күбрәк шикәр ашатсам, Сары тавык өчне дә салыр әле! Әхәт этиләрен күтәргә булды.

Менә тагын кич булды, олылар эштән кайтты. Сары тавыкның бүген ике күкәй салуы турында ишеткәч, алар да бик гаҗәпләнделәр. Ләкин беркем дә Әхәт кебек моңа шикләнеп тормады.

— Тик, кара аны, күкәйләреңне вата күрмә!— диде әнисе, төпчек улын кисәтеп.

Әхәт икеләнә калды. «Күрәсең, кайбер тавыклар чын-

нан да икешәрне сала торгандыр шул»,— дип уйлады ул. Ә инде икенче көнне дә энесе печәнлектән җып-җылы ике күкәй алып төшкәч, ул моңа чын-чынлап ышана язды.

## VIII

Шулай да шикләнүчән малай мондый эшкә бөтенләй үк ышанып җитә алмады. Беркөнне ул энесенең нишләгәнен, кая барганын, оядан кайчан күкәй алганын — барысын да күзәтеп, сагалап тормакчы булды. Иртән иртүк көрән кашка бозауны чишмә буена куалап илтеп куйды да, иптәш малайлары белән урманга җиләккә барудан баш тартып, тиз генә өйгә кайтты.

Таһир әле өстәл яныннан торып китмәгән иде, тәлинкәдә шикәр җебетеп, шикәр суырып утыра иде. «Әһә, менә тоттым, алдакчы!— диде Әхәт, күңеленнән шатланып.— Шикәрне Сары тавыкка гына ашатам дигән иде, үзе әнә нишләп утыра!»

Шикәрен суырып бетергәч, Таһир, караватка чалкан ятып, песи баласы белән уйнарга керешге: аңа үзенең бармагын ялатты, аның алдында бау очы селкеп, аны бераз биетеп алды.

Бераздан дәү әнисенең икенче мәртәбә самовар кайнатканы ишетелде. Ул шулай әледән-әле чәй кайнатып эчә һәм, чәй эчмәсәм тамагым туймый, дип зарлана иде.

Таһир, тәлинкә-йомыры чылтыраганны ишетеп, песи баласы белән уйнавыннан туктады да ашыгып дәү әнисе янына чыкты. Ул кечкенә өстәл янына килеп утырды һәм, күзләрен майландырып, шикәр савытына карап тора башлады. «Туймас тамак!»— дип уйлады Әхәт, энесенә ачуы килеп.

— Шул шакшы кулларың белән өстәл янына килергә ничек оялмыйсың?— диде дәү әнисе.— Бар, ю кулыңны!

Таһир кулларын ашык-пошык кына юды да яңадан дәү әнисе янына килеп утырды. Дәү әнисе аңа иң зур йомырыга чәй ясады, йомыры янына бәләкәй генә шикәр шакмагы куйды. Таһир бик озаклап чәй эчте.

Ишек төбендә чыбыркы ишеп булашкан Әхәтнең түземлеге бетә башлады. Малайлар белән урманга китмәвенә ул үкенеп тә куйды. Аның тизрәк урамга чыгасы килде.

Менә, ниһаять, абзар ягында тавыклар кытаклаганы ишетелде.

## IX

Таһир шикәрен генә капты да йөгереп тышка чыкты. Абыйсының үзен күзәтеп торуы турында ул башына да китереп карамады. Ул туп-туры абзарга юнәлде. Тавыкларның ничек кытаклаганына карап ул инде аларның күкәй салганнармы, юкмы икәнлеген аера башлаган иде. Хәзер, һичшиксез, берәр тавык күкәй салган булырга тиеш иде.

Әхәт сиздермичә генә энесе артыннан китте, ләкин абзар эченә кереп тормады, тышта гына калды һәм: «Нишләр икән бу?»— дип, ярыктан күзәтергә тотынды.

Таһир тиз генә печәнлеккә менеп китте. Анда бераз югалып торды да яңадан баскыч янына килде. Аның түбәтәе башында иде, димәк, Сары тавык әле күкәй салмаган булырга тиеш. Ләкин нишләптер ул бер дә аска төшәргә ашыкмады.

Әхәт тын да алмый күзәтеп торуында булды. Абзар эчтән икегә бүленгән иде. Аның бер башында кыш көне сыер, сарык ябыла торган җылы бүлеме бар иде. Җылы абзар түбәсенә кипкән печән тутырып куела һәм шул түбә «печәнлек» дип атала иде. Абзарның икенче башы исә читән белән генә тотып алынган иде. Читән абзар өрлекләре өстенә сәндерә кебек итеп агач тезеп куелган иде. Ләкин сәндерә дә, печәнлек тә бер-берсенә тоташмаган, алар арасында беркадәр бушлык бар иде.

Кулындагы такта кисәгенең бер башын Таһир сәндерә ягына ташлады. Тактаның икенче башы печәнлек ягында калды. Ике арада бик шәп басма барлыкка килде. Ә икенче якта — тавык оялары! Ай-һай, башы эшләгән соң малайның! Тавык ояларына ул җирдән менә алмый — баскыч бик текә, аннары баскычның аркылы агачлары да киң, аралы.

Таһир, абзар кыегына тотына-тотына, икенче якка чыга башлады. Чыкты да сәндерәдәге бер оядан тиз генә бер күкәй алды. Күкәйне ул түбәтәенә салды һәм яңадан шул ук басма буенча печәнлек ягына чыкмакчы булды.

Шул чакны Әхәт искәртмәстән:

— Белдем эшеңне!— дип кычкырып җибәрде. Шуннан соң ул нәрсә булганын карап тормады. Аның өчен хәзер бөтенесе аңлашылды. Ул, дәү энисенә әйтергә дип, тизрәк өйгә йөгерде.

## X

Дәү энисе өйдә юк иде. Әхәт урам капкасы янында Чулпанны күреп алды. Алар икәүләшеп абзарга килеп кергәндә, куркуыннан нишләргә белмәгән Таһир печән-

лектә елап тора иде, ә аста, җир өстендә, аның кулыннан төшеп киткән түбәтәй ята иде. Түбәтәй эчендәге күкәй ватылган, түбәтәй исә пычранып, буялып беткән иде. Абыйсы белән апасын күреп, Таһир тагын да ныграк еларга тотынды.

— Төш, карак!— дип кычкырды Әхәт.

— Менә ничек сала икән Сары тавык икешәр күкәй!— диде Чулпан, энесен мыскыллап.

— Төш!— дип кычкырды Әхәт тагын да.

— Төшмим!— диде малай, киреләнеп.

Әхәт печәнлеккә менәргә иткәч, кулына ул таяк алды да селтәнергә тотынды. Әхәт кире чигенергә мәҗбүр булды.

Таһир, елый-елый, шыңшый-шыңшый печәнлектә төшкә кадәр утырды. Төш җиткәч, дәү әнисе килде: ашарга төш, диде, нишләп анда бозау кебек мөгрәп утырасың, диде. Ләкин малай дәү әнисен дә тыңламады.

— Төшмим булгач, төшмим! Бер пот шикәр бирсәң дә төшмим!— диде ул һәм бер дә юктан тагын еларга керешеп китте.

Һәм төшмәде дә. Үзенең ярамаган эш эшләп тотылуы өчен ул шундый оялды, шундый гарьләнде — җир ярылса җир тишегенә кереп китәрдәй булды.

## XI

Балалар, этиләре, әниләре кайткач, көндез булган хәлнең барысын да сөйләп бирделәр. Габдулла абзый печәнлеккә үзе менеп китте. Елый-елый күзләре шешенеп беткән малаен ул Сары тавык оясы янында бөгәрләнеп яткан килеш тапты. Әтисенә Таһир киреләнеп тормады, бары тик аның күзләренә генә карамаска тырышты.

Габдулла абзый аны өйгә күтәреп алып керде. Алып керде дә, кырыс кына итеп:

— Әйдә, юын да яхшылап, ашарга утыр,— диде. Аның гаебе турында олылар үзара бер сүз дә әйтмәделәр. Таһир сабынлап битен-кулын юды, аннары ныгытып сөртенде дә ипләп кенә өстәл янына килеп утырды. Бүтән вакыттагы кебек хәзер иркәләнеп тәм-том теләнеп тә тормады, бармагын чәенә дә тыкмады — алдына ни куйсалар, шуны ашады.

— Улымның тегермәне шәп тарта!— диде Габдулла абзый бераздан.

Әхәт белән Чулпан шундук энеләреннән көләргә, аны үртәргә тотындылар.

— Көне буе ашамасаң, тарта ул тегермән!— диде Әхәт.

— Тегермәненә су күп килгәндер,— диде Чулпан. Әтиләре аларга кырыс кына карап алды.

— Көлмәгез!— диде ул.— Бер мәртәбә хаталанган икән, икенче кабатламас. Сабак булыр. Шулаймы, улым?

— Шулай...— диде Таһир әкрен генә.

Чыннан да, Сары тавык шуннан соң берәр генә күкәй сала башлады.

# ЭНҖЕЛЕ ҮРДӘК

*(Ике пәрдәле пьеса)*

**КАТНАШАЛАР:**

Кыяташ батыр.
Ана — Кыяташның әнисе.
Айсылу (Энҗеле үрдәк).
Хан.
Вәзир.
Сихерче.
Күл иясе.
Игенче.
Дию пәрие.
Акбүзат, Сакчы, Кызлар, Хезмәтчеләр, Беренче җен, Икенче җен, Җеннәр.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Идел буенда Кызлар тавы. Уртада мең яшәр имән. Әкрен генә җил исә, чәчәкләр тирбәлә, кошлар сайрый.
Беркадәр тынлыктан соң Игенче керә, карангалап имәнне әйләнеп чыга, иелеп җирне тыңлый.

Игенче. Ул-бу юк. Бары да үз урынында: имән шаулый, энҗе ташы елтырап ята. Бу имән төбендә, җир астында Болгар иленең Энҗе ташы — Бәхет ташы саклана! Сау бул, имән. Иртәгә мин тагын килермен. (*Чыга.*)

Чыр-чу килеп Айсылу һәм кызлар йөгереп керә.

Кызлар. Исәнме, имән!
Исәнме, дәү имән!

Айсылу. Син — олы имән, син — иң карт имән, син — иң яшь имән! Без тагын килдек синең яныңа...

Кызлар. Уйнарга-көләргә,
Күңел ачарга,
Серләр сөйләргә,
Киңәш сорарга!

А й с ы л у. Әйдәгез, кызлар, имәнгә атап җыр җырлыйбыз. (*Җырлый.*)

Идел буенда,
Кызлар тавында
Үсә дәү имән,
Мең яшәр имән.

Кызлар тавында
Үскәнгә имән
Илебез исән,
Йортыбыз исән.

Кызлар кулга-кул тотынышып имән тирәли әйләнәләр, җырга кушылалар.

Кызлар тавында
Үскәнгә имән
Илебез исән,
Йортыбыз исән.

В ә з и р белән С и х е р ч е керә. Куак артына яшеренеп кызларны күзәтәләр.

В ә з и р (*Сихерчегә*). Хәзер син күренмичә генә имән янына бар. Айсылу минем турыга җиткәч тә куркыт. Шунда мин аны хап иттереп тотып алырмын!.. Алырмын да... Бүген — соңгы көн. Булса — була, булмаса — юк. Минем башка түзәр тәкатем калмады. Бар!

С и х е р ч е. Киттем, хуҗам! (*Югала.*)

В ә з и р (*үзалдына*). Әйе, бүген — соңгы көн. Айсылу бүген йә минеке, йә... баканыкы булачак.

Кызлар түгәрәк әйләнгәндә, имән төбеннән С и х е р ч е килеп чыга. Кызлар чыркылдап кычкырып җибәрәләр, як-якка сибеләләр. Вәзир Айсылуны тотып ала.

А й с ы л у. Абау! Кем бу?

В ә з и р. Бу — мин, Айсылу. Тынычлан, матурым.

А й с ы л у. Син... кем? Вәзир?!

В ә з и р. Син ялгышмадың, мин — Вәзир, матурым.

А й с ы л у. Син нишләп монда, Вәзир?

В ә з и р. Мин сине күзәттем, Айсылу. Мин сине тотып алдым. Син миңа соңгы сүзеңне әйтергә тиешсең.

А й с ы л у (*ычкынмакчы була, ачуланып*). Мин сиңа соңгы сүземне әйттем инде: яратмыйм мин сине, яратмыйм!

В ә з и р. Миңа синең яратуың кирәкми, матурым, син үзең кирәк. Минем Хан кияве буласым килә.

А й с ы л у. Юк, юк! Мондый эшкә эти дә риза түгел.

В ә з и р. Хан әйтте: Айсылу үзе риза булса, мин кар-

шы түгел, диде. Шуңа күрә мин синең үзең белән сөйләшмәкче булдым да.

Айсылу. Мин каршы! Үзең карт, үзең ямьсез — карасаң котың алыныр. Җибәр мине! Җибәрмәсәң, этигә әйтәм.

Вәзир. Торып тор, матурым. Соңгы мәртәбә мин синнән яхшылык белән сорыйм...

Айсылу (*сагаеп*). Нишләмәкче буласың?

Вәзир (*серле*). Минем сине теләсә нишләтергә көчемнән килә, матурым. Бүген... озакламый җил-давыл чыгачак.

Айсылу (*куркып*). Син каян беләсең аны?

Вәзир (*янап, дәһшәтле*). Иң соңгы мәртәбә сорыйм: минеке буласыңмы, әллә?..

Айсылу (*ычкынмакчы була*). Булмыйм! Куркам мин синнән, җирәнәм мин синнән, Вәзир!

**Кинәт көчле җил исә, күк күкри, яшен яшьни, куркып кычкырган тавышлар ишетелә. Күктән Дию пәриенең койрыгы сузыла. Вәзир Айсылуны койрыкка таба этеп җибәрә. Койрык Айсылуны әләктереп ала да яңадан күккә күтәрелә.**

Вәзир. Миннән бүләк сиңа, Дию пәрие галиҗәнапләре!

Айсылу. Коткарыгыз!

Вәзир. Ха-ха! Соң инде, соң, матурым! Сине хәзер беркем дә коткара алмаячак. Ха-ха...

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

**Хан сарае. Вәзир ялгыз. Әрле-бирле йөренә.**

Вәзир. Нишләп һаман кайтып җитми бу тинтәк Сихерче?

Сакчы керә.

Сакчы. Олуг Вәзир, Сихерче килде — керсенме?

Вәзир. Керсен!

Сакчы чыга. Сихерче керә.

Сихерче. Синең боерыгың буенча, хуҗам, мин Болгар илендәге барлык авылларны, шәһәрләрне айкап чыктым.

Вәзир. Сүзеңне кыска тот — таптыңмы?

Сихерче. Юк, хуҗам, тапмадым. Мин үзем дә, авыллардагы, шәһәрләрдәге шәкертләрем дә Кыяташ батырны...

Вәзир. Лыгырдык! «Батыр», имеш! Тапмагач, ни пычагыма монда ут капкандай кайтып җиттең? Бар, күземә

күренмә, тагын бер кат ныгытып эзлә. Табарга! Ишетәсеңме, бернигә карамый табарга!

Сихерче. Табылыр, хуҗам. (*Китмәкче була.*)

Вәзир. Тукта. Җил-давыл белән кемнәр киткәнен белдеңме? Бәлки, ул инде күптән Дию пәрие галиҗәнапләренең җир асты базында ята торгандыр?

Сихерче. Белештем, хуҗам. Кыяташ... батыр... кичәге давылдан соң Дию пәрие галиҗәнапләре кулына эләгүчеләр арасында да, басылып, суга төшеп үлүчеләр арасында да күренми. Болгар илендә аның исемен телгә алучы да юк. Карале, хуҗам, әллә соң без юкка борчылабызмы? Әллә соң ул... ни... Кыяташ атлы углан әле бөтенләй дөньяга да тумады микән?

Вәзир. Ахмак! Көн дә мин аны төшемдә күрәм. Ул көчле, таза. Ул укны төз ата. Әлегә ул кылыч тота белми. Кыяташ кулына кылыч алса, ул чагында...

Сихерче (*куркып*). Ул чагында ни булыр, хуҗам?

Вәзир. А-а, ул чагында!.. Юк, юк, берни булмас! Болгар илендә туган, үлгән һәр кешене мин исәпләп барам. Ә менә аның туганын белми калганмын. Нинди зур хата!

Сихерче. Хата, бик зур хата, хуҗам!

Вәзир. Ахмак! Аңа быел унбиш яшь тулды. Ашыгырга кирәк, ашыгырга! Чиксез зур байлыкка, көчкә ия булу өчен мин Дию пәрие галиҗәнапләренә сатылдым. Аның ярдәмендә мин кеше ирешмәстәй теләкләремә ирештем. Болгар илендә миңа буйсынмаган бер генә кеше дә юк. Ханны мин уч төбендә биетәм. Кешеләр генә түгел, миңа хәтта җеннәр дә буйсына. Ләкин миңа болар гына аз.

Сихерче. Аз, хуҗам, аз.

Вәзир. Әйе, лыгырдык, аз. Дию пәрие галиҗәнапләре сине миңа турылыклы хезмәт итәргә дип бирде. Ничек хезмәт итәсең син?

Сихерче. Мин турылыклы хезмәт итәм, хуҗам.

Вәзир. Кыяташ кая?! Ул туганда син кайда булдың?

Сихерче. Мин аны көн-төн эзлим, хуҗам.

Вәзир. Ахмак, югал күземнән!

Сихерче юк була. Вәзир ялгыз.

Вәзир. Бөтен җир асты дөньясына Дию пәрие баш булган кебек, бөтен җир өсте дөньясына — барлык илләргә, барлык халыкларга мин баш булырга тиешмен. Мин! Ләкин Кыяташ табылмыйча торып, Дию пәриенә тотып бирелмичә торып, мин һаман да Болгар ханының вәзире генә булып калачакмын. Дию пәрие аның дөньяда яшәвен белә, көн дә ул аны миннән таләп итә. Бер Кыяташ өчен ул миңа бар дөньяны бирергә әзер!

Сакчы керә.

Сакчы. Хан килә! (*Чыга.*)

Хан керә. Аның артыннан берничә кеше ияргән. Хан тәхеткә утыра. Хезмәтчеләр, Ханның якын кешеләре читтә басып торалар.

Хан (*колакка каты булганлыктан, кычкырып сөйләшә*). Вәзир, син мондамы?

Вәзир (*кычкырып, ялагайланып*). Хәерле көн, изге Болгар иленең изге Ханы!

Хан. Кызым... Айсылу турында ул-бу ишетелмиме?

Вәзир. Юк, ишетелми, бөек Ханым.

Хан. Оах! Кызым!

Вәзир. Хәлең ничек, бөек Ханым? Күзең яхшы күрәме, колагың яхшы ишетәме? Йокың тыныч булдымы?

Хан. Ни сөйлисең, Вәзир?! Минем күзем начар күрә, колакларым начар ишетә. Узган төнне мин черем дә итә алмадым. Сөекле кызым Айсылуның юкка чыгуы мине акылдан шашар дәрәҗәгә җиткерде. Минем өчен кояш сүнде, Вәзир!

Вәзир. Айсылу юкка чыккач, минем өчен дә кояш сүнде, Ханым. (*Үзалдына.*) Диюгә турылыклы икәнлегемне күрсәтү өчен, Айсылуны мин аңа үз колларым белән биреп җибәрдем. Ләкин, Кыяташны тотып бирсәм, Дию пәрие Айсылуны миңа кире кайтарачак.

Хан. Оах, кызым! Ничәмә ел инде менә кара болыт килеп баса да, көчле давыл бар нәрсәне кырып-җимереп китә. Нинди хикмәт бу? Ничек котылырга бу афәттән? Юк микән дөньяда шуның серен белүче?

Вәзир. Андый кеше бар ул, бөек Ханым. Чит илдән мин бик тә укымышлы бер галим чакырттым. Әгәр шуннан сорап карасак?

Хан. Кайда ул — тиз арада китерт аны монда.

Вәзир. Баш өсте, бөек Ханым. (*Ишек ягына кычкыра.*) Әй, кем бар анда — хәзер үк чит ил галимен табып китерегез.

Сакчы керә.

Сакчы. Чит ил галиме монда. Керсенме?

Вәзир. Керсен.

Сакчы чыга. Сихерче керә. Башына чалма ураган.

Сихерче (*Ханга баш иеп*). Мин — Күпбелем углы Биккүпбеләм дигән атаклы галим булам. Дөньяда миннән дә белеклерәк, миннән дә укымышлырак беркем юк. Син чакырттыңмы мине, бөек Ханым?

Х а н. Әйе, мин чакырттым сине.

В ә з и р (*Сихерчегә*). Таптыңмы?

С и х е р ч е (*Вәзиргә*). Юк, хуҗам.

В ә з и р. Ханга дөресен әйт — һич югы монысы дөмексен тизрәк!

С и х е р ч е (*Вәзиргә*). Син дигәнчә булыр, хуҗам. (*Ханга.*) Ник чакырттың мине, изге илнең изге Ханы?

Х а н. Күпбелем углы Биккүпбеләм! Ничәмә ел инде менә көпә-көндез көтмәгәндә көчле җил-давыл чыга да минем авылларымны, шәһәрләремне җимерә, кешеләремне һәлак итә. Кичәгенәк шундый җил-давыл вакытында минем сөекле кызым Айсылу юкка чыкты. Кайда минем кызым? Нинди серле җил-давыл бу? Бармы шуннан берәр котылу юлы?

С и х е р ч е. Аннан котылу юлы юк, бөек Ханым. Бу гади җил-давыл гына түгел. Бу — Каф-тау артында җиде кат җир астында, җиде кат су астында яши торган өч башлы Дию пәриенең эше. Син инде beләсеңдер, бөек Ханым, дөньяда Дию пәриеннән көчлерәк беркем юк. Элегрәк ул үз тирәсендәге илләрне генә таласа, хәзер инде ерак җирләргә дә килә башлады. Ул үзенә якындагы барлык авылларны, шәһәрләрне кырып, кешеләрен ашап бетерде.

Х а н. Ах, мәлгунь!

В ә з и р. Ах, явыз!

Сарай кешеләре курку өннәре чыгаралар.

С и х е р ч е. Әйе, бөек Ханым, бик явыз ул Каф-тау арты Дию пәрие. Күп булса, бер-ике елдан ул синең илеңне дә кара җиргә әйләндерәчәк.

Х а н (*ачуланып идәнгә тукылдата*). Телеңә — тилчә! Сөйләнмә юкны!

С и х е р ч е. Мин, Күпбелем углы Биккүпбеләм, юкны сөйләмим. Мин йолдызларга карап фикер йөртәм, йолдызлар белән чагыштырганда, синең илең тузан бөртеге генә.

Х а н (*ярсып*). Үкчәңне күтәр, оятсыз галим!

С и х е р ч е. Синең сөекле кызың Айсылу менә шул Каф-тау арты Дию пәрие кулында, бөек Ханым.

Х а н. Оах, кызым! (*Башын тота, һушсыз булып егыла.*)

В ә з и р (*Сихерчегә*). Югал моннан!

Сихерче чыга. Хан тирәсендә ыгы-зыгы. Кинәт ишек артында ниндидер шау-шу ишетелә. Барысы да шул якка борылып карыйлар.

В ә з и р (*ишек ягына кычкыра*). Ни булды? Кем бар анда?

Сакчы керә.

Сакчы. Кызлар тавы янындагы авылдан Игенче килгән. Керсенме?

Вәзир (*үзалдына*). Ха-ха! Бик шәп! (*Сакчыга.*) Керсен!

Игенче керә. Хан тәхете алдына егыла.

Игенче. Хан! Илгә бәла-каза килде!

Хан. Нинди бәла-каза?

Игенче. Хан! Вәзир! Кешеләр! Кичәге җил-давыл... Идел ярындагы, Кызлар тавындагы Мең яшәр имәнне... төбе-тамыры белән...

Хан. Оах!

Вәзир. Булмас!

Игенче. Әйе, төбе-тамыры белән, җир астындагы Бәхет энҗесе белән бергә йолкып алып киткән!

Хан. Оах! (*Йөрәгенә тотына.*)

Вәзир. Менә бу кайгы дисәң дә кайгы! Болай булгач, бәхет китте бездән!

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Карурман уртасында Серле күл. Яр буйларында камышлык. Корыган агачлар, төпсәләр. Еракта таулар, кыялар күренә.
Камышлар арасыннан Кыяташ чыга. Кулында ук-җәя. Туктый, тирә-ягына карана, тагын кузгалып китә.

Кыяташ. Кая килеп чыктым соң мин? Нинди җир бу? Мин бит үзебезнең Зәңгәр күл буена үрдәк атарга дип чыккан идем. Туктале, тукта, шул ук Зәңгәр күл буе түгелме соң бу? Әнә таулар, кыялар. Анда минем әни булырга тиеш. (*Кычкыра.*) Әни-и! (*Тирә-як тып-тын.*) Әни-и! Ишетәсеңме, мин монда-а!

Җир астыннан Күл иясе чыга. Ул кечкенә. Сакалы озын. Йомгак кебек әрле-бирле тәгәрәп йөри дә корыган агач артына поса.

Күл иясе (*үзалдына*). Менә кызык, менә тамаша! Каян килгән, ничек килгән монда бу адәм баласы? Менә кызык, менә тамаша! Күпме яшәп Серле күл буенда адәми зат күргәнем булмады.

Кыяташ (*кычкыра*). Әни-и!.. (*Җавап юк.*) Туктале, нинди сәер җир соң бу шулай да? Юк, бу безнең Зәңгәр күл түгел.

Күл иясе (*Кыяташның алдына чыгып баса*). Әйе, бу сезнең күл түгел. Бу — безнең күл.

Кыяташ (*як-ягына карана*). Әллә колагыма гына ишетелде? Кемдер бар бугай монда.

К ү л и я с е. Мин бар монда, мин!

К ы я т а ш (*күреп ала*). Ә-ә, синмени әле бу? Нинди кечкенә адәмчек! (*Үзалдына.*) Үзе шундый ямьсез!

К ү л и я с е. Мин адәм түгел. Мин — җен, мин — Күл иясе!

К ы я т а ш (*каушап артына чигенә*). Шулаймыни?!

К ү л и я с е (*усал*). Ничек килдең син монда?

К ы я т а ш. Монда ничек килеп чыгуымны мин үзем дә аңлый алмыйм. Адаштым бугай мин. Карале, алайса, бу җеннәр күлемени?

К ү л и я с е. Әйе, җеннәр күле.

К ы я т а ш. Кайда соң ул җеннәр — күл төбендәме, күл буендамы?

К ү л и я с е. Телеңә салынма! Күпне белсәң, тиз картаерсың.

К ы я т а ш. Синең кебекме?

К ү л и я с е. Көлмә! Соңыннан еларга туры килмәсен. Шуны исеңнән чыгарма: монда килеп эләккән бер генә кеше дә кире киталмый. Йөз мең гаскәр саклый бу күлне. Минем гаскәр! Хе-хе, ник тынып калдың, батыр егет?

К ы я т а ш. Гафу ит, Күл иясе, белмәдем. (*Үзалдына.*) Сакалы нинди озын! Әни әйткән иде шул җеннәрнең көче сакалында дип... Туктале, мин сине! (*Кинәт алга ыргыла. Күл иясенең сакалыннан эләктереп ала да үзен югары күтәрә.*)

К ү л и я с е (*кычкыра*). А-ай, җибәр, батыр егет!

К ы я т а ш. Әһә, шулаймы, иблис мәлгунь?! Хәзер син минем кулда. Инде әйт: ник саклыйсың бу күлне йөз мең гаскәр белән? Нинди сере бар бу күлнең?

К ү л и я с е. Сакалымны җибәр, ай-ай, сакалымны! Җибәрсәң әйтермен.

К ы я т а ш. Җибәрми торсыннар әле!

К ү л и я с е. Сакалым, ай, сакалым! Харап итмә! Ни теләсәң шуны бирермен, ни сорасаң, шуны әйтермен.

К ы я т а ш. Ярар, иблис мәлгунь, бик әйбәтләп кенә мин синең сакалыңны кисеп алыйм әле...

К ү л и я с е. Ай-ай, кисә күрмә! Бел, минем сакалны киссәң, өеңә кайталмассың.

К ы я т а ш (*икеләнеп*). Алдамыйсың микән, иблис токымы?

К ү л и я с е. Юк, юк, җеннәр башлыгы беркайчан алдамас. Әйтә күр: ни телисең?

К ы я т а ш. Болай булгач, хәзер үк мине өйгә әни янына кайтарып куй.

К ү л и я с е. Була ул! Тик кайда торуыңны яхшылап аңлатып кына бир.

Кыяташ. Тыңла, иблис токымы: мин Болгар иленең Кыяташ атлы кешесе булам. Торган җирем — Очлы тау итәгендәге Зәңгәр күл буе. Беләсеңме?

Күл иясе. Беләм, батыр егет! Тик Зәңгәр күл бик зур бит ул. Аның кай төшендә өегез?

Кыяташ. Безнең өй тау куышында, Зәңгәр күлнең көньягында. Ялгыз кыя янында.

Күл иясе (*сөенеп*). Беләм, беләм! (*Үзалдына.*) Менә каптың кармакка, адәм баласы. Минем сердән элек синең үз сереӊ чишелде. (*Кыяташка.*) Тагын нинди теләкләрең бар?

Кыяташ. Әни янына буш кул белән кайтасым килми. Күлеңнән берәр үрдәк атып алыйк.

Күл иясе. Анысы да була! (*Сызгырып җибәрә. Камышлар арасыннан пырылдап үрдәкләр очып чыга.*) Әнә, күпме телисең, шул чаклы атып ал.

Кыяташ. Болай укны төзәп булмый икән. Туктале, башта мин сине ныгытып бәйләп куйыйм. (*Күл иясенең, сакалын үзенең билбавына бәйләп куя.*) Әйдә, җен, очыр тагын үрдәкләреңне.

Күл иясе тагын сызгыра, камышлар арасыннан тагын үрдәкләр очып чыга, Кыяташ ук ата. Аның аягы астына гына бер үрдәк килеп төшә.

Кыяташ (*үрдәкне ала, исе китеп*). Нинди матур үрдәк! Каурыйлары җем-җем итә, томшыгы — алтын, башында — энҗе ташы! Үзе шундый авыр! Әй син, шайтан, бер теләгемне үтәдең, инде икенчесен үтә. Әйдә киттек безнең өйгә! (*Карана, Күл иясеннән җилләр искән.*) Качкан! Юк! (*Үз-үзен тирги.*) Эх, җебегән! Эх, пешмәгән! Җен сүзенә ышаналармы соң?!

Якында гына җир астында Күл иясенең көлгән тавышы ишетелә.

Күл иясе. Кайтып кара инде хәзер өеңә!

Кыяташ. Алдакчы! Икенче мәртәбә кулыма эләксәң, белермен нишләтергә!

Күл иясе (*көлә*). Хе-хе, эләктерә алмассың, хе-хе... Сакалымны кисмәгән өчен шулай да мин сине исән калдырам: үзең теләсә ничек кайтып кит.

Кыяташ (*тавыш килгән төшкә аягы белән тибә*). Һич югы әйт, ялганчы җен, безнең өй кайсы якта? (*Җавап юк.*) Качты, куркак шайтан! (*Төпсәгә утыра, кайгыра.*) Инде нишләргә, ничек кайтырга?

Шул чакны җирдә яткан Энҗеле үрдәк тыпырчына башлый, очып китмәнче була. Кыяташ аягына баса, Энҗеле үрдәкне кулына ала.

Кыяташ. Син дә ычкынмакчы буласыңмы? Ычкынмый тор әле!

Э н җ е л е   ү р д ә к (*телгә килә*). Курыкма, егет, мин беркая китмим. Мин сиңа ярдәм итәргә телим.

К ы я т а ш (*бик нык гаҗәпләнеп*). Син... үрдәк... ничек тереледең? Җитмәсә үзең кешечә сөйләшә беләсең!

Э н җ е л е   ү р д ә к. Мин үлмәдем. Син минем канатымны гына яраладың. Шуның өчен рәхмәт сиңа, гүзәл егет. Хәзер син минем баштагы энҗе ташын ал.

Кыяташ Энҗеле үрдәк башындагы энҗе ташын ала. Энҗеле үрдәк җиңелчә генә кычкырып җибәрә дә бик матур кызга әйләнә. Кыяташ исе китеп артына чигенә. Җир астыннан К ү л   и я с е чыга, төпсә артына кача.

К ү л   и я с е. Менә кызык, менә тамаша! Бу адәм баласы Энҗеле үрдәкне атып төшергән ләбаса! Нишләргә хәзер, нишләргә?

Э н җ е л е   ү р д ә к (*Айсылу*). Тагын бер мәртәбә рәхмәт сиңа, батыр егет! Син мине яман сихердән коткардың. Әйдә киттек синең өеңә — мин юлны беләм.

К ы я т а ш. Өнемме бу, төшемме? Син шундый чибәр, мин сиңа карый да алмыйм... минем күзләрем камаша! Үз гомеремдә минем әнидән башка беркемне күргәнем юк. Кем син, тиңсез гүзәл: җенме, кешеме?

А й с ы л у. Сорашма, Кыяташ батыр.

К ы я т а ш. Кара! Кулыңны кайда канаттың?

А й с ы л у. Син яраладың.

К ы я т а ш. Мин? (*Айсылуның яралы кулына кагыла.*) Авыртамы?

А й с ы л у. Инде авыртмый. Син кагылу белән ярам да төзәлде.

К ы я т а ш (*исе китеп*). Карале, чынлап та!

А й с ы л у. Монда безгә озак торырга ярамый. Китик тизрәк моннан.

К ы я т а ш. Мин синең белән җир читенә китәргә дә әзер!

Күл иясе сиздермичә генә Кыяташның кулындагы энҗене төртеп төшерә, үзе шундук юк була.

К ы я т а ш. Ах, төшеп китте! (*Эзли.*)

А й с ы л у. Нәрсә?

К ы я т а ш. Энҗе ташы.

А й с ы л у. Энҗе ташы дисеңме? Мин сиңа әйтмәдеммени? Ул энҗе ташында синең, минем... тагын бик күп, бик күп кешеләрнең бәхете саклана.

К ы я т а ш (*эзли*). Менә монда аяк астына гына төште бит ул!

А й с ы л у. Эзләмә, табалмассың. Хуш, Кыяташ батыр. (*Яңадан үрдәккә әйләнә.*) Сиңа бер үтенечем бар: мине

югары күтәреп очырып җибәр. Үзең көнчыгышка карап кит — илең, өең шунда булыр. Туп-туры бар — артыңа да, уңга да, сулга да борылып карама.

Кыяташ (*өзгәләнеп*). Гүзәлем! Бәхетем! Ни булды — аңлат яхшылап? Юк, юк, мин сине җибәрмим!

Күл иясе (*җир астыннан көлеп*). Хе-хе, җибәрми кара — күрмәгәнеңне күрерсең!

Энҗеле үрдәк. Тотма, ярамый. Мине җибәрмәсәң, син дә үләрсең, мин дә үләрмен. Әнә җирдә бер каурыем ята. Шул каурыйны Болгар ханына алып кайтып бир. Хуш, хуш, Кыяташ батыр!

Кыяташ (*төшенке*). Бар, оч, миннән ирек сиңа! (*Очыра, артыннан карап кала. Җирдән иелеп үрдәк каурыен ала.*) Борчылма, теләгеңне үтәрмен, серле үрдәк.

Күл иясе (*җир астыннан чыга, үзалдына*). Хе-хе, карап карыйк — кем өлгеррәк булып чыгар икән? Менә хәзер каптырам да каптырам мин сине кармакка!

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Зәңгәр күл буе. Ана үзенең югалган улын эзли.

Ана (*җырлый*).

Җилләрдән сорадым, күрмәдек, диделәр,
Таулардан сорадым, юк, диде таулар да.
Кайда син, колыным, күз нурым, бер эндәш,—
Үлеме, тереме?.. Кайда син, кайларда?..

Юк, беркайда да юк. Шулай ук мәңгегә югалттыммыни мин сине, Кыяташ балам?

Елый-елый Ана әрле-бирле йөри дә, ерактагы тауларга таба китә. Шулай алдын-артын карамыйча барганда, көтмәгәндә Кыяташ белән очраша. Алар чак-чак кына бер-берсенә бәрелешмиләр, чөнки Кыяташ та, беркая борылып карамыйча, туп-туры бара.

Кыяташ (*сискәнеп китә, артына чигенә, әнисе ягына борылып карарга мәҗбүр була*). Аһ! Харап булдым — миңа бит читкә карарга ярамый!

Ана. Углым! Балам! Син түгелме соң?!

Кыяташ. Әни!

Кочаклашалар, елашалар.

Ана. Исән! Үлмәгән дә, югалмаган да!

К ы я т а ш. Әни, без кайда? Мин әле кайтып җиттемме?

А н а. Каян? Ач күзеңне, кара як-ягыңа: әнә безнең таулар, әнә безнең Зәңгәр күл буйлары.

К ы я т а ш. И әни, ярый әле кайтып җиткәнмен! Беләсеңме мин кайда булдым?

А н а. Кайда?

К ы я т а ш. Үзем дә белмим — әллә кайда... Төш дисәң төш түгел, өн дисәң өн түгел.

А н а. Теләсә кая ятып йоклама дип әйттем бит мин сиңа!

К ы я т а ш. Юк, мин йокламадым, әни. Сиңа әйтмичә генә Зәңгәр күл буена үрдәк атарга дип барган идем, йөри торгач, әллә нинди җиргә барып чыкканмын. Шунда, әни, беләсеңме, мин үземнең бәхетемне очраттым!

А н а. Менә сиңа кирәк булса! Нindирәк соң ул синең бәхетең?

К ы я т а ш. Ул шундый матур, әни! Бер бите ай, бер бите кояш. Башында энҗе ташы бар. Үзе үрдәк, үзе кыз. Аңа, әни, караган саен карыйсы килә, аның белән гел бергә буласы килә.

А н а (*уйчан*). Гаҗәп, бик гаҗәп, улым. Син чыннан да төш күргәнсең, ахрысы.

К ы я т а ш. Юк, әни, төш түгел бугай ул. Мин аны менә сине күргән кебек күрдем. Ышанмасаң, менә кара — аның каурые. (*Энҗеле үрдәкнең каурыен әнисенә бирә.*)

А н а (*исе китеп*). Чыннан да бик сәер каурый бу. Безнең күлдә мондый каурыйлы үрдәк юк. (*Үзалдына.*) «Үзе үрдәк, үзе кыз...», «Башында энҗе ташы бар...» Нинди энҗе булыр ул? Әллә теге... Бәхет энҗесеме?! (*Кыяташка.*) Улым, күз нурым, кайда ул Энҗеле үрдәк?

К ы я т а ш. Белмим, әни. Ул үзе очып китте, энҗесе төшеп югалды.

А н а (*күңеле сүрелеп*). Ә-ә, алаймыни?..

К ы я т а ш. Әни, бу каурыйны ул Болгар Ханына илтеп бирергә кушты.

А н а. Менә анысы булмас! Мин сине, улым, моннан соң беркая да үзеңне генә җибәрмәячәкмен.

К ы я т а ш. Әни!..

А н а. Улым, сүземне тыңла, оныт боларның барысын да! Син бары төш кенә күргәнсең. Ишетсен колагың, Хан янына бару турында уеңа да китермә!

К ы я т а ш. Ләкин мин ул кызга сүз бирдем, әни!

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Хан сарае. Вәзир ялгыз.

Вәзир. Айсылуны Дию пәриенә биреп җибәргәнгә тиздән бер ел тула. Мин һаман да Вәзир... Хан ялчысы... Каян табарга, ничек табарга шул Кыяташны?

Аяк астында серле шакылдау тавышы ишетелә. Вәзир тынып кала.

Вәзир. Кем ул анда?

Тавыш. Бу мин — Күл иясе.

Вәзир. Кер.

Аяк астыннан Күл иясе калка. Икенче яктан Сихерче керә.

Күл иясе. Сиңа күп көч, байлык телим, хуҗам.

Вәзир. Сөйлә — ни булды? Тик озакка сузма: тиздән Хан керергә тиеш.

Күл иясе. Яңалык бар, яңалык, хуҗам! Син эзләгән адәм табылды!

Вәзир, Сихерче (*икесе бергә*). Табылды?!

Күл иясе. Табылды. Мин таптым, мин, хуҗам!

Вәзир. Аңлатып сөйлә.

Күл иясе. Ыы... ни... Камышлар арасыннан килеп чыкты.

Вәзир. Кайда? Нинди камышлар арасыннан?

Күл иясе. Шул инде, шул, үзе килеп чыкты. Килеп чыкты да «әни» дип кычкырырга тотынды. Ни булган дип чыксам...

Сихерче. Кайсы авылда, кайсы шәһәрдә тора — шунысын гына әйт тә...

Күл иясе. Менә белмәдең, Сихерче! Ул шәһәрдә дә, авылда да тормый.

Вәзир (*түземсезләнеп*). Кайда ул?

Күл иясе. Ыы... ни... хуҗам, ул әйтте: Очлы тау итәгендәге Зәңгәр күл буенда, Ялгыз кыя янында, диде.

Сихерче. Беләм! Анда бер тирән озын тау куышы бар.

Күл иясе. Шунда, шунда! Үзе әйтте! Хе-хе...

Вәзир (*Сихерчегә*). Бар, тиз бул!

Сихерче. Киттем! (*Чыга.*)

Сакчы керә.

Сакчы. Хан килә, Хан! (*Чыга.*)

Вәзир (*Күл иясенә*). Югал!

Күл иясе югала. Таякка таянып Хан керә. Ул авыру, хәлсез. Аны ике яктан ике хезмәтче җитәкләгән.

Хан (*тәхеткә утыра*). Вәзир, соңгы сәгатьләрем якынлаша, ахрысы. Сиңа әйтеп калдырасы сүзләрем бар.

Вәзир (*сөенеп*). Тыңлыйм, Ханым!

Ишек артында ниндидер ыгы-зыгы ишетелә. Анда — Кыяташ.

Кыяташ (*ишек артында*). Кертегез мине, Ханда минем йомышым бар!

Хан (*башын калкыта*). Чү! Мин ниндидер ят тавыш ишеттем. Әй, кем ул анда минем янга кермәк була? Сакчылар, кертегез аны.

Сакчы керә.

Сакчы. Синең янга, бөек Ханым, ниндидер йолкыш углан кермәк була.

Вәзир (*сакчыга җикеренә*). Куалап җибәр, тинтәк! Бөек Ханның болай да кәефе юк.

Хан (*аягүрә баса*). Керсен, керсен! Минем ул йолкыш угланны күрәсем килә.

Кыяташ (*ишек артында*). Әнә, Хан керсен ди. Җибәрегез мине!

Кинәт ишек ачылып китә, бүлмәгә Кыяташ килеп керә.

Вәзир (*үзалдына*). Шул үзе! Кыяташ! Дөнья бетереп эзләгән кеше үзе килде. (*Як-ягына карана.*) Кая Сихерче, кая минем ышанычым?!

Ул арада Кыяташ Хан каршысына килә, баш ия. Бүлмәдәгеләр тып-тын калалар. Вәзир барлык кешеләрдән бер читтә аерылып тора.

Кыяташ. Кичер мине, Ханым.

Хан. Мин сине кичердем, батыр углан. Сөйлә: кем син, атаң кем, анаң кем? Каян килдең, ник килдең?

Кыяташ. Мин бер ярлы егет, Ханым. Исемем — Кыяташ.

Вәзир (*үзалдына*). Никтер мин аннан куркам. Минем кулларым, аякларым калтырый. Бу ни эш бу?

Хан (*Кыяташка*). Сөйлә, сөйлә, углан. Синең көр тавышың минем авыру йөрәгемә дәва булды.

Кыяташ. Мин, Ханым, Очлы тау итәгендәге Зәңгәр күл буенда, Ялгыз кыядагы тау куышында туганмын. Әнием мине шунда җил-давылдан саклап үстергән. Уналты ел буена мин беркемне күрмәдем, беркем белән аралашмадым. Бүген шулай, әниемнең сүзен тыңламыйча, үзем генә күл буена чыккан идем...

Хан (*җанланганнан-җанлана барып*). Шуннан, шуннан? Сөйлә, бертуктамый сөйлә. Сине күргәч, кызым Айсылуны күргән кебек булдым.

К ы я т а ш. Шуннан шул, Ханым, йөри-йөри ниндидер икенче күл буена барып чыкканмын. Шунда менә бу үрдәк кауырыен таптым. (*Ханга Энҗеле үрдәк кауырыен бирә. Бүлмә эче яп-якты булып китә. Сарай кешеләре аһылдап җибәрәләр, куллары белән күзләрен каплыйлар.*)

Х а н (*кауырыйны караштыра*). Нинди гаҗәеп кауырый! Үзе ялт-йолт килә, үзе шундый авыр! Беркайчан да мондый матур нәрсә күргәнем юк иде.

В ә з и р (*үзалдына*). Энҗеле үрдәк кауырые! Каян, ничек?! Күл иясе, җеннәр ни караган?

Х а н. Шуннан, шуннан, сөекле углан? Сөйлә, сөйлә. Бу кауырыйны кулыма алгач, мин яшәреп киткәндәй булдым. Күзем дә яхшырак күрә, колакларым да яхшырак ишетә башлады сыман. Бу гаҗәеп кауырыең өчен ни телисең, углан?

К ы я т а ш. Миңа берни кирәкми, Ханым.

Х а н. Вәзир! Бу угланга шушы кауырые өчен үзе күтәреп китә алган кадәр алтын бир.

В ә з и р (*каушаудан теле тотлыга*). Б... баш өсте, б... бөек Ханым! Минем дә беркайчан да м... мондый, кауырыйны к... күргәнем юк. Бер-бер сере юк микән моның? (*Үзалдына.*) Мин сине башкачарак әләктерермен, ахрысы.

Х а н. Чыннан да, әллә нинди кауырый бу. Теге... аты коргыры... чит ил галиме берәр нәрсә белми микән бу хакта?

В ә з и р (*куанган булып*). Менә-менә, м... мин дә шуны әйтмәкче идем, б... бөек Ханым! Чакыртыйммы үзен?

Х а н. Чакырт.

В ә з и р (*ишек ягына кычкыра*). Әй, сакчы, чит ил галиме керсен!

С и х е р ч е керә, түргә, Хан янына уза.

С и х е р ч е. Мин, Күпбелем углы Биккүпбеләм, синең каршыңда, бөек Ханым. Күреп торам, сине бу гаҗәеп кауырыйның сере кызыксындыра, ахрысы. Сөйләргә рөхсәтме, бөек Ханым?

Х а н. Сөйлә.

В ә з и р (*Сихерчегә*). Берәр нәрсә уйлап тап!

С и х е р ч е (*Вәзиргә*). Табармын, хуҗам! (*Ханга.*) Бу — Энҗеле үрдәк кауырые, бөек Ханым.

Х а н. Ул ниткән Энҗеле үрдәк тагын?

С и х е р ч е. Ул шундый үрдәк — син әле аның бер кауырыен күргәч тә яшәреп киткәндәй булдың. Әгәр син аның үзен күрсәң, итен пешереп ашасаң...

Х а н. Шуннан, шуннан?

Сихерче. Ничә яшькә яшәрәсең килсә, шул яшькә яшәрерсең, бөек Ханым!

Хан (*аягүрә баса*). Яңадан яшәрергә?! Иллегә? Кырыкка? Юк, егерме бишкә!

Вәзир. Әйе, әйе, егерме бишкә, бөек Ханым!

Хан. Ләкин ул Энҗеле үрдәкне каян табарга, ничек табарга?

Сихерче. Шундый матур каурыйны табып китергән углан сиңа үрдәкнең үзен дә табып китерер, бөек Ханым! (*Кыяташка карый, кинәт каушап кире чигенә, үзалдына.*) О-о, мин аның йөзенә дә карый алмыйм. Аннан нindидер серле көч бөркелә!

Кыяташ. Ханым, мин...

Вәзир (*Кыяташка*). Ты... тыныңны чыгарма! Кы... кы... каурыен таба белгәнсең, үрдәген дә табарсың!

Хан. Әйе, табарсың, батыр углан.

Вәзир. Өч тәүлек эчендә Энҗеле үрдәкне табып китермәсәң, без синең башыңны чабып өзәрбез.

Кыяташ. Кичер мине, Ханым!

Хан. Мин сиңа боердым, углан. Минем абзардан үзеңә кирәкле атны сайла да кирәкле корал, азык ал да, вакытыңны әрәм итмичә, бүгеннән үк юлга чык.

Вәзир (*Кыяташка*). Бар, бар, юлыңда бул!

Кыяташ чыга.

Сихерче (*Вәзиргә*). Аны болай коры кул белән генә алып булмас, хуҗам. Аңа каршы сихернең иң усалын кулланырга туры киләчәк.

Вәзир (*Сихерчегә*). Ник кулланмадың соң, лыгырдык?!

Сихерче. Оныткanмын, хуҗам! (*Куеныннан китап чыгара, актара, укый.*) Туктале, карап карыйм әле.

Вәзир. Бабилонда өч ел укыдың, Бохарада ике ел укыдың, җитмәсә Дию пәрие галиҗәнапләре янында жиде ел буена төрле сихер гыйлеменә өйрәндең. Шулай да кулыңнан кул ярысы да эш килми.

Сихерче. Таптым, хуҗам! (*Югала.*)

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Ялгыз кыядагы тау куышы. Ана судан кайтып керә.

Ана. Улым, Кыяташ, өйдәме син? (*Тыңлап тора, җавап бирүче юк. Чиләкләрен куя да кире ишек янына килә, күңелсезләнеп.*) Юк, кайтмаган. Менә тагын сорамыйча чыгып киткән. Аны хәзер тау куышында гына тотып

булмаячак. Канат чыгарган кош баласы кебек, ул һаман ireккә омтыла. Кая китәр минем яшь бөркетем? Шулай ук Хан янына китте микәнни? (*Шул чакны еракта ат тоягы тавышы ишетелә.*) Ул, ул! Минем лачыным! Атка атланган. Ләкин... нинди ат ул?

Еракта ат кешни. Тояк тавышлары тына. Бераздан Кыяташ кайтып керә. Бер кулында кылыч, икенче кулында калкан, өстендә тимерле киемнәр.

Кыяташ. Әни!

Ана. Синме бу, углым? Кайда йөрдең, каян алдың бу коралларны?

Кыяташ (*авыр сулап*). Әни, кичер мине — мин тагын да синнән сорамыйча, синең сүзне тыңламыйча хата ясадым. Мин тагын бәлагә тарыдым, әни!

Ана. Ни булды — сөйлә, углым.

Кыяташ. Булды инде, әни.

Ана. Димәк, Хан янына бардың?! Теге каурыйны алыпмы?

Кыяташ. Әйе, шул каһәр суккан каурыйны алып бардым. Хан миңа Энҗеле үрдәкне табып китерергә боерды. Өч көн эчендә табып китермәсәм, ул чагында... (*Елый.*)

Ана. Әйе, углым, бик авыр эш кушканнар икән сиңа. Тик шулай да авырлыктан куркып елау егетлек түгел.

Кыяташ (*елаудан туктый*). Кая барыйм, каян эзлим мин ул Энҗеле үрдәкне?! Әйтче, әни, ничек тапмак кирәк очкан кошны?

Ана (*уйланып*). Әйе, углым, очкан кошны табу җиңел булмас. Бүген сиңа уналты яшь тулды. Син балигъ булдың. Авырлыктан, кыенлыктан куркып, аптырап гомер буена шушы тау куышында яшәмәссең ич!

Кыяташ. Нишләргә соң, әни, нишләргә?

Ана. Киңәшем шул: хәзер үк юлга чык.

Кыяташ. Әни, кара төнгә каршымы?!

Ана. Әйе, углым. Кара төннән куркып йоклап яткан кеше беркайчан да эзләгәнен таба алмаячак.

Кыяташ. Әни, син миңа гел изгелек телидең. Рәхмәт яхшы киңәшеңә. Ләкин мин кая китәргә дә белмим. Күрсәт миңа туры юлны!

Ана. Углым, исеңнән чыгарма: дөньяда туры гына юллар юк. Һәркем үз юлын үзе салырга тиеш. Күреп торам, Хан сиңа ат биргән, корал биргән. Каяле? (*Улының коралларын күтәреп карый.*) Нинди җиңел! Юк! Мин сиңа әтиеңнең киемнәрен, коралларын бирермен. (*Куышның аргы башыннан яңа кылыч, калкан һәм тимерле киемнәр алып килә, Кыяташка бирә.*)

К ы я т а ш (*кылыч йөзен үбә*). Әтием кылычы!

А н а. Моннан уналты ел элек кара җил-давыл вакытында юкка чыккан әтиеңнең кылычы ул, углым. Бу кылыч аңа ата-бабадан калган. Ата-бабалар коралы кулыңда булганда, бернинди дошман да, бернинди сихер дә сине җиңә алмаячак. Әтиең кылычында безнең йөзләгән, меңләгән батырларның изге көче саклана.

К ы я т а ш. Әни, чынлап, бу кылычны кулыма алгач та мин үземне кыюрак, батыррак итеп тоя башладым. Тик нишләп соң син аны миңа элегрәк бирмәдең?

А н а. Бу кылычны, углым, теләсә кайчан тотарга ярамый. Үзеңә, илеңә, халкыңа үлем куркынычы килгәндә генә ул ярдәм итә. Бары шул чагында гына аның көче була. Менә хәзер шундый чак килде. Тау астында, яшел болында утлап йөргән Акбүзат булыр. Ул — әтиеңнең аты. Акбүзат синең иң якын юлдашың булыр. Тимерле киемнәреңне ки дә, кылычыңны кулыңа ал да, Акбүзатка атланып, көнбатышка карап кит.

Кыяташ әтисенең киемнәрен кия, коралларын ала. Әнисе белән саубуллашып, ишеккә юнәлә.

К ы я т а ш. Сау бул, әни. Изге теләктә тор!

А н а. Сау бул, углым, күз нурым. Бәхетеңне табып кайт, бөркетем!

Кыяташ чыга. Бераздан еракта әкренәя барган тояк тавышлары ишетелә.

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Тау-ташлар, урманнар арасыннан Акбүзатка атланган Кыяташ бара. Төн белән көн аралаша, тагын төн туа.
Тирә-якта яшеннәр яшьни, күкләр күкри. Ялгыз егет каршысына еланнар шуышып чыга, баш өстеннән каракошлар очып китә. Кайдадыр ямьсез тавышлар белән шүрәлеләр кычкыра, бүреләр улый, Кыяташ, кылыч белән уңга-сулга селтәнеп, үзенә юл ярып, туктаусыз алга бара. *(Җырлый.)*

Кара төн — алда,
Ят җирләр — алда.
Кемнәр бар анда?
Ниләр бар анда?

Акбүзат минем
Якын юлдашым.
Янда — калканым,
Кулда — кылычым.

Ят җирләр аша
Юллар ярырмын.
Каршы килгәнне
Кырып салырмын!

Менә алда бер генә тәрәзәле ялгыз өй күренә. Тәрәзәдә тычкан күзе кадәр генә ут.

Кыяташ. Ул нинди ут анда? Өй түгелме соң? Өй! Бу карурманда да кеше яшәр икән!

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Ялгыз өйдә учак янында, теше төшеп беткән Убырлы карчык кыяфәтендә, Сихерче җеп эрләп утыра. Ишек шакыган тавыш ишетелә.

Убырлы карчык (*Сихерче*). Кем бар анда? Керегез, кер, ишек ачык.

Кыяташ керә.

Кыяташ. Исәнме, әби.

Убырлы карчык. Бик исән әле, бәбкәм. Әйдә, түрдән уз. Чишен, ял ит. Хәзер менә аш пешәр. Күреп торам — ашыккансың, йончылгансың. Бик ерактан киләсең, ахрысы?

Кыяташ. Бик ерактан киләм, әби. Мин Болгар иленең Кыяташ атлы батыры булам.

Убырлы карчык (*елап җибәрә*). Һай, бәбкәм! Син туганнан бирле көтеп утырам мин сине урынымнан бер кузгалмый. Без апалы-сеңелле өч туганыек, беребездән — беребез чибәр кызларыек. Көннәрдән беркөнне җил-давыл чыкты да...

Кыяташ. Алайса, әбекәй, сез дә шул җил-давыл аркасында...

Убырлы карчык. Без дә, бәбкәм, без дә шуның аркасында менә шушы көнгә төштек. Явыз Дию пәрие безне яшьләй картайтты. Коткарсаң, син генә коткарырсың безне.

Кыяташ. Әби, сөйлә — ничек коткарырга сезне, ничек юк итәргә Дию пәриен?!

Убырлы карчык. Мин сиңа барысын да сөйләрмен, бәбкәм. Әле төн озын. Башта син чишен, җылын. Бергәләп менә аш ашарбыз.

Кыяташ чишенә, кылычын, калканын чөйгә элеп куя, учак каршысына килеп утыра.

Кыяташ. Алай мине күптән көтеп торгач, син минем кая баруымны да беләсеңдер, әбекәй?

Убырлы карчык. Беләм, бәбкәм, барысын да беләм. Син, Кыяташ батыр, Энҗеле үрдәкне эзләп барасың.

Кыяташ. Дөрес, әби!

Убырлы карчык. Сине Хан җибәргән булырга тиеш.

Кыяташ. Монысы да дөрес! Ләкин ничек, каян табарга ул Энҗеле үрдәкне — син әйтә алмассыңмы?

Убырлы карчык. Аны табуы җиңел түгел, бәбкәм. Энҗеле үрдәк Дию пәриенең җир асты сараенда, җиде кат койма эчендә, җиде кат ишек артында...

Кыяташ (*урыныннан торып*). Әби, әбекәем, әйтче, зинһар, кайда ул Дию пәриенең сарае?

Убырлы карчык. Аның сарае, бәбкәм, кеше аягы басмаган тау-ташлар, кыялар арасында. Анда син болай гына баралмассың. Дию пәрие патшалыгында синең атың арып егылачак, коралларыңның көче юкка чыгачак. Шуңа күрә, бәбкәм, мин сиңа үзеңнекеннән дә яхшырак ат бирермен, кораллар бирермен. Шулар белән син минем беренче тутам янына барып җитәрсең.

Кыяташ. Әби, мин хәзер үк юлга чыгам!

Убырлы карчык. Тыңлап бетер, ашыкма, бәбкәм.

Кыяташ. Тагын ни — сөйлә, әби?

Убырлы карчык. Тагын шул: мин биргән ат белән коралларны беренче тутам янында калдырырсың. Ул сиңа үзенең атын, коралларын бирер. Беренче тутамнан соң безнең иң өлкән тутабызны эзләп табарсың. Иң өлкән тутабыз сиңа дөньяда иң җитез, иң көчле ат бирер, иң үткер кылыч белән иң чыдам калкан бирер.

Кыяташ. Шуннан, шуннан, әбекәй?

Убырлы карчык. Безнең иң өлкән тутабыз сиңа Дию пәриенең сараена бара торган юлны өйрәтер.

Кыяташ. Әби, кая атың, кая коралларың — мин хәзер үк синең беренче тутаңны эзләп китәм!

Убырлы карчык. Бу кадәр түземсез булгач та булырсың икән, бәбкәм! Менә таң атсын, көн тусын...

Кыяташ. Юк, юк, әбекәй, минем күңелем түзми, минем йөрәгем ярсый — минем тизрәк Дию пәриенең сараен эзләп табасым килә!

Убырлы карчык (*уфтанган булып*). Нихәл итәсең, мин сине тоткарлый алмыйм. Ак юл сиңа, бәбкәм. Менә минем коралларым. (*Бирә.*)

Кыяташ (*Убырлы карчык биргән коралларны ала*). Рәхмәт, әби. Ләкин нишләп соң ул бик җиңел?

Убырлы карчык. Ул шулай тоела гына, бәбкәм. Синең илдә авыр булган әйбер монда, Дию пәрие биләмәләрендә, җиңел булып тоела.

Кыяташ. Гаҗәп, Ханның вәзире дә миңа шундый җиңел кылыч биргән иде.

Убырлы карчык. Монысын яшереп куйыйм әле — Дию пәриен җиңеп кайтканда кире үзеңә бирермен. (*Чөйдәге кылычны алмакчы була. Шул вакыт тышта Акбүзат кешнәп җибәрә, нәрсәгәдер тибә. Нидер ватылган, кырылган тавыш ишетелә.*)

Кыяташ (*урыныннан сикереп тора*). Бу ни хикмәт — синең кылычың агачка әйләнде, әби! (*Убырлы карчыкның чөйдәге кылычны алырга азаплануын күреп кала.*) Тукта, нишләмәкче буласың?! (*Убырлы карчыкны этеп җибәрә, тиз генә үзенең кылычын эләктереп ала, Убырлы карчыкка селтәнә. Убырлы карчык Сихерчегә әйләнә һәм юк та була. Янып торган учак та, өй дә юкка чыга. Тирә-як — тип-тигез дала. Каршыда ялгыз агачка бәйләнгән Акбүзат кына тора.*) Менә сиңа кирәк булса! Ярый әле бу бәладән дә котылдым. Моннан соң инде мине берни дә, беркем дә алдый алмас. Дию пәриенең оясын туздырмыйча, туры юлдан тайпылмам! (*Акбүзатка атлана, юлын дәвам итә.*)

Сихерче (*яшеренгән җиреннән чыга, Кыяташ артыннан карап кала*). Булмады. Китте, ычкынды... (*Куеныннан китабын чыгара, актара.*) Туктале, тукта, шулай да күрсәтермен әле мин сиңа күрмәгәнеңне, Кыяташ батыр!

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Карурман эчендәге Серле күл. Җеннәр күңел ачалар — җырлыйлар, биләр, төрлечә кыланалар. Кинәт ерактa ашыгып килүчеләрнең аяк тавышлары ишетелә. Җеннәр куркып кача башлыйлар.

Беренче җен. Туктагыз әле, ни булды, ник чабасыз?

Икенче җен. Чапмассың! Хуҗа белән Сихерче килә — күрмисеңмени?

Беренче җен (*артына борылып карый*). Әйе шул! Икесе дә ачулы.

Вәзир (*ерактан кычкыра*). Әй, туктагыз, тукта!

Беренче җен. Мин йөгерә алмыйм — аягым карыша.

Икенче җен. Ай, йөрәгем!

Җилләнеп Вәзир белән Сихерче килеп керә. Барлык җеннәр котлары алынып, туктап калалар, кайберләре җиргә егыла.

Вәзир. Теге йолкыш углан борын төбегездән Энҗеле үрдәк каурыен алып киткәндә дә шулай качыштыгызмы сез?

Беренче җен. Б-б-без түгел...

Вәзир. Кем соң? Мин качтыммы сездән, сез качтыгызмы миннән?

Беренче җен. Каурыйны без түгел, Күл иясе бирде.

Вәзир. Шулаймыни әле? (*Сихерчегә.*) Чакырт аны монда.

Сихерче таягы белән җиргә тукылдата, тыңлап тора да тагын тукылдата. Күп тә үтми, җир астыннан Күл иясе килеп чыга.

Күл иясе (*Вәзир алдында баш ия*). Мин кирәк булдыммы, хуҗам?

Вәзир. Теге йолкыш егеткә Энҗеле үрдәк каурыен син тоттырып җибәрдеңме?

Күл иясе. Ул аны үзе табып алды, хуҗам.

Вәзир. Аңа моннан юлны син өйрәттеңме?

Күл иясе. Энҗеле үрдәк өйрәтте, хуҗам.

Вәзир. Әй, син, кил бире! (*Беренче җенне чакырып ала.*) Күл иясенең теге йолкышка Энҗеле үрдәк каурыен биреп җибәргәнен күрдеңме?

Беренче җен. Күрдем, хуҗам. Кыяташ батыр безнең Күл иясенең сакалыннан тотып алгач, безнең Күл иясе, Кыяташ батырдан котылмакчы булып, Энҗеле үрдәкне атарга үзе кушты.

Вәзир (*Күл иясенә*). Дөресме шул?

Күл иясе. Ыы... Ни... дөрес, хуҗам.

Вәзир. Синең аңгыралыгың аркасында, кешеләр безнең яшерен эшләрнең эзенә төштеләр — аңлыйсыңмы шуны?!

Күл иясе. Кыяташны мин таптым, хуҗам.

Вәзир. Кыяташны син юк та итәрсең!

Күл иясе. Кыяташны мин юк итәрмен, хуҗам.

Вәзир (*барлык җеннәргә*). Әй сез, ачык авызлар! Болгар иленең Кыяташ атлы яшь адәме кулына кылыч алды. Ул хәзер падишабыз Дию пәрие галиҗәнапләре яши торган җиргә таба юл тота.

Барлык җеннәр (*куркышып*). А! О! У!

Вәзир. Тиздән ул монда, Серле күл буйларына килеп җитәчәк.

Котлары алынган җеннәрнең улаган, чинаган, кычкырган тавышлары ишетелә.

Вәзир. Куркаклар, хәзер үк сугышка әзерләнегез! Онытмагыз, бу соңгы сугыш булачак. Әгәр сез аны җиңә алсагыз, җир йөзендәге барлык кешеләр минем кулга төшәчәк. Шуннан соң без аларны әкренләп-әкренләп юк итәрбез.

Еракта ат тояклары тавышы ишетелә. Җеннәр качыша башлыйлар. Вәзир белән Сихерче дә, Күл иясе дә яшеренә. Акбүз атка атланган К ы я т а ш керә.

К ы я т а ш. Каяле, менә бу матур күл буенда бераз ял итеп алыйк. (*Атыннан төшә.*)

Шул вакыт Кыяташ яныннан гына уклар оча башлый. Шаулашып кинәт җеннәр килеп чыга. Кыяташ, кылычы белән селтәнеп, җеннәргә каршы ташлана. Ике арада сугыш башлана. Җеннәр кача башлыйлар.

В ә з и р (*качкан җиреннән, Сихерчегә*). Күрсәт көчеңне! Гаскәр кырылып беткәнче, сихерлә тизрәк шуны!

С и х е р ч е (*сугышка чыга, Кыяташка*). Нәрсәгә әйләнәсең килә: ташкамы, агачкамы? Хәзер мин сине!..

К ы я т а ш. Үзең ташка әйләнә күрмә!

Сугышалар. Кыяташ Сихерчене урталай чабып ташлый.

В ә з и р (*качкан җиреннән, үзалдына*). Инде чыннан да ышандым — җир йөзендә сине, батыр егет, берни белән дә җиңеп булмый икән. Ләкин син әле минем кемлегемне белеп җиткермисең! (*Качкан җиреннән чыга.*) Ха-ха-ха, Кыяташ батыр! Синең каберең күл төбендә булыр!

К ы я т а ш. Карап карыйк.

Сугышалар. Кыяташ Вәзирне кылычы белән чаба да Серле күлгә ыргыта.

К ы я т а ш. Үзең казыган кабердә үзең ят!

Кинәт арттан К ү л  и я с е килеп чыга да Кыяташны суга төртеп җибәрә.

К ү л  и я с е. Менә дөмектердем мин сине! Барысы да үлеп бетте. Мин генә исән калдым, мин генә!

## УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Серле күл төбе. Су үләннәре, ауган агачлар. Балыклар йөзеп йөри. Төртеп төшерелгән К ы я т а ш аягына баса, башын калкыта, як-ягына карана. Еракта Дию пәриенең сарае күренә.

К ы я т а ш. Менә хикмәт! Явыз Дию пәриенең сарае әллә шул үземе?

Д и ю  п ә р и е (*җир астыннан*). И-ы-о! Кем ул тынычсызлый мине?

К ы я т а ш. Ата шайтан, чык монда! Мин синең белән сугышырга телим!

Д и ю  п ә р и е. Хо-хо-хо! Нинди батыр ул минем бе-

лән сугышмакчы була? Фу-у, адәм исе килә! Әллә адәмме син?

Кыяташ. Әйе, мин — адәм! Бөек Болгар иленнән килгән Кыяташ батыр мин!

Дию пәрие. Кыяташ батыр? Хо-хо-хо! Күптән көтәм мин сине. Үзең килдеңмени? Хәзер чыгам яныңа.

Сарайдан ажгырып, авызыннан утлар чәчеп, өч башлы Дию пәрие килеп чыга.

Кыяташ. Сугышка әзерлән, ата шайтан!

Дию пәрие. Хо-хо-хо! Кыяташ батыр — бер кабуга бетми, ике кабуга җитми... Мин соң сине өреп очырам бит!

Кыяташ кылычын югары күтәреп, Дию пәриенә каршы ташлана. Дию пәрие бик каты өрергә тотына. Кыяташ чигенә. Дию өрүдән туктаган арада ул яңадан алга ыргыла да Диюнең бер башын чабып төшерә.

Кыяташ. Күрдеңме инде минем көчемне?!

Дию пәрие (*ярсып*). А-а-а! У-у-у!

Дию пәрие бик каты өрә. Еракта шытырдап агачлар сына, тау-ташлар ишелеп төшә. Кыяташ кире чигенә, качып тора. Дию пәрие өрүдән туктаган арада тагын алга ыргыла да Диюнең икенче башын чабып өзә. Дию пәрие иләмсез тавыш белән үкереп җибәрә, тагын өрә, ләкин аның хәле инде беткәннән-бетә бара. Кыяташ соңгы мәртәбә чабып бара да, өченче башны да кыеп төшерә. Көн яктыра, тирә-як тынып кала. Шул чакны аяк астында энҗе ташы ялтырап китә.

Кыяташ (*исе китеп*). Югалган энҗе ташы түгелме соң?! Шул үзе! Минем бәхет ташым! (*Иелә, энҗене кулына ала. Шул ук мәлдә каршысында бер кыз пәйда була. Бу — Айсылу.*)

Айсылу. Менә кем коткарган икән безне! Яшә, Кыяташ батыр!

Кыяташ. Бәхетем! Шатлыгым! Син тагын да гүзәл кызга әйләнгәнсең. Ә мин синең югалган энҗеңне таптым. (*Энҗене Айсылуга күрсәтә.*)

Айсылу. Син аны кылычың сабына беркетеп куй. Синең, минем, барлык кешеләрнең бәхете ышанычлы кулда саклансын.

Кыяташ. Синеңчә булыр. Ханга мин Энҗеле үрдәк алып кайтырга сүз биргән идем. Нишләрмен инде болай булгач? Ул минем башны кистерәчәк!

Айсылу (*көлеп*). Юкка кайгырасың, Кыяташ батыр. Алып кайт мине Хан янына. Нишләргә кирәген анда мин үзем белермен.

Кешнәп Акбүзат килеп җитә. Икесе дә Акбүзатка атланалар, китәләр.

Кыяташ. Киттек туган илгә.

## УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Хан сарае. Ишекләр, тәрәзәләр ачык. Тынлык. Тәхеттә ялгыз Хан утыра.

Хан. Ябыгыз ишекләрне, ябыгыз тәрәзәләрне! (*Тыңлап тора. Тып-тын.*) Әллә беркем дә калмаганмы бу сарайда? (*Кычкыра.*) Кемнәр бар анда? Ишетәсезме, ябыгыз ишекләрне, тәрәзәләрне!

Шул ук тынлык. Ачык ишектән кулына төенчек тоткан Ана килеп керә.

Ана. Исәнме, олуг Хан!

Хан (*тәхеткә утыра*). Бик исән әле, кем, хатын. Тиз генә ишек-тәрәзәләрне ябып куй әле — җил-давыл чыкмагае.

Ана. Керсен саф һава. Курыкма, олуг Хан, безнең илдә инде беркайчан да яман җил-давыллар булмас. Җил-давыл, кан-яшь, кайгы-хәсрәт оясын минем Кыяташ улым пыр туздырды. Ишетәсеңме, әнәерактан күңелле гөрелдек килә? Безнең илгә мәңге бәхет, шатлык кайта, олуг Хан!

Хан. Сүзләрең изге. Авызыңа бал да май, кем, хатын. Белмисеңме, минем Айсылуым да исән түгел микән? (*Тәхеттән тора, тәрәзә янына килә.*)

Тышта күңелле шау-шу. Шат кешеләр төркеме Хан сараена якынлаша. Тәрәзә турысыннан Акбүзатка атланган Кыяташ белән Айсылу узып китә. Бераздан алар җитәкләшеп Хан сараена килеп керәләр.

Айсылу (*Хан янына йөгереп килә*). Әти! Әтием!

Хан. Кызым... Айсылу, син түгелме соң?! (*Кызны кочаклый, елый.*)

Айсылу. Бу мин, әтием!

Хан. Кызым! Айсылу! Инде үлсәм дә үкенмим.

Айсылу. Мине менә Кыяташ коткарды. Ул шулай ук тоткындагы меңләгән кешеләрне... Дию пәриенең җир асты базларында үлем көтеп яткан безнең туганнарыбызны иреккә чыгарды.

Халык (*тышта*). Кыяташ безне иреккә чыгарды!

Хан (*Кыяташны танып*). Ә, бу син икәнсең, батыр углан! Кил бире. (*Кыяташ Хан янына килә, баш ия. Хан аны күкрәгенә коча.*) Рәхмәт сиңа, Кыяташ батыр.

Кыяташ. Ханым, мин синең боерыгыңны үти алмадым — кичер мине.

Айсылу. Дию пәрие мине сихерләп Энҗеле үрдәккә әйләндерде. Кыяташ эзләгән Энҗеле үрдәк мин ул, әтием.

Хан (*Кыяташка*). Шулай булгач, нишләп син минем боерыгымны үтәмәгән буласың ди?! Тиңсез батыр-

лыгыңны истә тотып, мин сиңа кызым Айсылуны бирәм, үзеңне тәхеткә утыртам. (*Тәрәзә ягына борылып.*) Халык, ишетәсезме, моннан соң илдә Хан булып Кыяташ батыр калачак!

Халык (*тышта*). Яшәсен Кыяташ!

Кыяташ. Рәхмәт сиңа, Хан! (*Әнисенә.*) Рәхмәт, мине саклап үстергән батыр анам! (*Халыкка карап.*) Кешеләр, мине тыңлагыз! Минем кулда ата-бабаларның изге кылычы. Аның сабына Бәхет энҗесе уеп утыртылган. Моннан соң бер генә дошман да безгә җил-давыл җибәрергә, безнең бәхетебезне тартып алырга батырчылык итә алмас. Моннан соң безнең күгебез гел аяз булыр!

Кыяташ белән Айсылу кулга-кул тотынышалар.
Барысы да җырлыйлар.

Таралды кара болытлар,
Нур балкый күгебездә.
Яшәсен ирек һәм бәхет
Сөекле илебездә!

Пәрдә.

# САТИРА-ЮМОР

## ТӘНКЫЙТЬЧЕ

Мин бик тәүфыйклы кеше: эчмим, тартмыйм, хатын-кыз белән чуалмыйм. Аннан да бигрәк, мин беркайчан да беркем белән дә ачуланышмыйм. Аннары мин бик сак кеше. Әйе, сак кеше. Югыйсә, безнең агай-эне бик алама бит ул. Берәр ничек кыек басканыңны сагалап кына тора. Күрдеме, шундук тотып ашарга әзер. Шуңа күрә, һәрвакыт алдыңны-артыңны карап йөргәнең яхшы. Берничек тә бәйләнерлек булмасын. Кыскасы, син миңа тимә, мин сиңа тимим. Вәссәлам! Җаның тыныч, ярмаң — аш...

Тагын шул, миндә әле сизгерлек дигән нәрсә дә бар. Мин кешенең аяк атлавыннан ук беләм — дусмы ул, дошманмы сиңа... Кирәк икән, җиде кат җир астында җылан күшәгәнен ишетәм мин! Җыеп кына әйткәндә, менә шундый әйбәт кеше инде мин.

Ләкин, шулай була торып та, кайбер агай-эне мине никтер яратып җиткерми. Чынлап, яратмыйлар. Күзгә карап та әйтәләр, карамыйча да әйтәләр: мыштым, диләр, ялагай, диләр, начальство алдында тәлинкә тота, диләр.

Алар, билгеле, көнләшкәнгә күрә шулай диләр. Чөнки бары мин генә диярлек мастерлардан Фәлән Фәләнеч белән яхшы мөнәсәбәттә. Шулай булмыйча, начальство белән телгә-тешкә керергә башыма тай типкәнме әллә минем?! Юк, анысы инде булмас. Башкалар теләсә нишләсен, әмма ләкин мин үзем андый юлга басмам! Ә бездә башсыз халык җитәрлек — кемнең кем булуына карамыйлар, селкеп салырга гына торалар.

Шулай бер җыелышта безнең агай-эне Фәлән Фәләнечкә каршы ябырылды. Бирделәр кирәген! Ярый әле мин яклап чыктым үзен, югыйсә, эшләре шәптән түгел иде безнең цех начальнигының.

Җыелыш беткәч, без ничектер моның белән бергә туры килдек. Кайсыдыр безне күреп калган. Икенче көнне килсәм... мине... шундый тәртипле кешене гәҗиткә төшергәннәр! Озын куллы итеп, Фәлән Фәләнеч алдында бишкә бөгелгән итеп төшергәннәр. Йөзем шундый ялагай, муеным нечкә, кулымда тәлинкә. Тәлинкәдә Фәлән

Фәләнечнең эшләпәсе. Фәлән Фәләнеч юан корсаклы, борыны югары чөелгән. Миңа карамый да.

Кеше-ни ишетә күрмәсен... үзара гына әйткәндә, Фәлән Фәләнечне дөрес эшләгәннәр. Ул чыннан да шундый зур корсаклы, тупас, эре. Бары мине генә мыскыллаганнар. Беркайчан да минем Фәлән Фәләнечнең эшләпәсен тәлинкәгә салып та, салмыйча да тотканым юк. Шулай ук минем исемнән әйтелгән: «Эшләпәгезнең тузанын кактым, кияргә була, Фәлән Фәләнеч!» — дигән сүзләр дә ялган.

Ачуымнан нишләргә дә белмәдем инде үзем дә! Шулай да түздем. «Ярар, күрсәтермен әле мин сезгә күрмәгәнегезне!» — дип уйладым күңелемнән.

Хәзер мин үч алырга җай чыкканын гына көтеп йөри башладым. Озак көтәргә дә туры килмәде — берзаман җае да чыкты моның.

Ләкин шул чагында мин чирләп киттем, өч көн бүлитендә яттым.

Дүртенче көнне эшкә бардым. Барсам, тагын җыелыш җыйдылар. Докладчы сөйләп бетерер-бетермәс борын, мин беренче булып сүз сорадым да, беренче булып трибунага менеп киттем. Менеп бастым да трибуна янына, тамак кырып, ачулы гына башлап киттем:

— Иптәшләр, ни өчен безнең цех артта бара? — дидем. — Чөнки, иптәшләр, безнең җитәкчеләр начар, ягъни мәсәлән, цех начальнигы Фәлән Фәләнеч... Сез беләсез, иптәшләр, Фәлән Фәләнеч — дорфа кеше, эшчеләр белән рәтләп сөйләшми, кеше сүзенә колак салмый... өстәл сугып кына кычкыра...

Шундыйрак сүзләр белән теттем генә Фәлән Фәләнечне! Кинәнгәнче тәнкыйтьләдем! Бөтен зал мине тын да алмый тыңлап торды. Исләре китеп, авызларын ачып тыңлыйлар. Күрәсең, минем кыюлыкка хәйран калганнар. Уен эшмени, миңа кадәр әле иң усал телләләрнең дә Фәлән Фәләнечкә шулкадәр каты бәрелгәннәре юк иде бугай.

Халыкны әйтәм, тыңлап-тыңлап утырдылар да, кинәт исләренә килделәр, шаркылдап көләргә, шаулашырга тотындылар. Көләләр бөгелеп-бөгелеп! Көләләр эчләрен тотып!

Мин инде аларның көлүенә игътибар итеп тормадым. Әйтәсе сүземне әйттем дә залга төштем, күкрәкне киереп, үземнең урынга таба атладым. Ә көлү тавышы һаман туктамый. Колак төбендә төрле сүзләр ишетелеп китә.

— Менә сиңа Мыштымбай! — диләр.

— Соңгарак калгансың шул: кичәгенәк Фәлән Фәләнечне эшеннән алдылар! — диләр.

Һы, әйттеләр яңалык! Аның алыначагы турында мин инде бер атна элек белгән идем.

*1964*

# ТАМАК ШЕШТЕ

Беркөнне иртән уянып китсәм, тамак шешкән. Әллә нишләп тавыш үзгәргән, баш та авырта, хәл дә юк. Үзе тагын төчкертә дә йөткертә. Менә сиңа имгәк! Авырыйсым килеп кенә тора идем менә монда.

— Болай булгач, эшкә бармассың инде,— диде хатын, минем мөшкел хәлне күреп.

— Нинди бармаган ул!— дидем мин, борын суын тарткалап.— Минсез анда берни бармаячак.

— Сөйләнмә, хәзер үк поликлиникага кит,— диде хатын.— Күрмисеңмени, әнә ич грипп булган... ангина... Синең өчен монда бөтен өй эче белән чирләп ятасы юк.

Хатын шулай дигәч, мин килешергә мәҗбүр булдым. Чыннан да, грипп-фәлән булса, харап эшләр!

Ашадым-эчтем дә, җылырак киендем дә, ух-вах килеп, поликлиникага киттем. Яшь кенә, чибәр генә бер туташ чишендереп минем үпкәне, йөрәкне тыңлады, аннары «а» дип кычкыртты, каккалады-суккалады: «Сезгә катарр булган»,— диде. Шуннан соң бу миңа алай итмәскә, болай итмәскә кушты, дару кәгазе язып бирде.

Мин, туташка мең-мең рәхмәтләр әйтеп, кабинеттан чыгып киттем. Юл уңаенда аптекага кереп дару алдым. Алдым да, тәмам тынычланып, өйгә таба атладым.

Ләкин шул чакны мин уйга калдым: бу «катарр» белән өйдә күпме ятарга туры килер?— дидем. Бер көндә терелтә торган берәр дару юк микәнни? Шулай уйлана торгач, дустым Галәвине исемә төшердем. Туктале, кереп чыгыйм булмаса, мәйтәм. Борылдым да, Галәвиләргә китеп бардым.

— Нишләп тамагың карлыкты?— диде Галәви, исәнлек-саулык сорашкач.

— Менә шуның артыннан йөрим әле,— дидем мин, йөткеренгәләп.— Салкын тигән.

— Салкын тигән? Грипп түгелме?— диде Галәви, куркып, артына чигенеп.

— Юк, юк!— дидем.— Грипп түгел, нииндидер катарр, ди. Әле генә врачта булдым.

— Врачта булдың?!— диде Галәви, исе китеп.— Салкын тигән өчен врачка бардыңмы? Үземә генә килгән булсаң соң! Мин сиңа кырык төрле дәва тапкан булыр ыем.

— Әле дә соң түгел,— дидем мин.— Менә шуңа кердем дә инде сиңа. Аптекадан дару алганыем да, синең белән киңәшим дидем: эчәргәме, юкмы... Кайчан терелә сең әле аның белән... Никтер ышанмыйм мин ул даруларга.

Шулай сөйләнгәләп мин даруны Галәвигә күрсәтмәкче булдым, ләкин Галәви кулын гына селтәде.

— Ташла, эчмә!— диде.— Акыллы кеше әптик даруын эчәмени! Бер яктан дару булса, икенче яктан агу бит ул. Йөрәккә, бавырга төшә, нервыны ашый. Мин дә заманында күп йөрдем врачларга. Берсе бер төрле сөйли, икенчесе икенче төрле сөйли. Берсе бер дару язып бирә, икенчесе икенче дару, Халтурщиклар! Шарлатаннар! Мин хәзер аларга аяк та басмыйм. Гайрәтем чикте. Медицина, гомумән, бернигә тормый.

— Шулай шул,— дидем мин, килешеп. Мин шулай дигәч, Галәви тагын алып-биреп медикларны сүгәргә тотынды.

— Иң ышанычлысы — халык медицинасы!— диде ул, кайнарланып.— Үлән, үлән тамыры, җимеш, чәчәк... Менә ул кайда чын медицина!

— Шулай шул,— дидем мин тагын да.— Өйрәт әле миңа да берәр нәрсә... тиз генә файдасы тия торганын... Үләм бит, малай... баш авырта, хәл юк.

— Ничек авырта? Кай җирең авырта?— диде Галәви.

Мин аңа сөйләп бирдем.

— Беләсеңме, нәрсә,— диде Галәви, бераз уйлангандай итеп торгач,— сиңа, иң яхшысы, яңа суырткан бал кирәк. Яңа суырткан бал җитмеш төрле авыруга дәва!

— Кыш уртасында каян тапмак кирәк яңа суырткан балны?!— дидем мин, гаҗәпләнеп.

— Яңасы булмаса, утырганы да ярый,— диде Галәви.— Файдасы әзрәк булыр, шулай да ярый. Ярты кило балга бер литр кайнар су саласың да ныгытып болгатасың...

— Ярты кило күбрәк булмасмы?— дидем мин.

— Булмас,— диде Галәви һәм, бу мәсьәләгә артык тукталып тормыйча, ялгап алып та китте: — Бал булмаса, алоэ яфрагын кайнатып эчәргә була. Анысын болай итәсең...

— Минем дә ишеткәнем бар ул алоэ турында,— дидем мин, аны бүлдереп.— Ләкин каян алырга соң шуны?

— Базарда тамыр-томыр сатучы карчыкларда булыр. Алар сиңа алоэны түгел, әҗәл даруын табып бирерләр!— диде Галәви.

— Мәшәкатьлерәк икән шул,— дидем мин.— Тагын юкмы?

— Анысы да булмаса, чи балан суы да эчәргә була,— диде Галәви.

— Юк, юк, булмый!— дидем мин, кулымны селтәп.— Хатын көн дә чыга базарга балан эзләп, һич туры китерә алмый.

— Алайса, андыз тамыры кайнатып эчәргә кирәк,— диде Галәви.

— Анысы тагын нәрсә?

— Шундый үлән бар,— диде Галәви.— Бик сирәк очрый. Женьшень кебегрәк. Безнең авылда элек бер карт булган, бөтен авыруларны шул андыз тамыры белән генә имләгән. Тамак шешкәч тә...

— Туктале, мин, булмаса, язып алыйм,— дидем мин.

Кесәмнән куен дәфтәрен чыгардым да өстәл янына килеп утырдым. Галәви башта сөйләгәннәрен яңадан кабатлап чыкты. Мин язып бардым. Ул көнне ул миңа тамак шешкәндә кулланыла торган барлык дәвалар турында, барлык им-томнар турында сөйләде. Нәрсә генә тәкъдим итмәде ул миңа! Мәтрүшкә, әчәлче, бөтнек ише үләннәр кайнатып эчү дисеңме, шешкән җиргә сарана күкәе, аксыргак тамыры тоту дисеңме, анадан тума килеш абага яфрагы ваннасында утыру дисеңме, миләш, аю камыры, чи бәрәңге кебек нәрсәләр ашау дисеңме...— берсе дә калмады! Аның әйтүенә караганда, аларның барысы да иң ышанычлы, иң тәэсирле дәва булырга тиеш иде.

Сөйли-сөйли ул арып бетте, хәлдән тайды. Ләкин тавышы әкренәя башладымы, чиләктән чүмеч белән су алып эчте дә дәртләнеп яңадан сөйләргә керešте.

Ниһаять, ул туктап калды, күзенә төшкән чәчләрен сыпырып ташлады да, көчкә тын алып:

— Менә шул...— диде.— Хәзергә бетте... бүтән белмим. Кайт та мин әйткәнчә...

— Ярый, рәхмәт,— дидем мин, урынымнан кузгалып.

Саубуллаштым да, Галәви өйрәткән даруларның кайсын куллансам яхшырак булыр икән дип, уйлана-уйлана кайтып киттем.

Урам буйлап әкрен генә барадыр идем, берзаман кемнеңдер кычкырганын ишетеп, артыма борылып карадым. Ул да булса, ашыгып-кабаланып Галәви килә! Тагы берәр яңа дару исенә төште микәнни? дип уйладым мин. Туктадым да көтә башладым.

— Карале... туктале!— диде Галәви, килеп җиткәч.— Каяле, күрсәт әле теге даруыңны?

Мин аңа аптекадан алган баягы даруны бирдем. Галәви даруның исемен укыды да «ә!» дип куйды.

— Ни, малай...— диде бераздан, тотлыгып.— Нишләптер минем дә тамак авырта башлады. Әптиккә кереп чыкмый булмас, ахрысы.

*1964*

# БАЛА ХӘСРӘТЕ

Кибет яныннан узып бара идем, канау аша чыкканда аяк таеп китте. Аяк тайгач, үзегез беләсез, егылырга туры килә. Нишлисең, мин дә егылдым. Егылып кына да калмадым — пычрак канауга йөзтүбән капландым! Минем капланганны кешеләр дә күреп тордылар, күреп тордылар да көләргә дә керештеләр. Пычранган өс киемемне, пычранган битемне-борынымны кая салып ташларга белмичә мин аксаклап өйгә кайтып кердем.

Мин кайтып кергәндә, әтидән башка өйдә беркем юк иде. Күреп алды да бу минем буяулы кыяфәтемне, бот чабып мине сүгәргә тотынды.

— И, нәҗес, шул хәлгә төшкәнче эчмәсәң!— диде.

— Мин, әти, таеп егылдым,— дидем мин, ыңгырашып.— Күрәсең ич — өстән явып тора.

— Таеп егылгансыңдыр!— диде әти, кычкырып.— Каеш алып менә моннан сыртыңны сыдырасы бар, малай актыгы! Кара, нинди уңган җегет — эчәргә өйрәнә башлаган!

— Җыгылырга да өйрәнә башладым инде, әти,— дидем мин, ипле генә шыңшып.

— Акча туздыручы! Игелексез!— дип кычкырды әти, кызганнан-кыза барып.

— Ярар инде, әти,— дидем мин, бу тавышка киртә куймакчы булып.

Ләкин кая ул киртә кую! Тузыныпмы-тузына минем әти-картлач. Ярар, тузынса, тузынып тик торсын! Пычрак өс киемнәрен шунда ишек төбенә салып ташладым да, аксаклый-туксаклый караватка менеп яттым.

Караватка ятып бер көрсенергә дә өлгермәдем — бик тә каты итеп тышта капка ачып ябылганы ишетелде. Сизеп ятам: әни кайта!

Килеп керде дә бу, исәнлек-саулык та сорашып тормастан, урындыкка утырып җыларга да керешеп китте.

— Сиңа тагын ни булды?— диде әти.

—Ниләр эшлим, ниләр кылыйм, Ходаем!— диде әни, телгә килеп.— Башкайларым хур булды... бөтен авылга, бөтен җир шарына башкайларым хур булды! Адәм рисвае итте!

— Нәрсә булды — сөйлә җүнләп!— диде әти.

— Нәрсә булсын — теге бала соң! Теге имансыз... җан кыйгыч! Эчеп-исереп йөргән... бөтен урам бетереп... бөтен мәхшәр алдында... Хәзер әнә канауда аунап ята, ди. Сәлимәнең кече кызы Сания әйтте. Син дә ятасың җанымны

үртәп. Бар тизрәк, бар, алып кайт! Күпер очы Махалар янында, ди.

Әни шулай сөйләнгәндә мин, үзалдыма көлемсерәп, тын гына караватта тыңлап яттым. Әти дә башта эндәшмәде, аннары минем якка төртеп күрсәтте дә:

— Эзләп йөрисе юк, әнә ята малаең!— диде.

Әни кинәт җылавыннан туктап калды, минем якка әйләнеп карады да:

— Кайчан кайттың, явыз?— диде.— Кайда эчтең, кем белән эчтең?

Мин әнигә җавап бирергә дә өлгермәдем — шул чакны икенче мәртәбә капка ачылып ябылган тавыш ишетелде. Тәрәзәдән үрелеп караган идем — җилләнеп Олы апа кереп килә.

Килеп керде дә бу тыны бетеп, бик тә шомлы, дәһшәтле бер пышылдау белән:

— Ишеттегезме әле яңа хәбәр?— диде.

— Нәрсә булган тагын?— диде әти.

— Безнең Зиннур... эчеп-исереп... кеше белән сугышып йөргән!— диде Олы апа.— Үзен тукмап канауга ташлап киткәннәр. Зәки бичәсе Назима әйтте. Карар җире калмаган, ди... Әти, бар тизрәк, бар, алып кайт үлгәнче!

Мин тагын да эндәшми-тынмый гына яттым. Шулай да ахырда түзмәдем — башны калкыткандай иттем дә, чаршау кырыеннан үрелеп:

— Мин монда, Олы апа! Мин әле үлмәдем!— дидем.

Минем тавышны ишетеп. Олы апа да кисәк кенә тынып калды.

— Әстәгъфирулла!— диде аннары.— Зиннур өйдә ләбаса!

— Өйдә булмый кайда булсын! Исереп кайтып егылды,— диде әти.

— И, энекәем, энекәем!— диде Олы апа.— Заттанәселдә юкны...

Мин әрепләшеп тормадым. Минем тәмам кәеф кырылды. Юрганыма ныграк төрендем дә шулай ятам тыптын гына. Ул да булмады, җылый-җылый Кече апамның килеп кергәне ишетелде.

Килеп керде дә бу күзенә ак-кара күренмичә, йөрәгенең иң түрдәге ноктасыннан чыккан бер инәлү белән:

— Әти! Әни! Апа!— дип кычкырып җибәрде.— Харап булдык!.. Безнең Зиннур... Безнең Зиннуркаебыз... эчеп-исереп... кешеләр белән сугышып... Яңавыл юлында пычак белән кадап киткәннәр! Ушиятаулар күреп кайтканнар? Канга батып... юл буенда канауда аунап ята, ди...

Өйдәгеләр аның сайравын моңаеп кына тыңлап тордылар да, бер-берсенә карашып алдылар.

— Нәрсә катып торасыз монда?!— диде Кече апа, кызган таба кебек яңадан чыжларга тотынып.— Әйдәгез тизрәк авыл советына! Милициягә әйтергә кирәк! Бу ни эш бу, ә?!

— Белмәссең инде, нишләтергәдер инде ул баланы!— диде әни, уфтанып.

— Нишләтергә?! Салып сугарга!— диде әти.— Икенче сабак булыр. Җыгылып йөрмәс теләсә кайда.

Мин тагын түзмәдем — юрган астыннан башымны чыгардым да, елмаерга тырышып:

— Кече апа, исәнме!— дидем. Кече апа минем тавышны ишетеп алды, ишетеп алды да кызулап минем янга килеп тә җитте. Бүтәннәр дә аның артыннан кузгалдылар, төрле яктан мине уратып алдылар да, чиратлашып миңа:

«Аракы эчү һәм аның зарары» дигән темага лекция укырга керештеләр. Мин, колакларымны үрә торгызып, аларның һәрбер сүзен йотлыгып тыңлап яттым.

Әмма шулай да миңа бу күңелле лекцияне тыңлап бетерергә насыйп булмады — тышта тагын да кемнеңдер капка ачып япканы ишетелде. Кырын күзем белән генә мин тәрәзәгә карап алдым. Ни күрим — балалар ияртеп Шәмсевафа кайтып килә!

Әти дә, әни дә, апалар да моны күреп алдылар, лекция укуларыннан туктадылар да, аяк очларына гына басып, теге якка чыгып шылдылар. Ә мин, күзләремне шытырдатып йомган хәлдә, кырыкка бөгәрләнеп, бар көчемә ястыкка сыендым.

Аһ Алла, бар икән күрәсекәйләрем! Күп тә эчмәдем бит инде югыйсә... кызылын гына... йөз грамм гына... Ни өчен дигәндә, миңа бит бүген, хатынкаем... балакайларым... кырык яшь тулды!

*1965*

# БУХГАЛТЕР МӘХӘББӘТЕ

Шалт та шолт чут төймәләре тартып утыра идем, бухгалтериягә шыгырдап торган унлык кебек яшь кенә, чибәр генә бер кыз килеп керде. Аның килеп керүе булды, үзем дә сизмәстән, мин кинәт чут салудан туктап калдым. Башымны калкыттым да, карап торам моңа исем китеп!

Шуннан бу йомшак кына атлап безнең Баш бухгалтер янына килде, аңа ниндидер кәгазь сузды, Фәлән Фәләнеч кәгазьгә кул куйган арада, як-ягына каранган-дай итте. Шул чакны бу минем күз карашы белән очрашты да, кызарып китте һәм кечкенә нуль төсле түгәрәк күзләрен тиз генә түбән иде.

Менә шунда гашыйк булдым да инде мин аңа.

Ул чыгып киткәч, мин шактый исемә-акылыма киләлми утырдым. Исемә-акылыма килгәч, тәмәке тартырга дигән булып, коридорга чыгып киттем. Тәмәке тарту кайгысы юк — коридорда моның артыннан карап калмакчы булам, янәсе. Кая ул! Күптән инде җилләр искән!

Шуннан соң мин яңадан бухгалтерия бүлмәсенә кердем дә, үз эшемә тотындым. Ләкин һич кенә дә ныклап торып бирелеп китә алмыйм — һаман теге күз алдында басып тора. Әйтсәм әйтим, ул көнне минем эшем эш булмады. Сәгать дүрткә чаклы мин көчкә түзеп утырдым. Баш авырта дидем дә, Фәлән Фәләнечтән рөхсәт сорап, бер сәгатькә алдан кайтып киттем.

Әйе, үз гомеремдә беренче мәртәбә мин эш сәгате беткәнче түзеп утыра алмадым, һәм үз гомеремдә беренче мәртәбә мин ул көнне исәп-хисапта хата җибәргәнмен! Шул турыда белгәч, мин бер атна буена кайгымнан нишләргә белми йөрдем. Зиһенемне буташтырып киткән пәри кызы турында исә атна буе исемә дә кертеп чыгармадым.

Ләкин бер атнадан соң мин яңадан уйлана башладым. Мин, билгеле, уйланып кына да калмадым. Мин хәзер тегендә-монда йөргәли башладым, тегенди-мондый сүзләргә колак сала башладым, һәм шулай йөри торгач, көтмәгәндә, мин моның эзенә дә төштем! Исемен белдем, кайда эшләгәнлеген, кайда торганлыгын белдем. Кыскасы, энәсеннән җебенә кадәр тикшердем.

Шулаен шулай да, ләкин ничек танышырга аның белән?

Хәзер инде мин көн-төн шул турыда баш вата башладым. Вата торгач, шулай да таптым бит җаен. «Туктале, хат язарга кирәк. Шуннан да яхшысы булмас»,— дип уйладым мин. Бер кичне утырдым да, күңелдә ташыган барлык кайнар хисләремне ак кәгазьгә бушатырга тотындым. Бушатып бетердем дә, дүрт битлек хатны конвертка салдым, адресын яздым һәм, кая басканымны да белмәстән, урамга чыгып киттем.

Мин туп-туры почта ящигы янына юнәлдем. Чаттагы зәңгәр ящик янына килеп кенә җиткән идем, каршым-

да мәгъшукамны күреп, каттым да калдым! Нишләргә хәзер — кире борылыргамы, әллә соң күрмәмешкә салынып, янынnan үтеп китәргәме? Юк, булмый. Алай да булмый, болай да булмый.

Туктаганмын да карап тик торам моңа. Аяк калтырый, куллар калтырый, колак очлары уттай яна. Ул да мине таныды. Туктап калды. Үзе кызарган, йөзеннән нурлар балкый.

Шулай карап тордым-тордым да, ни булса да булыр дип:

— Исәнмесез... Әлфия,— дидем.

— Исәнмесез,— диде бу да.

— Мин сезне беләм,— дидем мин.

Шулай дидем дә, аның кайсы урамда, ничәнче йортта, ничәнче квартирада торуы турында, кайда эшләве, аена күпме эш хакы алуы турында такылдарга тотындым. Ул башта аптырап калды, аннары кисәк кенә көлеп җибәрде.

— Каян беләсез сез аларны?— диде бу.

— Ы-мы...— дидем мин.— Белмәскә, ни... мин бит бухгалтер!

— Беләм. Мин дә сезне беләм!— диде бу.

— Шулаймыни?!— дигән булдым мин.

— Шулай шул,— диде бу.

Аннары миңа бер елмаеп карады да:

— Кая барасыз болай ашыгып?— диде.

— Юк, ашыкмыйм,— дидем мин.— Менә... ни... хат салырга килдем.

— Хат? Кемгә?— диде бу.

Мин кинәт каушап калдым, минем кинәт котым алынды!

— Сезгә...— дидем шулай да, бер агарып, бер кызарып.

— Миңа?!

— Әйе, сезгә...

— Бирегез, алайса, үземә генә,— диде бу.

Хәзер инде кире чигенер юл калмады. Тиз генә кулымны кесәгә тыктым да, хатны алдым да... Әлфиягә сузмакчы булдым.

Ләкин шул чакны мин бер нәрсә күреп калдым, һәм миндә кинәт бухгалтерлык тойгылары баш күтәрде. Мин хатны авызыма якынрак китердем. Әлфия минем нишләгәнне тын да алмый карап торды. Шуннан соң мин хатны яңадан аңа суздым.

— Менә... мәгез...— дидем.

Ләкин Әлфиянең күтәрелгән кулы кире төште, йөзе

ап-ак булды, нуль төсле күзләре нокта гына булып калды. Борылды да, итәгенә ут капкандай, китте дә барды.

Туктале, нәрсә булды бу? Ә? Нәрсә булды? Тукта, тукта, Әлфия! Җаным, бәгърем...

Юк, туктамады... китте, югалды. Ә мин торып калдым каккан баганадай. Бер кулымда хат, икенче кулымда... әле генә куптарып алынган дүрт тиенлек марка.

*1965*

## ШИФАЛЫ ДАРУ

Доктор янына бер әби килеп керде. Исәнлек-саулык сорашты да, буш урындыкка килеп утырды. Шуннан соң ул кесәсеннән пөхтәләп төрелгән бер кәгазь кисәге чыгарды.

— Син язып биргән даруның шифасы тиде, балакаем... рәхмәт төшсен,— диде әби.— Менә тагын килдем әле. Даруыңны яңа кәгазьгә күчереп кенә бирмәссең микән?

Доктор әбинең кәгазен алды да, әйләндергәләп карады. Бу чыннан да аның язуы иде.

— Шифасы тиде дисең, алайса?— диде ул.— Ничек эчтең соң? Мин әйткәнчә, көненә өч мәртәбә, аш алдыннан берәр аш кашыгы белән эчтеңме?

— Әйе, әйе, аш кашыгы белән эчтем,— диде әби.

— Рецепт кәгазең бик таушалып беткән икән. Яңгырга эләктеңме әллә?— диде доктор.

— Шуның өчен килдем дә инде, балакаем,— диде әби.— Язуы бетте шул. Мин аны тәлинкәдә җебетеп, шуның суын эчкәнием.

*1965*

## ЯШЬ ЧАКЛАРДА

### I

Беркөнне кич карчык белән дөрләп янган мич каршысына утырдык та, тынып калдык.

— Карчык, әйдәле, яшь чакларны искә төшерик,— дидем мин моңа.

— Әйдә, төшерик,— диде карчык.

— Әйдәле, сөйләде, алайса, беренче мәхәббәтең турында,— дидем мин.

— Була ул,— диде карчык һәм, чак-чак кына каушагандай итеп, ошбу хикәясен башлады.

## II

— Беркөнне әти мине күрше авылга утырмага илтеп куйды,— диде карчык.— Бертуган апаларга. Кыш көне. Шулай берзаман тәрәзә төбендә утырадырыем, капкадан алыптай карачкы килеп керде. Апа тиз генә утны каплады, мин тәрәзәгә капландым. Тәрәзәгә боз каткан. Ләкин мин алдан ук тын белән эретеп, пыялага «бәке» тишеп куйганыем. Ярар, килеп керде дә бу, басып тора ишегалдында нишләргә белмичә. Үзе озын, үзе таза... имән кебек, нарат кебек төз! Әйтәм бит менә, күрсәң, һуштан язарлык! Мин инде белеп торам: мине күрергә килгән бу. Ни өчен дисәң, бөтен авылда кунак кызы бары мин генә. Җитмәсә, бездә аулак өй. Апа да мин, мин дә апа. Кодагый әби дә, кода бабай да, җизни дә кунакта. Шуннан, бер урында басып торды-торды да бу, ипләп кенә, песи кебек кенә атлап, мин утырган тәрәзәгә килә башлады.

— Апа, сүндер утны!— дидем мин. Үзем шундук артка тайпылдым. Апа тиз генә утны сүндерде. Тышта ай яктысы. Җирдә энә табарлык. Ярар, тәрәзәгә килде дә бу, туң тәрәзә аша өй эчен күзәтә башлады. Кап-кара шәүлә булып тора, Ходаем, бөтен тәрәзәне каплап! Төшеңдә керсә, котың алыныр. Минем алай котым алынмады. Якынрак килдем дә тәрәзәгә, карыйм «бәкедән». Әле апа карый, әле мин карыйм. Без аны күрәбез, ул безне күрми. Шулай алмаш-тилмәш карыйбыз да, көләбез әкрен генә. Ә үземнең йөрәк дөп-дөп тибә. Бит очлары яна, колаклар яна! Барысы да бүгенгедәй. Әле булса күз алдымда тора: башына зур күн бүрек кигән, билен буган, күзләре серле, кулында күсәк...

— Карап торды-торды да бу, ипләп кенә кире китте,— дип дәвам итте карчык, авыр көрсенеп.— Апа, ник керми ул?— дидем апага.— Чакыр, керсен,— ди апа, көлә.

— Куркам, апа, әллә ни уйлавы бар,— мин әйтәм. Көтик, бәлки, үзе керер,— ди апа. Шуннан мин көтә башладым. Юк, керми генә бит! Туктаган да, як-ягына карана, үзе колак салып тыңлагандай итә. Шулай да бер мәлне баскычка таба атлап куйды бу. Шатлыгымнан чак-чак кына кычкырып җибәрмәдем. Юк, каһәр генә төшкән икән! Ике-өч адым атлады да, кыюсыз гына кире

борылды, ашыга-ашыга капкага таба юнәлде. Кинәт мин кычкырып җибәрдем: «Апа, китә!»— дидем. Апа тиз генә өстенә сырмасын каплады да, чоланга чыгып китте, шалтыратып тышкы ишекне ачты. Аның шулай ишекне ачуы булды, әлеге алыптай җегет капка баганасы артына качкан булды. Апа иплән кенә тамак кырды, шыпырт кына: «Кем бар анда?»— диде. Карачкы җавап бирмәде. Ул җавап бирмәгәч, апа да кире өйгә керде. Әйдә, йокларга ятыйк! Бетмәс андый төнге кунаклар, диде. Үзе никтер ачулы. Мин инде карышып тормадым. Кермәгәч кермәде. Күрәсең, бик яраткандыр инде ул мине. Яратсаң кыюсыз буласың диләр ич.

— Беттеме?— дидем мин.

— Юк, бетмәде әле,— диде карчык.— Икенче көнне дә килде бу, өченче көнне дә килде. Шулай башта урамда, өй тирәсендә йөрде, аннары ишегалдына керде, тәрәзәгә карап торды да, баскычка таба ике-өч адым атлап карады...

— Шулай да кердеме соң?!— дидем мин.

— Юк, кермәде... икенче көнне дә, өченче көнне дә кермәде,— диде карчык, янә дә авыр көрсенеп.— Менә шул булгандыр инде беренче мәхәббәт дигән нәрсә. Ашамадым, эчмәдем, кайгымнан хәтта йокламый башладым. Дүртенче көнне җизниләр кайтты. Бишенче көнне мин үзебезгә кайтып киттем. «Кайгырма! Күрерсең әле менә, озакламый яучы җибәрер!» дигән була апа, юата мине.

— Җибәрдеме соң?— дидем мин.

— Җибәрде! Әзерләнеп торган!— диде карчык, никтер үртәлеп.— Хәер, үзебезгә кайткач җибәрделәр... син җибәрдең...

— Әһә, менә ни өчен төче булгансың икән син ул вакытта!— дидем мин, аһылдап.

— Дөрес, шуның өчен...— диде карчык, үз гаебен танып.

## III

— Ярый, алайса, хәзер мин сөйлим,— дидем мин.— Шулай, карчык, яшь чаклар, кесә тулы борчаклар, саламнан тәртә каерып, чикерткә җиккән чаклар... Үзем таза, үзем чибәр — чиртсәң кан чыгарга тора! Беркөнне ат эчереп кайтам елгадан — юлыма бер кыз очрады. Суга бара бу. Битен япмаган. Үзе шундый чиб-бәр! Кара каш, кара күз, алсу битләр... яңа пешкән, өзелеп төшкән чия иреннәр! Күрсәң, атың да кирәкми, атаң да, анаң

да... суыр да үп, күтәр дә чап! Шуннан шул, мин моны сагалый башладым, карчык. Суга барганын күрдемме, атка атланам да, елгага су эчерергә китәм. Артыннан барам, артыннан кайтам. Сакчы кебек. Үзем һич тә сүз кушарга кыймыйм моңа. Бүтән чакта тегермән ташы кебек әйләнә торган тел, аны күрдемме, шып туктый. Хәзер бит инде йокы качты, малайкай. Нишләргә дә белмим, гел шуның турында уйлап үткәрәм гомерне. Ярар, шулай итеп, җәй үтте, көз үтте, кыш җитте. Бер көнне сыңар колакка чалынып калды — теге кызны күрше авылга утырмага алып китәләр ди... Хәзер инде минем башка кайгы төште, малайкай. Анда китсә, нишләр ул анда? Берәрсенә күзе төшсә?! Яисә берәрсенә ябышып кияүгә чыкса?! Харап бит эшләр, уйлап карасаң. Әти мине күреп алды да, әйтә: нәрсә балтаң суга төшкән кебек йөрисең, ди бу. Төшмәде әле, дигән булам мин. Шуннан, малайкай, әйттем дә салдым мин моңа: менә шундый, шундый хәл, әти, теләсәң нишләт — ассаң ас, киссәң кис, мин әйтәм, шул кызны алып бирмәсәң, бәхиллегем юк, мин әйтәм. Ярар, улым, диде әти, уйлап карарга кирәк, диде. Сине асып-кисеп миңа файда юк, диде, шулай да мин сине башлы-күзле итәрмен, диде. Тик башта әниең белән киңәшми булмас, диде. Шулай диде дә, әни белән сөйләшер өчен өйгә кереп китте. Ә ул арада, малайкай, минем кыз утырмага китеп тә барган! Шуннан шул, карчык, әти белән әнинең сөйләшеп беткәнен көтмәдем, атны җиктем дә, чаптым тегенең артыннан! Күрше авылда безнең туган тиешле кешеләр барые — туп-туры шуларга төштем. Төштем дә, кич булу белән киттем тегенең янына. Кулга саллы гына имән күсәк алдым — юлымны кара песи аркылы чыкмасын дип... Барып кердем тегеләрнең капкасыннан да, туктап калдым сукмакта.

— Туктале, тукта!— диде карчык, нидер сизенеп.

Ләкин мин туктап тормадым.

— Тыңлыйм: ишегалдында шылт иткән тавыш юк,— дидем мин, дәвам итеп.— Чалт аяз төн. Җиргә энә төшсә, энә табарлык. Минем йөрәк дөп-дөп тибә, аяк буыннары калтырый. Ә тәрәзәдә, малайкай, тычкан күзе кадәр генә ут яна. Карап торам шулай. Әлеге ут кисәк кенә сүнде дә куйды. Яттылар, ахрысы, дип уйладым мин. Тоттым да, карчык, малайкай, тәрәзәгә таба бара башладым...

— Тукта, җитте! Тукта!— диде кинәт карчык, күкәй кабыгыдай агарынып.

Мин чыннан да туктап калдым, йөрәк дөп-дөп тибә,

аяк буыннары калтырый. Дөрләп янган утка караганмын да, утырам шулай тын гына байгыш кебек. Карчык та утыра, карчык та эндәшми... байгыш кебек...

— Алайса, ул теге... син булгансыңмы?— диде бу бераздан, исен-акылын җыеп.

— Шулай шул, мин булганмын, карчык,— дидем мин.

Карчык тагын тынып калды. Аннары, барлы-юклы чәчләрен яулык эченә җыештырды да, кинәт кенә җыларга керешеп дә китте.

— Ай Аллам!— диде, күз яшьләрен сөртеп.— Үткән икән гомерләрем синең ише җебегән белән!

*1965*

# ЧҮПРӘ

Кайтып керде дә малай, кычкыра: «Әни, кибеттә чүпрә саталар!»— ди. Булмас, мин әйтәм, кеше ышанмас сүзне дөрес булса да сөйләмә димен. «Фәүзия апа әйтте, кирәк булса, әниең килсен дип әйтеп әйтте» ди малай. Нинди Фәүзия ул тагын? Безнең урамда Фәүзия дигән кеше юк, мин әйтәм. «Ул кеше түгел — сатучы» ди малай.

Ә-ә, шулаймыни әле ул?! Сатучы Фәүзия булгач, шул инде, шул. Моннан ике-өч ел элек чыннан да барые бер Фәүзия. Яңадан шул килде микәнни безнең кибеткә? Чүпрә дигәненә сөенсәм дә, Фәүзия дигәненә сөенәсе килмәде. Ярар, моңарчы чүпрәсез яшәдек, моннан соң да яшәрбез әле дидем дә, бармадым Фәүзия янына.

Икенче көнне шулай да түзмәдем — киттем иртүк булмастайны эзләп. Кибеттә беркем юк. Ак халат кигән бер-ике таныш кына моңаеп тора. Берсе Фәүзия. Әллә каян күреп алды да, эт кояшыдай балкып кычкыра бөтен кибеткә: исәнме, Галимә апа, ди, исән-сау гына йөрисеңме, Галимә апа, күрешмәгәнгә ни гомер, малаең үскәндер инде — дуктыр наук булгандыр, кызың да бик чибәрие — тилеәртистер, әллә балитта бииме соң, Сәлим абыйның теге вахытта башы авыртадырые — хәлләндеме, бигрәк якшы кешеләр иегез инде сез ди... тезә генә!— Һич авыз ачар хәл юк.

Миндә малай кайгысы да, кыз кайгысы да юк. Сүзен бүлдем дә моның, калмадымы берәр ярты кила? димен. Көлә Фәүзия, «ярты» калдырулар бетте бит ул хәзер ди. «Бөтене бар — кирәкме?» ди. Каяндыр астан алды да, яхшылап ап-ак кәгазьгә төрелгән бер кила чүпрәне китереп тә куйды минем алга. Елмаеп җибәрдем. Үз гоме-

ремдә беренче мәртәбә Фәүзия дөньяда иң яхшы кеше булып тоелды.

Шуннан шул, бер кила чүпрәне салдым да сумкага, үзем белән алып килгән сөт-кефир шешәләрен бирдем, бер катык белән бер кефир алдым, сөенечтән кая баскансымны белмичә киттем кайтып.

Кайтканда күңелгә әллә каян гына шик төште. Акчаны ялгыш санады, ахрысы, Фәүзия... имансыз, башы аягы астына килгере. Каяле, исәпләп карыйк. Мин аңа шыгырдап торган бишлек бирдем. Өстәвенә бер литрлы сөт шешәсе, аннан ике кефир шешәсе бирдем. Сөт шешәсе егерме тиен, ике кефир шешәсе — утыз тиен. Була биш сум да илле тиен. Алдым өч сумлык чүпрә, егерме җиде тиенлек кефир, егерме тугыз тиенлек катык. Булды бу өч сум да... өч сум да кырык... илле алты тиен. Өч сум илле алты тиенне алабыз биш сум илле тиеннән. Ике сум калыр иде, алты тиен килеп кысыла. Түгәрәкләп ике сум дип исәплик. Димәк, ул миңа ике сум чамасы кайтарырга тиеш булган. Чынлыкта ул миңа сиксән дүрт тиен генә биргән. Шулай булгач...

Калганын уйлап торасы килмәде. Билгеле инде, кәеф кырылды. Кайткач язып исәпләп карадым. Юк, бер сум да фәлән тиен чыкмый. Ярар, чыкмаса чыкмас — күргәне-күрмәгәне шул булсын дидем дә, чүпрәне сүтеп җибәрдем. Сүтсәм, ике күзем дүрт булды. Чүпрәм искереп, корып, бозылып беткән! Җылаплар җибәрә яздым. Ярый әле ирем Сәлим килеп җитте — тыелып калдым, елмайган булдым. «Нәрсә ух-вах киләсең баядан бирле?» ди бу. Әйтәсем килмәсә дә, әйттем. «Бар, кире илтеп бир үзенә!» ди. Йөзенә бәр — кеше алдап ятмасын, ди.

Нишлисең, оят булса да киттем яңадан. Шулай да йөзенә бәрмәдем: Фәүзия туганкаем, мин әйтәм, хата миндә, гаеп синдә... чүпрәң искергән икән ләбаса, ачуланма инде — кире ала күр, мин әйтәм. Чак-чак кына каушагандай итте, шулай да сиздермәскә тырыша. Баягыдан да ялагайрак кылана бу. «Ала күрмә, Галимә апа, ди, дүрт тәңкәгә итәк астыннан чүпрә алып ятырга син теге әллә кем түгел — «пенсионер» ди, мине яклаган булып сөйләнә. Монысы искерәк булган шул — тагын яхшырагын китермәсләрме, калдырырмын, бер дә хафаланма ди.

Көлә-көлә, сөйләнә-сөйләнә алды бу чүпрәне, башы баегыры. Мин инде җиңеләеп киттем, кыюлана төштем. «Баягынак син минем шешәләрне дә чигерергә оныткансың бугай, Фәүзия, димен. «Әйе шул, оныткханмын Галимә апа, ди. Шалт-шолт чут төймәләрен суккалады

да, уч тутырып бу миңа акча кайтарып бирде. Чүпрәле булып бер сөенсәм, акчамны кире алып икенче сөендем.

Ләкин... кайтканда күңелгә тагын шик төште. Нечектер бик җиңел генә булды бу. Тагын дөрес исәпләмәде ахрысы. Кайттым да, барысын да өр-яңадан кәгазьгә язып, өр-яңадан исәпләргә тотындым. Бер исәпләдем, ике исәпләдем — һич дөресен табып булмый. Әйе, тагын хата. Тик бу юлы ул мине түгел, мин ... аны алдаганмын. Төп-төгәл бер сум да унбер тиенгә!

*1986*

# ПУБЛИЦИСТИКА

## БЫЕЛ ТАГЫН «КАЗАН СӨЛГЕСЕ»

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында К.Тинчуринның, «Казан сөлгесе» белән яңа сезон башланды.

Драма әсәре буларак «Казан сөлгесе» шактый йомшак әйбер. Вакыйга революциягә кадәрге татар авылында бара. Авыл мәзиненең Саҗидә һәм Мөршидә исемле кызлары бар. Шәмси әби кызларга яңалыклар сөйли. Хәзрәтләргә Казаннан килен төшкән. Киленнең бирнәсе күп икән, бирнәгә дип Казан сөлгесе дә алып килгән икән. Кода булып туйга Казаннан Ильяс исемле шәкерт тә килгән, имеш.

Ильяс шәкертнең мәзин кызларына күзе төшкән. Көтүче киемнәре киеп, битенә ясалма сакал-мыек тагып Ильяс көтмәгәндә кызлар янына килеп керә. Үзен ул чуваш кешесе итеп таныта, шуның аркасында көлке хәлләргә кала. Кичен кызлар киндер тукмаган җирдә Ильяс белән Мөршидә очрашып, бер-берсенә мәхәббәтләрен белдерәләр. Яшьләр, үзләре генә калгач, «каравылчы килә!» дип куркып, якындагы мәчеткә кереп качалар. Таң алдыннан мәчеткә картлар килә, гашыйклар тотыла. Халык алдында хөкем итмәкче булып, аларның икесен дә ике яктагы киртә баганасына бәйләп куялар. Салих шәкертнең тапкырлыгы аркасында аларны коткаралар. Яшьләр җиңә, картлар көлкегә кала.

Пьесаның кыскача эчтәлеге шуннан гыйбарәт.

Комедия авыр жанр. Комедия, һичшиксез, көлдерергә тиеш. Моның өчен пьеса барыннан да элек үзенчәлекле, көлке ситуациягә нигезләнергә һәм, әлбәттә, геройлар да реалистик планда түгел, бәлки, көлке планда күрсәтелергә тиеш. Ләкин теләсә нинди көлке ситуация чынбарлыкны, тормыш дөреслеген чагылдырырга тиеш.

Әйтик, элекке авылда кызлар киндер тукмаганнар, кызлар янына яшь җегетләр килгән. Монысы — тормышта була торган хәл. «Казан сөлгесе»ндә яшьләр нишләптер авыл читенә, су буена түгел, мәчет алдына җыелалар һәм аларның кечке уеннары да шунда бара. Монысы инде бернинди гореф-гадәткә дә, бернинди логикага да туры килми. Иң мөһиме, бу — көлке ситуация була алмый.

К.Тинчуринның «Казан сөлгесе» менә шундый ясалма хәлләргә, көлке булмаган ситуацияләргә нигезләнгән. Автор текстында күрәләтә мәгънә хаталары, кәгазьгә язсаң кәгазь оялырлык әдәпсез сүзләр тулып ята. Кызлар киндер түгел, киндерә тукмаклыйлар, туйда Әсмага бүләк түгел, бирнә бирәләр. Мәзин үзенең хатынына һәм башкаларга ахмак, хәшәп, надан, ябалак дип эндәшә. Ялган көтүчегә карата чуаш калдыгы, чепи күз дигән сүзләр кулланыла. Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, Тинчурин геройлары гомумән ямьсез сөйләшәләр.

Көлүнең теләсә нинди файдалы, көлү гомерне озайта, күңелне күтәрә дигән караш бар. Әйе, көлү файдалы. Ләкин көлкенең дә төрлесе була. Берәүләр тапкыр сүз, җиңелчә шаярту белән, икенче берәүләр — тупас һәм әдәпсез хәрәкәт, тупас шаярту белән көлдерә. Сәхнәдәге көлдерү, әлбәттә, сәнгатьчә тапкыр, оста көлдерү булырга тиеш. Сәхнәдәге көлдерү тамашачыны көлдереп кенә калмаска, аны шулай ук уйландырырга, борчылдырырга да тиеш.

Безнең Академия театрында комедияләр еш куела. Быелгы репертуарда, мәсәлән, драмаларга караганда комедияләр күбрәк булачак. «Академия театры» дип аталган театр күптән инде көлке театрына әйләнде дип әйтергә була. Ләкин шунысы күңелсез, безнең комедияләрдә тупас һәм буш көлдерү өстенлек итә. Көлдерү өчен һәртөрле примитив алымнар куллану, кычкыру, чырчу килү һәм сәхнәдә бертуктаусыз буталу хәзер бездә гадәти хәл санала. Ничә еллар инде менә бер үк артистлар бер үк типтагы рольләрне башкаралар, төрле исемдәге спектакльләрдә бер үк хәрәкәтләрне кабатлыйлар, бер үк интонация, бер үк мимика белән сөйләшәләр. Театрның баш режиссеры, СССРның халык артисты Марсель Сәлимҗанов куйган «Казан сөлгесе» моңа бер мисал була ала.

Үзеннән-үзе аңлашылганча, пьеса текстындагы хаталарны, килешсез, ятышсыз урыннарны режиссер мөмкин кадәр бетерергә йә булмаса йомшартырга тиеш иде кебек. Ләкин вульгарлык мәсьәләсендә режиссер Тинчу-

ринны да уздырып җибәрә. Спектакльнең көлке чыганагы тулысынча тупаслыктан, мәгънәсезлектән һәм әдәпсезлектән гыйбарәт. Режиссер фантазиясе бары бер тирәдә — чит кешегә күрсәтелми торган оятлы нәрсәләр тирәсендә чуала.

Мәсәлән, беренче пәрдәдә шаян кызлар (Саҗидә белән Мөршидә), аталарына чапан китерәсе урында, аның зур төпле, буй-буй кызыл төстәге ыштанын алып киләләр һәм, икесе ике балагыннан тоткан килеш, ыштанны урталай ертып чыгаралар. Үз эшләреннән үзләре канәгать булып елмаеп торган кызларга карагач, болар бер дә шаян түгел, болар тиле-миле бугай дигән фикер туа. Тамашачыны шаккатыру өчен безнең атаклы актрисаларыбыз әллә нәрсәләр кыланалар: әле бер-берсенең бот арасыннан чыгалар, әле бик нык югары күтәрелгән итәкләре арасында буталып калалар. Тамашаның иң кызыгы Мөршидә белән Ильясның бөтен халык алдында чишенә башлавы була. Зал көлә һәм ...аптырап кала. Мин, тамашага күтәрелеп карарга кыймыйча, оялып һәм хурланып утырдым.

«Казан сөлгесе»ндә эчне пошырган икенче нәрсә — халыкка һәм халыкның гореф-гадәтләренә мөнәсәбәт мәсьәләсе. Спектакльдә халык икегә — яшьләргә һәм картларга бүленә. Яшьләр, гадәттәгечә, алдынгы карашлы. Аларның алдынгылыгы шул — ирекле мәхәббәткә омтылалар. Картлар — искелек, караңгылык тарафдарлары. Картлар аңсыз, аңгыра һәм эчкече. Мәзин, хәзрәт, староста, авыл картлары күмәкләшеп исерткеч эчәләр, күмәкләшеп, алпан-тилпән атлап, мәчеткә киләләр, күмәкләшеп хур кызларын, кәүсәр шәрабын, закусканы мактап такмаклар әйтәләр. Алар шул дәрәҗәдә ахмак һәм аңгыра яисә шул дәрәҗәдә исерек — баштарак чын кеше белән бүрәнәне дә аермыйлар, соңыннан исә, кешеләр агачка әйләнгән дип, «үле» бүрәнәләргә җеназа укырга җыеналар.

Без бик яхшы беләбез: эчкечелек безнең халыкка хас булмаган. Элекке авыл халкын тоташ исерек итеп күрсәтү ул — яла һәм мыскыл. Мәчет картларын эчкече итеп күрсәтү — икеләтә яла һәм мыскыл. Безнең күбебез дингә ышанмый. Ләкин безнең ата-бабаларыбыз динле булган, безнең Тукаебыз динле булган. Әле дә халыкның күпмедер өлеше дингә ышана. Динне танымау аны мыскыл итәргә хокук бирми.

Картларга каршы куелган яшьләр спектакльдә шат күңелле. Алар кыю һәм тапкыр. Ләкин аларның кыю-

лыгы, тапкырлыгы ахыр чиктә тормыш дөреслеген бозуга һәм оятсызлыкка кайтып кала. Белүебезчә, революциягә кадәр мәчет иң изге урын саналган. Мәчет янында киндер тукмау, кичке уеннар оештыру, гашыйкларның мәчеттә качып ятулары, манарадан дуэт җырлауише нәрсәләрнең берсе дә тормышта булмаган һәм була да алмаган. Элекке авыл яшьләрен «революционер» итеп күрсәтү ул чынлыкта янә дә халыкның диниәхлакый гореф-гадәтләрен мыскыл итүгә юнәлдерелгән.

«Казан сөлгесе» 1922 елда язылган. Тинчурин бу комедиясендә иске тормышны фаш итүне максат итеп куйган. Ләкин драматург, искелекне фаш итәм дип, халыкка һәм халык өчен изге булган нәрсәләргә тап төшерү юлына баскан. Моның өчен хәзер аны таләп иткән социаль заказны үтәгән һәм, тәҗрибәсе булмау аркасында, беренче адымыннан ук ялгыш якка каерган.

Монысы аңлашыла да кебек. Тик шунысы гына аңлашылмый: ник яңадан казып чыгарды икән безнең театр бу тузып-искереп беткән «сөлгене»? Кемне, нәрсәне тәнкыйтьләргә ниятләде икән ул шау-шулы, көлкеле спектакле белән? Тинчурин күз алдында тоткан искелек күптән инде юкка чыкты — мәчет манараларын кисеп ташладык, китапларны яндырдык, муллаларны сөрдек. Шулай булгач, тәнкыйть утын беркемгә дә каршы юнәлтеп булмый. Бәлки, бүгенге тамашачыга театр берәр төрле акыллы, гыйбрәтле сүз әйтмәкче булгандыр? Ләкин, күрүебезчә, «Казан сөлгесе»ндә акылсызлыктан башка берни юк.

Димәк, бу спектакльне театр бары тик көлдерү өчен генә, буш һәм мәгънәсез көлдерү өчен генә куйган дияргә туры килә. Юк, бөтенләй үк мәгънәсез дип тә булмый. Спектакль бүгенге тамашачыда билгеле бер тәэсир тудыра ала. Элекке заман турында бик аз белгән яшь тамашачы, «Казан сөлгесе»н карагач: безнең халык надан һәм аңгыра булган, элек тә эчкәннәр һәм төрле бозыклык эшләгәннәр, шулай булгач, ник безгә дә эчмәскә һәм бозыклык эшләмәскә?! дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин.

Өлкән буын тамашачының күпчелеге башта ук «Казан сөлгесе»нә карата кире фикердә булды дисәк, ялгышмабыз дип уйлыйм. Спектакльдән чыкканда еш кына олырак яшьтәге кешеләрнең сукрануын ишетергә туры килә. Шунысын да әйтергә була: 17 октябрьдә театрда мин татар интеллигенциясеннән бер генә танышымны

да очратмадым. «Казан сөлгесе»нең куелуына нәфрәтләнеп редакцияләргә хатлар килүе дә билгеле.

Театр җитәкчеләре белә микән бу турыда? Беләдер дип уйлыйм. Ләкин алар күптән инде тәнкыйть дигән нәрсәне санга сукмыйлар. Хәер, соңгы ун-унбиш ел эчендә театрга карата чын тәнкыйтьнең әйтелгәне дә юк. Нинди генә рецензия язылмасын — театрда барысы да ал да гөл. Һәр спектакль — шедевр. Артистларның барысы да — талант.

Анысы дөрес — безнең артислар булдыклы, Сәлимҗанов — талантлы режиссер. Ләкин безгә шунысы да мәгълүм: Сәлимҗанов үзен диктаторларча тота — яраткан кешесен якынайта, яратмаганын якын да җибәрми. Театрда бары аның сүзе генә сүз. Үзара тәнкыйть юк дәрәҗәсендә. Шуңа күрә дә театр, тәнкыйть фикерләргә колак салмыйча, һәр яңа сезонын «Казан сөлгесе» белән ача, «Казан сөлгесе» белән яба. Шуңа күрә дә, сәнгатьтәге ниндидер милли казаныш сыман итеп, һәр гастрольгә үзенең әшәке «сөлге»сен алып чыга һәм бөтен Союз буенча татарның данын сатып йөри.

Менә быел тагын Академия театры, итәк күтәреп, ыштан төбен күрсәтеп, яңа сезон башлап җибәрде. Тамашачы көлә. Шулай да кемнән көлә соң ул? Әлбәттә, үзүзеннән көлә. Ягъни без үзебездән үзебез көләбез. Көләргә түгел, җыларга кирәк безгә! Уйланырга кирәк, халык, мирас, культура турында төплерәк итеп, җитдирәк итеп уйланырга һәм уйландыра белергә кирәк. Менә шулай үзебездән көлә-көлә мәнсезгә, гамьсезгә һәм пошмас җаннарга әйләнеп беттек түгелме соң без?!

Партия безне активлыкка, яңача яшәүгә һәм яңача иҗат итүгә өнди. Бу өндәүгә, ниһаять, Татар академия театры әһелләре дә кушылырлар дип ышанасы килә.

*1986*

## ТӨРКИЯГӘ ЙӨЗ БАЛА

Тирә-якта сүзләр йөри: төрек, Төркия... Төркиягә, Төркиядән... Киләләр, баралар. Кайталар да, исләре китеп, «их!», «ах!» дигән мәкаләләр бастыралар. Әле күптән түгел шундый бер мәкалә күренеп калды. «Татарстан — Төркия: мәгърифәт берләштерә» дип атала («Т.Я.», 5.11.1991). Казандагы Милли мәктәпләр фәнни-тикшерену институты директоры Ф.Ю.Йосыпов интервью бирә. Ул да Төркиядә булган, андагы «Төрек җәмгыяте» вәкил-

ләре белән берлектә «дөньядагы барлык төрки дәүләтләр өчен» үрнәк уку планнары, норматив таләпләр эшләүдә катнашкан. Шулай итеп, әле кичәгенәк кенә Мәскәүгә фәлән министрлыкка, фәлән институтка тиешле инструкцияләр-күрсәтмәләр алырга барган кебек, бу юлы Ф.Йосыпов «Яңа үзәккә» чыгып чапкан икән.

Төркия матур ил, борынгы ил. Төркиягә барган өчен генә кешене гаепләп булмый. Тик монда шунысы аңлашылмый — Төркиядәге «Төрек дөньясы» җәмгыятеннән без беркайчан «дөньядагы барлык төрки дәүләтләр өчен», димәк, Татарстан өчен дә «уртак мәгариф концепциясе» эшләүне сорамадык шикелле. Безнең үзебездә институтлар, галимнәр тулып ята. Йосыпов үзе дә әйтеп тора: «безнең институт хезмәткәрләре тарафыннан эшләнгән «Милли мәктәпләрне үзгәртеп кору концепциясе» төрек җәмгыятендә югары бәяләнде» ди. «Югары бәяләнгән» концепцияне Каф-тау артына барып раслатып йөргәнче, шушында үзебездә тормышка ашыра башласак, яхшырак булмас иде микән?

«Төрек мәгариф системасы Европада иң алдынгылардан санала» ди Ф.Йосыпов. Иң алдынгы мәгариф системасы булган ил башка яктан да, әйтик, экономика, фән, культура ягыннан да иң алдынгысы булырга тиеш иде кебек. Төркия, белүебезчә, Европада (Көнбатыш Европада бигрәк тә) иң койрыкта сөйрәлүчеләр рәтеннән исәпләнә.

Ф.Йосыпов әйткәнчә, төрек мәктәпләрендә ике генә фәнгә игътибар итәләр икән. Икенең берсе — төрек теле, икенчесе — математика. Төрек мәгарифенең алдынгылыгы, Йосыпов фикеренчә, күрәсең, менә шунда чагыладыр да инде. Ике генә фәнгә игътибар итү, минемчә, төрек мәгариф системасының алдынгылыгын түгел, арттальгын да чагылдыра. Элегрәк барлык Төркия халкының 50%, көнчыгыш өлкәләрендәге халыкның 80% укый-яза белми дип язалар иде. Хәзер бу саннар, бәлки, башкачарактыр, ләкин Төркиянең тоташ укый-яза белүчеләр иле түгел икәнлеге һәркемгә мәгълүм дип уйларга кирәк. Халыкны тиз арада укырга-язарга өйрәтү өчен төрекләр, минемчә, менә шундый «ике фәнле» гадирәк, очсызлырак юлны сайлаганнар да инде. Төркия турында сүз барганда, әлеге методның азчылык милләтләрне төрекләштерүгә хезмәт итүен дә истән чыгарырга ярамый.

Төркиядә төрекләрдән тыш башка телдә сөйләшүче бик күп халыклар — курдлар, гарәпләр, черкеслар, Кав-

каз халыклары, греклар, әрмәннәр, славяннар, яһүдләр һ.б. яши. Монда шулай ук этник төрек булмаган төркиләр — төрекмәннәр, әзәрбайҗаннар, карапапахлар, гагаузлар, татарлар һ.б. бар. Гасырлар буена төрекләр империячел рухта тәрбияләнгәннәр, гасырлар буена Төркия хакимнәре башка халыкларны көчләп төрекләштерү политикасы алып барганнар. Азчылык милләтләрне кысу, изүдә төрле метод кулланылган һәм кулланыла. Мәсәлән, 1915—1922 елларда төрек гаскәрләре миллион ярым әрмәнне юк итәләр. Бүгенге Төркиядә 6 яисә 12 миллион чамасы курд бар дип уйланыла. Милләт буларак курдларның бернинди хокуклары юк. Ф.Йосыпов исәпләгәнчә, «шәфкатьле, миһербанлы», төрекләр курдларының һәртөрле милли хәрәкәтләрен ерткычларча бастыра киләләр. Курд авыллары әледән-әле бомбага тотыла, курд авылларына төрек гаскәрләре басып керә. Меңәрләгән курд патриотлары төрмәләрдә черетелә.

Бүгенге Төркиядә курдларның гына түгел, төрек булмаган башка барлык халыкларның дини, милли хокуклары бик нык киселгән. Бик аз сандагы һәм ярым-йорты грек, әрмән, яһүд мәктәпләрен исәпләмәгәндә, азчылык милләтләр телендә бернинди мәктәп, матбугат юк. Төркиядә барлык милләтләр «төрек» дип атала һәм языла. Нәкъ бездәге «бердәм совет халкы» кебек дип әйтер идем, охшашлык тулы түгел. Советлар Союзында, яхшымы-начармы, милли республикалар, милли мәктәпләр, милли культура яшәп килде һәм шуның аркасында без исән калдык. Төркиядә боларның берсе дә юк һәм булмады.

Төрекләрнең башка халыкларга карата империячел мөнәсәбәте Төркиядәге татарлар язмышында да ачык күренә. Россиядәге дини, милли изүгә түзә алмыйча, бәхет, ирек эзләп татарлар элек-электән солтан иленә агылганнар. 1917 елгы революциядән соң да, 1941—1945 еллардагы сугыштан соң да бик күп татарлар Төркиягә килеп урнашканнар. Кая гына барып чыкмасын, һәркайда татар үз телендә мәктәп ачкан, китап язган, китап бастырган. Финляндиядә, Кытайда, Япониядә, Германиядә, хәтта ерак Австралиядә, Америкада чит халыклар арасында яшәүче татар утраулары бүгенгәчә үз телен, үз культурасын саклап кала алган. Татар бары Төркиядә генә юкка чыккан. Дөрес, бөтенләй үк түгел — анда әле дә үзен татар дип исәпләүчеләр бетеп җитмәгән. Килделәр бит. Күрдек, ишеттек. Телләре тел түгел, җырлары җыр түгел. Барысы да чит-ят, барысы да төрекчә.

Тәннәрендә чыкмаган җаннары гына — «татар» дигән җаннары гына калган.

Төркиядә татарны әле булса Чыңгыз хан монголлары дип беләләр, имеш. Шуңа күрә дип әйтимме, бигрәк тә алар безнең милләт исемен яратмыйлар икән. Быел Казанга килгән бер төрек профессоры театр залындагы халык алдына чыгып: «Әгәр сез «татар» исеменнән баш тартсагыз, без сезгә ярдәм итәчәкбез» дигән, имеш. Казаннан барган берәр татар шулай халык алдына чыгып: «Төрек» исеменнән баш тартсагыз, без сезнең белән дуслашачакбыз» дисә, төрекләр, ихтимал, андый кешенең сөяген он итеп ташлар иде. Безнең театрдагы халык төрек профессорына шаулатып кул чапкан, имеш. Хәер, «Казан утлары» журналында Төркиягә кагылышлы материалларда «татар» диясе урында берничә мәртәбә инде «төрек» атамасы кулланылды. Күрәсез, бездә әле үзенең «төрек»ме, «татар»мы икәнлеген аермаучылар да җитәрлек.

Профессор Йосыпов Төркиядәге инглиз телендәге лицейлар белән килешү төзегән. «Алар быел ук Татарстан җөмһүриятеннән 5—6 классларда укучы 100 баланы кабул итәргә әзерләр» ди ул. «Алар Төркия хисабына укыячаклар... Лицейның унберенче классын тәмамлаганнан соң милләтебез балаларына Америка, Англия, Греция, Кипр, Төркия университетларында белем алу өчен юл ачылачак» дип дәвам итә профессор.

«Нинди шәп перспектива! Болай булгач, киләчәккә безнең татар Америка президенты да була алачак» дип сөенергә мөмкин кайберәүләр. Ләкин, Америка президенты булу ихтималы турында хыялланганчы, иң элек үзебезнең хәлне ачыкласак, дөресрәк булмасмы? Беренчедән, нишләп бездән аларга 100 бала да, нишләп алардан безгә бер бала да юк? Икенчедән, нишләп 5—6 классларда укучыларны? Нишләп, әйтик, 1—2 классларда укучыларны яисә бакча балаларын түгел? Бит төрекнең төп максаты татардан Америка президенты ясау түгел, төрек ясау! Мәскәүдәге Халыклар дуслыгы университетында да Африка негрларын, Азия «чучмек»ларын җыеп укытып, Африканы, Азияне урыслаштырырга азапландылар лабаса. Төркиянең үз хисабына 100 татар баласын укытырга ниятләвендә дә шундый ук хәйлә ятканлыгы үзеннән-үзе аңлашылып тора түгелме соң?

1981 елгы бер белешмәдә Төркиядә 10 мең татар бар диелгән. Элегрәк татар анда күбрәк булган. Академик

В.В.Бартольд солтан иленә миллионлаган татарларның күченүе турында яза. Димәк, Төркиядә бер миллионга якын татар төреккә әйләнгән. Казахстанда татар — берике миллион, урыста ничә миллиондыр — бер Ходай үзе белә. Миллионнар янында 100 бала — чүп кенә диярләр, бәлки. Без аларны белем алырга, кеше булырга җибәрәбез диячәк Ф.Йосыпов.

Шулай да булсын. Ләкин йөз баланың яртысы туган иленә кире кайтмаска, кайбер яшьләр (бигрәк тә кызлар) «оҗмах иле»ндә бозык юлга кереп китәргә мөмкин. Кире кайткан яртысы ни белән шөгыльләнер икән? Тәрҗемәче булырлар, фән белән шөгыльләнерләр, бәлки. Арада төрекчелек белән яхшы коралланып өлгергән «милли» патриотлар да табылырга мөмкин. Мондый патриотлар: «татарны төрекчә укытырга кирәк!» дип дәгъвалаша башласалар? Ул чагында инде татар тормышында яңа борчулар, ызгыш-талашлар килеп чыгачагын көт тә тор.

Бу бер дә саташу яисә юри куркыту түгел. Казанда әлегә бер генә «төрек» бар — ул да булса Рафаэль Мөхәммәтдинов. Бер үзе генә дә ул инде күп нәрсәне бутап өлгерде. «Татар» исеменнән баш тартып, «булгар» дип аталырга кирәк дигән тәкъдимне иң элек ул күтәреп чыкты («С.Т.», 11.9.1988). «Мы не татары, мы — булгары!» дип, КГБ пенсионерлары соңлабрак шау-шу куптардылар. Беренче булып Р.Мөхәммәтдинов барлык төрки халыклар өчен төрек алфавиты нигезендә эшләнгән яңа әлифба проекты тәкъдим итте («С.Т.», 29.4.1990). Шул ук Р.Мөхәммәтдинов «Иттифак» партиясен оештыручыларның берсе булды. «Иттифак» исеменнән бүген күбрәк Ф.Бәйрәмова бәргәләнә. Оештыручыларның берсе күләгәдә калды. Ләкин ул анда да тик ятмый. Күптән түгел Мөхәммәтдинов бөтен дөнья төрки халыклар берләшмәсен төзеде һәм шуның башлыгы булды.

Бөтен дөнья төркиләре, бөтен дөнья славяннары, бөтен дөнья герман халыклары... Кемнәр генә хыялланмаган «бөтен дөнья»ны берләштерү турында! Ләкин әлегә андый идеянең бер җирдә дә тормышка аша алганы юк. Һәр халык үз илендә булып үзенчә яшәргә тырыша. Дөньяда бүген герман, славян, роман, гарәп телле дистәләгән аерым-аерым дәүләтләр бар. Славян телле халыкларны көчләп берләштергән Югославия күз алдында таркала бара. Совет империясен әйткән дә юк. Төркия гегемонлыгында төрки халыкларны яисә анда төрки дәүләтләрне берләштерергә тырышу да — буш хыял. За-

рарлы һәм куркыныч хыял. Гомер-гомергә без болгар-кыпчак-казан-татар милләте булганбыз. Шулай булып калырбыз да.

Моннан биш йөз еллар элек тә төрек белән татар арасында бүгенге сымаграк хәл барлыкка килгән. Алтын Урда таркалгач, аның биләмәләрендә бәйсез дәүләтләр оеша. Күп тә үтми, бәйсез Казан ханлыгы госманлы төрекләр тәэсиренә эләгә. Ләкин Казан файдасына төрекләр кыл да кыймылдатмыйлар. Киресенчә, Мәскәүнең көчәюенә, Казан ханлыгының җимерелүенә хәтта төрек солтаннары гаепле дип тә әйтергә була. Дөньяны дер селкетеп торган Сөләйман Кануни урысларга бармак кына янаса да, Мәскәү, бәлки, узынмас, Казан, бәлки, исән калыр иде.

«Казан» бүген яңадан аякка басмакчы. Моңарчы төрекнең безгә ирек алырга булышканы булмады, безнең әлегә чын ireккә ирешкәнебез юк. Шулай да төрекнең күзе безнең якка текәлгән. Урыска бездән ни кирәк булса, аңа да шул кирәк. Бүген алар безнең милләт исемен танымыйлар, иртәгә безнең телне танымый башлаячаклар. Инде бүген үк татар матбугатында этешә-төртешә төрекчелек үзенә хокук даулый.

Русның башка, татарның башка телдә сөйләшүе, диннәрнең төрле булуы безне тулысынча йотылудан саклап килгән барьер хезмәтен үтәгән. Төрек белән татар арасында, географик араны исәпләмәгәндә, андый киртә юк. Бәйсезлек, милли аң һәм милли горурлык үз-үзебезне саклауда безнең өчен иң ышанычлы барьер булачак.

Мин, билгеле, Татарстан белән Төркия арасында бернинди багланышлар булмасын дип әйтергә җыенмый. Мин Татарстанның киләчәктә Төркия белән дә, башкалар белән дә аралашып, алыш-биреш итеп яшәвен телим. Ләкин халыклар, дәүләтләр арасындагы һәртөрле элемтә, һәр төрле алыш-биреш халыкара принциплар нигезендә һәм тулы тигезлек шартларында гына була ала.

Заманында Такташ чит илләргә озатылган казлар өчен дә пошынып шигырь язган. Төркияне күз алдында тотып, Тукай: «Китмибез!» — дигән. Татарстанның бәйсезлеге бүген мәйданнарда, митингларда гына хәл ителми. Йөз казны түгел — йөз баланы яклап безгә чаң кагарга кирәк. Җитәр! Күп таралдык, күп тараттык. Инде китмибез дә, җибәрмибез дә!

*1991*

# БЕРЛӘШӘБЕЗМЕНИ, БАТУЛЛА?

*Мәсьәләгә бер караш*

1991 елның 30 мартында университетның 1 нче аудиториясендә татар язуын латин графикасына күчерү мәсьәләсендә җыелыш булды. Җыелышны Иҗтимагый үзәкнең мәгариф бүлеге оештырды. Ә.Кәримуллин доклад ясады. Җыелыш, 1939 елда гамәлдән чыгарылган яңалифне — татарча-латинча әлифбаны яңадан торгызырга кирәк, дигән карар кабул итте. Җыелышның карар текстын әзерләүдә Р.Батулла белән мин дә катнаштым. Карарны Батулла үз кулы белән язды.

Беркадәр вакыттан соң шул ук Батулла берничә юлдашы белән Төркиягә киткән, аннан, имеш, төрек латинына нигезләнгән яңа әлифба алып кайткан — шуны яклап интервью бирә («Ш.К.», 18.12.1991).

«Мин анда кабул ителгән уртак алфавит белән килешәм. Бөтенебез дә шул нигездә язсак, дистә ел эчендә тугандаш халыклар бер-берсенә якынаячак,— ди Батулла һәм өстәп куя,— менә бу чын мәгънәсендәге интернационализм була»,— ди.

Белүебезчә, һәр алфавитның төп максаты — туган телдә укырга-язарга өйрәтү. Шунлыктан һәрбер алфавитта ана теленең фонетик үзенчәлекләре мөмкин кадәр тулырак чагылыш табарга тиеш. Милли алфавит ул — туган телнең көзгесе һәм шул ук вакытта аның ышанычлы сакчысы да.

Алфавитта телнең фонетик үзенчәлекләрен чагылдыруга тиешенчә игътибар итмәү яисә алфавитка аның төп максатына туры килми торган өстәмә бурычлар йөкләү әдәби телне үзләштерүдә кыенлыклар тудыра һәм тел практикасында төрле бозуларга юл куя. Мәсәлән, рус графикасына нигезләнгән татар язуында татар теле фонетикасының күп кенә үзенчәлекләре исәпкә алынмады. Шуның белән бергә, татар әлифбасына аның төп максатына туры килми торган өстәмә бурычлар йөкләтелде. Русча-татарча алфавит ярдәмендә татар баласы татар әдәби теленә генә түгел, рус әдәби теленә дә өйрәнергә тиеш булды. Нәтиҗәдә, татар теленә өйрәнү арткы планга чигерелде, бөтен игътибар рус теленә юнәлтелде.

Төркиядән алып кайткан һәм барлык төрки телләр өчен яраклы дип уйланылган «уртак алфавит» төрек теленең фонетик үзенчәлекләрен чагылдыра торган «төрек

латинына» нигезләнгән. Бу үзе генә дә башка төрки телләрнең фонетик үзенчәлекләрен танымауга, барлык төрки телләрнең авазлар системасын төрек теле авазлар системасына яраклаштыруга юл ача.

Интервьюдан күренгәнчә, «уртак алфавит» ярдәмендә татар баласын татарча укырга-язарга өйрәтү турында берни әйтелми. Алай гына да түгел, Батулла төрки халыкларның үз теленә ярашлы мөстәкыйль алфавитлары булу ихтималын да танымый. «Әгәр без латиниканы үзебезчә кабул итсәк, үзбәкләр, казахлар үзенчә... димәк, без тагын бер-беребезнең китапларын укый алмаячакбыз»,— дип кайгыра ул.

Монда төрле сорау туа. Башка төрки телләрдәге китапларны укый алу үз телендәге китапларны укый алуга караганда мөһимрәкмени? Дөньядагы барлык цивилизацияле халыклар, бер-берсе белән аралашу максатында, бер-берсенең китапларын үз телләренә тәрҗемә итәләр. Бары төрки телле халыкларга гына тәрҗемә тыелганмыни яки бер төрки телдән икенче төрки телгә тәрҗемә итү мөмкин нәрсә түгелмени?

Башка төрки телләрдәге китапларны уку-укымау турындагы сүзләр — Батулла фикеренең баласы гына. Анасы — башкада. «Исмәгыйль Гаспралының бөек хыялы булган уртак төрки телгә ясалма рәвештә ирешеп булмый, әлбәттә, әмма уртак алфавит безне якынайтачак»,— ди Батулла. Шулай итеп, уртак алфавит аша — «уртак төрки телгә», «якынаю»га таба барабыз икән.

Нәрсә соң ул «якынаю»? Рәсми мәгълүматлардан күренгәнчә, соңгы елларда элекке СССРда 7 миллион чамасы татар булган. Шуларның 700 меңгә якыны Үзбәкстанда яши һәм үзбәкчә китап укый-укый, үзбәк белән бик нык якынайган икән. 300 меңнән артык татар Казагыстанда яши һәм, казахча китаплар укып, шулай ук казах белән якынаеп беткән, имеш. 72 мең татар Кыргызстанда, 80 меңе — Таҗикстанда, 46 меңе — Төркмәнстанда. 31 меңе Әзәрбайҗанда яшәп ята икән. Татарның 940 меңе (чынлыкта миллион ярым чамасы) Башкортостанда, 10 меңе — Бурятиядә, 18 меңе — Комида, 41 меңе — Марида, 46 меңе — Мордвада, 99 меңе — Удмуртиядә, 38 меңе — Чувашиядә, 11 меңе — Якутиядә, 37 меңе — Ханты-Мансида, 2 меңе — Чукоткада, 9 меңе чамасы Ямал-Ненецта яши. Татарстанның үзендә бер миллион 700 мең чамасы татар исәпләнә. Әйтүләренә караганда, аларның да кимендә яртысы башка милләтләр белән якынайганнан-якыная баралар икән.

Татар өчен «якынаю» менә шул була. Күрәсез, «якынаю»га татар үзеннән җитәрлек дәрәҗәдә өлеш керткән инде. Моннан да артыграк нинди якынаю кирәк соң сезгә, әфәнделәр?!

Хәзер Батулла телгә алган «уртак төрки тел»гә игътибар итеп карыйк. Билгеле булганча, һәрбер тел конкрет һәм милли Төркиләр өчен уртак телне без каян һәм ничек алырбыз икән дә, конкрет нинди төрки телне «уртак» дип игълан итәрбез икән?

БМО карары белән барлык төрки телләр арасында татар теле өйрәнү һәм аралашу өчен иң кулае дип табылган иде. Төркиләрнең киләчәктәге уртак теле менә шул татар теле булырга тиеш микән әллә? Юк, татар теле турында Батулла — ләм-мим. Төреккә нигезләнгән «уртак алфавит»ны яклап чыккач, аныңча, күрәсең, төркиләрнең уртак теле дә төрек теле булырга тиештер инде.

«Славян халыклары бердәм, дус яши бит, ни өчен теле, дине, тарихы бер булган төрки халыклар берләшмәскә тиеш?!»— ди Батулла. Славян халыклары «бердәм, дус» яшәгән өчен генә, төрки халыклар «берләшергә» тиеш, дигән логиканы бик үк аңлап булмый. Монда тагын төрле сорау туа. Славян халыклары бердәм, дус яши, ә төрки халыклар үзара дошманлашып яшимени? «Славян халыклары» дигәндә Батулла барлык славян халыкларын күз алдында тотамы, әллә аерым дәүләтләрдәге славян халыкларын гынамы? Мәсәлән, Югославиядә яшәүчеләрнең күпчелеге — славяннар. Югославия бүген таркала бара. Ике славян халкы — серблар һәм хорватлар бер-берсенең каннарын коялар. «Бердәм, дус» халыклар шулай үзара сугышып торырга тиешләр микәнни? Төрки халыклар берләшкән очракта, ничек, ни рәвешле һәм нинди шартларда берләшерләр икән? «Уртак алфавит»ка нигезләнгән тел-язу берләшмәсе булырмы ул, әллә территорияләр берләшмәсе булырмы?

Батулланың «теле, дине, тарихы бер булган төрки халыклар» дигән сүзләре дә сорау артыннан сорау тудыра. Алыйк дин мәсьәләсен. Төрки халыкларның күпчелеге ислам динен тота. Ләкин төркиләр арасында башка дингә табынучылар да җитәрлек. Татарның үзендә генә дә христиан динендәге керәшеннәр бар. Төрки телле чуашлар, якутлар, гагаузлар шулай ук христиан динендә. Төрки тувалар буддизм диненә, карайлар (караимнар) иудаизм (яһүд) диненә табыналар.

Тел, тарих мәсьәләсендә төрки халыкларда, гомумән,

бернинди «бер» булу юк. Бүгенге көндә 25 ләп мөстәкыйль төрки тел исәпләнә. Тел ягыннан төркиләр, башлыча, ике зур төркемгә — кыпчак телләләр һәм угыз телләләр төркеменә бүленәләр. Төрек, төркмән, әзәрбайҗаннар угыз телләләр төркеменә карыйлар. Кыпчак төркемендәге татар, үзбәк, казах... телләре угыз телләрдән шактый аерыла. Төркиләр тарихына хәтта кагылып торасы да юк. Һәр халыкның — үз тарихы, үз язмышы.

Төрки халыклар элекке СССР территориясендә генә түгел, башка илләрдә дә яшиләр. Кытайда 5 миллион чамасы. Монголиядә 100 мең чамасы, Иранда 8 миллион чамасы, Әфганстанда 1 миллион 600 мең, Гыйракта 200 мең, Сириядә 40 мең төрки бар. Югославиядә, Болгариядә, Румыниядә, Польшада, Германиядә, Израильдә, Финляндиядә шулай ук күп кенә төркиләр яши.

Менә шушы таралган, таркалган чуар халыкларны берләштермәкче булабызмы инде без? Хәлебездән килер микән? Чыңгыз хан империясеннән дә көчлерәк империя төзи алсак кына инде...

Интервьюда Батулла Н.Фәттахның «Төркиягә йөз бала» («Т.Я.», 5.12.1991) мәкаләсенә дә кагылып уза. «Безне, ничә еллар инде, махсус рәвештә, пантюркизм дигән бүкәй ясап, гел куркытып килделәр. Андыйлар әле бүген дә бетмәгән...» ди Батулла. Шул ук абзацта: «Тар милләтчелек белән халыкны үстереп тә, саклап та булмый», дигән сүзләр дә бар.

Шулай итеп, без — пантюркизм дигән бүкәй белән куркытучылар, тар милләтчеләр, безне «уртак алфавит» белән сөендерүчеләр исә — «киң милләтчеләр» һәм халыкны үстерүчеләр, саклаучылар булып чыга.

Беренчедән, «пантюркизм» дигәндә Батулла, күрәсең, Н.Фәттахның «гегемонизм» сүзен күз алдында тота. Ләкин «пантюркизм» белән «гегемонизм» — икесе нәрсә. Куркыту өчен «пантюркизм»ны элегрәк бик оста файдаландылар. Монысы — дөрес. Әле бүген дә бетеп җитмәгән «андыйлар»га Н.Фәттахның бернинди катнашы юк. Киресенчә, «пантюркизм», «тар милләтче» кебек сүзләрне «андыйлар» еш кына минем үземә карата кулландылар.

Икенчедән, пантюркизм, кайберәүләр исәпләгәнчә, куркыту өчен уйлап табылган «бүкәй» түгел. Заманында пангерманизм, панславизм дигән идеологияләр булган кебек, пантюркизм да булган. Әйтик, пангерманизм тарафдарлары герман телләрендә сөйләшүче барлык халыкларны берләштерү һәм бөек Германия төзү турында

хыялланган булсалар, пантюркистлар да барлык төрки халыкларны берләштерү һәм бөек Төркия төзү турында хыялланганнар. Тарихтан билгеле булганча, пангерманизм, панславизм идеологларының хыяллары күпмедер дәрәҗәдә тормышка да ашты. Германия фашистлары 1930—1940 елларда герман һ.б. телле күршеләрен басып алып, Бөек Рейх (империя) төзү бәхетенә ирештеләр. Ләкин мондый бәхет озакка бармады. 1945 елда тар-мар ителгән Германия хәрабәләрендә бөек Совет империясе барлыкка килде. Сугыштан соңгы елларда барлык славян халыкларын бергә җыю һәм бөек рус халкы тирәсенә туплау турында коммунистлар пропагандасы бернинди тартынусыз язып һәм сөйләп торды. Панславизм, марксизм-ленинизм идеяләренә нигезләнгән Совет империясе дә, белүебезчә, озак яши алмады.

Госманлы төрекләр дәүләте беренче бөтендөнья сугышы чорында ук таркалды. Шунлыктан пантюркистлар үзләренең идеяләрен тормышка ашыра алмый калдылар. Кайбер төрки халыкларның бәйсезлеккә ирешүе һәм Төркиянең экономик үсеш юлына басуы тәэсирендә ниндидер төрек даирәләрендә элекке хыяллар, күрәсең, яңадан баш калкыта.

Батулла яратып кулланган якынаю, берләшү, уртак тел, уртак алфавит — боларның берсе дә безнең өчен ят һәм яңа түгел. Боларның барысы да совет пропагандасы арсеналыннан алынган. Ләкин төркиләрнең, шул исәптән татар халкының теленә, язуына, киләчәк язмышына кагылышлы рәвештә кулланганда, бу төшенчәләр «бүкәй» пантюркизмны түгел, реаль пантюркизмны аңлата. Дуслык, туганлык, бердәмлек кебек ягымлы, ятышлы сүзләр артында без татыган «изм»нар шәйләнә башлый.

Әлифба тирәсендә бүген шикле сәүдә бара. Төреккә нигезләнгән татар алфавитын башта үзебездә эшләп карадылар. Академия төзелгәч, әнә, Төркиядән алып кайтканнар. Хәреф үзгәртү мәсьәләсе кузгатылгач кына да төрекчә өч проект игълан ителде. Дүртенчесен игълан итеп тормаганнар — бер җыелышта ул кире кагылган. Татар матбугатында татар теленең, татар язуының миллилегенә, бәйсезлегенә каршы ачыктан-ачык һөҗүм бара. Төрек теле белгече Р.Мөхәммәтдиновның татар язуы мәсьәләсендә кирәгеннән артык активлык күрсәтүе дә сагаерга мәҗбүр итә.

30 мартта, университетның 1 нче аудиториясендәге

җыелышта Батулла, трибунага чыгып: «Рус табаны астында булуга караганда, төрек табаны астында булу артыграк»,— дигән сүз әйтте. Батулла кем табаны астында булырга тели, анысы аның үз эше. Ләкин 440 ел буена зарыгып көткән һәм әле булса килеп җитмәгән азатлык, бәйсезлек безгә бер табан астыннан чыгып икенче табан астына керү өчен кирәкми. «Безнең беркем табаны астында буласыбыз килми!» диде Римзил Вәлиев шул ук җыелышта, күпчелек фикерен белдереп.

Гарәпчәдән латин графикасына күчкән вакытта татар делегациясе төрек белән дә, башкалар белән дә тигез хокуклы партнер булып сөйләшкән. Ул чакта һәрбер халык үз теленә ярашлы үз әлифбасын кабул иткән. Татарның татарлар тарафыннан иҗат ителгән яңалифе бүгенге татар теле үзенчәлекләренә тулысынча җавап бирә. Яңалифне яңадан торгызу — ул безнең үз мирасыбызга карата хөрмәтебезне күрсәтәчәк һәм шул ук вакытта тайпылышсыз рәвештә милли бәйсезлеккә, мөстәкыйльлеккә омтылышыбызны да чагылдырачак.

Бәйсезлеккә омтылган өчен генә без, билгеле, дуслыктан, туганлыктан, аралашудан баш тартырга җыенмыйбыз. Без бары тигезлек, тулы тигезлек саклануын гына, үзара мөнәсәбәтләрдә һәр ике якның бер-берсен хөрмәт итүен генә телибез. Төркия университетларының безгә тел-язу кагыйдәләре, төрле проектлар, күрсәтмәләр әзерләп ятарга хаклары булмаган кебек, Төркиягә барып чыккан теләсә кемнең татар исеменнән ниндидер кәгазьләргә кул куеп йөрергә дә хакы юк. Татар теле, татар язуы мәсьәләләре Татарстанда гына һәм парламент дәрәҗәсендә генә хәл ителә ала.

Иң ахырда Батулланың тагын бер җөмләсенә тукталасым килә. «Әгәр без уртак бер алфавитка күчмибез икән, гомумән, күчеп мәшәкатьләнүнең кирәге юк»,— ди Батулла. Нәрсә бу? Ультиматуммы, әллә соң... тирәнгә яшерелгән җеп очымы?

*1992*

## ШАГЫЙРЬНЕ МЫСКЫЛ ИТКӘННӘР

«Хөрмәт» дип аталган сатирик хикәясендә («Ш.К.», 25.10.1996, 6 бит) Фәнзаман Баттал Шарль Шәркәйнең тетмәсен теткән. Шарль Шәркәйнең кемлеге соңга таба беленер, хәзергә без аны хикәя авторы тасвирлаганча күз алдына китерергә тырышып карыйк.

Шарль Шәркәй бала вакытында ук кәнфит ярата, җырлар уйлап таба. Үсә төшкәч бу Казанга килә, вузга керә, әнисе турында, комсомол, партия турында шигырьләр яза. Яшь шагыйрь аеруча әнисен ярата. «Әнисе турында егермеләп җыр язган өчен хатын-кызлар советының премиясен алырга да өлгермәде, комсомол премиясенә лаек дип таптылар»— ди Ф.Баттал Ш.Шәркәй турында. Үзенең иҗат, юлында адым саен һәртөрле җүнсезлекләр эшләгән яшь шагыйрь, хикәя авторы язганча, «бер гәҗит редакциясендә «пачутлы» вазифага да хуҗа була», якында гына фатир ала һәм, иң әшәкесе шул — яраткан әнисе үлем түшәгендә ятканда Казанда торып кала. «Җеназага кайтып җитмәде»— ди Ф.Баттал. Ш.Шәркәйнең иң зур гаебе, бәлки, ул гына да түгелдер әле. Беләсезме, ел саен ул «Тукай премиясе даулап йөри», «Кремль һәм Минкаб тирәсендә бутала» икән. Аннан соң әле ул «КПСС урынына калган кодрәтле түрәне» мактап шигырь дә язган, шигырь, имеш, түрәнең үзенә дә ошаган икән.

Шарль Шәркәйнең (яисә Шәрхемулланың) этлекләре, әшәкелекләре, саный китсәң, тавык чүпләп бетерерлек түгел. Ф.Баттал язганча, ул «үзеннән түбәндәрәк утыручылар белән офицер итеге шыгырдаткандагы тавыш белән иренеп кенә сөйләшергә» өйрәнгән, үзләре авылына кайткач, «монысы реликвия булыр дип», бабасыннан калган «шкаф хәтле чаңлы сәгатьне» Казанга алып киткән. Дөрес, шулай да әнисенә «япунский электронный сәгать» калдырган икән. Аннан соң ул бәдбәхет шагыйрьнең җыруларын әледән-әле радиодан тапшыралар икән. Җитмәсә, аның әле мыегы да бар, имеш!

Сез, бәлки, әйтерсез, кая соң монда сатира? диярсез. Шулайрак шул, чыш-пыш булып чыккан Ф.Батталның «сатирик хикәясе»— «сатира» дисәң сатира түгел, «хикәя» дисәң, хикәя түгел. Ни генә булмасын, Җинаять кодексында: әниләр турында егермеләп җыр язарга, Кремль һәм Минкаб тирәсендә буталырга, мыек үстерергә ярамый дигән сүзләр юк шикелле.

Нәрсә соң бу шулай да? Минемчә бу чыш-пыш кына түгел, бу күрәләтә мыскыл. Менә ничек итеп көлә Ф.Баттал Шарль Шәркәй дип атаган шагыйренең бер шигыреннән.

Малай чагында ук Ш.Шәркәй үзенең әнисенә багышлап шундый җыр чыгарган, имеш:

Бакчабызда араладым
Кәбестә araлaрын.
Кәбестә араларыннан
Таптың син балаларың...

«Җырның беренче такмагын укыгач, әнкәсе бот чабып көлде»— ди Ф.Баттал. Әлеге шигырен Ш.Шәркәй «район газҗитенә» алып бара. Анда бер абзый әйтә: «Кәбестә арасыннан чыкмый бит ул бала... Әниеңнән сора каян чыкканын (!— *Н.Ф.*) ...Балаларны коедан алалар бездә»,— ди.

Малай, сүз тыңлап, шигырен болай дип үзгәртә:

Коелардан су алганда,
Ябыштым чиләгеңә.
Авыр булгандыр, беләмен,
И, әнкәй, беләгеңә.

Бу юлларны укыгач, редакциядәге бер апа: «Коедан алмыйлар баланы... Ләкләк дигән кош китереп бирә сабыйларны»,— ди. Яшь шагыйрь тагын үзгәртә шигырен һәм иң соңгы вариантта бу болай була:

Сиңа безне алып килгән
Озын муенлы ләкләк.
Картуф ашаттың чиләкләп,
Һич йөрмәдең эләкләп.

Ф.Батталның шушы шигырьгә кагылышлы сатирасыннан тагын бер өзек белән танышыйк:

«Шәрхемулла... хат саен әнкәсенә бер шигырь юллады:

Каз-үрдәкләр вак-вак атлап кайта
Су буеннан, әнкәй, күрәмсең?
Авылыма очып кайтыр булам,
Бик сагындым казлар өмәсен...
Унбиш казың унбиш шатлык булды,
Унбиш кайгың булды кайчакта...

Хәзер инде аңлашылгандыр атаклы сатирикның кайсы шагыйрьдән һәм аның кайсы шигыреннән көлгәнлеге. Әлегә без исемен атамаган шагыйрьнең «Әнкәй» дигән шигырендә:

Әнкәй безне Сөннән алып кайткан,
Сөн суында юган иң элек...

Без әнкәйнең биш шатлыгы булдык,
Биш кайгысы булдык кайчакта,—

дигән илаһи сүзләр бар. Әниләр турында исәпсез-хи-

сапсыз шигырьләр язылган. Аларның күбесе бер-берсенә охшаш, шунлыктан ул шигырьләрнең кайсы кемнеке икәнлеге бик үк истә дә калмый. Ләкин Роберт Миңнуллинның беренче мәхәббәт кебек тәэсирле, тирән фикерле сүзләрен сез беркемнеке белән бутамаячаксыз.

Бездә чыннан да баланы елгадан, чишмәдән яки коедан алып кайталар дигән ышану яши. Бу безнең рухи байлыгыбызның бер өлеше. Бу безнең ун мең, йөз мең, хәтта миллион еллар артында калган ата-бабаларыбызның дөньяны танып-белүдәге фәлсәфи карашларының бер чагылышы. Ф.Баттал, шушы сабыйларча карашны шигъри юлларга күчереп, аны яңарткан һәм әдәби образ рәвешендә үстергән Роберт Миңнуллиннан көлү белән бергә, шул карашның-ышануның үзеннән дә көлә. «Бәттәч, ялган бит бусы! Менә дигән сәвит язучысы булырсың, Алла боерса, болай ук шыттыра белгәч»,— ди ул Ш.Шәркәйнең әнисе сүзләре белән.

Нәрсә әйтәсең мондый тәнкыйтькә карата? Берни әйтеп булмый. Әйтәсе дә килми. Шулай да Ф.Батталның икенче бер хикәясендә Тукай һәм аның «Шүрәле»се тәнкыйтьләнсә, әллә ни гаҗәпләнмәссез дип уйлыйм.

«Шәһри Казан»ның әлеге санында (25.10.1996, 3—4 битләр) Нәҗибә Сафинаның «Буылганның буыны тотмый» дигән «публицист сүзе» дә басылган. Монда мин аңа да тукталырга һәм, озын булса да, аның сүзләрен дә күчереп китәргә мәҗбүрмен.

«Әйе, кайберәүләргә Хәтер көнен рәсмиләштерсәләр ни дә, юк ни,— дип яза Н.Сафина.— Алар моңа битараф. Ә менә танылган шагыйрь, Дәүләт Советының мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясе рәисе, Татарстан балалар фонды президиумы әгъзасы, «Сабантуй» газетасының шеф-мөхәррире, Муса Җәлил бүләге лауреаты, халыкара Андерсен бүләге дипломанты Роберт Миңнуллин Хәтер көнен рәсмиләштерүгә каршы тавыш бирде.

...Башкортстанда чыга торган «Өмет» газетасына биргән интервьюсында әлеге героебыз, ягъни Р.Миңнуллин, үзенең көрәштәшләре — Ринат Мөхәммәдиев, Разил Вәлиев, Фәндәс Сафиуллин кебек депутатларны хезмәттәшләрем дип атаган. Ә күпләргә билгеле бу шәхесләр өчесе дә Хәтер көнен яклап тавыш биргән».

Н.Сафина сүзләреннән аңлашылганча, Р.Миңнуллинның җинаяте аның Хәтер көнен рәсмиләштерүгә каршы

тавыш бирүендә генә түгел, бәлки, үз көрәштәшләрен «хезмәттәшләрем» дип атавында да чагыла икән. Мондый сәер шелтә белән килештек тә ди. Ләкин мәкалә авторының үзеннән өлкәнрәк һәм абруйлырак шагыйрьне тора салып дигәндәй «әлеге героебыз» дип түбәнсетергә тырышуы белән һич тә килешәсе килми. Бу миңа бер мәгънәсезлек, әдәпсезлек булып тоела. Н.Сафина мәкаләсенең югарыда китерелгән өзегендә шуңа охшаган мәгънәсезлекләр шактый нык күзгә ташлана. Мәсәлән, «Өмет» газетасындагы ниндидер интервью турындагы хәбәр монда бөтенләй урынсызга кыстырылган сыман. «Өмет» газетасында Р.Миңнуллинның интервьюсы булганмы, булса, анда ниндирәк сүзләр әйтелгән — без моны белмибез. Иң мөһиме шул, үзенең интервьюсында Р.Миңнуллин кайсы хезмәттәшләрен телгә алды икән дә, аларны ниндирәк тәртиптә санап китте икән? Н.Сафина версиясендә нишләптер Туфан Миңнуллин онытылып (?) калдырылган. Ул да Р.Миңнуллинның «көрәштәше» һәм «хезмәттәше» түгелмени?!

Монысы, беренчедән. Икенчедән, «күпләргә билгеле бу шәхесләр» арасыннан Н.Сафина Ринат Мөхәммәдиевне беренче урынга куйган. Минем белүемчә, депутат Р.Мөхәммәдиевнең халык аңындагы даны-дәрәҗәсе, яңача әйткәндә, рейтингы, мәкалә авторы икенче, өченче урында санап киткән депутатларныкыннан артыграк түгел. 1996 елның 15 октябрендә Казанда, Ирек мәйданында, Хәтер көне митингысында, мәсәлән, Ринат Мөхәммәдиевне, әллә ялгышып, әллә ялгышмыйча, «оятсыз» дип атадылар.

«Шәһри Казан»ның 26 октябрь саны, 2 бит, «Татар барда — хәтер бар» дигән гомуми баш астында, «Татарстан халык депутаты, шагыйрь Роберт Миңнуллинга һәм тагын кайберәүләргә «Шәһри Казан» укучыларының рәнҗүле хатлары» дигән аңлатма белән, тулысынча Роберт Миңнуллинны тәнкыйть итүгә багышланган. Рәнҗетелгән укучыларның барысы да Хәтер көнен рәсмиләштерүне яклыйлар һәм халык дошманы Р.Миңнуллинны төрлечә акылга утыртырга тырышалар. Хатларның һәркайсында бер үк җөмлә төзелеше, бер үк фикер сөрелеше ярылып ята — барысын да бер үк кул белән язганнар дип торырсың!

Казанда Хәтер көнен уздыру, билгеле булганча, дини, милли, иҗтимагый оешмалар тырышлыгы белән, моннан биш-алты еллар элек башланып китте. Быел Татарстан парламентының кайбер татар депутатлары шушы

көнне рәсмиләштерү мәсьәләсен кузгаттылар. Тавыш бирүдә депутатлар икегә бүленде — татарларның күпчелеге яклады, руслар һәм кайбер татарлар, шул исәптән Р.Миңнуллин, каршы тавыш бирде. Ни өчен каршы булуын аңлатып Р.Миңнуллин язып та чыкты. Аның аңлатмасында йомшак, урынсыз акланулар бар. Шулай да аның позициясе дөрес һәм мин аны тулысынча яклыйм. Шул ук вакытта минем яклап тавыш бирүчеләрне ниндидер гөнаһ эштә гаепләргә дә исәбем юк — бу хакта да ачык итеп әйтергә кирәк. Минемчә, яклап тавыш биргән депутатлар кайбер әһәмиятле нәрсәләрне уйлап җиткермәгәннәр.

Әлеге закон проекты кабул ителгән очракта, Татарстан гражданнары, нинди милләттән булуларына һәм нинди дин тотуларына карамастан, Хәтер көнен билгеләп үтәргә тиеш булырлар иде. Ләкин Хәтер көне ул безнең көн, бары безнең генә көн! 1552 елда җиңелгән татар халкының Кайгы көне. Закон нигезендә мәҗбүриләп без, җиңелүчеләр, үз кайгыбызны җиңүчеләргә дә тагарга тырышабыз түгелме соң? Телисезме, теләмисезме, бу бары шулай гына була ала. XVI гасырдагы канлы вакыйгалардан соң бик күп вакытлар үтсә дә, русның үз җиңүен оныткан да юк, безне үзенә тиң дип таныганы да юк. Мондый шартларда, мондый атмосферада Татарстан халкының татардан кала яртысын Хәтер көнен билгеләп үтәргә ышандыру мөмкин булмаячак. Бу инде көн кебек ачык, монда хәтта сүз озайтып торуның кирәге дә юк. Күрәсең, шуны истә тотып, «рәнҗетелгән укучылар» Хәтер көнен рәсмиләштерүгә каршы тавыш биргән рус депутатларына да, битараф татар депутатларына да тел тидермиләр. Алар бары бер генә кешене дөмбәслиләр. Татарның 1996 елгы хәле өчен дә, 1552 елгы хәле өчен дә бары тик ул гаепле диярсең!

Тагын шунысын да әйтергә кирәк, алай-болай Хәтер көне рәсмиләштерелә калса, бу безнең милли хокукларны киңәйтүгә берни өстәмәс иде. Бу бары үзара каршылыкны арттыруга гына хезмәт итәр иде. Хәтер көнен уздыруга рәсми структуралар аяк чалмыйлар шикелле (һич югы, Казанда, Татарстанда дип әйтик). Димәк, кайгы көненә әзерлек һәм аны тиешенчә башкару эшләрен гамәлдәгечә, әлегечә, дини, милли, иҗтимагый оешмалар җитәкләсә, иң дөресе шул булыр иде.

«Шәһри Казан» битләрендә уйналган әлеге спектакльдә Хәтер көне һәм милли мәнфәгатьләр турында сүз күп булды. Шулай да төп максат тирәндәрәк ята

сыман. Бер депутатны, танылган шагыйрьне, аерып алып тукмау белән бергә, татар җәмәгатьчелегендә ыгы-зыгы, тотрыксызлык атмосферасы тудырырга тырышу да юк түгел иде шикелле. Шул ук вакытта болганчык суда балык тотарга яратучылар, башкаларның башына басып, тагын да югарырак үрләргә хыялланмыйлар микән дигән уй да килә.

*1996*

## ЭЧТӘЛЕК

*Ә.Нәҗипова.* Олы әдип «кечү»е . . . 7
Кичү. *Роман* . . . 11
Кырык дуртнең май аенда. *Повесть* . . . 288

**Балалар өчен хикәяләр**

Әттә . . . 349
Сарапулдан кайтканда . . . 355
Тегермәндә . . . 358
Безнең бабай . . . 378
Балыкчылар . . . 381
Велосипедлы Мөнир . . . 383
Ирек, Алмас һәм Җәлил . . . 384
Өч туган . . . 386

**Пьеса**

Энҗеле үрдәк . . . 398

**Сатира-юмор**

Тәнкыйтьче . . . 424
Тамак шешә . . . 426
Бала хәсрәте . . . 429
Бухгалтер мәхәббәте . . . 431
Шифалы дару . . . 434
Яшь чакларда . . . 434
Чүпрә . . . 438

**Публицистика**

Быел тагын «Казан сөлгесе» . . . 441
Төркиягә йөз бала . . . 445
Берләшәбезмени, Батулла . . . 451
Шагыйрьне мыскыл иткәннәр . . . 456

Литературно-художественное издание

Фаттахов Нурихан Садрильманович

*(Нурихан Фаттах)*

Избранные произведения
в пяти томах

Том 4

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.П.Клипова*
Корректоры *Р.Н.Кыямова*

Нәшриятка 04184 нчы номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 5.09.2002.
Форматы 84×108 $^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 24,36+форз.0,21. Шартлы буяу-оттиск 24,67.
Нәшер-хисап табагы 25,49+форз.0,36.
Тиражы 3 000 данә. Заказ Б-456.

Татарстан китап нәшрияты. 420111, Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111, Казань, ул.Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066, Казан, Декабристлар ур., 2.